Мөсәгыйт
ХӘБИБУЛЛИН

# Айбиби

**Тарихи роман**

Казан
Татарстан китап нәшрияты
2004

УДК 820/89(470)
ББК 84(2Рос=Тат)–4
Х 12

**Хәбибуллин Мөсәгыйт**

Айбиби: Тарихи роман. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2004.— 302 б.

Төрки халкының дүрт-биш буынын тәшкил иткән хазар-болгарлар, нигездә, Идел елгасының тамагында көн күргәннәр. VIII–X гасырларда держава дәрәҗәсенә күтәрелгән, Идел, Терек, Сулак, Бузан елгалары буйларында яшәгән, Таман ярымутравында гомер иткән халыклардан ясак җыйган, Киев Русе, Идел буе Болгар дәүләтләренә вассал рәвештә бәйле булган, каханат X йөзләрдә сүтелә-таркала башлый.

X йөздә Хазарстан пайтәхетенә яһүд раввaларына бәйле Йосыф кахан утыра. Күпсанлы хатыннар тоткан кахан Идел буе Мөхәммәд ханның икенче кызын сараена тарттыра. Айбибинең мәхәббәттә күзе яңа гына ачылып килә. Аны кахан раввалары Хазарстанга — дәүләт башында утырган Йосыф каханга алып китәләр. Айбиби Йосыф каханга беренче күрүдә үк гашыйк була...

ISBN 5-298-01360-0
© Татарстан китап нәшрияты, 2004

Бу хакыйкый тарихи хәлләргә
йөз тотып язылган әсәремне инде
күптән мәрхүм булган әнием
*Мөнәвәрәгә* һәм әтием *Мөдәррис*
истәлегенә багышлыйм.
*Автор*

# Кереш сүз

Хазарстан җире комлы тугайлыклардан, куе үләнле үзәнлекләрдән торган даладан нык кына аерылган. Һәм, әлбәттә, утрак көн күргән халыкларның яшәү рәвешләре дә. Хазарстан җиреннән үтеп, Каспий диңгезенә койган Җаек, Идел, Терек, Сулак кебек елгалар, борынгы заманда Хазар дип аталган диңгезгә җитәрәк, хәтфәдәй яшел үләнле меңнәрчә төрле чәчкәләр белән бизәлгән болыннар, таллыклар, әрәмәләр хасил итә-итә, елгачыкларга тармакланып, Каспий диңгезенә бихисап күләмдә су китергән; карлы сулы язгы ташулар китүгә, камыш-таллыкларда кош-кортлар бәбкә-бала чыгарган, ә болынтугайлар куе канлы көтүлекләргә әверелгән. Идел тамагында һәм Терек елга буйларында даннары ераkларга таралган безнең борынгы бабаларыбыз көн күргәннәр. Елга-инеш буйларындагы ташу белән ашланган җирләрдә карбыз-кавын, татлы виноград үстергәннәр, сөрүле басуларда иген иккәннәр, хәтта дөге җитештергәннәр, күрше-тирә халыклар белән генә түгел, Византия, Иран, Кытай кебек илләр белән сәүдә иткәннәр.

X гасыр башларында Хазарстан иле пайтәхетендә утырган Йосыф кахан үзенең кан кардәше Испания хәлифе Габдрахман III сараенда хезмәт иткән Хасдай ибн Шафрутка язган хатында иле хакында мондый юллар бар: «...минем илемдәге муллык исәпсез-хисапсыздыр, бездә бик күп басулар, болыннар — алар барысы да диңгезгә аккан елгалардан сугарыла, һәм елгалар вә елгачыклар безгә барысын да мул итеп бирә — балыгын да, кош-кортын да, игенен дә, җимешен дә...»

Шушындый тарихи язма фактлар булуга карамастан, Русиянең исемле академигы Б.А.Рыбаков Хазарстан илен Калмык җирләрендәге комлы далага утыртa. Ул гынамы, безнең бабаларыбыз хазарларны ярымкүчмә халык булган дип язарга кыя. Ә менә Хазарстан җирләрен аркылыга-буйга йөреп, археологик тикшерүләр уздырган Л.Н.Гумилев үзенең «Открытие Хазарии» дигән хезмәтендә Хазарстан җирләрендә яшәгән халыкларның өч эпохага караган һәйкәлләрен, көнкүреш әйберләрен таба һәм мондый нәтиҗәгә килә: «...тәүге башта сарманнар культурасы, безнең эрада — синхрон төрки-хазар һәм XIII–XIV йөзләрдә татар культурасы».

Бәхәссез, бу төбәкләрдә көн күргән халыклар илнең ландшафтына җайлашып гомер иткәннәр. Безнең борынгы бабаларыбыз болгар-хазарлар да туган илләренең ландшафтына карап яшәгәннәр.

Галимнәр раславынча, безнең эраның икенче йөзендә Каспий диңгезе 32 метрга күтәрелә. Бу инде туфан калку белән бердер. Шушы дәверләрдә елгалардан диңгезгә шул чиккә җитеп су килә ки, Идел елгасы яңа эз сала, диңгезгә җитәрәк күпсанлы тармакларга аерыла, ә уртада зур гына мәйданлы утрау хасил була. X йөздә туфан кебек су басу янә кабатлана. Хазарларның башкаласы Самандарны су юа, чөнки бу кала VI гасырда Иран шаһиншаһы Хәсрәү инженерлары тарафыннан саманнан күтәрелгән була. Кала юыла, ә халык корырак җирләргә күчеп китәргә мәҗбүр ителә. Бу каланы гарәп мосафирлары «Саман капка» дип атаганнар. Хазар иле каханы әүвәл шул калада утырган Самандарны су юдыргач, башкаласын Идел тамагында хасил булган утрауга күчерә. Ләкин инде ул бу башкаласын, нигездә, сараен, янган аксыл-сары кирпечтән күтәртә. Дөнья сәяхәтчеләре язмаларында мондый юлларны укырга була: «...гөлбакчаларда хозурланып, тәмле шәраб эчеп ял иттек тә, Болгарга таба кузгалдык...»

Әйтергә кирәк, хазарлар чорында, бүгенге доллар кебек, фарсыларның көмеш дирһәмнәре йөрештә була, гәрчә Хазар каханы үз акчасын суктырса да. Шул ук вакытта үз сәүдәгәрләре ярдәме белән кахан Самарада, Болгарда зур кәрвансарайлар салдыра, хәтта борынгы Казан каласын да читләтеп үтми, үз кулына алып, бу шәһәрне зур базаркалага әверелдерә. Скандинавия сагаларында Бөек Пермь дип җырланган төбәктә дә каханның кәрван-сарае була. Тик менә тарихи язмаларга кереп калган базаркалалардагы күн капчыкта йөрткән алтын-көмешләре бу калаларның каханга йөз тотулары турында сөйләсә дә, кая соң шул Хазарстан иленең тарихы?.. Ил башында китаплы яһүд раввалары утырган ич! Хәтта Киевтә дә инде мөселманлашып киткән яһүд сәүдәгәрләре үзләренең колонияләрен булдырганнар. Моны Биссарабия дигән Киев каласындагы мәйданда күпләп гарәп дирһәмнәре һәм башка әйберләр табылуы да раслый. Ләкин XI гасырда аякланып киткән Русия тарихчылары, сәясәтне күздә тотып, «Араб мәйданы»н «Биссарабия мәйданы» дип үзгәртәләр. Шушы җөмләне язгач, тарихи хәлләргә кагылган галим Лев Николаевичның Хак Тәгаләгә йөз тоткан сүзләрен китерәсем килә: «...как ни странно, некоторые

события, пережитые нами в XX веке, находят себе объяснение в далекой истории, где заблуждения переплетаются с истиной, но истина их превозмогает».

Русия галимнәре «Историю надо защищать, а не переписывать» дигән фикер әйтә башладылар. Ә бит телиләрме моны Русия тарихчылары, теләмиләрме, тарихларын барыбер үзгәртергә тиеш булачаклар, чөнки ялган тарих ялган белгечләр хәзерли.

713 елда хәлифәтнең сәргаскәре Маслама Хазарстанга яу килә һәм каты сугышлардан соң Тимер капка (бүгенге Дербент) шәһәр-кальгасын алуга ирешә, ул гынамы, илнең эчкәре өлкәләренә үтеп керә. Кахан ислам динен кабул итәргә мәҗбүр була. Вәләкин яһүд сәүдәгәрләре тырышлыгы белән кахан ислам диненнән ваз кичә. Шул хәлдән файдаланып, ил башында утырган Булан кахан яһүдләр динен янә яңартып җибәрә һәм төрле илләргә таралган раввindependent сараена чакырта. Әмма хәлифәт бу хәлне онытмый, 732 елда Хазарстанга янә яу оештыра. Яу барып чыкмый, Хазарстан илендә айлар буена коеп яңгырлар ява. Бу хакта «Хазары» хезмәтендә Русия тарихчысы С.А.Плетнева болай дип яза: «Во главе войска встал, как девять лет назад, сын кагана Барджиль. Армянские источники сообщают, страной в то время правила мать кагана Парсбит, поскольку прежний каган неожиданно умер».

Әнә шулай башланып киткән канлы сугышлар хәлифәт белән каган арасында елларга сузыла. X йөз башларында ил башына Йосыф кахан килә. Ләкин ил белән яһүд раввалары идарә итәләр, кахан исә курчак идарәче урынына гына тәхеттә утыра. Нәкъ менә шул Йосыф кахан Испаниядә булган кан кардәше белән хатлар алыша да инде. Хазарстан һәм аның халкы, иле-җире, державага әверелеп барган чорында буйсынган яисә вассал рәвешендә килешеп яшәүгә йөз тоткан ил-халыклар искә алына. Ни гаҗәп, Хазарстан турында шул чорлардагы хатлар сакланып калган, кайбер археологлар төрле әйберләр казып тапканнар, ә менә хазарлар үз тарихларын язмаганнар. Әйтик, грекларның, әрмәннәрнең, фарсыларның, гарәпләрнең, хәтта соңгарыбрак булса да язылган русларның тарихлары бар, Хазарстанның юк. Шуңа карамастан Русия тарихчылары, үз тарихларын язганда, безнең бабаларыбызны читләтеп үтә алмаганнар. Күренекле галимнәр М.И.Артамонов, С.А.Плетнева һәм башкалар белән бергә бу эшкә мөхтәрәм галим Лев Николаевич Гумилев керешә. Соңгы елларда хөрмәткә ия галим үзенең хезмәтен борынгы карталар һәм язмалар аша гына түгел, шәхсән үзе оештырган археологик казылмалар аша да дәлилли. Әйтик, б.э.к. II йөзләрдә яшәгән греклы Эростофин дөнья картасын төзи һәм борынгы хазар-татарның бабалары булган скифларның (сөннәрнең) кай тарафларда көн күрүләрен дә күрсәтә. Шул гасырларда, әмма чак кына соңрак Мисырда патша булып утырган Птоломей үз картасында скифларны ике тармакка бүлә — сарматларга һәм скифларга, ә бүгенге Киев төбәкләрен «Германия» дип билгели.

Тарихта билгеле булганы шулдыр: Бөек Төркиләр каханаты 550–580 елларда көнчыгыш һәм көнбатыш төркиләренә бүленә. Бу чорда каханат Дон елгасыннан Кытай стенасына кадәр җирләрне били, Иран, Византия чикләренә барып җитә. Туганнар үзара ызгыша башлыйлар, нәтиҗәдә Ашин (Бүре) һәм Дулу ыруларына бүленәләр. Дулу ыруы көнбатыш җирләрен үз кулына ала.

Ике туган халык үзара ызгышудан соң, Ашин ыруы өстен чыга, Таман ярымутравында, Дон буйларында, Идел елгасының урта һәм түбән төбәкләрендә яшәгән төрки-болгарлар вассал рәвештә, ә беришләре бөтенләй Хазар каханаты канаты астына кертеләләр, шул исәптән Киев каханаты да. Тарихта шунысы билгеле: кайбер Русия галимнәре «черноризец» дип атаган Нестор XI гасырда гына Русия тарихын язарга керешә. Немец галиме Г.Эверес русларны, хазарлардан чыкканнар, дип яза. Күренекле галим Дмитрий Иловайский тирәнгәрәк төшеп багып карый, славяннар төрки-болгарлардан, гуннардан һәм болгарлардан килә, дип язып чыга.

Бәхәссез, бүген руслар дип аталган халыклар да җиһангир полководец Аттила белән Ауропага барганнар, шул исәптән Каспий диңгезе буйларына кайтып, утырып калган хазарлар да. Ә менә «рус» сүзе вә атамасы «викинг» сүзеннән килә, ягъни швед телендә «диңгез буендагы база». «Варяг» сүзе исә, викинг, норманнар сүзе белән тарихка кереп киткәннәрне — «ирекле диңгез пиратлары» дип кенә атарга кирәк. Чөнки варяг эскадралары гасырлар буена Англиягә, Ирландиягә, Франциягә, Испаниягә һ.б. илләргә, һәм шул исәптән Киев каханатына, Идел буе Болгарына, Хазарстанга, Харәземгә, хәтта хәлифәт калаларына яу йөриләр. Тарихчылар «Рыцари удачи» дип атаган пиратларның башында исем-атамалары да моны раслый: «Баш чирәбен ватучы», «Елан», «Яман», «Канлы айбалта», «Капкорсак», «Талаучы», «Чучка», «Җанкойгыч», «Бетле сакал» һ.б. Викинглар бүгенге славян халкыннан бик ерак торган халык. Дөнья халыкларын талап йөрүче викинг-варягларны тарихлары түренә утыртып, үз вакытында Владимир Мономах кенәз зур хата кыла. Лев Николаевич Гумилев раславынча: «...Датский король Эрик III Добрый (1095–1103 елларда) тәхеткә утырырга җыенган Киев кенәзе Святополк каласына килә... Һәм, очрашудан соң, Русия тарихы «Повести временных лет» норман теориясенә йөз белән борыла». «Норманской теории» — легенды, которая «складывалась постепенно и искусственно»,— дип өсти галим. «Повести временных лет»тагы: «Пошел Святослав на хазар. Услышав же, хазары вышли навстречу во главе с каганом и сошлись биться, и в битве одолел Святослав хазар и столицу, и Белую Вежу взял...» — дигән сүзләр тарихи хәл-хакыйкатьтән ерак тора.

Бу дәвердә, ягъни 964–967 елларда, Каспий диңгезе көтмәгәндә 19 метрга күтәрелә. Терек елгасы буйларындагы авыл-калаларны су баса. VI гасырда фарсы шаһиншаһы инженерлары салган Самандар

каласы (каханның беренче башкаласы), гомумән, су астында кала, шул исәптән каханның яңа башкаласы да. Әнә шулай империя дәрәҗәсенә ирешкән каханат Самандар, Итил, Бәхтияр, Актүбә, Шайтан каласы кебек кала-кальгаларын югалта, ягъни бу калалар барысы да су астында калалар йә ташкынлы елгалар тарафыннан юылалар. Кахан сарае эзсез югала, аның нигезен хәтта Гумилев та таба алмый. Халыкның күп өлеше, бигрәк тә болгар-татарлары, Идел буе Болгарына күчеп килә һәм күп кенә бүген дә телгә алынган шәһәр-салаларга һәм авылларга нигез салалар. Дөрес, соңрак күчеп килгән халыкларны «нугайлар» дип язучы тарихчылар да бар, тик бит бу халык шул ук татар-хазарлар! Тарихчылар күз угыннан еректарак калган янә бер мәсьәләне искәреп үтү зарур булыр — Хазарстан каханы яһүд раввалары һәм түрәләре генә яшәгән Аккалада (Айбалдада), ягъни «Итиль» дип Русия тарихына кереп киткән утраудагы шәһәрдә, дөнья тарихчылары бары тик аларны гына «хазарлар» дип атаганнар. Гарәп тарихчылары язганча, Идел елгасының якын тирәсендә һәм Ханбалыкта (бу кала сигез-тугыз километрга сузылган була) — төп шәһәрдә татарлар кардәшләре — төрки болгарлары яшәгән. Ялланып хезмәт иткән мөселман гаярьләре янына каханны һәм аның сараен дүрт мең аерым гаскәри саклаган. Димәк, сарай-кала шактый нык ныгытылган һәм зур булган. Әнә шул сарай-кала читендә, нигездә, татарлар яшәгән, гарәп мосафирлары аларны «хазарлар» дип язсалар да, гади халык «татарлар» дип йөргән. Нәкъ Русиядәге төрле милләт вәкилләрен чит илләрдә «руслар» дип атаган кебек. Тарихчылар «нугайлар» дип язган халыклар да татарлар булалар. Нугай Урдасына кергән халыклар да, Әстерхан татарлары кебек, «татар» телендә сөйләшкәннәр, шул ук Хазарстаннан чыккан төркиләр дә. Әнә шул татар-хазарлар, кала-авылларын су баскач, Җаек, Идел, Сакмар, Ык һ.б. елгалары буйларына күчеп, кала-сала, авыл салып утыралар. Һәм аларны XIII гасырда Алтын Урда берләштерә, төрле төрки диалектларда сөйләшкән туганнарыбызны үз кул астына җыя. Сәнәгати, сәнгати һәм мәдәнияти яктан хазарлардан һич тә калышмаган төрки-болгарлары ханы Илһам күчеп килгән тугандаш татарларга ил-җир бирә. Биләмҗир халкы үзенә бер кала күтәрә һәм ул шәһәрне сәяхәтчеләр Биләр дип атый башлыйлар. Бүгенге Алабуга каласы шул чорларда аякланып китә. Бредәге халык та һич тә күктән төшмәгән, нигездә, Хазарстаннан күчеп килгән халыктыр. Кахан һәм аның раввалары идарәчелегеннән азат ителгән борынгы заманда Хаҗитархан дип аталган (бүген Әстерхан) шәһәр дә кайчандыр без бергә яшәгән Хазарстан халыклары, гәрчә бүген безне Казан татарлары дип атасалар да. Тарихта билгеле: татар-кыпчаклар күтәргән Саксин каласын баскынчы монголлар 1229 елда җимерәләр. Идел буе сәүдә үзәгенә әверелгән шәһәр җир белән тигезләнә, шул исәптән монголларга теше-тырнагы белән каршы торган Илһам хан җитәкләгән Болгар каласы да. Татарлар, Русия тарихчылары язганча, бер дә XIII йөзләрдә бу төбәкләргә кайдандыр күчеп килмәгәннәр, ә йөзләрчә еллар буенча шушы төбәкләрдә көн күргәннәр, Хазарстан кебек куәтле вә көчле, тергә вә аркадашы булмагач, әлбәттә инде Болгар ханы монголларга берүзе генә каршы тора алмаган. Иң гаҗәбе, Болгарга 1236 елда монголлар яу килгәндә, алар арасында татар-хазарлар да була, шул исәптән кайчандыр изге Кирилл чукындырган төрки-казаклары да. Бу халык 1223 елда аркадаш йөзендә болгарлар туздырганнан соң калган 3 мең сугышчысын, шул исәптән орышта бер күзен югалткан Сүбәдәй баһадирны да Идел аша чыгаралар. Тарихчылар аларны «бортниклар» һәм «гребенские казаки» дип язалар. Рязань халкын исә гади хазарлар «сөннәтле казаклар» дип йөргәннәр. Чөнки раввалар бу халыкны сөннәткә тарттырганнар, ә кахан сөннәтле халыкларга зур-зур ташламалар ясаган. Тарихка берьяклы караган Б.А.Рыбаков исә: «...аларны мөселман миссионерлары сөннәткә тартканнар»,— дип яза.

Җаек, Агыйдел, Идел һ.б. елгалар буена Хазарстаннан күчеп утырган татарлар турында Лев Николаевич Гумилев «Открытие Хазарии» китабында болай дип яза: «После возвращения из Европы хунский народ распался на четыре ветви. Первая поселилась на берегах Хуанхэ (Суыксу) в пригорьях Алашаня. Другая осталась на берегах Селенги и Забайкалья. Третья укрылась на склонах Тарбагатая и Джунгарского Алатау. Четвертая отступила на берега Урала и Волги, где смешавшись с уграми, превратилась в гуннов, а позднее в булгар, далее в татар. **Такова история татарского народа**» *(Ассызык авторныкы).*

X йөздә Хазарстан халкын күз угында тотып, Л.Гумилев мондый нәтиҗәгә килә: «На 12 метров поднялся уровень Каспийского моря — до абсолютной отметки минус 20 метров. Дельта частью была залита, а частью превратилась в непроходимые камышовые джунгли. Под водой оказались почти все те земли, на которой располагались хазарские села и нивы... Хазарию постигла судьба легендарной Антлантиды. Народ Хазарии, лишенный Родины, рассеялись в этническом конгламерате Золотой Орды».

Русиянең тарихы саналган «Повести временных лет» елъязмасына һич кенә дә ышанып булмый. «К XII веку Хазария, лишенная иудейской общины, превратилась в маленькое мусульманское ханство со столицей в городе Саксин, в дельте Волги» дип өсти галим. «А Саксин был взят монголами в 1229 году, и остатки убежали на север». Димәк, Болгар ханлыгына. Елъязмада ялган өстенә ялган менеп ята. Әйтик, «Повести временных лет»та мондый юллар бар: «...потомки хазар платили в 1113–1118 годах дань Киеву». «Нет,— дип яза галим Гумилев,— не платили, ибо в 1117 году «придоша Белевежци в Русь», то есть те русские очистили левый берег Дона, в том числе его пойму, сохранив за собой гегемонию в степи между Доном и Карпатами. И кроме того, культурный комплекс Белой Вежи был связан с

черниговским Поднепровьем, а не с Киевым...» Димәк, монда да елъязмачы ялганга барган. Тик менә ни өчен?

Чөнки «Русь не была единой» дип дәвам итә галим. Бу вакытта поляннар белән северяннар үзара ызгыша. Чернигов белән Киев икесе ике дингә йөз тоталар. Ә Киевтәге Киев-Печор монастыре исә 1060–1061 елда гына аякланып китә, ягъни киялеләр гарәп графикасында башланган тарихларын, үз сәясәтләренә җайлап, яңабаштан яза башлыйлар. Елъязманы тәрҗемә итә башлаган монах Никон Тамантарханга кача. Нигә Тамантарханга? Бит анда төрки-болгарлары, ягъни изге Кирилл чукындырган болгарлар. Димәк, Киевтән, гомумән, төрки болгарларны гына түгел, христиан динендәге болгарларны да куганнар. Елъязма дәвам ителми. Бары тик 1113 елда гына Киев-Печор монастырендa утырган монах Нестор елъязманы дәвам итәргә керешә, ягъни тәрҗемә итәргә.

Бит Русия тарихында Хазарстан җитди урын тотса да, Русия тарихчысы Дмитрий Иловайский, нәкъ шуның өчен булса кирәк, елъязмачы Несторны «черноризец» дип атый. Шуңа охшаш сәяси үзгәртүләрне җентекләп тикшергәннән соң, Русиянең исемле галиме Дмитрий Лихачев «Повести временных лет» елъязмасына мондый бәһа-мөһер суга: «...летопись — литература исторического жанра, а не хроника, бесстрашно фиксирующая события, и не история — «поиск истины» или, более современно,— «исследование».

Хөрмәткә ия XX гасыр Русия тарихчысының сүзләреннән соң мин берни дә өсти алмыйм. Кызганыч ки, Русиянең күп кенә тарихчылары «Повести временных лет» елъязмасына әдәби жанр дип түгел, чын тарих дип карадылар, шуңа таянып, йөзләрчә хезмәт яздылар, диссертацияләр якладылар, гуманитар фәннәр докторлары булып киттеләр, иң гаҗәбе, рус халкын гына түгел, Русиядә яшәгән башка милләт вәкилләрен дә шуңа ышандырырга тырыштылар. Бәлкем, бу борынгыдан килгән төрки дөньясының эзен җуйдыру өчен кирәк булгандыр аларга.

Нәүбәттәге «Айбиби» дигән тарихи романым әнә шуларның барысын да искә алып, шактый дәлилле хәлләргә таянып язылды. Һәрхәлдә, тарихыбызда булган хәлләрдән ерак китмәдем, гәрчә әдәби әсәрдә бу чара алшарт итеп куелмаса да. Хазарстан дәүләте төрки-татар-хазарларның бер чылбыр бөҗрасы буларак яшәргә хаклы булса да, бу илнең асыл тарихын читләтебрәк үтәргә тырыштылар. Хак, татар-хазар халкы йөзләрчә еллар руслар белән аралашып, хәтта сугышып, кан коешып яшәү сәбәпле, Русия тарихчылары татар-хазарларны читләтеп үтә алмадылар. Әйтик, исемле тарихчылардан М.И.Артамонов, С.А.Плетнева һ.б., бигрәк тә Л.Н.Гумилев Хазарстан дәүләтенең тарихын безгә калдыру өчен күп тырышты. Бу халыкның тарихын ул, язма чыганаклар аша гына түгел, археологик казылмалар алып барып һәм, табылган материалларга таянып, шактый зур күләмле хезмәт язды. Заманында Америкага күчеп киткән Төркия галиме Мәмәт Сәүдияр үзенең Кырым татарларына багышлаган хезмәтендә хазар-татарлар турында болай ди: «Хазарстан дәүләте, гомумән, төрле халыклардан тукылган беренче федерацияләрдән була. Һәр халык мөстәкыйль рәвештә үз халкы белән идарә итә. Аланнар, Төньяк Кавказда төпләнеп калган гуннар, Дагстан халыклары, бүгенге болгар-татарларның атасы Кубрат хан төзегән дәүләт таркалгач, Тамантархан ярымутравында укмашып калган төрки-болгарлар, Дори халыклары — барысы да өч йөз елга якын Хазарстан дәүләте кул астында гомер итәләр һәм каханат аларда бары тик наместникларын гына тота».

Шушы мәгълүматларга таянып әйтә алабыз: бүген Каспий диңгезе буйларында көн күргән әҗәриләр дә, Әстерхан, Себер, Казан һәм башка төбәкләрдә гомер иткән татарлар да борынгы Хазарстан дәүләтенә кергәннәр. Шул исәптән башкорт, бөҗәнәк, угыз кардәшләребез дә, чуаш, караим, гагауз туганнарыбыз да, хәтта безнең күрше-күләннәребез мари, удмурт, мордва халыклары да, соңрак килеп кушылган славяннар да заманында бер Хазар дәүләте казанында кайнаганнар. Азия, Көнчыгыш Аурупа, ары таба төркиләр чылбырын дәвам иткән Дәште кыпчак, Алтын Урда империяләре дә дөнья халыклары белән сәүдә итү серләрен Хазарстаннан алалар. Хуннар — гуннарны, гуннар — төрки болгарларны, төрки-болгарлар хазарларны дөнья тарихына тартып чыгарсалар, хазарлар әҗәри, гагауз, караим халыкларын бирделәр. Бу халыкларның әдәбиятында, мәдәниятендә, хәтта сәнәгатендә дә уртаклык бар. Болар барысы да безнең тарихыбыз. Ә борынгылар «Тарихы юк халыкның киләсе дә булмас» дигәннәр.

Тарихи әдәбият, үткәннәрдән гыйбрәт алып, укучыны нияте, уе-хисе белән борынгы бабаларыбыз кылган хаталарны булдырмаска тырышса — яхшы якларын гына үрнәк итеп алса — без мәңгелек. Инде теленнән, иманыннан, тарихыннан мәхрүм ителсә, аның юлы бердер — теге йә бу көчле милләт эчендә эреп бетү. «Тарихсыз, мәдәниятсез, хәтерсез халыкны көчле милләт йотмаса, җир йотар» дигәннәр борынгы япон философлары. Үз халкыңның шанлы тарихына, милләтеңнең казанышларына, кылган мактаулы гамәлләренә кинәнеп яшәү, халкың өчен горурлану — менә ни озын гомерле итә милләтне!

Матур әдәбият исә татар халкының кечкенә булса да хатирә үрентеседер. Тарихи тамырлардан аерылмасын кеше. Шунда, бары тик шунда гына татар милләте телен, илен, рухын югалтмас...

*Автор*

## I

— Ислам, Ислам, дим! Син кая югалдың?! Нигә мине ташладың?! Мин хәзер елыйм. Яисә сакчыларым чакырам, күреп тор, чакырам...

— Айбиби, Айбиби, мин монда, монда! Мин хәзер киләм. Мин сиңа, көмеш кыңгырау чәчкәсен тутырып, чык суы китерәм. Минем әнием әйтә, шушы чәчкәгә тутырган чык суын эчсәң, үлемсез буласың, ди.

— Ислам, тизрәк кил. Мин куркам. Бу урманда аюлар, урман мәчеләре, барслар йөри, диләр.

— Курыкма, курыкма, хан кызы. Мин хәзер... Менә чәчкәм касәсен чык суы белән тутырам да... Сиңа шул суны эчерәм дә...

Ниһаять, уң кулына кыңгырау чәчкә касәсен тотып, Ислам атлы егет хан кызын калдырган аланга килеп чыкты. Аланны тутырып, бөрмәле бала итәкле күлмәген җәеп, алан уртасында утырган хан кызын күрде дә егет исе-акылы киткән берәүдәй туктап калды. Куе үлән һәм төрле төстәге чәчкәләр белән күмелгән алан уртасында, зәңгәр күлдәге төнбоек чәчкәсен хәтерләтеп, Айбиби утыра. Бу манзарага сокланмаслык та түгел иде, бу манзарага ул тәмам сихерләнде. Алан уртасында хан кызы түгел, күктән иңгән алиһә утыра кебек тоелды. Аңа таба бер генә адым ясаса да, һәм ни дип кенә дәшсә дә, бу гүзәл сурәт юкка чыгар кебек иде. Шушы сихри көчкә ия күренеш, җәннәт-оҗмахларда гына була торган әкияти-чын алан, аланны тутырып, итәгенә зәңгәр тасма тарткан күлмәген җәеп утырган хан кызы аны, чынлап та, бер мәлгә әкият дөньясына алып кереп китте. Җитмәсә, хан кызы, күкбаш чәчкәләрдән үреп, башына таҗ кигән иде.

— Айбиби, хан кызы Айбиби, мин сиңа үлемсез итә торган чык суы җыйдым,— дип, ниһаять, Ислам кыюсыз гына хан кызына таба кузгалды.

— Минем үлемсез буласым килми, сарай табибы улы Ислам, җыйган суыңны үзең эч...— Хан кызы маңгаена төшеп торган чәчкәләрдән үргән таҗын күтәрә төште, егетнең күзләренә карады.— Нигә озак йөрдең?.. Мин курыктым, бик курыктым, беләсең килсә, сарай табибы Хәбибулла агай улы Ислам.

— Әйтәм бит мин сиңа, хан кызы, кешене үлемсез итә торган чык суы җыйдым, тамчылап диярлек, һәр чәчкәдән, һәр яфрактан. Аннары анда, Идел култыгына, аккошлар төштеләр. Көтүләре белән.

Аккошлар сүзен ишетүгә, хан кызы егеткә кулын бирде.

— Минем ул аккошларны күрәсем килә, сарай табибы улы Ислам. Алып төш мине Идел култыгына,— дия-дия, аягына басты, үзе үк алдан елгага таба кузгалды. Аптырабрак калган Ислам кулындагы чык тулы чәчкәне кабып йотты да хан кызына иярде. Ни гаҗәп, елгадан качарга теләп, болын ягына ерып кергән култыкка, чынлап та, аккошлар төшкәннәр иде. Калганнары очканнармы, култыкта өч кенә аккош калган. Икесе парлы, берсе бер читтәрәк, ялгызак. Аккошлар су төбеннән җим эзлиләр иде. Кешеләрне күрүгә, сагая калдылар. Әмма шундук тәүге хәлгә килеп, җим эзләүләрен дәвам иттеләр. Пар аккош камышлар арасынарак үтеп, сөешә башлады. Муеннарын муенга урыйлар, томшыклары белән шыкылдатып, бер-берсенә нидер әйтәләр кебек иде. Ялгызак аккош бертын аларга карап торды да, башын кырын салып, су читенә үк килеп баскан Айбибигә күз салды. Айбиби моңа кинәнде һәм кулындагы бер чәчкәне аңа ташлады. Аккош, янә бер тапкыр Айбиби ягына башын кырын салып, карап алды. Һәм чәчкәгә таба йөзеп килә башлады. Айбиби, үзе дә сизмәстән, суга ук керде. Аккош ул ташлаган чәчкәне томшыгына элде дә, су өстенә үк чыгып, биеп алды. Айбиби аңа чәчкәләрдән үргән башындагы таҗын ташлады. Аккош, янә башын кырын салып, аңа карап алды, ахыр йөзеп килеп, таҗны килер җайда ук муенына элде. Элде дә шундаен кинәнеп бии башлады ки, хәтта канатларын җәеп җилпенеп алды. Пар аккошлар да моңа игътибар иттеләр, сөешүдән тукталып, шул якка карап тора башладылар. Айбиби аккошлар кебек ап-ак күлмәк кигән иде, аякларында кызыл болгари итек, муенында зәңгәрсу тасма, башында кызгылт-сары өрфә яулык, яулык астыннан аксыл бөдрә чәчләре чыгып тора, шуңа күрәме болай да гүзәл хан кызы кошлар гашыйк булырдай тагы да гүзәлләнеп киткән иде. Сарай табибы улы Ислам, бу тамашага мөкиббән китеп, сихерләнгән килеш, ни кылырга белми тора. Ни тамаша, аккош Айбибигә таба йөзеп килә башлады, шул хәлгә сихерләнә төшепме, хан кызы да аккошка каршы китте. Ислам тәмам курка калды. Аккош Айбиби янына ук килеп җитте. Янә канатларын җәйде, гүя Айбибине суга — кочагына чакырды. Инде су Айбибинең балтырларына җитте, аккош белән адәм баласының иң гүзәл заты менә-менә кочаклашырлар, һәм Аллаһының оҗмах кошы аны күтәреп алып китәр сыман. Ислам дәшәсе итте, тавышы чыкмады, ул, чынлап та, бу хәлгә әсәрләнгән, сихерләнгән берәүдәй катып калган иде. Парлы аккошларга ишләре кылган гамәл ошамады булса кирәк, алар, ялгыз аккошны чакыргандай, каңгылдашып алдылар да очарга җыена башладылар, һәм су өстеннән йөгереп, канатларын киң җәеп, кузгалып та киттеләр. Хан кызы Айбибигә бер адым килеп җитәр-җитмәс калган ялгыз аккош ишләренә таба карады һәм каңгылдап алды да алар артыннан кузгалды. Ул, кем беләндер саубуллашкандай, моңсу итеп каңгылдады, аккошның хәсрәт тулы моңсу-сагышлы тавышы Айбибинең йөрәгенә үзе дә аңлап җиткермәгән сагыш хәсрәте салды.

— Сау бул, сау бул, аккошым, сау бул, оҗмах кошым!..— дия-дия, Айбиби бертын су буйлап барды, ахыр туктады һәм бер мәлгә инде күздән югала башлаган аккошына карап торды. Бары тик шуннан

соң гына судан чыкты һәм Ислам янына килеп, күкрәгенә капланды. Капланды да сызланулы вә әрнүле тавыш белән:

— Табиб улы Ислам, табиб улы Ислам, ул китте, китте, минем аккошым китте,— дип елап җибәрде. Менә кайчан кичәле-бүгенле тулышкан күңеленең буасы ерылды Айбибинең. Аны бит иртәгә, нәкъ менә иртәгә, Аккалага кахан кырына алып китәчәкләр, Хазар каханы сараена.

Ислам кызны тынычландырырга теләде, иңбашларыннан сөйде, күкрәгенә кысты, ахыр ике битенә кулларын куеп, хан кызының күзләренә карады. Карады һәм хан кызының күзләрендә яшь күреп, шул чиккә җитеп тәэсирләнде ки, хан кызының яшь белән сугарылган битләренә, дымлы иреннәренә тартылганын сизми дә калды. Иреннәренә кагылып кына узды, яшьле битләреннән үпте. Әнә шул үбүдәнме, кинәт хан кызына нәрсәдер булды, ул сискәнеп китте, тәне буйлап үзе дә аңламаган тетрәнү узды, шундук башына шаулап кан саугандай итте. Хан кызы тәмам буынсыз калды, сыны китеп, ишелеп төшә башлады. Бу хәлгә югалып калган Ислам хан кызын кулына күтәрде дә яр өстенә таба кузгалды. Ә яр өстендә аларны хан кызының өч сакчысы көтеп тора иде.

— Ни булды, сарай табибы улы, хан кызына?! — дип сорады баш сакчы коры гына. Артык койты сорагангамы, Ислам каушый калды, хан кызын аягына бастырды да сүзсез торды.

Ул арада хан кызы исенә килде, баш сакчыга карады да шактый кырыс төстә:

— Берни дә булмады, баш сакчы, барыгыз, кайта торыгыз! — дип боергандай әмер бирде.

— Минем сезне ташлап китәргә хакым юк, хан кызы,— диде баш сакчы һәм Ислам ягына ым кагып: — Әллә сарай табибы улы...

— Мин сабый бала түгел, баш сакчы. Мин буй алган хан кызы. Мине иртәгә Аккалага алып китәчәкләр, Аккалага! Кахан тарттыра мине үз сараена. Ә табиб улын миңа бәйләп атам җибәрде, баш сакчы... Ишетәсеңме, атам!..

— Аккалага?! — дип, өчесе дә бергә кабатладылар сакчылар һәм күзгә-күз карашып алдылар. Бу хәл сакчыларга көтелмәгән хәбәр иде булса кирәк, ат башларын кайтыр якка бора башладылар.

— Хан кызы! — дип кычкырды баш сакчы.— Атларыгыз аланда, тышаудалар...

— Яхшы, баш сакчы, яхшы, атларны табарбыз,— диде, ниһаять, батырая төшеп Ислам. Һәм, елмаеп, хан кызына күз төшереп алды, чөнки бу куәтне аңа нәкъ хан кызы биргән иде.

— Миңа ни булды, Ислам? — диде хан кызы, егет кырына ук килеп.— Ни булды миңа, сарай табибы улы Ислам?..

— Сезне аккош сихерләде, хан кызы,— диде Ислам һәм кызның кулыннан алды да атларын калдырган аланга таба әйдәде.

— Синең атаң минем белән Аккалага барачак, Ислам,— диде хан кызы.— Озата барачак. Син дә атаң белән мине озата барыр идеңме?

— Мин атамнан сабак алам, хан кызы. Минем бөтен хыялым кешеләрне сәламәтләндерү, аларны бәхетле итү. Сәламәт тәндә — сәламәт акыл, дигәннәр борынгы бабаларыбыз.

— Һәр адәм баласының да язмышы Тәңре кулында, сарай табибы улы Ислам. Тәңре ни язган, һәммә җан иясенә дә шул булачак, гарәпләр әйтмешли, һәр кеше Аллаһы язган юлдан үтәчәк.

— Сезне Аккалага алып китәләр, хан кызы. Бу да язмышмы?

— Бу Аллаһы теләге, сарай табибы улы Ислам. Борынгылар язмыштан узмыш юк, дигәннәр. Димәк, Аллаһы миңа шул язмышны юраган, әйе, фәрештәләре аша.

— Хан кызы, әйтимме бер сүз?

— Әйт, сарай табибы улы Ислам.

— Атаң Талиб исән булса, хан кызы, ул сине кахан кырына җибәрмәс иде. Аның болай да кырык хатыны бар, диләр ич.

— Мин каханга кырык беренче хатын булып тартылам, сарай табибы улы Ислам. Ә кырык беренче хатын баш хатын вазифасын үтәячәк, диде атам Мөхәммәд хан.

— Әйе, мин дә бу хакта ишеткән идем, хан кызы.

— Сарай табибы улы Ислам, син минем Мөхәммәд атама тел тидермә. Атам Талиб хан мин тугач та вафат була, яшь хатын булып килгән хан сараендагы анама Мөхәммәд хан өйләнә. Ә ул мине үз кызы итеп үстерде, укытты, белекле итте.

— Минем исемем Ислам, димәк, мин пәйгамбәрләр сакчысы, минем сезне саклыйсым килә, хан кызы.

— Пәйгамбәрләр сакчысы икәнсең, сарай табибы улы Ислам, син мине исән-имин атама кайтарып тапшыр. Бар, атым китер!

Күрше аланда утлаган атларның аякларындагы тышауларын чишеп, Ислам хан кызына җете кара бияне китереп, йөгәнен кулына тоттырды. Хан кызы бала итәкле күлмәген күтәрә төшеп, кызыл болгари итек кигән аягын өзәңгегә куйды да, очып диярлек иргә менде һәм елдыр гына аланнан чыгып та чапты.

— Мин аккошым куа киттем, сарай табибы улы Ислам, аккошым! – дип кычкырды. Ислам атына атланды һәм хан кызын куа китте. Ләкин урманнан чыккач кына Айбибине куып җитте. Алар икесе дә күзгә-күз карашып алдылар һәм, атларын тыя төшеп, янәшәдән атлатып киттеләр.

Хан кызы Айбиби янә-янә егеткә карап алды һәм үзалдына нәүмизләнеп, елмаеп куйды.

— Рәхмәт сиңа, сарай табибы улы Ислам, син бик яхшы юлдаш икәнсең.

— Синең аккошың булсаммы,— дип, якын итеп, хан кызына дәшә башлады Ислам,— канатларыма утыртыр идем дә мин сине, хан кызы Айбиби...

— Һәм кай тарафларга алып китәр идең хан кызын, сарай табибы улы Ислам? Әйтче, кай тарафларга? — дип, эчке бер самими киная белән елмайды Айбиби.

Ислам бер мәлгә югалып калды. Ул белә иде инде, кызлар, яшь кызлар үз үсмер ишләрен бик үк тиң күреп бетермиләр, «кызлар, гадәттә, иртәрәк өлгерәләр» дигән иде бер тапкыр атасы аңа. Ә менә яшь бикәләр, киресенчә, яңа мыегы шытып чыккан егетләрне куеннарына сыендыруны тәмам изге гамәлгә санийлар. Монысын инде Ислам үзе дә бик яхшы белә иде.

Икенче мәлдә инде хан кызы ат тезгенен тартып алды һәм:

— Рәхмәт, сарай табибы улы Ислам, мең рәхмәт. Тик минем язмышым хәл ителгән инде. Атам Мөхәммәд хан хәл итте аны. Ул миннән бик үтенде, сине олуг илбашы көтә, балам, диде. Атам миңа әйтте, кахан сине кырык хатыны булса да рәнҗетмәс, чөнки син баш хатын сыйфатында булырсың, диде. Минем бер дә кахан белән тәмсезләнәсем килми, балакаем, диде. Чөнки Идел буе Болгары Хазарстанның вассалы, шул сәбәпле мин сине аңа җибәрми булдыра алмыйм, балакай, диде. Бу атаңның каханга биргән изге анты дип кабул итә күр, диде. Хак булса, баш хатын буларак, мин һәрдаим кахан кырында утырачакмын — илчеләр кабул иткәндә дә, раввалар табынында да. Мин Аккалага тартылгач, кахан Болгарга ташламалар ясаячак, сарай табибы улы Ислам. Һоп, Каракошым, һоп...

Хан кызы атын куалый-куалый алга ыргылды, Ислам бер мәлгә югалып калды, җитмәсә, хан кызы бу сүзләрне аңа түбәнсетеп тезде кебек тоелды. Ә бит хан кызының аты аның аты белән ияргә ияр, тезгә тез барганда, Айбиби тарафыннан хуш исләр килә һәм аның зиһенен томалый башлаган иде.

— Хан кызы, хан кызы, тукта! Каханны Ханбалыкта утырмый, диләр ич?!

Айбиби кузгала башлаган атын тыя төште һәм, артка каерылып, Исламга карады.

— Кахан Идел елгасы уртасындагы утрауга салынган Аккалада утыра, сарай табибы улы Ислам. Ул каланы гарәпләр Ай-Балда дип язалар. Аккалада каханның варислары гына түгел, хатыннары да, раввалары да яши. Шунда ук карачылары, куштаннары, тагын әллә кемнәре... Аккошлар булыйкмы, сарай табибы улы Ислам?!

— Булыйк, булыйк, хан кызы, булыйк!

— Без аккошлар! — диделәр дә калага таба чаптылар.

Ислам ни теләсә дә хан кызының атын куып җитә алмады. Хан кызы, күзгә күренеп, аңардан ерагая бара иде. Аның ак күлмәге күктәге ак болытларны хәтерләтеп кабарган, кыз гүя аккош үзе иде. Тик ул җирдә, әллә нигә күккә генә күтәрелә алмый изалана кебек иде. Ислам исә, калага кереп барган хан кызы артыннан атын ни куса да җитә алмады гына түгел, ерагайганнан-ерагая барды. Ислам басу капкасына җиткәндә, хан кызы биредән әллә кайчан узган, юл тузаны гына зәһәр еландай сузылып калган иде.

Чарасыз калган берәүдәй, Ислам атын тыя төште, күп тә үтми өйләре утырган тыкрыкка борылды. Кинәт кенә аңа кыен булып китте. Хан кызының кыланышын ни дип юрарга да белмәде. Көлә идеме хан кызы аңардан, яшьсенә идеме, әллә соң бөтенләй баласындымы?.. Алай дисәң, нигә кочагына инде дә, нигә үзен үбәргә һәм сөяргә бирде, хәтта хуштан язды кебек. Әллә соң юри генә кыландымы?.. Ләкин ни генә булмасын, Ислам шат иде, көтмәгәндә ул хан кызы белән урманга чыкты, Идел буена төште һәм, таң калып, аккошлар белән сөйләшкән хан кызы белән булды, кочагына иңдерде, зифа буен, кайнар тәнен тойды. Тагын да гаҗәбрәге, хан кызы, ялгыз аккошка гашыйк булгандай, суга ук кереп китте, аккошы да, кеше телен белгәндәй, аңа таба йөзеп килеп, канатларын җәеп, хан кызын кочарга теләде кебек. Аккошның муенында хан кызы ташлаган чәчкә-таҗ, томшыгында ал чәчкә. Кем сихерләде җырларда гына җырлана торган аккошны — хан кызымы, әллә соң аккош үземе?.. Ислам күрде ич, күрде, аккошның күзләре тагы да кызарыбрак киткәндәй булды, ә хан кызының йөзендә әсәрләнү хисләре аша туган соклану тойгысы. Моны ни белән аңлатырга да белмәде Ислам һәм бу хәлне гомумән аңламады, чөнки ул атасыннан азмы-күпме дөньяви фәннәрдән генә түгел, кош-корт һәм хайваннар, җанвар-җәнлекләр турында да сабак алган иде. Кошларның кеше белән аралашуын күз алдына китерә алмый иде ул. Бүген исә шуңа шаһит булды. Аккош белән хан кызының сөйләшкәнен күрде. Ләкин ул шушы булган хәлне беркемгә дә сөйләмәс. Һич булмас димә, диванага санаулары бар. Ә менә әнисенә сөйләр. Юк, үбүе хакында аңа да сөйләргә ярамас. Хан кызын үптем, хан кызы кочагымда хуштан язды, дисә, әнисе ничек кабул итәр. Ул да җүләргә санамасмы?! Хан кызы ич! Кемнең аны үбәргә, кочагына иңдерергә хакы бар. Җитмәсә, хан кызы артыннан бер тотам калмый сакчылары йөри. Ханга җиткерсәләр, сарай табибы улы сәнең кызың кочаклады, хуштан язгач, яр өстенә күтәреп менгерде, дисәләр?!

Атын, иярен дә алмый, абзарга җибәрде дә өйгә керде, аяк киемен салып, түргә узды, сәкегә утырды һәм уйга калды.

Мич ягыннан әнисе чыкты, башын иеп утырган улын күрде дә туктап калды.

— Карале, улым, кайларда йөрдең? Атаң кайтты, сине эзләде. Нигә күзгә карарга кыймый торасың, әллә соң ул-бу булдымы үзеңә, аттан егылмагансыңдыр бит?.. Юкмы?

— Хан кызы белән урманга чыккан идек. Идел буена төштек, Аккошлар култыгына. Аккошлар төшкәннәр иде.

— Шуннан, шуннан, улым, ни булды инде? — Ананың күңелен тәмам кызыксыну басты, ул, чарасыз калып, улы кырына, киез җәйгән сәкегә утырды.— Аккошлар анда һәр елны ике-өч тапкыр төшәләр. Җәйләп калганнары да булгалады. Ә синең нигә сөмсерең коелды соң әле?.. Аккошлар хан кызын күтәреп алып китмәгәннәрдер бит?

Ислам, сәерсенеп, әнисенең күзләренә карады, әнисе күз төпләре белән әкрен генә елмая һәм елмаюы шулай ук әкрен генә иреннәренә таба күчә бара иде.

— Хан кызын күтәрерлек аккош буламы соң, әнием?

— Нигә булмасын ди, була ул, була. Әкиятләрдә кызларны һәрчак аккошлар канатларына утыртып алып китәләр. Ә ул аккошлар арасында, мөгаен, Йосыф каханның да аккошы булгандыр. Хан кызын канатына утыртып алып китәргә иткәндер.

— Көлмә әле, инәй, беләсең килсә, хан кызын иртәгә Аккалага озаталар.

— Әтиең әйтте инде, озаталар. Кызганып куйдым әле балакайны. Атасы Талиб хан да яшьли диярлек вафат булды, Айбиби балага исем кушканнар гына иде, тәхеткә килгән Мөхәммәд хан Талиб ханның яшь хатынын сараена — үз кырына алды, никахлар укытып, улым, никахлар укытып... Чөнки Талиб ханның яшь хатыны күз алмастай чибәр вә сылу иде. Ирләр алдына чыкса, барысы да аһ итәрләр иде. Ләкин ул, бичара, Талибын үтә яраткан идеме, озак яшәмәде, Тәңребез үз кырына алды. Әнә шулай анасының күкрәк сөтен тәмләп кенә калган бала сарай абыстае Рәшидә кулында калды. Мөхәммәд хан, рәхмәт аңа, баланы үз кызыдай карап үстерде, гарәпләрдән, фарсылардан мөгаллимнәр китертте, баланы белемле итте. Хәзер әнә, буй алгач кына, каханның раввалары күреп алганнар, балакайны... Яраткан кешесе булдымы икән соң балакайның?!

— Бүген аңа мин гашыйк булдым, инәй, мин!

— Йә, йә, улыкаем, ни дип әйттең инде син аңа?

— Хан кызы минем кочагыма иңде, мин аны сөйдем, үптем, мин шул мәлдә гүя күккә аштым, инәй, күккә! Беләсең килсә, мин аны урларга барам. Бүген үк, төнлә белән...

Исламның әнисе Гөлзифа кечкенә кызларга мәдрәсәдә сабак бирә, абыстай сурәтендә йөри торган кеше иде, улы хан кызын «урлыйм» дигәч, кинәт йөзгә үзгәрде, бермәл ни әйтергә белми яңа сакалы төртеп чыга башлаган улына карап торды.

— Саташасың инде әллә, улыкаем. Алла диген. Сөйләмә юкны, әйткән сүзең фәрештәләрнең «амин» дигәненә туры килүе бар. Хан кызы ла ул. Безгә тиң баламы?! Бу сүзләрең Мөхәммәд ханга җиткерсәләр, һич булмас димә, еланнар базына ташлатыр үзеңне. Атыңа ышан, ханга ышанма, дигәннәр борынгылар.

— Ә мин аны яраттым, инәй, битләреннән үптем, күзләреннән...

— Әстәгъфирулла, ни сөйлисең син, улыкаем? Борын астыңа яңа өч бөртек йон чыккан, ә ул хан кызын урларга җыена. Мөхәммәд хан ишетсәме бу сүзләрең, балакаем...

— Ишетсен, мин аны кочагымда тоттым, битләреннән тозлы яшьләрен яладым. Яраттым, яраттым мин аны, инәй, ишетәсеңме, яраттым! — Ислам кинәт кенә урыныннан купты да әнисенең алдына төште.— Бир миңа фатихаң, инәй, бир!

— Һай Аллам, балакаем, чарасыз итмәсәнә ананңы?! Сакчылары да ишеттеләрме синең ни... хан кызын, дим...

— Юк, сакчылар күрмәделәр дә, ишетмәделәр дә, инәй.

— Йа Аллам, Ходай бар икән әле, бар икән. Саклаган минем диванамны зинданнан. Бу сүзләрең хан ишетсәме, таш атып үтертер, таш атып, балакай. Хан кызы Айбиби илгә бер чибәр бит ул, илгә бер чибәр. Үзе акыллы, үзе укымышлы, өч-дүрт телдә сөйләшә, үзе күз алмастай гүзәл. Мөхәммәд ханны да әйтер идем инде, борынына яңа ис керә башлаган балага каханга ярәшкән кызын биреп җибәргән.

— Мин җиткән егет инде, инәй, җиткән егет! Һәм мин хан ышанмастай кешенең улы түгел, атам сарай табибы, анам балаларга сабак укыта — калада бер абыстай.

— Карале, улым, сиңа кызын биреп җибәргәндә, Рәшидә абыстай да анда идеме? Ул да ризалык бирдеме?

— Рәшидә абыстай анда юк иде, анда булган булса, ул да ризалык биргән булыр иде, инәй.

— Мөхәммәд ханны әйтәм, соңгы көндә булса да Аккошлар култыгын күреп кайтсын дигәндер инде, бичара. Атасы да бичара, кызы да...

— Нигә бичаралар, инәй?

— Бичара булмыйча, кем булсыннар соң алар, каханга баш иеп торалар лабаса! Мөхәммәд хан икенче кызын җибәрә бит инде ул хатыннарга туймас каханга, икенче кызын. Айгөле үз кызы иде, бара-баруга йөккә уза да, бер бала табып, вафат була. Раввaларга баш бирмәгән ул бала, дип җиткерделәр. Горур, тәкәббер бала иде Айгөл кызы.

— Миңа ничә яшь инде, әнием? Унҗиденче языма аяк бастым, хан кызы да...

— Хан кызы башка ул, балакай, кызларның яшен санамыйлар. Мөхәммәд пәйгамбәр тугыз яшьлек Гайшәгә дә өйләнгән, никахлап, олылап.

— Барыбер мин хан кызына гашыйк, әнием! Йөрәгем белән гашыйк. Хан мине еланнар базына ташласа да, илдән куса да, минем хан кызы Айбибигә булган гыйшкымны йөрәгемнән уеп ала алмаячак, инәй-инәкәем!

— Гашыйк булдың?! Бер син генә гашыйк идеме ул балага, улыкаем! Баҗайлар ханы Түрә дә яучыларын җибәреп карады, Айбибине кайсыдыр улына тарттырмакчы булды. Тын елгасы буенда җәйләгән кыпчак ханыннан да яучылар килделәр, Кара Болгардан да. Бирмәде Мөхәммәд хан Айбибине, берсенә дә бирмәде.

— Ә мин яучы җибәрсәм, әнием, Мөхәммәд ханга, дим?

— Тиле дигән саен тигәнәк буе сикермә әле, улым. Ул бала илгә бер гүзәл генә түгел, әйем. Беркөнне шулай шәехне очраттым. Һәй, гүзәл зат, сарай табибы Хәбибулла бикәсе, ди бу. Туктадым. Шәех кадәр шәех дәшә ич, Бохарада укып кайткан. Хан кырында киңәшче йөзендә утыра. Әйе, киңәш-сабак бирер. Килде олуг башы белән кырыма. Ни, ди, әйт әле җәмәгатеңә, җибәрмәсен Айбиби баланы кахан кырына, ди. Безнең үзебезгә дә акыллы балалар кирәк, ди, улыкаем. Хәбибуллаңа шул хакта әйт әле, шәех бик үтенде, дип, атаң тыңлап та тормады. Чалмага төренгән бар кеше акыллы дигән сүз түгел, анасы, башымны катырып йөрмә, Мөхәммәд хан ни кылганын бик яхшы белә, дип кенә ташлады. Хан аның үзен дә Ханбалыкка озатмакчы була әле, анасы, диде атаң, улыкаем. Хәер, шәех тә, хан да, атаң да, син дә, мин дә — барыбыз да Аллаһы колларыбыздыр, барыбыз да Тәңре ярдәме белән яшибез вә көн күрәбез. Рәшидә абыстай әйтә, һәр туган балага рух шәмен Аллаһы фәрештәләре куя. Ә шәех исә, атаң әйтә, Аллаһы фәрештәләренең җирдәге шәүләсе генә. Шулай дигән Сөләйман пәйгамбәр. Буең җитмәстәйгә үрелмә, көчең җитмәстәйгә тотынма, дигәннәр борынгылар. Син, улым, хәзер күңелеңне гыйшык-мыйшыкка түгел, белемгә беркет. Бу дөньяда фәрештәләрнең белем шәме — китап вә белемдер. Хан кызының үз язмышы, синең үз язмышың. Күңелеңне юк-бар белән алгысытма. Кыз бирү кемгә кайгы, кемгә шатлык китерәдер. Минем дә гүзәл кыз Айбибине бер дә яше кырыкка җиткән каханга бирдертәсем килми. Мөхәммәд хан ул гүзәл кызын комсыз каханга җибәреп барыбер уңмас кебек миңа. Чөнки угызлар безгә якынрак, ә алар инде Хазарстан җирләренә кереп җәйли башлаганнар. Бер дә борчылма, улым, син яшь әле, гашыйк та булырсың, хатын-кыздан гарык та булырсың. Хатын-кыз шулай ул, башта кочакка иңә, аннары өйгә керә, ахыр ир белән идарә итә башлый. Хан кызына гашыйк булдым дип, диванага башың сала күрмә тагын. Үтәр ул, яшьлектәге мәхәббәт язгы ташу гына бит ул. Кар сулары китүгә үк үз эзенә төшә, кар сулары үтүгә үк. Беренче мәхәббәт әнә шул синең күңелеңдә туган язгы ташу гына бит ул. Чын мәхәббәт өйгә атка атланып керми, чын мәхәббәт өйгә мүкәләп керә, мәңге шунда калам, итәк тутырып бала табам, дип.

— Әйе шул, әнием, миңа калса, хан кызы Айбиби аккошка гашыйк булды. Сукыр кеше шикелле, аккош дәшүгә, суга кереп китте.

— Суга?! Бу ни дигән сүз инде тагын, улым?..

— Аккош аны кочагына алды кебек. Һәрхәлдә, миңа шулайрак тоелды.

— Аккошлар алар кызларга охшаган, балакай. Кияүгә чыгалар да туган якларын мәңгегә ташлап китәләр... Ул Аккошлар култыгына без дә җыелышып төшәдер иек. Ап-ак күлмәкләр кияр иек. Безне күргәч, култыкка төшкән аккошлар беравыздан каңгылдаша башларлар ие. Һәй, сөенерләр иде дә соң. Әле су өстенә үк чыгып биергә, әле чума-чума уйнарга, бер-берсен куышырга тотынырлар ие. Араларында әле шул уеннарга катнашмыйча, боек кына бер читтә торучы ялгызаклар да булырлар ие, улым. Димәк, нindидер бер явыз җан аның ишен уктан алган. Аккошлар шулай бит алар, бер кавышкач, мәңгегә бергә булалар. Инде теге йә бусы ишен югалта икән, мәңгегә ялгызак гомер итәләр. Йә, ярар, улым, акыл сатып утырмыйк, бар, атларны эчереп кер. Ат караучы, хатыным бәбәй китерде, абыстай, атларны улыңыз гына эчерер, дип сорап киткән ие. Һәй, улым, улым, менә син дә үсеп җиттең. Анаң белән кызлар турында сөйләшеп утырасың.

Гөлзифа улының аркасыннан ләпи-ләпи сөйде дә Исламны ишеккә таба этәреп җибәрде, үзе исә тамак төбенә килеп тыгылган яшь төерен йотып җибәрә алмый, күз кабакларын әчетеп куйган шатлык вә башына кайгы китерергә җыенган улының аркасына карап калды. Йөреше, кыяфәте, атлап китүләре тач атасыныкы иде. Сөйгән сөяк сөйгән сөякне бирер, дигән бугай Мөхәммәд пәйгамбәр, хак икән, дип уйлады. Ни хәл итмәк кирәк, әнисенең җан җылысы, эчкерсез үз итеп сөйләшеп утыруы, күрде ич, улына да күчте. Һәм улының да күзләре дымланды бугай, әмма ир-егет буларак күз яшен әнисенә күрсәтергә теләмәде. Димәк, ил халкына вә ватанга янә бер ир-егет терәк булачак дип кинәнде ана.

* * *

Ислам төш күреп ята иде. Имеш, ул һаман Айбиби белән Аккошлар култыгында, ә аларны аккошлар уратып алган, бигрәк тә гүзәл кошлар хан кызы Айбибине сөяләр, суга таба сөйриләр. Имеш, Айбиби аккошлар белән суга кереп тә бара инде, Ислам аңа таба атлыйсы итә, әмма аяклары гүя җиргә ябышкан, кузгала да, дәшә дә алмый. Ә хан кызы Айбиби чыр-чу килә кебек, көлә дә сыман һәм инде суга кереп бара. Аккошлар кинәнәләр, каңгылдашалар. Айбиби аны да үзе белән чакыра, кул изи, хәтта дәшә сыман...

— Ислам, Ислам улым, дим! Тор, әллә саташып ятасың инде. Кемгәдер дәшәсең кебек тоелды. Тор, дим, кояш чыгып килә. Ашыйбыз да сарайга барабыз. Хан дәшә.

Ислам тәмам уянды, «хан дәшә» сүзен ишетүгә уянды, хәтта торып утырды.

— Ни булды, әтәй?

— Хан сине сарайга дәшә, дим. Башта Айбиби кызы белән мине җибәрәсе иткән иде, кинәт кенә фикерен үзгәрткән — Айбиби кызы, мине Ислам табиб озатсын, дигән. Мөхәммәд хан Айбиби кызы сүзен тыңламый буламы.

Ислам барысын да үз колагы белән ишетте. Аны Айбиби онытмаган, ул аны Ханбалыкка кадәр озата барачак, атасы Хәбибулла урынына.

— Хакмы бу, әтәй?

— Әйе, хак.

— Бүген үкме?

— Өйләдән соң кузгаласыз. Юын, аша да сарайга барабыз.

— Мин Ханбалыкка барам, әтәй, Айбибине озатырга?!

— Әйе, хан кызы Айбибине озатырга, улым. Айбиби атасыннан үзе үтенгән. Миңа әйтте хан, улың риза булса, мин риза, диде.

— Мин риза, риза, әтәй, риза.

Мич ягыннан күлмәк чабуын ыштан бөрмәсенә кыстырган Гөлзифа әнисе чыкты, ашык-пошык юынып, тыз-быз киенеп йөргән улына карады да:

— Ни булган моңа тагын, корт чаккандай өтәләнә. Атасы, дим?

— Ашарга әмәллә, анасы,— диде Хәбибулла.— Мөхәммәд хан малайны табиб йөзендә Айбиби кызын озатырга җибәрә...

— Нәмәрсә, нәмәрсә дидең син, атасы?.. Җиткерделәр дә микәнни инде. Харап иттең, Хәбибуллам, баланы харап иттең шул сарайга иялəштереп. Имеш, ханның хатыннарын оста дәвалый.

Ислам ул арада юынган, киенгән, табын җәелгән сәке башына килеп утырган иде инде.

— Нәрсә җиткерделәр тагын? — дип сорады Хәбибулла.

— Безнең дивана кичәгенәк хан кызын, әйе, ниткән...

— Ничек ниткән?! — дип курка кала сорады ир канаты.

— Әйе, ничек, ничек. Кочаклаган, үпкән, гашыйк булган хан кызына безнең дивана.

— Кабат әйтәм, безнең диванаы Мөхәммәд хан табиб йөзендә кызын озатырга җибәрә, мине түгел, улыбызны.

— Харап иттек, харап иттек баланы, Хәбибуллам, харап иттек!.. Баш салырга чыга улыбыз, атасы. Моны Мөхәммәд хан юри эшли. Сакчыларыннан бер-бер сүз ишеткән дә.

— Ни ишеткән?

— Безнең Ислам кочаклагач, хан кызы хушыннан язган, Ислам хан кызын ярга күтәреп алып менгән. Күтәреп, атасы, кулына күтәреп. Егетләр кочагына кергән һәр кыз хуштан язмый, атасы. Бер-бер яман эш кылган безнең дивана. Шул сәбәпле Мөхәммәд хан улыбызны Ханбалыкка дип җибәреп, ансат кына котылмакчы була.

— Үз акылыңдамы син, анасы, дим. Минем угылымны юк итәргә Мөхәммәд ханның башына тай типкәнме?!

— Менә шул улыбыз хан кызы Айбибигә яучы җибәрергә тора иде әле. Урлап качам, дип тә янады.

— Бар әле, улым, чыгып тор әле. Атлар сайлый тор,— диде коры гына табиб Хәбибулла.— Монда анаң чуаш сырасын эчкән бугай...

Ислам ялт кына чыгып китте. Гөлзифа сәкегә утырды да, ике учына башын салып, селкенеп тора башлады.

— Атасы, атасы, дим...

— Сөйләмә миңа тузга язмаганны, анасы. Башы яшь булса да, малайның акылы үзе белән, андый юләрлеккә бармас, иншалла.

Ислам ишек артында тыңлап тора икән, ишек ачып:

— Хак әйтәсең, әтәй, бармыйм. Мин, әнием әйткәндәй, дивана түгел.

— Кер әле, алай булса, анасы, ә син тиз генә табын хәстәрлә, Ислам, син дә булыш. Ризык янында киңәшик иплəп кенә,— диде Хәбибулла. Ире шулай диюгәме, Гөлзифа урыныннан купты, мич кар-

шыннан ризык-нигъмәт чыгарды, самаварын яңартты. Һәм, авызын яулыгы белән каплый төшебрәк, табынга утырды.

Тәүге сүзне ялгап җибәрер өчен булса кирәк, Ислам анасына карап алды да:

— Мин дивана түгел, әтәй, хан кызын рәнҗетергә минем башым да ике түгел.

— Хан үзе дә Исламны ошаткан. Ипле табиб аякланып килә, диде.

— Ошаткан,— диде кырыс кына пәрәмәчкә үрелә-үрелә Гөлзифа.— Ошаткандыр шул. Теге кәнтәй җариясен дәвалады бит малаең. Ятакка калган кәнтәй икенче көнне үк йөреп киткән, диделәр. Имеш, безнең менә бу күзле бүкән чиренә күрә дәва тапкан.

— Анасы, табибның сүзе генә түгел, кулы да дәвалый.

— Кулы гына дәваласа ярый да бит, малаеңа шуннан соң күпереп мыек чыга башлады.

— Анасы, сөйләмә юкны, кеше сүзе кеше үтерә, диләр. Ханга җиткерсәләр. Ә хан ул яһүдә җариясен ярата.

— Түшәккә калган җария, Ислам дәвалагач та, сикереп торып бии башлаган, шулаймы?!

— Беләсең килсә, анасы, ул хатынын дәваларга Исламны хан үзе җибәрде. Һәм рәхмәт улыбызга, сарай куштаннары алдында йөземә кызыллык китермәде.— Хәбибулла, мыек астыннан гына, бер гамьсез рәвештә пәрәмәч ашап утырган улына күз төшереп алды.— Ә син тизрәк аша да ат дирбияләрен карап куй. Ханбалык якын җир түгел.

— Мин ашадым инде. Рәхмәт, әнием, рәхмәт, әтием.

Уллары чыгып киткәч, Гөлзифа чәй көйли-көйли иренә карап алды, әмма ни сәбәпледер әйтергә кыймый тора иде. Хатын-кыз холкын белгән табиб Хәбибулла юри хатынны күрмәмешкә салына, ашавын дәвам итә, малай турында сүз беткән дип уйлый иде. Ислам чыгып киткәч, Гөлзифа, тамагы туйганны сиздереп, амин тотты һәм җилле генә ишеккә таба үтте, ишекне ачып, малай тыңлап тормыймы дип урап килде. Килде дә, күлмәген ыштан бавына кыстырып, иренең амин тотканын көтте, тиз арада табынны җыештырды. Һәм янә ир каршында пәйда булды.

Авыр булса да, сөйләшү буласын сизеп алган Хәбибулла:

— Утыр әле, Гөлзифа, яныма. Утыр-утыр. Күрәм ич, әйтер сүзең бар.

— Юк инде, атасы, утырмый гына әйтәм, утырсам, күңелем йомшарыр дип куркам. Менә нәрсә, атасы, алай булгач, мин дә улым белән Ханбалыкка китәм.

Хәбибулла нидер әйтергә дип авызын ачты, вәләкин кисәк тыелып калды. Ат дулый — түзәргә була, тыярга да, туктатырга да әмәлен табалар, ә менә сыер дуласа, мир белән дә туктатып булмый, диләр. Дәшкән — бер откан, дәшмәгән — ике откан.

— Ачулы кеше белән сөйләшүе авыр, анасы. Ә малай өчен бер дә кайгырма, озатып та йөрмә, барыр ул анда, барыр да әйләнеп тә кайтыр, иншалла. Ханбалык Рим түгел.

— Бердәнбер баладан мәхрүм итәсең бит мине, атасы!

— Бәй, кайчан гына әллә нишләп күремем юк, балага уздым, ахры, дип шәбәеп йөргән иең түгелме!

— Узса соң, иш янына куш ярап торыр. Әнә шәех әйтә, бер бала тапкан ананы фәрештәләр оҗмах капкасына якын да җибәрмәячәкләр, ди.

— Шәехне тыңласаң, оҗмахны күреп кайткандай кылана ул. Ә сез хатыннарга җитә калган инде. Малайны Айбибигә ияртеп җибәрергә хан үзе үтенде, анасы, үзе!

— Хан кушты дип, коега төшәр идеңме?

— Төшәр идем, анасы. Ханга минем генә түгел, беләм ич, синең дә рәхмәтең зур. Аннары хан сараенда хезмәт итәм ич мин. Кайчак, синең кочагыңнан аерып, җылы түшәктән дә дәшеп алалар.

— Ханның улын дәвалаган кебек кәнтәйләреме?..

— Анасы, сөйләмә әле булмастайны. Минем аларга колагым да селкенми.

— Колагың селкенмидер анысы... Балалар, дим, кайчан кузгалалар?

— Бүген өйләдән соң. Шуңа малайны ашыктырам. Барысын да үз вакытында хәстәрләргә кирәк. Табибка үзенә бер олау бирелә. Болай хезмәтчегә барысын да әзерләп куярга кушкан идем дә... Җәй айлары бит, туктый-туктый барырлар, дигән булды хан хәзрәтләре.

— Әйт әле, атасы, нинди кыз бала кырык хатын куенында яткан ир янына ашкынып барсын инде. Каханның раввалары да килгәннәрме?

— Айбибидән күзләрен дә алмыйлар. Яраннары белән сөннәтле казаклары да шунда. Тәмам корычка төренгәннәр. Унлап равва, берсеннән-берсе тәкъва, берсеннән-берсе тәкәббер. Кырык беренче хатын булып тартыла бит бала. Имеш, бу йола Сөләйман пәйгамбәр заманнарыннан ук килә.

— Бездән кемнәр озата бара инде хан кызын?

— Рәшидә абыстай. Зарланды әле ул. Мин аннан кайта алмам инде, хушлашыйк, Хәбибулла, дигән була. Мин аңа болай дидем, олау-олау кайтырсыз әле, олау-олау.

— Нигә алай дисең, атасы?

— Угызлар теш кайрыйлар.

— Кемгә?

— Хазарстанга. Угызлар белән без дә кардәшләшеп беттек инде. Угызлар каханының илчеләре Болгардан да китми башладылар. Әнә шулай Мөхәммәд хан ике ут арасында калып бара. Кахан кул астында ич без. Угызлар да кан кардәшләр, Йосыф кахан да кияүлеккә йөз тота. Угыз ханы да улына Айбибине сораган иде. Мөхәммәд хан Йосыф каханны сайлады.

— Айбибине әйтәм, балакайны, кырык хатыны өстенә кахан астына ятсын инде. Безнекеләрдән кем озата?

— Алпар йөзбаш. Айтуган йөзбаш та озатырга җыена дип ишеттем. Имеш, Айбиби исән-имин Йосыф кахан кулында булырга тиеш. Ә бит Айбибине баҗайлар ханы Түрә дә улына сораткан иде.

— Һәй, атасы, ул баҗайларның бер дә кыйблалары юк, диләр ич. Әле тегеләргә ялланып сугышалар, әле боларга.

— Әйе, анасы, кәҗәнең маллыгы, баҗайның кардәшлеге, диләрме әле? Тик бит баҗайлар да безнең төрки кардәшләребез, анасы. Иншалла, барысы да әйбәт булыр. Мин, әйтик, үзем бик борынгы төркиләрдән. Нәсел тамырым Идел буе Болгарын аякландырып җибәргән Кодрак ханга барып тоташа.

— Минем атам-бабаларым Түрә ханнан. Шуннан ни, атасы?

— Кодрак ханның орлыгы Аттила ханга барып ялгана, анасы.

— Түрә ханның орлыгы атаң башынамы, атасы. Әллә ниләр сөйләп утырма әле, атасы. Орлык, имеш.

— Гөлзифам, Гөлзифам, дим. Ничә тапкыр әйткәнем бар сиңа, хатын-кыз бер генә баласын да су буеннан да, кишәрлектән дә, әрәмәдән дә табып алып кайтмый.

— Беләм,— диде Гөлзифа кайнарланып, торып, йөреп килеп, ир каршына басты.— Беләм, беләм, атасы, беләм. Тик менә син соңгы көннәрдә миңа, хатыныңа орлык салырга оныта башладың. Әллә соң ханның кәнтәйләренә сала башладыңмы ул орлыгың?..

— Сөбханалла, ни дигән сүз инде ул тагын, анасы! Малайның тыңлап торуы бар.

— Әйтсәм әйтим инде, атасы, күрше Мәйсәрә югары оч чишмәдән ике кыз табып алып кайтты инде. Өченчесенә җыена.

— Сөйләмә әле, анасы, надан карчыклар сүзен. Кемгә кирәк ул синең иләк авызлы Мәйсәрәң.

— Һи-и, атасы, атасы, башың җүләргә салып утырмасана. Мәйсәрә кебекләрне ил бетереп эзлиләр. Чөнки ел саен бер бала таба. Әле әрәмәдән, әле...

— Әрәмәгә син дә йөргәлә...

— Җир уба сине, атасы, билләһи, җир уба. Күр әле, чәчәктәй күрше хатынына ни әйтә. Колмак җыярга төшә ул әрәмәгә, ипекәй камырын кабартырга чүпрә ясарга...

— Шуннан кабарып кайтамы?

— Яһүдләргә сата ул колмакны, яһүд сәүдәгәрләренә.

— Урман-әрәмә тулы шүрәле бездә, шүрәлеләрдән дә курыкмыймы Мәйсәрәң. Шүрәлеләр бит кети-кети уйнарга яраталар.

— Минем әрәмәдә ул шүрәлеләрне күргәнем булмады, атасы. Күргән булсам, бәлкем, уйнап та алган булыр идем — кети-кети. Әйе, мин кемнән ким?!

— Син, анасы, калада бер абыстай, хан табибы хатыны. Хан табиблары чуерташ түгел, җирдә сибелеп ятмыйлар.

— Алай бик борының чөймә әле, атасы. Куй әле шаяртуыңны, атасы. Малайга кайсы атыңны бирәсең?

— Туры айгырны алыр.

— Юк, атасы, туры айгырың бия күрдеме, күзе-башы тона. Син аңа кола бияне бир. Былтыр сабан туенда икенче булып килгән бияне.

— Ярый, шулай итәрмен, анасы.

— Карале, атасы, туктале тукта. Әллә соң синең дә күрше Мәйсәрәгә күзең төштеме?

— Күз — шайтан, уй — йолдыз, диләр. Мәйсәрә болай ирләр күзе төшмәслек хатын түгел кебек, анасы.

Гөлзифа бер мәлгә мутланып киткән иренә ни әйтергә белми югалып калды. Ахыр, ыштан бавына кыстырган итәк чабуын бер ычкындырды, бер янә кыстырды, шул сәбәпле хатынның болай да калку янбашлары тагы да калкып киттеләр, ул да түгел, күкәй салырга җыенган тавык кебек, оя эзләгәндәй, ишекле-түрле йөреп килде.

— Җүләрем Хәбибулла, мине, беләсең килсә, тилергән аккоштан башка берәү дә кочмады. Хак, Хөршидә туенда Мөхәммәд хан билемә кулын салган иде, сыпырмадым инде, ханыбыз ич...

— Хан кадәр ханның кулы сиңа тартылган икән, димәк, син, Гөлзифакаем, баллыларның баллысы, татлыларның татлысы.

— И-и-и, атасы, без синең белән үртәшеп торабыз, ә Мөхәммәд хан ут йотадыр. Йосыф каханга икенче кызын озата бит инде, икенче кызын, алма кебек кызларын. Кахан дигәч тә, ни хакы бар аның бер көтү хатын белән торырга?!

— Бусы баш хатын булып бара, баш хатын булып, анасы.

— Баш хатын булмагае, таш булып барсын — кырык хатынга бер ир, әйтсәм әйтим инде, кырык хатынга бер ир, кырык тавыкка бер әтәч кебек бит ул.

— Айбибидә абыстайлар акылы бар, анасы, кайгырма, монысы бирешмәс. Шәех тә ул баланы мактап бетерә алмый. Җаен табар, табар ул бала каханны ничек кул астына алырга. Хатын ир белән, ир ил белән идарә итә, дигәннәр борынгылар.

— Безнең Исламны да шул шәехкә сабак алырга бирә алмадың, атасы.

— Дөнья үзе мулла, анасы, дөнья өйрәтә адәм баласын ничекләр яшәргә. Белем белем белән, тормыш тормыш белән.

— Балакаем, Айбибине әйтәм, бер атналар элек кенә бер гамьсез уйнап йөридер иде, шул баланы кахан кадәр каханга богаулап алып китсеннәр инде.

— Кайгырма, анасы, киләчәктә һәр кыз бала бары тик үзе сайлаган егетенә генә кияүгә чыгар.

— Кайчан буласы инде ул көннәр, атасы?

— Ахыр заманнан соң, ахыр заманнан соң, анасы.

— Ә халыкның бер дә хан кызы Айбибине Хазарстанга җибәрәсе килми, барысы да кызганалар.

— Бала ата-анага гына түгел, барча халыкка да газиз, Гөлзифа.

Гөлзифа тынычлана төште, ире кырына килеп утырды.

— Карале, атасы, ул бала аркасында безнең дивана ул-бу яманлык кылып ташласа? Хан кызы безнең улыбызның күңеленә ут салган булса?

— Нинди ут тагын ул?

— Мәхәббәт уты. Кашан кызлар тавында син җүләрне күргәч, миңа да кабынган иде ул ут. Күлмәгем яна дип торам.

— Очраштык, сөйләштек, вәгъдәләр бирештек, нигә шунда, күлмәгем көйри башлады, дип әйтмәдең соң?..

— Һәй, сиңа сөйләдең ни дә, сөйләмәдем ни, башың җүләргә салып утырма лабаса. Үзең дә имчәк бозавыдай тагылдың ич үземә. Гашыйк булу яман гамәл бит ул, бигрәк тә яшь чакта.

— Гашыйк булу бәхет ул, анасы, кеше башына ишелеп төшкән бәхет. Гашыйклар турында әдипләр мәңгелеккә юллама алган әсәрләр язалар.

— Безнең дивана хан кызын урлап баҗайларга качса?..

— Көтүдән качкан атка тышау салалар, анасы. Йә, мин углан янына чыгыйм әле, ни кырып ята икән.

Шулай диде дә табиб Хәбибулла, торып, ишеккә таба китте.

Гөлзифа тәрәзәгә барып капланды. Бала газиз иде анага. Ә ул угылын да, ирен дә ярата иде.

**II**

Карачы апа һәм Рәшидә абыстай һәрдаим хан кызы Айбиби кырында булдылар. Сарайда хезмәт иткән барча хатын-кыз хан кызын озатырга чыккан иде. Хан кызы утырып китәсе арбадан ерак түгел Мөхәммәд хан тора, аның янында ханның кара биясенең йөгәненнән тоткан җан сакчысы. Димәк, Мөхәммәд хан, яраткан кара биясенә атланып, кызын басу капкасына кадәр озатачак, бәлкем әле, арырак та озата барыр. Сарай ишегалдында күпсанлы олаулар, мичәүләп җигелгән бер ишләр. Бер ишләргә җигелгән атлар икесе дә бер төстә. Атлар талымсызланып алалар, күчәрбашлар, аларны тыя төшеп, дилбегәләрен тартып куялар. Иң алда, кирмән капкасы янында диярлек, түбәсе рум чүпрәге белән капланган үтә бизәкле арба, хан кызы арбасы, арба янына һаман хатын-кыз агыла. Хатын-кызлар, гадәттәгечә, татар-төркиләргә хас чуар киемнәрдән, кызыл болгари итекләрдән. Итекләренә төрле чәчкәләр чигелгән. Ярата хатын-кыз матурлыкны — болгар татар-төркиләре бигрәк тә. Мөхәммәд ханга татар-төрки хатын-кызларының чуар киемнәре ошый — бала итәкле күлмәкләре дә, бер якка авыша төшкән алтын-көмеш җепләр белән укаланган калфаклары да. Хан кызының башында да шундый ук калфак, өстендә җиңелчә җиңсез алтын җепләр белән тукылган җилән, муенында сандугач күкәе хәтле генә гәрәбәләрдән җыелган муенса. Хан кызының кулларында көмеш беләзек, бармакларында җемелдәп торган зөбәрҗәт ташлы йөзекләр. Барысының да күзләре хан кызында. Яшь ич, гүзәл ич, сылу ич кыз. Хан кызы үзен ураган хатыннар белән сөйләшә, ә күзе чак кына арырак басып торган атасы ягында. Бит очар кошлар туган якларына әйләнеп кайтсалар да, кызларның бик сирәкләре, кияүгә чыкканнан соң, туган туфракларына аяк басалар, бигрәк тә хан кызлары, чөнки алар күп очракта чит ил ханнарына кияүгә чыгалар. Айгөле дә мәңгегә киткән кебек аерылышкан иде. Һәй, елады да мәрхүмә. Аңа карап Мөхәммәд ханның да күзләре яшь белән тулышкан иде. Бусы нигәдер бер дә сыкранмый, елмая-көлә, әле тегеңә шаяртып дәшә, әле монысына. Кыз янында, авызына керердәй булып, Рәшидә абыстай басып тора. Ул — баланы үстерүче, аңа дөньяви хәлләрдән белем бирүче. Әмма Айбиби аны тыңламый, күз карашы белән кемнедер эзли, тапмый булса кирәк, арба баскычына баса, аяк очларына күтәрелә. Аяк очларына басканда, хан кызының чигүле болгари итекләре күренеп китә, артык үрелеп карагангамы, башындагы калфагы кузгалгандай итә, хан кызы, кемнедер эзләвен дәвам итеп, калфагын җай гына төзәтеп куя, һәм янә атасы Мөхәммәд хан ягына күз ташлап ала.

Мөхәммәд хан кызына ияк кагып кына җавап бирә. Имеш, рәхмәт, кызым, сер бирмисең. Ә ханның уйлары әллә кайда. Ә бит Айбибине сорап, Өрәк елгасы буйларында җәйләгән баҗайлар ханы Түрә дә килгән иде, үзенә түгел, улына. Ике ай элек кенә булды бу хәл. Мөхәммәд хан Түрә ханны олылап каршы алды. Ислам динен яңа танып ята икән Түрә хан, башта Дала ханын шуның белән котлады Мөхәммәд хан. Ачык далада йөри-йөри ханның йөзе тутлаган, чәче көл төсенә кергән. Улының исеме-аты Айдар, диде. Матур исем. Исеме җисеменә туры килсә, ике дә уйламый биргән булыр иде егеткә Айбибиен Мөхәммәд хан. Һәм Түрә хан, яучы йөзендә килеп киткәч, шулайрак ниятләгән иде дә. Тик насыйп булмады кыз Түрә хан улы Айдарга. Кахан раввалары өлгеррәк булдылар. Әле булса күз алдында, Түрә ханның китүенә көн дә үтмәде дияргә була, Болгарга өерләре белән яһүд раввалары килеп төштеләр һәм, табынга утыруга, Мөхәммәд ханның Айбиби атлы кызын Йосыф кахан йортына тарттыру турында сүз башладылар. Һәм үтә кыю рәвештә, хәтта Мөхәммәд ханга авыз ачарга да бирмәделәр. Халык теленә баҗайлар дип кергән бөҗәнәкләр ханы Түрә белән бер-берсенә ярдәмләшү, теге йә бу явыз ният белән ил өстенә килгәндә, аркадаш булу турында да вәгъдәләшкәннәр иде югыйсә. Ләкин соңгы елларда биш анадан туган баҗай-бөҗәнәкләрне мәҗүси угызлар көнбатышка таба кузгаттылар, шул сәбәпле күпсанлы угызлар Хазарстан җирләренә кереп җәйли башладылар. Әмма угызларга кахан аркылы төште. Мөхәммәд хан кардәше буларак угыз ханына ярдәм дә итә алмады, каханга ярдәмгә гаскәрен дә җибәрмәде. Әмма каханга тиешле ясакны һәрдаим җибәреп торды. Әрсезләнеп киткән кахан Болгар халкыннан гаскәриләр таләп итә, ул гынамы, җиткән бер кызын сараена тарттыра башлады. Бабалары Алмас хан, мәрхүм, Хазар каханы кул астыннан чыгу өчен Багдад хәлифенә мөрәҗәгать итә, ахыр ислам динен дәүләт дине дәрәҗәсенә күтәрә, әмма хәйләкәр хәлиф Болгарга ярдәм акчасын җибәрә алмый, ә менә дине илгә ябышып кала. Ил вә халык инде күптән ислам диненә йөз тота. Вәләкин бүген Мөхәммәд ханга аркадашлар кирәк иде. Бик кирәк. Кара Болгарны, явыз рәвештә, Әскәр каханны үтереп, баскынчы варяг Хельг үз кулына төшерде. Ә бит ислам дине Кара Болгарга да кереп бара иде инде. Әнә шул баскынчы Хельгнең дәвамы бүген Дунай буе кардәшләрен туздырып йөри. Дунай буйларында көн күргән кардәшләребез мишәрләрне рәнҗетә. Шушындый буталчык чорда Мөхәммәд хан кемгә йөз тотарга тиеш?.. Каладыр бер кеше — Йосыф кахан. Яһүд раввалары кул астында ил белән идарә итсә дә, Йосыф кахан төрки җан, углан канында төркиләр каны ага иде. Димәк, Мөхәммәд хан яраткан кызын каханга биреп җибәреп дөрес эшли, хаталанмый.

Мөхәммәд хан янә-янә кызы утырып китәсе арба ягына күз ташлап ала. Аңа яраткан кызы елмаеп кул изи, шатланган кебек кылана, ә бит бөтенләйгә китә балакай, бөтенләйгә...

Соңарды, соңарды баҗайлар ханы Түрә, ике-өч ай алданрак киләсе калган сиңа. Хәзер соң инде, һични кылып булмый. Чарасыз иде Мөхәммәд хан. Туганые Талиб ничәмә еллар тәхеттә утырды, бер генә кызын да кахан йортына җибәрмәде, бер генә кызын да. Ә менә аңардан кахан кызлар таләп итә, ясак түләтү генә җитмәгән, кызларын да сараена тарттыра. Хан акылына сыя торган гамәл түгел иде бу. Бер-бер хәл булыр ул каханга, булмый калмас, әмма хәзергә Мөхәммәд хан сабыр итәргә, тешен кысып булса да, барысына да түзәргә тиеш. Бәхәссез, бу кызы да янәдән туган ягына әйләнеп кайтмаячак. Моны Мөхәммәд хан гына түгел, кызны озатырга килгән һәммәсе дә белә. Тик хан кызы үзе генә күрше ыстанга утырмага барган кебек кылана иде. Юри кыланамы бу бала, әллә булмаса ихтыяр көче олыданмы?.. Иңенә ишелеп төшкән кайгыны бар кеше дә яшерә белми, ихтыяр көче нык булган кешеләргә генә хас сыйфат бу. Әнә шул көчне күрде Мөхәммәд хан Айбиби кызында. Ялгышмаса, күңеле Хак Тәгаләдән ерак йөрмәсә, бу кызы апасына охшамас, бара-баруга каханга тышау салыр, иншалла. Димәк, кызның көлә-елмаюында нindидер сәбәп бар. Халык кына түгел, атасы Мөхәммәд хан да күреп бетермәгән сәбәп. Ни? Нинди сәбәп? Олуг сәясәткә йөз тоткан сәбәпме, әллә соң самими балалык халәте генәме?.. Тукта, тукта, кемне эзли бу кыз бала карашы белән?.. Күрче, Алпар йөзбаш янында торган табиб Хәбибулла улына кул изи ич бу бала! Йа Ходa, моны ничек аңларга инде тагын? Кичә үзе үк егет белән урман аша чыгып, Аккошлар култыгына чыгарга рөхсәт бирде ләбаса!.. Китәр алдыннан булса да җилләнеп кайтсын дип кенә җибәргән иде югыйсә. Әллә соң шул арада табиб Хәбибулла улына гашыйк булдымы кыз? Һич булмас димә. Яшьлектә була торган хәл ич! Менә монысы кирәкмәс иде. Мөхәммәд ханның бер дә Йосыф кахан белән бәхәскә керәсе килми иде. Әлегә кадәр шөкер итә, кул-аяк богаударак булса да, барысы да әйбәт кенә бара иде шикелле. Хан буларак ил-халкы белән ару гына идарә итә. Хак, як-ягына шайтаннар кебек кахан карачылары баскан, кайчак хәтта борылырга да бирмиләр, һәр адымын күзәтеп торалар. Әнә яраткан кызын да Түрә хан улына ярәшергә дә өлгермәде, көне белән диярга була, кахан раввалары калага килеп җиттеләр. Фәрманга каханбәк үзе кул салган. Имеш, Айбиби кызың үсеп-исәеп җиткән икән инде, син аны кахан кырына озат. Имеш, каханның кызны күрәсе килә. Күрәсе генә килсә бер хәл, кахан аны кырык беренче хатын йөзендә баш хатыны итмәкче. Ә кырык беренче хатын һәрдаим кахан кырында аерым тәхеттә утырачак. Хазарстан төркиләре арасына килеп, ил дилбегәсен үз кулларына алган яһүд раввалары үзләренә бер мәһабәт сарайда яши башладылар. Гарәпләр ул каланы ак кирпечтән күтәрелгәнгәме, Ай-Балда дип язалар, гади халык Аккала дип йөри. Ә гади халык — мөселманы, христианы, мәҗүсие — Иделнең сул ягындагы Ханбалыкта көн күрә. Шул исәптән кахан гаскәрбашы Сабир да шул калада утар тота, әмма аңа кахан кирпечтән өй

салырга рөхсәт иткән, калган халыклар исә өйләрне сәмәннән генә салалар. Сабир каханбәк тә яһүдә хатынга өйләнгәнгәме, балаларын кахан сарае мәдрәсәсендә укыта. Айбиби кызын Алпар йөзбашка озатырга тапшырып дөрес эшләде Мөхәммәд хан. Күр әле, йөзбаш кырында кара биягә атланган кем ул?! Сөбханалла, Хәбибулла улы лабаса! Шул үзе, кечә Айбибине Аккошлар култыгына алып төшкән егет. Инде нишләргә? Егетне алып калыргамы, әллә соң барысына да кул селтәп, һични кылмаскамы?.. Әйе, барысына да күз йомарга...

Шулчак Мөхәммәд ханның гүя зиһене ачылып китте: егетне атасы урынына җибәреп дөрес эшләде. Мин кызны исән-имин кахан раввaларына биреп җибәрдем, калганын Тәңремә тапшырам, ни язганы булыр. Шул уй башына килүгә, Мөхәммәд хан атына атланды һәм камчысын күтәрде.

— Кузгалырга, юлга! — дип кычкырды.

Иң алдан киң итеп ачып куелган кальга капкасына таба хан кызы арбасы кузгалды. Алпар йөзбаш үз яраннары белән капкадан чыгып ук бара иде инде. Хан кызы арбасы артыннан бер тотам калмый бирнә байлыклары төялгән олау кузгалды. Мөхәммәд хан иелеп, кара биянең ял астын сыпырды. Имеш, сабыр ит. Ат иясен аңладымы, бер мәлгә шым булды, юкса, олаулар кузгалуны күреп, хан аты тыпырчына башлаган иде. Шулай да яхшы ат буларак, иясенә канәгатьсезлек белдергәндәй, көмеш тәңкәләр тезгән иярен зеңләтеп алды. Кеш тиресе белән каймалган, аю тиресе салган иярдә утырган хан җан сакчысына:

— Аллага тапшырдык! — диде дә, атын җилле генә юырттырып, кальга капкасыннан чыгып китте.

Бары тик басу капкасына җиткәч кенә олау туктады, хан кызы арбасыннан төшеп, атасын көтеп алды. Мөхәммәд хан кызына җитә-җитүгә атыннан төште, ат тезгенен җан сакчысына ташлады да кызын кочагына алды.

— Кызым бәгырем, рәнҗеп китмә атаңа, зинһар, рәнҗи күрмә...

Ханның тавышы калтырап куйды, күзенә яшь пәрдәсе эленде. Мөхәммәд хан ни кылырга белми, бертын кызын кочаклаган килеш торды да, бераз тынычлангач, арба кырында басып торган шәехкә һәм абыстайга күз яшен күрсәтмәскә теләп булса кирәк, атына таба борылды һәм барыр җайда:

— Кузгалыгыз! — дип кулын күтәрде. Шул мәлдә хәтере аша бер вакыйгага узды. Сарай табибы Хәбибулланың улын беренче тапкыр сарайда күргәч, егетне ошатып булса кирәк, уенын-чынын бергә кушып: «Кияүләр үсә, Хәбибулла»,— дигән иде. Әмма табибы да югалып калмады: «Сәнең кызларың дөньяда бер гүзәллә рдер, хан. Хәер, чибәрләрне бакчада су сибеп үстермиләр, алар ханнар кочагын татыган гүзәл хатыннардан туалар»,— дигән иде.

Чибәр, сылу һәм үтә зифа сынлы Айбиби атасы Мөхәммәд күз каршында үсте. Бу балага, бу баланың сөйкемлелегенә, акылына, гүзәллегенә сарайда сокланмаган кеше юк иде. Айбиби бала чакта да, буй алгач та, җиткән кыз булгач та гүя сарай бакчасы гөле иде. Әнә шул бакча гөлен, ил бакчасы гөлен диярга була, Мөхәммәд хан Йосыф кахан кырына биреп җибәрде. Ни әйтте соң әле яраткан кызы Айбиби хан борылып киткәндә: «Юк-юк, атам, мин сиңа рәнҗемим, рәнҗемим»,— диде бугай. «Белеп кит, кызым, син ил гүзәле, ил мактанычы»,— дия-дия, атына таба кузгалган иде Мөхәммәд хан. Арбасына утыргач, кызы янә атасына кычкырды:

— Сау бул, атам, сау булыгыз, туганнарым, җанкайларым!..

Үзе атасы һәм халык белән саубуллаша, үзе елмая-көлә, йөзендә шатлык нурлары бии. Мөхәммәд хан кызын аңлады да, аңламады да. Хак, кыз бала сугым түгел, пычак астына алып китмиләр, әмма нигә алай шатлана, көлә-елмая кызы Айбиби?..

Ахыр чиктә, олау басу капкасыннан чыгып киткәч, капкага кадәр озата килгән Мөхәммәд хан тынычлана төште — соңгысын яхшыга юрады һәм Аллаһысына тапшырды, чөнки белә иде: барысы да — яманы да, яхшысы да бер Аллаһы кулында.

Мөхәммәд хан калага таба борылды, кайтыр юлда ул ике җан сакчысының берсенә бер кәлимә сүз дә әйтмәде. Кәефе кырылудан түгел, күз алдында торган кыласы хыяллары тормышка ашмаган өчен. Яратмады ул кырындагы Йосыф кахан шымчыларын, яратмады һәм бер тапкыр да алар белән ачылып сөйләшмәде, чөнки сөйләшер, киңәшер сүзе юк иде. Сатлык җан һәр чорда да сатлык җан булып калачак, хәтта теге дөньяга киткәч тә иблискә йөз тотачак ул адәм, ди торган иде атасы. Талиб хан чорында каханның бер генә шымчысы да сарай түренә узарга кыймады, чөнки Талиб хан аларны үтәли күрер, бер тапкыр да тәхет ягына уздырмас иде. Һәр илбашының сер сөйләрлек үз кешеләре була, ә сезнең белән минем боткам пешми, дип кенә әйтер иде. Ә бит баштагы мәлдә Хазарстан белән Идел буе Болгары тиңдәш рәвештә кушылганнар иде, еллар үтә-үтә каханат көчәеп китте һәм Идел буе Болгар дәүләтен үз канаты астына алды, ягъни вассалы итте. Үз вассалы итүгә үк хазар каханы әле ясакны арттырды, әле гаскәриләр сорый башлады. Бу инде каханатның узынуы иде. Ләкин кайчанга кадәр барыр бу узыну?.. Бәлкем, Хазар каханатына нәкъ менә Мөхәммәд хан тәхеттә утырганда нокта куелыр. Бик мөмкин ич, чөнки каханатка башка вассалары да баш бирми башладылар. Сукыр түгел, моны гына күрә иде Мөхәммәд хан. Заманында Мөхәммәд хан кан кардәшләре бөҗәнәкләргә өмет иткән иде, барып чыкмады, күчмә халык буларак, көчәеп килгән угызлардан куркып, көнбатышка таба күченделәр. Бөҗәнәкләрнең җәйләүләрен угызлар биләделәр. Хазарстан яһүдләре, сөннәтле казакларга таянып, угызларны

ил-җирләренә кертмәскә иткәннәр иде, тегеләр сорап та тормадылар — виноград бакчаларына кадәр таптап уздылар, әйе, өермәдәй. Сөннәтле казаклар, каханны ташлап китеп, кара урманга кереп постылар. Һәм угызлар киткәч, шуннан торып, каханга хезмәт күрсәтә башладылар. Кара урман эчендә үзләренә кала күтәрделәр, хәтта Идел буе Болгары белән сәүдә итә башладылар. Бу хәлдә, әлбәттә, поскан сөннәтле казакларга яһүд сәүдәгәрләре ярдәмгә килделәр. Ә Болгарга килеп оялаган гарәп имамнары угызларны мәҗүсиләргә саныйлар, алты мең еллар төркиләр табынган Тәңрене мыскыл итүгә кадәр барып җитәләр иде. Сараена кереп оялаган имамнарның бу хәле дә Мөхәммәд ханга ошамый иде. Әмма кала-салаларга мәчетләр күтәреп, иртәнге якта азан әйтә башлаган имамына кагылудан куркып, баш-баштаклыкларын күрсә дә, күрмәс булды. Имамнар гына түгел, Йосыф кахан яһүдләре дә аның һәр адымын күз угында тоталар иде. Мөхәммәд хан Айбиби кызын Йосыф каханга үзе кодалады. «Кызым, кызыкаем, сине анда хөрмәт итәрләр, кахан сине күрү белән гашыйк булыр, сине беренче көннән үк баш хатыны итәр. Тора-бара акыл белән эш итсәң, син каханның уң кулы булырсың, хәтта ил белән идарә итә башларсың. Чөнки борынгы бабаларыбыз «Хатын ир белән, ир ил белән идарә итә» дигәннәр». Күрде ич, Айбиби кызы моңа бер дә гаҗәпләнмәде, ничек кирәк, шулай кабул итте. Кыз гүя үз сәләтенә вә көченә ышана иде. Моны күреп Мөхәммәд хан: «Бирсен Ходай»,— дип кенә әйтә алды. Шул ук вакытта әрнүле бер кимсенү тойды — икенче кызын озата бит инде. Ай, бичара, каханга углан бала таба һәм баласына күкрәк сөтен дә бирә алмый вафат була. Бусы белән ни булыр?.. Айгөл кызының улы исән кала, баланы тәрбиягә Йосыф каханның анасы Сара ала һәм ни сәбәпледер Аккаладан Таман тархан төбәгенә күчеп китә. Углан кан кардәше Гали тархан карамагында үсә. Аты Гаязетдин, диделәр. Угланны һәм әбисе Сараны Мөхәммәд хан Болгарга да дәшеп караган иде, әмма анакай: «Балигъ булгач та, балигъ булгач та»,— дип әйтеп әйткән дип ирештерделәр Мөхәммәд ханга.

Мөхәммәд хан Хазарстан каханының канат астына хатыннар җыю гамәле белән килешмәде. Киявенең бу гамәлен кыргыйлыкка, гафиллеккә кайтарып калдырды, гәрчә үзе мөэмин-мөселман буларак, өч-дүрт хатын белән торырга хаклы булса да. Тик ислам диненең бу чарасы белән дә килешеп җитмәде Мөхәммәд хан. Ләкин ул идарә иткән халык, халыкның тоткан дине ислам дөньясы кануннарына йөз тотарга мәҗбүр иде. Ни генә булмасын, Мөхәммәд хан өчен мең еллар элек кагыйдәләштерелгән йолакагыйдәләр, тәртипләр, кануннар бүгенге көнгә кадәр үз көчендә кала аламы? Ә бит кешелек һәрдаим тәрәккыяткә омтылган һәм шунда ихласи хакыйкать тапкан. Әйтик, ничек аңларга Мөхәммәд пәйгамбәрнең: «...кемнәр хак юлга керәләр, алар минем карендәшләрем булыр, кемнәр исә каршы төшәләр, алар минем дошманнарым булырлар»,— дигән сүзләрен? Моны ничек аңларга, ничекләр моны башка дингә табынган халыкларны дустанә-тату яшәргә өндәргә? Хазарстанга кылыч белән ислам динен китергән Мәрван сәргаскәр гамәле беләнме? Кан коеп. Кяферләр, имансызлар ич дипме?! Тарихта билгеле, соңрак Хазарстанга яу килгән сәргаскәр Маслама Биләмҗир каласын ала. Кан кою шул чиккә җитә ки, ир-ат әсирләрне вә үсмер ир балаларны кылычтан уздырта, әсирләр үтә күп булу сәбәпле, меңнәрчә кешене Сулак елгасына батырып үтерергә әмер бирә. Шушы кешеме ислам дине варисы?! Бу буладыр милади белән 723 елда. Багдад хәлифе милади белән 735 елда инде картаеп килгән сәргаскәр Масламны янә Хазарстанга яу җибәрә. Хәлиф сәргаскәре башкаланы ала, кахан далага кача. Сәргаскәр Маслама каханның гаиләсен вә куштаннарын әсир итә һәм каханга шарт куя: ил-дәүләтең белән үзең идарә итәсең, гаиләң-куштаннарың да кайтарырмын, тик ислам динен генә кабул ит. Кахан риза була. Маслама шундук далага качкан каханга үзенең имамнарын җибәрә... Әлбәттә инде, ислам дине әкренләп каханның аркадашы булган Идел буе Болгарына да үтеп керә. Бары тик шул гына. Ләкин бит дин аркасында Болгардан йөзләрчә гаилә башка илләргә күчеп китә. Болгар дәүләте өчен бу да зур югалту була. Мөстәкыйль Болгарны кул астына алгач, вассал йөзендәге ханга Йосыф кахан яучылары Мөхәммәд ханга Айбиби кызы өчен алтын таулар вәгъдә иттеләр. Мөхәммәд хан моңа ышанды да, ышанмады да. Империя куәтенә ирешкән Хазарстан үз кулы астындагы ил-халыкларга вәгъдәләр биргәләде инде, вәләкин берсен дә үтәмәде, барысы да ялганга корылган булып чыкты. Кахан исеменнән Болгарга ташламалар ясарга вәгъдә иткәндә, Мөхәммәд хан яучы раввакларга бер сүз дә әйтмәде, яучыларны рәнҗетүдән түгел, ә вәгъдәләрнең үтәлми калуын яхшы белгәнгә дәшмәде ул. Бары тик ирен чите белән көлемсерәп кенә алды. Тарихта булган хәл, Хазар каханы 922–923 елларда Ханбалыктан мөселман сәүдәгәрләрен куа. Алар олау-олау Идел буе Болгарына күчеп киләләр. Алмас хан исә аларга каладан урын бирә — Ага Базардан. Болгар халкы өчен кулай гамәл иде бу. Тик күп тә үтми, Хазар каханы Харәзем сәүдәгәрләрен Идел буе Болгарына уздырмый башлый. Бу хәл исә Мөхәммәд ханны янә кыен хәлгә куйды.

Харәзем аша Идел буе Болгары базарларына чиннар гына түгел, фарсы-согдиан һәм гарәп сәүдәгәрләре кәрваннары да киләләр, аларның күбесе хәтта Казан төбәгенә хәтле узалар иде. Бәлкем, Айбиби кызы Йосыф кахан кырына барып җитеп, каханның баш хатыны булып киткәч, раввалар Харәзем сәүдәгәрләрен дә Болгарга уздыра башларлар. Бу хакта Мөхәммәд хан, җай китереп, Айбиби кызына да читләтебрәк булса да әйткән иде.

Сарай-кальга капкасына җитәрәк, асма күперне төшергән арада, Мөхәммәд хан үзенә таба чаптырып килүче җайдакны күреп, атыннан төште һәм, ат тезгенен җан сакчысына ташлап, җәяүләп асма кү-

пергә таба китте. Килеп җитәр-җитмәс, хан кальгага кереп китәр дип булса кирәк, җайдак кычкыра ук башлады:

— Олуг хан, олуг хан!

Мөхәммәд хан туктады, җайдак исә, килеп җитәр-җитмәс, атыннан сикереп төште һәм, хан янына йөгерә-атлый килде дә, бер тезенә төште.

— Йә? — диде аңа Мөхәммәд хан.— Әйт әйтер сүзеңне!

— Ханиям, Дунай Болгары кардәшләрдән Пәхлеван ханның улы Шәмгун басу капкасын кереп ята. Углан Болгарга зур йөк белән килә, Сез, галиҗәнаплары каршына.

— Сөенчеме, көенчеме китерә углан?

— Ханнар сере — Аллаһы середер, ханиям. Сөенечен дә, көенечен дә үзе җиткерер.

— Зур йөк белән, дисең,— диде Мөхәммәд хан һәм җан сакчысына атын китерергә ишарә ясады.— Пәхлеван хан христиан динен кабул итеп ята, дип ирештерделәр миңа, димәк, улы ул диннән йөз чөергән, атасы белән килешмәгән,— дия-дия, сөенче китерүчегә бөтенләй игътибар итми, атына атланды да, күпергә таба кузгалды хан. Пәхлеван кардәшенең христиан динен кабул итүе Мөхәммәд ханга ошамады, ләкин ул моңа ышанып та җитмәде. Ата-бабаларыбыз гасырлар буена табынган Тәңре диненә хыянәт иткән үз бабаларына да рәнҗүле иде Мөхәммәд хан. Бит Тәңре дине дә күктәге Тәңре Алласы аша гаделлекне эзләгән. Аллаһыны да имамнар күктә дип расларга тырышалар. Мөхәммәд хан бу ике диндә һәрдаим уртаклык эзләде һәм күп очракта кайбер кануннары тәңгәл килүгә кинәнер дә иде. Христиан динен кабул иткән төрки туганнары исә бер Аллалыктан баш тартып, үзләренә Иисус Христос язмышы хикәятен уйлап таптылар һәм әнә шул пәйгамбәрне өч йөздә күрә башладылар. Әнә шулай Византиянең епископлары, императорлары Аллаһының җирдәге илчеләренә әверелделәр. Бу хакта да яхшы белә иде Мөхәммәд хан. Тик менә буласы кияве Хазар каханы уздырган сәясәтне генә аңлап бетерми иде. Әмма күп очракта аның белән дә килеште, бер халык ич. Чөнки раввалар урап алган кахан үз илендә диннәргә ирек биргән, әйе, элегрәк бу гадәти хәл була, вәләкин заманалар үзгәрә ич, кахан да, гәрчә үзе төрки телдә сөйләшсә дә, яһүдләр диненә өстенлек бирә башлый. Бусын инде Мөхәммәд хан үз күзе белән күреп торды. Әмма янә гөнаһка санамады, чөнки кахан һәм раввалар Аккала дигән сарай-утрауга кереп бикләнсәләр дә, үзләренә буйсынган халыкларга үз диннәрен көчләп такмадылар, ә бит христиан руханилары, шул исәптән мөселман руханилары да диннәренә түндерү өчен кылычка ябыштылар. Кая монда гаделлек?! Гаделлектән ерак хакыйкать иде бу. Иллә хан буларак ул ил халкыннан аерыла алмады, аерылырга да теләми. Димәк, кардәшен якларга Мөхәммәд хан дөрес кузгалды.

Әнә шундый уйлар узды юлда барганда Мөхәммәд хан башыннан. Бүген һәр халык, үз диненә таянып, үз кыйбласын сайлый. Ахыр килеп, кайсы дин хакыйкатькә якын торып, яши-тора өстен чыгар — бер Аллаһы үзе белсә беләдер.

Әле булса хәтерендә, бу юлдан бик күп төрки кавемнәре көнбатышка таба кузгалган. Булган шундый чорлар да. Булган. Алмас ханның оныгы Арпат, мажарлар кавемен җитәкләп, көнбатышка таба юнәлә. Ерак бабаларының җирләренә барып утырырга итә. Тик менә ни өчендер Арпат углан үзләренең кардәшләре Дунай буе Болгарына ябырыла, илбашы Сәмигъ ханны елганың уң ягына чигенергә мәҗбүр итә. Бу хәлгә аны Византия императоры котырткан, дигән фаразлаулар да бар барын. Ахыр чиктә Дунай буе Болгар ил-халкын талагач, Паннониягә юнәлә, әмма мин монда төпләндем инде, дип, халкын Дунай буенда калдыра. Чигенсә дә көч-куәтен югалтмаган кардәше Сәмигъ хан көтмәгәндә мажарларның елга буенда калган халыкка ябырыла. Ил-халыкларын сакларга калдырган гаскәриләрне тармар итә, әсир ителгән бала-чагаларны Арпат хан талап киткәннән соң ялгыз калган ир-егетләренә өләшә, бик күпләрен кол итеп, Византиягә илтеп сата. Әнә шулай үч үчкә илтә, кардәш халыклар кардәш халыклар белән сугыша, ә моның нигезендә Византия императоры сәясәте ята: «Бүлгәлә, үзара ызгыштыр һәм идарә ит». Гаскәр белән Паннониядән әйләнеп кайткан Арпат хан таланган ил-җирен күреп, кире борынгы бабалары Аттила хан нигез салган Гунстанга (бүген Будапешт) таба борыла. Ил-халкын югалткан Арпат хан каны кайнаудан юл өстендә яткан Мравия илен талый, ир-атларын үтереп, хатын-кызларын үзе белән алып китә. Менә нишләткән империя сәясәте бертуган халыкларны, гасырлар буена бертугандай күрше-шабра булып яшәгән мажар-төрки халыкларын...

Яуга чыгар алдыннан алай да, табын җыйганчы ук, Мөхәммәд хан углан Шәмгунны кабул итәргә булды. Ни әйтсәң дә, бер анадан туган халыклар ич. Шәмгун углан әйткән вакытка килеп тә җитте. Мөхәммәд хан һәр мөселман түрәсенә хас садәлек белән аны тәхетеннән торып, хәтта аңа таба ике-өч адым ясап ике куллап күреште һәм бер читкә куелган өстәлгә урын күрсәтте.

— Исән-имин килеп җиттегезме, углан?

— Шөкер кылам, шөкер кылам, кардәшем. Мин Идел буе туганнарым хозурында булуыма бик шатмын. Миңа юлда ук ирештерделәр, Айбибине кахан үз кырына тарттырган икән.

— Тарттырды,— диде Мөхәммәд хан, кымызчыга касәсен сузып.— Тарттырды, Шәмгун углан, тарттырды. Кызны үз ризалыгым белән биреп җибәрдем. Айбиби дә сынатмады, бер дә аһ ормады.

— Минем атам Кияли кенәзе Сарманай белән ызгышып ята. Византия империясе безгә ясак түлисе иде, шул ясакны үзем җыям, бу төбәктә үзем түрә булып калам, дип оран салды.

— Үзе генәме? Бөҗәнәкләрнең ялланып сугышулары бер бүген генә түгел, алар минем аркадашым угызларга да кахан белән бергә каршы чыкканнар иде. Угызлар үзләрен Өрәк елгасына кадәр кудылар, Өрәк елгасына кадәр, углан. Кһм, димәк, син, углан, Идел буе Болгар ханыннан ярдәм сорарга килдең?

— Атам христиан динен кабул итмәде, хан, булмады ул хәл. Мин сездән ярдәм алырга килдем, гаскәриләр сорарга! Атам әйтте, Мөхәммәд хан каханга да баш бирми ята, иншалла, ярдәм кулын сузар.

— Алай-алай,— диде Мөхәммәд хан.— Кыюсың, углан, артыгы белән кыюсың. Мин үзем дә кеше кешесе ич, минем өстән кахан раввалары күзәтә, җитмәсә, икенче кызымны Аккалага биреп җибәрдем. Хуш, углан, тоткан динең нә соң?

— Тәңребездер, хан, Тәңребездер. Калагызны күрдем, хан, хозурдыр кала, кая карама мәһабәт биналар, мәчетләр вә мәдрәсәләр. Туганкай атам сезне көтә, сезне!

— Мәнем нә якын кешем юк, нә тәхет йөген күтәрерлек угланым, Шәмгун углан. Идел буе Болгары илен якларга кем калыр соң? Мин атаңа ярдәмгә кузгалсам дим?..

— Мин, Мөхәммәд хан, мин!

Мөхәммәд хан авызына китергән касәсен өстәлгә куйды, башын кырын сала төшеп, Шәмгун угланга карады, текәлеп дияргә була, хәтта сынап, ышаныр-ышанмас бер караш белән.

— Күрәм,— диде, ниһаять, Мөхәммәд хан.— Зиһенең саф, акылың үзең белән. Бихуш! Тик бит син әле мәҗүси, мәҗүси, углан.

— Мин иртәгә үк ислам динен кабул итәм, хан, иртәгә үк. Сарманай кенәз узынды, бабалары кәсебен дәвам итәргә кереште. Әле бер халыкка яу йөри, әле икенче халыкка. Хәтта Патшакаланы үзенеке итмәкче. Тик бит яман кенәзнең юл өстендә без ятабыз...

— Сарманай кенәзгә кахан да ачулы, ишеткәнем хак булса, ул да Сарыкалага төнлә яу килгәне өчен кенәзне акылга утыртмакчы. Мин дә шул тарафларга кузгалсам...

— Безгә берләшергә кирәк, хан, бергә булырга! Атам сезне көтә, хан, сезне!

— Аксакаллар ни әйтер бит әле, углан, аксакаллар...

— Алар да килешерләр, хан, алар да килешерләр.

Мөхәммәд хан янә бер тапкыр сәерсенеп карап алды угланга.

— Әйе, мин барысын да көткән идем синнән, углан, әмма...

— Мин үзем белән атамның барлык байлыгын алып килдем, хан, барлык байлыгын, кызларыбызны да, асыл егетләребезне дә. Сарманай кенәз бездә берни дә таба алмас, берни дә...

— Ә картлар, ә халык?! Халык, туганый?!

— Менә шул халыкны коткарырга чакырып килдем дә инде мин сезгә, хан. Баш иеп, атамның барлык байлыгын төяп.

— Хөрмәтеңә рәхмәт, углан.

— Барысына да император гаепле, хан. Үзеннән ясак түләтеп яткан атам өстенә Сарманай кенәзне җибәрмәкче. Яу йөрү өчен Сарманай кенәзгә илчесе Калакир аша унбиш кадак алтын җибәргән. Ә теге башкисәр кенәз, шул алтынга алданып, үз күршеләренә яу йөрергә җыена. Император Никифор Фоке да бер дә ышанычлы һәм сүзендә тора торган кеше булмады. Бердәнбер өмет сездә, хан.

— Мин кеше кешесе ич, углан, бу яуга Йосыф кахан аркылы ятса?!

— Тәхеттә түгел, Идел буе Болгарын сакларга мин калам, хан. Сез юлга чыгуга ук, мин каханга бер генә кеш тиресе дә җибәрмәячәкмен. Каханга ясак түләү, гомумән, булмаячак.

Шәмгун углан шулай диюгә, Мөхәммәд хан бу егеттә Аттила бабаларының горурлыгын һәм кыюлыгын күреп, аркасын турайтыбрак утырды һәм көлемсерәп куйды. Яшерми, ошады аңа Шәмгун углан. Һәм бар ягы белән дә. Ләкин кешене вә батырлыкны орыш кырында сыныйлар, чәй өстәле янында түгел. Моны да яхшы белә иде Мөхәммәд хан. Шуңа карамастан ул иртәгә үк табын җыярга булды.

— Яхшы, углан. Мин синең киңәшең тотармын. Ахыр чиктә угызлар белән мин солыхта, бертуктаусыз кызлар алышып вә бирешеп торабыз. Ә Йосыф каханның үз кайгысы үзенә бик җиткән. Ул да император Никифор белән Сарманай кенәзне акылга утыртмакчы, нинди юллар белән, миңа хәбәр итмәде, мин белмим. Иң мөһиме, безнең максатлар бер, углан, максатлар — узынганнарны урыннарына утырту...

Мөхәммәд хан вәгъдәсендә торды, яу олавын вә гаскәриләрен тиз җыйды. Табынга җыйган аксакаллары да, кардәшләре булгангамы, Дунай буендагы кардәшләре дәшкәнгәме, берсе дә каршы килмәде, бары тик башына тавык оясы кадәр чалма ураган имам хәзрәтләре генә:

— Углан имандамы соң? — дип сорады.

— Углан мөслим-мөселман, имам хәзрәтләре, мөслим-мөселман,— диде. Хан кадәр хан шулай дигәнгәме, табында бу хакта яңадан сүз кузгатмады.

Атна дигәндә җыенып, кул астына ике төмәнгә якын гаскәри туплап, юлга кузгалгач кына, ил идарәсен Пәхлеван хан улы Шәмгунга тапшырып, имамнан фатиха алгач кына, Мөхәммәд хан тынычлана калды — нәкъ менә юлда, ат өстендә барганда соңгы айда булган хәлләргә, кылган гамәлләренә исәп-хисап бирә башлады. Кем алдында? Әлбәттә инде, мөэмин-мөселман буларак, Аллаһысы алдында, күзгә күренмәгән, әмма һәрдаим аның күңелендә булган Аллаһы алдында...

### III

«Мин Идел елгам белән саубуллашам, мин туган туфрагым белән саубуллашам, мин аккошлар кебек туган якларыма кайтырмын, кайтырмын»,— дия-дия үз-үзен юатты Айбиби каладан чыгып, олы юлга төшкәч. Алпар яугирләре чак кына алдан баралар, күк йөзендә күңел өчен генә булса да бер болыт кисәге дә юк. Аны хәтта болытлар да озатмый, димәк, бу аның язмышы. Тик үзе сайлаган язмыш түгел, Йосыф кахан сызган язмыш. Идел тамагындагы утрауга урнашкан Аккалада илбашы булып торган Йосыф кахан кем аңа да, сарай табибы улы Ислам кем аңа?.. Әнә шулай уйлана-уйлана Айбиби сиртмәле арбада йокымсырап китте. Колак барысын да ишетә, юк-юк та арбалар шыгырдавы колакка килеп ирешә, кемнәрдер көлешәләр, шунда Айбиби колагына җыр моңы килеп иреште...

Хан кызы, ач ишегең, мин керәем,
Сине зифа буйлы, диләр, мин күрәем.

Айбиби сискәнеп китте, һәм хәтта торып ук утырды, үзе дә сизмәстән тыенкы гына җырчыга җавап бирде:

Минем буем зифалыгын син белерсең,
Сазлардагы сары камышларга күз ташласаң...

Җыр иясе хан кызын ишеткәндәй дәвам итте:

Хан кызы, ач ишегең, мин керәем,
Кашкайларың кара, диләр, мин күрәем.

Айбиби, үзе дә сизмәстән, аңа җавап бирде:

Минем сачем каралыгын килсә беләсең,
Базарларда кара ефәк күргәнсеңдер...

Җырчы ары таба дәвам итте:

Хан кызы, ач ишегең, мин керәем,
Синең кашың кара, диләр, мин күрәем.

Айбиби җырчының сүзләренә янә җавап тапты:

Минем кашым каралыгы нидән димсең?
Шагыйрьләрдә кара каләм күргәнсеңдер...

Җырчы туктады. Айбиби ни кылырга белми түбәсе ябык сиртмәле арбаның япмасын ачып карады. Һәм арба артыннан атын атлатып кына барган Исламны күрде дә, шатлыктан түзәр әмәле калмагач, ат караучысына арбага бәйләгән атының тезгенен чишәргә һәм арба кырына китерергә кушты. Егет шундук атның тезгенен малкайның муенына ташлап, арба кырына китерде, Айбиби арбадан ук атка атланды. Хан кызының атка атлануы булды, аның янына бер уч дала әреме тоткан ат менгән Ислам килеп җитте, алар күзгә-күз карашып алдылар. Менә шунда егет белән кыз йөрәкләре белән сөйләшеп алдылармы, икесе дә атларын далага юнәлттеләр. Хан кызының өрфә яулыгы җилферди, күлмәге күпергән, аның артыннан ат муенына ята төшеп, сарай табибы улы Ислам элдерә. Ул арада хан кызының ачык далага чыгып чабуын кахан сакчылары күрделәр, раввалар кычкырыша башладылар. Кахан сакчыларының йөзбашы булса кирәк, Алпар йөзбаш янына чапты, барып җитүгә, камчысы белән ачык далага чыгып чапкан хан кызына таба күрсәтте.

— Кайтырлар,— диде аңа йөзбаш.— Кайтырлар, борчылма. Бераз җилләнерләр дә кайтырлар.

Әмма Алпар йөзбашның соңгы сүзләрен ишетмәде бугай кахан сакчысы, артыннан килеп җиткән ишләре белән егет белән кызны куа китте.

Йөзбаш Алпар янына ат менгән өч равва килеп туктады.

— Кем җибәрде хан кызын, Алпар йөзбаш? — дип кырт сорады баш равва. Равва йөзгә алышынган, кипкән иреннәрен кыскан, күзләре кахан яугирләре киткән якта.

— Мөхтәрәм равва,— диде Алпар йөзбаш, баш түбәсен генә каплаган равваның чәпләшкәсенә күз ташлап.— Кайтыр хан кызы, бераз җилләнеп киләсе килгәндер.

— Кайтмаса?! — дип сорады равва, кырыс төстә.

— Мөхәммәд хан йөзбашы кыз өчен башы белән җавап бирәчәк, равва, башы белән...

— Һы,— диде равва һәм, түш кесәсеннән кульяулыгын чыгарып, шаулатып борынын тартты.— Хан йөзбашы хан кызы арбасыннан күзен дә алмаска тиеш.

Ул арада инде каханның яугирләре егет белән кызны борып китергәннәр иде.

Өлкәнме, баш раввамы әүвәл хан кызына, аның муенына уралган өрфә зәңгәр яулыгына һәм гүзәл мөлаем йөзенә карап алды, ахыр карашын Исламга күчерде, равваның ни соравын белгән кебек, хан кызы әүвәл яулыгын рәтләп башын бәйләде, күзләрен генә калдырып, йөзен каплады, шуннан соң гына тыенкы гына сорады:

— Ни булды, равва? Нигә бу шау-шу?

— Кем бәендә бу егет? — дип сорады равва.

— Минем бәйдә, равва,— диде аңа Алпар йөзбаш.

— Бу егет минем табибым, аңа шикләнеп карамасагыз иде, равва,— диде хан кызы һәм атын арбасына таба бора башлады.

Равва йөзбаш Алпарга күз ташлады һәм кырыс кына:

— Йөзбаш Алпар, егет сезнең бәйдә икән, сезнең бәйдә булсын, хан кызы тирәсендә уралмасын! — диде боергандай һәм китеп тә барды.

— Ишеттеңме? — диде башын түбән иеп ни әйтергә белми торган егеткә йөзбаш Алпар.— Син ут белән уйныйсың, сарай табибы улы Ислам, ут белән!..

**IV**

Хәрбиләр кулына күчкән хакимият, телиме моны, теләмиме, тора-бара сугышка йөз тота башлый — яу йөрү, сугыш аның төп максатына әверелә. Йосыф кахан ашыкты, нәрсәгә генә тотынмасын, өлгермәм дип курыкты. Яу чыкканда барысын да исәпкә алып, барысын да алдан күреп эш итәргә кирәк. Империя буларак Хазар каханаты кул астында дистәләрчә халыкларны тота, аларга чамалы гына ясак сала, ә инде баш бирмәүчеләрне сабырландырырга шул тарафларга яу кузгала, куәтен күрсәтә иде. Бу хәл һәр ел кабатланмаса да, шактый еш булгалый иде. Ни сәбәпледер Йосыф каханның әлегә хәтле төшенә алганы юк, аның кул астына кергән һәр халык мөстәкыйльлеккә, бәйсезлеккә омтыла, ул гынамы, ташламаларга йөз тота, хөрриятькә өмет итә. Ә Йосыф кахан моңа бара алмый, чөнки халыкларны бәйдә тоту өчен аңа көчле гаскәр кирәк, гаскәр өчен исә гаскәрбашлар акча таләп итәләр. Акча җыю гомум керемнән тора, халыклардан кергән ясактан, сәүдәгәрләрдән җыйган салымнан. Канат астына бабалары җыйган халыкларны күз угыннан ычкындырмас өчен, Йосыф кахан һәр илдә шымчыларын тота. Алар теге йә бу илдә барган сәясәт турында каханга һәрдаим хәбәр итеп торалар. Бу гаять җитди мәсьәләне империядә, нигездә, раввалар хәл итә. Теге йә бу халык баш калкыта башласа, Йосыф кахан Византия императоры кебек гаскәре белән баш калкытучылар өстенә ташланмады, раввалары аша ул халыкка ташламалар ясады, түрәләренең гүзәл кызларын сараена тарттырды.

Бу хәл үзенә күрә империя канаты астына кергән түрә белән кардәшләшү иде. Бу чараны аның бабалары да кулланган һәм Йосыф кахан да читләтеп үтә алмады. Әйтик, заманында көчле вә куәтле булган Идел буе Болгары ханнарының кызларын Аккалага тарттыру күптән инде сәяси вә кардәши гадәткә әверелеп киткән иде. Идел буе Болгары аша империягә затлы тиреләр ага, бакыр-тимер, иң мөһиме, гаскәри егетләр. Болгар төркиләренә сөннәтле казакларга өйрәткән кебек тел өйрәтеп торасы юк иде, шул исәптән бөҗәнәкләргә дә. Хак, Йосыф кахан беркайчан да сөннәтле казакларга ышанып җитмәде. Акчаны вакытында түләмәгәндә, сөннәтле казаклар сакларын ташлап китәргә дә күп сорамыйлар иде. Диннәре аша Йосыф кахан аларга тәэсир итә алмады. Христианнар христиан булып калдылар, мөселманнар — мөселман, мәҗүсиләр — мәҗүси. Вәләкин каханнар тарафыннан борын заманнардан ук өстенлек яһүд диненә бирелә килгән, Йосыф кахан да бу канун-гадәтне бозарга теләмәде. Шул ук вакытта ил белән идарә итүне үз кулларына ала барган раввалар да эчен пошыра башлаганнар иде. Җитмәсә, раввалар коточкыч хәйлә уйлап тапканнар — каханны ефәк бау белән буып сорыйлар. Имеш, тагын ничә ел хаким булып торасың?.. Бу коточкыч чараны күптән белсә дә, моңа кадәр Йосыф кахан бу хәл-чарага игътибар итмәгән иде, кырык яше якынлаша башлагач, ул кинәт кенә уйга калды: ә бит аны да раввааларның ефәк бау белән буып сораулары бар. Бу яман гадәтне туктату өчен нишли ала ул?! Шул хакта киңәш-сабак сорап, Испаниядәге кардәше Хасдай ибн Шафрутка да хат язып карады, әмма хәйләкәр кардәше хаттагы ул юлларны гүя укымагандай каханның бу соравына, гомумән, җавап бирмәгән иде. Хак, Исраилдән килгән вә чакырылган раввалар Хазарстанда синагоглар, мәдрәсәләр салдылар, яһүдә хатыннардан туган балаларны Талмудка, Мишәгә тугры калырга укыттылар. Бу чараларны үз чорында Булан кахан кертеп калдыра. Аның хакында тарихчылар: «Ул гадел, тугры хаким булган»,— дип язып калдырганнар. Ә мөселман имамнары аның хакында: «Ул Аллаһыдан курыкты, ил кануннарын саклады, яшәү рәвеше итеп борынгы бабаларыбызның васыятьләрен үрнәк итеп алды»,— дип язып куйганнар. Шуңа карамастан бу чорда каханат авыр көннәр кичерә. Ни сәбәпледер 922–923 елларда көчәеп киткән раввалар Биләмҗирдән мөселманнарны куа башлыйлар. Хәер, бу хәлләр элегрәк тә булгалаган. Әйтик, 910 елларда кахан сарайдагы имам Шәмси Тәбирне куа. Олуг имам белән йөзләрчә мөэминнәр Киялигә күчеп китәләр, Айдар хан канаты астына. Менә кайчан Кияли каханаты көчәя башлый.

Болгар төркиләренә ияреп, Киялигә гарәп миссионерлары, сәүдәгәрләре, һөнәрчеләре юнәләләр. Киялидә мөселманнар колониясе барлыкка килә, кахан белән килешеп, гарәп-төркиләр үзләренә баш гарәп сайлыйлар. Идел буе Болгарыннан Киялигә таба зур сәүдә юлы ачыла. Киялидә кахан белән килешеп, акча суктыра башлыйлар. Бу хәлгә Хазар каханының да эче поша башлый.

Әмма норман короле Хельг хәйлә юлы белән Киялине кулына төшерә. Хазар каханы моның өчен аңа рәхмәт укымый укуын, мәгәр әмер-үтенеч кебегрәк фәрман белән илчеләрен Киялигә җибәрә: «Мөселманнарга каршы берләшик, ә мин сиңа ясак салуда ташлама ясармын». Канунг Хельг хазар каханы белән килешә. Әнә шулай канунг Хельг хазар каханы үтенече белән мөселман илләренә яу артыннан яу йөри башлый. Ләкин баскынчы варяг үз йөзендә кала — элек Хазарстанга ясак түләп яткан кайбер халыкларны канат астына җыя. Хак, канунг Хельг хазар каханы алдында аклану йөзеннән милади белән 912, һәм 919, һәм 922 елларда Хазарстан аша һәм кахан рөхсәте белән Хазар диңгезенә чыгып, Күрә елгасы буйлап гарәпләрнең Барда башкаласына ябырыла һәм бик күп байлыкларын талап, кире борыла. Бу хәл хакында гарәп сәяхәтчесе әл-Масуди дә телгә ала. Ләкин Йосыф кахан тәхеткә менгәч, барысы да үзгәрде. Баскынчы Хельг Киялидән куылды, Идел буе Болгарында үлемен тапты. Ил тәхетенә канунг тарафыннан үтерелгән Әскәр каханның оныгы Әнвар утырды. Йосыф кахан аңа көне белән илчеләрен җибәрде — ясак таләп итте. Әмма нишләмәк кирәк, Кияли каханы тәхеттә озак утыра алмады. Ясакчы германлылар аны үтерәләр. Тәхеткә хатыны Ольга менә. Ольга үлгәч, ил башына аның улы Святовит килә, ягъни Сармалай Мәҗүси кахан Хазарстанга бөтенләй баш бирми башлый. Менә кем ачуын китерә иде Йосыф каханның, менә кемгә тәхеткә килә-килүгә теш кайрый башлады ул.

Ләкин Йосыф каханның бүген сәясәт турында уйлыйсы килми иде. Ул Мөхәммәд ханның гүзәл кызын көтә. Яңа көн тууга, Йосыф кахан хан кызына юлда ул-бу булмагае дип, үз кырына сөннәтле казакларның атаманы Кушбугазны чакыртты. Кирәкмәгән калын тавышлы Кушбугаз кушаматын алган атаман килеп кергәч, ул аны кече өстәл янына дәште, бармак шартлатып кына бавырчысына кымыз китерергә кушты, ләкин Кушбугаз ике кулын күтәрде.

— Минем аш түгел ул, галиҗәнабым, минем аш түгел. Минем кымыздан сару кайный, эч күбә. Миңа грек шәрабы килешә төшә,— диде.

Грек шәрабын кунакка көмеш кубокны тутырып китерделәр. Кунак сусаган булса кирәк, кубок кулына эләгүгә, аны күтәреп эчеп тә куйды. Йосыф кахан шәрабчысына янә бармак шартлатты, янәсе, кубокны тутырып куй. Икенче кубокны эчеп куйгач кына сөннәтле Кушбугаз, озын мыекларын сыпырып, каханны тыңларга җыенды.

— Чын атың ничек, исемең, дим?

— Кушбугаз мин, галиҗәнабым, Кушбугаз. Туа-туганнан бирле Кушбугаз. Атам кушкан исемем хәтерләмим, бәләкәй чакта әнием Карун дигәнне азрак хәтерлим.

— Карун атаман, сиңа мин зур йөк йөклим. Син бүген үк хан кызын каршы алырга кузгаласың. Яраннарыңны ал да элдер. Мөхәммәд хан кызы сараема тартыла, ул хәзер юлда, ә ул гүзәл затка баҗайлар ханы Түрә үз малаена дип кармак салган булган икән, ягъни ярәшергә теләгән. Тик минем раввиларым җитезрәк булып чыктылар. Кызны илдә бер гүзәл, диләр... Аның исән-имин сарайга килеп җитүе зарур. Дала бүресе баҗайлар ханы Түрә тик ятмыйдыр, юлга төшеп, кызны урлап алып китүләре бар. Син аларга аркылы төш. Иң елгыр егетләрең ал, хан кызын исән-имин минем сараема кайтарып тапшырсаң — буш итмәм.

— Хәзер үк кузгалыйммы, каханым?

— Хәзер үк, алар ярты юлны узганнар булса кирәк инде.

Кушбугаз атаман торып басты, камчысы белән болгари итегенә сугып алды.

— Мин киттем, каханым. Атна дигәндә, хан кызы синең куеныңда булыр.

— Ак юл сиңа, Куш... Карун атаман,— диде Йосыф кахан һәм атаманга китәргә ишарә ясады.

Ишеккә җиткәч, Кушбугаз атаман туктады, борылып, каханга:

— Гадәттә, төрки бабаларыбыз кызларын олау-бирнә белән озаталар иде, каханым.

— Гадәтләр генә түгел, диннәр дә алышына, атаман. Юлыңда бул!

## V

Үскәндә аны әтисе җилкәсенә утыртып йөрде. Айбиби, егылудан куркып, әтисенең чәчләренә ябышыр иде. Яратты аны Мөхәммәд хан, үз баласыдай карап үстерде. Яшермәде, Айбиби үсеп-исәя төшкәч, аңа атасы Талиб хан турында сөйләде. Ни гаҗәп, Айбиби моңа бер дә шаккатмады, гәрчә бу хакта беренче тапкыр ишетүе булса да, чөнки ул аңа бик якын иде. Заманында атасы Талиб хан яшь хатынга өйләнә — Айбибинең әнисенә. Әнисе Айбибине таба да вафат була. Әнә шулай Айбиби бәби чактан ук әнисез кала. Мөхәммәд хан баланы үз кызы Айгөлне тәрбияләгән Рәшидә абыстайга тапшыра. Айбиби үскәндә һәрдаим Айгөл апасы белән була. Айбибигә җиде яшь тулгач, Хазар каханы Идел буе Болгарына килде, Мөхәммәд хан белән бабалары төзегән килешүне яңартты. Хан кызларын да шунда күрде һәм

икесенә дә зөбәрҗәтле алтын балдаклар бүләк итте. Айгөл апасының аркасыннан сөйде, Айбибинең башыннан сыйпады. Мөхәммәд хан каханның кызлар белән сөйләшеп торуын күрде дә Рәшидә абыстайга тиз генә аларны алып китәргә кушты. Балдаклар нәкъ аларның бармакларына ясалганнар иде. Айбиби моңа игътибар итмәде, кинәнде, ә менә унөченче язына аяк баскан апасы Айгөл балдакны уч төбенә кысты да бик озак бер ноктага текәлеп карап торган иде. Айбиби үз балдагын апасына күрсәтте, шатланды, әле бер бармагына, әле икенче бармагына киде, кулларын әйләндереп, көзге алдында уралды. Шуннан дүрт-биш ел да үтмәде, кахан апасы Айгөлне сараена тарттырды. Һәй, елады да соң апасы, күзләре кып-кызыл булды, Айбибине кочып, мыштым гына кемнеңдер исемен кабатлады, шул исем белән тәрәзәгә карап дәште. Айбиби аңлады да, аңламады да. Кем бар анда, апасы кемгә дәшә дип, каткат тәрәзәгә барып карады. Сарай ишегалдында да, бакчада да, кирмән капкасына таба сузылып яткан юлда да беркем дә юк иде. Ахыр, апасы янына килеп сорады.

— Нигә елыйсың, елама, син еласаң, мин дә елыйм,— дигән булды.

Айгөл апасы бер сүз дә әйтмәде, аны кочагына алды да, селкенә-селкенә, такмаклый башлады.

— Минем анда барасым килми, килми, апаем Айбиби, килми!..

— Кая, кая, апам?

— Аккалага, Аккалага, кахан кырына. – Һәм шунда чәнчә бармагына кигән кахан балдагын салды да, тәрәзәне ачып, ишегалдына атты.— Кошлар, алыгыз, алып китегез шул балдакны, алып китегез, алып китегез дә явыз каханга илтеп бирегез!..

Менә кайчан барып җитте үсмер Айбибигә — апасы Айгөлне Аккалага Хазар каханына хатынлыкка тарттыралар икән. Һәм иртәгә үк аны Аккалага алып китәчәкләр, аны, ягъни Айбибине апасыннан аерачаклар. Әнә шунда Айбиби чырыйлап елап җибәрде.

— Җибәрмим мин сине аңа, явыз каханга, җибәрмим, апам, җибәрмим. Әйдә, атама әйтәбез, җибәрмәсен сине Аккалага, явыз каханга, җибәрмәсен!

Хәзер инде Айгөл апасы идәндә тәгәри-тәгәри елый башлаган Айбибине үзе юата башлады.

— Чү, чү, Айбиби апаем, елама, мин аннан тиз кайтырмын, менә күрерсең, әйләнермен дә кайтырмын. Мин аңа, тукта әле, карале күзләремә, карале,— апасы аның битләрен ике учына алды, яшьле күзләренә карады,— мин аңа сине яратмыйм, дип әйтермен. Яратмаган кеше белән торалармыни? Ул мине җибәрер, син мине басу капкасында каршы алырсың. Мин аннан сиңа матур-матур чәчкәләр, ефәк күлмәкләр, яулыклар алып кайтырмын. Аннары без синең белән кулга-кул тотынышып, Аккошлар култыгына төшәрбез, аккошларга җим ашатырбыз...

Апасы Айгөлнең һәр сүзе Айбибинең йөрәгенә үтеп керде. Менә апасын басу капкасында каршы ала, аны яугирләр озата киләләр, менә алар, кулга-кул тотынышып, Аккошлар култыгына төшәләр, горур кошларга җим ташлыйлар, кинәнәләр.

Айбиби тынычланды һәм бераздан, арып, йокыга китте.

Ул уянганда, Айгөл апасы юк иде инде, аны Хазарстанга алып киткәннәр иде. Айбиби тагын, нигә мине уятмадыгыз, дип еларга тотынды. Аны юаттылар, тынычландырырга тырыштылар, ахыр Мөхәммәд хан үзе кызны Аккошлар култыгына атка атландырып алып төшеп китте. Атасы аңа: «Без аккошларга Айгөл апаңа сәлам юлларга кушарбыз, алар безнең сәламебезне апаңа тапшырырлар һәм ул шатланыр»,— диде.

Айбиби моңа да ихластан ышанган иде.

Ә бит бөтенләй алай булмаган, Рәшидә абыстай әйтте: апасын бәйләп салган кебек арбага салып алып киткәннәр  кахан раввалары.

Апасы елаган-елаган да тәмам хуштан язган. Һәм шунда Рәшидә абыстай Айгөл апасының бер бала табып, вафат булуы турында да әйткән иде. Имеш, ул углан баланы каханның анасы Сара анакай тәрбиягә алган һәм углан белән Таман тарханы Гали кырына күчеп киткән.

Хәзер әнә шул ук каханга хатынлыкка Аккалага Айбибинең үзен алып баралар. Тик нигәдер Айбиби апасы кебек хуштан язар хәлләргә килеп еламады. Моңа атасы Мөхәммәд хан да, Рәшидә абыстай да һәм сарай куштаннары да вә хатын-кызлары да игътибар иттеләр. Дөнья күргән хатын-кызлар үзара: «Ятим үсте ич, шуңа бер дә исе китми»,— дип сөйләнделәр. Тик бит Айбиби бер дә ятим үсмәде, атасы Мөхәммәд хан аны Айгөл кызыдай якын күрде, үз итте, ахыр килеп, Айбиби биредә үзен бер дә ятим тоймады, хәтта үсеп-исәйгәч, атасы Талиб хан булуы хакында белгәч тә, Мөхәммәд атасына ят итеп карамады, аны беркайчан да чит күрмәде.

Айбиби, япмалы арбаның чаршавын күтәреп, далага күз ташлады. Юлдан ерак түгел, үрә каткан йомран аны күрде дә әче итеп сызгырып җибәрде һәм күз ачып йомганчы өненә кереп югалды. Ул арада йомран оя-өне янындагы шайтан таягына уткойрык кунды, бу кошчык та кемнедер үз кырына дәшә, койрыгын селкә-селкә сайрый башлады. Әйе, ялгыз калу, ялгыз яшәү һәр җан иясенә дә ямандыр. Айбибигә дә кырыннан Исламны алып киткәч, нигәдер ямансу булып китте. Күңеленә кереп оялаган Йосыф каханның кырык беренче хатыны булу теләген мизгел эчендә дала җиле алды. Юлга кузгалганнан соң, беренче тапкыр хан кызының ямансу күңелен сагыш хисе биләде. Ул үзенең сарайдан чыгып китүен янәдән күз алдыннан уздырды. Әйе, ул үзен гамьсез тотты, моны барысы да күрделәр, гаҗәпләнде-

ләр, хан кызын аңламадылар, аптырабрак калдылар. Атасына да Айбибинең бу халәте, үз-үзен тотышы ошамады. Әмма кызы янына килеп, шул хакта сүз әйтергә кыймады, киресенчә, Айбибидә ихтыяр көче күреп горурланды хәтта. Бер сагышлана башлагач, Айбибинең күз алдына Идел буенда таралып үскән шомырт агачлары килде, шау чәчәктә утырган шомыртлардан соң, көннәр җылытып җибәрер иде, Идел балыкчылары зур-зур җәеннәрне тотарга балан чәчкә атканны көтәрләр иде. Үз гомерләрен су астындагы яр куышларында уздырган җәеннәр, балан чәчкә атуга, нииндидер могҗизаи сиземләү белән куышларыннан чыгалар, ишләрен эзлиләр, теләсә нинди җимгә дә кабалар иде. Айбибине кармак белән җәен тотарга атасының алостазы Мирхәйдәр бабакай алып төшәр иде. Ул җәеннәрнең кай тарафларда саташып йөргәнен-йөзгәнен белгәндәй, кармакларын салыр һәм Айбибигә калкавычларны карарга гүя сакка куяр иде. Җәен вак-төяк балык кебек чиртеп маташмый, җимне зур авызына каба да өненә алып китә, ләкин кармак һәм кармак кылы аны җибәрми, нәкъ менә шунда Айбиби кинәнеп кычкырып җибәрер иде: «Бабакай!» Кармакка капкан балыкларны сарай хезмәтчесе килеп алыр, чәбәләнеп яткан җәеннәргә карый-карый бавырчылар өенә туктарлар, шул мәлдә җир астыннан калыккандай кечкенә малаен җитәкләп, сарай табибы Хәбибулла килеп чыгар, кечкенә малай исә арбада яткан җәеннәргә игътибар итми, ни сәбәпледер Айбибигә карап торыр, аның һәр хәрәкәтен күз угында тотар иде. Айбиби аны күрмәде һәм аңа карамады да. Андый малайларны күргәне бар иде инде аның — бер дә исе китми иде. Һәм хәтта соңрак та ул аларны күрмәде, күрсә дә исе китмәде. Тик менә иртәгә китәбез дигәндә, атасының нәкъ шул инде үсмер булган егет белән урманга җибәрүен янә гадәти бер хәл дип кабул итте. Кабул итте, тик елганың Аккошлар култыгында аның белән әллә ни булды, егетнең күлмәк тукымасына сеңгән, моңа кадәр беркайчан да иснәмәгән исле егетнең кочагына иңдерде, әллә булмаса табигый затны затка тарту һәр адәм баласына Аллаһы биргән мәхәббәтме?.. Ни булды аңа Аккошлар култыгында? Нигә ул әлегә кадәр бер дә исе китмәгән егетнең күкрәгенә капланды да алсу битләрен үбәргә рөхсәт итте, хәтта иреннәренә кадәр тартылды егет, гәрчә җаны көеп китүен тойса да, аның кочагыннан чыга алмады, хәтта тәмам буынсыз калды.

Әллә соң шулай башланып китәме кызлар күңелендә егетләргә карата булган мәхәббәт?.. Әгәр дә шулай икән, нигә ул Йосыф каханга кырык беренче хатын булып тартылырга риза булды да, нигә мин аны яратмыйм, мин башкага гашыйк булдым дип, атасына әйтмәде?.. Кем моны аңа аңлатыр? Ни бу? Гашыйк булумы, әллә булмаса яшьлектәге бер хис дулкынында тибрәлеп алу гынамы?.. Әйе, ул Ислам кочагында әнә шул хис дулкынында тибрәлде, чак кына көймәдән егылып төшмәде — хис дулкыны көймәсеннән. Тик бит бу хис бик тиз үтте, мизгел эчендә... Икенче мәлдә инде Айбиби үз халәтенә кайтты — хан кызы халәтенә.

Әйе, аларны һәрчак сарай табибы Хәбибулла дәвалады һәм әллә ниткән үләннәр белән. Сарай кешеләре авырганда табиб әллә ниткән үләннәрдән төнәтмәләр кайнатыр, шуларны авырып киткән сарай кешеләренә эчерер һәм аның янында һәрчак әнә шул улы Ислам булыр иде — Айбибине бер мәлгә генә хис ташкынына күмеп ташлаган егет.

Күзләре дымланып ук тора иде, ни сәбәпледер Айбибине яр өстенә күтәреп алып менеп, аягына бастыргач, иң гаҗәбе, хан кызы сурәтенә кереп, сакчыга кырыс кына боерык биргәч, әнә шул егет тәмам каушый калган иде. Ахры, егет хәзер генә булган хәлне аңламады — төшендә итеп кабул итте бугай. Чөнки егет тәмам агарынып калган иде, бит ул хан кызын үпте, бит ул хан кызына кагылды, җитмәсә, яр өстенә күтәреп алып менде, ул гынамы, хан сакчылары моны күреп тордылар...

Айбиби үзалдына елмаеп куйды. Менә хәзер Ислам атлы егет аның кырында булса, ул аның һич тә тартынмый битенә кагылып алыр иде, хәтта битеннән булса да үбәр иде, хәтта рәхмәт әйтер иде.

Менә кайчан хәтер кәтүгә сүтелә башлады Айбибинең. Бит ул Исламны күптәннән белә, тик игътибар гына итмәде. Үсмер егет еш кына атасына ияреп, сарай хатын-кызлары ягына керде. Атасы теге йә бу авыруны караган арада, бигрәк тә яшь хатыннар егетне үртәргә керешерләр иде. Имеш, кайчан инде бу егет хан кызы Айбибигә яучылар җибәрә, кайчан өйләнә инде. Имеш, хан кызын, хатының булгач, бушка дәваларсың инде, безне дә онытмассың, айга бер булса да ашка дәшәрсең... Айбиби синеке инде, табиб улы, синеке... Әнә ул авырып китте әле. Салкын тигән диме, җофар юрганы астыннан да чыкмый. Бу хәл чынлап та шулай иде, Айбиби авырып урында ята, хатыннар үртәүгә, табиб улы бит очларына кадәр кызарынды, колаклары яна ук башлады, хәер, Айбиби дә боларның барысын да күрмәс өчен юрган астына кереп поскан, аның да бөтен тәне ут янды. Һәм, ни гаҗәп, шул көнне берни булмаган кебек сәламәтләнеп киткән иде. Шунда тәҗрибәле үтә чая бер хатын:

— Бу балакайны мәхәббәт сәламәтләндерде,— дигән иде.

«Нинди мәхәббәт, кемгә булган мәхәббәт?» дип сорыйсы килде Айбибинең, тик сорый алмады, оялды. Чөнки ул табиб улына, ичмасам, бер тапкыр да кызыксынып карамады. Ул гүя аның өчен юк иде, сарайдагы һәр кеше кебек, ул бары тик табиб улы гына иде.

Тик менә балачактагы өтек кебек кенә күренгән малай, үсмер булгач, ахыр, атасының яһүдә хатынын тәмам үләргә яткан җирдән аякландырып җибәргәч, табиб улына Айбиби дә кызыксынып карап алган иде. Ә инде Аккошлар култыгына төшкәч булган хәл күз алдына килүгә, Айбиби үзалдына кызарынып куйды. Ә бит ул чынлап та хуштан язды, чынлап та Ислам атлы егет аны үпте һәм сөйде, ә ул

шуңа гүя эреп китте. Әнә шундый хиссияти уйлар һәм уйланулар белән Айбиби йокыга киткәнен сизми дә калды.

Иртән уянуга, Айбиби арбасына Рәшидә абыстай күчеп утырды, олау туктап калгач, Айбибине ашка дәште. Ашап-эчеп, олау янәдән кузгалып киткәч, Айбиби арбасына күчеп килгән Рәшидә абыстай хикәятләр сөйләргә кереште. Элек абыстаеның хикәятләрен тыңлар-тыңламас утырыр иде, әмма ошбу юлга чыккач, гыйлем галимәсен дикъкать белән тыңлады. Рәшидә абыстай әллә ниткән мажаралы могҗизалар белә иде. Абыстай сөйләм тәменә керер алдыннан әүвәл күлмәк итәкләренә кадәр җыя төшәр, баш яулыгын чишә төшәр һәм, ике кулын күтәреп, Аллаһыга дога кылыр иде. Шуннан соң гына: «Йә, балакаем, ничек йокладың бүген, һәйбәт йокласаң, тәнеңә вә жаныңа-рухыңа йокыңнан көч-куәт алган булсаң, инде мине тыңла. Ниндәен төш күрдең бүгенге йокыңда, балакай?..»

Айбиби аңа хәтерендә калган төшне сөйләде. Чынлап та бүгенге йокысында иртәнге якта гына үзен аккошлар белән кай тарафкадыр очканын күргән иде. Имеш, аңа җиңел-җиңел һәм ул оча ала икән ич! Һәм ул күтәрелде дә аккошларга ияреп очып китте.

«Синең Аккалага күчеп китүеңә ишарә бу, балакай»,— диде абыстай.

Аннан соң арба пәрдәсен ачып, иксез-чиксез далага күз ташлап алды, шуннан соң гына: «Борын-борын заманда, әле безнең ерак бабаларыбыз Идел буйларына күчеп килә башлаган вакытларда, ошбу төбәктә һичкемгә буйсынмаган тархан яшәгән. Көннәрдән бер көнне күктән Тәңренең ярдәмчесе төшкән дә: «Сиңа бу язда мәхәббәт килер, ләкин Тәңрең сине ташламас»,— дигән. Шуннан соң тархан язны зарыгып көтеп ала. Ниһаять, табигать уяна башлый. Елгалар таша, гөрләвекләр ага, болын-тугайлар шау чәчкәгә әверелә, сайрар кошлар, ашкынып, берсен-берсе эзли-эзли өздереп сайрыйлар, елгаларда арып төшкән казлар каңгылдаша. Һәр җан иясе, һәр тереклек — җанлысы-җансызы — бер-берсенә тартыла, иш ишен тапканнары дошманнары көнләшерлек итеп сөешәләр, назлашалар.

Ә тарханга Тәңре җибәргән мөлдерәп тулган мәхәббәт килми дә килми. Ә тархан Идел яр өстенә кырын төшеп ятканда, мөлдерәп торган манзарага, хәйрани төсләргә мөкиббән китеп торганда, аңа кемдер әкрен генә дәшә: «Гунныяр, Гунныяр!» Тархан егет як-ягына карый, дәшкән кешене эзли, зәңгәр күккә бага, әмма анда чәчри хәлләргә килеп сайраган тургайдан башка берни дә күрми. Егет яткан урыныннан сикереп тора, атына сызгыра, аты утлаган җирдән җилле генә иясе янына килә. Шулчак егет кырында күктән төшкән алиһә пәйда була һәм әйтә: «Мин Кытай императоры кызы, мине башка бирәүгә, яратмаган кешегә кияүгә бирәләр — ил түрәсе Юсигә. Ә мин сине күрдем дә сиңа гашыйк булдым, сине яраттым. Син ирекле кеше, син беркемгә дә баш имәгән егет, диделәр миңа...»

Егет ни кылырга белми аптырап кала. Чөнки аның Идел буена күчкәннән бирле бер генә адәми затны да күргәне булмый. Һәм, төшемдә түгелме бу күренеш, дип алиһәгә үрелә. Тархан булып бу төбәккә килгән Гунныяр атын йөрткән бу егетнең кулы кызга тиюгә, кыздан якты нурлар коела башлый, йөзе — айга, күзләре йолдызга әверелә. Гунныяр егет кызны кочакларга, кулына күтәреп, атына утыртып алып китәсе итә, әмма шул мәлдә үк кыз юкка чыга, егет колагына: «Көнчыгышка таба кузгал, көнчыгышка таба, мине шунда табарсың»,— дигән кызның моңлы тавышы ишетелә. Гунныяр сикереп атына атлана да тавыш килгән якка таба чаба. Тик алиһәнең тавышын куып җитә алмый. Егет Алтай тауларына җиткәч кенә туктый, хәйран калып, биек-биек тауларга карап тора. Һәм егет колагына янә Тәңре тавышы ишетелә: «Син үткән җирләр дә, син туктаган таулар да синең җирләрең булыр. Шунда үзеңә ишләрең дә табарсың».

— Безнең бабаларыбыз Алтайдан килмәгәннәр, Алтайдан кайтканнармыни, Рәшидә абыстай?

— Кайтканнар, балакаем, кайтканнар. Идел буйларына кайтканнар, аннары баһадирыбыз Аттила аларны Ауропага таба алып киткән, чөнки анда колбиләүгә көйләнгән Рум дәүләте яшәгән, ә ул дәүләттә безнең асыл егетләребезне үз базарларында җантовар итеп сатканнар, үзләренә атлы гаскәриләр итеп алганнар. Шул явызлыкка түзми, безнең бабаларыбыз Ауропада явыз колбиләүчелеккә нигезләнгән империяне туздырып кайтканнар. Ул батыр гаскәриләр башында ата-бабалары нәсел җебе Гунныяр атлы баһадирга барып ялганган Аттила бабабыз торган. Гәрчә ул Ауропада ятып калса да, Аттила баһадир үз үлеме белән Ауропа халыкларын коллыктан коткара.

— Мин кем соң, Рәшидә абыстаем, колмы, әллә?..

— Син кол түгел, балакай, син Хазар каханы кырына тартылган хан кызы».

Шул сүзләрне әйтте дә Рәшидә абыстай хан кызын кочагына алды һәм аркасыннан сөя-сөя матур-матур сүзләр тезә башлады. Тик моның белән генә Айбибигә тынычлану килмәде, ул күз яше белән елый башлый. Нигә аны әтисе Мөхәммәд хан кырык яшьлек каханга биреп җибәрде, бит ул хан, ил ханы, ил терәге?..

— Чү, балакай, чү-чү, күз яшең чыгарма, әнә синең кырыңа Гунныярың килә, сине коткаручың,— диде.

Абыстай шулай диюгә, Айбиби күз яшен яулык очына сөртте дә, арба япмасын ачып, аның арбасына таба җилле генә юыртып килгән ир-егеткә, Рәшидә абыстае әйтмешли, ир-атка карады.

— Хан кызы, хан кызы Айбиби. Атың китердем, арбадан төшеп янә бер җилләнеп киликче!..

— Абыстаем, анакаем, мин китим, китим шул егет белән, даланы әйләнеп кайтыйм, каткан бәгырем йомшармасмы...

— Бар-бар, балакай, каткан бәгырең йомшартып кайт. Егет сөяр, кыз сөелер, шунда туар мәхәббәт, дигән бер шагыйрь.

Хан кызы Айбиби абыстайның күзләренә карый, хәзер генә моңсулыкка йөз токкан битләре, тулынкы иреннәре елмаюга җәелә, һәм арба янына ук килеп туктаган егеткә күз ташлый, икенче мәлдә инде очып диярлек, арба кырына ук китерелгән атка атлана һәм, алга чыгып, далага чаба. Ислам аны куа китә. Нигәдер бу юлы алар артыннан раввaларның яугирләре кузгалмыйлар, тик күз карашлары белән генә озатып калалар.

Иллә Айбиби ерак китә алмый, алар каршына каханның елгыр яугирләре килеп чыгалар. Хан кызы туктарга мәҗбүр була һәм аны кахан җибәргән яугирләр кире олауга борып китерәләр. Раввалар канәгать, елмаялар, бер-берсенең күзләренә карашалар.

Хан кызының юлына аркылы төшүче яугирләр Карун атаманның сөннәтле казаклары икән. Раввалар моны ерактан ук күреп алдылар, шуңа кинаяле шатланалар иде. Хан кызы юлына аркылы төшкән сөннәтле казакларны җиткермәде, олаудан алдан ук килеп җитте һәм атыннан төшми генә артына әйләнеп карады. Сөннәтле казаклар киемнәре белән үк башкалардан аерылып торалар иде. Хан кызы арба янына җитүгә, ат тезгенен хезмәтчесенә ташлады да атыннан җиргә төшми генә арбага күчте. Ул арада сөннәтле казаклар килеп җиттеләр һәм атларын арба белән янәшә атлатып киттеләр. Күп тә үтми, арба янына үтә чуар киенгән сөннәтле казакларның атаманы килеп җитте. Ул арбага якын ук килде дә камчы сабы белән пәрдәне ачып:

— Хан кызы Айбиби, мин атаман Карун, кахан әмере белән сәне каршы алырга җибәрелдем, шатланасы ит,— диде.

Айбибигә бу кешенең кыяфәте генә түгел, эретерәк сөйләшүе дә ошамады, ул дәшмәде, алай да Алпар йөзбаш ягына таба китеп барган Исламга күз төшереп алды. Һәм тынычлана төште бугай, кырыс кына:

— Кахан әмерен үтәдегез, атаман. Инде китә бирегез,— диде.

— Мин биредә кахан йөген үтәргә дип килдем, хан кызы Айбиби.

— Үтәргә килгәч, үтәгез, хан кызы арбасына тагылып бармагыз, атаман Карун. Карун бит сезнең атыгыз?

— Әйе, Карун мин Карун, хан кызы. Мине сине каршыларга дип кахан Йосыф үзе җибәрде. Әйе, күз-колак булырга.

— Китегез арба яныннан, чарасыз итмәгез мине, атаман Карун!

Ни тәкәббер, үзсүзле булса да, атаман Карун арба пәрдәсен төшерде һәм теләр-теләмәс кенә яугирләре янына таба кузгалды.

Айбиби әллә ни зур сәбәп булмаса да, елап алды, бер мәлгә яулык очы белән йөзен каплап торды. Шаярып булса да, барган җайда ул Исламга: «Урла мине, урла, сарай табибы улы Ислам, урла»,— дигән иде. Егет аны әллә чын итеп кабул итте инде, аты белән: «Миңа ияр!» — диде дә алдан чапты. Бер мәлгә, бары тик бер мәлгә генә Айбиби икеләнә калган иде, шул вакытта җир астыннан чыккандай атаман Карун килеп чыкты. Яугирләре күп түгел, ләкин күренеп тора — елгырлар, ут-су кичмәсәләр дә, йөзләрендә үк өмет юк. Айбиби табиб улы Ислам артыннан кузгалса, шундук аны уратып алачаклар һәм сак астында диярлек олау янына китерәчәкләр. Шуның өчен Айбиби атын кинәт кире борды һәм олауга таба чапты. Кая булды Ислам атлы егет, ни уйлады аның хакында, ул белмәде. Хәер, моңа бик үк исе дә китмәде, ул аңа: «Урла мине, урла!» — дип шаярып кына әйткән иде, шул ук вакытта белә иде, каханның сөннәтле казаклары килеп чыкмаганда, аның бу гамәленең чынга әверелүе дә бар иде. Тик моның ахыры ни белән бетәсен генә белми иде Айбиби, ул хакта уйларга, гомумән, вакыты калмаган иде. Хәзер инде соң, ул каханның үтә яман казаклары кулында, хәзер аңардан күз дә алмаячаклар, болардан равва яугирләреннән качып киткән кебек качып китеп булмаячак, чөнки бу халык турында Айбибинең атасы авызыннан да ишеткәне бар иде — имансызлар, башкисәрләр...

* * *

Юлга чыгар алдыннан уены-чыны белән йөзбаш Алпар үзе белән барган сарай табибы улының хан кызыннан күзен алмавын күргәч:

— Урла син аны, урла! — дип котырткан иде. Шуннан соң егетнең бу эшне чынга алырга җыенуын күреп, үзе үк курка калган иде. Ә инде хан кызыннан башка ишләре янына әйләнеп кайткач, йөзгә үзгәреп, егетне орышып ташлады:

— Башың икеме әллә синең, табиб улы. Мин сине шаяртасың дип торам, ә син, дивана, хан кызын чынлап та урларга иттең бугай. Беләсеңме мине моның өчен Мөхәммәд хан нишләтәчәк?.. Дәшмисең, чөнки бик яхшы беләсең — башым кистерәчәк, башым! Һәм мәйданга чыгарып, бөтен кала халкы алдында. Мине — баһадир йөзендә йөргән йөзбаш Алпарны!..

— Мин беләм, йөзбаш Алпар, беләм. Ләкин йөрәк яна бит, йөрәк! Гашыйк булдым мин хан кызына, гашыйк! Мин чынлап та дивана хәлендә хәзер, чарасыз калдым, чарасыз...

— Ә син өмет ит,— диде йөзбаш Алпар, егетнең гашыйк булуына инанып.— Өмет ит. Бәлкем, синең мәхәббәтең көчлерәк булып, хан кызы сине сайлар, ә Йосыф каханны җир убар, йә булмаса, кахан сараен су басар...

Ислам, гаҗәпсенеп, йөзбашка карап алды, башын түбән иде һәм тыенкы гына:

— Син хаклы, йөзбаш, мин бернәрсә дә кыра алмамдыр.

— Әйтәм бит, өмет ит, адәм баласы өмет белән яшәргә тиеш. Хан кызына мәхәббәтең саф булса, хан кызына ихлас күңелдән гашыйк булган булсаң, сарай табибы улы Ислам, Аллаһы Тәгалә синең теләгеңне күрер һәм бахырга ярдәм кулын сузар.

— Һәй, баллы да соң сүзләрең, йөзбаш, мелләләр бер якта торсын. Әйе, син хаклы, мин аны урлый алмам, алмадым. Беләсең килсә, хан кызы моны үзе теләмәде. Күрдем ич мин, сиздем ич мин, минем мәхәббәткә җитди карамый хан кызы, бераз баласынып кабул итте. Хак, көлмәде, вәләкин серле мәхәббәт ташкыны аның күңелендә булып алды.

— Бәлкем, хан кызы синнән, синең ашкынулы-ярсу хис белән тулы мәхәббәтеңнән курыккандыр. Чөнки ташкын булып кеше күңеленә килеп кергән мәхәббәт тиз сүнүчән була, дөрләп кабына да бик тиз сүнә. Андый язгы ташкындай килгән мәхәббәтнең нигезе булмый, Ислам, нигез ташы булмый. Ә хатын-кызлар бу мәсьәләдә егетләрдән күп тапкыр акыллыраклар, чөнки киләчәк турында уйлыйлар. Шуның өчен сиңа, Ислам, Аллаһыдан ялварырга гына кала. Син шул хакта көн-төн уйла, көн-төн, синең мәхәббәт нурларың вә уй-хисләрең җепләре хан кызына бер бармаса бер барып җитәр, чөнки мәхәббәт адәм баласы өчен мең еллар элек тә, хәзер дә сер булып кала бирә. Мәхәббәтнең серләре бер Аллаһыга билгеле булса билгеледер, сарай табибы улы Ислам.

— Бер дә минем атамнан ким кеше түгел син, йөзбаш. Ул да шулай мине дөнья көтәргә өйрәтә. Йөзбаш Алпар, әйт әле, безне Аккалага кертерләрме?

— Менә анысы инде Йосыф кахан кулында, тели — кертә, тели — Ханбалык басу капкасыннан да уздыртмый. Һәрхәлдә, безне Ханбалыкка уздырырлар дип уйлыйм. Җай чыкса, Ходай мине тархан белән очраштырса, тархан Булат белән, дим, мин аңа бу хакта әйтеп карармын, сарай табибы улы Ислам. Хан кызына үлеп гашыйк булган Кодрак хан заманнарыннан килгән нәсел җебе дәвамы төрки-болгар егеттә бар, диярмен. Аннары әйтермен, ошбу егетне Мөхәммәд хан кызын озатырга табиб итеп җибәрде, диярмен. Аңлар ул мине, хезмәтебезне бергә башлаган идек Талиб хан кул астында. Ары таба Булат үсте, Хазар каханы аны Аккалага үз кырына алды. Хәзер Булат бәк кулында Аккала гына түгел, Ханбалык халкы да.

— Мин боларның берсенә дә ышанып җитмим, йөзбаш. Әмма шуны ачык беләм: мин хан кызына гашыйк.

Шулчак кемдер:

— Аккала, Аккала! — дип кычкырып җибәрде.

Алда, офык читендә чынлап та экиятләрдә генә була торган мәһабәт кала күренде. Рәшә дулкынында бу кала күңелне тагын да җилкендереп, үзенә чакырды. Кала күренүгә, олау да адымын тизләтте, ә бериш яугирләр калага таба чаптырып киттеләр һәм берара җирне урап килделәр.

— Аккала, Аккала!..

Күп тә үтми, Аккаланың уң ягында очсыз-кырыйсыз Ханбалык шәһәре күренде. Менә моңа чынлап та шаккатырлык иде — зур иде Хазарстанның башкаласы, Йосыф кахан яшәгән Аккала күл өстендәге төнбоек чәчкәсен хәтерләтеп балкып тора. Ләкин бит адәм күзенә һәрчак башта матурлык ташлана, хан кызы Айбибигә дә шулайрак тоелды. Аккала дигән тавышны ишетүгә, ул ат тотучы янына чыгып басты һәм әнә шул күз өстендә чәчәкләрен җәеп торган Хазарстан башкаласының йөзек кашы булган Аккаланы күрде дә, үзе дә аңлап җиткермичә: «Аккала, Аккала!» — дип кычкырып җибәрде. Моңа бик күпләре сәерсенделәр, хәтта башларын чайкап куйдылар, бары тик раввалар гына, күзгә-күз карашып, елмаешып алдылар. Әйе, үз дигәннәренә ирештеләр, бөҗәнәкләр ханы улының борын астыннан дияргә була, Мөхәммәд ханның бердәнбер гүзәл кызын Йосыф каханнарына алып кайталар. Ә бит соңга кала яздылар. Кызны каладан алып чыгып киткәч, юлда очраган яһүд сәүдәгәрләре ирештерделәр — Түрә ханның улы Айдар Болгар калага таба кузгалган икән. Килеп җитмәде Айдар углан, эләктерә алмады хан кызын, олау инде калага җитеп килә. Ә бит далада очрашкан булсалар, үтә гаярь бөҗәнәк сугышчылары хан кызын тартып алып киткән дә булырлар иде. Мөхәммәд хан яугирләре бөҗәнәкләр белән сугышмаслар иде — кан кардәшләр, мөселманга мөселман канын кою гөнаһ, ул кеше мәңге тәмугта яначак, ә раввалар кулында бары тик Йосыф кахан яллаган сөннәтле казаклар гына. Бу халыкка да ышану кыен, бу халык сугыш кырын ташлап качарга да күп сорамый иде. Ләкин нишләмәк кирәк, яһүдләр борынгы римләннәрдән соң беркайчан да, бер халык белән дә сугышмадылар, чөнки кан кояр дәрәҗәгә җитеп сугышыр җирләре калмаган иде. Моны гына аңлыйлар иде яһүд раввалары. Ләкин бирәдә яшәгән, меңнәрчә еллар шушы төбәкләрдә көн күргән төрки кавемнәре ил-җирле булгангамы, моны аңламыйлар, үз җирләре өчен сугышуны табигый бер хәл итеп кабул итәләр, шул сәбәпле күп очракларда

баш китәр дәрәҗәләргә җитеп, дошман белән орышалар, кан белән сугара-сугара булса да, туган туфракларын саклыйлар иде.

Аккаланы күрүгә, сарай табибы улы Исламның тел очына килгән беренче уе: «Димәк, хан кызы Айбиби шушы калада яшәячәк»,— булды. Ә бит ул инде хан кызына булган мәхәббәтенең ихласлыгына ышанган иде һәм соңгы мәлгә кадәр нидер өмет иткән иде. Әйе, урлап качу турында... Барып чыкмады. Булат бәккә, бәхәссез, йөзбаш Алпар аны хан кызының табибы дип тәкъдим итәчәк. Тик ничекләр кабул итәр Булат бәк бу хәбәрне?.. Ахыр килеп, Йосыф каханны диннәргә битараф кеше дип ирештерделәр. Әмма менә монысын Ислам аңламады. Ничек битараф булмак кирәк, илбашы ич ул. Ә дин атасы әйтүе хак булса — ил терәге, ул гынамы, халыкның рухы, иманы, ниһаять. Имеш, әнә шуңа Йосыф кахан битараф. Атасы әйтүе хак булса, 922–923 еллардан соң каханның яһүд раввалары мөселманнарны Аккалага кертми башлаганнар. Ул гынамы, 910 елда мөселманнарны илдән куу 922 елда янә кабатлана.

Ә бит кахан бәге Сабир да, кала бәге Булат та мөселманнар. Ничек керәләр алар кахан кырына. Атасы әйтүе хак булса, каханбәк тәхет ягына керә-керүгә, аяк киемнәрен сала һәм шуннан соң гына кахан кырына уза. Каханбәк Сабирны яһүдләр динен кабул иткән, дип сөйлиләр дигән дә булды атасы. Чөнки хатыны яһүдә икән. Ә яһүдләр яһүдә хатыннан туган балаларны гына үз милләттәшләре итеп таныйлар. Ялгышмаса, каханбәк Булат җиде суда буталган яһүдә хатынга өйләнсә дә, чыгышы белән төрки, ата-бабалары да төрки болгарларыннан булганнар. Бу хакта да хәбәрдар иде Ислам. Әнисе белән атасы шул хакта еш кына бәхәскә кереп китәрләр иде. Атасы әнисен үртәр иде. Имеш, синең нәсел җебе яһүдләргә барып тоташа. Әнисе шунда әйтеп ташлаган иде: «Йә, булса ни, әйе, бабамның бабасының бабасы яһүд булган, бөҗәнәк ханында табиб булып хезмәт иткән. Шуннан ни, шуннан ни, тәкәббер төрек җан?! Мөхәммәд пәйгамбәребезнең дә бер хатыны яһүдә булган ич!»

Аккаланың аерым биналары ап-ачык күренә башлады, ә Исламның башыннан вә теленнән «яһүд» сүзе төшмәде. Ләкин аның янә бер тапкыр хан кызы Айбибине күрәсе килә иде, күрергә иде дә, күзләренә карап сорыйсы иде — теләп киләме ул Йосыф кахан кырына? Тик хәзер кем уздырсын аны хан кызы арбасы тирәсенә?.. Чынлап та, хан кызы арбасын Карун атаман казаклары уратып алганнар иде. Алтынга ялланган казаклар аны, әлбәттә, арба кырына якын да җибәрмәсләр. Ислам бер ат башына алдан барган йөзбаш Алпарга күз ташлап алды. Аңардан сораса?.. Юк, кирәкмәс, ул да аны аңламас, Мөхәммәд хан аңа хан кызын кахан кулына тапшырырга кушты. Һәм ул моны шулай итәр дә.

Ул арада Ханбалыкның басу капкасына җиттеләр, Карун җитәкләгән сөннәтле казакларның бер ише алга уздылар, капкаларны каерып ачтырдылар, бер ише хан кызы арбасын боҗрага алган килеш бөтен кала аша Аккалага таба юл алдылар. Урамнар тулып халык чыкты, күрәсең, Йосыф каханга кырык беренче хатын итеп Идел буе Болгары ханы кызы Айбибине тарттырулары хакында халыкка җиткән булган инде. Кызны озатучы Мөхәммәд хан ир-егетләре вә кызлары барысы да ыспай киенгәннәр, киемнәреннән күзләр чагыла, алар хан кызы арбасы артыннан баралар, барысыннан да аерылып торалар, алар артыннан раввалар тагылганнар. Табигый хәл, каханга өч-дүрт елга бер булмаса да яшь хатын тарттыралар һәм һәрчак шулай килен китерүчеләр кала урамнарыннан узалар, утрауга урнашкан күперләрдән генә керергә мөмкин булган Аккалага юнәләләр. Ханбалык халкы өчен бу да тамаша иде.

Идел елгасы аша утрауга үтәр өчен көймәләр тезеп салынган һәм ул-бу була калганда мизгел эчендә икегә аерыла торган күпергә җитүгә, олау туктады. Тәбир шәех белән Рәшидә абыстай арбаларыннан төштеләр, алар янына килеп раввалар кушылдылар. Тәбир шәех күпер башында торган сакчыларга баш иде, тегеләр исә карусыз аларны күпергә уздырдылар. Карун атаман күпер башында торган сакчыга кул изәде дә: «Мин үз вазифамны үтәдем»,— дип булса кирәк, сөннәтле казаклары белән борылып китеп барды. Күпергә хан кызы арбасын, бирнәле олауны гына уздырдылар, калганнарын барысын да, шул исәптән Алпар йөзбаш яугирләрен дә, кире бордылар.

Хан кызы арбасы күперне үтеп, Аккалага узуга, сарайга җитәр-җитмәс, тугыз баскычның берсендә өлкән равва пәйда булды. Өлкән равва баш түбәсен ак чәпләшкә белән каплаган, кулында гәүһәр ташлардан тезелгән тисбе. Хан кызы арбасы килеп туктауга, ул ашыкмый гына баскычлардан төште, нигәдер сак кына атлап, арба янына килде һәм арба япмасының пәрдәсен ача төшеп:

— Сау-сәламәт килеп җиттекме, хан кызы Айбиби! — диде.

— Шөкер кылабыз, өлкән равва. Тик мин хан кызы түгел инде, Йосыф каханга тартылган Мөхәммәд кызы Айбиби, каханның кырык беренче хатыны булачак баладыр.

Менә моны һич тә көтмәгән иде өлкән равва, ул тәмам аптырый калды, һични аңламый як-ягына каранды, әмма хан кызына әйтер сүз тапмады. Каушау түгел иде бу, булган хәлгә, көтелмәгән хәлгә аптырап калу иде.

— Юл бик алҗытты, мине тизрәк кирәк җиргә урнаштырсагыз иде, өлкән равва,— диде аңа Айбиби.

Шулай диде дә хан кызы Айбиби җай гына арбадан төшә башлады, өлкән равва аңа кул бирергә мәҗбүр булды һәм хан кыз җиргә баскач:

— Йосыф кахан сезне көтә,— дип әйткәнен сизми дә калды.

Ә бит өлкән равва Идел буе Болгары ханы кызына кул бирү түгел, эндәшергә дә тиеш түгел иде кебек. Әйе, кем өлкән равва да, кем яңа гына кахан сарае ишегалдына аяк баскан кыз бала?..

— Кахан мине көтмәсә, мин шул ук арба белән илемә кайтып китәчәкмен, өлкән равва. Сез тарттырдыгыз мине монда кырык беренче хатын итеп, сез җавап та тотыгыз. Юкса минем рәнҗүем бар. Ә хатын-кызларны рәнҗетү өлкән равваларга да оят, гәрчә Сез, өлкән равва, сарайда хөрмәткә ия кеше булсагыз да.

Шулай диде дә хан кызы Айбиби сарайга таба китте, өлкән равва бер мәлгә ни кылырга белми тораташтай катып торды, ахыр, исенә килеп, хан кызы артыннан титаклады. Айбиби баскычлардан менә башлауга, сарай ишекләре ачылып китте һәм ишектә ике хатын-кыз күренде.

— Хуш киләсез, балакай, хуш киләсез,— диделәр алар беравыздан һәм Айбибине култыклап алдылар да сарайга алып кереп киттеләр.

Сарай тарлавыкларыннан уза-уза, ниһаять, якты бер залга килеп чыктылар, ике якта да гөлләр, ары таба шактый киң тарлавыклы тыкрыкка килеп керделәр.

— Балакай, синең бүлмәң кырык беренче булыр, апаң Айгөл яшәгән иде анда, иң матур, иң зур, һәйбәт итеп җыештырылган вә җиһазланган бүлмә.

— Мин Хазарстанга каханның кырык беренче хатыны булып килдем, абыстайлар.

— Әйе, балакай, кахан кабул иткәннән соң баш хатын булачаксың, баш хатын!

— Кахан хатыннарына кем күз-колак булып тора?

Абыстайлар күзгә-күз карашып алдылар, елмаештылар, әмма икесенең берсе сүз әйтмәде. Ишек янына җиткәч кенә абыстайларның өлкәнрәге:

— Раввалар, хәрам атакайлар карар сезне, алар хезмәт күрсәтерләр, балакай, алар. Саклыйлар да сезне алар, ашаталар да, хезмәтче вазифасын да үтиләр.

— Ә раввалар, раввалар нигә хатыннарга?

— Раввалар хатыннарга сабак бирәләр, балакай, сабак.

— Кайчан кахан мине үз кырына дәшәр?

Абыстайлар бу сорауны бөтенләй көтмәгәннәр иде булса кирәк, күзгә-күз карашып алдылар да, икесе дә башларын ия төшеп көлемсерәп куйдылар.

— Нәүбәтең җиткәч, балакай, нәүбәтең җиткәч,— диде абыстайның өлкәнрәге.— Ә хәзергә юынчистарын да ашарга дәшкәнне көтеп тор.

— Мин баш хатын буларак иң түрдә утырырмынмы?

Абыстайның кечесе бот чапты һәм өлкән абыстайның колагына:

— Бусы Айгөл булмас, каханны үзе биетмәгәе әле,— дип пышылдады. Айбиби абыстайның бу сүзләрен ишетсә дә, йозак белән маташкандай кыланды. Ахыр, каерып, ишекне ачты да бүлмәгә керде. Ләкин нидер исенә төшеп, кире чыкты һәм китеп барган абыстайларга:

— Минем абыстаем, шәехем, табибым Ханбалыкта калды. Аларга бирегә керергә кем рөхсәт бирер, абыстайлар? — диде.

— Кем булсын, балакай, кем булсын, кахан үзе, булачак ирең,— диде тәмам югалып калган өлкән абыстай һәм терсәге белән ишенең касыгына төртеп алды.

Айбиби шап итеп ишекне япты һәм яңадан ачты. Аның бу кыюлыгына исләре-акыллары киткән абыстайлар һаман баскан урыннарында торалар иде. Айбиби аларга:

— Инде китегез, мин сезгә рөхсәт итәм,— диде.

Шунда өлкән абыстай лып итеп күтенә утырды, икенчесе аны күтәреп бастырырга кереште. Айбиби көлә-көлә ишекне япты һәм бүлмәгә күз йөртеп чыкты.

## VI

Аккалага һәм бөтен бер Ханбалыкка тархан-түрә булып торган Булат бәк сарайда барган һәрнәрсәдән дә хәбәрдар иде. Нәүбәттәге кызны Аккалага кахан кырына тарттыруга аның бер дә исе китмәде. Күп хатыннар белән яшәсә дә, Йосыф кахан үз акылында иде. Хак, аңа ирештерә торалар, кахан кайбер хатыннарын бөтенләй дәштерми икән. Шул ук вакытта Булат бәк каханның хәленә дә керергә тели иде. Кырык хатын! Һәммәсенең күңелен күрергә кирәк, ә ул — Йосыф кахан илбашы да ич әле, ил-халык белән идарә итә. Сүз дә юк, аның кырында һәрдаим өлкән равва утыра, вәләкин тәхетне бит Йосыф кахан били. Ул бирә әмер, ул яу чыга, ул теге йә бу ил белән солых төзи, сәүдә эшләрен җайга сала. Яшь булса да, каханга кырык яшьләр чамасы булуын да белә иде ул, ир янында ир иде әле кахан. Аннары үз кул астына кергән бер генә илне дә күздән яздырмый, күз угында тотарга тырыша. Каханның бу сәясәте дә ошый иде Булат бәккә. Соңгы елларда раввалары һәм бай сәүдәгәрләре аша Византия, Рим, Венеция сәүдәгәрләре белән тыгыз элемтәдә тора башлады, хәтта Идел аша төшкән викинглар дип аталган Скандинавия башкисәрләре белән дә тату яшәргә тырышты. Хак, әлегә борынгы кахан Вениямин кебек аларны мөселманнарга каршы котыртмады, Идел аша Каспий диңгезенә чыгарып, яр буйларында көн күргән мөселман калаларын пиратлардан талатмады, әмма Фәләстыйннан, Дәмәшкътан, Чананнан, Хо-

таннан, Коканнан, Чиннардан килгән сәүдәгәрләрне рavvаларына колач җәеп каршы алырга кушты. Һәм рavvалары шулай иттеләр дә. Бүген Итил аты белән дөньяга таралган Ханбалыкта Хамадан, хәтта Ктисифон сәүдәгәрләрен дә таба аласың. Заманында Иран шаһиншаһы яһүдләрне иленнән куа, ә алар Итил һәм Харәзем төркиләрен сайлыйлар, чөнки кунакчыл, ярдәмчел, кимсетелгәнне, рәнҗетелгәнне якларга әзер халык. Ни чара кылмак кирәк, Аккалада укыттылар Булат бәкне һәм кемнәр дә түгел, яһүд равvалары. Әнә шулай Булат бәк сарайга үтеп керде, соңра хәтта тархан исемен алды — Итил каласы тарханы. Зур йөк иде бу аның өчен, үтә зур йөк. Ләкин Булат бәк сынатмады, эшне белеп алып барды. Ә менә кахан хатыннары белән кызыксынмады. Әллә барлар иде Булат бәк өчен төрле илләрдән тартылган хатыннар, әллә юк. Әмма көннәрдән бер көнне нәүбәттәге хатыннарны кабул итеп торган абыстай аны шаккатырды. Чираттагы кахан хатыны буласы Идел буе Болгары Мөхәммәд хан кызы Айбиби, килә-килүгә, баш хатын булып ала һәм хәрам аталарны гына түгел, равваларны да биетә башлый. Хак, абыстайның арттыруы да бар иде, арттыргандыр да, ләкин Булат бәктә ил түрәсе буларак бу кыз турында кызыксыну туды. Хакмы, чынлап та шулай кыю кыланамы сарайга баш хатын булып килгән Мөхәммәд хан кызы?..

Шул хакта күбрәк белергә теләп, Булат бәк сарайга юнәлде, баскычтан күтәрелүгә, җир астыннан чыккандай, аның каршында өлкән равва пәйда булды.

— Һи, кем, Булат бәк. Безгә Идел буеннан, Болгардан, дим, аждаһа китерделәр бит әле, аждаһа. Кахан кырына кермәгән, ашханәдә баш хатын йөзендә түр башына менеп утырган.

— Сөйләмә булмастайны, өлкән равва, килешми.

— Ирдәүкә инде, ирдәүкә, кахан кочагында булмас борын ирдәүкә. Куып җибәрер аны кахан, тотмас. Сатып җибәрер, дим.

— Сатса, үзем алам,— диде Булат бәк, уенын-чынын бергә кушып.

Өлкән равва кырын күзе белән Булат бәккә карап алды, елмайды һәм аяк очына ук килеп кунган күгәрченне куркытты.

— Тик бит кыз гүзәл, күз алмастай гүзәл, Булат бәк. Җитмәсә, сылу, зифа, күзләре йолдыз, иреннәре бал, битләре кояш вә айдыр. Пешкән кып-кызыл алма инде менә, тәмам җитешкән, өз дә кап, Булат бәк, өз дә кап.

— Ә син аны каханга күрсәтмә, өлкән равва.

— Бу ни дигән сүз инде тагын, Булат бәк. Кала башы бит син!

— Кала башы булганга әйтәм дә инде. Каханыбызны бозып куюы бар, гарәпләр бар этлекне хатыннардан күрәләр.

— Без дә хатыннардан күрәбез анысы, Булат бәк, без яһүдләр дә.

— Ә менә без алай дияргә ашыкмыйбыз, без төркиләр, өлкән равва.

— Нигә алай дисең, Булат бәк?

— Ирдәүкәләр бездә борын заманнарда да булганнар, өлкән равва.

— Булганнар, хак, бу хакта греклы тарих атасы Геродот та яза. Ләкин төркиләр нә куәтле халык булсалар да, үз тарихларын язмаганнар, Булат бәк.

— Безнең тарихны башта чиннар урлый, өлкән равва, аннары фарсылар, безнең тарихка таянып, үз тарихларын язалар, ахыр менә сез — яһүдләр безнең тарихны дәвам итәсез, хәтта бит Изге Китабыгызда да безнең халыкны телгә алмый үтеп китә алмагансыз. Булан каханга рәхмәт укыгыз, ул безне сез, равvалар, белән туганлаштырды, ул булды безне берләштерүче. Тугры хаким, гадел хаким була, мәрхүм.

Өлкән равва бик озак дәшмәде. Булат бәк хаклы иде. Тарихсыз кала язган төрки халкы дөньядагы һәр халыкка үз тарихларын язу өчен мөмкинлек биргән. Әйтик, шул ук кытайлар татарлар атлы кавем булмаса нәрсә турында, кем хакында тарихларын язарлар иде. Төп дошманнары вә күршеләре төркитатарлар булганга, тулы канлы тарихларын яза алалар чиннар. Шулай ук фарсылар да. Фарсы шагыйрьләрен нәкъ менә үзләре туран дип атаган татарлар поэмалар язарга илһам бирәләр. Бу халыкның бер өлеше яһүдләр арасында гына түгел, гарәпләр арасында да эриләр. Ә бит һәр халыкка да читтән килгән кан яңа шытым бирә, дөньяви хәлләргә яңа караш китерә.

Булат бәк кузгала башлады.

— Минем Мөхәммәд хан кызын күрәсем килә, өлкән равва.

— Кирәкмәстер кызны күрү, Булат бәк. Тешләк хатын булыр кебек ул. Йосыф балакай түзмәс аңа, чөнки кахан үтә нәзакәтле кеше.

— Кахан, хак, йомшаграк табигатьле, вәләкин нәкъ шушындый утчагыр хатын җитми иде аңа, өлкән равва. Каханның гына түгел, минем дә күрәсем килеп китте әле Мөхәммәд ханның аждаһа кызын, өлкән равва.

— Киңәш итмәс идем, бәгем. Әүвәл Йосыф үзе күрсен, үзе хәл итсен. Алып каламы, куамы, сатып җибәрәме?..

— Әйтәм бит, сатса, үзем алам, өлкән равва. Ул бала минем күрмәс борын каным кыздыра башлады. Үземә түгел, минем үз хатыным, өлкән равва, каханның кырык хатынына торырлык.

— Шулай дип сөйлиләр сөйләвен, ләкин хатының күргәнем булмады, Булат бәк. Чибәр хатын җил тубалы бит ул — дала буйлап тик тәгәри, кая таба җил, тубал шунда, чибәр хатын да шулай. Акыл кирәк хатыннарга, Булат бәк, акыл, акыл белән яшәү җитми аларга, бер ир затка йөз тотып...

— Акыллы хатыннарны олау аты итәләр бу заманда, өлкән равва. Ә ул хатын чибәр дә, акыллы да, сылу да, зифа да булса ничек, өлкән равва?

— Бар син әйткән сыйфатларны да бер затка биргән хатынны ил түгел, мир дә сөймәс, Булат бәк. Мөхәммәд хан кызы да шул көнгә калмагае, дим.

— Анысы инде Йосыф кахан эше, өлкән равва. Тели — астына сала, тели — Фанәгүр базарына чыгарып сата. Тик сатмас ул аны, эчем сизә, сатмас, шундаен хатын җитми безнең каханга, утчагыр хатын.

* * *

Айбиби бүлмәсенә керергә кыймады Булат бәк, ә хәрам атакайны чакыртып алды һәм каханның булачак хатынын кунак бүлмәсенә дәшәргә кушты. Хәрам атакай тәңкәне тешләп карады, Булатка кире сузды.

— Әллә кайчан кисеп аттылар инде минем, ул кадерлем, Булат бәк. Кешенең ир заты булып, горур төстә йөрүе үзе бәһасез бәхет икән.

— Ал, җый син ул алтынны, өй сатып алырсың, гаилә корырсың, дивана баш.

— Гаилә кору өчен гайрәтем юк ич, дим бит, Булат бәк. Ә монда минем тамагым тук, өстем бөтен...

Булат бәк бер тәңкә алтынны хәрам атакай кулыннан алды да тарлавык буенча тәгәрәтеп җибәрде, хәрам атакай хәтта тәңкә тәгәрәгән якка әйләнеп тә карамады.

— Бик күрәсең килсә, мин аны дәшәрмен, тик озак сөйләштермәм,— диде хәрам атакай, Булат бәккә таба карамый гына.

— Мин сиңа меңнәрчә рәхмәтләр тезәм, меңнәрчә рәхмәтләр, атакай.

Хәрам атакай бер сүз әйтми китеп барды һәм күп тә үтми, Айбибине җитәкләп килеп тә җитте. Һәм карлыккан тавыш белән түгел (карлыккан тавыш таза-сәламәт ирләрдә була), нечкә бала тавышы белән:

— Мин кырыгызда булырмын,— диде.

— Саумы, хан кызы! — диде Айбиби килеп җитүгә Булат бәк.— Исән-имин килеп җиттегезме?

— Юл имин булды, Булат бәк. Рәхмәт.

— Мин каханның тарханы булам. Аккала да, Ханбалык та минем кулымда, хан кызы.

— Сезнең кулда башыгыздагы бүрек кенә, Булат бәк, анысын да Болгар базарыннан сатып алгансыздыр әле,— диде Айбиби.

Булат бәк хан кызының бу сүзләренә тураебрак басты, тирә-ягына күз ташлады, тагын берәрсе тыңлап тормыймы, янәсе, бигрәк тә өлкән равва, ялт итеп бүреген салып, угаларга тотынды. Бит ул бу ирдәүкә кызга нидер әйтергә тиеш иде, тик тәмам зиһене чуалды, әйтергә теләгән сүзе күңелендә төерләнеп калды.

— Мин китим инде, Булат бәк,— диде хан кызы.

— Әйе, әйе, китегез,— диде Булат бәк, баш ия-ия, һәм игътибар итте, хәрам ата аңа ирен чите белән генә елмаеп китеп бара иде.

«Аждаһа ук булмаса да, шул тирәдә икән шул»,— диде үзалдына Булат бәк, китеп барган хан кызы белән аның артыннан титаклаган хәрам атакайга карап. Һәм үзе дә кисәк кенә борылды да сарайдан чыгып китте. Тәүге кәефе гүя аяк астына төшеп, туфрак-тузанга әверелгән иде.

* * *

Бер кич аерым бүлмәдә кунганнан соң, Айбибине кахан кырына алырга килделәр. Башта кахан аны тәхет ягында кабул итәргә булган икән, хәрам ата шул хакта кереп әйткәч, ул аңа бер сүз дә әйтмәде, әмма ашыкмый гына киенә башлады. Һәм, сәер хәл, аңа кисәк дулкынлану килде. Ул гасабилануга кадәр барып җитте, битенә кершән сөрткәндә, кулларына кадәр калтыравын тойды. Нигә булыр бу?.. Әллә соң мин аңардан шулай куркаммы?.. Курыкмыйм ич, курыкмыйм! Шулай дип үзен юатты, әмма күңеле тыныч түгел иде, йөрәгенә кадәр ешрак тибә башлады. Көзгегә кат-кат күз ташлады. Барысы да әйбәт кебек иде, буе-сыны да, йөзе-кыяфәте дә... Тик барыбер дулкынланды... Нindirәк кеше икән кахан? Хатын-кыз күзе төшәрлекме?.. Кырык хатын белән тора ич! Аңамы кыз кадерен белү!.. Курыкма, кыю бул, кыю бул, Айбиби, кыю бул!..

Хәрам ата, ишекне ачып, башын тыкты.

— Балакай, сүзне алдан башлама. Кахан ошатмас. Үзе сорасын. Йомышларың соңнан әйтерсең.

— Яхшы, сез дигәнчә итәрмен, хәрам ата,— диде аңа Айбиби, ишек ягына карамый гына, һәм тынычлана төште. Әйе, аңа кем белән булса да сөйләшергә кирәк икән, тынычлану өчен.

Тарлавыкка чыкты, хәрам ата чүәген сөйрәп алдан китте һәм Айбибигә әйләнеп карамый гына:

— Кахан йомшак табигатьле кеше, рәнҗетә күрмә тагын үзен, балакай.

— Ул мине рәнҗетмәсә, мин аны рәнҗетергә тырышмам, хәрам ата.

— Бик әйбәт, бик әйбәт, балакай. Менә тәхет ишеге, мин анда үтмәм, кыю бул, балакай. Кахан кыюларны ярата...

— Рәхмәт, хәрам ата.

Айбиби күренүгә, ишек яры торган сакчылар айбалталарын читкә алдылар һәм тәхет ягы ишекләре ачылдылар. Эчкәре ишекләрне ачучылар Айбиби үтүгә, ишекләрне ябып та куйдылар. Айбиби чак кына башын күтәрде һәм түр якта киң терәкле тәхеттә утырган каханны күрде. Ул аңа затлы күренде, һәрхәлдә, күңел күзе шулай кабул итте. Айбиби керүгә һәм аңа күз ташлауга, кахан тәхетеннән купты, әкрен генә, бер сүз әйтми, аның янына килде, ияк очыннан алып, башын күтәрде, күзләренә карады.

— Мин сине көттем, Айбиби,— диде. Гап-гади итеп әйтте: «Мин сине көттем». Аннары терсәгеннән алды да бер якта торган кечкенә өстәлгә таба алып китте. Айбибине урындыкка утыртты һәм үзе аның каршына утырды. Менә шунда Айбиби каханның йөзенә күз төшереп алды. Тутсылрак йөзле иде Йосыф кахан, күзләре кара-күгелҗем, Идел ярларында үскән бөрлегән төсен хәтерләтәләр. Кечкенә йомры сакал, төз борын. Киңчә кашлы. Кул бармаклары нечкә, озын. Әмма тыгыз бәдәнле сыман тоелды Айбибигә булачак ире.

— Исем-атың Айбиби бит, шулаймы, хан кызы?

Айбибигә аның тавышы, нәзакәтле итеп соравы ошады, ул аңа сусыл иреннәрен җәеп елмайды. Әйе, Идел буе Болгар ханы кызының исеме Айбиби, Талиб атасы биргән исем. Әнә шул бала Йосыф каханга кырык беренче хатын булып тартылды. Кабул итсә, кабул итсен, кабул итмәсә, кайтарып җибәрсен. Әчтән шулай дисә дә, ни сәбәпледер бу сүзләрне әйтергә кыймады, аны нидер тыйды, нидер дәштермәде.

— Мин сине, Мөхәммәд хан кызы, болай ук гүзәл булырсың дип уйламаган идем. Мин өлкән раввины да кисәтеп куйдым, атаңа да кат-кат әйттем, Айбиби кызың баш хатын булыр, дип. Һәм мин ялгышмаганмын. Син чынлап та гүзәл зат, минем аккошларымны хәтерләтәсең.

Йосыф кахан Айбибинең кулына үрелде, кулын кулга куйды. Ахыр урыннан купты да Айбибинең алдына тезләнде.

— Ни эчә, ни тели хан кызы Айбиби?

— Чия төнәтмәсе, кахан, чия төнәтмәсе.

Кахан көмеш кыңгырауны зеңләтте. Ишектә хезмәтче күренде.

— Миңа грек шәрабы, хан кызына чия төнәтмәсе китер.

Бавырчы булса кирәк, каханга баш иде дә чыгып китте һәм күп тә үтми, ике кулына ике көмеш бокал тотып килеп тә керде. Бавырчы шул чиккә җитеп юан гәүдәле иде ки, Айбиби аңа кызыксынып карап алды, чөнки теге атлаганда, як-якка авыша, ә аяклары йөрми, шуып йөридер кебек иде. Бокалларны өстәлгә куеп киткәч, Айбиби каханнан сорап куйды.

— Нигә ул шулкадәр юан?

— Бирәннәр санында йөри ул, һәр елны беренче урынны ала. Без ел саен бирәннәр ярышы уздырабыз, шул ярышта һәр елны миннән бүләк ала. Хәрам ата ул, алар барысы да юаннар. Аларга ашаудан башка берни дә кирәкми. Минем хатыннарыма да алар хезмәт күрсәтәләр.

— Ә раввалар нишлиләр?

— Раввалар! — дип гаҗәпләнде Йосыф кахан.— Раввалар һәммәсенә дә күз-колак булып торалар, барысына да. Сарайдагы бар тәртипләрне дә Булан кахан урнаштырып калдырган. Һәм шул тәртип белән яшибез, көн күрәбез, хан кызы Айбиби.

Шулчак тәхет ягына бер көтү җария кызлар килеп керделәр, барысы да өстәлне уратып, каханга килеп елыштылар. Айбиби ни кылырга белми каушый калды. Болар кемнәр? Нинди кыз балалар?..

— Булды, булды,— диде аларга Йосыф кахан.— Булды, китегез.

Кызлар ничек килеп кергән булсалар, шулай чыгып та киттеләр. Айбибинең каханнан сорыйсы килде: «Кемнәр, нинди кызлар болар?» Тик теле бармады. Кызларның яшькелт матур күлмәкләре, башларындагы өрфә калфаклары гына бермәл күз алдында торды.

— Гаҗәпләнмә,— диде аңа кахан.— Хатыннарымнан туган кызларым, мәдрәсәдә укыйлар. Улларым да бар, ләкин аларның берсе дә Аккалада юклар, төрле биләмәләрдә тәрбияләнәләр.

— Кызларыгызны да равваларыгыз укытамы?

— Равваларым укыта. Равваларны мин махсус чакыру аша Исраилдән тарттырдым.

Ни әйтә ала иде ул аңа. Һични! Бит ил каханы, кахан идарә иткән ил астында уннарча ил вә халыклар, барысы да каханатка ясак түлиләр, шул исәптән Идел буе Болгары да. Моны гына яхшы белә иде Айбиби. Ул хәзер үк аңа үз таләпләрен куярга тиеш, иртәгә соң булып куюы бар. Хәзер үк. Айбиби каршында грек шәрабы эчеп торган Йосыф каханга карады, елмайды.

— Хөрмәткә ия кахан, мин Хазарстанга үз иркем белән килмәдем, богаулап ук озатмаса да, мине атам сезнең кырга җибәрде. Мине, хөрмәткә ия Йосыф кахан, йөзләрчә кеше озата килде. Шулар ара-

сында минем шәехем, абыстаем, табибым бар. Алар бире килеп йөрерләрме, әллә булмаса, мин үзем Ханбалыкка алар янына чыга йөрерменме?..

Йосыф каханның тутсыл йөзенә елмаю галәмәте кунды, башын түбән иеп, бермәл як-якка чайкап торды, шуннан соң гына Айбибинең зәңгәр күзләренә карады. Карады да ни сәбәпледер коргаксыган иреннәрен ялап куйды.

— Сарайга бары тик мин биргән мөһерле тәңкә белән генә кереп була, Айбиби. Синең белән килгән гаскәриләр кайтып китәрләр, атаң белән шулай килешенгән. Ә менә абыстаң белән табибың бире керә йөрерләр, аларга кахан мөһере бирелер. Шәехкә юк, шәех Тәбирне мин беләм, аңа иленә кайтып китү хәерлерәк булыр, Мөхәммәд хан кызы Айбиби. Бу минем әмерем шул булыр...

— Рәхмәт галиҗәнаплары, мин сезнең игелегегезне гомерем буена онытмам.

— Гомер буе,— диде Йосыф кахан һәм бокалын өстәлгә куйды.— Шартнамәләргә гадәттә мин илчеләрне кабул итү бүлмәсендә имзам сала идем, хан кызы. Сиңа ташлама ясарга булдым...

Шул сүзләрне әйтте дә кеткелдәп көлеп алды һәм кесәсеннән ике алтын тәңкә чыгарып бирде.

— Шушымы рөхсәт тәңкәсе?

— Ләкин бер шарт белән, якыннарың син бирегә килгән көннән бер ай вакыт үткәч кенә керә алалар. Бу алтын тәңкәләрне мин үз илемдә суктырам. Алар йөрештә, ләкин Аккалага үтү өчен сугылган тәңкәләрдә минем сурәтем вә исемем язылган.

— Ай эчендә мин авырып китсәм?

— Үзем дәвалармын, үзем,— диде Йосыф кахан көлемсерәп.

— Иншалла, Тәңрем мине ташламас.

— Тәңре мәҗүсиләр алласы, хан кызы. Минем сараемда юк-барга ышанмасагыз иде. Мин илемдә һәм калаларымда барча диннәргә дә ирек бирдем, барча диннәргә дә. Ханбалыкта мәчетләр дә, чиркәүләр дә, синагоглар да бар. Минем илемдә һәр адәм баласы үз динен тота ала, хан кызы Айбиби. Шуның өчен синең мөслимә булып калуыңа мин каршы түгел, әмма нә христианнарга, нә мөселманнарга Аккалага керергә рөхсәт ителми. Бу хакта да белеп торсагыз иде, Мөхәммәд хан кызы Айбиби.

Шул сүзләрне әйтте дә Йосыф кахан янә көмеш кыңгыравын зеңләтте, шундук тәхет ягына өч-дүрт равва керде һәм алар бер сүз әйтми, Айбибине өстәл яныннан култыклап алдылар да тәхет ягыннан алып чыгып киттеләр. Һәм янә бер сүз әйтми, аны үз бүлмәсенә кертеп калдырдылар. Ни гаҗәп, ни өчен шулай дип, Айбиби дә сорамады, раввалар да бер кәлимә сүз әйтмәделәр, алып чыгып барганда, кечкенә өстәл янында грек шәрабы суырып утырган Йосыф кахан да авыз ачып бер сүз әйтмәде.

Бүлмәсенә кергәч, Айбибигә кинәт авырсу булып китте. Ул күңел күзе белән карамый гына бүлмәдәге җиһазларны күздән кичерде һәм түр яктагы ятакка барып ауды. Нәкъ менә ауды. Ул һични аңламады һәм аңлар халәттә дә түгел иде. Ни өчен Йосыф кахан шулай итте. Бик матур итеп кенә сөйләшеп утырганнар иде югыйсә. Әйе, күзгә-күз карап, елмаешып. Айбиби бермәл өнсез калды. Ни өчен, ни өчен, ни өчен?! Сорау, сорау, сорау. Әйе, ни өчен аны Йосыф кахан үз кырыннан бик тиз озатты?.. Кинәт атта далага чыгып чапкан Ислам күз алдына килде. Ислам, бәгырь, кая син, кайларда йөрисең?! Син булсаңмы, син булсаң, мине... Әйе, нишли алыр иде Ислам?.. Һични кыла алмас иде, чөнки ул әсир ителде һәм аны Мөхәммәд хан кызын Хазарстан каханы Йосыф әсир итте. Каханнан барысын да көткән иде Айбиби, ләкин һич тә болай булыр дип уйламаган иде. Әллә соң бик акыллы булырга теләдеме?.. Бик ихтимал ич. Нинди ир зат инде үзеннән акыллы хатын-кызны яратсын, ул аңардан көне белән читләшә, көне белән... Шулай диде аңа Рәшидә анакае, шулай. Бик акыллы булып күренергә тырышма, акыллы ир-атны үзеңнеке итәргә теләсәң, башыңны беразга юләргә сал. Үзеңнеке иткәч, акылың күрсәтерсең... Димәк, мин кахан алдында акыллы булырга теләдем, ә бу хәл каханга ошамады. Хәер, син моны үзең теләгән идең ләбаса! Уен-көлке белән каладан чыгып китсәң дә, күңелең бер дә кырык хатыны булган каханга тартылмады, нигәдер күз алдында һәрчак Ислам торды, Ислам булды. Хак, Йосыф кахан аңа ошады, күңеле кинәт йомшарып, йөгәнсезләнеп китте, ләкин бу хәл шундук үтте. Тик бит үтте аны раввалар алып киткәч, югыйсә утырасы да утырасы иде Йосыф кахан белән...

Айбиби яшь төеренең тамак төбенә килеп бөреләнүен тоя, күзләре дымлана, бите буйлап яшь бөртекләре ага башлый. Ләкин ул аңа игътибар итми. Күз алдына яшь томаны аша әле Ислам, әле Йосыф кахан килә. Икесе дә аны кызганалар, юатырга телиләр сыман. Ә ул аларга үпкәле, елый да елый. Их, кырында Рәшидә анакае булса икән! Юата белер иде ул аны, аркасыннан сөя-сөя юатыр, матур-матур сүзләр тезәр иде.

Айбиби шыңшый ук башлады. Шул вакыт тәүге хәрам ата ишекне кысып кына ачты да башын тыкты. Элек игътибар итмәгән иде хәрам атага, ә ул чөенке борынлы, мөлдерәп торган симез йөзле, кысык күзле иде.

— Айбиби бала елый,— диде хәрам ата, ишекне киң итеп ачты, әмма бусагадан узмады.— Тиздән сиңа да нәүбәт җитәр, балакай, елама. Мин сине ашарга дәшәм, ашханәгә, хатыннар анда инде сине көтәләр — баш хатынны.

— Мин баш хатын түгел, мин хан кызы, Мөхәммәд хан кызы.

— Менә шулай, ачулан, ачулану белән үз көеңә кайтырсың. Хан кызымы син, Йосыф кахан хатынымы, сарайга тартылгансың икән, баш хатын инде син, балакай. Баш хатын. Һәм аста, ашханәдә, Йосыф каханның кырык хатыны кулларына кашык тотарга куркып сине көтәләр.

— Хәзер үкме?

— Хәзер үк, балакай, хәзер үк. Битеңдәге яшьләрне әнә теге сөлгегә һәйбәтләп сөрт тә, әйдә...

Айбиби чынлап та кыюланып китте, хәрам атага ияреп китте, барыр җайда ул аңардан сорады:

— Атың ничек, хәрам ата?

— Саул идем, хәзер инде миңа ул исем белән бик сирәк дәшәләр.

— Димәк, син, бичара, яһүд.

— Яһүд, балакай, яһүд. Мине Византиядә шул хәлгә төшерделәр. Рим халкын христиан диненә өндәп йөргән өчен яман халык тотты да...

— Нинди яман халык?

— Мәҗүсиләр, имансызлар.

— Син аларга каһәр укы, атакай, каһәр.

— Каһәр укып кына булган әгъзам кайтса икән ул, балакай.

...Аларны күрүгә, өстәл янында утырган хатыннар шым булдылар, барысы да Айбибигә текәлделәр. Хәрам ата Айбибине кулыннан тотып, тиешле урынга утыртты, Айбиби исә тезелеп утырган хатыннарга күз йөртеп чыкты да, чуар киенгән һәм берсеннән-берсе чибәр күренгән ишләренә сәлам юллады, ахыр:

— Табындагы ашларыгыз тәмле булсын, хатыннар,— диде.

Хатыннар барысы да елмаештылар һәм кашык-ризыкларына үрелделәр. Айбиби дә алдына куелган ризыкка күз ташлады. Савытта балык ите иде, сөяксез диярлек. Хатыннар үзара тыенкы гына сөйләшә-сөйләшә ашадылар, хәрам атакайлар китергән һәр ризык тәмле тоелды Айбибигә, ләкин кайбер ризыклардан баш тартучы хатыннарны да күрде ул. Шунда аның күзе тутсылрак йөзле, зур кара күзле бер хатынга төште. Хатын Айбибигә карый да елмая, карап ала да елмая. Күлмәге яшькелт-сары, өрфә тукымадан булган яулыгын маңгаена төшереп үк бәйләгән. Яулыкка җәйран сурәте төшерелгән. Хатынның бармаклары нечкә, очлаеп киләләр. Сул як битендә чәнчә бармак бите хәтле генә миң. Әллә ясалма, әллә туа-туганнан килә — белмәле түгел. Күз керфекләре озын, өскә таба кайтарылып тора. Күзләрен күтәреп, Айбибигә караган саен, баш хатын буласы һәм инде шул вазифаны үти дә башлаган Мөхәммәд хан кызына уңайсыз булып китә һәм ул аның тарафына карамас була. Хак, Айбиби берәм-берәм башка хатыннарга да күз төшереп чыкты, ләкин ахыр чиктә зур кара күзле хатын барыбер аны җәлеп итә төште.

Табынга алма-хөрмә, җиләк-җимеш китерделәр. Нигәдер Айбиби хатыннар йөзендә моңсулык күрмәде, хатыннар үзара сөйләшә-сөйләшә ашыйлар, хәтта көлешеп тә алалар, ә менә зур кара күзле хатын берсе белән дә сөйләшми, аралашмый, тик әкрен генә ашап утыра, әмма юк-юк та Айбиби ягына карап ала һәм, озын керфекләрен каккалап, күзләрен түбән төшерә иде. Күр әле, бер гаиләдәй яшиләр икән бит Йосыф каханның хатыннары, ә аңа әллә ниләр сөйләп бетерделәр. Әйе, өйдә чакта, сарайда — Болгарында. Имеш, хатыннар арасында төрле хәлләр булгалый, үзара кахан өчен ызгышып та алалар. «Тик бер ирне ничек кырыкка бүлергә була икән?» — дип уйлады Айбиби, бала башы хәтле зур алманы пычак белән телгәли һәм телем-телем ашап утыра-утыра. Бәхәссез, кахан хатыннары барысы да аны өзелеп яратмыйлар һәм үзләренә тиешле көнне зарыгып көтеп алмыйлардыр. Бит нигездә аларны бикләп тоталар. Хак, еш кына калага алып чыгалар, Идел буена алып төшәләр, көймәләрдә йөртәләр, әмма һаман да шул бер хәрам аталар.

Ашап-эчкәч, шау-шу килә-килә хатыннар бүлмәләренә таралыштылар, Айбиби дә хәрам ата озатуында үз бүлмәсенә таба кузгалды. Шунда ул кырын күзе белән генә күрде, хәрам атадан кала төшеп, әнә шул зур күзле хатын атлый һәм аңа, нидер әйтергә теләгәндәй, ымсынып куйгандай итә. Һәрхәлдә, Айбибигә шулай тоелды. Хәрам ата исә башын түбән игән дә атлый да атлый, берәүне дә күрми, күрергә дә теләми сыман. Аңа кахан хатыннар оясы ике дөнья бер морҗа иде, күрәсең. Хәрам атакайга күз ташлауга, хәтер күгендә эленеп калган карт алаша пәйда булды. Андый атлар күбрәк субашларда, ягъни иген игүчеләрдә, җир сукалаучыларда булырлар иде. Мескен ат сукадан туктагач, арып-алҗуы шул чиккә җитә иде булса кирәк, күз кабакларына кунган явыз чебеннәрне дә кумас иде. Бу хакта аңа Рәшидә абыстай да сөйләде, мескен атны адәми затлар кайчандыр рәнҗеткәннәр, бер әгъзасыннан мәхрүм иткәннәр. Тик бу ни була инде?! Кая монда гаделлек?! Ничек Аллаһыдан курыкмыйлар кахан раввалары?.. Рәшидә абыстае бу хакта бик тәфсилләп сөйләсә дә, ул вакытта Айбиби моңа гомумән көлеп караган иде. Монда исә ул кешеләрне үз күзе белән күрде һәм хәрам атаны Айбиби кызганып куйды.

— Хәрам ата, бар инде, син кит, үз юлыңда бул. Мин үзем дә бүлмәмне табармын.

— Яхшы, балакай,— диде хәрам ата һәм аягын сөйрәп китеп барды.

Айбиби артына әйләнеп карады, зур күзле хатынны көтеп алды.

— Исем-атың ничек? — дип сорады ул, хатын килеп җитәр-җитмәс.

— Хәдичә атлы мин, Хәдичә атлы.

— Кай илдән тартылдың?

— Гарәбстаннан.

Төрки телдә сакаурак сөйләшсә дә, сүзләрне дөрес әйтә иде Хәдичә хатын.

— Атаң-анаң кем иде?

— Хәлиф җариясе идем мин, хәлиф җариясе. Минем сезнең бүлмәгезгә керәсем килә, әйтер сүзем бар,— диде хатын, Айбибинең күзләренә карап. Зур кара күзләрдә нииндидер сихер бар кебек тоелды Айбибигә, әмма хатынның кәефен кырырга теләмәде.

— Әйдә соң,— диде ул һәм алдан китте.

Бүлмәгә кергәч, Хәдичә хатын әйтте:

— Бүген безне Аккошлар култыгына алып төшәчәкләр, Йосыф кахан да киләчәк.

— Нинди аккошлар тагын?

— Монда аккошлар үрчетә торган култык бар, Идел елгасы култыгы, шунда аккошлар төшәләр, ә без аларны ашатабыз, Айбиби.

— Син минем исемемне дә беләсең? — дип «син»гә күчте Айбиби.

— Безгә бу хакта раввалар күптән җиткерделәр инде. Сезгә Идел буе Болгарыннан баш хатын тарттырачаклар, диделәр. Кахан ятагына керергә нәүбәтне дә син куячаксың, диделәр. Минем кахан ятагына кергәнем булмады дияргә була.

— Нигә алай, Хәдичә? — Айбиби хатынны кулыннан алды, ятакка утыртты.

— Яратмадым мин аны. Ул үз динен барча диннәрдән дә өстен күрә. Ә бу саташудыр. Аннары мине ул никахсыз алырга теләде. Шуның өчен минем синең белән сөйләшәсем килә. Син дә бит мөслимә. Кахан ятагына никахсыз үтәргә исәбеңме әллә?

Моны Айбиби Хәдичә хатыннан көтмәгән иде, ул аның янәшәсенә утырды, ике учы белән хатынның битләреннән алды, күзләренә карады. Һәм гүя төпсез диңгезгә чумгандай хис итте үзен. Ни бу, ни булды аңа?.. Айбиби аны кочагына алды, назлый-сөя башлады, гүя Хәдичә хатын нәни бер бала иде. Хәдичә калтырана һәм аңа елыша башлады. Ахыр елап ук җибәрде.

— Без бүген, өрфә күлмәкләр киеп, Аккошлар култыгына төшәчәкбез. Барчабыз да...— диде шыңшый-шыңшый Хәдичә.

— Син әле дә сафмы?

Хәдичә Айбибинең күзләренә карады, күзләрендә мөлдерәмә тулы яшь иде.

— Мин мөслимә, мөслимә, Айбиби. Мөслимә. Ә ул мине кимсетмәкче, рәнҗетмәкче. Булмас ул, булмас!..

— Тынычлан, Хәдичә, сине мин рәнҗетергә бирмәм.

Хәдичәнең зур күзләре тагы да зураеп киттеләр. Ул бертын ни әйтергә белми торды. Ышанды да кебек ул Айбибигә, ышанмады да, чөнки бит хан кызы каханның ятагында да булмаган иде. Моның өстенә хәрам атакайлар күзәтәләр, баш хатын булып алган Айбиби кемне дә булса яклаbackward, йә булмаса, аңа нинди дә булса ярдәм итсә — Айбибине җәза көтәчәк һәм бик яман җәза. Айбиби белми булса кирәк әле, Хазарстанда ил белән Сабир каханбәк идарә итә, ә каханбәк белән кахан, кахан белән өлкән равва. Хәрам аталар да барысы да өлкән раввага буйсыналар, әйе, сарайдагы казнабашка кадәр өлкән раввага хисап тота. Тәүге өлкән ravваның кахан хатыннарының беренә күзе төшә һәм, җай китереп, теге бичара хатынны бүлмәсенә алып керә. Ә хәрам аталар бу хәлне каханга җиткерделәр. Кахан исә каханбәк Сабирны дәшеп алды да барча хатыннары алдында бер-берсен яратышып кавышканнарны кылычтануздыртты. Гыйбрәт булсын өчен. Менә нинди шартларда яшиләр алар кахан кулында. Айбиби исә боларның берсен дә белми булса кирәк.

— Безне далага да алып чыккалыйлар. Бер тапкыр шулай далага чыккач, кыргый угызлар каханның ике хатынын урлап алып киттеләр, кахан сакчылары кыз урлаучыларны куа барсалар да, якын килергә курыктылар, чөнки угыз мәргәннәре оста мәргәннәр, очкан кошның күзенә тигезәләр. Әмма кахан моңа бер дә лаф ормады. Шул хатыннар иленнән вә халыкларыннан тагын икешәр хатын тарттырды.

Айбиби бер сүз дә әйтмәде. Ул белә иде, яһүд раввалары борын-борын заманнардан ук күп хатыннар тотканнар. Әйтик, Сөләйман пәйгамбәрнең 900 хатыны була. Ә менә Хазарстан каханына 900 хатын тотарга раввалар рөхсәт бирмәгәннәр. Кырык хатын җитәр, дигәннәр. Һәм шул хакта хәтта канун чыгарганнар. Йосыф кахан да әнә шул канунга таянып яши, ил белән идарә итә.

Шулай диде дә Хәдичә хатын янә Айбибигә килеп сыенды һәм елтырый башлаган күзләре белән хан кызына карады.

— Минем дә кемнәрдәндер сөеләсем килә, Айбиби. Сөй әле, ярат әле мине, мин бичара саф калган кыз баланы, синең кебек кыз баланы, Айбиби ахирәт.

— Ахирәт! — дип гаҗәпләнде Айбиби, ә үзе Хәдичәне кочагына алды, чәчләреннән сыйпады, аркасыннан, янбашыннан сөйде, әнә шуннан соң аның үзенә дә әллә ниткән аңлап та, аңлатып та булмаган якынлык ташкыны килеп орылды. Аның кочагында Хәдичә түгел, гүя сарай табибы улы Ислам ята иде. Юк, кахан үзе. Айбиби Хәдичәнең башын тагы да күкрәгенә кыса төште һәм күкрәгенә елышкан саен мөслимә кызның калтырана башлавын тоеп, ни өчендер кисәк сискәнеп китте. Бөтен тәнен тетрәнде-

реп, сәер бер халәт узды, колак түрендә татлы бер рәхәт зеңләп, йөрәгеН җилкетеп куйды. Шушы назлау, шушы сөю аңа шул чиккә җитеп рәхәт бирде ки, ул чак кына кычкырып җибәрми калды. Һәм шунда зиһене аша курку хисе узды. Кемдер ишекне шакый кебек тоелды.

— Кем бар анда?!

Хәдичә иңенә төшкән өрфә яулыгын рәтләде, кызарынып киткән күзләре белән көзгегә барып капланды. Һәм Айбибигә карамый гына:

— Никахсыз каханны яныңа алма, хан кызы,— диде.

Айбиби торып, ишекле-түрле йөреп килде.

— Ничек инде никахсыз, Хәдичә ахирәт?..

— Мулла чакыртсын да никах укытсын, шуны таләп ит. Син баш хатын буласы кеше, шуны таләп ит. Минем кебек. Без хәзер синең белән ахирәтләр, Айбиби.

— Ахирәтләр,— диде тыенкы гына Айбиби, бу сүзнең ахырына төшенми торып.

— Ләкин бит аның мине...

— Әйтмә алай, Мөхәммәд хан кызы, әйтмә,— дип, Айбибигә таба борылды Хәдичә. Аның зур кара күзләрендә чаткылар җемелди кебек иде.— Без ахирәтләр, ахирәткә кадәр бергә булырга тиешбез.

— Кахан бар хатыннарын да үзе...

— Белмим,— диде Хәдичә, аның янына ук килеп.— Белмим, кайбер булачак хатыннарын хәрам аталар сөяк белән...

— Бу хакмы, Хәдичә?

— Кахан кайбер хатыннарын әнә шул ысул белән эш иткәннән соң кабул итә, диләр. Ләкин мин ышанмыйм. Хәрам аталар миңа кагылмадылар, гөнаһка керәсем килми.

— Өлкән равва да сабак бирәме?

— Атнага бер, шимбә көнне, шимбә яһүдләр көне.

— Мин аны кайчан күрә алам?

— Белмим, ләкин син аны күрерсең. Ул кайчак Аккошлар култыгына да төшә... Каханга ияреп.

— Нигә?

— Белмим. Өлкән равва һәммәсенә дә баш кеше, хәтта кахан да аңа буйсына.

— Миңа кахан табибым һәм абыстаем сарайга кертергә рөхсәт бирермен, диде. Тик бер айдан соң дип әйтте.

— Табибың кем?

— Җиткән егет, мин аңа гашыйк идем, тик Йосыф каханны күрдем дә ул күңел түремнән китеп, читкәрәк басты кебек.

— Син каханга гашыйк булдың, Айбиби?!

— Юк, дисәм, ялганлармын дип куркам, Хәдичә ахирәт. Ул минем алдыма тезләнде, башын тезләремә салып торды һәм мин аны үзем дә сизми башыннан сыйпый башладым. Ошады миңа кахан, Хәдичә ахирәт, кичер мине.

— Абыстаең бу хакта беләме?

— Юк, ул бернәрсә дә белми, алар Ханбалыкта, аларны сарайга уздырмадылар.

— Мин сиңа бернинди дә киңәш бирә алмыйм, ахирәтем, йөрәгең ни тели, йөрәгең ни әйтә — шулай ит.

Шулай диде дә Хәдичә хатын чыгып китте. Айбиби ятагына килеп утырды да, маңгаен учларына салып, бертын уйланып утырды. Ниләр сөйләде ул ком сахрасыннан килгән һәм бөтенләй ят табигатьтә туып үскән кызга һәм, иң гаҗәбе, нә атасын, нә анасын белмәгән кешегә. Ә бит аның равваларның шымчысы булып куюы да бар иде. Айбибинең бер мәлгә зиһене чуалды, ни уйларга белми үзенең самимилегенә исе китеп, бик озак бер ноктага карап торды. Кая караганын ул белмәде, чөнки бөтен уйхисе күңел түрендә, йөрәген тыңлый иде. Шунда ишек шакыдылар, гадәттәгечә хәрам ата башын ишеккә тыкты.

— Мөхәммәд хан кызы Айбиби балакай, өрфә күлмәгең ки. Күлмәгең шкафта. Аккошлар култыгына төшәбез.

— Ярый, атакай,— диде Айбиби. Һәм, торып, көзге янына килде, битләрен сыйпаштырды, чәчләрен рәтләде, шкафны ачып, дистәләрчә күлмәкләр арасыннан өрфә күлмәкне табып, анадан тума чишенде, шул күлмәкне киде дә нindider үзе дә аңлап бетермәгән оялу тоеп, көзге алдына килеп басты. Хак, адәм тәнен өрфә күлмәк яшерә иде, ләкин барыбер тән күренә, сихерле бер серләр йомгагы аша күренә иде. Айбиби нечкә биленә, калку күкрәкләренә игътибар итте, эчкә баткан кендегенә, гәүдә-сынына һәм, барысыннан да канәгать калып, үзалдына елмайды. Аны шушы күлмәктә күргәч, кахан йә егылып китәр, йә сукыраер. Сукыраймаса да, Айбибигә ияреп киткәнен сизми дә калыр. Кинәт кенә Айбиби бер башка үскәндәй булды. Баш хатын булганы өчен генә түгел, гүзәллеге һәм зифалыгы белән дә, зәңгәр күзләре белән дә, төсе-йөзе белән дә... Тагын ние белән?.. Менә анысын белми иде Айбиби.

* * *

Аккошлар култыгына аккошлар ашатырга төшкәндә, Хәдичә анда иде инде. Хатыннар барчасы да аңа игътибар иттеләр. Чөнки Айбиби аларның барчасыннан да күлмәк төсе белән генә түгел, яшьлеге, сафлыгы белән аерылып тора иде, чөнки аның йөзенә каханның һәммәсенә дә битараф булган гамьсезлеге, хатын-кызга булган мәхәббәтсез генә тартылу халәте кунмаган иде. Ул чынлап та хатыннар арасында Идел суы читенә сибелгән гади ташлар арасындагы бәллүр иде. Күзе-йөзе генә түгел, гәүдә-сыны да җем-җем итеп тора, үзенә дәшә, чакыра иде. Моны Айбиби шундук сизеп алды һәм, әлбәттә, ахирәте Хәдичә дә.

Айбибигә аккошларга җим ашатырга җим китереп бирделәр. Җим вак балыклардан тора, тубалга салган, су кырына киләсе дә аккошларга ташлыйсы гына. Һәм Айбиби шулай итте дә. Шунда бер могҗиза булып алды. Ике аккош сөешә башладылар һәм беркемгә игътибар итми яратышалар иде. Муеннарын муеннарына урыйлар, әле чумып китәләр, әле канатларын җәеп кочаклашкандай итәләр дә су өстендә биешә башлыйлар. Хатыннарның күзләре сөешкән аккошларда иде. Кошларның сөешүләре хатыннарны тәмам сихерләде, алар тып-тын калдылар, хәтта үзара сөйләшүдән дә туктадылар. Әмма бер читтәрәк торган хәрам аталар бу хәлгә исләре китми ком өстендә утыра бирделәр. Хәдичә Айбиби янына килде һәм ахирәтенең кулыннан алды да каты итеп кысты.

— Алар бер-берсенә гашыйклар, алар бер-берсен яраталар, шулаймы, Айбиби?

Шунда хатыннарның берсе:

— Кахан, Йосыф кахан! — дип кычкырды.

Барысы да кахан килгән якка әйләнеп карадылар. Йосыф кахан чынлап та килә иде һәм нәкъ алар, ягъни хатыннары аккошлар ашаткан җиргә. Йосыф кахан җемелдәп торган яшькелт-кызылсу халаттан иде, аны хәрам атакайлар каршы алдылар һәм су буена озата кузгалдылар. Һәр атакайның кулында озын таяк.

— Таяклар нигә? — дип сорады Айбиби, Хәдичәгә карамый гына.

— Таяклар каханга үрелгән хатыннарның кулларына сугарга,— диде Хәдичә.

— Каханга тотынырга да ярамыймыни?

— Ярамый.

— Баш хатын буласы кеше мин тотынсам. Әйе, гәрчә ятагында булмасам да.

— Син, Мөхәммәд кызы Айбиби, башта раввалар кулыннан узарга тиешсең?

— Ничек раввалар кулыннан?

— Алар синең сафлыгың тикшерергә тиешләр.

— Сине дә тикшерделәрме?

— Мине дә тикшерделәр. Ләкин мин мөслимә буларак каханнан баш тарттым. Никах укыткач, дидем. Кахан килеште, әмма мулланы чакырмый да чакырмый.

— Йосыф кахан төрки ич, нигә ул...

— Атасы төрки булган, диләр, ләкин әнисе Сара Таман тархан кулында, ул анда Айгөл хатынның угылын үстерә. Балигъ булгандыр инде ул бала.

— Апамның улы бирегә беркайчан да кайтып күренмәдеме?

— Юк, моны кахан үзе теләми, диделәр. Каханны ефәк бау белән сынагач кына, өлкән равва рөхсәте белән угланны бирегә алып кайтачаклар.

Айбиби күзләрен каханнан алмады, ә үзе Хәдичә хатынны тыңлады, аны Йосыф кахан кызыксындыра башлады. Ул аның кырына кырык беренче хатын булып килде. Кайчан һәм кай көнне мәшһүр кахан аны ятагына тарттырыр. Тарттырган хәлдә ул нишләргә тиеш, каханга Хәдичә хатын кебек шарт куяргамы, әллә карусыз кочагына иңәргә тиешме?.. Кем аңа бу хакта киңәш бирә ала? Һичкем. Чөнки киңәшчесе Рәшидә абыстай кырында юк, ансыз аңа биредә яшәве кыен булыр, бик кыен хәтта.

Күр инде, Йосыф кахан туп-туры аңа таба килә. Туп-туры, һичкемгә игътибар итми. Айбибигә җитәрәк атакайлар туктадылар, таякларына таянып, нидер көтеп тора башладылар. Кахан Хәдичәгә: «Кит!» — дип кул гына селтәде. Шулчак Айбибигә оялу килде. Бит аның бөтен тәне-җаны хәтта үтәли күренә. Хак, Рәшидә абыстай аңа барысын да өйрәтте, ирләр белән хатыннар арасында булган хәлләрне дә тәфсилләп сөйләр иде. Ни кылырга, ничекләр үзеңне тотарга. Бигрәк тә кыз белән кияү арасында буласы якынлыкны, булганнан соң булган хәлләрне... Тик бит монда ул кияүгә чыкмый, аны көчләп каханга тарттырдылар, көчләп. Ул монда бары тик атасы Мөхәммәд хан үтенече белән генә килде. Бары тик! Һәм ни кылмак кирәк, Йосыф кахан аңа ошады. Юк, ул аңа гашыйк булмады, була да алмады, ләкин инде кахан аны алтын җеп белән булса да үзенә бәйләгән иде. Бу беренче очрашуда ук булды, кахан үзенең башын аның тезләренә салгач та...

Йосыф кахан гадәттән тыш озын халаттан иде, халаты ялт-йолт килә, башында шундый ук алтын җепләр белән тукылган чәпләшкә. Ярым яһүд, ярым төрек Йосыф кахан, ике халыкның да сыйфатын үзенә җыйгандай, үзен горур тота. Моны аның кыяфәтеннән үк күреп була. Баш чөелгән, ияге алга чыккан, күзләрендә эчке бер хиссият белән тулы елмаю. Ул өстен, барчасыннан да өстен, әле яшь, ир урта-

сы, ә монда яңа табадан төшкән кебек бер кабып йотардай Идел камышлары арасында үскән чәчкә кебек асыл зат — япь-яшь кыз бала, җитмәсә, Идел буе ханы кызы, аксөякләрдән, борынгы аксөяк нәселләрдән килгән сылу.

Якын ук килгәч кенә күрде-тойды Айбиби: Йосыф кахан күрер күзгә бер дә хатын-кыз кызыкмаслык ир зат түгел икән шул. Сарайда чакта каханның буй-сынына ул чаклы игътибар итмәгән иде Айбиби, монда исә кахан бөтен барлыгы белән аның күңеленә кереп оялады. Ул аны күңеле белән кабул итте. Бит-йөзе генә түгел, сызылып киткән кара мыегы да каханга килешеп тора иде. Күз карашында ниндидер йомшаклык, табигыйлек, эчкерсезлек.

Янындагы Хәдичәне гүя җил алды, Йосыф кахан аның каршына ук килеп басты. Айбиби оялудан (үтәли күренә иде ич, аңа бу ир-ат аның йөрәк тибүен күрә кебек тоелды) башын түбән иде, аяк очларына карады. Һәм шунда каханның болгари итек башында бармак башы кадәр зөбәрҗәт таш күреп, күзе чагылып китте.

— Айбиби, Айбиби,— диде килеп туктауга Йосыф кахан.— Аккошлар ашатырга төштекме? Ошадымы безнең аккошлар? Әйе, минем аккошлар?..

— Мин аларга җим ашаттым инде, хөрмәткә ия кахан,— диде Айбиби һәм бер читтәрәк басып торган атакайларга күз ташлап алды. Моңа кахан да игътибар итте, борылды да атакайларга китәргә ишарә ясады.

— Айбиби Мөхәммәд хан кызы атакайлардан ояла,— диде Йосыф кахан.

— Мин сездән дә оялам, Йосыф кахан, сездән дә. Алып китегез мине моннан, югыйсә мине җир убар.

— Җир убар,— дип кеткелдәп көлеп алды Йосыф кахан, һәм күз ачып йомганчы Айбибине кулына күтәреп алды да ерак булмаган чатырга таба алып китте. Айбибинең өне алынды, ул курка калып, каханның муенын кысып кочты.

— Менә шулай, шулай кирәк, хан кызы,— диде Йосыф кахан, һәм аны чатырга кертеп, йомшак җофар тиресе җәелгән түшәккә салды. Ә үзе сиздерми генә кырына ятты.

— Миңа оят, миңа...

Йосыф кахан бер сүз әйтми, аны сөя-назлый башлады. Башта Айбиби үзе дә аңламаган курку тойды, ахыр сөю-назлауга чарасыз калып, үзе үк аңа тартылды. Кахан аны шундаен сабыр һәм әкрен генә назлады вә сөйде, үпте, яратты ки, Айбиби хуштан язар дәрәҗәгә җитеп, үзе дә сизмәстән татлы итеп ыңгырашып куйды. Шушы халәте, татлы итеп ыңгырашып куюы, торган саен каханга сыена баруы илбашының канын кыздырды бугай, ул сак кына аның күлмәген салдырды, тыгыз күкрәгенә кагылды һәм Айбибине бөтенләй чарасыз итте. Ул инде бернәрсә дә ишетми, ул наз-сөюдән тәмам хиссият дулкынында тирбәлә иде. Ләкин кинәт Айбиби авырту тойды, авырту йөрәгенә ук булып кадалгандай итте, әмма ул инде һични тоймады, хуштан язган иде.

Зиһене аның бик акрын ачылды, сизелер-сизелмәс кенә. Башта ул күзләрен ачмый гына янындагы кешене капшады. Йосыф кахан иде аның кырында. Һәм ул анадан тума шәрә ята, күзләрен йомган, тәнәгъзалары тәмам таралган сыман. Зиһен почмагында ниндидер шәм яна, әмма аңлашып җитми, ни булды аңа?.. Шулай буламы хатын булу? Нигә ул аңа һични әйтә алмады. Бит ул мөслимә, һич югы, никах укытсыннар иде... Нигә шулай ул аңа карусыз бирелде. Белде бит ни өчен каханның бирегә алып кергәнен. Белде, әмма һичнинди каршылык күрсәтмәде. Бу ни була инде... Әнә Хәдичә үз-үзен тыя алган, никахсыз каханны үз кырына китермәгән, ә ул хан кызы Айбиби каханның наз-сөюенә чарасыз калып, хуштан язуга кадәр барып җиткән. Нигә соң әле ул булган хәлне сизми калды?! Нигә?!

Шунда кинәт янә йөрәгенә энә белән кададылар. Булган хәл кисәк яңадан кабатланды. Айбиби янә хуштан язды. Уянып китсә, Йосыф аның битләренә суккалый.

— Уян, уян инде, Айбиби! Ни булды сиңа?!

— Мин белмим, кахан, мин бернәрсә дә белмим. Мин курыктым, бит мин сиңа никахсыз бирелдем, бит мин мөслимә?!

Айбиби кисәк капланды да үксеп-үртәлеп еларга тотынды. Кахан югалып калды, аны юатырга керешә, үзе сөйде-назлады...

Айбиби шактый вакыттан соң гына тынычланды һәм бер сүз әйтми чатыр түшәменә карап ятты.

— Мин хата кылдыммы, каханым?

— Юк, Айбиби җанкай, син хата кылмадың. Син миңа бирелдең, каханга...

— Мин моңа шатланырга тиешме?

— Әйе. Чөнки син минем баш хатыным. Бу сарайда сиңа беркем бер сүз әйтә алмас. Беркем бер сүз дә, Айбиби җан!

Ул аны тагын сөя-назлый башлады, ә үзе тылсымлы сүзләр тезде. Ул аны әле Аккошлар култыгындагы аккошка, әле күлдәге төнбоек чәчкәсенә, әле күктәге айга, әле йолдызларга, әле кояшның үзенә тиңләде. Ахыр әйтеп куйды:

— Син минем бердәнберем!

— Бердәнбер кеше кырык хатын белән тормый, Йосыф кахан.

Йосыф кахан бер мәлгә югалып торды, нидер әйтәсе итте, әмма әйтмәде, Айбибине рәнҗетермен дип уйлады бугай.

— Син минем иң-иң яраткан хатыным, Айбиби.

Ни гаҗәп, кахан янә аны сөйде, назлады, үпмәгән җирен калдырмады. Айбиби янә бөтен тәне буйлап тетрәнү үтүен тойды, назга бирелеп, аңа тартылды. Күр әле, аның бармаклары тигән бер җирен гүя рәхәтлек уты өтеп ала. Шушымы мәхәббәт?.. Ә Ислам?! Ислам белән булганда ни булды соң?.. Болай ук татлы булмады ич! Ә монда кахан кагылган саен күккә аша, җаны күгәрчен кебек гөрли башлый.

Арып-алҗып бертын яткач кына, Айбиби аңа әйтте:

— Мин һичкем гафу итмәслек гөнаһ кылдым, каханым. Мин, Мөхәммәд хан кызы.

— Шатланасы ит, Айбиби, шатланасы ит, Айбиби, шатланасы ит!

Шулайдыр, бик ихтимал, ул шатланырга тиештер. Ни өчен? Кахан йөрәгенә үтеп кергән өченме?.. Никахсыз! Нә уйлар, нинди бәһа бирерләр миңа фәрештәләрем...

Ә шулай ятуы рәхәт иде. Бөтен тәнендә тымызык кына уяну хисе, җаны ял итә. Уналты ел буена көткән һәм Аллаһы тарафыннан бирелгән Ана булу йөген алган тән-җан сабырланып калган иде. Хәтта яңа гына йөрәгенә ук кадаган кеше дә инде аңа ят түгел, якын, бик якын булып күренде, гәрчә каханның кырык хатыны булса да, ул аныкы булды һәм ул аңа бирелде, һәм үзе теләп...

Айбиби үз йөрәк тибешен тоя, күңел түрендә челтерәп кенә чишмә ага башлаган кебек иде. Чишмә челтери, ә күңел сафлана бара. Бит ул әнә шул сафлыгын югалтты, ә күңел сафланган, агарынып, чистарынып, пакьләнеп киткән кебек. Әллә соң бәхетле мизгел дигәне дә шушымы?..

— Сизденме шуны, Айбиби, син бит мине кочагыңда кысып үтерә яздың. Мин үзем дә күккә ашкандай бер халәттә калдым, кичер. Мин сине ярattым. Инде тор, киен. Идел суында коенып чыгыйк. Мин сине тагын дәшәрмен. Җаның сүрелә төшсен, татлыны тансыклый төш. Син баш хатын ич. Мин дә, өлкән равва да шулай хәл иттек.

Менә кайчан, әнә нинди сүзләрдән соң Айбибинең күңеленә гарьләнү килде. Һәм ул, тезләрен кочаклап, торып утырды, бертын як-якка селкенеп алды, үртәлде, кимсенде, әмма дәшмәде. Тик бераз шулай торгач кына:

— Миңа оят, оят, каханым. Атакайлар алдында, кырык хатының алдында син мине көпә-көндез чатырыңа күтәреп алып кердең... Шуннан соң мин аларның күзләренә ничекләр күреним? — диде.

— Сиңа оят булырга тиеш түгел, син горурлан. Бу хәл моңа кадәр бер хатыныма да тимәде.

— Никахсыз...

— Дин кануннарым бозмадым мин, Айбиби. Минем дәүләтем үзенә бер сәясәт белән яши. Мин Багдадка да, Византиягә дә баш имәдем, имәячәкмен дә... Хак, мин, атам төрки булса да, яһүдләр диненә йөз тотам, әмма борынгы төрки бабаларыбызның Тәңре динен дә күз угыннан ерак йөртмим, ислам динен дә чит күрмим, христианнарга да ук атканым юк. Дәүләтемдә мин аларның барысын да тигез күрәм. Дөньядагы бер дин дә адәм балалары яратып якынлык кылганны гөнаһка санамый. Ә менә һәр дин бу мәсьәләгә карата үз канунын чыгарган. Менә монысы инде зур хатадыр, Айбиби. Миңа уннарча халык ясак түли, мин ул халыклардан гаскәриләр җыям, шул гаскәриләр белән дошманнарыма яу йөрим, ил-халкымны яклыйм, аларның тыныч яшәүләрен телим. Синең Аккалага тартылуың аркасында атаң Мөхәммәд ханга мин ташлама ясадым, аны күп кенә ясаклардан азат иттем. Моны мин синең өчен эшләдем, Мөхәммәд хан кызы Айбиби, синең өчен. Мин беләм, сине Мөхәммәд хан тәрбияләп кенә үстерә, синең атаң Талиб хан. Бу хәлгә, исән булса, Талиб атаң да каршы килмәс иде. Мин тынычлык телим, мин тынычлык яратам. Һәм тәртип.

— Раввалар сиңа ярдәм итәләрме, каханым?

— Әйткәнем булыр, раввaларым сиңа да, миңа да ярдәм итәрләр, Айбиби хатын.

— Мин сиңа ышанам, ышанам, каханым, ышанам... Мин үз нәүбәтемне һәрчак сагынып көтәрмен...

— Яраткан егетең бар идеме? Миңа җиткерделәр, синең кулыңны бөҗәнәк ханы Түрә улы Айдар сораган икән?

— Мин белмим, бик мөмкин, сорагандыр да, ләкин син, каханым, өлгеррәк булып чыктың, синең белән чәчем бәйләдем...

Йосыф кахан бер сүз дә әйтмәде, Айбибинең битеннән үбеп алды да, иңенә халатын салып, чатырдан чыгып китте.

Ул да түгел, Айбиби киенеп өлгерүгә, чатырга өч равва керде һәм өчесе дә хан кызының аягына төштеләр.

— Ни тели, Айбиби хатын?..— диделәр раввалар бер-авыздан.

— Мин теләгәнем алдым инде, раввалар, юлыгызда булыгыз... Хатыннарны да алып китегез...

Бу аның беренче боерыгы иде, раввалар ни сәбәпледер гаҗәпләнә калып булса кирәк, күзгә-күз карашып алдылар, әмма бер сүз әйтми чатырдан чыгып шылдылар. Чатырда берүзе калган Айбиби чатыр эченә күз йөртеп чыкты, ахыр хәзер генә кахан белән икәүләшеп аунаган ятакка күз ташлап алды. Күзе ятакка төшүгә, каханның үзен назлавы зиһенендә чагылып үтте. Барысы да шулай хатын булалар микән?.. Айбиби шушы ятакта нәрсәдер тапкан да, югалткан да кебек иде. Ничек булды соң әле? Кахан

аны сак кына шушы ятакка китереп салды, аннары назлый-сөя башлады. Айбиби анадан тума шәрә калуын сизми дә калды. Аннары ни булды? Юк, анысын күз алдына китерәсе килми. Җанга рәхәт тулып ятканда, кинәт авырту булды. Калганын Айбиби хәтерләми. Ни булды шуннан, ни кылды аның белән Йосыф кахан?.. Хәтерли алмады. Нигә карышмады ул! Бит кул-аяклары да богауда түгел иде...

Шаккатмалы хәл иде.

Ләкин булганы булган иде инде. Ул көн эчендә хатын булды.

Айбиби бертын чатыр эчендә басып торды да, япманы ачып, тышка карады. Нә су буенда, нә комлыкта бер кеше дә юк иде, бары тик аккошлар гына саллы гына арлы-бирле йөзәләр. Матурлар, горурлар, башларын югары тоталар. Айбиби чатырдан чыкты да су буена таба китте, барыр җайдан чүәген салып атты һәм килер җайдан ук чишенә башлап, салган әйберләрен ташлый-ташлый суга җитте, кереп үк китте. Аңа рәхәт-рәхәт булып талгын җил чыгарган дулкын килеп орылды, дулкын аны гүя үзенә дәште, Айбиби, колачларын киң җәеп, йөзеп китте. Аккошлар аңа карап туктап калдылар. Менә шунда, ар яктагы камышлык кырында, Айбиби ялгыз аккошны күрде. Айбибине күргәч, аккош каңгылдап куйгандай аваз чыгарды һәм күптәнге танышын күргәндәй, аңа таба йөзеп килә башлады. Килеп җитәрәк, тәпиләренә басты, канатларын киң җәеп, җилпенеп алды. Айбиби белән уйнарга теләгәндәй чумды һәм аңа таба су астыннан йөзеп китте. Ләкин нидәндер курка калды, кире су кырына таба борылды. Яр кырына җитәрәк судан чыкты, башын чайкап, әйләнеп аккош калган якка карады. Аккош аның янәшәсендә иде. Ул, канатларын җәеп, Айбибине кочагына алгандай итте дә, кинәнә-кинәнә, су өстендә биергә кереште. Аның бу кыланышына йөзләрчә аккошлар карап тордылар, ә бер ишләре берни булмаган кебек су төбеннән җим эзләделәр.

Аккош аңа килеп сыенуга, Айбиби, коты алынып, судан йөгереп чыкты һәм рәхәтләнеп үзеннән-үзе көлә башлады. Аккоштан курыкты ич, аккоштан, үзенең иң яраткан кошыннан!..

Көлә-көлә киенде, ә аккош һаман су өстендә бии, әле әйләнеп килә, әле каңгылдап куя. Өс-башын киде, чүәкләрен эзләп тапты һәм шунда аңа рәхәт булып китте, әйтерсең барысын да Идел суы юган иде, кылган гөнаһысын да, мәхәббәтен дә (кемгә икәнен ачыкламады), гүя ул сафланып, пакьләнеп калган иде. Һәрхәлдә, Айбибинең күңелендә шундый хис туды. Чатырны узып, сарайга таба юнәлгән генә иде, аңа каршы өлкән равваның килүен күрде. Бу кешенең йөзе таныш иде инде аңа. Шып туктады, көтеп алды. Өлкән равваның баш түбәсендә ак төстәге чәпләшкә, өстендә юка җилән, аягында болгари итек, кулында сырлап ясалган чукмарбашлы таяк. Кабак битле, кирәкмәгән зур бөкре борынлы өлкән равваны беренче күргәндә үк ят иткән иде Айбиби, хәзер исә эндәшми генә узып китмәкче иткән иде, рухани аның юлына таягын куйды.

— Биби хатын, сезне аш кырында кахан көтә.

— Минем исемем Айбиби, өлкән равва.

— Әйе, Айбиби хатын, сезне кахан көтә,— дип кабатлады өлкән равва һәм, юл өстеннән таягын алып, аңа юл бирде, ә үзе Айбиби белән янәшә атлап китте.

Өлкән равва сөйләде дә сөйләде, Айбиби аны тыңлаган саен хәйран кала барды. Бу ни хәл инде, яңа сарай йортына аяк баскан хатынга өлкән равва дәүләт серләрен дә сөйли. Айбиби, әлбәттә, күп нәрсәне аңламады, әмма аңлагандай, ияк каккалап барды. Бит ул каханның баш хатыны!

— Айбиби хатын, миңа кахан җиткерде, синең ике якын кешең Ханбалыкта калганнар икән.

Дөньяви сәясәттән кинәт кенә табигый тормыш хәлләренә күчкән өлкән равваны Айбиби янә аңламады. Әмма бу хәл аның үзенә кагылганга, колаклары торды, хәтта өлкән равваның каршына чыкты.

— Кахан миңа, алар бер айдан соң гына сарайга үтә алалар, дигән иде, миңа алар бүген кирәк, бүген, өлкән равва.

— Кахан әйткән икән, бер айдан ул кешеләрең сарайда булырлар, Айбиби хатын, бер дә борчылмагыз. Кахан әйткән сүзендә тора торган кеше. Менә без килеп тә җиттек,— диде өлкән равва һәм, Айбибинең терсәгеннән алып, ишектә торган сакчыларга ым какты.

— Мин бу киемнән кахан янына үтә алмамдыр, өлкән равва.

— Кахан сезне көтә, әйдәгез, алдан узыгыз...

* * *

Йосыф кахан Айбибине ишеккә каршы килеп алды һәм очрашуда утырган кечкенә өстәл янына утыртты, көмеш кыңгыравын зеңләтте. Бавырчысы керде.

— Аш-суны минем ятагыма хәстәрлә,— диде аңа кахан. Бавырчы баш иеп чыгып киткәч, Йосыф кахан ике терсәген өстәлгә терәде дә ияген учларына салып, Айбибигә: — Баш хатын буларак, мин сине, Айбиби каханбикә, туп-туры ятагыма алып керермен. Гаҗәпләнмә, күрәм ич, күзләрең зурайттың. Берсекөннән дә калмый мин Киялигә таба яу ук булмаса да, шул максат белән әлеге тарафларга кузгалам. Ләкин каханбәгем миңа, башта Византия җирләренә таба кузгалыйк, дигән киңәш бирде. Мин килештем. Византия императоры Сарманай кенәзне Дунай кардәшләребез өстенә яу кузгаткан. Әүвәл без

шул якка кузгалырга булдык. Тик син, Айбиби җан, үпкәләмәсәң иде, каханбәк Сабир әүвәл Византиянең үзенә яу йөрик, ди. Мин килештем. Шул ук вакытта мин хәл итәргә тиешмен — син минем белән юлга чыгасыңмы, биредә каласыңмы?

— Биредә калам, каханым.

— Мин аны шулай дип уйлаган идем дә, Айбиби җан,— диде Йосыф кахан, торып, Айбибинең кулыннан алды да ятак ягына таба алып китте.

**VII**

Айбиби үз дигәненә иреште — Рәшидә абыстай белән табибә йөзендә Исламны сарайга уздырды. Хак, ул табиб Исламга хатын-кызлар киемендә узарсың дигән шарт куйды. Моны ничек аңлагандыр Ислам, әмма аңа ирештерделәр, иртәгәдән дә калмый абыстай белән табибә сарайда булачаклар. Бу хакта өлкән равва хәбәрдар идеме, юкмы, Айбиби белмәде, иң мөһиме, үзе теләгән ике кешесе иртәгәдән дә калмый аның кырында булачаклар иде.

Төшке ашны ашап, бүлмәләренә таралгач, Айбиби кырына Хәдичә хатын килеп керде. Рөхсәт сорады, бүлмәгә уздыргач, Айбиби аңа түрдән узып, утырырга урын күрсәтте.

— Нә йомыш-йөк китерде инде Хәдичә хатынны? — диде Айбиби көлемсери төшә.

— Мин, баш хатын Айбиби, сарайдан качарга булдым. Һәм син, баш хатын Айбиби, мөслимә буларак миңа бу гамәлемдә ярдәм итәрсең.

Айбиби моны һич тә көтмәгән иде, торып, йөреп килде, Хәдичә хатынга якынрак урындыкка утырды.

— Ни өчен мин сиңа ярдәм итәргә тиеш, Хәдичә хатын? Ни өчен, чөнки үзең дә беләсең, кахан белән өлкән равва моның өчен минем башымнан сыйпамаячаклар...

— Син мөслимә, мин дә мөслимә, Аллаһы да әйткән мөслимәләр бер-берсенә ярдәм итәргә тиешләр.

Айбиби һични аңламый, бертын тәрәзәгә карап торды. Тәрәзәдән зәңгәр күк йөзе күренә, ә анда ялгыз болыт кисәге йөзә. Ул аңлый иде, мөслимә Хәдичә каханның хатыны булудан баш тарткан, әле булса кыз булып йөри, ә Айбиби алай итә алмады, ул кахан алдында ихтыяр көчен югалтып, анықы булды. Гөнаһ кылды. Ләкин бу гөнаһмы? Бит ул каханны яратты, аның куенында үзен оҗмах кошы итеп хис итте. Ә монда ком сахрасыннан китерелгән мөслимә кыз каханның кочагыннан баш тартып кына калмый, җитмәсә, Аккаладан качарга җыена, һәм аңа мөслимә буларак Айбиби ярдәм итәргә тиеш. Тик ничек. Әйе, теләге булганда да ничек качыра ала ул аны?..

— Аккаладан качу мөмкин хәлме, Хәдичә хатын?

— Бик теләсәң мөмкин хәл, мөслимә Айбиби.

— Хәдичә хатын, иртәгә минем кырыма минем табибым керәчәк...

Шулай диде дә Айбиби соңгы сүзеннән курка калды. Шуннан ни, Ислам ничек качарга ярдәм итә алыр Хәдичә хатынга сарайдан...

Бит алардан хәрам аталар күз дә алмыйлар.

— Мин ары таба биредә кала алмыйм, баш хатын Айбиби. Минем дә сарайда кешеләрем бар барын. Миңа ул кеше ирештерде, тиздән Хазарстанга угызлар ябырылачак, алар болай да инде каханның җәйләүләрен минлекләделәр. Ә кахан чарасыз, һични кыла алмый. Өлкән равва аңа Харәзем әмиренә мөрәҗәгать итәргә кушкан. Кахан икеләнә икән. Менә шунда син ярдәмгә килергә тиешсең, Айбиби хатын. Харәзем әмире Йосыф каханга шарт куйган — ислам динен кабул ит. Ә кахан икеләнә. Чөнки кахан ислам динен кабул иткән хәлдә, Харәзем әмире шундук Аккалага имамнарын җибәрәчәк, диде миңа ул кеше.

— Хәдичә хатын, мин сиңа бүген һични әйтә алмыйм. Син мине тәмам чарасыз иттең. Ул табибә минем туган илемдә чакта ук яраткан егетем иде. Ләкин мин аны каханны яраткан кебек ярата алмадым, ул минем яшьлектәге җиһаннан төшеп сүнгән йолдызым гына булып калды. Аның егет икәнен белсәләр, кахан мине дә, аны да кичермәс. Икебезне бер көймәгә бәйләп, Идел буенча агызып җибәрер. Болай да инде мин аны алдадым, табибәгә күренәсем бар, дип, сарайга керергә рөхсәт алдым. Ахыры ни белән бетәр, бер Ходай үзе белә. Мин язмышым белән уйныйм ич, Хәдичә хатын, язмышым белән. Мин кичәле-бүгенле генә белдем, каханнан балага уздым. Инде шул халәтемдә шушындый ялганга барыйммы, Хәдичә хатын?!

Айбиби ике кулы белән йөзен каплады, бертын дәшми торды, Хәдичә хатын да баш хатыннан моны көтмәгән иде бугай, ни әйтергә белми, каушый калды, Айбибинең алдына тезләнде, башын аның тезләренә салды һәм шыңшып елап җибәрде.

— Мин сабыр итәрмен, Айбиби, сабыр итәрмен. Мин качмам, ишетәсеңме, качмам. Мин беләм, Аллаһы адәм баласы өчен иң олуг һәм иң ихлас мәхәббәт. Кичер мине, Айбиби, кичер, мин сине каханга шул чиккә җитеп гашыйк булырсың дип уйламаган идем, кичер... Мин сабыр итәрмен, сабыр итәрмен...

* * *

Илчеләре угыз ханнары белән сөйләшүләр алып барсалар да, ел коры килү сәбәпле, угызлар көтүләре белән генә түгел, үзләре дә Хазарстан җирләренә үтеп керделәр, хәтта кайбер калаларны туздырдылар. Чарасыз калган Йосыф кахан Харәземгә илче йөзендә өлкән равваның үзен җибәрде. Китәр алдыннан ул аңа кырт кисеп әйтте:

— Бу сәяси чара, иң әүвәл син әмир имамнары алдында ук ислам динен кабул ит. Һәм катгый рәвештә әйт: кахан да имамнарың сарайга килү белән ислам динен кабул итәчәк.

Ни гаҗәп, күпне күргән өлкән равва каханның бу сүзләренә бер дә гаҗәпләнмәде, башын иеп тыңлап торды, ахыр: «Дин кабул итү — әҗәл алу түгел, кабул итәрмен,— диде. Һәм өстәде: — Вакытлыча булса да, чөнки минем күңелемдә бабаларыбызның тәүге Яхвасы калыр...»

Йосыф кахан өлкән раввасын хуплагандай үз итеп елмайды, әмма өлкән раввасы йөзендә елмаю галәмәте күрмәде.

Өлкән равва чыгып киткәч, Йосыф кахан һични күрмәс күзләре белән бер ноктага карап утырды. Хата кылмадымы ул, ялгышмадымы? Бит ул өлкән равва кадәр өлкән раввасын күптән инде ислам динен кабул иткән Харәзем әмиренә җибәрде. Шул ук вакытта ышана иде, илчелектә азау теше чыккан өлкән раввасы аның теләген җиренә җиткереп үтәп кайтыр. Шуның өчен аңа тынычланып яуга чыгып китәргә дә була. Ул тарихны яхшы белә иде, яһүдләр беркайчан да үзләренең диннәрен теге йә бу халыкка көчләп такмаганнар. Моңа беренче тапкыр христиан динен байрак итеп алган Сирия греклары һәм Рим куштаннары керешәләр. Хак, аларны империянең императорлары кабул итмиләр, башта, гаҗәп, христиан динен империя тарафыннан гасырлар буена рәнҗетелгән, җәберләнгән гади халык кабул итә. Ә гарәпләр исә, үз диннәрен башка халыкларга тарату өчен, соңрак кылычка ябышалар. Бит тарихта билгеле — гарәпләрнең сәргаскәрләре Мәрван белән Маслама Хазарстан төбәкләрендә көн күргән халыкларны канга батыралар, каханнарны бу дингә табынырга мәҗбүр итәләр һәм янә кылыч белән. Хазарстан гарәпләр тарафыннан яулана. Биләмҗир халкы тәмам кырыла — кылычтан уздырыла. Киң болыннары, тугайлары Сулак елгасына гарәп сәргаскәре тарафыннан меңнәрчә бер гаепсез кешеләр батырылып үтерелә. Мәетләрдән елга буыла, ярларыннан чыга. Моны хәтта күз алдына китерүе дә кыен. Ә бит сәргаскәр изге диннәрнең берсенә табынган кеше була — мөселман. Мөгаен, Коръәнне дә укыган булгандыр ул сәргаскәр. Ә бит Коръәндә: «...адәми зат ярамаган гамәл кылса, гөнаһның иң яман җәзасына тартылыр»,— диелгән. Нинди йөз белән, ничекләр мөселман кешесе бер гаепсез бала-чагаларны, карт-корыларны вә хатын-кызларны елгага һәм типсә тимер өзәрдәй егетләрне батырып үтерергә боерды икән? Гарәп сәргаскәре тарафыннан кылынган үтә яман гамәл ич бу. Шушы яудан соң Биләмҗир төбәкләре, Кавказ тирәләре тәмам бушап кала. Моның белән генә тынычланмыйлар: гарәп сәргаскәрләре бушап калган төбәкләргә Сирия тарафларыннан 24000 гаиләне күчереп утырталар. Төрле телдә сөйләшкән кавемнәрне. Бабалары төрки булган шушы яман хәлләрне Йосыф кахан беркайчан да онытмады. Инде шул чорларда кылыч аша ислам динен кабул иткән харәземлеләр — безнең кан кардәшләребез, без хазарлыларны ислам диненә күчәргә мәҗбүр итәләр. Нинди бәһа бирергә тиеш бу хәлгә Хазарстан илбашы. Кая безнең бабаларыбыз көн күргән Ярыксу, Акташ кебек калалар. Кем аларны җир белән тигезләп китә?.. Шул ук гарәп сәргаскәрләре түгелме?!

Йосыф кахан тәхет ягыннан тәмам кәефе кырылып чыкты. Һәм кырына Айбиби хатынны китерергә кушты. Баш хатын атын йөрткән Айбиби килеп кергәч, ул аны ишек каршында ук каршы алды. Хатын килеп елышуга, тәхет ягына үтеп, өстәл янына утыртты.

— Утыр әле яннарыма, Айбиби җан. Минем синең белән киңәшәсем килә. Син — мөслимә. Миңа да шул динне кабул итәргә туры килер сыман.

— Мин синең кырыңа сине ислам диненә өндәргә дип тартылмаганмындыр, шәт, Йосыфҗан?..

— Юк, юк, Айбиби җан. Минем каламда мәчетләр дә, чиркәүләр дә, синагогалар да бар.

— Мин сиңа бу хакта киңәш бирә алмыйм, Йосыфҗан.

— Миңа синең киңәшең кирәкми, Айбиби җан, миңа синең җаның-тәнең, моңсу күзләрең кирәк.Синең кочагыңда мин юаныч табам, дөньямны онытып торам. Бу да ир-ат өчен зур бәхет.

— Нигә соң сиңа, бәгырь, кырык хатын?..

— Бу гадәт яһүдләрдән килә, Сөләйман пәйгамбәр заманнарыннан ук, Айбиби җан.

— Син, Йосыфҗан, үз кырыңда ятагыңа бер тапкыр да тарттырмаган хатыннарны да тотасың ич?

— Кемне?

— Әйтик, Хәдичәне. Ә аның илендә сөйгән егете калгандыр...

— Аккошлар гына аерылышкач, моң-зарга калалар. Яраткан егетеннән аермадым мин аны, иясе биреп җибәрә, һәм яман максат белән, мине мөселман итәргә. Динне мин, Айбиби җан, үзем теләп кабул итәргә тиешмен. Мин кабул иткән дин, минем калебемә тәңгәл килергә, җан-тәнемә зыян китермәскә тиеш. Хәдичәне иленә кайтарып җибәрү минем дошманнарымны гына арттырыр иде. Дөрес, минем

аны сатып җибәрергә дә хакым бар, ләкин минем моңа барасым килми. Аккошларым сата алмаган кебек, мин хатыннарым сата алмыйм, әйе, гәрчә моңа хакым булса да. Мин бүген Харәземгә киткән өлкән раввамны көтәм. Чөнки Сарманай кенәзне акылга утырту өчен, әүвәл мин угызлар белән килешү төзергә тиеш. Ә угызлар Харәзем әмиренә бәйле халык, гәрчә тегеләре әлегә мәҗүсиләр булсалар да. Аннары угызлар бик борынгы заманнардан бирле Идел буе болгарлары белән теләктәшлектә гомер итәләр, Болгар ханнары угызларга кызларын бирәләр, үзләре төрки болгар кызларына өйләнәләр.

— Кем ул Сарманай димим, чөнки беләм, Кияли каласы түрәсе. Нигә син аның өстенә яу кузгаласың соң, Йосыфҗан?

— Яратмыйм мин ул сатлык җанны. Ул, Византия императорына ялланып, безнең кардәшләребез Дунай буе болгарларына яу йөрде, ил-халыкны талап кайтты. Хәзер янә шул тарафларга яу кузгалырга җыенып ята икән. Мин моңа чик куярга булдым. Бит ул минем ясакчым...

— Кичер мине, Йосыфҗан, зинһар, кичерә күр. Бит мин иң әүвәл синең турында кайгыртам, исән булсаң иде, ил-халкың саклап, дәүләтең камил яшәтсәң иде, дим...

— Абыстаең белән табибәңне күрдеңме соң әле? — дип сорагач, Айбиби кинәттән эсселе-суыклы булып китте. Ни әйтә ала иде ул аңа? Һични!

— Аккошлар култыгындагы агачларга һәрчак каракош төшә, Йосыфҗан. Куркам мин алардан.

Айбиби шулай диюгә, Йосыф кахан аның күзләренә карады һәм елмаеп куйды.

— Курыкма, Айбиби җан, каракошлар аккошларның түшләрен ярмаслар, аларны минем мәргәннәрем саклый. Алар махсус ясалган шалашларда каракошларны күзәтәләр, әгәр дә мәгәр каракошлар аккошларга ташланалар икән, аларны шундук уктан алачаклар.

— Ул мәргәннәр су коенган хатыннарны да күрәләрме?

— Юк, аларның хатыннарга карарга хаклары юк, рөхсәт ителми. Каракошлар түгел, безне бүген христианнар белән мөселманнар йотарга торалар, Айбиби җан. Әлегә кадәр мин ике диннең берсен кабул итмәдем. Әйе, әлегә кадәр, вәләкин миңа хәзер ислам динен кабул итми хәл калмады. Чарасыз калдым мин, Айбиби җан, чарасыз...

Айбиби дәшмәде, ул әкрен генә торды да каханны ятакка таба алып китте. Каханның кулы салкын иде. Ләкин ул белә, кахан ятакта һәрчак кайнар йөрәкле булды. Һәм ярата-назлый вә сөя белүе белән Айбибине дә үзенеке итте. Мәңгегә!.. Һәрхәлдә, каханны кулыннан тотып, ятакка таба барганда шулай дип уйлады Айбиби.

...Иртәнге якта хәрам аталар Айбибине кахан ятагыннан алырга килделәр. Өстенә киеп, көзгегә карап йөзен хушбуй белән югач, Айбиби әле булса иренеп яткан кахан янына килде һәм ир канатның кулын кысты. Ятак бусагасын атлап чыгуга, хәрам атаның берсе аңа хәбәр ирештерде.

— Сине, баш хатын, бүлмәңдә ике кеше көтә,— диде.

Айбиби чак кына: «Рәшидә абыстай белән Ислам табиб!» — дип кычкырып җибәрмәде, кычкырды да кебек, ләкин аның хатасын янәшә атлаган хәрам атакай төзәтте.

— Исламия табибә, Айбиби хатын, Исламия табибә.

Эчке авазын хәрам атакай авызыннан ишетүгә коты алынган Айбиби кисәк туктап калды, хәрам атакайларның күзләренә карады, ләкин аларның берсе: «Исламия табибә, Айбиби хатын, Исламия табибә»,— дигәч кенә тынычлана төште, һәм адымын дәвам итте.

— Әллә соң ул-бу булдымы, Айбиби хатын? — дип сорады атакайның берсе.

— Ю-юк, атакай, берни дә булмады, әллә нигә эчем...

— Була торган хәл,— диде шул ук атакай.— Була торган хәл, балакай. Йөккә уздыңмы әллә?

— Юктыр, юк бугай,— диде Айбиби, тәмам курка калып.— Ә йөккә узган булсам ни?

— Берни дә юк, берни дә юк, Айбиби хатын. Йөккә узуга, кахан сезне ятагына тарттырмый башлар, бары тик.

Ул арада аның каршында җир астыннан чыккандай, Рәшидә абыстай белән Исламия табибә пәйда булдылар. Аларны күрде дә Айбиби Рәшидә абыстайның кочагына ташланды һәм күз яше белән елап җибәрде. Рәшидә абыстай хәрам атакайларга: «Китегез!» — дип, кул ишарәсе ясады. Атакайлар киткәч һәм бераз тынычлана төшкәч кенә, Айбиби күзләрен яулык очына сөртеп, Исламия табибәгә күз ташлады, ләкин кочагына иңмәде, бары тик күрешергә кулын гына сузды.

— Исәнме, сарай табибы улы Ислам! — диде.

Тагын әллә ниләр әйтергә дип авызын ачты, әмма сүз таба алмады, теле гүя аңкавына ябышкан иде. Чөнки күңеленә үтә сәер тойгы тулды: Ислам мәхәббәт кахан янында тәгаен үсмер малай булып кына калган иде. Һәм шулай да түгелме соң?..

Айбиби аңа елмайды, әмма янә бер сүз дә әйтә алмады. Борылды да, Рәшидә абыстайның кулыннан алып, бүлмәсенә таба алып китте һәм барыр җайда ук: «Абыстаем-анакаем, мин аны яраттым, яраттым»,— диде.

— Кемне? — дип сорады гаҗәпләнә төшеп Рәшидә абыстай.

Айбиби җавап бирмәде, бүлмәсенең ишеген ачты һәм аларны бүлмәсенә алып керде. Утырыштылар. Дога кылдылар, шуннан соң янә күзгә-күз карашып алдылар да елмаешып куйдылар.

— Сине күрер көн дә булыр икән, балакай,— диде Рәшидә абыстай.
— Кем уздырды сезне, танымадылармы? — диде Айбиби һәм кызарынып утырган Исламга күз төшереп алды.
Моны күреп, Рәшидә абыстай:
— Оялды инде, оялды, ләкин нишләсен, башка чара калмагач, килеште инде,— диде.
— Кахан белсә?! Кахан белсә, абыстаем?! — диде курка калып Айбиби. Хәер, ул бу хәлгә күптән курка башлаган иде инде. Хәзер исә тәмам аркалары өшеп киткәндәй булды.
— Исламия,— диде, Айбибинең каушый калуын күреп, Рәшидә абыстай.— Исламия, дим, син чыгып тор әле, булмаса. Минем Айбибигә әйтәсе сүзләрем бар.
— Ярый соң,— диде Ислам һәм килешсез генә, бер дә хатын-кызларга хас булмаган адымнар белән ишеккә юнәлде. Бүлмәдә калган хатын-кызлар, ишек ябылуга, елмаешып алдылар һәм хәтта прых-прых көлешә башладылар.
— Йә-йә, балакай, ничекләр булды соң? Кахан белән, дим? Әллә соң чынлап та яраттыңмы үзен?..
— Яраттым, абыстаем-анакаем, яраттым. Миңа хәзер беркем дә кирәкми.
— Һәй, балакай, бит каханның кырык хатыны, кырык, синнән башка кырык хатыны!
— Кырык түгел, утыз тугыз гына.
— Нигә алай дисең?
— Хәдичә атлы хатын бер тапкыр да кахан ятагында булмаган, кыз көйгә йөри.
— Ни өчен?
— Кахан Хәдичә кызның шарты белән килешмәгән.
— Нинди шарты белән?
— Ислам динен кабул итмәгән.
— Игелекле бала, димәк.
— Мин игелексезме, абыстаем?
— Син дә игелекле. Чөнки син ихлас күңелдән яратып яткансың кахан кырына, ә ул каханны яратмаган.
— Ә мин аны нигәдер яраттым, абыстаем, яраттым. Елга култыгындагы аккош та мине яратты. Аның аккошы ул. Ялгыз калган, ишен үтергәннәр, каракош алган, диме...
— Бу ни инде тагын, балакай, нинди аккош та, нинди каракош тагын?..
— Кахан аккошлар ярата, аларны күз карасыдай саклый, хатыннарыннан җим салдыра. Аккошлар арасында парлылары бар, ялгызларын да очратырга була. Бер ялгыз аккош миңа гашыйк булды, анакаем.
— Мин синең анакаең түгел, балам.
— Син мине тәрбияләп үстердең, син мине кеше иттең, миңа белем бирдең, миңа телләр өйрәттең. Аккошларның берсе — ялгызагы — мине кочаклады хәтта, анакай, кочаклады.
— Сине аккош кочаклады?! — дип гаҗәпләнде Рәшидә абыстай, һәм, ни әйтергә белми, чынмы, юриме сөйли, дип булса кирәк, күзләренә карады.
— Балакай, чын булса да, моны кешегә сөйләмә, яме! Сөйләмәссеңме?! Кырык хатын арасында яман ниятлеләре дә бардыр, тилемсерәде баш хатын, дип сөйләп йөрүчеләре дә табылыр. Аккошларыңны ашат, кинәндер үзләрен, вәләкин, балакай, кешегә сөйли күрмә. Ишек артындагы Исламны онытмыйсыңдамыни соң?! Ул синең өчен көннәр буена ут йота, теленнән синең исемең төшми.
— Мин инде бөтенләй башка кеше, абыстаем, бөтенләй башка кеше. Ислам минем хәтер йомгагыма уралып калган яшьлегемдәге якты бер матур хатирә генә булып калыр. Хәзер мин бөтен отырым белән Йосыф каханга гашыйк. Беләсеңме, анакаем, мин аны Хәдичә хатын белән таныштырам. Бүген үк. Чибәр хатын, мөслимә, саф җанлы. Мин аны Хәдичә хатын бүлмәсенә илтеп калдырырмын да табиб дип таныштырырмын.
— Һай Аллам, балакай, мөмкин хәлме бу? Ул, бичара егет, сине күрер өчен, хатын-кыз киемендә сарайга үтте. Бит белсәләр, аның башын кисәчәкләр, шул ук хәрам атакайларың. Кахан бу эштә синең дә катнашуыңны белсә, нә кылыр?..
— Мине ул гаять зур бәһагә сатып җибәрер, анакаем.
— Ай-һай, балакай, сатып торырмы икән ул сине, җаныңны шундук җәһәннәмгә олактырмасмы?!
— Ахыр чиктә ул мине зинданга ташлатыр, анакай.
Айбиби шулай диюгә, ни сәбәпледер икесе дә тынып калдылар, әйтерсең лә кахан аларның мәкерләрен белеп алган иде инде. Рәшидә абыстай бүлмәгә күз йөртеп чыкты. Бүлмәне ялгыз хатынга исәпләп, барысын да искә алып җиһазлаганнар иде. Бүлмә зур түгел, түр якта киң генә тахта, тәрәзә каршында тез биеклек кенә өстәл, аның янында ике кечкенә урындык. Урындыклар зәңгәр бәрхет белән тышланган, читләре җофар тиресе белән каелган. Ятакта да җофар юрган, мендәр византиялеләр чүпрәгенә аккош сурәте төшерелгән тукымадан, ишекъяры җиз таз һәм кечкенә җиз комган, шунда ук болан мөгезенә эленгән фарсылар сөлгесе. Ишек эчке яктан шудыргыч белән бикләнә. Каханның хатыннарын хәрам атакайлар саклыйлар, сарайдагы тәртипләрне раввалар күзәтәләр. Аккошлар култыгыннан кайт-

канда, хатыннарга хәрам атакайлар гына түгел, кайбер көннәрдә раввалар да күз-колак булалар икән. Бу хакта аңа кала сакчысы Булат бәк сөйләгән иде инде. Сарайга үтәргә дә ярдәм итте. Исламның кем булуын белә торып, сарайга уздырды. Ә бит Исламның ир-егет икәне ачылганда, кахан аның да башыннан сыйпамаячак. Чөнки биредә барысы да хаким Йосыф кулында, кинәт кенә гашыйк булган Айбибинең ир затында.

Шул мәлдә Айбиби, сыдырылып, идәнгә төште дә Рәшидә абыстайның тезләреннән кочаклады.

— Анам-абыстаем, мин сине шундаен юксындым, шундаен юксындым!

Рәшидә абыстай аның башына кулын куйды, бер мәлгә моңсу бер карашы белән тәрәзәгә карап торды. Шул мәлдә тәрәзә каршыннан бер адәми зат узды, Рәшидә абыстай сискәнеп китте һәм, торып, Айбибине аягына бастырды.

— Утыр әле янәшәмә, балакаем, утыр. Син бу гамәлең белән үзеңә генә түгел, атаңа да зыян китерүең бар. Кахан, угызлардан курыкса да, аларны төп дошманнары итеп күрми. Әтрәк кавемендәге угызлар әле булса мәҗүсиләр ич. Ислам дине, нинди йөздә булса да, бире таба узса, Исламның кем икәнен раввалар белсәләр, кахан беребезне дә кичермәс. Инде табибәнең чын йөзе ачылган хәлдә... хәтта әйтергә дә куркам. Әнә тәрәзә каршында кемдер үтеп-сүтеп йөри башлады да инде. Ул Хәдичә дигән хатын сине сатмасмы соң, балакай?.. Син, балакай, очар кошлар кебек фикер йөртәсең. Кошлар һавада оча, ә без синең белән җир адәмнәре, безне бик тиз тотарлар.

— Кошлар да безнең кебек җан ияләре, анам.

Рәшидә абыстай янә бер Айбибинең күзләренә карады, шикләнеп-сагая калып, имеш, син, балакай, барысын да ихластан сөйлисеңме? Айбибинең күзләрендә чаткылар биешә иде. Һәрхәлдә, Рәшидә абыстайга шулайрак тоелды. Әнә шунда абыстайның кинәт хәтер кәтүге сүтелеп китте, һәм яшьлеге күз алдына килеп басты. Әйе, аның да дивана хәленә җитеп гашыйк чаклары булды ич, булмады түгел. Әле булса хәтерендә, Талиб ханга гашыйк булды ул. Һәй яратты да соң хан аны, хатыны итеп түгел, сөяркәсе итеп. Рәшидә дә, һич ятсынмый һәм курыкмый, аңа тартылды. Хан ич ул, кыю, тәкәббер, мәһабәт олуг хан иде. Рәшидәне кочагына иңдерер иде дә, артык хәрәкәт ясаудан куркып, тынып калыр иде, әйтерсең лә бер-бер сүз әйтсә йә булмаса хәрәкәтләнсә, нидер җимерелер, йә булмаса, елганың буасы ташыр кебек иде. Унҗиде яшенә яңа аяк баскан Рәшидә олуг ирнең тән исен хуштан язар хәлгә килеп иснәр иде дә ул да тынып калыр иде. Талиб хан һәрчак йөрәгенә зарланды, шуңамы, Рәшидә аның кочагына иңүгә, кымшанырга да куркып торыр иде. Һәм Аллаһыдан сорар иде: бир аңа куәт, бир көч, яшәсен ул, яшәсен, ил-халык хакына, ахыр килеп, минем хакка... Шуннан, Рәшидәнең ни теләгәнен, яшь кызның ни теләгәнен белгәндәй: «Синең янда, Рәшидәкәй, минем йөрәгем дә тынычланып китә»,— дияр иде. Йөрәге авыру Талиб хан, өченче хатыны итеп, аңа өйләнергә дә теләде, әмма Рәшидә моңа үзе риза булмады. Ул болай да бәхетле иде, болай да кануни хатыннардан да бәхетлерәк иде. Аны ул тәгаен яратып сөйде, назлады... Талиб хан аны вафаты көненә кадәр яшь хатыным минем, дип йөрде. Алай гынамы, табибәм дип әйтер иде. Чөнки горур хан, Рәшидә белән булганда, ичмасам, бер тапкыр да йөрәгенә зарланмады. Халык аны «гали» хан дияр иде, ә Рәшидә аны күктән төшкән фәрештә булмаса да, пәйгамбәрләргә тиңләде. Рәшидә сарайда балаларга сабак бирде, ә Айбибине исә бишектә чакта ук үз баласыдай карады. Онытa алмый ул көнне, онытырлык булдымы — Талиб хан, йөрәк өянәге тотып, вафат булды, дип килеп әйткәч, кадала-каплана сарайга йөгерде, ләкин аны сарай имамы вафат булган Талиб хан кырына уздырмады. Рәшидә ике кулы белән йөзен каплады да үксеп-үртәлеп елап җибәрде. Моңа берсенең дә исе китмәде, чөнки сарай гына түгел, ил белән халык елаган иде ул көнне.

Айбибине кочагында тотканда, Рәшидә абыстайның күз алдыннан әнә шундый хатирәләр узды, һәм ул үзалдына уфтанып куйды. Ә бит шул чакта ханның кануни хатыннары аның мәете янында иделәр. Ул, хан үтенеченә каршы килми, мулладан никах укытып кияүгә чыккан булса, имам аны мәрхүм янына уздырган да булыр иде, Рәшидә яраткан затының, һичьюгы, нурлы йөзен күреп калган булыр иде. Әйе, аның шушы ир заты белән үләргә дә риза булуы хак иде, үләргә дә, борынгы төрки хатыннары кебек... Әнә шундаен чикләргә җитеп яратты ул Талиб ханны, әле кочагында тоткан Айбиби баланың әтисен. Тик менә үз кызыдай карап үстергән баланың кырык хатыны булган ир түрәсенә гашыйк булыр һәм үзе үк: «Мин аны яраттым»,— дип әйтүен ни дип юрарга да белмәде. Ә бит син, балакай, кырык яшьлек каханның кырык хатыны арасында кырык чуерташ арасында җемелдәп яткан зөбәрҗәттәй җемелдисең — гүзәлсең, акыллысың. Тиңең, язганың, минемчә, балакай, кырык яшен тутырып яткан Йосыф кахан түгел, ә сарай табибы улы Ислам. Тик бу хакта мин сиңа әйтмәм, хакым юк, чөнки мин үзем дә синең атаңа, исәрләнер дәрәҗәгә җитеп, гашыйк булган идем. Һәм мин аңа никахсыз биреләдем, һәм бер тапкыр да, хәтта Аллаһым алдында, үземне гөнаһлы санамадым, чөнки мин аны бөтен йөрәгем-җаным белән яраткан идем. Әйе, минем бу балакайның язмышы белән уйнарга хакым юк.

Укымышлы кеше буларак, Рәшидә абыстай белә иде: кеше язмышы туа-туганнан бирле фәрештәләр кулында гына түгел, иблисләр кулында да. Моның янына Аллаһы аңа аң-белем алырга мөмкинлек биргән. Рәшидә абыстай бик яхшы белә иде: тулы канлы мәхәббәт килгәндә, акыл вә аң икенче урынга күчә, иң алга хис ташкыны чыга, ә ул моны үз башыннан кичерде, саф мәхәббәт барысыннан да куәтлерәк, көчлерәк икән.

— Узыйк булмаса, анакаем, Хәдичә кырына. Ул мине көтмидер, ләкин ул мине кабул итәр. Без ахирәтләр. Исламны да алырбыз. Таныштырыйк та без аларны, үзләрен генә калдырыйк.

— Килешерме соң бу гамәл? — диде Рәшидә абыстай.— Исламның синнән башка берәүне дә күрәсе килми кебек. Һәрхәлдә, мин аның тел төбеннән шуны аңладым.

Алар тарлавыкка чыктылар, Ислам утырган эскәмия янына уздылар. Рәшидә абыстай егет янына — хатын-кыз киемендә булган Ислам янәшәсенә утырды. Дога кылдылар. Гәрчә яһүдләр сараенда булсалар да, мөслимәләр ич. Хәдичә хатын бүлмәсенә уздылар. Янә дога кылдылар. Сөйләшә башладылар, бер-берсенә карый-карый, серләрен уртаклаштылар. Айбиби көмеш кыңгыравын зеңләтте, хәрам атакай килеп керүгә, табын хәстәрләргә, җиләк-җимеш китерергә кушты. Чәй янында Рәшидә абыстай юкюк та Хәдичә хатынга карап-карап алды. Өлгергән алмалар, хөрмәләр, күл тутырып, җәйрәп чәчәк аткан төнбоеклар була, ләкин бу хатын кебек моңсу йөзне күргәне юк кебек иде аның. Ирләр кочагын тансыклап, сөю-мәхәббәттән мәхрүм ителгән хатын кебек күренде Рәшидә абыстайга ком сахраларыннан Хазар-станга китерелгән кыз бала. Ул дине вә иманы аркасында барысыннан да ваз кичә һәм хәтта кахан кочагыннан да. Бу мөслимә хатында ихтыяр көче шулхәтле көчле, күрәсең, яһүд кешесе астына ятмас өчен, кахан кадәр каханнан баш тарта. Мөслимәләр хакында яман уйдагы раввалар хәлифә җибәргән кыз бала белән һични кыла алмыйлар, ахыр чиктә Хазарстанга тартылган кыздан кахан үзе үк ваз кичә һәм раввaларына кызны үз ихтыярында калдырырга куша. Әнә шулай мөслимә Хәдичә, гәрчә кахан хатыны исәбендә йөрсә дә, кырык хатын арасында берүзе кыз булып кала бирә. Шул хакта уйлап утырганда, Рәшидә абыстай яңа гына Айбиби сөйләгән хәлләрне күз алдына китереп алды. Әйе, Айбиби каханга гашыйк була һәм... Ә бу мөслимә хатын... Айбиби кебек утка очкан күбәләктәй итми...

Ниһаять, Рәшидә абыстай Хәдичә хатыннан сорап куйды:

— Атаң-анаң исәннәрме соң, балакай?

— Юк,— диде Хәдичә, гадәти бер хәл турында сүз баргандай.— Мин хәлиф сараенда үстем. Хәлиф минем атам да, анам да иде. Бире таба озатканда, хәлиф миңа әйтте: «Каханны ислам диненә инандыр». Мин хәлифнең үтенечен гамәлгә ашыра алмадым, абыстай, кахан изге динебезне кабул итмәде, баш тартты.

— Ә син туган якларыңа кайтыр идеңме, балакай?

— Хатын-кызлар очкан кошлар бит алар, абыстай. Хәлиф сараена минем кайтасым килми, ләкин туган ягымны сагынам, шул тарафларга юлдаш тапсам, ике дә уйламый китәр идем, абыстай.

— Ә Харәзем әмиренә китәр идеңме? Хак булса, Йосыф кахан Харәзем әмире ярдәмендә баскынчы урыслардан һәм угызлардан котылмакчы.

— Харәземлеләр — мөселманнар. Китәр идем, абыстай. Тик мине кем моннан коткарыр, кем булыр юлдашым?

— Сине, балакай, менә бу егет озатыр,— диде Рәшидә абыстай, Ислам ягына ымлап. Баядан бирле Исламның хатын-кыз булуына шикләнеп утырган Хәдичә, егет аңа карауга, яулыгы белән күзләрен генә калдырып, авызын каплады, сәерсенеп, хәтта гаҗәпләнеп, янә-янә Исламга карап алды. Табиб Ислам да, бит алмаларына кадәр кызарынып, ни әйтергә белми каушый калды.

— Миңа беркем дә кирәкми, абыстай, беркем дә...

— Йә-йә, балакай, бала-чага булма. Сиңа биредән котылырга башка чара юк. Йә Харәземгә китәсең, йә хәлифә тарафларына.

— Миңа ирләр кирәкми, ирләр куенында үләрмен дип куркам, абыстай.

— Ир-ат агач түгел, агач басып кына кеше үлә, балакай.

Хәдичә тәмам югалып калды. Кем бу абыстай — Айбибинең абыстае? Әллә соң шымчымы? Бик ихтимал ич, шымчылар сарай тулы.

— Кахан ислам динен кабул итсә, мин дә Айбиби кебек сарайда калыр идем, абыстай.

Абыстай белән Айбиби күзгә-күз карашып алдылар һәм ни әйтергә белми аптырап калдылар. Сүзне янә Рәшидә абыстай башлады.

— Сине, балакай, ышанычлы табиб егет озатыр. Хак, ул әле хатын-кыз киемендә. Чарасыздан шулай киенде ул, сарайга керү өчен. Без сине башта Фанәгүргә җибәрербез, Гали тархан кырына, аннан Харәземгә юл алырсыз. Айбиби, ничекләр булса да, каханны күндерер, дип уйлыйм мин.— Рәшидә абыстай Айбибигә күз ташлады һәм ризалыгың бир, дип ым какты.— Күндерерсең бит каханны, Айбиби?

— Хәдичә хакына мин утка керергә дә риза, абыстай, чөнки ул минем ахирәтем.

— Миңа табиб кирәкми, мин исән-сау,— диде Хәдичә.

— Бик яхшы,— диде бу юлы Айбиби.— Бик яхшы, Хәдичә ахирәт. Мин бүген үк кахан белән сөйләшәм, һәм без сезне Харәземгә озатабыз, Таман тарханы Гали аша.

— Нигә Таман тарханы аша? — дип сорады Хәдичә.

— Колларны Тамандарханда саталар, ә без сине кол исәбендә Харәземгә озатабыз, Хәдичә ахирәт.

Айбиби шул сүзләрне әйтүгә, Рәшидә абыстай яшел атлас күлмәген шаулатып торып басты һәм ишекле-түрле йөреп килде. Айбиби көмеш кыңгыравын челтерәтте, шундук хәрам атакай килеп җитте. Айбиби аңа савыт-сабаларны алып чыгып китәргә кушты һәм Исламга карап:

— Табибә Исламия, сиңа Хәдичә ахирәтем белән юлга чыгарга туры килер.

— Мин аны озатырмын, озатырмын,— диде моңа кадәр сүзгә катнашмый утырган Ислам.— Тик мин аны кемгә тапшырырмын?

— Әйттем ич инде, син аны Фанәгүрия аша Харәземгә алып китәрсең.

— Башкача мөмкин түгелме, Айбиби?

— Мөмкин түгел, ахирәтем. Мөмкин булса, мин сине дала аша җибәрер идем, тик дала хәзер угызлар кулында.

Айбиби, ишек бавына кулын салгач, янә бер ахирәте Хәдичәгә карап алды һәм әйтте:

— Табибә Исламия хәзергә синдә кала. Бүлмәңә хәрам атакайларны кертмә. Калганын иртәгә хәл итәрбез.

Хәдичә, нидер әйтергә дип, аңа таба ымсынгандай итте, әмма тыелып калды, бары табибәсе ягына күз төшереп кенә алды. Ислам ни әйтергә белми, Айбибинең әмерләрен үтәргә ризалыгын белдереп, башын иеп утыра бирде.

Айбиби белән Рәшидә абыстай чыгып киткәч, Ислам, торып, тәрәзә каршына барып басты. Аңа оят та иде, шул ук вакытта Айбибинең әмерен үтәргә әзер дә иде. Ул Айбибидән күзләрен дә алмый утырды, ә менә Хәдичә хатынга карарга да яхшысынмады. Ничектер ошбу киемдә дәшәргә оят иде аңа. Хатын-кыз киеменнән ич, ниндидер үзе дә аңлап бетермәгән уңайсызлану тоя. Беренче булып аңа Хәдичә хатын дәште.

— Безне, Ислам табиб, каханбәк озатачакмы?

— Әйе, каханбәк. Тик каханбәк Сабир түгел, аның ярдәмчесе.

— Мөселманмы ул?

— Мөселман, мөселман, Хәдичә,— диде Ислам, беренче тапкыр хатынның күзләренә карады. Карады да тәмам сихерләнгән берәүдәй югалып калды. Хатынның чем-кара күзләрендә ниндидер чаткылар уйный кебек тоелды аңа. Ул әсәрләнеп куйды, ни әйтергә белми ишекле-түрле йөри башлады.

— Мин кичке ашка китәм,— диде Хәдичә тора-тора.— Мин сезгә дә ашарга алып керермен йә хәрам атакаемны җибәрермен. Тик ул кергәндә, йөзегез капланган булсын.

— Яхшы, Хәдичә, мин шулай итәрмен. Тик мин сезгә уңайсызламыйммы соң?..

— Һич юк, һич юк, мин сезгә урынны идәнгә җәярмен йә үзем идәнгә ятармын,— диде Хәдичә һәм, йөзен каплаган яулыкны алып, көлемсерәп алды. Тулынкы иренле иде Хәдичә хатын, күзләре кап-кара, йөзе тутсыл, әмма мөлаем итеп тыйнак кына елмая, ул гынамы, тәҗрибәле хатыннарга хас үзенә бер үзгә булган елмаю белән елмая иде, әйтерсең лә нидер әйтәсе килә, шул ук вакытта кыймый.

— Мин сезне чарасыз итмәмме соң, Хәдичә?

— Сез мөслим бит?.. Мөслим. Мин сезгә, Ислам табиб, анама ышанган кебек ышанам.

* * *

Идел буе Болгары сараенда күп еллар хезмәт иткәнгәме, Рәшидә абыстай бар нәрсәдән дә хәбәрдар иде. Һәм ул каханның кылган гамәлләрен якларга керешкән Айбибигә — Исраил балалары кулында булган Хазарстан сараенда барган сәясәт вә гамәлләр белән каханга булган мәхәббәтеннән сукырая башлаган Мөхәммәд хан кызына аңлатырга кирәк, дигән фикергә килде. Ул белә иде: Хазарстанда борын-борын заманнардан ук, һәрхәлдә, ил башына раввалар килгәч булган хәлләрне янә бер кабатларга булды.

— Балакай, син шул чиккә җитеп Йосыф каханга ышанмасаң иде. Хазарстанга Исраил балалары килеп, ил белән идарә итүне үз кулларына төшергәч, төркиләрдән килгән каханнарны, ефәк бау белән буып, сынарга керешәләр. Бу йола-гадәтне кем уйлап тапкандыр, бер Хода үзе белә, вәләкин төрки бабаларыбызда мондый яманлыкларны кылмаганнар да кылмаганнар. Хазарстанда бу яман гадәтне Исраил балалары канунлаштыралар. Илгә теге йә бу яман афәт килсә, каханнарын гаеплиләр, имеш, аның аркасында ил өстенә афәт килде. Ефәк бау белән буыла башлаган һәм аңын җуя башлаган каханнан сорыйлар: «Тагын ничә ел ил белән идарә итәсең?» Кахан ничә ел әйтә, шул вакыт узгач, аны барыбер үтергәннәр. Тәхеткә йә аның улын, йә оныгын утырткannар.

— Мин бу хакта беләм, беләм, анакай, беләм. Йосыф кахан үз көчендә, үз куәтендә, аңа кагылырга кыймаслар.

— Раввалармы, балакай?

— Әйе, раввалар, анакай, раввалар.

— Чир китә, гадәт кала, балакай. Ничек син алай кистереп әйтәсең, бит раввалар Йосыф каханны да, синең ир-канатыңны да шулай сынаулары бар. Ни өчен, дип сорама. Әйтәм: угызлар җәйләүләрне туздырып йөриләр, канунг Сарманай төнлә белән Сарыкалага ябырылган. Башбаштакланып, кала хал-

кына: «Сез бүгеннән миңа ясак сала башларсыз»,— дип шапырынып йөргән. Кахан бу яман яуга аны Византия императоры котырткан, дип бара. Ә үзе шул тарафларга яу кузгалырга ашыкмый. Тиз арада каханга Византия императорын акылга утыртасы иде, ахыр Кияли Сарманайны. Сарманай безнең кардәшләребез Дунай буе болгарларына яу өстенә яу йөри икән, кардәшләребез далага качып китә башлаганнар.

— Каханның гаскәре куәтле, ул аңа бик тиз чара күрер, абыстай.

— Тимерне кызуында сугалар, балакай.

— Мин аны ашыктырырмын, анакай, ашыктырырмын. Ул мине тыңлар.

— Хельг дип аталган Киялине кулына төшергәч, шаман атын да, король атын да йөрткән, безнекеләр Үләт дип атаган башлыкны Вениямин кахан иленнән куа, балакай. Үткән гасырда була бу хәл. Хәзер әнә Кияли түрәсе янә баш калкыта башлады. Кем чик куяр аңа, кем?.. Атаң Мөхәммәд ханмы, Йосыф каханмы?..

— Минем каханымны бер дә сугышка җибәрәсем килми, анакай.

— Илбашы булгач, яу йөрми тормас. Бит ул кахан! Гәрчә ил гаскәриләре белән каханбәк Сабир идарә итсә дә, балакай. Кардәшләребез үз кулына төшерсә, Сарманай кахан Хазарстанга ясак салудан да баш тартуы бар, балакай. Кахан иң әүвәл шул хакта уйларга тиеш. Кара Болгар тәхетендә утырган Сарманай кахан бүген чик куймаса, кахан үзенә генә түгел, ил халкына да баз казыр, балакай. Каханыңа, сине тыңлар итсә, шул хакта да җиткерсәң иде.

— Шуларның барысын да исәпкә алып, Йосыф кахан өлкән равваны Харәзем әмиренә җибәрде, анакай.

— Бик хуш, бик хуш. Мин ышанам, өлкән раввага ияреп, имамнар да Хазарстанга килеп төшәрләр. Менә шунда мөселманнар Аккалага үтеп керерләр, менә шунда, балакай...

— Нәрсә менә шунда, анакай?

— Менә шунда илдә тәртип урнашыр. Талиб мәрхүм әйтер иде, сәясәт хатын-кызның тел-фикер сөрешен генә түгел, калебен дә боза, дип. Әллә мин сиңа артыгын да сөйләп ташладым инде, балакай...

Алар ишек янына килеп җиткәннәр иде инде, Рәшидә абыстай туктап калды, һәм Айбиби, үзен генә калдырып, кире борылды.

— Чәй эчеп китәр идең, анакай,— диде аңа Айбиби.

— Минем күрәсе кешем бар, балакай. Ә сине тиздән кахан кырына алырга килерләр. Ир — баш, хатын — муен, дигәннәр бабаларыбыз, калганын үзең кара. Ак теләкләр сиңа, балакай...

## VIII

Өлкән равва, Харәзем әмире тарафыннан Ибраһим исемен алып, кайтып төште һәм, Аккала күперен узуга, үзен каршы алучы раввадан:

— Кахан кая? — дип сорады.

Равва аның белән исәнләште дә тәхет ягына таба күрсәтте. Өлкән равва Ибраһим зур-зур адымнар белән (аңа өч-дүрт имам ияргән иде, аларны башларындагы чалмаларыннан ук аерды каршы алучы равва, шуңа өнсез калды бугай, чөнки өлкән раввага авыз ачып сүз дә әйтмәде) сарайга таба юнәлде һәм үзенә ияргән имамнар белән тәхет ягына ук узды. Йосыф кахан каханбәге Сабир белән нидер сөйләшеп утыра иде, өлкән равваны һәм аңа ияргән чалмалы имамнарны күрде дә аягүрә басты. Каханга өлкән равва һәм имамнар баш иделәр, сәлам юлладылар. Йосыф кахан өлкән раввага, уң як урындыкларда утырган имамнарга сул як урындыкларга күчеп утырырга кулы белән ишарә ясады.

Имамнар, шул исәптән өлкән равва да, дөя йоны тутырган артсыз урындыкларга утыруга, кулларын күтәреп дога кылдылар, авыз эчләреннән дога укып, Аллаһы әкбәр! дип битләрен сыпырдылар, шуннан соң гына каханга һәм каханбәккә сәлам юлладылар.

Дога кылу галәмәте үткәч, Йосыф кахан өлкән раввага карады. Бу инде: «Йә, ни йөк белән кайттың?» — дигәнне аңлата иде.

— Харәзем әмире тарафыннан угыз ханы кисәтелде, алар иртәгә үк илдән чыгып китәчәкләр, бүген исә өч имам безнең йөзбашларыбыз озатуында яу килгән түмәнбашларга юнәләчәкләр. Моның өчен сездән фатиха кирәк, галиҗәнаплары Йосыф кахан.

Имамнар дога кылгач, ни кылырга белми тәхетенә утырган Йосыф кахан янә барысын да күздән кичерде һәм өлкән раввага да, имамнарга да түгел, гаскәрбашы Сабирга карап:

— Өч имамга да йөзбашлар бир, имамнарны далада ыстан туктап йөргән угызларга озата барсыннар. Бу минем әмерем генә түгел, Харәзем әмиренеке дә, каханбәк Сабир.

— Баш өсте, галиҗәнаплары! — дип сикереп торды каханбәк Сабир һәм ишеккә таба китте... Имамнар дәррәү күтәрелеп, аңа иярделәр.

Тәхет ягында өлкән равва белән Йосыф кахан гына калдылар.

— Мин моның ахырын ни белән бетәсен белмим, Йосыф углан, әмма мин син кушкан йөк-йомышны җиренә җиткереп үтәдем. Үзем әмир каршында ук ислам динен кабул иттем, әмма күңелем түрендә Яхвам калды. Аны минем күңелемнән беркем дә җуеп ала алмас.

— Минем дә,— диде Йосыф кахан һәм, килеп, өлкән равваны кочты.

— Мин Хазарстаным саклап калырга телим, нинди юллар белән булса да. Тиздән без дәшкән викинглар килеп төшәрләр, һәм без аларны мөселманнар өстенә җибәрербез, алар Харәземне дә читләтеп үтмәсләр, һәм без тәүгечә барчасы белән идарә итәрбез, атакай.

Шушы хәлләрдән соң бер ай да үтмәде, Йосыф кахан табын җыйды. Табынга җыелган каханбәк, бәкләр, угыз төмәннәрен ил-далаларына борып җибәргән имамнар да, тарханнар да бар иде. Йосыф кахан аларга барысын да ирештерде. Кара Болгар каханы Сарманайның узынуын, Дунай буе кан кардәшләребезгә кат-кат яу йөрүе турында да, үзенең тиздән шул тарафларга яу чыгарга җыенуы хакында да әйтте. Табындагы барчасы да кахан белән килештеләр. Йосыф кахан угызларны Хазарстан җирләреннән вә үләнле болыннарыннан китәргә мәҗбүр иткән имамнарга үзенең рәхмәтен җиткерде һәм аларны сараенда калдырасы, киңәшчеләре итәсе хакында әйтте. Имамнар каханның бу сүзләрен, «амин!» дип куәтләп, кабул иттеләр.

Табыннан соң Йосыф кахан менә ничәнче көн инде, сарайдагы гадәти тәртипләрне бозып, Айбибине үз кырына дәштерә. Айбиби Йосыф кахан кырына кинәнә-кинәнә килде. Һәм алар һәр килгән төндә бер-берсен сөешеп туймадылар. Каханның бу хәленә раввалар гына түгел, сарайдагы бернигә дә исләре китмәгән хәрам атакайлар да игътибар иттеләр, сарай куштаннары турында әйтеп тә торасы юк.

Әнә шундаен төннәрнең берсендә Айбиби Йосыф каханның кочагына иңде дә әкрен генә: «Мин чынлап та балага уздым, каханым»,— диде. Кахан бер мәлгә дәшми ятты. Ахыр, ниһаять, аңына барып җитте, — Айбибинең башын артка каерып, күзләренә карады.

— Димәк, син теге вакытта шаярып әйтмәдең?

— Чынлап, чынлап, Йосыфҗан, чынлап.

— Минем Мөхәммәд хан кызларының берсеннән бер угылым үсә инде, Айбиби, син дә миңа угыл бала тапсаң... Мин синеме!..

— Нишләтерсең мине, каханым, ниләр кылыр идең минем белән?

— Гадәттә мин йөкле хатыннарымны илләренә кайтарып җибәрә идем. Ә менә син миңа угыл бала тапсаң... Мин хатыннарымның барчасын да куып таратачакмын, Айбиби җан, барысын да.

Айбиби бер сүз дә әйтмәде, чөнки каханның сүзләренә ышанмады. Кем моны аңа рөхсәт итәр? Раввалар килешерме, бит кахан бу гамәле белән аларның кануннарын бозачак, кануннарын!

Ләкин Йосыф кахан һәр адымын, табын җыеп, киңәшчеләре белән килешеп, уртак тел тапкач кына ясады. Хатыннарын тарату турында ул башта табын җыеп сөйләшергә, аксакаллары белән киңәшергә булды. Иң әүвәл аның бу адымын имамнар яклап чыктылар, өлкән равва да каханның бу адымын хуплады, раввалар да кахан белән килештеләр. Хәер, равваларны өлкән равва кисәткән булгандыр, чөнки һәр табынга алар, башта үзләре табын җыеп, киңәшеп, уртак бер фикергә килеп керерләр иде. Менә шул табында Йосыф кахан Византиягә яу кузгалырга нияте булуы хакында да әйтте. Император Никифор Фокеның яшь полководец Иоанн Цимисхий тарафыннан үтерелеп, империя тәхетенә утыруы хакында да җиткерде. Тәхеттә утырганда, император Никифор яу йөрүдән башы чыкмаган Сарманай кахан Кырым тарханы улы Калакир аша 15 кадак алтын җибәргән икән. Әмма бер шарт белән — шул алтынны аклау өчен Сарманай кахан Дунай буе болгарларына яу йөрергә тиеш булачак. Сарманай кахан, күп тә үтми, дружинасы белән Дунай буйларына яу кузгалачак, дигән хәбәр ирешә, диде Йосыф кахан табын аксакалларына. Шунда өлкән равва:

— Безгә дә Византия тарафларына яу кузгалып, бер җайдан Сарманай каханны да акылга утыртып кайту мәслихәт булыр иде,— диде.

Табындагылар һәммәсе дә өлкән равва белән килештеләр. Бары тик имам хәзрәтләренең берсе генә:

— Кахан галиҗәнаплары, Византия императорында яман утчагыр бар. Ахыр килеп, үч-үчкә илтмәсме? — дигән булды. Ләкин аңа бөтенләй игътибар итмәделәр, табын шаулаша башлады, кахан белән дә барысы да килештеләр.

Табын таралгач, Йосыф кахан каханбәк Сабирга тәхет ягында калырга кушты. Барысы да таралып, тәхет ягыннан чыгып беткәч, кахан аңа кечкенә өстәл янына утырырга ымлады.

— Каханбәгем, бүген үк Мөхәммәд ханга чапкының җибәр. Византиягә таба яу кузгалсын. Әйттер, кахан белән далада очрашырсыз, дип.

— Галиҗәнаплары, Мөхәммәд ханның Дунай буе Пәһлеван ханга ярдәмгә кузгалуы хәерлерәк булыр иде шикелле миңа.

Йосыф кахан сул кулын уң кулы белән каплады.

— Каханбәк Сабир, Болгарстан да, Хазарстан да, Дунай буенда көн күргән Бәгырь вә Пәһлеван ханнар да, хәтта анда көн күргән антлар да безнең Аттила бабаларыбыздан килгән кан кардәшләребез. Мин бабам Мөхәммәд ханның кан кардәше Пәһлеван ханны юлбасар нәселдән килгән Сарманайга каршы яу чыгуына каршы түгел. Ләкин бабам онытмасын иде...— Йосыф кахан, бер ноктага текәлеп, ни-

дер уйлап утырды, шуннан соң гына: — Бабамның гына куәте җитәр микән ул юлбасар каханга? Бит аның кулында яман варяглар, дөнья халкына баскынчылар яманаты чыккан варяглар, ягъни пиратлар,— диде.

— Сез хаклы, без бергә булырга тиешбез, галиҗәнаплары,— диде каханбәк Сабир, гәрчә каханның тел төбен аңлап җиткермәсә дә.— Мин бу хакта, Мөхәммәд ханга хәбәр ирештергән идем инде, галиҗәнаплары.

— Өлгерсең, каханбәгем, өлгерсең, мактыйм. Алай да, каханбәгем, сиңа киңәшем бар, ягъни синең белән киңәшәсе бер үтә четерекле кыласы гамәлем бар. Мин, каханбәк Сабир, хатыннарымны илләренә кайтарып җибәрергә булдым.

— Һәммәсен дәме?

— Әйе, каханбәгем, әйе, һәммәсен дә. Янымда бары тик бер хатыным — Айбиби калыр.

Каханбәк Сабир шикләнебрәк каханның күзләренә карады. Ул каханның сүзенә ышанып җитмәде бугай, чөнки яхшы белә иде: өлкән равва һәм аның раввалары бар бит әле. Алар ни әйтә, бигрәк тә өлкән равва. Ләкин бу хакта теге якка да, бу якка да Йосыф каханга сүз әйтергә яисә киңәш бирергә кыймады. Инде хатыннарын куарга тели икән, аларны югары бәһагә Фанәгүр базарына илтеп саттырсын. Азмы-күпме казнага акча керер. Яуга хәзерләнгәндә, ул акча сөннәтле казакларга түләргә ярап куяр. Бу — бер. Икенчедән, хатыннарны саткан акча турыдан-туры өлкән равва кулына керәчәк. Ә гаскәриләр җыярга, нигездә, раввалар катнаша. Баҗайларны да алар ялладылар, угызларның беришен дә, сөннәтле казакларны да, поскан казакларны да, гаярьләрне дә. Яу уңышлы үткән хәлдә, моңа каханбәк Сабирның иманы камил иде, Йосыф кахан, яңа туган айдай җиңүче йөзендә Хазарстанга кайтып төшәчәк. Шулай иткәндә, раввалар да, өлкән равва да борынгы бабалары кебек каханның муенына ефәк бау сала алмаслар. Ләкин моның өчен Йосыф каханның яубаш булуы зарур. Каханбәк сукыр түгел, күрә: яубаш булырга кахан үзе дә әзер.

— Димәк, сезнең әмер белән мин кичекмәстән төмәннәрем барлый башлыйм, галиҗәнаплары? — диде, ниһаять, каханбәк Сабир.

— Башла! — диде катгый рәвештә Йосыф кахан һәм, сүзе бетүен аңлатып, торып басты.

## IX

Йосыф кахан яу кузгалуны һәр көн күз угында тотты, акча табучы өлкән равваны да, төмәннәр өчен җавап бирүче каханбәк Сабирны да, олаучылар башы әрмәнле Вартанны да ашыктырды. Барысы да әзер булгач, ул янә табын җыйды һәм раввларына яу кузгалуының төп максатын аңлатты. Ә яу чыгуының төп максаты моннан гыйбарәт иде: Сарманай кенәзне һәм Византия императоры Никифор Фокены төрле котыртулар аша үзара сугыштыруга ирешү. Моның өчен Йосыф кахан Византиягә дә һәм Кияли каласына да үзенең йөзләрчә шымчыларын җибәргән иде инде. Яу чыгу мәсьәләсендә Йосыф кахан табынга кереп утырган имам хәзрәтләре белән дә киңәшкәндәй итте. Имеш, бик кыенга кала башласа, ул, Йосыф кахан, Харәзем әмире Мөхәммәтгалигә мөрәҗәгать итә аламы?.. Имамнар ышандырдылар: итә ала.

Шунда, табын җыены барганда ук, тәхет ягына Йосыф каханның ышанычлы шымчыларының берсе килеп керде һәм, табындагыларның һәммәсенә дә баш иеп, сәлам юллагач, кахан кырына узды һәм илбашына яңа хәбәр җиткерде. Йосыф кахан аның иңенә кулын куйды һәм барчасы алдында да:

— Минем ышанычлы адәмем безгә сөенче алып кайткан, җыендашларым. Византия императоры Никифор Фоке үтерелгән, аның урынын олуг император булган Константинның кызына өйләнгән яшь полководец Иоанн Цимисхий утырган. Ә ул безнең кардәшләребез болгарларны яулаган Сарманай каханга каршы яу кузгалган. Безгә ашыгыч төстә яшь император Иоанн Цимисхий белән солых төзергә һәм тиз арада шул тарафларга яу кузгалырга кирәк. Әйе, сузмыйча.

— Иоанн Цимисхий белән Сарманай сөйләшүләр генә алып баралар әле, галиҗәнаплары,— диде каханның ышанычлы шымчысы.

— Сөйләшә торсыннар,— диде аңа каршы Йосыф кахан.— Ә без кузгала башларбыз. Хак, безнең төп дошманыбыз Сарманай кахан түгел, Кияли түрәләре безгә һәрдаим ясак түләп тордылар. Әмма Сарманай кахан тәмам узынды, хәтта безнең Сарыкалага яу килергә кыйды. Димәк, Иоанн Цимисхий кахан Сарманай дружинасына бер яктан ябырылса, без икенче яктан ябырылырбыз. Мин әйттем!

* * *

Иртәгә яу кузгалабыз дигән кичне, Йосыф кахан үз кырына Булат бәкне чакыртып алды.

— Утырып тыңла, Булат бәк. Сиңа әмерем шул булыр: мин яу кузгалуга ук, син минем хатыннарымны таратасың. Үз иреләренә куй.

Булат бәк Аккалага да, Ханбалыкка да баш иде. Ул Йосыф каханга тугры хезмәт итте, кахан да Булат бәктән канәгать иде. Күп сөйләшми, кушканны җиренә җиткереп үти, әмма Булат бәк Йосыф ка-

ханга ышанып җитмәде. «Ничек инде хатыннарны куарга, өлкән равва ни әйтер? Бит башта ул әмер бирер иде...»

Алай да сорап куйды:

— Айбиби хатын да кайтып китәрме, галиҗәнаплары?

— Айбиби хатын сарайда калыр, бәк.

— Кахан белән яу китәм, дисә?.. Төрки ханбикәләрдә бу хәл булгалаган, галиҗәнаплары.

Йосыф кахан елмайды, аркасын тәхетенә терәтебрәк утырды.

— Айбиби хатын сарайда калыр, дидем түгелме мин сиңа, Булат бәк?!

— Яхшы, галиҗәнаплары, мин ялгышканмын.

— Калалар өчен генә түгел, калага кергән-чыккан, килгән-киткән халыклар өчен дә син җаваплы, Булат бәк, син!

— Мин кемгә буйсынырга тиеш булачакмын, галиҗәнаплары?

Йосыф кахан тәхетеннән күтәрелде, үз каршында бер тезенә төшеп торган Булат бәк янына килде, чәпләшкәле башына кулын куйды.

— Чәпләшкә кигәнсең, ә акылың дала төлкесенекеннән ары китмәгән, Булат бәк. Миңа, миңа буйсынасың!.. Аккала белән ике арада чапкыннарым йөреп торыр. Мәгәр үзең дә колакларың шәлперәйтеп, көтеп торма. Син кала башлыгы, кала тарханы, Булат бәк! Сиңа равваларым ярдәм итәрләр.

— Яхшы, галиҗәнаплары,— диде Булат бәк килешеп, Йосыф кахан аңа, чыгып кит дип, кул ишарәсе ясады.

Сарайдан чыгуга, Булат бәк, эчке бер кимсенү тоеп, күпергә таба атлады. Күперне чыкканда, Булат бәк Йосыф каханның баш хатыны Айбибине күз алдына китерде. Гүзәл иде Айбиби хатын, моның өстенә яшь, шуңа күрә булса кирәк, бу хатын сарайга килә-килүгә, Йосыф кахан үзгәрде, равваләр әйтүе хак булса, хатынны көнаралаш үзенә тарттыра башлый, ахыр һәр көн, дияргә була. Моны Булат бәк аңлады да, аңламады да. Аңлады — үзе дә хатыны Таңгөл кырына ашкынып, күрергә сагынып, тансыклап кайтыр иде, аңламады — кырык хатын тота ич кахан, кырык! Айбибигә гашыйк булуыдыр. Бит Булат бәк үзе дә Таңгөлен күрде дә тәмам телсез калды. Ни дә булса әйтер иде, әйтер сүзе аяк астына төшеп киткән кебек — сүзе табылмады. Кызның иңнәрендә көянтә-чиләкләр, атламый кебек кыз, гүя йөзә инде менә, су өстеннән йөзгән үрдәк кебек, юк, аккош кебек. Горур, тәкәббер, янбашлары уйный, шуңамы күргән саен күрәсе килә, күзләр дә кызганнан-кыза бара. Җитмәсә, әнә шул серле адымнары белән үзенә дәшә, дәшеп кенә калмый, җепкә бәйләп тарта. Түзмәде Булат бәк, меңбаш булган кеше ич, тәвәккәлләп, кызның каршына килеп басты. Кыз курыкмады, тик әллә ничек серле бер караш ташлады да, егетне урап-әйләнеп чыкты һәм ары китте. Булат бәкнең күзләрендә кызның күбәләк җилпенгәндәй керфекләре һәм серле карашы гына йөрәк түренә кереп калды.

— Кем кызы бу чибәр? — дип сорады таныш сәүдәгәрдән.

— Габдулла бай кызы. Юкка күзең кыздырма, егет. Ничәмә яучыны борды инде бу гүзәл зат. Бора да җибәрә, бора да җибәрә. Атасы да: «Кыз үзе сайласын иш буласы кешесен»,— дип кинәнгән була.

— Әтисеме шулай ди?

— Әтисе инде, әтисе. Бай яһүд сәүдәгәре дә улына сорап карады. Кыз үзе риза булса, бирәм, дигән атасы. Аннары: «Егет үзе килсен»,— дип шарт куйган.

— Кем шарт куйган?

— Кыз инде, кыз.

— Кызның аты ничек?

— Таң гөле, Таңгөл. Исемне дә куя белгәннәр бит үзенә.

Булат бәк Болгар базарына күз ташлады, яр буендагы мәһабәт өйгә. Ә анда Идел яр буенда сары кирпечтән күтәрелгән капкаларына кадәр бизәкле өй. Ханбалыкта яндырылган кирпечтән өй салырга кахан гына рөхсәт бирә. Димәк, Габдулла сәүдәгәрнең сарайда ышанычлы кешесе бар. Ә ышанычлы кеше — өлкән равва.

— Байның хатыны яһүдә, шулаймы?

— Яһүдә, шуннан ни, адәм баласы?

— Кибетең еракмы?

— Ике өй аша.

— Әйдә, минем синең кибетеңне күрәсем килә. Ошаса, бер-бер нәрсә алырмын да...

— Мин кораллар сатмыйм, киемнәр белән генә сату итәм. Атың ничек соң, ил бәндәсе?

— Сарай бәге мин, агай-эне, сарай бәге. Әле генә кахан яныннан чыктым.

Сәүдәгәр Булат бәккә борылып карады да, исе китмәгәндәй, кибет ишеген ачты.

— Габдулла байның тагын кызлары бармы?

— Таңгөлнең үсмер туганы бар. Бөҗыр да бөҗыр, ул да бөҗыр. Әллә кахан бәгенә кыз ошадымы? — дип сорады сәүдәгәр, лавкага киемнәр тезә-тезә.— Сиңа бер киңәш, кахан бәге. Син кызга туганы аша үтеп кер. Бүген нигәдер күренмәде, кыз елгага суга төшкәндә, энесе гел озата төшә.

— Саклый, димәк...

— Саклангאнны саклармын, дигән Хода, кахан бәге. Синең булачак каенишең яхшы кораллар, хәрби киемнәр ярата. Син әнә шуннан башла. Әйе, бер дә яучылар җибәреп торма. Үзең йөр. Кыз сиңа өйрәнсен, күрә йөрсен. Хатын-кыз күргәнгә ябыша, күрмәгәннән кача.

— Әйдә, синең киңәшең тотып карыйк. Бир әнә теге җемелдәп торган укалы җиләнне, нәкышле хәнҗәрне, укалы түбәтәйне һәм болгари итекне. Бир, бир, бәһасендә тормам. Тагын әнә теге руннар пәкесен бир, ике җәплене.

Киемнәрне ефәк капчыкка тутырып чыкты да Булат бәк елгага таба китте. Елга яр кырында гына челтерәп чишмә ага, әнә шул чишмәдән су алырга төшә Габдулла бай кызы Таңгөл. Атының тезгенен хайванның бәкәленә элде дә, ерак йөрмә, дип, утларга җибәрде, ә үзе елга ярына утырды да кызны көтәргә булды. Габдулла байның бер эчәсе килмәсә, бер килер, гүзәл кызын суга җибәрер, әнә шунда Булат бәк кызга йөгән «кигерер». Сабыр, сабыр, Булат бәк, сабыр ит. Ашыкма. Кыз сиңа өйрәнсен. Бер күрен, ике күрен, өч күрен.

Ләкин эңгер-меңгер вакыт җитте, кыз чишмәгә суга төшмәде дә төшмәде. Бу ни бу?! Габдулла бай бөтенләй чәй эчми яши микәнни? Өенә барып чыкса?.. Караңгы төшә башлады. Булат бәкнең аты да пошкырына, ашап туйды, иясенә дәшкәндәй итә. Инде нишләргә?.. Әллә соң иртә таң белән бире килергәме? Бүләкләр кулда... Менә шунда инде, караңгы төшеп килгәндә, чиләкләр тавышы ишетелде. Булат бәкнең колагы шаулап китте, йөрәге колак төбендә үк дөп-дөп тибә башлады.

Ул әкрен генә торды да чишмәгә таба кузгалды. Таңгөл чиләкләренә су алып маташа иде, артында ук аяк тавышы ишетеп, торып басты, шул мәлдә үк яман тавыш килде.

— Тукта! Тагын бер адым, мин сине укка алам!

Булат бәк борылып карады һәм эңгер караңгыда угын җәягә элгән Таңгөлнең энесен шәйләде.

— Мин коралсыз, батыр егет, коралсыз,— дип, кулларын җәйде Булат бәк. Элек һәрдаим җан сакчыларын үз янында йөртер иде, бүген исә әллә ни булды Булат бәк белән, каханнан чыкканнан соң, барыр юлын югалткандай йөри. Әллә соң Хода үзе китердеме аны монда — Таңгөл янына. Бәлкем, бу кыз минем язмышымдыр...

— Тагын бер адым! — дип кабатлады укчы малай.

— Апаң су алсын инде, булышыйм апаңа су алырга,— дигән булды Булат бәк.

— Тагын бер адым! — дип кабатлады янә бер тапкыр үсмер.

— Мин сиңа, мәргән егет, изге ният белән килдем, ишетәсеңме, изге ният белән. Күрәсең, минем кулларым буш. Атым өстә утлый, карак та, бур да түгел мин.

— Камил, Камил! — диде, ниһаять, апасы Таңгөл.— Куй ук-җәяң. Миңа чиләкләремне яр өстенә алып менәргә ярдәм ит.

— Алып менсен яныңдагы бүкәй. Бу минем боерыгым,— диде үсмер.

Үсмер шулай диюгә, Булат Таңгөл янына килде, һәм йөзенә гүзәл кызның татлы исләре килеп бәрелүгә үк башы әйләнеп киткәндәй булды. Чиләкләрне биргәндә, чиләк тоткасы белән бергә кызның да нечкә вә йомшак бармакларына кагылып алды Булат бәк, юри, имеш, ялгыш эләктерде. Аннары җайлы гына ике чиләккә дә мөлдерәмә салкын чишмә суын тутырып алды да йөгерә-атлый, әмма бер тамчы суны да түкми, яр өстенә менде һәм, чиләкләрне куеп, кыз артыннан чишмә янына төште, кыз кулын сузуга, күтәреп алды, очыртып яр өстенә алып менде һәм чиләкләре янына бастырды. Кулыннан тотты да, ике тезенә төшеп, кызның эңгер караңгылыгында тагын да серләнеп киткән күзләренә карап:

— Мин сиңа яучым җибәрәм, яучым, Таңгөл,— диде.

Ул арада алар янына батыр үсмер килеп басты, үрелеп, Булат бәкнең иңенә суккалап:

— Җитте, сиңа китәргә вакыт,— диде.

— Ә мин сиңа, каениш, рун пәкесе алып килдем, җилән...

— Күрсәт,— диде боерулы тонда үсмер.

Булат бәк атына сызгырды, ат килеп җитүгә, ияренә таккан капчыкны алды да, капчыктан җиләнне чыгарып, үсмернең иңбашына салды, рун пәкесен кулына тоттырды. Үсмер бер мәлгә югалып калды, моңа кадәр күпме генә яучылар килмәсен, бер генәсе дә бу тамаша бүләк китермәгәннәр иде Камилгә. Ә бу Булат атлысы мулдан җибәрде.

— Син кайта тор,— диде үсмер, бүләкләр кулына керүгә.

Апасы көянтәсенә чиләкләрне элде, һәм гүзәл Таңгөл караңгы төшеп килгән эңгер эченә кереп чумды.

— Апаңны югалтсаң? — диде үсмергә Булат бәк.

— Мин мәче кебек төнлә дә күрәм,— диде үсмер, эретерәк кенә.

— Үскәч, мин сине үз кырыма алам, сарайга хезмәткә,— диде Булат бәк һәм атының тезгененнән алды.

— Ә син апамның күңелен яуларга теләсәң, яучы булып үзең кил, адәм баласы.

— Үзем?!

— Әйе, үзең. Ә хәзер кит. Бүләкләрең өчен рәхмәт. Ошадың син миңа. Апам этине түгел, мине тыңлый, мине! Белеп кит!

Шулай диде дә үсмер, апасы артыннан йөгерде. Булат бәк бер мәлгә ошбу үсмергә ни әйтергә белми торды, ахыр атына атланды да Аккала күперенә таба чапты.

Ни гаҗәп, чишмә янына икенче килүендә Булат бәкне үсмер каенише үтә гаҗәпләндереп:

— Минем җизнәм буласың килсә, бүген үк урла Таңгөл апамны. Иртәгә Биләмҗир тарханы улыннан безгә яучы килә, апамның тарханның угланын күргәне бар, ошаткан иде, риза булып куюы бар, ә син миңа ошадың,— диде.

Үсмер егеттән Булат бәк моны көтмәгән иде, бертын ни әйтергә белми торды. Ахыр чарасыз калды, чөнки һич тә моңа әзер түгел иде:

— Кайдан, чишмә яныннанмы? — дип сорады.

— Әйе, кич суга төшкәч урла,— диде үсмер.

Булат бәк тәвәккәлләде, үзе белән ике җан сакчысын да алып, кичке якта елга буена, чишмә чыккан төбәккә юнәлде. Буласы каенише анда иде инде.

— Хәзер апам килеп җитә, мин бу хакта апама да әйттем инде. Урла. Ләкин минем белән бер җан сакчыңны калдырырсың. Мин аның аяк-кулларын бәйләп, атама алып кайтырмын. Ә ул атама булган хәлнең асылын сөйләп бирер. Аңлаштыкмы? — диде булачак каениш.

— Аңладым, аңладым, каениш, аңладым,— дип, Булат бәк, эңгер иңеп килгән вакытта, чишмә янында Таңгөлне көтәргә булды. Ләкин Таңгөл ашыкмады, күренмәде дә күренмәде. Чарасызлана башлаган Булат бәк гасабилана башлады, хәтта янәшәсендә басып торган булачак каенишенә:

— Атаң ул-бу сизмәгәндер бит? — дип сорап куйды.

— Юк, сизмәде. Яучы килеп төшкән булса гына инде,— диде.

— Яучы бүген килергә тиеш идемени?

— Бүген килергә тиеш иде. Сабыр ит, булачак җизнәй, төшәр апам суга, төшәр. Атам ни дә булса төпченәдер. Беркөнне дә шикләнеп, нигә син, кызым, эңгер төшкәндә, чишмәгә суга төшә башладың әле, дип зарланып алган иде.

Шунда, Ходайның хикмәте, эңгер иңә башлаган караңгылык эченнән, кичке эңгерне ерып, чиләкләрен бер кулына, көянтәсен икенче кулына тотып, Таңгөл килеп җитте. Булат кызны күрде дә, килеп җитәр-җитмәс аңа таба китте, чиләк-көянтәсен алып җиргә куйды һәм Таңгөлне кулына күтәрде. Шулчак булачак каенише аңа:

— Җизнәй буласы кеше, куй, калдыр апамны, юкса укка алам! — дип янамасынмы.

— Без бит сөйләшкән идек инде, каениш,— дигән булды, әле булса кулында тоткан кызны җибәрмичә. Моның өстенә кыз аның муенына сарылган, кайнар сулышы белән муенын пешерә.

— Җан сакчың кая?

Шунда гына эшнең асылына төшенеп, Булат бәк караңгылыкка кычкырды.

— Хаҗибәй, бире кил!

Җан сакчы килүгә, үсмер малай аңа җиргә ятарга кушты, әмма теге икеләнә калды.

— Җиргә ят! — дип боерды аңа үсмер Камил.

— Ят инде, ят! — диде аңа Булат бәк.— Ят!

Теге сузылып яткач, үсмер Камил беркемгә дә игътибар итми, җан сакчының ефәк бау белән кулларын бәйләде, ахыр аякларын, шуннан соң гына булачак җизнәсенә:

— Атыңа сызгыр! — диде.

Булат бәк сызгыруга, ат җилле генә чаптырып килде, оста хәрби буларак, Булат бәк кызны ияргә утыртты да, үзе дә атланды һәм булачак каенишенә:

— Ышан, Камил каениш, мин апаңны рәнҗетмәм, кайту белән мулладан никах укытырмын.

— Сыза тор, атамның сизеп алуы бар,— диде аңа кырыс кына үсмер егет. Энесенең җавабына башта апасы кеткелдәп көлеп җибәрде, аңа ияреп Булат бәк елмайды, чөнки кай тарафтандыр аның колагына ат тояклары тавышы килгәндәй булды.

Инде каенише булып киткән Камил атасыннан ничек котылгандыр, Булат бәк сорашмады, әмма Габдулла бай улы Камил әсир итеп алган җан сакчысын туй булгач кына азат итте һәм түрдә кукраеп утырган киявенә:

— Яучы җибәргән булсаң да, синдәй егеткә кызым биргән булыр идем, кияү,— диде.

Шунда атасы сүзенә куәт өстәп, ишек яры утырган Камил улы әйтә салды.

— Ай-һай, атам, бит син Булат җизнәйнең җан сакчысын гына түгел, мине дә: «Апаңны саклый алмадың, малай актыгы»,— дип, кар базына ташлаган идең,— диде.

— Ташладым, хак. Вәләкин эшнең асылын әйтүгә, икегезне дә чыгарып, табыныма утырттым,— диде ата кеше.

Әнә шулай өйләнгән иде Йосыф каханның кала тарханы Булат бәк. Һәй яратты да соң Таңгөлен Булат бәк. Кич кояш баюга, ятулары була — таң ата. Төнне төнгә кушасы килгән чаклары да булды, яшерә алмый, яшерәсе дә килми. Ә кайчак, буш вакытлары булган чакта, Таңгөлен далага алып чыгып китәр иде дә, инеш буендагы куе таллыкка алып кереп, сөеп туймастай яратыр иде. Булды, булды андый чаклары да. Үлепләр яратты Таңгөлен, үлепләр...

Яратыр-сөяр иде дә, дала төлкеләрен вә йомраннарын куркытып: «Яратам, яратам мин сине, Таңгөлем»,— дип, кулына күтәреп алып, зыр-зыр әйләндерер иде. Мәхәббәт уты татлы айдан соң сүрелә, диләр. Сазаган ир-егетләр әйтсә әйтәләрдер моны. Булат бәк Таңгөлен айлар үтә-үтә дә тансыклады, юксынып-сагынып өйгә кайтты, кайтып керүгә, кулына күтәреп алды да бердәнберен түшәккә илтеп салды... Әллә ни булды Булат бәк белән, әллә ни күңелен тартып торды Таңгөлгә! Ятса — ул, торса — ул. Әллә соң Йосыф кахан да аның сыман гашыйк булдымы Айбиби хатынга. Бит кырык хатынга ия кеше иде. Кырык хатынга! Ә хәзер аңа бер Айбиби хатын кирәк. Шаккатмалы хәл. Хәзер Булат бәк, ул яуга китүгә, кырык хатынның берсен дә сарайда калдырырга тиеш түгел, кырык хатынның берсен дә. Бары тик, сарай күркәме булып, Айбиби хатын калачак. Димәк, каханга минем чирем кагылган, мәхәббәт чире. Тикмәгә генә раввалар «Мәхәббәт ул — чир» димиләр икән шул. Мәхәббәт чире белән чирләгән була инде Йосыф кахан. Имамнар мәхәббәтне «Аллаһы бүләге» дигән булалар. Ни генә булмасын, мәхәббәт бар, дигән нәтиҗәгә килде сарай күпереннән чыгып, атын өенә таба борганда Булат бәк. Кала тарханы булса да, ни өчендер аңа сарай раввалары Аккалага өй салырга рөхсәт итмәделәр. Имеш, мөселман, ул гынамы, Болгар төркие. Ә Болгар төркиләре гыйлемле халык. Шуның өчен Болгар төркиләре белән сарай раввалары арасында һәрдаим ачыктан-ачык бармаган, әмма һәрчак булып торган бәхәс барды — кем өстен. Әйе, кем өстен Хазарстанда — яһүдләрме, төрки болгарларымы? Чөнки бу халык, борын-борын заманнардан бирле ошбу төбәкләрдә көн күреп, Аттила баһадир чорларын хәтерләтәләр, һәм нәкъ менә төрки болгарлары «акацирлар» йөзендә Аттила ханның төп көчен тәшкил иткәннәр. Моны да яхшы беләләр иде сарай яһүдләре. Шуңа карамастан, соңгы йөзьеллыкта Хазарстан белән яһүд раввалары идарә итә башладылар. Әмма каханны — илбашын төркиләрдән сайладылар, йә булмаса, кушылган гаиләдән килгән ир-атны тәхеткә утырттылар. Тик менә тәхеткә Йосыф кахан килгәч, сарай халкы шомлана башлады. Йосыф кахан баш калкытып кына калмады, үзенең кем каныннан килүен дә аңлатырга кереште. Өлкән равва белән аның раввалары бу хакта ничек уйлыйлардыр, әмма Булат бәк кала тарханы буларак яхшы белә иде: төркиләр янә өстен чыга башладылар, Харәзем әмиренең имамнары сарайга үтеп кереп кенә калмадылар, үз киңәшләрен бирәләр. Булат бәк бу хәлгә кинәнде. Шул ук вакытта ул раввaларны да хөрмәт итте. Чөнки ил байлыгы алар кулында иде. Мул акча исә — көчле гаскәр, ә көчле гаскәр — ил куәте.

**X**

Төрки болгарларының кахан сараена үтеп керүләренә бер дә шаккатасы түгел иде. Кубрат хан чорларында ук инде Хазар каханаты белән берләшеп алган Кубрат ханның баш улы Батбай аксакаллары кахан сараендагы табыннарда утыралар. Хазарстан сараен үз кулларына төшергән раввалар да Муса пәйгамбәр кануннарына таянып яшәгән төрки болгарларын ят итмәделәр. Ул гынамы, яһүдләр тарихы йөзендә дөнья халыкларына ирешкән тарихларында да, ягъни Библиядә, яһүд руханилары төркиләрне «Туран» аты белән телгә алалар. Ул вакытта дөнья төркиләрен үз тарихларына фарсылар кертеп җибәрәләр. Аталары, каханнарның нигез ташлары «тураннардан» чыккангамы, бу хакта Йосыф кахан да яхшы белә иде. Чөнки нәкъ шул борынгы төркиләрнең ак тәнле кавемендәге кыз аның куенында. Дөньядагы бөтен бәла-казаларны яһүдләрдән күргән колбиләүчелек исәбенә куәтләнеп киткән римләннәр дә, фарсылар да, бу илләргә христиан дине үтеп керә башлагач, яһүдләрне илләреннән куа башлыйлар, хәтта эзәрлекләүгә кадәр барып җитәләр. Әнә шунда илләр буйлап саташып йөргән раввaларны Хазарстан каханы кабул итә. Имеш, китаплы халык. Хазарстан каханаты нәкъ менә ил-халык белән идарә итүне үз кулларына алгач, көчәеп вә куәтләнеп китә. Шул сәбәпле булса кирәк, Хазар каханы Идел буе төрки болгарлары белән бер тапкыр да орышмады да, сугышмады да. Ислам динен кабул иткән имамнар да, кахан раввалары да ниндидер юллар белән тату яшәүгә ирештеләр. Хак, ислам дине хакында Болгар мөселманнары белән еш кына бәхәсләр туа тора, хәтта кахан мөселманнарны илдән дә кугалады. Вәләкин бу ике ил халкы беркайчан да зурдан кубып орышмады. Ни өчендер, сәүдәгәрләренең һәм раввaларының сүзләрен тыңлап, Йосыф кахан башкисәр викингларны дәшәргә булды. Ләкин әле бу тиз генә булмас, викинглардан хәбәр килмәде, килгән хәлдә дә ул башкисәр халыкны Идел тамагы аша үздыру турында гына сүз барачак. Ләкин Йосыф кахан өчен каладыр бер дошман — Византия империясе һәм каханат канаты астыннан чыгарга теләгән Сарманай. Дәүләт хакиме буларак, Йосыф кахан Идел буйларында көн күргән төрки халыклары белән тату яшәргә тырышты. Аларга ярдәмгә бай сәүдәгәрләрен җибәрде, шәһәрләрдә сәүдә кальга-калалары күтәртте, төрки бәкләренә вә әмирләренә чибәр яһүдә кызларын озатты. Бу яһүдләрнең ата-бабаларыннан килгән сәясәт иде. Әнә шул яһүдә хатыннардан туган ир балаларны сараена тарттырды, укытты. Илбашлары итте. Инде күптән даны ераkларга таралган Ефәк юлы да Хазарстан сәүдәгәрләре кулында иде. Шуларның барысын да бер җепкә тезеп уйлый торгач, Йосыф кахан «Мин дөрес юлда!» дигән фикергә килде.

Кич белән ул янә үз кырына Айбиби хатынны тарттырды. Хәрам атакай Айбиби хатынны ятакка кертте дә ишекъяры торып калды.

— Нәрсә булды, нигә торып каттың?! — дип, хәрам атага карады Йосыф кахан.

— Хатыннар таратылгач, без сарайда калырбызмы, балакай?

— Калырсыз,— диде Йосыф кахан һәм, шыл моннан, дип, кул селекте.

Айбиби, ни кылырга белми, аның кырында басып тора иде, Йосыф кахан, гадәттәгечә, аны кулына күтәрде дә ятагына таба алып китте. Алып барганда, хатынның билен кыса төште булса кирәк, Айбиби: «Ай!» — дип кычкырып җибәрде. Йосыф кахан аны сак кына ятакка салды һәм сорап куйды:

— Ни булды, Айбиби җан?

Айбиби каханның күзләренә карады һәм тыенкы гына:

— Бәбиемне рәнҗетә күрмә,— диде.

Менә кайчан каханга кинәт канат үсте, менә кайчан ир уртасы кеше, үз-үзен белештермичә очынып, бүлмә буйлап йөреп килде һәм хатын янына ятты, ул гынамы, көйли-көйли шигырь әйтте:

Без бергә, бергә, бәгырь, син дә, мин дә бәхетле,
Синең белән бер тән, бер җан булдык, бәгырь, бу көндә...

Чынлап та, ни булды аңа кинәт, нигә бу хәбәргә шулай шатланды? Бит мондый хәбәрне бер Айбиби хатыннан гына ишетмәде, аның кырына кергән һәр хатын булмаса да, күпләре, балага уздым, дип, каханны куандырмакчы иттеләр, ләкин бер тапкыр да бу чиккә җитеп шатланмаган иде. Җитмәсә, Айбибинең апасыннан Тамантархан Галидә инде балигъ булган улы бар. Ләкин күңеле белән сизә-тоя иде Йосыф кахан: Айбиби хатын углан бала тапканда, аны шул углан алыштырачак.

Шул уй башына килүгә, Йосыф кахан хатынны кочагына иңдерде, сак кына назлый башлады.

— Йосыфҗан, Йосыфҗаным,— диде Айбиби ир-канатына.— Миңа ирештерделәр, син хатыннарыңны куарга әмер биргәнсең икән. Аккошларыңны мин үзем генә ашатырмынмы?

Самими иде Айбиби, ләкин самими янында самими. Йосыф кахан белә иде: Айбиби хатын белемле, теләсә кем белән бәхәсләшә ала, бу хатыннан хәтта өлкән равва да курка төшә. Ләкин самими кебек күренгән Айбиби хатын аккошларга гашыйк иде.

— Аккошларны ашатучылар табылыр, син миңа малай тап, Айбиби җан, малай. Менә шунда мин сине күккә чөячәкмен.

— Мин куркам, син яуга китәсең ич!

— Мин яудан исән-имин кайтырмын, Айбиби. Кайтырмын да сине далага алып чыгармын. Иксез-чиксез далага. Һәм шунда мин мәңге синең белән калырга ант эчәрмен, мәңге!..

— Аккошлар култыгына каракош төшә. Ә ул яман кош, явыз кош!

— Каракош суга төшми, Айбиби җан. Ул тирәктә утыра, аккошлардан көнләшә, үлепләр көнләшә.

— Синең әләмеңдә дә аккош сурәте, Йосыфҗан. Ә Византия императоры әләмендә каракош тамгасы.

— Менә шуның өчен мин Византия императоры тарафына яу кузгалам да инде, Айбиби җан. Каракош тамгасын сайлаган Византия императоры. Ә каракош тамгасы — явызлык билгесе.

— Аккошлар култыгында моңсарлары да бар. Мин аларны кызганам, Йосыфҗан.

— Ишләрен укка алганнар аларның, Айбиби җан. Алар җан сөйгәннәрен югалтканнар, җан сөйгәннәрен, Айбиби җан. Чөнки аккошлар бер генә тапкыр кавышалар, ә ишен югалткан аккош яңадан бер генә аккош белән дә кавышмый. Ялгыз яши, ялгыз үлә.

— Мин дә гүргә кергәнчегә кадәр бер сине яратырмын, Йосыфҗаным, бары тик сине! Еш кына мин үземне әнә шул ялгыз калган аккош итеп тоям, Йосыфҗан. Барма яуга, каханбәгең генә җибәр.

— Юк инде, Айбиби җан, мин бу яуга барырмын. Чөнки бу яудан соң мин равваларыма буйсынмый башлаячакмын. Тик син елама. Көт, сабыр ит. Нык бул. Мин кайтырмын, һәм без, һәр көн улыбызны җитәкләп, аккошларны ашатырга төшәрбез.

— Нигә соң миңа кадәр күп хатын тоттың, Йосыфҗан бәгырь?

— Бу раввалар йөге иде, равралар йөге, Айбиби җан. Мин алардан өстен чыкмаган хәлдә, алар мине юк итәчәкләр.

— Ефәк бау белән буыпмы?

— Ефәк бау белән буып, Айбиби җан. Яудан кайткач, алар моны кылырга кыймаслар.— Йосыф кахан Айбибинең иреннәренә баш бармагын куйды.

— Йосыфҗан...

— Яудан кайткач, мин бары тик синең белән генә торачакмын. Тик син башта миңа углан бәби тап.

— Йорт зирәклек белән корылыр, акыл белән ныгытылыр, ахмаклык белән сүтелер, дигән Сөләйман пәйгамбәр.

Гадәттәгечә, Йосыф кахан Айбибинең сүзләренә гаҗәпләнә калды. Бу хатын барысын да белә иде, хәтта пәйгамбәрләрнең гыйбарәләрен дә.

— Сөләйман пәйгамбәрнең вәгазьләрен беләсең — мин шат, Айбиби җан. Ләкин син мине мактамасаң иде, чөнки Сөләйман пәйгамбәр мактауны яратмаган, ул бу хакта: «Сине үз халкың түгел, башка халык мактасын»,— дигән.

— Ләкин бит синең равваларың һәрдаим Сөләйман пәйгамбәр вәгазьләрен тәкрарлыйлар, ялкынланып сөйлиләр, һәм алар һәрвакыт хаклылар. Ә Сөләйман пәйгамбәр бу хакта: «Ялкынлы тел белән мәкерле күңел — көмеш йөгертелгән савыт кына ул»,— дигән.

— Син дә, раввалар да хаклы, Айбиби җан. Артык акыллы хатынны ирләр яратып бетермиләр. Син мине акылың һәм тапкыр сүзләрең белән түгел, аккошларың белән үз иттең.

— Син — илбашы, акыллы кеше, Йосыфҗан. Акны карадан аера белерсең дип ышанам. Мин сине яратам, һәм мин синнән углан бала табачакмын, Аллаһы боерган итсә. Һәм Аллаһым миңа бу гамәлемдә ярдәмгә килер.

Әнә шулай сөйләшә-сөйләшә, йокыга киткәннәрен сизми дә калдылар. Ишек шакыгач кына, Айбиби дерт итеп уянып китте һәм Йосыфына кагылды. Йосыф кахан күзләрен ачты, бертын түшәмгә карап ятты. Шуннан соң гына:

— Мин хәзер әзер булам,— диде.

Торып киенделәр, юынып табынга утырдылар. Шуннан соң гына Йосыф кахан Айбибине ишеккә кадәр озата килде, битеннән үбеп, колагына:

— Бирешмә, Айбиби җан, мин кайтырмын,— диде. Икенче мәлдә инде кахан: «Кертегез хәрби киемнәремне!» — дип кычкырды.

Киенеп тәхет ягына чыккач, кахан кырына беренчеләрдән булып өлкән равва керде, аның артыннан ук каханбәк Сабир.

— Галиҗәнаплары, барысы да әзер! — дип, тураебрак басты каханбәк.— Сезгә кара бия дирбияләнде, җайдак атта кара бия булыр.

— Өлкән равва Ибраһим,— дип, кинәт бер читтә басып торган өлкән раввага дәште Йосыф кахан.— Сарай синең кулда, кала Булат бәк кулында булыр.

— Хуш, Йосыф углан, хуш. Ак юл сезгә,— диде өлкән равва.

— Тәңребез юлдаш булыр, иншалла! — дип әйтеп ташлады каханбәк Сабир.

Ни кахан Йосыф, ни ишекъяры торучы сакчылар моңа игътибар итмәделәр, ә менә өлкән равва куырылып куйгандай итте. Ул арада тәхет ягына имам хәзрәтләре керде һәм, изге юлга чыгар алдыннан, Аллаһыбызга дога кылыйк, дип, ишек кырындагы түмәргә утырды. Йосыф кахан белән өлкән равва күзгә-күз карашып алдылар да аяк өсте генә имам белән бергә битләрен сыпырдылар.

Хазарстан яһүдләре өчен генә түгел, сарай куштаннары өчен дә ят чара иде бу. Әмма нишләмәк кирәк, өлкән равва, үзе үк Харәземгә барып, Ибраһим атын алып кайтты. Йосыф кахан аңа «өлкән раввам Ибраһим» дип дәшкәч тә, өлкән равва сискәнеп киткән иде, ләкин моңа игътибар итүче булмагач, уздырып җибәрде. Ахыр килеп, моңа бик үк гаҗәпләнәсе дә юк, Харәземдә генә түгел, Ханбалыкта да күпчелекне мөселманнар тәшкил итәләр иде инде. Бары тик шуңа күрә генә чарасыз калган раввалар сарайларын утрауга салдырдылар. Ләкин диннәрдән утрауларга качып кына котылып булмый икән шул. Әнә шуны аңлады өлкән равва, Йосыф каханны яуга озатканда.

* * *

Сара анакай, атна дигәндә, Аккалага кайтып төште. Һәм Гаязетдин углан белән. Ни хикмәт, өлкән равва кулыннан әмерне алуга, Сара анакай, бер көн дә кунмый, Казан тарафларына юл чыкты. Бу хакта Айбибигә өлкән равва әйтте.

— Нигә алай, безне дә күрмичә? — диде Айбиби.

— Сара анакай Аккаланы да, Ханбалыкны да яратмады, Айбиби хатын. Була бит шулай яратмаган кешеләрең, яратмаган калаларың, яратмаган ирләрең, хатыннарың... Әйтик, Хәдичә хатын Йосыф каханны яратмады. Һәм шул сәбәпле без аны беренчеләрдән иленә озаттык, табибәсе белән бергә.

Айбиби үзалдына елмаеп куйды һәм уйлады: «Димәк, өлкән равва Исламның егет кеше икәнен белми калган»,— дип кинәнде.

Айбиби, бала итәкле күлмәгенең итәген күтәрә төшеп, баскычтан сарайга күтәрелә башлады, өлкән равва аңа иярде.

— Өлкән равва, сезне сарайда Рәшидә абыстай көтә,— диде Айбиби, артына әйләнеп карамый гына.

— Рәшидә абыстай, мине?! — дип гаҗәпләнде өлкән равва һәм ничәнчедер баскычта туктап калды.

— Әйе, аның сезне күрәсе, ни турындадыр киңәшәсе килә,— диде Айбиби, баскычлардан менеп баскач кына борылып, өлкән раввага карады.

— Мин хаким дә, хөкемдар да түгел, Айбиби хатын.

— Сез хаким дә, хөкемдар да, өлкән равва. Аннары Аккала каласының ачкычы да сезнең кулда.

— Төп ачкыч Булат бәк кулында, Айбиби хатын.

— Ә сез, баш равва, сарай әүлиясы, кылычсыз баһадир, акыл иясе, каханның уң кулы, өлкән киңәшчесе. Сезнең киңәштән башка каханыбыз кыл да кыймылдатмый, өлкән равва.

Айбиби хатын аңа өстән аска карап тора иде, өч баскычка түбәндә басып торган өлкән равва үзе дә аңламаган кимсенү тойды. Әйтерсең баш хатын аңардан да өстен иде. Ә бит һәр биләмәдән аның теләге белән теге йә бу тарханның кызын Аккалага тарттырдылар. Шул исәптән Айбиби хатынны да. Ә бу хатын — мөслимә. Шушы мөслимә хатын килгәч, сарайда барысы да асты-өскә килә башлады түгелме?.. Харәзем әмире, имамнар да шушы хатын килгәч, тәхет ягына кадәр үттеләр, хәтта каханга үз киңәшләрен бирә башладылар. Хак, һәр хакимнең тәүге максаты — кул астындагы түрә-тарханнарны, сарай куштаннарын, шул исәптән равваларны да куркытып тору, тик өлкән равваны түгел. Әйе, түгел иде. Бүген исә... Заманында Булан каханнан барысы да дер селкенеп, куркып торганнар. Явызларга явыз була, баш игәннәрне мактый Булан кахан. Ләкин һәр кахан өчен дә үтә начар нәтиҗәгә китерә торган бу гамәл ил халкын үчкә китерәчәк, шул исәптән сарай куштаннарын да. Тик бит Булан кахан явызларны кылган явызлыклары өчен кичерә дә, гафу итә дә белгән. Әмма кайбер сарай кануннарын бозган аксөякләрне рәхимсез рәвештә җәзага тарттырган.

Моны ул кул астындагылар узынып китмәсеннәр, кемгә хезмәт итүләре хакында онытмасыннар өчен эшли. Ул вакытта бүгенге өлкән равва да үз адашының шәкерте иде әле. Ибраһим рavваның исәеп килгән чагы, ә ни сәбәпледер Булан кахан аның остазы өлкән равваны күралмый башлады. Мөселманнарны яклаган өчен, дииделәр. Шуннан кисәктән көннәрдән бер көнне аның адашы вә остазы юкка чыкты. Ә икенче көнне Булан кахан яшь Ибраһимны үзенә дәшеп алды һәм кистереп:

— Бүгеннән сарайда син булырсың өлкән равва,— диде.

Шуннан күп тә үтми, Булан каханны чәнчеп үтерделәр. Кем, ни өчен — һичкем белмәде. Ил тәхетенә Йосыф углан утырды. Яшь Ибраһим аның өлкән раввасы вә киңәшчесе булып китте. Сарайга Идел буе Болгарыннан Мөхәммәд ханның Айгөл кызын тарттырдылар. Ләкин ул бала тапты да якты дөньядан китте. Менә хәзер аның алдында Мөхәммәд ханның икенче кызы. Тәкәббер, горур, биленә таянып, эретерәк рәвештә сөйләшә. Кахан Йосыф исә моңа кадәр булмаган хәлгә барды — яуга киткәндә, Булат бәккә, сарайдагы барча хатыннарын да илләренә озатып, бер Айбиби хатынны гына калдырырга дип, әмер-фәрман биреп китә. Һәм Ибраһим равва белән киңәшмичә. Әллә соң шулай тараламы империяләр, әйтик, Иран, Рим империяләре. Рим империясеннән килгән Константин Византия тәхетенә утыруга, сенатка төкереп карый башлый. Әмма Хазарстанда барысы да әйбәт иде, тик менә хатын килгәч, әллә ни булды, кахан да үзгәрде, сарай куштаннары да өлкән равваны санга сукмый башладылар, мөселманнар да, имамнары да тәхет ягына кадәр үтеп керделәр. Барысына да кахан гаепле — кырык хатынын куарга фәрман язып, бер шушы хатынны калдыра. Нәрсә бу? Әллә соң, чынлап та, бу мәхәббәт дигән хикмәт бармы? Йосыф кахан, кырык яшенә килеп җиткәндә шушы хатынга күзе-башы тонар хәлгә җитеп гашыйк булды. Моңа ышануы кыен иде, гәрчә хатын күз алмастай гүзәл булса да...

— Мин керермен Рәшидә абыстай янына, юк, мин аны үземә дәштерермен, Айбиби хатын,— диде, ниһаять, өлкән равва. Һәм Айбиби борылып китеп баруга, үзе дә әкрен генә кузгалды.

«Тарихтан гыйбрәт алу кирәк иде Йосыф каханга, тарихтан»,— дип авыз эченнән тәкрарлады өлкән равва һәм ни өчендер борынгы бабаларының хаталарын искә алды. Шул ук вакытта сарай ишеген үтеп баручы Айбиби хатынга янә күз ташлауга: «Алиһә икән шул бу бала, алиһә»,— дип мыгырдап куйды. Зиһене фәлсәфи китапларны укып, тарихта булган хәлләрне мантыйкый рәвештә хәл итәргә көйләнгән булганга, бүлмәсенә кереп, йомшак кәнәфигә утыргач та, бабалары тарихын күзаллаудан ерак китмәде. Моның сәбәбен белә иде кебек өлкән равва Ибраһим, шул ук вакытта еш кына яһүд тарихларында бабалары кылган хаталарны зиһене аша кат-кат уздырыр иде.

Борын-борын заманнарда яшәгән бабалары, мисырлылар әсирлегеннән исән-имин котылып, ассириялеләрдән шаһиншаһ Кир ярдәме белән азат ителеп, туган туфракларына кайткач, ни өчен соң әле өсләренә ябырылган римләннәргә каршы тора алмыйлар? Бу тарихны да яхшы белә иде өлкән равва. Йосыф Флавий язган «Яһүдләр сугышы» китабын кат-кат укыганы бар. Ошбу канлы сугыш римләннәр тәхетендә Кай Калигулла утырганда була. Рим легионерлары бабаларының җирләренә вә калаларына басып керәләр. Яһүдләрнең гаскәриләр башында торган Йосыф Флавийны богаулап Римгә алып китәләр. Ул анда укый, белем ала һәм егерме алты яшендә, судта катнашып, үлемгә хөкем ителгән якташларын йолып алып кала. Империя кануннарын яхшы белмәгән хәлдә, ай-һай, ирешә алыр иде микән моңа Йосыф Флавий. Шул хәлдән соң Рим кануннарын яхшы өйрәнгән Йосыф иленә кайта һәм үз халкын империягә каршы баш күтәрергә котырта. Ул арада Рим тәхетенә Нерон утыра. Йосыф Флавий, тарихчы буларак, үз-үзенә ачыш ясый: «Яһүдләр үзләренең тарихларын булган хәлләргә таянып язсалар, эллиннар үз тарихларын экиятләргә, легендаларга әверелдерәләр». Тарихчы Йосыф, яһүдләр тарихын язганда, Хак Тәгаләгә йөз тота. Әйтик, Птоломей VI чорында яһүдләргә Антиах ябырыла. Кала артыннан кала алаала, бабаларын җиңә һәм ravваларга шарт куя: моннан ары балаларыгызны сөннәткә бирмисез, корбан чалуда чучкага өстенлек бирәсез!

Изге алтүргә чучка баласын кертеп, корбан итүне яһүд ravвалары кабул итмиләр. Җиңүчеләр яһүд халкын моңа кадәр тарихта булмаган җәзалар белән җәзалыйлар. Халык моңа түзми, баш күтәрә. Мәдин каласы раввасы Хасманайның улы Маттай җиңүчеләрдән Синай тавына кача, ахыр аннан төшеп, үз кырына ишләрен җыеп, баскынчылар өстенә ябырыла. Баскынчыларның түрәсе булган сәргаскәрне

хәнҗәр белән чәнчеп үтерә һәм илен баскынчылардан азат итә. Һәм ил белән үзе идарә итә башлый. Маттай вафат булгач, тәхетне өлкән улы Яһүдкә калдыра. Яһүдне тәхеттә Яһүдәта алыштыра. Баскынчы Гиркан яһүдләрнең аталары булган Давытның каберен ача. Ә Давыт яһүдләрнең иң бай патшалары була. Һәм патша табутындагы 3000 талантны ала, шулардан 300 талантны Яһүдстанны ташлап киткән хәлдә сезгә бирәм, дип ышандыра. Әнә шулай Гиркан беренчеләрдән булып бабаларының каберен ача һәм андагы хәзинәдән файдалана. Шул хәлләрдән соң яһүдләр тәхетенә Иохан килә һәм ил белән күп еллар идарә итә. Ул үлгәч, тәхеткә бавилләр әсирлегеннән кайткан Аристабал утыра. Аны үз туганы чәнчеп үтерә. Ниһаять, Яһүдстан тәхетенә Рим императоры Цезарь ярдәмендә Ирод килә. Иродны ил башына аның тарафдарлары Антоний күтәрә һәм сенатта раслатуга ирешә. Әнә шулай Капитолиядән фатиха алып, Ирод Римнән туган иленә кайта һәм ил белән идарә итә башлый. Әлбәттә, Рим вассалы булган Ирод патшаны халык яратмый. Әйе, кем була соң яһүдләрнең тарихын язып калдырган Йосыф Флавий? Йосыф Флавий — яһүдләр тарихчысы. Гайсә пәйгамбәр еллар саны белән 37 нче елда туа, әнисе ягыннан Маккавәйләр буыныннан. Йосыф Флавий яһүд мөгаллимнәреннән генә сабак алмый, грек каһиннарыннан сабак ала, грек философларының мәктәпләрендә укый. Егерме алты яшендә Римгә килә һәм биредә император Нерон артисты Алигәр аша Неронның хатыны Поппей белән таныша. Нәкъ менә Поппей ярдәме белән Йосыф Флавий яһүд равваларын үлемнән коткарып кала. Башта ул римләннәр яклы булган фирка әһеле булып йөри, соңыннан азатлык өчен көрәшкән яһүдләрнең сәргаскәре булып китә. Тиз арада үзенә 10000 гаскәри җыя, аларны коралландыра. Башкаласы итеп алган Иопатан һәм Тиверанд, Гамали, Вирасай, Тарихәй һ.б. калаларны кулына төшерә. Бу хәлне ишетеп, Рим империясе аңа каршы сугышларда җиңүләрдән җиңүләргә барган полковник Веспасианны җибәрә. Көчле кагортлар, җиңелүне белмәгән легионерлары белән Веспасиан тиз арада Йосыф яулаган һәм ныгыткан калаларны үз кулына төшерә. Йосыф үз кешеләре белән Иотапат кальгасына кереп бикләнә. Вәләкин бик күп югалтулар аша булса да исән кала: кырык иптәше белән кирмән эчендәге тау куышына чигенә. Кальганы кулга төшергән Веспасиан Йосыф качкан тау куышына илчеләрен җибәрә: «Бирел, бирелгән хәлдә мин сезнең барыгызны да исән калдырачакмын»,— ди. Әмма Йосыф бирелик дисә дә, иптәшләре: «Без азатлык өчен нинди югалтуларга дучар ителдек, шәһит киткән ишләребез күзенә ничек күренербез»,— дип, Йосыфка каршы төшәләр. Шунда хәйләкәр Йосыф ишләренә болай ди: «Инде шәһит киткән ишләребезгә корбан булырга теләмибез икән, һәр икебез җирәбә тотышып, кем баш чыга, ишен үтерсен»,— дигән тәкъдим ясый. Үлемгә дучар ителгән ишләре, дошман кулыннан үлгәнче, үз ишем кулыннан шәһит китеп, оҗмахка керим, дип, бер-берсен үтерәләр. Исән каладыр Йосыф белән аның бер иптәше генә. Шунда Йосыф аңа тәкъдим ясый: «Бирелик, бер-беребезне үтерсәк, дошман кинәнер генә, бирелсәк, исән калсак, без римләннәргә каршы тагын көрәшербез һәм халкыбыз алдында йөзебез ак булыр»,— ди. Иптәше килешә. Һәм алар, кулга-кул тотышып, чатыр корып, яһүдләрнең храмы мәйданы алдында утырган Веспасиан янына керәләр. Керә-керүгә, чатыр түрендә җәелеп утырган Веспасианга Йосыф болай ди: «Тагын ике айдан син император буласың, синнән соң империя тәхетен улың Тит биләячәк...» Җиңүче буларак, полковник Веспасиан аның бу күрәзәлегенә ышанмый, шаркылдап көлә генә. Әмма Йосыф күрәзәчене җәзаларга бирми, ике ай буена бу яһүдне күз карасы кебек саклагыз, дип, легионерларына тапшыра. Ни хикмәт, ике айдан чынлап та император Нерон үтерелә, һәм җиңүләрдән җиңүләргә барган Веспасианны сенат Римгә дәшә, һәм аны император итеп күтәрәләр. Римгә кайтып киткәндә, ул Йосыфны улы Титка биреп калдыра. Әтисе, сенат тарафыннан расланып, Рим тәхетенә утыргач, Тит яһүдләрнең барлык изге китапларын Йосыфка кайтарып бирә һәм, әсир ителгән булсалар да, храмга кереп бикләнгән 190 равваны азат итә. Әнә шунда Йосыф Титның фамилиясен ала, Тит аны Римгә алып кайта, хәтта атасы сараена сәркатип итеп куя һәм аны дәрәҗәле Рим гражданины итә. Үзенең соңгы елларына кадәр Йосыф Флавий император сараенда хезмәт итә һәм шунда яһүдләр тарихын язарга керешә. Йосыф Флавийның төп максаты элегрәк яһүдләр тарихын язган һәм хакыйкатьтән ерак йөргән Юста Тижериадка каршы чыгу була. Чөнки Римгә килеп урнашкан бу кеше Йосыф Флавийны Рим империясенә каршы чыгасың, дип гаепли. Йосыф Флавий, хакыйкый тарихны язып, яһүдләр турында римләннәр язган әкият-легендаларны юкка чыгарырга тели һәм нindидер күләмдә моңа ирешә дә. Тик нигә яһүдләр халкын һәр империяләр дә эзәрлеклиләр һәм хәтта илләреннән куугa кадәр барып җитәләр соң?! Менә моны аңлый да, аңламый да иде өлкән равва Ибраһим.

Килә бер чор, Бөек Рим империясе таркала башлый, һәм кочагына христианнар хәрәкәтен алган Константин, үз дошманы Лицинийны юк итеп, башкаласын Византия төбәгенә күчерә һәм шуннан торып империя белән идарә итә башлый. Ләкин Йосыф Флавий язган яһүдләр тарихы бу императорның да өстәлендә ята. Чөнки христиан дине шул тарафлардагы Галиләйдән килгән була, һәм күп кенә вакыйгалар яһүдләр тарихыннан алына. Йосыф Флавий китабында: «Империяләр мәңгегә килми, ә халык мәңгелек, чөнки аны Ходай яраткан»,— дигән сүзләр дә була. Яһүдстан римләннәр заманыннан ук таратылырга дучар ителә. Гарәпләр дә Исраил балаларын читләтеп үтмиләр. Яхва аллаһыларына тугры калган, рәнҗетелгән яһүдләр Иранга юнәләләр, вәләкин әүвәл яһүд халкын фарсы аксөякләре колач җәеп каршы алсалар да, еллар үтә-үтә, яһүдләрдә нindидер мәкер күреп, аларны илләреннән куалар. Җитмәсә, Византия императоры, бигрәк тә пасха көннәрендә, яһүдләрне эзәрлекли башлый, борынгы яһүд

диненә тугры калып, ит ашамаган яһүдләрнең авызларына кургашын койдырта һәм күбесен хәтта чукынырга мәҗбүр итә. Чарасыз калган яһүдләр янә дөнья буйлап сәфәр чыгалар һәм, ниһаять, Хазар-стан төркиләренә килеп елышалар. Ә Хазарстан төркиләре аларны араларына алу өчен табын җыялар һәм табында: «Нишлибез, алабызмы илебезгә бу илдән илгә куылган халыкны, юкмы, аксакаллар?» — дигән мәсьәләне күтәрәләр. Кахан дәшми. Бу четерекле мәсьәләне аксакалларына хәл итәргә бирә. Шунда бер аксакал тора да: «Алыйк үз арабызга илдән илгә куылган бичараларны, чөнки яһүдләр китаплы халык»,— дигән фикер әйтә. Әнә шулай илләр буйлап каңгырып йөргән яһүдләр Хазарстан төркиләре тарафыннан кардәшләре кебек кабул ителәләр.

Өлкән равва кәнәфиендә борсаланып куйды һәм ишек сакчысына:

— Миңа Рәшидә абыстайны дәш,— дип, урыныннан торып йөреп килде.

Ни өчен Иран шаһиншаһы иленнән куа соң әле яһүдләрне?..

Әйе, үтә үткен яһүд раввалары яһүдләрнең чибәр һәм күп телдә сөйләшә алган кызларын шаһиншаһ сараена уздыралар. Шаһиншаһ аларны бик теләп кабул итә, хәтта берничәсенә өйләнә дә. Ә яһүдәләрдән туган балаларны раввалар үзләре укыталар. Белемле яһүд егетләре шаһиншаһ сараена үтеп керәләр, вәзирләрен алыштырыр дәрәҗәгә җитеп, шаһиншаһка якынлашалар. Вәләкин кайсыдыр шаһиншаһ, яһүдләр дине сарайга үтеп керә башлагач, курка кала һәм аларны сарайдан гына түгел, илдән куарга әмер бирә. Ә менә Хазарстан төркиләре аларны кабул итәләр. Ул гынамы, төркиләрнең бәкләре, төмәнбашлары, хәтта ханнары яһүдләрнең гүзәл кызларына өйләнәләр, ә тегеләр үзләре тапкан балаларны Мишә кануннарына һәм Талмутка таянып, сарай мәдрәсәсендә тәрбиялиләр. Кахан сарае яһүд кызлары белән тула. Кахан шул чиккә җитеп байый ки, Идел уртасындагы утрауга Аккала күтәртә. Сарай кальга-дивар белән уратып алына, зур кала — Ханбалыкка чыгу өчен күпер салына. Әнә шулай яһүдләр Хазарстанны үз кулларына ала башлыйлар. Моны да яхшы белә иде өлкән равва Ибраһим. Тик нигәдер күңелендә ниндидер канәгатьсезлек туа башлады. Хәзер генә түгел, бу хәл аның белән элек тә булгалады, ләкин болай ук шомга калдырмаган иде әле. Чөнки Йосыф балакай юлдан язды, ә моның төп сәбәбен өлкән равва Айбиби хатыннан күрә башлады. Ә бит төркиләрне һич кенә дә кысрыклау булмады. Аларның мөселманы да, мәҗүсие дә үз диннәрендә калдылар. Империядән качып, төркиләр арасына килгән христианны да кысмадылар яһүдләр, гәрчә Византия императорлары яһүдләрне илләреннән кусалар да. Әйе, әнә шулай уйлана-уйлана, өлкән равва әле бөтен хатаны Айбиби хатынга такты, әле үз җирләрен кулларында тота алмаган, үзара ызгышып, илләрен вә җирләрен югалткан бабаларын орышты. Ләкин бит тарих раслый, бабалары үз җирләрен, үз илләрен кан коймый гына дошманга бирмәгәннәр, ил-калаларын, храмнарын сакларга тырышканнар. Әйе, күп кырганнар яһүд халкын римләннәр, ләкин ошбу куәткә ия империя Яһүдстан җирендә ятып калган кан кардәшләренең — легионерларының санын үз тарихларында күрсәтмиләр, ә менә ил-ватаннарын саклаганда шәһит киткән яһүдләрне бермә-бер диярлек артык күрсәтәләр. Рим империясенең коллар чоры бик тә аяныч бетә: менә бүген яһүдләр идарә иткән Хазарстан төркиләре каһарманы Аттила хан Рим капкасына кадәр барып җитә. Һәм Римне тез чүктерә. Рим императоры Валентиан яубаш баһадир каршына чыгарга курка, үзенең рухание папа Левка 21 пот алтын биреп чыгара. Мескен папа каһарман баһадир алдына килеп тезләнә, каланы җимермә, алып кит бар байлыгыбызны, дип ялвара. Аттила хан каланы җимерми, кире борыла. Әмма ялган тарих язучы Рим куштаннары үз тарихларын «Аллаһы кылычын йөрткән Аттила күктәге кылыч тоткан Ходадан курыкты да кире иленә таба борылды» дип язып куялар. Моны да яхшы белә иде өлкән равва Ибраһим. Ә бит әнә шул бөек халык, Рим империясен коллыктан азат итеп кайткан төркиләр, гәрчә Аурупа тарихчылары аларны гуннар дип атасалар да, яһүдләрне үзләре арасына алдылар. «Бәлкем, мин ялгышамдыр, Йосыф балакай дөрес эшләгәндер. Бит Хазарстанның төп терәге — төрки бәкләре һәм ханнары, бер дә мәҗүси Сарманай кахан түгел. Җитмәсә, кахан ел саен юлбасарлык кыла, Хазарстан канаты астына кергән халыкларыннан рөхсәтсез ясак җыя...»

Ишек шакыдылар, нишләптер өлкән равва сискәнеп китте, чөнки уйга чумып утыра иде.

— Керегез, кер,— диде ул һәм торып басты.

Рәшидә абыстай керде, яулык очы белән авызын каплады, әйтерсең авызыннан артык сүз чыгып китәрдән курка иде.

Өлкән равва кул ишарәсе белән аңа кечкенә өстәл янына узарга дәште. Кечкенә өстәлдә Коръән Шәриф ята, өлкән равваның кулында Талмуд күреп, абыстай каплаган авызын ачып:

— Өлкән равва Коръән Шәриф укый,— диде.

— Һәр изге китап — белем чишмәсе,— диде өлкән равва, өстәл янына килеп, кечкенә урындыкка утырды, абыстайга урын күрсәтте. Өлкән равва кулындагы китапны Коръән Шәриф белән янәшә өстәлгә куйды һәм абыстайның күзләренә карады. Айбиби хатынныкы кебек абыстайның да күзләре зәңгәр иде.

— Сезне минем кырга Айбиби хатын җибәрде, шулаймы, Рәшидә абыстай?

— Юк, Ибраһим, сезнең кырга мин үзем килдем. Йомыш бар сезгә.

— Имам хәзрәтләре җибәрдеме, аның йөген үтисезме, абыстай?

— Юк, мине сезнең янга кем дә җибәрмәде, өлкән равва Ибраһим, мин үзем килдем, үзем...

Өлкән раввага исеме белән бик сирәк кешеләр дәшәләр иде, хатын-кыз авызыннан үз исемен ишеткәч, өлкән равва уңайсызлана калды, дорфарак сораулар биргәнгә үкенү тойды. Ул янә каршында утырган абыстайның күзләренә карады һәм кинәт әллә нишләп китте. Кемгә булса ошаттымы, күңеле шулай якын иттеме абыстайны, аңламады. Тик абыстайның итагатьле итеп елмаюы, серле итеп күзләренә каравы йөрәгенә оялаган иде инде. Ул моны җаны-тәне белән тойды.

— Талмуд бик матур күн белән тышланган, болгари күн. Бисмиллаһир-рахман ир-рахим,— дип, Рәшидә абыстай Талмудны кулына алды, күпертек иреннәре белән үпкәндәй итте, күкрәгенә кысты. Шуннан соң гына: «Илаһым, аермасаң иде ил бәндәсен дүрт китаптан: бере —Инҗил, бере — Тәүрат, бере — Зәбүр, бере — Коръәннән»,— дип, китапны кире өстәлгә куйды.

Ибраһим равва, ни әйтергә белми, бер мәлгә югалып калды. Чынын гына әйткәндә, абыстайдан ул моны көтмәгән иде. Ничекләр итеп елмая, үз итеп елмая, ә бит менә шул елмаюны ул бу хатыннан беренче очрашуда ук күрергә теләгән иде. Сүз дә юк, Рәшидә абыстай Рим матренасы түгел, кочагыңа кереп ояларга тормас, вәләкин үзе үк синең бүлмәңә килеп кергән икән, моның бер-бер сәбәбе булырга тиештер бит инде?.. Тик нинди сәбәп? Менә шуны беләсе килә иде аның Идел буйларында үскән, әле хатын-кыз тәмен вә гүзәллеген югалтмаган абыстайдан.

— Сез әйткән һәр китап дүртесе дә Аллаһы җимешләредер, абыстай.

— Сез хаклы, Ибраһим, һәр китап — ул тормыш агачы, бар халык эчендә яшәү мәгънәсе, дөньялыкта яшәү мәгънәсе. Әнә шул китаплардагы мәгънәләрне аңлап яшәүчеләр бар, аңламаучылар бар. Безләрне мин аңлаучыларга кертәм, Ибраһим.

Бу ни инде тагын, нигә Ибраһим моңа кадәр булмаган каушау тоя. Ни дә булса әйтергә тиештер бит инде.

— Кахан яуда, без монда, абыстай. Ил мәшәкатен өстемә аударып китте илбашыбыз. Хатыннарын илләренә озатырга әмер-фәрман биреп киткән каханыбыз.

— Бу хакта Айбиби белән киңәште микән соң кахан, Ибраһим?

«Менә абыстай белән исемнәребез атап кына сөйләшә башладык. Хәерле булсын»,— дип уйлады өлкән равва.

Өлкән равва Ибраһим, Харәземгә барып, ислам динен кабул итеп кайтса да, күңеле вә йөрәге һәм җаны-тәне белән Яхвасына тугры кала бирә иде. Ул бу мәсьәләгә фәлсәфи яктан килде. Ислам дине дә шул ук Тәңре һәм Яхва кебек илаһлар утырткан изге агач җимешләре. Тик бу ике динне бабаларыбыз берләштерә генә алмаганнар. Ә менә Аллаһы илчесе пәйгамбәр Мөхәммәд галәйһисәлам, Аллаһы иңдергән вәгазьләргә таянып, үзенә бер юл сайлый. Бик ихтимал, аңа чынлап та Аллаһы үзе изге китапларның берсе — Коръән Шәрифне ирештергәндер. Ни генә булмасын, төркиләр белән яһүдләр Хазарстан җирендә бер халык булып оешып киткәннәр икән, монда Аллаһының да теләге булмагандыр, дип әйтергә кем кыяр?!

Өлкән равва Ибраһим каршында утырган абыстайга янә бер тапкыр игътибар белән карап алды. Абыстай тоташ актан киенгән иде, күлмәгенең бала итәкләренә генә зәңгәрсу тасма бәргән, һәм башындагы яулыгы да шул тасма төсендә. Моның өстенә абыстайның зәңгәр күзләре килеп кушыла. Идел буе төрки-болгар хатын-кызлары киемне дә сайлый беләләр иде. Болын күрке чәчкә булса, хатын-кыз күрке — кием ич. Болар, кара гарәп хатын-кызлары кебек, бер дә тоташ карадан киенеп, бит-башларын пәрәнҗәгә томалап йөрмиләр. Ә бит гарәп хатыннары да шул ук мөслимәләр, шул ук җир йөзендә яшиләр. Димәк, гарәпләр хатын-кызны бераз кимсетсәләр дә, төрки болгарлары моңа бармаганнар һәм моны бер дә гөнаһка санамыйлар. Һәрхәлдә, каршында утырган хатын бер дә кара гарәп хатынына охшамаган иде. Шушы уйлардан соң Ибраһим ошбу хатын йөзендә моңа кадәр күзенә чалынмаган, чалынып та күңел игътибарыннан читтә кала биргән назлылык галәмәте күрде. Абыстайда бар хатын-кыздагы кебек күркәмлек, мөлаемлык, итагатьлелек күзгә чалына, шул ук вакытта нәзбереклек тә бар. Ә бит нәзбереклекне Ходай Тәгалә бар хатын-кызга да тулы килеш бирмәгән. Биргән булса, бар хатын-кыз да ил гүзәле булыр иде. Кемдер аңа әйткән иде: «Кыз бала ана кулындагы камыр ул, сабый чакта ана кеше үз баласын ничек әвәли, үскәч тә, ул баладан ана биргән гүзәллек китми». Айбиби хатынны Рәшидә абыстай әвәләп үстергән, үзенә охшатып, үз холкын, үз кыланышларын, үз мөлаемлылыгын да...

Өлкән равваның бүлмәсенә моңа кадәр бер генә хатын-кызның да аяк басканы юк иде. Рәшидә абыстай, беренчеләрдән булып, бусагасын атлап керде.

— Китап уку — зур бәхет ул, Ибраһим, зур бәхет,— дип кузгалгандай итеп куйды Рәшидә абыстай.

Шунда өлкән раввага кисәктән курку килде. Китә ич! Җибәрмә!

Аның башына шаулап кан саугандай булды. Ул янә бер тапкыр Рәшидә абыстайга назга тансыклаган ирләр күзлегеннән карады. Карады һәм үз-үзенә таң калды. Күзе төште бит аның абыстайга! Йоклап яткан ирлек гайрәтен уятты бу абыстай. Аның яшендә бик сирәк була торган хәл бу! Менә кайчан Йосыф балакайның хәленә керде өлкән равва. Кырык хатыны була торып, бер хатынга ябышып калуын аңлады. Чынлап та, баштагы мәлдә Йосыф балакайның Айбиби хатын тирәсендә дивана хәленә килеп гашыйк булып йөрүен бөтенләй аңламады ул, аңларга да теләмәде. Һәм хәзер, бүген, менә шул мәлдә, дивана хәленә төшеп булмаса да, аның күңеленә дә тымызык бер мәхәббәт хисе кисәк өермәгә әверелеп

килеп тулды. Айбиби хатын Йосыф каханны сихерләде, дигән фикер белән килешер-килешмәс аптырап та йөргән иде ул. Хәзер әнә шушындый ук сихер кармагына үзе эләгә түгелме?.. Кахан Айбиби хатыннан башкаларны күрергә дә теләмәде. Йә, дигәндә, тә, дип, өлкән раввага табынып торган Йосыф балакай, Айбиби килгәч, тәмам үзгәрде дә куйды. Авыр кичерде Ибраһим равва каханның бу мавыгуын, үтә авыр кичерде. Башта, татлы айлары узгач, онытыр, дип өмет итте, көтте, сабыр итте. Тик бер ябышкан купмый икән шул, Йосыф кахан, бар хатыннарыннан да баш тартып, ятагына һәрчак Айбибине тарттыра башлагач, тәмам аптырашта калган иде. Инде үзе менә шул хәлгә калып утыра түгелме?! Әйе, каршында утырган абыстай да ул кичергән тойгыларны кичереп утырса?.. Илбашының рухани атасы ич ул, ерак бабаларын Бөек Кир азат иткәч, Ярми, күрәзә кебек, ничек үз халкының динен, телен саклап калырга борчылып яшәгән рухани. Аның улы Язикәй анда күккә омтылган туксан метрлы манараны да, асылынып торган оҗмах бакчасын да, елга суы кебек кешеләр һәм кәрваннар агып торган Иштар капкасын да күргәндер. Йөз меңнәрдән арткан кала халкы — бавилләр, халдиләр, ассирәйләр, иләмәтләр, гарәпләр, финикәйләр, яһүдләр һәм греклар арасында яшәп, Ефрат аша салынган күпер аша чыкканда, үз халкын шушы дөнья ташкынына әверелгән халык арасында эреп, юкка чыгар дип курыккандыр. Баштагы мәлдә Ибраһим равва да Ханбалыкта шулай дип куркып яшәгән иде. Хәзер, шөкер кыла, ул яһүдләрне аерды: аерым Ай-балда каласында көн күрәләр, ләкин төрки тел үтемлерәк, яһүдләргә якынрак булдымы, яһүд халкы, төрки телдә сөйләшә башласа да, динен онытмады, ташламады, күңеле белән Яхвага тугры калды. Инде әсирлектәге яһүдләр өстендә «Аллаһы кылычы» булып эленеп торган фарсыларның Мардүк алласы да һәм бавилләрнең патшалары да гасырлар туфрагы астында калды. Ә бит үз заманында, шушы шәһәрдәге кебек анда да үзенең көче-куәте, мәһабәтлеге, күзне камаштырырлык җемелдәве белән дөнья халыкларын шаккатырган каласы да яһүдләрне йота. Ләкин аларның күбесе ерак Синай тауларын онытмыйлар, илләрен фиргавеннәр җимергәч тә, күңелләре белән Исраилгә тартылалар. Ярми улы Язикәй бердәнбер көнне төш күрә һәм Яхва алласы аңа әйтә: «... мин сезне, илегездән ераклаштырып, дөнья илләре буенча таратсам да, сезгә мин кече гыйбадәтханәгез булып торырмын һәм сезгә бердәм йөрәк бирермен, ә таш булып каткан йөрәгегезне алырмын, һәм җан иңдергән йөрәк бирермен, әмма ул йөрәк минем сезгә иңдергән җан булыр. Мин сезнең Аллаһыгыз булырмын». 588 елда (б.э.к.) Мисыр тәхетенә фиргавен Хофра утыра. Бөек фиргавен Нохоның улы: «Яһүдләр, әсирлектә яшәгәндә дә, үз аллаларына тугры калдылар»,— дип, ташка суктырып калдыра.

Бу уйлану иде. Бу — тарихка төшеп, бабалары кылган хаталарны кабатламас өчен чара эзләү иде. Рәшидә абыстай, аны оныткандай, изге китапларны актарып, укып утыра. Ә Ибраһим равва тарихка кереп чумды, уе-хисе, акылы-зиһене белән хәтерендә калган бабаларының тарих сәхифәләрен актарды.

Шунда көтмәгәндә Рәшидә абыстай бер китаптан мондый юлларны укый башлады. «Руфиянең ире Яһүд көтмәгәндә вафат була. Тол калган яшь хатын Яхүднең атасы кырында калыргамы, китәргәме, дип уйланып утыра. Әтисе аңа әйтә: «Инде нишлисең, килен?» Килене атасына әйтә: «Кая син китәсең — мин шунда барам, кая син туктыйсың, кая яшисең, һәм мин шунда яшәрмен. Синең халкың — минем халкым, синең Аллаң — минем Аллам, кая син үләсең, мин шунда үләрмен, кая сине күмәләр, мин шунда синең каберенә кереп ятармын. Аллаң мине кабул итсен һәм догасын бирсен, үлем генә аерса аерыр синнән мине»,— ди. Аллаһы изге җанны кабул итә — Вафлимәдә Руфия үз иренең туганы Ваузәгә кияүгә чыга, ә аның оныгының оныгы Давыт яһүдләрнең иң куәтле патшалары була».

Өлкән равва Ибраһим тәмам өнсез калды, ул моны Рәшидә абыстайдан һич тә көтмәгән иде. Ул торды да Рәшидә абыстай каршына тезләнде, башын аның тезләренә салды. Абыстай дәшми һәм ул да. Әллә соң йөрәкләре сөйләшәме?.. Әгәр абыстай да ул кичергән тойгыларны кичерсә?.. Ул нишләргә тиеш, илбашы киңәшчесе һәм рухани?..

Көрсенеп куйды бугай, ни өчен икәнлеген үзе дә аңламый калды. Рәшидә абыстай аның башына кулын куйды һәм:

— Борчылмагыз, бер дә борчылмагыз, Ибраһим равва. Йосыф кияү әмирнең имамнарын сараеңа уздырган икән, ул бер дә гөнаһ кылмаган, бу гамәле белән ил-халкын гына түгел, аркадашларын да саклап калды. Бездә: «Бер тиредән тун тегеп булмаса да, бер хатын белән дә гомер итеп була»,— диләр, Ибраһим. Хак, Аллаһыбыз фатихасы белән шактый хатыннар тотканнар. Сөләйман пәйгамбәр дә күп хатынлыкны хуп күргән, ләкин ул бит моңа чарасызлыктан барган. Халкы дөнья халыклары арасында эреп бетүдән курыккан.

Өлкән равва башын күтәрде, Рәшидә абыстайның күзләренә карады.

— Борынгы акыл ияләре, киләчәкне гүзәллек коткарачак, дигәннәр, әллә соң чынлап та шулаймы, абыстаем? Айбиби хатын аккошлар ярата. Бер ялгыз калган аккош та аның яныннан китми...

— Аккошлар — оҗмах кошлары, аларны яратмый мөмкин түгел, Ибраһим.

— Кешелекне, бик ихтимал, чынлап та гүзәллек коткарыр, тик империяләрне түгел, Рәшидә абыстай. Империяләр башта ил-халыкларны яулыйлар, аннары ирек дауларга керешкән үзләре яулаган халыклар белән пычакка пычак килеп орышалар. Ә без, Аллаһыбыз каргаган халык, алар арасында тулганабыз.

— Һәр халыкка да Аллаһы Тәгалә җир-ил бүлеп биргән, Ибраһим, бары тик Аллаһы бүлеп биргән җирдә яшәсә генә, теге йә бу халык бәхетле була, дигәннәр борынгылар да. Безнең бабаларыбыз илдән-илгә мул үләнле тугай-болыннар, елга буйларын сайлап ил-җирләр гизсәләр, сез, китаплы халык буларак, һаман үз динегезгә тугры калуыгызны дәвам итәсез. Ә бит диннәрнең төп максаты — һәр халыкка Җир-Ана, Аллаһы бүлеп биргән Җир-Ана. Сез, яһүдләр, үз Җир-Анагызны Хазарстанда таптыгыз. Безнең халык сезне якты йөз белән каршы алды, үз арасына кабул итте. Хуш итегез, моның өчен Аллаһыга, рәхмәт укый-укый, дога кылыгыз да Ходай Тәгалә биргән дөньялыктагы гомерегезнең рәхәтен күрегез. Берәүнең дә ике туып, ике тапкыр яшәгәне юк, Ибраһим равва.

— Без һәр канатыбыз астына кергән халыкка йомшак итеп ясак салдык. Ә кайберләре талау белән мавыгалар,— диде Ибраһим равва.

— Кахан кул астындагы халыкларны талаган шаман Хельг турында әйтәсезме, раввам? Юлбасар булган бит ул, хәтерем ялгышмаса, аны үз вакытында бик белеп иленнән куалар. Калган гомерен зимагурлыкта, илләр талауда уздырып, шаман Хельг каберен Идел буе Болгарында таба, кадерсез рәвештә утырып килгән көймәсенә куеп яндырыла, җирдә үк үз тәмугын таба ул зат, раввам! Җирдә үк! Бүгенге Сарманай да баскынчы булып чыкты. Каханыбыз шул кешене акылга утыртырга чыгып китте түгелме соң, раввам?!

— Йосыф кахан аңа карата фәрман чыгарды инде — юк итәргә!

— Гадел фәрман, гадел фәрман, раввам.

— Миңа Харәзем әмире җибәргән имамнар ошамый, абыстай.

— Килешми ил руханиена чарасыз калу, раввам, килешми. Башы яшь булса да, Йосыф кияү үз халкына бер дә хилафлык кылмады кебек, раввам? Сезгә Харәзем имамнары белән кулга-кул тотынышып эшләргә кирәк, раввам. Заманында кемнәр Лачын каханны юк иттеләр, шул ук башкисәр варяглар түгелме?..

— Юк, хаталанмагыз, абыстай,— диде өлкән равва һәм Рәшидә абыстайның кулыннан алып, тахтасына китереп утыртты, ә үзе янәшәсенә кунды.— Греклар Игорь дип атаган, варяглар үзләре Ингвар, без Лачын дип йөргән каханны германлылар үтерәләр. Германлылар кенәзе Мал белән ата варяг Свенельд улы Людь.

Өлкән равва бәхәсләрдә һәрчак җиңеп чыкты. Булан кахан чорында үз сараена равваларны, имамнарны, христиан руханиларын дәштерә кахан. Диннәрдәге хакыйкатьне эзли. Әнә шул бәхәстә яһүд раввасы җиңеп чыга, хак, христиан рухание шундук җиңелә, ә имамны яһүд сәүдәгәрләре сатып алганнар, дип язалар. Ләкин бу хәлне үз күзе белән күрмәгәнгәме, өлкән равва моңа ышанмады. Тик бит шушы бәхәстән соң Византия императоры яһүдләрне генә түгел, үзенең христианнарын да пасха бәйрәмен уздырудан тыя. Хак, хәйләкәр император пасха бәйрәмен шимбә көненә туры килгәндә генә тыя. Ә инде 723 елда Византия императоры Лев III Исавр үз илендәге яһүдләрне көчләп чукындыра башлый, моның өстенә үзенә хезмәт иткән яһүдләргә гарәпләр белән безгә каршы шымчылык итәсез, дип гаеп тага. Нәтиҗәдә Византиядә тукталган яһүдләр янә бер сабырлык күрсәткән төркиләргә таба кузгалалар. Ә Хазар каханы, диннәрне тыймый гына түгел, аларга калаларында синагогалар салырга, гыйбадәт кылырга рөхсәт итә. Гарәп сәяхәтчесе бу хакта: «Хазарстан каханы гадел патша була»,— дип язып калдыра. Хазарстанга күчеп килгән яһүдләр, күп тә үтми, Ефәк юлын үз кулларына төшерәләр, тарихчылар теленә Итил дип кереп киткән Аккала-Ханбалык дөнья халыкларының сәүдә үзәгенә әверелә.

Рәшидә абыстай әкрен генә кузгала башлады. Шунда өлкән равва аның биленә кулын салды, һәм абыстай һуштан язган сыман «аһ» итте дә тахтага сузылып ятты. Өлкән равва ни кылырга белми аптырый калды. Әмма абыстай әкрен генә күзләрен ачты һәм:

— Курыктым мин синнән, Ибраһим,— диде.

— Әллә табибым чакыртыйммы, абыстай?

— Табибың! — диде гаҗәпләнеп абыстай.— Табибың, раввам!

— Мин хатын-кыз лабаса, раввам, хатын-кыз!

— Сез миңа ошадыгыз, абыстай, ошадыгыз. Ләкин мин... яһүд, ә сез, абыстай, мөслимә. Гәрчә мин сезне яратсам да...

— Без фикердәшләр булып кына калыйк, раввам, фикердәшләр.

— Юк инде, абыстай, йә сез минем гомер юлдашым, йә бер елга суын эчеп яши торган ике зат булып калыйк.

— Тик бит, раввам, без елганың икебез ике ярында басып торабыз икән ич, шәйләми торам тагын.

— Мин сезне бүген җибәрмим, абыстай, җибәрмим...

Рәшидә абыстай бүлмәне күздән кичерде, ниндидер бер уфтану белән көрсенеп куйды.

— Гөнаһлы булабыз бит, раввам, гөнаһлы... Ярый, раввам, син мине үзең килеп алырсың,— диде дә, торып, ишеккә таба юнәлде.

Егет чактагы җитезлек белән равва Ибраһим аның каршына төште.

— Өстәл дә хәстәрләтимме, абыстаем?

— Өстәлдә бал, ятакта хатын-кыз булганда, йокы да татлы була, раввам,— диде абыстай һәм равваның яңагына кагылып алды. Кырык яшен тутырып узган хатын кулыннан хуш исләр килде, равва, аның кулын эләктереп, кул аркасын үпкәнен сизми дә калды.

**XI**

Ул белә иде: Ибраһим пәйгамбәр яһүдләргә Яхвадан Җир-Ананы Исраил төбәгеннән сорап ала. Бу буладыр безнең эрага кадәр 2800 еллар элек. Ибраһим пәйгамбәр үз халкын Ханнанга алып китә һәм Иисус Навин ярдәмендә Фәләстыйнны яулый. Әнә шулай Иисус Навин Ибраһим пәйгамбәр ярдәмендә яһүд халкын саклап кала. Дөнья халкы өч меңенче елга аяк басарга торганда һәм моңа кадәр узган гасырлар дәверендә Рим империясе яһүдләр халкын Җир шары буйлап тарата. Әйе, Рим империясе Исраил балаларын бөтен дөньяга вак ташлар кебек сипте. Кем җыяр ул ташларны?.. Кем керешер шул изге гамәлгә?.. Әлбәттә, раввалар. Хазарстанның өлкән раввасы булу белән бергә, Ибраһим сарай мәдрәсәсендә яһүдә хатыннардан туган балаларга сабак укытты. Иң әүвәл ул Исраил балаларына «Тора» сүзен аңлатты, ягъни Тәүрат сүзен. Тәүрат ул — үгет-нәсыйхәт, киңәш-сабак вә күрсәтмә дигән мәгънәне аңлата. Тәүратны кем язганны берәү дә белми. Әмма яһүд халкы бу изге китапның юлларын меңнәрчә еллар буена атадан балага күчерә бара. Тәүрат әле дә һәр яһүд кешесе өчен иң изге китапларның берсе булып кала бирә. Ибраһим пәйгамбәрдән Давыт пәйгамбәргә кадәр ундүртенче буында яһүдләр җире бавилләр тарафыннан яулана. Барча халык әсир ителеп, безнең эрага кадәр 598 елда бавилләр патшасы Нәбүхәдәнәсәр II Иерусалимны ала, яһүдләр патшасы Иохинәйне әсир итә, каланы җимерә. Бик күп халыкларны, әсир итеп, үз иленә алып китә. Яһүдләр патша рөхсәте белән бирედә синагога төзиләр. Хәтта шул хәлдә дә Яхва аларны коткара. Безнең эрага кадәр 539 елда бавилләрне фарсы шаһиншаһы Кир II яулый, һәм, яһүд халкын азат итеп, илләренә китәргә рөхсәт итә. Яһүдләр исә: «Безне Бөек Кир түгел, раввабыз коткарды»,— дип, изге китапларына язып куялар. Тик нигә Яхвалары аларны бавилләргә әсир итәргә бирде икән?! Менә шуны аңламады өлкән равва.

Иртәнге аштан соң өлкән равва Ибраһим елга ягындагы бакчага чыкты. Башында һаман шул бер уй бөтерелде. Зәңгәр күккә карады: очы-кырые булмаган җиһанда кояштан башка берни дә юк иде. Бары тик офык читендә генә болытлар куерып килә. «Сөенче» китабында мондый юллар бар: «Дөньядагы мин бар иткән барча тереклек тә, үз халкының нәселен саклау өчен, кулыннан килгәнен барысын да кылырга тиеш. Мин барча адәми затларга да, кош-кортларга да, җәнлек-хайваннарга да саклану кораларын бирдем: керпегә — чәнечкеләр, бүрегә — үткен тешләр, кешегә — акыл. Ләкин ошбу дөньяда һәр тереклек иясе үз кануны белән яши, әмма әкәм-төкәмне ат басып китә, керпене хәйләкәр төлке суга ташлап ашый, бүрене юлбарыс ботарлый, ә кешегә Аллаһы акыл бирә». Әнә шул акыл иясе, дәверләр үтә-үтә, бер-берсен кыру өчен, камилдән-камил корал җитештерә, үз-үзенә дошман таба һәм камил корал вә акыл аша теге йә бу халыкны яулый һәм кул астына ала, аңа телен, динен, гореф-гадәтләрен тага башлый. Заманында Византия Хазарстанга грек уты белән янады. Әмма төркиләрнең атлы гаскәре Византия белән көрәшкә чыкты. Әнә шулай куәтле империя белән Хазарстанга тыныч-имин яшәргә мөмкинлек туды. Тик озак дәвам итәрме бу хәл?.. Хазарстан ялланган гаскәриләр аша үз илен һәм халкын саклый. Ялланган гаскәриләр дәүләткә бик кыйммәткә төшә. Моны да яхшы белә иде өлкән равва Ибраһим. Нигә батыр яһүдләр үз илләрен саклый алмадылар икән?.. Кем гаепле моңа?.. Гайсә пәйгамбәрме?! Юк, тагын бер тапкыр юк. Ул, бичара, бары тик тынычлык теләп, үз үлеме аша халыкка тынычлык китерә. Тик аның үлеме генә халыкка тынычлык китерми. Дөнья халыклары үзара сугышулардан туктый алмый интегәләр. Төркиләр баһадиры колбиләүчелеккә дә чик куйды. Әмма дөньяда орыш-сугышлар һаман туктамый. Җитмәсә, өлкән равва үзе үк, мөселманнардан котылырга теләп, баскынчы викингларны үз иленә дәште. Бөек Римгә халык каргышы аша Аллаһы каһәре төшә. Бу империя инде сүтелеп, таралып килә. Әмма руханилар тарафыннан изгеләр санына кертелгән император Константин, көнчыгышта яһүд халкының Гайсәсен алып, христиан дине уйлап тапты һәм каһәр яуган империя оештырып җибәрде. Шушы каһәр төшкән империя тора-бара Исраил балаларының җирләрен дә кул астына алды. Бүген инде Исраил балаларына ул тарафларга барырга да ярамый башлады. Кайчан Хода яһүд халкын Аллаһы сайлаган җиргә кайтарыр да иректә рәвештә дөнья көтәргә мөмкинлек бирер?.. Бер Хода белсә беләдер моны. Әмма туган туфракны кайтып күрәсе килә. Килерме ул көн? Күрерме ул көнне Хазарстанда көн күргән өлкән равва Ибраһим?! Килер, өлкән равва Ибраһим моңа җаны-тәне белән ышана иде. Әйе, һәр яһүд кебек...

Хазарстандагы хезмәтен ул бик ерактан башлады. Башта адашы Ибраһим кул астында хезмәт итте. Ә инде ул олыгаеп, йөрмәс хәлгә килгәч, Хазарстан каханы Булан яшь Ибраһимны үз кырына алды. Тагын да гаҗәбрәге шул булды — аның хакында берәү дә кызыксынмады, гүя аны Яхвалары үз кырына алган иде. Яшь Ибраһим да бу хакта кемнән дә булса сорарга кыймады. Бары тик Хазарстан сәүдәгәрләре Ефәк юлын үз кулларына алгач кына, Ибраһимга адашы Исраил җиренә киткән дигән хәбәр ирешә. Соңгы елларда көчәеп киткән гарәп сәүдәгәрләре Ефәк юлын үз кулларына ала башладылар. Бу хәл өлкән равва Ибраһимны янә пошаманга салды. Җитмәсә, кара гарәпләр үз тарихларын яһүд раввалары-

на илтеп ялгадылар. Шаккатмалы хәл иде бу! Әрсез гарәпләр үз диннәрен Идел буенда көн күргән болгар төркиләренә китереп бәйләделәр һәм, иң гаҗәбе, тыныч рәвештә. Идел буе Болгары ханы Алмас, хәлифәнең юмакай сүзләренә алданып, ислам динен кабул итә. Әйе, хәйләкәр хәлифә аңа тау-тау алтын вәгъдә итә, имеш, минем дин аша син Хазар каханаты кул астыннан чыгачаксың. Бу хәбәр килепирешүгә, Идел буе төркиләрен кул асларында калдыру өчен, Хазарстан раввалары Алмас ханга ташламалар ясарга мәҗбүр булдылар. Алмас ханга хәлифәдән берни дә таммады. Ләкин гарәпләр барыбер оттылар, чөнки төрки болгарлары аша гарәпләр үз диннәре белән дала угызларына, ары таба кыпчакларга үтеп керделәр.

Хазарстан каханы Римнән, Ираннан, Византиядән куылган яһүдләрне китаплы халык дип кабул иткән иде. Әнә шул китаплы халык тора-бара Хазарстанның идарә түрәләрен, бәкләрен әкрен-әкрен генә үз кулларына алды һәм ил белән идарә итә башлады. Хазарстанга көчеп килгән раввaларның төп хыяллары көчле төрки халыклары белән туган җирләрен кулга төшерү иде. Әмма ул теләк-максат барып чыкмады, гарәпләр өлгеррәк булып чыктылар. Инде хәзер әрсез гарәпләр яһүдләрнең туган туфракларын гына түгел, куәтле төркиләрнең дә җирләренә кул суза башладылар. Чарасыз калган өлкән равва алардан котылу өчен яман викингларны чакырырга мәҗбүр булды. Бу яман юлга заманында Вениямин кахан да баса. Викинглар көче белән мөселман илләрен талата, гәрчә шушы яулардан меңләгән викинглардан унлабы гына исән-имин әйләнеп кайтсалар да. Аның каравы ясакчылары исәбенә керткән викинглар каханны алтынга күмәләр. Ләкин «җилдән килгән — җилгә китәр» дигән бит Хода. Вениямин кахан берни дә отмый. Менә хәзер Хазарстан янә шул юлга басарга әзерләнде. Ләкин ахыры ничек бетәр? Берәү дә белми иде, хәтта өлкән равва үзе дә.

Бик озак карап һәм уйга калып утырды өлкән равва хозур бакчада. Ахыр кахан чатыр кырына узды, киез җәйгән ташка утырды.

Хазарстан илен, нигездә, төркиләр саклыйлар иде. Өлкән равва төрки бәкләре белән беркайчан да бәхәскә кермәде. Аларга гүзәл яһүд кызларын кияүгә бирде, үз кешеләре итте. Үз туган туфракларыннан куылган яһүд халкы өчен, борынгы бабалары бавилләрдә тернәкләнеп киткән кебек, аякланып китү иде. Өлкән равва һәрдаим Яхвасыннан могҗиза көтте. Бит кайчандыр китерә бавилләргә могҗиза йөзендә Бөек Кирны. Китерә. Һәм шул адәм аларны әсирлектән азат итә. Кабатланырмы ул могҗиза тагын бер?! Кабатланырга тиеш, чөнки өлкән равва Ибраһим гына түгел, бөтен дөнья яһүдләре моны телиләр иде. Хак, Хазарстанда да начар яшәмиләр алар, бар нәрсә дә үз кулларында. Сугышчан төркиләр ярдәме белән Хазарстан тәмам чәчәк атты. Хазарстан белән чиннар гына түгел, фарсылар да, Византия греклары да исәпләшергә тиеш булдылар. Бәхәссез, бу да җиңү иде. Тик менә ялгыз калуы гына бераз эчен пошыра иде өлкән равваның. Бал чәчкәседәй чибәр яһүдә кызга өйләнеп тә уңмады. Бер Ходабелә, ни сәбәплеер шул хатын дала бәгенә иярде дә китте. Башта өлкән равва яугирләре белән куып тотарга һәм хатынны кылычтан уздырырга теләгән иде, әмма уйлана торгач, бу адымны ясамаска булды. Әйе, шул мәлдә аның хәтеренә Коръәндә булган Аллаһы сүзләре исенә төште. Анда мондый юлларны укыган иде ул: «Хатын-кыздагы мәхәббәт, иминлек, кызгану хисе ул затка Аллаһы тарафыннан бирелгән. Үз кырындагы хатын-кызны сүздән, иректән мәхрүм итсәң, ул йортка игелек тә, тынычлык та, гаделлек тә иңмәс...»

Шул сүзләрне күңеленнән кичерүгә, өлкән равва утырган урыныннан торды да аккошлар ашаткан су буена таба кузгалды. Бу урын аңа кай ягы беләндер оҗмахка охшаган кебек иде. Әйе, Аллаһының оҗмахында да шушындый урыннар бардыр. Судагы аккошлар гына түгел, аяк астындагы алтын төсендәге ком да биредә күңелне сафландыра, йөрәкне тынычландыра иде. Кинәт кенә күңелдәге якты хисләр кузгалып куя, офык читендә төрки бәге белән качкан гүзәл хатыны күз алдына килгәндәй була. Ул әле таллыктагы күл өстенә тәңкәләрен җәеп яткан төнбоек өстендә пәйда була, әле гүя аккошлар арасында йөзеп йөри. Хатыны ташлап киткәннән соң, өлкән равва беркемгә дә гашыйк була алмады. Ул бөтен гомерен каханат белән идарә итүгә багышлады. Һәм бу өлкәдә күп нәрсәләргә ирешә дә кебек. Әйе, ирешә. Тик соңгы вакытта үзе тәхеткә күтәргән Йосыф балакай гына баш бирми башлады. Моның сәбәбен дә белә иде өлкән равва — Айбиби хатын гаепле. Шул бозды карусыз бер аны тыңлаган Йосыф баланы.

Кирәк бит, нәкъ аның турында уйлаганда, Айбиби хатын күренде. Каханбикә өстендә — ерак чиннардан китерелгән тукымадан тегелгән яшькелт төстәге атлас күлмәк. Башында — кырын төшкән алтын җепләр белән тукылган калфак. Муенында — өрфә шарф. Күлмәге су төсендә булгангамы, өлкән равва Айбиби хатынны судан чыгып килгән алиһәгә охшатты. Айбиби хатын, өлкән равваны күрдеме, күрмичәме, аккошларга җим ашата башлады. Ул тәмам су кырына килде һәм тәмам су төсенә керде. Аккошлар аның кулларыннан җим алалар, томшыкларын шыкылдаталар, кинәнәләр, су өстендә биеп алалар, гүя ашаткан өчен хатынга рәхмәт укыйлар иде. Кинәнде бугай Айбиби хатын. Булат бәк калган хатыннарның барчасын да, бүләкләр төяп, илләренә озатты. Ярый торган хәл идеме бу! Ичмасам, кахан аның белән киңәшеп тә тормады. Бәхәссез, бу хәлгә өлкән равваның ачуы чыкты, тик һични кыла алмады. Ә бит Айбибине генә түгел, барча хатыннарны да Йосыф балакайга өлкән равва үзе тарттырган

иде. Шул исәптән Айбибине дә. Хәзер исә үзе үк әнә шул гүзәл затны күралмый башлады. Нигә булыр?!

Әллә соң шушы баланы Йосыфтан көнләшәме?.. Юк, тагын бер тапкыр юк. Айбибине сарайга тарттыргач һәм шушы гүзәл затны Түрә ханы улы Айдар кулыннан тартып алгач, дияргә була, өлкән равва куанып бетә алмаган иде. Аннары шушы баланы тәрбияләп үстергән Рәшидә абыстай белән танышты. Яшерми, ошады аңа абыстай. Тик ул аңа бик акыллы күренде. Ә бит борынгылар: «Акыллы акыллыны яратмас»,— дигәннәр. Әллә соң яһүдләр үзләре кебек бик борынгы тарихлы халыкка тап булдылармы?.. Исраил балалары төрки кавемнәр тарафыннан йотылырга дучар ителделәрме?.. Китапта: «Чит-ят җирләргә киткән халык, җирле халык арасында көн күрә-күрә, башта телен, аннары җырын онытыр»,— диелгән ич. Бер дә гаҗәп түгел, андый хәлләр дә булгалап тора. Бу хакта да яхшы хәбәрдар иде өлкән равва.

Өлкән равва Ибраһим, аяк астындагы җир сулышын ишетергә теләп, аякларына карады. Күп кенә кешеләр бәхетне күктән көтәләр, бактың исә, адәм баласы тулы бәхетне җирдән, туган туфрактан ала икән ич! Ул, ниһаять, һичнигә карамый ил дилбегәсен үз кулына алырга тиеш. Ул болай да Тәүрат кануннарын бозуга таба бара. Үзе сайлаган Йосыф каханны ефәк бау көтә. Һәм ул моны үзе кылыр, үзе!

Тик кай чорда яши ул, кай илдә?! Сугышчан төркиләр арасында түгелме? Тәвәккәл, батыр, кыю халык, иң гаҗәбе — туган туфрагын саклап, кан коюны бәхеткә саный. Моның өстенә күпләре мөселманнар, кара гарәпләргә диннәре аша бәйле халык. Ахыр килеп, биредәге яһүдләр тулы канлы Исраил балаларымы? Бармы, калдымы тулы канлы яһүдләр Хазарстанда?! Күпме яһүдә кызлары төрки бәкләренә ябышып кияүгә чыктылар, күпмеләре бабаларын искә дә алмый башладылар. Юк, елга агышын кинәт кенә борып җибәрү мөмкин булмаган кебек, халыкны да тиз генә үзгәртеп булмый икән. Хазарстанда әле кан кушу дәвам итә, һәм бу гамәлнең башында өлкән равва үзе тора түгелме?.. Тик бит кул кушырып утыру да бернинди нәтиҗә бирмәячәк. Хак, моны да яхшы аңлый иде өлкән равва Ибраһим.

Шушындый фәлсәфи уйларга чумып торган өлкән равва кырына Айбиби хатын килеп басты.

— Саумысыз, өлкән равва! Нинди уйларга баттыгыз? Икенче тапкыр дәшәм бит инде үзегезгә.

Өлкән равва башын иеп кенә исәнләште. Айбиби хатынга текәлебрәк карады. Тәмам алиһә иде хатын. Бирсә бирер икән Хода адәм баласына гүзәллекне. Аның күзләренә карап торган хатын тыенкы гына елмая иде. Хәтта сәер итеп елмаюында да нindидер сихрилек күрде өлкән равва. Әллә соң әнә шул елмаюындамы бу хатынның мәхәббәте? Шул елмаюы белән Йосыф каханны әсир иттеме?..

Өлкән равва дәшмәгәч, Айбиби хатын өрфә шарфы белән авызын каплады. Зәңгәр күзләре генә калгач, хатын тагын да гүзәлләнеп киткәндәй булды. Хатынның бу карашында сихри шигырь юлларыдай гүзәллек тулып ята иде. Аккошлар култыгына сарай җарияләре төшәләр, бераз шаулашалар иде, әмма өлкән равва белән Айбиби хатынны күрделәр дә шым булдылар. Алар артыннан төшә килгән мөгаллимә абыстай кыл тарта, шунда ук кубыз зеңләп куя.

— Сарайга таба кузгалыйк, Айбиби хатын. Минем сезгә сүзем бар,— диде, ниһаять, өлкән равва һәм үзе алдан кузгалды. Өлкән равва каршына таба җария атлый, юри янбашларын уйната булса кирәк. Өрфә ыштаны биленнән дә узмаган, мул җиңле күлмәк дигәне дә кендеккә җитми туктаган. Җария шундаен сыгылмалы сынлы, зифа буйлы иде ки, озын муенындагы алсу шарф сүтелеп, кош булып очып китәр сыман. Биюче җария, янбаш белән биюче, җәннәт алиһәсе. Һәрхәлдә, өлкән равва Ибраһимга шулай тоелды. Җария аның кырыннан үтеп китте, өлкән равва хәтта аның сулышын, битенә сарылып киткән тән җилен тойды. Кайда йөри ул, әллә соң чынлап та җәннәттәме?..

— Өлкән равва, өлкән равва,— диде Айбиби хатын.— Мин сезгә өченче тапкыр дәшәм инде, ә сез барасыз да барасыз. Теге каракош Аккошлар култыгыннан китми дә башлады.

— Ике аккошның башына җитте инде ул, мәлгунь, кай арада ташлана да, кай арада кошның күкрәген яра, кай арада ботарлый, Йосыф углан укчылар да куйган булды инде. Хак, берсен укка алдылар. Ләкин җирдә явызлык бетәме,— диде өлкән равва, барыр җайда башка берәүгә җавап биргәндәй. Өлкән равва туктады, борылып, каракош утырган агачка карады һәм уйлап куйды: «Ә бит бу каракошның илгә яман хәбәр китерүе дә бар. Әйтик, бик ихтимал, ул Йосыф кахан язмышы артыннан килгәндер,— диде эченнән генә һәм янә сарайга таба кузгалды.— Ләкин Йосыф кахан ошбу дөньядан китү белән генә Хазарстан яшәүдән туктамас. Яшәү дәвам итәр, ә менә син, гүзәл хатын, иреңнән мәхрүм калырсың»,— дип, артыннан килгән Айбибигә әйләнеп карады өлкән равва. Мәгәр уйлаган уен Айбиби хатынның күзенә бәреп әйтергә кыймады. «Ил башына үлем килсә, гаепне хатын-кыздан эзлә»,— дигәннәр борынгылар. Ә бит тарихта мисаллары да күп булган. Әйтик, Бөек Искәндәр, фарсыларны җиңгәч, аның каршына бер бите ай, бер бите кояш булган гүзәлне китереп бастыралар. Искәндәр күрә дә сылу затны, гашыйк була. Ул хәтта урыныннан кубып, чынмы бу, күктән төшкән алиһә түгелме, дип, кызның беләгеннән тотып карый. Ләкин шунда кызны китерүче әйтә: «Дарий шаһиншаһның кызын китердем сезгә, галиҗәнабым. Нә кылыйм, сезнең чатырда калдырыйкмы, сатып җибәрикме?»

Дарий шаһиншаһ кызы икәнне белгәч, Бөек Искәндәр, үзенең кем икәнен раслау өчен, кире урынына утыра һәм әйтә: «Мин фарсыларның ирләрен җиңдем, килешмәс миңа аның кызыннан җиңелү». Тик шулай булдымы икән, грек халкы, Искәндәрнең данын тарихларга калдыру өчен, кеше ышанмастай ял-

ганнарга барганнар. Бу хакта да яхшы белә иде өлкән равва. Чынында исә Бөек Искәндәр Дарий шаһиншаһның гүзәл кызын үзе белән йөртә, ахыр аны яһүд сәүдәгәренә сатып җибәрә. Менә бусы хактыр, чөнки бу хакта Исраил балалары тарихларында искәртелә. Әйе, Искәндәр даны еракларга таралган фарсыларны җиңә, ләкин Дарий шаһиншаһның гүзәл кызын түгел. Безнең Йосыф балакай да шул сукмакка төшеп бармыймы?.. Чик, чик куярга кирәк моңа!

Янә тарихтан бер мисал. Фарсылар шаһиншаһы Баһрамның беренче хатынынннан туган улы атасының яшь хатынына кызыга. Тик бу хәл булмый. Ләкин мәкер тулы хатын шаһиншаһына: «Сәнең улың мине ятагына дәште»,— дип әйтә. Ялган хәбәр. Эш киресенчә була, хатын үзе яшь егеткә тәкъдим итә: «Мине ятагыңа алмасаң, атаңа җиткерәчәкмен»,— ди. Әйе, яный. Ләкин саф күңелле яшь кеше бу хыянәткә бармый. Шаһиншаһ вәзирен дәшеп ала һәм улын зинданга ташларга боера. Әмма улы бу хәлне белеп ала һәм төрки-тураннарга кача. Сөмбел атлы була егет. Туран ханы егетне бик теләп кабул итә һәм сараенда яшәргә рөхсәт бирә. Улының качып китүен ишетүгә, шаһиншаһ аны үтерергә ике җалладын җибәрә. Һәм алар илче йөзендә Туран ханы сараена үтеп керәләр дә Сөмбелне бакчага дәшеп алалар. Икенче көнне генә бер гаепсез угланны йөрәгенә хәнҗәр кадалган килеш хан бакчасында табалар. Бу үлемдә дә хатын-кыз гаепле була ич! Безнең хәлдә дә Йосыфның үлемен бу гүзәл хатынга тагып булыр иде, ләкин өлкән равва моңа бармас. Чөнки ефәк бау белән каханнарны буып үтерү күптән инде гадәткә кергән. Шуның өчен яһүдләрнең аталарының аталары Давыт пәйгамбәр хатын-кыз турында болай дигән: «Хатының сүзен тыңлап, теге йә бу ил түрәсе кул астындагы кешеләрне илдән куарга яки җәза бирергә җыенса, ул, затлы вә зыялы ир-ат буларак, киресен эшләргә тиеш. Хатының сүзен тыңлап гамәлләр кыла башласаң, кылган гамәлләрең беркайчан да синең файдаңа булмас». Хатыны өлкән раввага хыянәт иткәч, ул да ни кылырга белми чарасыз калган иде.

Өлкән равва тирә-ягына карады, ул арада Айбиби хатын каядыр китеп барган иде инде. «Китә бир»,— диде ул, битараф бер рәвештә, чөнки аның бу хатын белән бер дә сөйләшәсе килми, ә менә Рәшидә абыстай белән әңгәмә корып утырасы килә иде. Акыллы хатын, җитмәсә, бар нәрсәдән дә хәбәрдар.

Өлкән равва йөзмә күпергә чыга торган ишекләргә якынайды, әмма, күпер тирәсендә шау-шу ишетеп, шым туктап калды. Йөзмә күпер аша баһадир яугире Карун һәм аның ишләре белән Йосыф кахан кайтып килә иде. Аңа сарай сакчылары «Ур-ра!» кычкыралар, хәтта кемдер быргы тавышы чыгарды. Йосыф кахан ап-ак атта, башындагы алтын төсендәге очлымы кояшта ялт-йолт итә. Сарай баскычына җиткәч, кахан атыннан төште, биленә таккан кылычын сул кулы белән тота төшеп, ашыга-ашыга баскычлардан менә башлады. Өлкән равва аның каршысына чыгасы итте, әмма икенче мәлдә ишек артына посты. Бары тик кахан үтеп киткәч кенә, өлкән равва ишек артыннан чыкты һәм, һични булмаган кебек, ишекләрне үтеп, сакчыларга күз дә ташламый, әкрен генә баскычлардан түбән таба төшә башлады. Ул күрде: Йосыф кахан, төп гаскәрен далада калдырып, Карун атаман яугирләре белән генә кайткан, ашыккан. Кем янына?.. Әлбәттә инде Айбиби хатын янына. Өлкән равва белән барысы да сәламләшәләр, димәк, өлкән равва әле үз көчендә. Ул ышана иде: Йосыф каханнан котылгач, аны тагы да хөрмәт итә башларлар. Өлкән равва кораллар саклагыч амбарлары тарафына таба атлады. Амбарлар яр астында, сарайдан читтәрәк салынганнар иде. Тар сукмактан түбән таба төште һәм шунда аның каршында сәер бер карт пәйда булды.

— Сәлам юллыйм сиңа, Исраил баласы Ибраһим. Сәлам юллыйм!

— Сәлам, картлач. Кем син?

— Мосафир мин, мосафир, Исраил баласы Ибраһим.

— Йомышың әйт, дөнья мосафире.

— Саул мин, Саул. Чит илләрдән юл тотам, сиңа, ил руханиена. Йосыф каханга ерак Андалусиядән хат китердем. Хөрмәткә ия кардәшебез әл-Шафрут җибәрде. Ләкин мин әүвәл сине күрергә теләдем. Миңа сәүдәгәрләрең ирештерделәр: Йосыф балакайга ефәк бау салырга җыенасыз икән.

— Юк сүз. Кеше сүзе кеше үтерер, диләр.

— Әл-Шафрут сине кисәтә, өлкән равва Ибраһим, Йосыф балакайга хыянәт итсәң, Яхвабыз сине мәңге кичермәс. Яхва аны үз канаты астында саклый. Тәүратка тугры булган халкыбызны барча илләрдән дә куганда, Йосыф углан Исраил балаларын үз кырына җыйды, сугышчан төркиләр белән уртак тел тапты. Яман греклар Гайсә пәйгамбәрне Иисус Христос йөзендә үзләренә алдылар. Иисус Христос гаделлек өчен үз-үзен корбан итте, шәһит китте, дип лаф оралар. Моңа кадәр Рим империясен кыйблалары итеп алган борынгы греклар, ил байраклары итеп, әйе, дин тугралары итеп, төрки баһадиры Аттила ханның символын алдылар. Кем моңа гаепле? Без түгелме, мескен Исраил баласы Ибраһим? Ә син, өлкән равва Ибраһим, дөньяга сибелгән яһүдләрне туган туфрагыбызга җыю урынына, кулыңа ефәк бавы алырга торасың. Син, Исраил баласы вә рухание буларак, үзең яшәгән халыкны күккә күтәреп мактамасаң да, тату яшәргә өндә. Киресен кылганда, синең иленә дә Яхва каһәре төшәчәк, син аны дошман йөзендә көтмә, Аллаһы Тәгаләнең кодрәте зур, ул, синең гөнаһлы башыңа каһәр җибәрү өчен, башка юлла-рын да табар. Менә сиңа Давыт пәйгамбәр Исраил балаларына биреп калдырган Тәүрат. Ал, ал, курыкма!

Сәер карт Ибраһимны гүя сихерләде: баш түбәсенә ак чәпләшкә каплаган, бит-йөзен сакал-мыек баскан картның кулыннан тышы ялтырап беткән китапны алды һәм, кинәт ниндидер авырлык тоеп, тезенә чүкте. Ул башын күтәргәндә аның каршындагы серле карт юкка чыккан иде инде. Өлкән равва: «Җир йоттымы әллә үзен?» — дип, як-ягына каранды. Ләкин берәү дә аның кырында юк иде. Кулындагы китапны ачты, шулчак аның йөзенә яшен чаткысыдай куе яктылык бәрде. Өлкән равва күзләрен йомды, бөтен тәне буйлап тетрәнү узуын тоеп, китапны кире япты. Һәм янә кинәттән гаип булган мосафирны эзләде. Тәмам чарасыз калды, якындагы ташка утырды да дога кылды һәм, куллары калтыравын тоеп, Яхвасына мөрәҗәгать итте: «Син Исраил балалары өчен генә түгел, син дөнья халкы өчен дә бердәнбер һәм мәңгелек!»

## XII

Каласына кайтып, гүзәл хатыны кырында бер төн уздыргач кына, Йосыф кахан, тәхет ягына чыгып, кылган гамәлләренә, үз-үзенә хисап бирергә кереште. Яу чыгып дөрес эшләдеме ул? Җавабы бер булды — дөрес эшләде. Шөкер кыла, барысы да әйбәт булды. Сарманай каханны да акылга утырттты, дөресрәге, юк иттерде. Башбаштак вә үтә явыз каханның язмышы нәкъ ул уйлаганча бетте. Хак, Түрә хан кулына мул итеп алтын салды һәм ул Сарманай каханны Киялигә кайтармаска вәгъдә итте. Һәм кайтармады да.

Әле булса хәтерендә, күчмә төркиләрнең юлдашлары булган әкрен генә җилгә дә баш ияргә торган кылганнарны куып барганда, башына төрле уйлар килгән иде. Ниятенә ирешерме? Әмма шымчыларына рәхмәт, барысын да җиткереп тордылар. Шул ук шымчылары ниндидер юллар белән Византия императоры Никифор Фокены тәхеттән азат итүгә ирештеләр. Яшь полководец Иоанн Цимисхий ихтирамга лаек мәрхүм Константинның кызына өйләнә һәм: «Илгә хыянәт иттең!» — дип, Никифорны үтерә. Йосыф каханның шымчылары котыртуы буенча, яшь император Дунай буе болгарларын туздырырга яу килгән Сарманай каханга каршы кузгала... Килә һәм Сарманай каханга шарт куя: «Император Никифор биргән 15 кадак алтынны кире кайтар һәм яхшы чакта Дунай буе Болгарын ташлап кит!» Баскынчы варягның моңа җен ачулары чыга һәм ул яшь императорның илчеләренә болай дип җавап бирә: «Мин сине моннан куып кына калмам, патшакалаңа барып, Аурупа белән идарә итә башлармын. Орыш белән куркытырга мин сиңа бала-чагамы әллә!»

Сарманай кахан белән Византия императоры Иоанн Цимисхий арасында сугыш әнә шулай башланып китә. Ул арада Йосыф каханның каханбәге көчле атлы гаскәре белән Кырымга юнәлә: Кырым халкын талый, ары таба Киялигә таба кузгала.

Тик илгә кайтуга, аның кәефен кырдылар. Кемнеңдер котыртуы буенча, кара мәзиннәр Ханбалыктагы синагогаларны җимергәннәр. Кайта-кайтуга, Йосыф кахан кара мәзиннәрне тотарга һәм зинданга ташларга кушты. Мин алардан сорауны үзем алырмын, диде. Өлкән равва үзе күренмәде, ләкин кахан кырына ярдәмчесен җибәргән иде. Кара мәзиннәрне хөкем итүне үз кулына алырга теләгән, әмма Булат бәк аңа моны кылырга бирмәгән: «Кара мәзиннәрне үзем хөкем итәм»,— дип әйтеп әйтте Йосыф кахан, дигән. Һәм Йосыф кахан аңа шулай дип җиткергән иде дә. Чөнки яудан кайткач, Йосыф кахан үзендә көч-куәт иңүен тойды һәм өлкән раввага баш бирмәскә дигән фикергә килде. Бу хакта аңа кайта-кайтуга Айбиби хатын да искәртте. Хак, хатын сүзен ул колак яныннан гына уздырды, вәләкин исеннән дә чыгармады. Чөнки беләсе килә иде: кем кушуы буенча кара мәзиннәр синагогаларны җимергәннәр?.. Кара халык — кара сарык, бер генә мәзин дә моңа баш алып керешмәскә тиеш иде кебек. Мөселман халкына хас сыйфат түгел бу, һәрхәлдә, Хазарстанда яшәгән мөселман халкына. Шуңа күрә өлкән равваның ярдәмчесенә: «Мин кара мәзиннәр хыянәтенә үч итеп, Ханбалыктагы мәчетләрне, чиркәүләрне җимерергә әмер бирмәм, миннән моны көтмәгез. Мин башта хыянәтнең асылына төшенермен»,— диде.

Ахыр килеп, яудан кайтыр юлында ул бабасы Мөхәммәд ханны очратты. Идел буе ханы ике төмән белән Дунай буенда көн күргән кардәшләрен якларга кузгалган булган икән. Хәер, Йосыф кахан үзе дә бу хакта бабасына ирештергән иде. Әле булса күз алдында, бабасы белән алар Тын елга буенда очраштылар һәм яугирләренә ял бирделәр.

Йосыф кахан бабасын чатырына алып керде, кунак итте. Табынга утыргач, берәр касә кымыз эчкәч, Йосыф кахан бабасына болай диде: «Мин шат, бик шат сине күрүгә, бабам. Без үз дигәнебезгә ирештек. Киялидә хәзер Якуб олан утыра, Иске урыста — Олег олан. Уйнаштан тапкан угланны Кияли аксакаллары Холмградка озатканнар. Без янә барысыннан да өстен булып калдык, бабам».

«Хазарстан үз куәтендә, кияү, үз куәтендә,— дигән иде бабасы. Һәм өстәде: — Сиңа янаучылар булыр, сак бул, кияү...» Әмма кемнән сакланырга тиешлеген әйтмәде, алай да Йосыф кахан бераз чамалый иде — раввалардан, үзенең раввларыннан.

Икенче көнне кояш чыгуга, Йосыф кахан бабасын озатып җибәрде, ә үзе ашыгыч төстә башкаласына юнәлде. Бабасы күңеленә ниндидер шом салган иде.

Төрле диннәргә йөз тоткан халыклар яшәгән ил белән идарә итү җиңел түгел иде Йосыф каханга. Гәрчә аны әүвәл башта айга ике-өч тапкыр гына халыкка чыгарып күрсәтсәләр дә, ул, тәхеткә килгәч,

яһүд раввалары китергән бу йола-гадәтне юкка чыгара башлады. Ә инде сарайга Айбиби хатын килгәч, тәмам раввbooларны тыңламый: табыннарда үз фикерен уздырды. Раввaларның беришe аның белән килештеләр, өлкән равва яклылары йөзләрен чытып утырдылар. Барысын да күрде Йосыф кахан, сукыр түгел иде. Ул күзәтә иде, соңгы елларда теге йә бу ил, җир өчен генә түгел, дин өчен сугыша башлады. Ил-җирне басып алып, яуланган халыкны үз диненә көчләп керткән яулаучылар ешаеп бара. Әйтик, кара гарәпләр үз диннәрен Хазарстан төркиләренә көчләп тагалар. Куәтле хәлиф сәргаскәре Мәрван Идел буенда һәм Кавказ тарафларында көн күргән төркиләрне шулай итәләр. Ә бит дин кабул итү кешенең йөрәге аша узарга тиеш, кылыч белән янап түгел. Кая монда гаделлек?!

Йосыф кахан бетекчесен дәштерде. Бетекчесе керeп, кечкенә өстәл янына бөкләнеп утыргач, каурый каләмен чәченә тигезеп алды да Йосыф каханга карады.

— Яз! Яз, сәне...

Шулчак ишектә Ханбалык имамы күренде. Башына яшел төстәге чалма ураган имамны күрүгә, Йосыф кахан бетекчесенә чыгып торырга кушты. Имам керде дә ишек кырындагы түмәргә утырып дога кылды, шуннан соң гына сәлам юллады.

— Исән-имин яудан кайттыгызмы, Йосыф балакай?!

— Шөкер кылам, имам хәзрәтләре, шөкер кылам. Тик бит миңа кайта-кайтуга яман хәбәр иреште, имам хәзрәтләре. Кара мәзиннәр кардәш яһүдләрегезнең храмын җимергәннәр.

— Каһәр аларга, каһәр, Йосыф балакай, каһәр!

— Мин аларны зинданга ташлаттым. Соңрак хөкем итәрмен.

— Кахан хәзрәтләре, каханатның куәте — бердәмлектә, татулыкта, дустанәлектә, мәрхәмәтлелектә, кулга-кул тотынып яшәүдә. Мәзиннәр гафиллек кылганнар. Өлкән равва Ибраһим да сезнең карар-фәрман белән килешкән икән.

— Килеште, килешми кая барсын,— диде Йосыф кахан һәм тәхеткә аркасын терәбрәк утырды.— Мин, ил-халкым исән-имин һәм җитешле яшәсен, дип, ерак җирләргә яу йөреп кайттым, ә монда мәнсез мәзиннәр яһүд туганнарының изге йортларын җимереп яталар. Мин моның өчен аларны, зур мәйданга чыгарып, бөтен кала халкы алдында дар агачына астырырга тиеш идем. Шулаймы, имам хәзрәтләре? Кыргый гамәл бу, борынгы римләннәргә хас гамәл. Мин Ханбалыктагы мәчетләрне дә җимертә ала идем, ләкин явызлык явызлыкка китерер, дип, моңа бармадым. Әмма кара мәзиннәргә җәза яман булыр, имам хәзрәтләре.

Йосыф кахан, синең белән сүзем бетте, дигән сыман, кул селтәде, бу инде чыгып кит, дигәнне аңлата иде.

Имам хәзрәтләре артыннан ишек ябылуга, тәхет ягына Айбиби хатын килеп керде.

— Каханым Йосыфҗан! Аккошлар култыгында бер аккошны каракош ботарлаган, түшен ярган да...

— Укчылар ни караган!

— Бичара аккош бөтенләй минем кулга өйрәнеп беткән иде.

— Йә-йә, бала-чага булма, Айбиби җан. Аккош адәм баласы түгел, мин адәм балаларын да хөкем итәргә җыенам әле.

Айбиби каядыр укыган иде «Ир куәте тау-таш актарыр» дигән сүзләрне. Йосыф кахан шулай дию-гә, Айбиби кинәт кенә тынычлана калды, гәрчә вакыт-вакыт кошлар кебек туган якларына очып китәсе килсә дә, ир кырында һәрчак тынычланыр, сихри көчкә ия булган ошбу кеше янында үзе дә батыраеп китәр иде. Ул арада аш ягына килеп керделәр, Йосыф кахан, табында утырган һәммәсенә дә баш ия-ия, Айбиби хатынның кулыннан тоткан килеш түргә узды, утырыштылар, дога кылдылар, һәм Йосыф кахан табындагыларның һәммәсенә дә сәлам юллады.

Моны Йосыф кахан юри эшләде, югыйсә утыра-утыруга үзе аш башларга тиеш иде кебек, әмма хөрмәт йөзеннән, нәкъ китап кушканча, өлкәннәргә мөрәҗәгать итте.

— Ризыктан рәхим итик, өлкәннәр.

Раввaларның да, имамнарның да бер табында утырулары начар түгел иде, әмма күңелдә ниндидер кимсенү хисе бар. Бит теләп кабул итмәде ул Хәрәзем имамнарын, теләп кабул итмәде. Ни хикмәт, үзе әкрен генә ашады, үзе борынгы бабалары турында уйлады. Сигезенче гасырда бабалары Булан яһүд раввaларыннан яңа исем ала — Сабраилә. Булан каханның нә ислам, нә христиан диннәрен кабул итәсе килми, аның бу диннәргә кагылмый гына үзенә бер дине булган дәүләт төзисе килә һәм яһүдләр динендә туктала. Чөнки табында инде Иранннан, Византиядән куылган раввалар утыра, алар арасында Ефәк юлларында йөргән исемле сәүдәгәрләр дә бар. Ә алар акчалы халык, акчалы гына түгел, кан кардәшләре аша бөтен илләр белән элемтәдә торалар, Ефәк юлы да алар кулында. Һәм Хазарстан куәтләнеп киткәч, бу хәл шулай була да. Ары таба Хазарстан тәхетендә Үбәдәй, Хиския, Манасси, Нисси, Минегем, Вениямин, Шарон-Булан утырып алалар. Ниһаять, тәхеткә Йосыф углан килә. Аны да раввалар сайлыйлар — бар ягын да искә алалар: бабалары яһүд булсын, аналары турында әйтеп тә торасы юк, гәрчә төп чыгышлары төрки булса да. Хак, төрки халыклары аларны беркайчан да яһүд исемнәре белән атамадылар, исемнәрен үз телләренә җайлап, үзләренчә дәштеләр һәм яздылар. Тарихтан шунысы билгеле: милади белән 737 елда гарәпләрнең сәргаскәре Мәрван, Тимер капка аша узып, зур югалтуларга ду-

чар ителсә дә, Хазарстан каханын җиңә, башкаласын ала, гаиләсен, туганнарын әсир итә. Кахан далага качарга мәҗбүр була. Хәйләкәр сәргаскәр, дала халкын җиңә алмавын аңлап, каханга илчеләрен җибәрә, ә илчеләр Хазарстан каханына сәргаскәрнең шартын куялар: «Ислам динен кабул ит! Кабул иткән хәлдә мин сиңа илең-җирең, башкалаң гына түгел, гаиләңне дә кайтарып бирәм». Кахан риза була. Әмма күп тә үтми, янә яһүдләр диненә кайта. Менә Хазарстан янә бер тапкыр ислам динен кабул итәргә мәҗбүр ителде. Ләкин бу озакка барырмы? Бармас. Раввалар сарайга кереп оялаган имамнарга тешләрен кайрыйлар, моның өстенә хәйләкәр раввалар, кара мәзиннәргә бик күп акча түләп, яһүдләрнең синагогаларын җимерәләр. Имамнарның хыянәтеме бу, әллә соң равваларның астыртын сәясәтеме?! Йосыф кахан шуның асылына төшенергә тели иде. Бәхәссез, өлкән равва равваларын гына түгел, яһүдләр яклы сарай куштаннарын да каханга каршы котыртып ята. Моны эчке бер сиземләү белән тоеп йөри иде Йосыф. Бәлкем әле ефәк бауны да кулланырга телидер. Баш бирмәгән раввалар каханнардан ефәк бау аша котылганнар бит. Чөнки сарай гына түгел, хәтта тәхет тә раввалар кулында. Ә башлап йөрүчеләр хәрам атакайлар булачак. Бу хакта да яхшы белә иде Йосыф кахан. Инде нишләргә тиеш ул?.. Әллә соң башлап үзе һөҗүмгә күчсенме?.. Әйтик, иң әүвәл имамнарны сарайдан илләренә кудыртыр. Һәйбәтләп, кунакка озаткан кебек, олылап хәтта?.. Аннары ил язмышын да, тәхет язмышын да, үз язмышын да вакытка тапшырыр...

## XIII

Иртәгә далага чыгасылары турында Йосыф кахан хатыны Айбибидән башка беркемгә дә әйтмәде. Бу аның, яудан кайтканнан соң, дөньяви агышка үзгә карашы иде. Яманлыкка да, игелеккә дә ул тәҗрибәне раввалардан туплады. Хәзер һәр кылган һәм кыласы гамәлен үзбаш эшләде, теге йә бу әмер-фәрманын чыгарганда, Айбиби хатын белән дә киңәшеп алгалады. Фикер уртаклыклары тәңгәл килгәндә, алар икесе дә кинәнделәр һәм бер-берсенә тагын да якыная төштеләр. Хатыннарын илләренә куып җибәргәч, Йосыф кахан күп вакытын эшләренә бирде. Дәүләт даирәсендә эшләгән кешеләргә игътибарлырак булырга тырышты, һәрхәлдә, үзен мөстәкыйль илбашы итеп күрсәтте. Йосыф кахандагы бу үзгәрешне күреп-күзәтеп торган өлкән равва, ни кылырга белми, гасага сабышты. Әүвәл ул Айбиби хатын белән сөйләшергә булды, әмма хатынның көне белән булган әңгәмәне каханга җиткерүе бар иде, моның өстенә каханбикә йөкле, соңгы көннәрен чүпләп ята. Сөйләшү килеп чыкмаса, хатынны борчырмын, хатынга ул-бу була калса, Йосыф аны кичермәс, дип уйлады. Бу инде өлкән равва өчен көтелмәгән яңалык иде. Әйе, курка башлады түгелме үзе тәхеткә утырткан баладан?..

Алай да тәвәккәлләде, көннәрдән бер көнне туп-туры Йосыф кахан утырган тәхет ягына килеп керде. Керде, сәлам юллады һәм, гадәттәгечә, каханның уң кулындагы түмәргә килеп утырды.

Бик озак дәшми торды, аралары суынып бара ич, ничекләр беренче булып сүз катсын.

— Йә, атакай, нә йомыш? — диде аңа, башын чөя төшеп, Йосыф кахан.

— Кхм, Йосыф балакай, сиңа сөенче китердем әле, ә син иртәгә далага чыгарга җыенасың икән. Кхм, әйе, йончып китмәгәе, дим, киленне әйтәм.

— Өлкән равва, далага чыгу минем эш, сөенчең әйт.

— Сөенче,— дип башын күтәрде һәм Йосыф каханның күзләренә карады өлкән равва.— Әйе шул, сөенче шул, Йосыф кахан, Иделнең өске ягыннан викинглар төшеп киләләр. Тиздән Аккалада булырлар. Шул хакта әйтергә дип кергән идем.

Йосыф кахан тәхет терәгенә аркасын турайтыбрак утырды.

— Минем өчен яман сөенче бу, өлкән раввам. Викингларны мин чакырмадым, син чакырттың. Үзең каршы ал, үзең хәл дә ит.

— Мин Харальд корольгә ышанычлы сәүдәгәрем синең белән киңәшеп җибәргән идем кебек, Йосыф балакай...

— Нигә безгә ул сугыш чукмарлары, атакай?!

— Викингларны элек тә яллаганнар, балакай. Көчле, кодрәтле, куәтле халык. Вениямин кахан үз вакытында викинглар ярдәме белән кара гарәпләр явыннан котыла, Каспий диңгезенә чыгарып, мөселманнарның калаларын талатып, Ефәк юлын тагы да ныгыта. Безгә бүген Харәзем әмире үз динен тага башлады. Викинглар аркасында Харәзем әмиреннән дә котылырбыз. Харальд король ышандырган, таланган малның яртысын сездә калдырырмын, дигән. Викингларны Харальд корольнең энесе Гудред җитәкли икән.

— Харальд Соры Тире турында минем дә сәүдәгәрләрдән ишеткәнем бар, атакай. Ләкин мин ул баскынчыларга ышанып җитмим.

— Ышанырга туры килер, балакай, ышанырга туры килер. Мөстәкыйль һәм бәйсез ил белән идарә итәм дисәң, ышанырга туры килер.

— Баскынчы викингларга таянып, төрки туганнарыбызга бау салыйкмы, атакай. Ни күрсәк, ил белән күрербез, ләкин викингларны диңгезгә уздырмаска кирәк.

— Ул викинг дигәннәреңнең, балакай, Казан каласында гаилә корып калганнары да бар.

— Туфрак чакыра кешене, атакай, кендек каны тамган туфрак.

— Нинди туфрак та, нинди кан, балакай?

— Дөнья явызлык белән тулды, атакай. Соңгы елларда гына күпме халыкны кузгаттылар, күпме халык яңа җирләргә куылды, күчеп утырырга мәҗбүр булды. Шул исәптән безнең бабаларыбыз да.

Өлкән равва үзе сабак биреп үстергән Йосыф каханга гаҗәпләнү катыш аптырап карап алды. Ә бит кахан хак әйтә. Тик ни чара кылмак кирәк, Яхвабыз безне шулай йөрткәч.

— Йөкле Айбиби хатынны далага алып чыгасың?..

— Алып чыгам, атакай. Дала һавасын сулап кайтырбыз.

— Миңа яңалык артыннан яңалык ирешеп тора, Йосыф балакай.

— Нинди яңалык?

— Кияли тәхетенә, ике туганын үтереп, колбикә Малушадан туган Ульдәмир утырган икән. Кырында баскынчы варяглар, ди. Сәүдәгәрләрем җиткерделәр. Ульдәмир, мин — кахан, дип, күкрәк кага икән.

— Утыра бирсен, ясагын гына түләсен.

— Кул астында яманнан да яман варяг дип аталган сугышчылар, ди, җибәрмәс ул безгә ясакны, атасы да баш тартып ята иде инде.

Йосыф кахан дәшмәде. Аның беркем белән дә сугышасы килми иде. Кияли каханы Ульдәмир аның тарафына килгән хәлдә ул аңа каршы чыгар, әмма үзе ул тарафларга бармас.

— Викингларны безгә барыбер каршы алырга туры килер, балакай.

Йосыф кахан янә дәшмәде, аның инде ары таба өлкән равва белән сөйләшәсе килми, моны өлкән равва да сизеп алды һәм әкрен генә күтәрелде дә ишеккә таба юнәлде. Йосыф кахан аның бөкрәя төшкән аркасына карап калды. Иртәгә ул далага чыгачак, шунда саф дала һавасында барысы турында да уйланыр һәм ниндидер бер нәтиҗәгә килер. Шул мәлдә ни сәбәпледер Йосыф каханның күз алдына Айбибинең апасы Айгөл килде. Мөхәммәд ханның тәүге кызын да яраткан иде ул. Әмма йөккә узып, бала тапкач, ул нигәдер Айгөл янына кермәде. Килене янында анасы Сара утыра, хатын ир бала тапкач, куанып бетми, Айгөл янына Йосыфны чакыртты. Анасы чакырткач, алай да Йосыф бала тапкан хатын янына керде, әмма хатын җан тәслим кылган иде инде. Бу хакта белгәч, Йосыф борылды да чыгып китте, хәтта анасы кулындагы балага да карамады. Соңыннан, тәхет ягына чыгып утыргач, йөрәге чәнчеп куйган иде. Чөнки бу хатынга ул: «Бәби тапканда, кырыңда булырмын»,— дип вәгъдә иткән иде. Вәгъдәсендә тора алмады. Хәер, ул вакытларда шул ук өлкән равва барча бала тапкан хатыннарны илләренә озата торды, ә кахан титулын йөрткән Йосыф гүя аның кулында курчак иде, хәтта нишлим, дип, киңәшеп тә тормады. Менә ни өчен аның өлкән раввага карата фикере үзгәрде, ерактан килә икән ич бу рәнҗү, хәтта бала чактан ук. Анасы да икенче көнне үк исән калган баланы алды да Тамантархан төбәгенә китеп барды. Соңыннан гына белде: кинәт кенә китеп баруының сәбәбе янә шул өлкән равва Ибраһимда булган икән. Ул, һичкемгә әйтми, анасының кулын сораган, кахан хатынына өйләнәсе иткән, ә анасы Сара аның белән сөйләшергә дә теләмәгән.

Тик Айбиби белән инде ул тәүге хатаны кылмас. Айбиби хатын да аңа исән-имин ир бала тапса, сәясәттән тагын да ерагая төшәр. Сәясәттән ерагаер, ләкин ил белән идарә итүне үз кулына алыр. Ниһаять, ул үзенең кем икәнен күрсәтергә тиеш. Бүген үк! Юк, иртәгәдән. Һичкемгә әйтми, Айбиби хатынын һәм хезмәтчеләрен алыр да далага чыгып китәр. Хәер, каханбәге Сабирны дәшәр. Озатсын, күз-колак булсын...

Иртән-иртүк ашап-эчкәч, далага чыгарга җыена башладылар. Хәер, каханбәк Сабир барысын да әзерләп куйган иде инде, Айбиби хатын батырланып атка атланырга иткән иде, Рәшидә абыстай бирмәде, каханбәк Сабир да киңәш итмәде. Имеш, килешми йөкле хатынга атка атланып йөрү.

— Ә бит безнең әбиләребез бәбиләрен ат өстендә тапканнар,— дип этәчләнеп карады Айбиби. Ләкин аңа ары таба авыз ачарга да бирмәделәр, бигрәк тә Рәшидә абыстай белән кендек әби. Киңәштеләр-киңәштеләр дә Айбибине сиртмәле арбага утыртырга булдылар, Йосыф кахан арба белән янәшә ат өстендә барыр, диделәр.

Йосыф кахан берсе белән дә сүз көрәштермәде, ул барысы белән дә килеште, бары тик Айбибинең нурлы йөзен күреп елмайды гына.

Күк йөзе аяз, далада тыныч иде. Сәер төбәккә утырган иде Ханбалык. Каладан чыгып, басу капкасын узуга ук, дала башлана. Ары-бире йомраннар йөгерешәләр, ул арада өннәренә җитүгә, тырпаеп басалар да әче итеп сызгырып җибәрәләр. Әремнән әремгә, шайтан таягыннан шайтан таягына уткойрыклар куна-оча күченәләр. Алар шулай без куркыткан бөҗәкләрне тоталар, диде аңа янәшәсендә утырган Рәшидә абыстай. Айбибинең күз карашы әле офык читенә юнәлә, ир канаты Йосыфка, шул ук вакытта, карынындагы баланың тибешүен тоеп, үзалдына елмаеп куя. Әллә соң ул да сизәме даланы, бабаларыбыз даласын?.. Сабыр, сабыр ит, балакаем. Мин сине тиздән табармын, боерган итсә, даладан кайткач та, күп тә үтми, син дә якты дөньяга чыгарсың, һәм атаң сине кулына алыр да Тәңребезгә күрсәтер. Шулай иткәннәр борынгы бабаларыбыз, дип уйланып барды Айбиби.

Бик матур инеш буендагы болынга тукталдылар. Хезмәтчеләр казан асып җибәрделәр, ирләр сарыкларны чалдылар. Күп тә үтми, казаннар кайнап чыкты, далага ит исе таралды. Йосыф кахан Айбибине култыклады да инешкә таба алып китте. Ир канаты әле аның калкып торган корсагына кагылып ала, әле аркасыннан сыйпый, әле, туктап, күзләренә карый. Карый да нәүмизләнеп сорап куя:

— Куркасыңмы, бәгырь?

— Син кырымда булганда, мин бернидән дә курыкмыйм, Йосыфҗаным.

Йосыф кахан хатынның чынаяктай ак битенә кагылып ала, биленнән кочмакчы итә, әмма кулы җитми, шуңа икесе дә көлешеп алалар, Айбиби исә:

— Без икәү шул инде, икәү, әтисе,— ди. Шулчак нидер булды, Айбиби: — Аһ! — диде дә җиргә таба иелә башлады.— Йосыфҗаным, мин үземә күз тигердем, күз,— дип, тәмам хәле китеп иренең кулына ябышты. Курка калган Йосыф хатынны кулына күтәреп, корылып беткән чатырга таба кузгалды һәм кычкырды:

— Сабир каханбәк, Сабир каханбәгем, егетләрең җибәр, егетләрең!..

Ул арада таза ике егет килеп җитте, кахан кулыннан аһ-ух килгән хатынны күтәреп алдылар да чатырга таба йөгерделәр. Йосыф кахан аларга иярде, ләкин чатыр каршында егетләр кулыннан эчкәре алып кереп киткән хатын янына аны уздырмыйлар.

— Кендек әби кая, кендек әби! — дип, чарасыз калгандай, арлы-бирле йөрде Йосыф кахан.

Чатыр япмасын ачып, Рәшидә абыстай чыкты.

— Кендек әби дә, мин дә монда, кияү, сабыр ит, барысы да, иншалла, әйбәт булыр.

Йосыф каханга сабырлык килмәде, ул чатыр тирәли йөрергә кереште, бер әйләнә, ике, өч — санын онытты. Ә чатыр эченнән килгән үзәк өзгеч һәр тавыш йөрәгенә ук булып кадалды. Ниһаять, чатыр япмасын ачып, Рәшидә абыстай чыкты, Йосыф каханны чакырып, эчкәре уздырды. Яктыдан кергәнгәме, Йосыф каханның күзләре күрмәс булды, әмма түрдә яткан Айбибине шәйләде, ул да түгел, кендек әбие кулындагы нарасыйга күзе төште.

— Менә кара, кара улыңның ирлек горурлыгын, Айбибиең малай тапты, Йосыф кахан, малай!

Йосыф кахан баланы тоткан кендек әбигә якын ук килде, нарасыйга кулын сузды, бала шундук аның бармагын эләктереп алды һәм, һәрхәлдә, аңа шулай тоелды, шундаен иттереп бармагын кысты ки, Йосыф кахан: «Зур үскән, зур!» — дип әйткәнен сизми дә калды. Аннары Айбиби янына килде, хәлсезләнеп калган хатынның битенә кулын куйды, ахыр кулын алды, яратып, сак кына кысты. Һәм: «Нык бул, нык бул!» — диде.

Чатырдан чыккач, ул бар көченә кычкырып җибәрде:

— Сабир каханбәк, Сабир каханбәк, Айбиби хатын миңа малай тапты, малай!

Һәммәсе дә: хезмәтчеләр дә, пешекчеләр дә, гаскәриләр дә «Ур-ра!» кычкырдылар, хәтта бу тавышка әлегә кадәр йокымсырап торган дала уянып киткәндәй булды. Ул арада кымызчыларның берсе Йосыф кахан кулына кымыз тулы касә тоттырды, касәне күтәреп эчеп җибәрде дә илбашы савытны болынга таба атты. Касә артыннан яшь-җилбәзәк кенә түгел, олысы-кечесе дә ташландылар, чөнки беләләр иде: кахан касәне китергән кешене буш итмәячәк, кимендә дирбияле алмачуар атын бирәчәк.

Ул арада Йосыф кахан янә чатырга әйләнеп керде, шыңшый башлаган баланы кулына алды, сабый, еларга җыенып, йөзен чытты.

— Еласын, еласын, кияү, күз яше сулышны ача, йөрәкне йомшарта,— диде Рәшидә абыстай.

Сарайга кайткач, хезмәтче хатыннар арасында сөйләшү булып алды.

— Айбибие малай тапкач, каханыбыз әллә күз яше белән елады инде.

— Хатыным югалтырмын, дип елады ул, җүләр баш.

— Кырык хатын тоткан кахан хатын өчен елый, ди, ахмак.

— Син үзең ахмак. Гүзәлләрнең гүзәле ич бусы, күз алмалы түгел үзеннән. Минем тилем әйтә...

— Кем ул синең тилең? — дип, күршесен чеметеп ала икенчесе.

— Минем ахмагым, беләсең килсә, шамакайланып торма әле, Нурсөя. Әйе, минем тилем әйтә, ни, ди, сине кочканда, күз алдымда каханның Айбибие тора, ди, менәтерәк. Торсын, мин әйтәм, ул торсын, мине коч, дим. Кочам да, дигән була, мин кочып кына кахан хатыны булсаң ие син, ди, Нурсөякәем...

— Кем күрде, чынлап та күз яше белән еладымы кахан?

— Мин күрдем, мин,— диде кендек әби.— Мөлдерәмә күз яше белән җылады. Бәхеттән, кинәт кенә иңенә ишелеп төшкән бәхеттән елады каханыбыз. Кеше бәхеттән дә елый кайчак, балакайлар.

— Елагандыр, ир бала — ил киләчәге бит, ир куанычы гына түгел,— диде, әңгәмәгә нокта куеп, хатын-кызлар янындагы бер ир-ат.

* * *

Туп кебек угыл тапкач, Айбиби хатын йөзендә тәмам күктәге йолдызлар биешә башлагандай үзгәреш булды. Һәм каханбикә көне белән сарай куштаннары алдында тәгаен бер башка үсте. Хәрам атакайлар Айбиби янында тәгәрәп кенә йөрмиләр иде. Айбиби, нарасыен күтәреп, еш кына Аккошлар кул-

тыгы буендагы чатыр кырына чыгып утырып, баласын имезә торган булып китте. Саф һавада бала йокымсырый, ахыр кинәт уянып китә һәм ашыга-кабалана чупыл-чупыл янә имә башлый. Имеп туйгач, күзләрен ача, әнисенә бага, әнием икән дигәндәй, янә күзләрен йома. Айбибинең бөтен бәхете хәзер — балада. Аның улы бар, бәбкәче, наные. Ана аны күкрәгенә кыса, үбә башлый. Шулчак бала уяна, әнисенә карый. Баланың әтисенеке кебек кара күзләрендә ялвару да, үтенеч тә юк, бары тик авызы белән имчәкне генә эзли.

— Ачыктың дамы, мә инде, мә, им. Им дә зур үс, яме, улым, атаң кебек зур үс!

Бала имә башлый, авыз читләреннән тулышып сөт ага, ул ашыга, кабалана, шул хәлгә Айбиби көлеп җибәрде. Ә бала исә, әллә куркып, әллә гаҗәпләнеп, кисәк имүдән туктады, бертын ни булды дигәндәй, анасына карап торды һәм тагын чулт-чулт имә башлады.

— Ашыкма, ашыкма алай, Ибраһимым. Анаңда сөт җитәрлек...

Ибраһим, диде дә Айбиби сискәнеп киткәндәй булды. Һәм ни өчендер тирәктә утырган каракошка карады һәм йөрәге «жу» итеп китте, хәтта колаклары шаулап алды. Әйе, каракош аның йөрәгенә һәрвакыт шом салды. Каракошка күзе төшкән саен куркып китә иде, әнә шул курку бүген дә кабатланды. Һәм хәзер инде үзе һәм аккошлары өчен генә түгел, баласы өчен дә курыкты. Яман каракош аның күз алдында берничә тапкыр купшы үрдәкләрне алды һәм хәтта аккошларны ботарларга да күп сорамады. Бу хакта ул Йосыфына да әйткәләде, әмма ир заты моңа игътибар итмәде. Кошларның үз дөньясы, кешеләрнең үз дөньясы, дип кенә котылды. Нинди туймас каракош ул, нигә көннәр буена шул тирәктә утыра, нигә аны, ниһаять, укчылар укка алмыйлар. Менә минем улым гына үсеп җитсен әле, күрмәгәнегезне күрсәтер үзегезгә. Тотармын да укка алырмын. Әйеме, улым, әйеме, Ибраһимым!

Янә «Ибраһимым» диде дә Айбиби суда йөзгән үрдәкләргә, аккошларга карады. Нигә әле ул улына Ибраһим исеме куштырды? Әллә соң имам хәзрәтләре: «Матур исем, уртак пәйгамбәребезнең исеме»,— дип куәтләгәнгәме? Ни гаҗәп, имам хәзрәтләрен өлкән равва да яклады, Йосыф та бу исем белән килеште. Аннары баланы сөннәткә утырту да бик тиз хәл ителде. Билгеле инде, баланы беренче көннән үк карарга Рәшидә абыстай алынды. Бу хакта Айбиби Йосыф белән дә сөйләшкән иде инде. Рәшидә абыстайга, бала караганда ярдәм итәргә, ике хәрам атакайны билгеләделәр. Шунда өлкән равва әйтеп куйды: «Мин дә баланы күз угында тотармын». Моңа берәү дә игътибар итмәде, ә менә Айбиби, шул сүзләрдән соң йөрәгенә ук кадалгандай, күкрәгенә кулын куйган иде.

Тар табында бу хәлләр хәл ителгәнгәме, сарайда моңа бик үк игътибар итмәделәр, ягъни балага исем кушу, аны сөннәткә утырту сарай халкы өчен әллә ни зур вакыйга булмады. Рәшидә абыстайга баланы карарга аерым бер бүлмә бирелде, кояш ягында, җылы, һәйбәт итеп җиһазланган. Күрше бүлмәгә хәрам атакайлар урнаштылар. Киң, иркен иде бүлмә. Әнә шулай бала мәшәкате хәл ителгәч, Рәшидә абыстай баланы анасы янына имезергә генә йөртә башлады. Бала имеп туюга, Рәшидә абыстай аны бүлмәгә алып кайтты, җырлый-җырлый йоклатты. Ни гаҗәп, тамагы туйганчы имгәч, бала ана кулында чакта ук йокыга китәр иде. Йокласа да, йокламаса да, Рәшидә абыстай матур-матур сүзләр белән сөйләште, гәрчә наный барысын да аңлый иде, ә инде сабый чәбәләнеп ятканда, тәгаен гел аңа: «Әйт әле, әйт әле, әннә, эттә, дип әйт»,— дип эндәшер, ә бала шуңа охшаш сүзләр чыгарып дәшсә, куанычыннан нарасыйны кулына алыр иде дә тәрәзә каршына илтеп: «Әнә күрәсеңме тирәкне, күрәсеңме, син тиздән шул тирәк кебек зур булып үсәрсең һәм атаң кебек ил белән идарә итәрсең»,— дип тәкрарлар иде.

Көннәрдән бер көнне, әнә шулай сөйләшә-сөйләшә баланы йоклатканда, Рәшидә абыстай бүлмәсенә шакымый-нитми өлкән равва килеп керде. Рәшидә абыстай, әйләнеп, ишекъяры карады да сискәнеп китте.

— Абау, Ибраһим, куркыттың ич,— дип әйткәнен сизми дә калды.

Якын кешеләр арасында гына була торган бу әйтем алар өчен шулкадәр көтелмәгән хәл булды ки, икесе дә гаепле кешеләр сыман күзгә-күз карашып алдылар да елмаештылар. Беренче булып өлкән равва дәште:

— Мин сиңа китап китергән идем, Рәшидә абыстай.

Өлкән равва «сиңа» диюгә, Рәшидә абыстай, сәерсенеп, әмма үпкәләми, өлкән равва Ибраһимга күз ташлап алды, әмма бер сүз дә әйтмәде, бары тик ирен чите белән елмаеп кына куйды. Алай да рәхмәт йөзеннән:

— Син бик кирәк китап китергәнсең, Ибраһим, рәхмәт инде. Кайчак бала йоклаганда укыйсы килә,— диде Рәшидә абыстай, үзе дә «син»гә күчеп.

— Мин бүген беренче тапкыр намазга утырып карадым, Рәшидә абыстай, булмады, барып чыкмады, башка әллә нинди уйлар килә.

— Беренче тапкыр булмаса, икенче тапкыр булыр, Ибраһим. Булыр ул, булыр. Күңелең кинәт кенә кабул итмәгәндер, ә тора-тора күңелең дә кабул итәр, иншалла, итәр. Изге гамәлгә утырганда, күңелгә яман уйлар килү гөнаһ түгел, алардан намаз аша котылырга теләү — изге гамәл, Аллаһыдан ярлыкавын сорау кирәк. Китабың ни хакында соң?.. Фарсы патшалыгында хикмәтле хикәятләр, дисеңме?.. Син миңа яһүд пәйгамбәрләре турында да китап вәгъдә иткән идең түгелме, Ибраһим?

— Анысын да китерермен, Рәшидә абыстай, китерермен. Тик бит әле илдә дөньялар бозылып тора, абыстай...

— Ни булды алай, Ибраһим?

— Ханбалыкта кара мәзиннәр яһүдләрнең изге йортлары — синагоганы җимергәннәр, ковчегка ут салганнар иде бит, абыстай, ковчегка... Ә бит без бергә яшәгән халык, бер тамырдан чыккан, абыстай. Төрек баласы Мәхмүд Газнави күп еллар Иран империясе тәхетендә утыра. Хазарстан белән тату яшәүгә йөз тота.

— Ибраһим, Ибраһим, дим, бик кычкырып сөйләшмә әле, баланы уятырсың.

Сәясәткә кереп киткән өлкән равва кисәк сөйләүдән туктады, як-ягына карап алды.

— Әйе шул, әйе шул, гүзәл абыстай, сүз башым башка иде ич — никах укыту иде.

Өлкән равва, үзенең кем булуы хакында онытып җибәргән сыман, бүлмәгә күз йөртеп чыкты, бераз гына елмаеп һәм көлемсерәп торган Рәшидә абыстайда карашын туктатты да, күкрәгенә кулын куеп, баш иде.

— Җомгага кадәр, абыстаем,— диде дә борылып чыгып китте.

Рәшидә абыстай, өлкән равва Ибраһим артыннан ишек ябылуга, иңбашын сикертеп куйды һәм өлкән равва калдырган китапны кулына алды. Кулына алуы булды, аның бөтен тәне буйлап яшен чаткысыдай тетрәнү узды. Ул, коты алынып, китапны кире өстәлгә ташлады һәм, догасын укый-укый, өлкән равва чыгып киткән ишеккә карады. Рәшидә абыстай Хазарстанга килгәнче үк инде өлкән равваның сарайда кем булуын яхшы белә иде. Өлкән равва Ибраһим Йосыф каханның киңәшчесе генә түгел, хакиме дә, хөкемдары да. Сарайда кылынган сәяси хәлләр, хәтта уеннар да — барчасы да аның башында туа, кахан аша гамәлгә аша иде. Түрә хан Мөхәммәд ханның кызын улына сорап Болгарга җибәрүен ишетүгә, бу ике зур кавемнең кушылып китүләреннән куркып, өлкән равва яучылыкта азау тешләре чыккан ravvаларын Идел буена озатты. Биш яучы кахан исеменнән ханга, кызын Хазарстанга озаткан хәлдә, алтын таулар вәгъдә итә, ягъни ташламалар ясарга. Моңа, әлбәттә, Идел буе төрки болгарлары ышанып җитмәделәр, ләкин аксакаллар һәм Мөхәммәд хан үзе риза булгач, дәшмәс булдылар. Бер сүз белән, һәр чорның үз сәясәте, үз кыйбласы, үз фәлсәфәсе була. Һәрхәлдә, бик күп сәяси хикмәтләрне күргән борынгы халык буларак, Идел буе төрки болгарлары һәм аларның ханы раввалар белән килешергә, дигән фикергә киләләр.

Ә Мөхәммәд ханның баш тартырга да хакы бар иде. Бит хан инде, бер кызын кахан кырына җибәреп, үз башына хәсрәт алды. Үз аллалары Яхвадан башканы күрмәгән, күрергә дә теләмәгән, үзләренең Муса пәйгамбәр заманнарыннан ук килгән Тора-Талмутларына ябышып ятуларын фанатикларча дәвам иткән яһүдләр үк булмасалар да, төрки телдә сөйләшкән хазарлыларны Рәшидә абыстайга да аңлавы кыен иде. Ләкин ул өлкән равваның хәленә керергә булды. Бит яһүдләр арасында исемнәре ерак мөселман илләре халыкларына таралган, мөселман кануннарын саклаган кешеләр дә бар. Шул ук вакытта Хазарстанда Византиядән килгән епископлары да бар иде. Һәрхәлдә, сарайга үтеп кермәсәләр дә, миссионерлар буларак үз эшләрен эшлиләр иде.

Нигә өлкән равва ислам динен кабул итәргә ашыкмый, төрле сәбәпләр таба, ул гынамы, сарайга килеп оялаган Харәзем әмире имамнарын илдән куарга җыена, дигән хәбәр ирешкән, иң әүвәл Рәшидә абыстай өлкән равваның кылын тартып карарга булды. Вәләкин моның өчен аңа өлкән равва Ибраһим белән якынаерга кирәк иде. Хак, бу теләк белән янәшә хатын-кызларда була торган «мине дә яраталар» дигән горурлык хисе дә бар иде абыстайда. Ни генә булмасын, «мин ялгышмыйм» дип уйлый иде Рәшидә абыстай, ә ялгышадыр өлкән равва Ибраһим. Тик ничек, Йосыф каханның йөрәген Айбиби яулаган кебек, һәм нинди юллар белән бу кешенең күңеленә үтеп кереп, йөрәген яуларга?

Башына шундый уйлар килүгә, Рәшидә абыстай күрше бүлмәдәге хәрам атакайларны дәшеп, җомгага кадәр Ибраһим янына кереп чыгарга булды. Имам да килгәндер инде. Әйдә, укытсын никахны.

Хәрам атакайларга йоклаган баланы калдырып, уянса, әнисенә илтегез, дип, Рәшидә абыстай, бәйрәмгә баргандай, матур итеп киенде дә, тәвәккәлләп, өлкән равва бүлмәсенә таба кузгалды. Оялу да, бераз курку да бар иде һәм, яшерми, өлкән раввага бераз мәхәббәте бар иде. Бу мәхәббәте яшьлектәге тәүге мәхәббәтләрдән дә татлырак булыр сыман тоелды аңа, чөнки нигәдер күңеле ашкына, җиңелчә генә булса да, йөрәге ешрак тибә башлаган иде.

## XIV

Йосыф кахан әкрен генә үз көченә кerә бара иде. Ул инде сарайда өлкән равваның нинди сәясәт алып барганын бераз чамалый: яудан кайтыр алдыннан гына сатлык кара мәзиннәргә учлап акча түләп, Ханбалыктагы синагогаларны җимертә һәм Йосыф кахан кулы белән аларны зинданга ташлата. Бу хәлгә тәмам ышана калган Йосыф каханның шушы вакыйгага карата Шарун равва күзен ачты. Синагогаларны җимерүне өлкән равва үзе оештырган. Шушы вакыйга-гамәлне корал итеп алып, өлкән равва сарайдагы имамнарны гына түгел, Рәшидә абыстай белән Айбиби хатынны да Аккаладан кудырмакчы, бер җайдан христианнарны да. Аннары Йосыф каханга керешер. Йосыф каханга карата аның кулында

ефәк бау бар. Рәхмәт Шарунга, Йосыфны әллә чынлап та үз итеп, әллә үзе өлкән равва булырга теләп, аңа барысын да җиткерде. Шарун равваның өлкән равва булырга теләвенә бер дә гаҗәпләнәсе түгел, чөнки бу кеше үзен Булан каханның оныгы, дип йөри иде. Хак, кырык хатыннан туган улларын вә оныкларны барлаучы юк иде, вәләкин өлкән равва аларның барысын да белмәсә дә, беришен күз угында тота һәм теләсә кайсысын кахан итеп тәхеткә күтәрә ала иде. Йосыф кахан, өлкән равваның ни кылырга җыенуын яхшы белгәнгә, бу кешегә каршы ни эшли алуы турында уйлана башлады. Өлкән равва сарайдагы имамнарны һәм Рәшидә абыстай белән Айбибине кудырып кына тынычланмас, каханбәк Сабир белән кала тарханы Булат бәккә дә кул сузар. Бит бу ике кеше дә мөселманнар, җомга намазына кадәр йөриләр. Шул ук вакытта өлкән равва белә иде: Хазарстан тынычлыгы әнә шул каханбәк һәм бәкләр кулында. Хәтта Аккала да алар кулында. Вәләкин ни генә булмасын, өлкән равва мөселманнарны һәм христианнарны илдән кудырачак. Кемнән кудыртачак? Шул ук төрки бәкләреннән. Ил белән кем идарә итә соң? Хазарстан яһүдләре төркиләр дөньясы уртасында калсалар да, ил белән идарә итүне үз кулларында тоталар. Ләкин төрки бәкләренә кайбер ташламалар ясамыйча да мөмкин түгел. Ахыр килеп, каханның сул кулында утыручы Харәзем әмире җибәргән имам хәзрәтләре үзе ни тора. Мең мәзингә, йөз муллага торырлык адәм. Ә бит өлкән равва Харәзем имамнарын үзе барып алды. Хак, харәземлеләр дә буш итмәделәр, Хазарстан җирләренә кереп җәйли башлаган угызларны куып җибәрделәр. Моны да зур җиңүгә санаган иде өлкән равва. Тик менә Йосыф балакай кисәк кенә үзгәрде. Викингларны чакыру мәсьәләсендә дә сыртын кабартты, имеш, үзең чакырттың, үзең хәл дә ит.

Рәхмәт равва Шарунга, Йосыф каханның күзен ачты. Имеш, өлкән равва ике якка да ярарга тырыша һәм илне бик тиз баетырга тели. Аннары өстәде: «Нигә син, илбашы, өлкән равва кубызына биисең? Киңәшчеләреңне үзең сайла. Сара анаң беркайчан да өлкән равва Ибраһимга ышанмады. Казанга киткәндә, бу хакта сиңа да искәртергә үтенде. «Гаязетдин угланны Казанга тархан итеп җибәрүен хуплыйм, ләкин өлкән раввадан сак булсын»,— дип әйтергә кушты». Ни гаҗәп, Айбиби хатын да, сарайга килә-килүгә, өлкән равваны өнәп бетермәде. «Беренче киңәшчең синең, Йосыф кахан, өлкән равва түгел, ә Айбиби хатын»,— диде Шарун равва. Ләкин бит «Хатының тыңла, үзеңчә эшлә» дигән гыйбарә дә бар ич әле. Әйе, Йосыф кахан өлкән равва белән бер-бер чара күрергә тиеш. Тик нинди юл белән? Иртәгә табын, раввалар бу табында мөселманнарны һәм христианнарны каладан куарга карар чыгарачаклар. Һәм куа да башларлар, ә ул — илбашы — бу чарадан читтә калыр. Кыл бер-бер чара, өлгеррәк бул, Йосыфҗан! Шулай дип әйтер иде Айбиби хатын. Ләкин бу хакта Йосыфына бер сүз дә әйтергә теләми, бала белән мәшгуль. Инде нишләргә тиеш ул?.. Йосыф кахан тәхетеннән купты, ишекле-түрле йөрергә кереште. Әйе, иртәгә түгел, бүген табын җыярга тиеш ул... Юк, башта Шарунны чакыртырга. Аннары имамнарны дәшәргә. Имамнарны илдән куу дигән сүз табын аша чыгарга тиеш түгел, ул хәл итәргә тиеш моны. Бүген, хәзер үк. Ашык, Йосыф, ил өстенә югарыдан яман викинглар төшә, аннан соң булып куюы бар.

— Йомышчым, Шарун равваны дәш!

— Баш өсте, галиҗәнаплары.

Күп тә үтми, болары минем кешеләр, дип, ике ише белән Шарун равва килеп керде. Йосыф кахан аларга аяк өсте генә үз фикерен җиткерде. Шарун аның фикерен хуплады. Аларны бүлмәгә чыгарды, шәрабчысына грек шәрабы бирергә кушты, ә үзе өлкән имамны дәштерде. Ләкин тәхет ягына, сорамый-нитми, тарханбәк Булат килеп керде.

— Бик вакытлы йөрисең, тарханбәгем. Идел буйлап викинглар төшә, кальгадагы гаскәриләрне күздән кичер, коралларын барла, булмаса, корал амбарларыннан бирергә куш. Тиз йөр!

— Баш өсте, галиҗәнаплары,— диде Булат бәк һәм чыгып та китте.

Булат бәк артыннан ишек ябылырга да өлгермәде, имам күренде. Ул, керә-керүгә, ишек кырындагы түмәргә утырды, дога кылды, шуннан соң гына каханга сәлам юллады.

Йосыф кахан тәхеткә утырган иде инде, ул да дога кылгандай итте. Һәм:

— Уз, хәзрәт, түрдән уз, түр түмәргә утыр,— диде.

Имам хәзрәтләре түргә узды, кахан күрсәткән түмәргә һәм янә дога кылды, ике куллап йомры сакалын сыпырып алды.

— Каханга Аллаһыбыз куәт бирсен,— диде.

Йосыф кахан тамак кырды, сезгә әйтер сүзем бар дигәндәй, кулын күтәргәндәй итте.

— Имам хәзрәтләре, сез әлегә кадәр минем табынымның иң күркәм кунагы булдыгыз. Тик яман хәбәр ирешге бит әле. Безнең илгә викинглар яу чыккан, мин беләм: алар Аккаланы да читләтеп үтмәсләр... Әйе...

Имам хәзрәтләре бу хакта хәбәрдар икән инде, Йосыф кахан шулай диюгә, як-ягына карап алды.

— Без ни кылырга тиеш инде, кахан хәзрәтләре?

— Сез, имам хәзрәтләре, бүген үк илегезгә таба кузгалырсыз. Буш китмәссез. Һәммәгезгә дә тулы дирбияле ат булыр.

— Хуш, хуш, кахан хәзрәтләре, хуш.

— Мин сезне, имам хәзрәтләре, әмирегезне хөрмәт итеп, колач җәеп кабул иттем, сараема уздырдым, табынымда утырттым. Илдән тынычлык китәргә тора. Әмирегезгә шулай дип әйтегез. Сезнең бүген үк китүегез хәерлерәк булыр. Юлыгызга җитәрлек акча бирелер. Казнабашка әйтелгән.

— Бихуш, яхшы,— диде имам хәзрәтләре.— Без хәзер үк кузгалыйкмы, кахан хәзрәтләре?

— Хәзер үк. Атларыгыз иярләнгән, казнабаш сезне кала күперендә көтә.

Имам хәзрәтләре чыгып киткәч, Йосыф кахан Шарун раввага дәште һәм имамнарны озатырга кушты. Шарун равва ишләре белән аның әмерен үтәргә чыгып киткәч, Йосыф кахан янә тәхетенә утырды да тирән итеп көрсенеп куйды. Аның өчен янә бик тә авыр бер эш калган иде — Айбиби хатын. Ул аны да озатырга тиеш. Әмма ничек, ничекләр әйтергә тиеш ул аңа?.. Авыр аңа, аның Айбибине һәм баланы бер дә җибәрәсе килми иде. Тик бит хәл итте инде, кире чигенү булырга тиеш түгел!

Башта сандыгыннан үзенә дә, хатынына да, балага да гарәп остасыннан ясаткан бөтиләрне алды. Һәр бөтигә дә гарәп һәм яһүд хәрефләре белән аларның сурәтләре ясалган, исемнәре язылган иде. Ул бу бөтиләрне аерылышканда бирергә дип ясатмады, балага елы тулгач бирергә иде исәбе, әмма нишләмәк кирәк, хәзер бирергә туры килер, вакытлыча булса да, аерылышалар ич. Бөтиләрне учына кыскан килеш, Йосыф кахан Айбиби бүлмәсенә таба кузгалды. Ләкин Айбиби бүлмәсендә юк иде. Шуннан ул Аккошлар култыгына юнәлде. Барыр җайда уйлады. Ул аңардан берни дә яшермәс, барысын да әйтер. Айбиби бүген үк Болгарга таба кузгалырга тиеш. Озатуны оештыруны Булат бәккә йөкләр. Тик башта Айбибинең ризалыгын алырга кирәк иде аңа. Айбибидәге күз камашырлык матурлык, үзенә тартып торган серле итеп елмаюы аны беренче күрүдә үк әсир иткән иде. Башта ул, бу хәл үтәр, дип уйлады, әмма үтмәде, Айбиби хатынны күргән саен күрәсе, тыңлаган саен тыңлыйсы килде. Ә инде Айбиби аңа углан бала да тапкач, ул, гомумән, югалып калды. Моның өстенә күптән түгел бабасыннан илчеләр килде, Мөхәммәд хан оныгына бүләкләр җибәргән, ә үзе, авырып китеп, ятакка калган икән. Моңа кадәр ул Айбиби хатынны кырына чакыртып алыр иде, бүген исә үзе аның янына юнәлде. Аягы атлады, ә күңеле икеләнде — әйтер сүзен әйтә алырмы, югалып калмасмы?.. Йосыф каханның күңеле тыныч түгел иде. Моның өстенә үзе дә авырып киткәч, тәхетне кемгә васыять итүе турында бабасы бер кәлимә сүз дә язмаган. Илче дә бу хакта бер сүз дә әйтмәгәч, Йосыф кахан уйлап куйган иде — Идел буе Болгар тәхетенә ханны үзе тәкъдим итәр. Үзе! Шунда ук башына бер уй килде: бүген Казанда тархан булып утырган Гаязетдин угланны тәкъдим итәргә... Сарайдан чыгып, Аккошлар култыгына таба атлаганда, бу уй Йосыф каханның тәмам бөтен зиһенен биләде. Бу хакта ул Айбибигә дә әйтер, җиткерсен атасына. Ни гаҗәп, бу арада аның ягына өлкән равва керми башлады. Ни сәбәпледер Йосыф каханның да күрәсе килми иде аны. Кичә ятагына тартылгач, бу хакта Айбиби хатынга да әйткән иде, тик хатын, бер дә исе китмичә: «Үз җаена яши бирсен, Йосыфҗан»,— дип кенә җөпләде.

Айбиби чатыр каршындагы түмәрдә бала имезеп утыра иде, кырын күзе белән генә ир канатының килүен күргәч, торасы итте, әмма Йосыф кахан кулын күтәрде.

— Ю-у-ук, ю-у-ук, күтәрелә күрмә! — диде.

Йосыф кахан хатыны кырына килеп утырды, култык ягындагы аккошларга күз төшереп алды.

— Безнең янга килергә булдыңмы, этием? — диде Айбиби, бала теле белән әйткәндәй.

— Башына йөз кайгы төшкәч килде улы кырына, Айбиби хатын, мең төрле уй төшкәч. Бабай анда ятакта ята икән, авырып киткән, тәхетне кемгә васыять итте икән, Айбиби?.. Синең белән дә киңәшмәдеме?..

Якында гына хәрам атакайлар утыралар иде, Йосыф кахан аларга: «Югалыгыз күз алдымнан!» — дип кул селтәде. Хәрам атакайларны чатыр яныннан гүя җил алды.

— Атам авырып киткәнен ишеттем, Йосыфҗан, ишеттем... Борчылма, каханым, атам Болгар тәхетенә лаеклы кеше табар.

— Табуын табар анысы, Айбиби, тик бит бер дә киңәш-сабак итмәде.

— Йосыфҗан, Идел буе Болгарында борын-борын заманнардан ук ханны сезнең равваларыгыз кебек төрки аксакаллары хәл итәләр. Гадел рәвештә. Кытай сәүдәгәрләре сөйләгәне хак булса, Йосыфҗаным, борынгы бабаларыбыз үз ханнарын ак киезгә утыртып, өч тапкыр кулларында күтәргәннәр, соңыннан өч тапкыр чатыр тирәли әйләндереп чыгарганнар, шуннан соң гына тәхеткә утыртканнар. Тәхеткә утыргач, аның кулына алтын саплы Тәңре кылычы тоттырганнар.

— Бездә, Айбиби хатын, кахан сайлаганда, башта аны ефәк бау белән сулышы кысылганчы буалар һәм аңа сорау бирәләр: «Ничә ел тәхеттә утырырга, ил белән идарә итәргә исәбең?» — дип.

— Сине дә шулай тәхеткә утырттылармы, Йосыфҗан?

— Мине дә, Айбиби җан, мине дә.

— Ә син ничә ел тәхеттә утырам дип әйттең?

— Хәтерләмим, Айбиби җан, хәтерләмим.

— Безнең борынгы бабаларыбызның бабасы Аттила ханны да киезгә күтәреп тәхеткә утыртканнар, дигән иде миңа имам хәзрәтләре.

— Аннары Аттила хан Римгә кадәр барып җиткән, шулаймы, Айбиби җан?

— Шулай, каханым. Идел тамагына кайтып утырган төркиләр дә Аттила белән Ауропага барганнар. Соңра, еллар үтә-үтә, Аттила ханның оныгының оныгы Кубрат хан Таман ярымутравына үзенә ыстан төзи һәм башкаласы Фанәгүрне атый. Калганын үзең дә беләсең, каханым.

— Хазарстан каханы Болгар ханы Кубрат белән орыша, төрки болгарлары ханының улларын тарата.

— Син хаклы, каханым. Ике туган халык сугыша, бер-берсен кыралар.

— Безгә бүген иң яман баскынчылар килеп яталар, дигән хәбәр иреште, Айбиби җан, иң яман баскынчылар — викинглар. Явызлыклары белән даннары дөнья халыкларына таралган юлбасарлар. Шуның өчен мин сезне, Айбиби җан, Болгарга кунакка җибәреп торырга булдым.

Бу хәбәр аңына җитүгә, Айбиби бераз дәшми торды. Бу ни бу?! Шатланырга тиешме ул моңа, әллә Йосыф кахан шул юл белән алардан котылырга телиме?..

Йосыф кахан кулын Айбибинең иңенә куйды, әкрен генә сыйпый башлады.

— Бу шулай кирәкме, Йосыфҗан, моны син чынлап та шулай телисеңме?..

— Сез минем бу дөньяда иң кадерле кешеләрем, Айбиби җаным, иң кадерле кешеләрем. Сугыш булыр, пиратларның Аккалага бәреп керүләре бар. Мин сине гүзәллегең өчен генә түгел, акылың өчен дә яраттым. Син мине рух байлыгың белән дә әсир иттең, Айбиби җан. Сез бүген үк Болгарга китәрсез. Бүген үк, Айбиби җан.

Айбиби өчен бөтенләй көтелмәгән хәл иде бу. Ләкин кайтарып сорарга кыймады. Йосыф кахан сак кына баланы кулына алды, йокымсырап киткән баланың маңгаеннан үпте һәм торып басты.

— Рәшидә абыстай да минем белән китәрме, Йосыфҗан?

— Рәшидә абыстай да китәр. Сезне озатырга Булат бәк кешеләр бирер. Борчылма, Айбиби җан, барысы да әйбәт булыр. Имам хәзрәтләрен мин озаттырдым инде, Айбиби җан.

Хазарстан каханы Йосыф сүзләренә сәерсенеп калса да, ул аңа ышана иде, гәрчә буласы хәлләргә шомланыбрак куйса да, ир канатына бер сүз дә әйтмәде. Хәер, нәрсә әйтә ала иде ул аңа?.. Һични! Чөнки бу чорда хатын ир белән, ир ил белән идарә итә торган заман иде. Ә һәр заман хатын-кызга үз шартларын куйды, вазгыятькә буйсынмый булдыра алмады Мөхәммәд хан кызы Айбиби, чөнки ул да шушы чорның корбаны иде.

## XV

Каханбәк Сабир Йосыф кахан белән көнбатышка яу йөрсә дә, күңеле һәм дөньяга карашы белән өлкән равва Ибраһим яклы иде. Юк, хатыны яһүдә булганы өчен генә түгел, кылган гамәлләре, акылы белән Йосыф каханнан өстен булганын күреп. Өлкән pавваның өстенлеге нидән гыйбарәт иде соң, бу хакта беркайчан да төбенә кадәр төшеп уйламады.

Булат бәк исә кала-сарай карачысы. Ул бер тапкыр да яуга чыкмады, әмма калада тәртип урнаштыруда аның кебек кешене табу кыен иде. Ул илгә килгән чин сәүдәгәрләре белән дә, Көнчыгыш даласы кыргызлары белән дә, румнар белән дә, фарсылар белән дә уртак тел таба белде һәм һәммәсе белән дә алар телендә сөйләште. Аккалага да, Ханбалыкка да Булат бәк күз-колак булып тора, каханга да ул нәүбәт торып керми, ишек шакып та, ишек ярында торган айбалталарын чалыштырган сакчылар белән дә исәпләшеп тормый, чөнки аларны үзе куя һәм хезмәт хакын да, казнабаштан акча алып, үзе түли иде. Әмма Булат бәк өлкән pавваны өнәп бетермәде. Хәер, моңа гаҗәпләнәсе түгел, Булат бәкнең хатыны яһүдә түгел, төрки болгары, балаларын да сарайда укытмый, кала мәдрәсәсендә укыта. Булат бәккә берәү дә сүз әйтә алмады, чөнки һәр эшен җиренә җиткереп башкара иде. Шуларның барысын да исәпкә алыпмы, өлкән равва Булат бәккә янә бер йөк өстәде: яһүдә хатыннардан туган, сарайда белем алган балаларны, сарай мәктәбен тәмамлаганнан соң, җылы җиргә эшкә урнаштырырга. Бу өстенлекне әллә күрәләр иде төрки бәкләре вә морзалары, әллә юк, әмма бу хәл Булат бәкнең ачуын китерә башлады. Моңа кадәр ул раввалар чыгарган бу канунга буйсынды һәм дәшми генә эшен башкарды. Әмма өлкән равва теләге белән Идел буе Болгары Мөхәммәд ханның икенче кызын Йосыф каханга кырык беренче хатын йөзендә тарттыргач, Булат бәктә үзе дә аңлап бетермәгән көчеш булды, аң көчеше. Ул pавваларга бөтенләй башка күзлектән карый башлады. Нигә әле яһүдә хатыннардан туган балалар гына илнең иң дәрәҗәле мәктәбендә укырга тиешләр?! Нигә төрки хатыннардан туган балалар ул өстенлекләрдән мәхрүм ителәләр?! Кем чыгарган бу канунны? Ә бит әнә шул куштан яһүдләр төркиләр житештергән ипине ашыйлар, pаввалар турында әйтәсе дә юк, балда-майда гына йөзмиләр. Бер генә яһүд тә виноград үстерми, балык та тотмый, тез тиңентен су ерып, дөге дә җитештерми. Ул гынамы, сарай мәктәбен тәмамлагач, сәләтлеме ул бала, юкмы, йә Ефәк юлында тамгачы булып китә, йә төрки бәкләре вә морзаларында сәркатип булып утыра. Гаскәриләргә дә аларның бик сирәкләрен генә алалар. Орыш кырыннан качса да, яһүд баласына җәза юк. Бу нинди Аллаһы сайлаган халык!

Элегерәк Булат бәк Хазарстан тәхетендә курчак йөзендә утырган Йосыф каханга әллә ни шаккатмый иде. Хазар-станда борын заманнардан килә бу гадәт. Әмма Йосыф каханның кырык хатынын ае-

рып җибәргәч, Булат бәк гаҗәпсенде гаҗәпсенүен, барыбер артык исе китмәде. Тик Айбибине күргәч кенә өнсез калгандай булды. «Күр инде, алиһә икән бит бу гүзәл җан, алиһә икән ич!»

Шушы хәлдән соң, Булат бәк, кала тарханы буларак, Йосыф кахан белән дә килеште, өлкән pavваның да хәленә керде. Чөнки, хак булса, хатыннарны куу мәсьәләсен Йосыф кахан берүзе хәл иткән, дигән хәбәр ирешкән иде аңа. Димәк, яһүд булулары белән мактанып йөргән куштаннарның Йосыф кахан борыннарына чиртте. Кинәнде Булат бәк, яшерми. Ләкин, шул ук көнне дияргә була, бер куштан аның янына килде дә: «Булат бәк, минем дә кызым буй алды, тап әле шуңа арурак кияү-егет»,— дип әйтмәсенме. Нә сабыры төкәнсә дә, яһүд агасына, дөресрәге, ярым яһүд агасына, бер сүз дә әйтмәде Булат бәк, тик яңак итен генә чәйнәде. Әмма: «Карап карармын»,— дип әйтмичә дә булдыра алмады. Сарай куштаннарының кыз балаларын кияүгә бирүне, егетләрне бай яһүд сәүдәгәрләренең кызларына өйләндерүне дә йөкләгәч (бу да раввалар чыгарган карар иде), Булат бәк тәмам чыгырыннан чыкты һәм шул сорау белән мөрәҗәгать иткән яһүдне эт итеп орышып ташлады. Ә ул сарай корты икән, шундук өлкән раввага җиткергән, ә тегесе Булат бәкне үзенә чакыртты.

— Булат бәк,— диде кәнәфигә аркасын терәп утырган өлкән равва,— бу нинди хәл инде, безнең хөрмәткә ия равваларыбызны орыша башлагансың. Бер дә ярый торган нәрсә түгел бу, Булат бәк. Син хәзер аны эзләп тап та гафу үтен... Бу булыр — бер, икенчедән, тамгачыларыңа әйт: яһүд сәүдәгәрләренең тауарларын тамгасыз гына базарларга уздырсыннар. Кахан карары вә фәрманы дип кабул ит.

Менә кайчан Булат бәк чыгырыннан чыкты.

— Мин ул яһүдә кызларына бала табарга да булышыйммы, өлкән равва?

Өлкән равва әкрен генә каршында басып торган Булат бәккә башын күтәреп карады, әмма, ни гаҗәп, бер сүз дә әйтмәде. Бары тик: «Бар, юлыңда бул»,— дип, кулын гына селтәде.

Сарайдан чыгып барганда, Булат бәккә каханбәк Сабир очрады, әмма гаскәрбаш аңа кул бирү генә түгел, хәтта исәнләшмәде дә, әйтерсең лә Булат бәк аның өчен юк иде. Ә әйтәсе сүзе бар иде Булат бәкнең каханбәккә. Кичәгенәк угланы Асылбәк аны туктатты да: «Миңа да бер чибәр яһүдә кызын тап әле»,— дип көлемсерәп алды. Каханбәк Сабир улы Асылбәк сарайда казнабаш янында ярдәмче булып йөри иде, яшь, чибәр, башында чәпләшкә, ак җилпәзәк кигән, борын астында сызылып киткән кара мыек. Балда-майда йөзә егет. Заманында Йосыф каханның хатыннарына да күз салгалый икән, дип җиткергәннәр иде хәрам атакайлар Булат бәккә. Әмма Булат бәк моңа игътибар итмәгән иде. Йосыф каханның хатыннарына кул салган кешеләр гомерләрен зинданда бетерделәр, һәм моны кем дә түгел, кахан әмере белән Булат бәк үзе башкарды. Кахан зинданыннан берәүнең дә исән чыкканы юк әле. Булат бәк аңа: «Зиндан җылый анда, сине көтеп»,— дип шаяртып китсә дә, күрде ич: Асылбәк углан тәмам йөзгә үзгәреп калган иде.

Кала-салаларда Булат бәк тәртипне саклады, берәр җирдә каханга, йә булмаса, түрә яһүдләргә карата начар сүз әйтсәләр, үзенең елгыр яугирләре белән шундук барып җитте һәм тиешле чарасын күрде. Ә менә сарай сорыкортлары белән уртак тел таба алмады, гәрчә Аккала куштаннарына кадәр аңа буйсынсалар да, нигездә, куштаннарны өлкән равва үз кулында тотты. Ничәмә еллар эшләп, каханда хезмәттә торып, Булат бәк барыбер сарайда барган хәлләргә төшенеп җитмәде, һәм төшенергә дә теләмәде бугай. Аңа Ханбалыкта да эш бик җиткән иде. Хак, бер хәлне бик тә беләсе килде: кахан зинданга яптырган мәзиннәрне чыгарырга фәрман бирерме, юкмы? Әллә, булмаса, башларын кистерерме?..

Тагын бер яман хәбәр аның эчен тырный иде — Иделнең югары башыннан төшеп килгән викинглар. Бу яман халык белән орыш булырмы? Бит алар телиләрме моны, юкмы, Аккала аша үтәргә тиеш булачаклар?.. Равва Шарун аңа үтеп барышлый гына: «Аккалага викинглар килә, диңгезгә чыгачаклар, сезнең мөселман калаларын талаячаклар, юлбасарларны кахан үзе чакырган, дияр идем, ялгышырмын дип куркам, ә менә өлкән равва чакыруын Харальд корольгә үзем озаттым, карт төлкегә ышанып булмый, калаңны нык сакла»,— дип китеп барган иде. Ышанды да, ышанмады да Булат бәк Шарун раввага, чөнки аның элек тә шаярткалаганы бар иде. Шаяртуының чын булган чаклары да булды, булмады түгел, ләкин зурдан кубып викингларны чакыруны күз алдына китерә алмады Булат бәк. Шул ук вакытта белә иде: сәясәткә кереп чумган яһүд түрәләреннән барысын да көтәргә була. Тукта, тукта, Харәзем әмире имамнарын озата да башламадымы кахан?.. Үзе үк, кунактан киткән кебек, һәйбәт дирбияле атлар белән, кесә тутырып акча бирә-бирә?.. Ни булыр бу?! Сөннәтле казаклар да ни өчендер Ханбалыкта уралалар. Моны ничек аңларга, ә кала тарханы берни дә белми?! Өлкән раввамы, кахан үзе чарасыз калдымы?.. Чөнки аның ярдәме белән Идел буе Болгарлары гына түгел, Харәзем сәүдәгәрләре дә Ефәк юлын үз кулларына төшереп яталар, яһүд сәүдәгәрләре күптән инде шул хакта зарланып йөриләр. Хак, Булат бәк моңа кинәнде генә. Төрки мөселманнарының сәүдә мәсьәләсендә үҗәтлек күрсәтүләре аның өчен куанычлы хәл булса да, Булат бәк бераз курка калды. Алай да башта ул җан сакчысы Актайны каравыл йортына чакыртып алды. Теге килеп кергәч, аңа янәшәсендәге түмәрдән урын күрсәтте.

— Утыр, Актай, йөгем тыңла. Сәхибулла йөзбашың ал да Болгарга юнәл. Анда Мөхәммәд хан ятакка калган икән, авырып киткән, сырхаулап, дим. Хәйлә генә түгелме, чынлап та урынга калганмы хан? Калган булса, кемгә тәхетне васыять иткән? Сора, тартынып торма. Дунай буе Пәһлеван ханның улы Шәмгун аның кул астына килгән иде, ул ни кылып ята, чынлап та Пәһлеван хан угылымы? Пәһлеван

хан угылы булса, кемгә йөз тота, илаһи диндәме?.. Аннары тагын бер үтенеч: Мөхәммәд хан кырында каханның наместнигы утыра булса кирәктер. Аның күзенә чалынмаска тырыш. Син кахан илчесе түгел, Таман тархан Гали илчесе. Искәрдең?!

— Баш өсте, Булат бәк!

Кайчандыр Актай каханда йөзбаш булып йөргән иде, Сабир каханбәк белән килешеп, Булат бәк Актайны үз кырына алды. Ошады егет Булатка. Һәм ул аңа үзенә ышанган кебек ышана башлады. Булат бәк каршында басып торган егеткә карады да: «Нинди асыл егетләребез бар, ә кахан Карунны дәшкән»,— дип көрсенеп куйды.

— Хәзер үк китәсез, күпергә кадәр үзем озатырмын,— диде Булат бәк һәм ишеккә таба алдан кузгалды.

Йөзбашын күпердән чыгарып җибәргәч кенә, Булат бәк кире сарайга таба борылды. Сарайга кереп барганда, аңа равва Шарун очрады.

— Булат бәк,— диде ул кала тарханына.— Әйтергә онытканмын. Кахан үзенә яңа ярдәмче алды. Үгез дә үгез, ул да үгез.

Булат бәк аның кырыннан бер сүз әйтми үтеп китте. Каханның үз кырына батырларны җыюына бер дә шаккатасы түгел, викингларны көтә. Үгез дигәне атаман Карун яугире булса кирәктер. Инде тәхет ягына кереп барганда, аның каршында Рәшидә абыстай пәйда булды. Абыстай өлкән равва бүлмәсеннән чыгып килә иде, Булат бәкне күрде дә кала тарханының тәгаен юлына аркылы төште.

— Булатҗан,— диде ул, якын ук килеп.— Тыңла әле, мине тыңла, дим. Сак бул, бәгем, кахан барча мөселманнарны да каладан куарга әмер биргән. Олан белән Айбибине дә, мине дә Болгарга, ары таба Казанга озатып ята. Без бүген үк чыгып китәбез. Ни булган икән каханга, Булат бәгем?..

Шулвакыт өлкән pавваның бүлмә ишеге ачылды, ишектә өлкән равва күренде.

— Башта бире кереп чык әле, Булат бәк. Кер әйдә, кер, нигә туктап калдың!..

Урлашканда тотылгандай, Булат бәк тәхет ягындагы сакчыларга күз төшереп алды да өлкән равва бүлмәсенә таба борылды.

— Кер, кер, түрдән утыр,— диде аңа өлкән равва.

— Рәшидә абыстай сездән чыгып бара иде кебек, өлкән равва?

— Рәшидә абыстайга тимә, Булат бәк. Аны куеп тор.

— Абыстайның күзләрендә йолдызлар биешә иде, өлкән равва,— дип елмайды Булат бәк көлемсерәп.— Кәефләр ничек соң, өлкән равва? Изге юлдасыздыр бит?..

— Гөнаһ кылмадым, мин шуны яхшы беләм, Булат бәк. Ләкин моны куеп торыйк әле, кала тарханы Булат бәк.

Өлкән равва аны кечкенә өстәл янына дәште.

— Кунак кабул иттең, димәк, өлкән равва.

— Һәй, кем бар анда, кымыз керт! — дип, бавырчысына дәште өлкән равва, Булат бәкнең сүзләрен колак яныннан уздырып.

Кымызчы чокырларга кымыз койгач, Булат бәк рәхәтләнеп эчеп куйды.

— Дала кымызы, кыпчакларныкы, тамакны ярып керә. Шөкер итәм әле, өлкән равва, каханыбыз, Йосыф кахан, дим, бер хатын белән генә тора башлады.

— Нигә алай дисең, Булат бәк? Хатын янына хатын сыя, диләр бит төркиләр.

— Сыюын сыя анысы, тик бит һәр хатынның үз кубызы була. Һәрберсе үз кубызына биетә башлый.

— Әйт әле, Булатҗан, кем адәм баласын оҗмахтан кудырта?

— Һауа анакай, Һауа анакай, өлкән равва.

— Ә шулай да минем Һауа анабызны гаеплисем килми, Булат бәк. Аллаһы Тәгалә һәр ир заты адәм баласына да орлык биргән, ә ул коелырга тиеш. Коела торган урыны — хатын-кыз. Аны тора-бара мәхәббәт дип атый башлыйлар, нечкәртәләр, кисәкләргә бүлгәлиләр. Сөләйман пәйгамбәр исә күпхатынлыкка чарасыздан бара, күп кенә асыл егетләре орыш кырында ятып калгач, тол калган хатыннарны үз учагына алырга мәҗбүр була.

— Алай булгач, безнең каханыбыз да, күп хатын тотып, изге гамәл кылган булып чыга бит, өлкән равва.

— Хак Тәгалә шулай, Булат бәк, Хак Тәгалә шулай. Ләкин каханыбыз үз кадерен үзе белмәде. Хәзер инде без хәл иттек, аны зур сынау көтә.

— Яман йола,— диде Булат бәк, башын чайкап.— Яман йола. Ә минә хатын-кызларга килгәндә, миңа калса, бөтен яманлык алардан башлана, өлкән равва.

— Әйтмә алай дип, Булат бәк. Хатын-кыз куены — оҗмах ул, оҗмах, Булат бәк. Йә, куеп торыйк ул хакта. Мине бүген синең диндәшләрең борчый, Булат бәк, синагогаларны җимергән кара мәзиннәр, каланың кара халкы. Хак, син аларны тиз тоттың, үтә гаеплеләрен зинданга ташладың. Ә бит храмнарны җимерүдә шактый халык катнашкан булган, Булат бәк.

— Әйе, катнашкан. Ләкин мин, өлкән равва, кала тарханы буларак, аларның иң яманнарын гына зинданга ташлаттым, анда да кахан үзе әмер биргәч кенә.

— Үч-үчкә илтмәсме соң, Булат бәк. Миңа иреште: бай сәүдәгәрләребез мәчетләрне җимерергә гарь егетләрне яллап йөриләр икән.

— Ә миңа ирештерделәр, өлкән равва: кемдер Хазарстанга сөннәтле казак атаманы Карунны чакырткан. Егетләрен, башкисәрләрен, дим, кала читендә калдырып, Карун үзе сарайга ук үткән икән. Ә мин, Аккала тарханы, ул хакта бернәрсә дә белмим. Карунның кем икәнен мин бик яхшы беләм, алтынга ул үз атасын да дар агачына асачак.

— Карунны мин чакыртмадым, Булат бәк. Бу хәл кахан эше булса кирәктер. Яудан кайткач, кахан тәмам үзгәрде, хатынынннан аерып алып та булмый башлады үзен. Мин түгел, кахан уйный башлады ил язмышы белән, Булат бәк.

Булат бәк туктады, күзен-кашын җимереп, баш түбәсенә кара төстәге чәпләшкә каплаган өлкән раввага карап торды.

— Сез түгел, димәк, өлкән равва?

— Ышан, Булат бәк, без, раввалар, үзебез каханны хөкем итәргә җыенабыз.

Өлкән равва, аякларын алыштыргалап, бер урында таптанып алды.

— Бу хакмы, өлкән равва?

— Бу чараны һәр чорда да үтәгәннәр, Булат бәк.

— Бер дә гадел чара түгел, өлкән равва. Әйтегез әле, өлкән равва, бу хакта кахан беләме?

— Мин сиңа дәүләт даирәсендә утырган раввалар серен әйттем, Булат бәк. Башыңда акылың булса, сер сакларсың, дип ышанам мин сиңа.

— Өлкән равва,— диде Булат бәк руханиның чапан якасыннан эләктереп,— өлкән равва, ә бит сезнең викингларыгыз белән каханның Карун атаман китергән егетләре канга-кан килеп орышулары бар. Мин нишләргә тиеш булачакмын ул чакта, кемне якларга?.. Мин беләм, хәбәрдар: сөннәтле казаклар — көймәче викингларның кан дошманнары. Теге елда, Карун яуга киткәч, Ука елгасы буйлап килеп, бөтен хатын-кызларны диярлек төяп алып киткәннәр иде. Беришен Хазарстанга китереп саттылар, күбесен Византия сәүдәгәрләренә биреп җибәрделәр. Кем уздырды Идел тамагы аша баскынчы викингларны, өлкән равва? Сез ич!..

— Булды андый хәл, Булат бәк, булды. Әмма үткән эшкә — салават.

Булат бәк өлкән равваның якасыннан җибәрде, арлы-бирле йөреп килде.

— Минем әллә нигә кулым кычыта, өлкән равва. Сез, раввалар, каханнан котылырга телисез, кахан белән бергә ил дә җимерелмәсме соң?.. Бу хәл илдән мөселманнарны куудан башланмасмы?..

— Без Хазарстаннан синагогаларны җимерүдә катнашкан мөселманнарны гына куачакбыз, Булат бәк, аннары аларны котырткан бай мөселман сәүдәгәрләрен, руханиларны, имамнардан алып муллamунтагайларны. Курыкма, Булат бәк, бу чара сезгә кагылмый...

— Ләкин минем халкыма кагыла, өлкән равва, менә шул туфракта көн күргән халкыма, өлкән равва. Бар кеше дә үтә яман карак та, үтә яман диндар да булмый.

— Без төрки кардәшләребезнең кадерен беләбез, Булат бәк, бик яхшы беләбез. Халкыбыз илдән илгә каңгырып йөргәндә, бабаларыгыз безне үз ергәләренә алдылар.

Булат бәк дәшмәде. Өлкән равва хаклы иде. Бу чынлап та шулай була. Булат бәк үзе дә кахан сараендагы мәктәптә равва мөгаллимнәреннән сабак алды. Тик, яши-яши, кечкенә Хазарстан дәүләтен империя иткән дөнья илләрен вә халыкларын яуларга керешкән Византия, Хәлифәлек кебек куәтле илләргә көндәш булырлык үсте, даны еракларга таралды. Хазарстан белән сәүдә итмәгән халык юктыр. Тик бит шул ук раввалар бүген үзләре зур дәрәҗәгә күтәргән илне таратырга җыеналар. Көн эчендә диярлек бер дәүләттә ике түрә барлыкка килде. Берсе — өлкән равва, икенчесе — кахан. Кайсын якларга тиеш Булат бәк? Борын заманнарда, куәтле төрки каханатыннан беренчеләрдән булып, Дулу нәселе аерылып чыга. Дулу ергәсенә кергән баһадир Аттила хан Римгә кадәр барып җитә һәм шунда башын сала. Бит аның гаскәриләре арасында Ашин ыруыннан да гаскәриләр була. Беришләре шушы төбәкләргә әйләнеп кайталар, аларга көнчыгыштан килгән кан кардәшләре килеп кушылалар һәм Хазарстан дәүләтен төзиләр. Дулу ыруыннан чыккан Кубрат хан исә җиденче гасыр башларында үзенә дәүләт оештыра. Соңыннан бу ике кавем канга-кан килеп сугышалар — тәхет бүлешәләр. Төрки кавемнәренә хас сыйфат бу. Хак, дәһшәтле дәүләт башлыгы Кубрат хан дәүләт оештырып калдыра. Җиденче гасырларда була бу. Тик уллары аталары аякландырып калдырган дәүләтне саклый алмыйлар. Шуңа карамастан берәм-берәм үз дәүләтләрен оештыруга ирешәләр. Шуларның берсе — Идел буе Болгары дәүләте — Дулу ыруыннан килгән куәтле кавем. Менә кемгә таянырга тиеш иде Йосыф кахан, ә ул ызгыш-талаш аша илләрен вә җирләрен югалткан өлкән раввага йөз тота. Хак, яһүд раввалары Хазарстанның дәрәҗәсен күтәрделәр: Йосыф кахан идарә иткән дәүләткә дистәләрчә халыклар ясак түли, сөннәтле казаклар да, посканнар да каханга тугрылыклы хезмәт итәләр. Тик кайчанга кадәр дәвам итәр бу хәл? Бит раввалар үзләре үк төркиләр төзегән дәүләтне җимерергә керешеп баралар. Әйе, чит ил юлбасарларын яллый-яллый. Менә шуны аңламый иде Булат бәк. Түзмәде кала тарханы: өлкән равва яныннан чыгып китәр алдыннан, руханиның күзләренә карап, болай диде:

— Өлкән равва, борынгы бабаларыгыз кебек безнең бабаларыбыз төзегән илне җимерергә телисез икән, һичьюгы, каханбәк Сабир һәм минем белән киңәшергә идегез. Мин сезгә моны кылырга бирмәм, өлкән равва. Ишетәсезме, бирмәм!..

Шул сүзләрне өлкән нәрванын күзләренә бәреп әйтергә дә өлгерми калды, ишектә Йосыф каханның йомышчысы күренде.

— Булат бәк, сезне кахан дәшә. Тиз булыгыз!

— Мин хәзер анда булырмын,— диде, йомышчыга таба борылып Булат бәк.— Тик башта өске кирмәнгә менеп, тупчыларым, укчыларым, сөңгечеләремне күздән кичерим. Ил өстенә яу килә ич! — диде.

Булат бәк шул сүзләрне әйтүгә, йомышчы яһүд белән өлкән равва күзгә-күз карашып алдылар. Хәер, болай кыю рәвештә өлкән равва белән сөйләшүенә Булат бәк үзе дә: «Минме бу?» —дип, үз-үзен тотып карау дәрәҗәсенә җитеп килә иде инде.

Булат бәк кальганы саклаучыларның һәммәсен дә күздән кичергәч кенә аска төште, артыннан ияреп йөргән равваларга һәм сөннәтле казакларга да игътибар итми, туп-туры кахан янына юнәлде. Кахан ишегендә торучы сакчылар айбалталарын читкә алдылар, һәм килер җайдан Булат бәк тәхет ягына узды. Ул, гадәттәгечә, аяк киемнәрен салып тормады, әмма каханга җитәрәк, төркиләрчә бер тезенә төште.

— Мин сезнең алда, галиҗәнаплары!

— Тор! — диде аңа Йосыф кахан.— Башта зиндан ачкычын бир!

— Галиҗәнаплары,— диде Булат бәк, аягүрә торып басуга.

Ләкин аңа Йосыф кахан сүз әйтергә бирмәде.

— Зиндан ачкычын! — дип кычкырды.

Әгәр дә мәгәр аяк астындагы җир идәне-ние белән убыла, дисәләр, Булат бәк Йосыф каханның боерыгына ышана төшкән дә булыр иде, ләкин бит кахан аңардан — кала тарханыннан — зиндан ачкычын сорый. Ә бит кахан аңа ул ачкычны үз кулы белән биргән иде. Булат бәк биленә таккан күн капчыктан Болгар остасы ясаган ачкычны чыгарды һәм сүзсез генә Йосыф каханга сузды. Ачкычны кулына алуга, Йосыф кахан Булат бәкнең артында пәйда булган равваларга:

— Зинданга! — дип боерды.

Булат бәк тәмам өнсез калды, аны шундук ике яктан эләктереп алдылар һәм, сөйрәп диярлек, тар тарлавыктан зинданга таба алып киттеләр. Булат бәкнең яшен тизлеге белән зиһене аша: «Үзем төзеткән зинданда үтерәчәкләр»,— дигән уй килде. Күптән түгел генә Булат бәк үзе бер ярсу йөрәкле сөннәтле казакны шушы зинданга китереп ташлаткан иде. Ишекне дә үзе ачты, яһүд сәүдәгәренең кызын урлаган егетне дә зинданга ташлатып, үзе бикләде. Хак, кахан әмере белән егетне чыгарып җибәрде, әмма ни өчен аны зинданга ташлыйлар? Ни гаебе бар?! Булат бәк белми иде. Теге вакытта кыз урлаган егетне өлкән равва зинданга ташларга боерган иде. Өлкән равва егетне зинданга ташлатты, ә кахан, бу хәлне ишеткәч, Булат бәкне үз кырына чакырып алды һәм егетне чыгарып җибәрергә кушты. Менә хәзер Булат бәкнең үзен зинданга ташлыйлар.

Һәм ташладылар да.

Иң сәере — Булат бәк каршылык күрсәтмәде, акланырга да теләмәде. Хәер, кем алдында нинди гаебе бар иде аның — ул белми иде.

Ишекләр ябылгач, чылтырап йозаклар бикләнгәч, Булат бәк аркасы белән ишеккә сөялде дә, булган хәлгә чарасыз калып, аңын җыя алмый торды. Һәм ул кинәт, тамагы ертылырдай хәлгә җитеп, бар көченә кычкырып җибәрде. Ләкин берәү дә аны ишетмәде, берәү дә аңа җавап бирмәде. Ул белә иде: зиндан елга астында, өстән су ага, тавышны ишетү мөмкин түгел, балыклар исә аңа җавапсыз калачаклар. Әмма ул тагын-тагын кычкырды, тамагы әрнешә башлагач кына кычкырудан туктап, сыдырылып, арты белән төшеп утырды. Булган хәлгә кинәт кенә ышануы кыен иде. Булат бәк ике якка башын чайкый-чайкый ыңгыраша башлады. Эчке әрнүе шул чиккә җитте ки, йөрәге дөп-дөп тибүгә, колаклары чыңлауга, тамак төбенә яшь төере килеп тыгылды, күзләреннән яшь бөртекләре атылып чыкты, һәм яшь бөртеге белән бергә бәгыре катты, ул, аңын җуйган кешедәй, тораташтай катып калды.

## XVI

Таман ярымутравы тарханы Гали Йосыф каханга дигән хатны әйбәтләп төрде дә мөһерен сукты һәм сөенче йөртүчесе Чатан Чокырга бирде һәм унбашы Сабырга:

— Чокырны син озатасың, бер атналык ризык ал,— диде.

— Мин анда калырмынмы, галиҗәнабым? — диде сөенче йөртүче Чокыр.

— Ислам кардәшеңнең йомышын йомышлагач кына, туган туфракка таба юл алырсың, кара аны, кардәшем башыннан бер чәче дә төшмәсен.

— Баш өсте, тарханым, барысы да сез әйткәнчә булыр, Ханбалыкка беренче тапкыр гына баруым түгел.

Әнә шулай алар иртә таң белән Ханбалыкка таба кузгалдылар. Каланы чыгып, олы юлга төшүгә, берара атларын җилле генә юырттырып бардылар да, төркем башында барган Чокыр атын Ислам белән янәшә куеп, атлатып кына бара башладылар.

— Әйт әле, Ислам кордаш, яшерми әйт, тархан әйтмешли, чынлап та син Йосыф кахан кулындагы Мөхәммәд хан кызы артыннан йөрисеңме?..— Ислам җавап бирергә авызын гына ачкан иде, Чокыр аны туктатты.— Сабыр ит. Башта мин сөйлим. Кан кардәше буларак, Гали тархан Мөхәммәд ханны якын итә. Без борынгы төрки бабаларыбыз кавеменнән ич. Гали тарханның бабасының бабасы — кара гарәп сәргаскәре Мәрванга каршы сугышкан кеше. Бер сүз белән, хөрмәткә ия нәселдән.

— Моның белән ни әйтергә телисең, Чокыр кордаш?

— Гали тархан әйткәне хак булса, Йосыф кахан авыр хәлдә калган икән. Өлкән равва, каладагы мөселманнардан котылырга исәп тотып, яман баскынчы викингларны дәшкән, дигән фараз йөри. Мин шуны да ачыклап кайтырга тиешмен, кордаш.

— Викинглар элек тә баркаслары белән Идел буйлап төшкәләгәннәр. Ил халкын талаганнар да кире киткәннәр. Ә халык калган, халык янә аякланып киткән, ил-каласын торгызган.

— Ләкин бит хәзерге баскынчылар изге йортларны да җимерәләр, андагы байлыкларны да талап китәләр, ди.

— Минем аларда кайгым юк, кордаш. Миңа бүген Айбибине күрергә кирәк, таш яуса да, мин аны күрермен.

— Сарайга үтеп керергә исәбеңме, кордаш?

— Кирәк икән, сарайга да үтәрмен.

— Ай-һай, кордаш, Аккалага үтә алырсыңмы икән? Анда синең белән минем кебекләрне энә күзеннән уздырып кертәләр. Ә Айбиби хатын — Аккалада,— диде башын чөя төшеп Чокыр.— Айбиби хатын бала тапкан икән ич инде, җүләр баш, бала тапкан, таштай-тукмактай углан бала! Баш сала торган хыял бу, кордаш, баш сала торган. Биримме үзеңә бер киңәш?.. Бир, дисәң, тыңла. Мин Аккаланы яхшы беләм. Куенымда Таман тарханы Гали биргән мөһерле хат бар. Мин ул хатны Йосыф каханның үз кулына кертеп бирергә тиешмен. Тархан әмере.

— Димәк, син, Чокыр кордаш, үзең белән мине дә Аккалага алып керә аласың...

Чокыр як-якка башын чайкап куйды, көлемсерәп:

— Һич мөмкин хәл түгел, кордаш. Хатны мин үзем генә кертә алам. Аннары Айбибине күрүем дә шикле, чөнки миннән каханның бүреләре күзләрен дә алмыйлар.

— Нинди бүреләр?

— Раввалары.

— Ә миңа калса, сарайны сөннәтле казаклар саклыйлар.

— Сөннәтле казакларны беркайчан да сарайга кертмәделәр. Сөннәтле казаклар бары тик ялланып кына сугышалар, Ислам кордаш. Сарайны Таман тархан яугирләре саклыйлар, безнең егетләр!

— Сират күперен үтәргә кирәк икән, мин сират күперен дә үтәрмен, әмма Айбиби кырына узармын, Чокыр кордаш.

Әлегә кадәр уйнап-шаярып кына сөйләшеп килгән Чокырның Исламга ачуы килдеме, беравык дәшми барды. Ул бераз аптырашта калган иде. Бер бала тапкан хатынга шулай дивана хәленә калып гашыйк булу мөмкин хәлме?.. Мөмкин булса, сәламәтме ул егет, ягъни үз акылындамы?.. Чокыр шулай уйланып барды-барды да янә Ислам ягына күз төшереп алды, янәсе, чынлап та үз акылыңдамы син, егет. Юк, җитди сөйләшә егет, сагышы йөзенә үк бәреп чыккан.

— Аккалага үтәргә бер юл бар барын, кордаш Ислам.

— Нинди юл? — дип, иярендә күтәрелә төште Ислам.

— Ул юлны минем атам сала. Елга астыннан үтә ул юл. Туп-туры сарайга алып керә. Булан кахан чорында була бу хәл. Анда эшләгән кешеләрнең Булан кахан барысын да кылычтан уздырта. Ә менә атама тими. Беркемгә дә дәшмәскә, әйтмәскә, дип ант иттерә дә иленә кайтарып җибәрә.

— Бу чынлап та шулаймы, Чокыр кордаш?

— Чокыр беркайчан да ике сөйләмәде, Ислам кордаш. Күрдем ич, син, чынлап та, бер баласы булган Йосыф кахан хатынына гашыйк. Мәхәббәткә хыянәт иткән кеше тәмугта яначак, ди иде минем атам. Кем, кайсыгыз хыянәт итте яшьлектәге мәхәббәтегезгә?.. Курыкма, дөресен әйт?..

— Минем аны гаепләргә хакым юк, кордаш. Айбибине атасы Мөхәммәд хан кахан равваларына биреп җибәрде. Калганы миңа караңгыдыр.

— Бәлкем, ул үзе теләп Йосыф каханга... Кеше күңеле — карурман, диләр бит.

— Мин аны яраттым, мин аңа үлепләр гашыйк булдым, Чокыр кордаш, үлепләр гашыйк булдым. Мин аны күреп сөйләшмәсәм, аның авызыннан ихлас сүзләрен ишетмәсәм, үләчәкмен. Кайда, ни сәбәпле — белмим. Ләкин мин, кылыч йөзеннән булса да, сарайга узарга һәм, сөйгәнемнең күзенә карап: «Син, Айбиби җаным, мине оныттыңмы әллә?» — дип сорарга тиешмен.

— Мин аңладым син дивана башны, аңладым. Ни өчен чәчкә кебек Хәдичә хатынны туган иленә озаттың? Ә бит ул синең күзеңә генә карап тора иде. Син, җүләр баш, нидер әйтерсең дип, алып калырсың дип!..

Ислам, бик ихтимал, беренче тапкырдыр, Тәңресе алдына төшкәндәй, Аллаһысына мөрәҗәгать итте: «И-и-и Ходаем, бир миңа куәт, бир миңа көч, өстә кодрәтең колыңа, бир мөмкинлек сөйгәнемнең йөзенә багарга. Мин аңардан бары тик бер сүз сорармын: оныттымы мине, Идел буен, аккошларын?! Әллә яшьлек мәхәббәтен мәңгегә йөрәгеннән җуйдымы? Җуеламы икән кеше күңелендә язгы ташкын сулары кебек йөрәк түренә кереп оялаган сафтан-саф мәхәббәт!..

* * *

Чокыр шапырынмаган икән, Аккалага җитүгә, аларны карусыз күпердән уздырдылар. Сөенче йөртүче Чокыр, атыннан төшми генә, аларга Таман тархан мөһер суккан хат-төргәкне күрсәтте, ә Исламны минем «җан сакчым» дип, янәшәсендә тотты. Сакчылар Таман тарханы Гали бәкне яхшы беләләр иде, көймәле күпердән генә түгел, аларны сарай капкасына кадәр уздырдылар. Сакчыларга якыная башлауга, Чокыр, хат-төргәкне баш очына күтәреп:

— Таман тарханы Гали бәкнең Хазарстан каханы Йосыф каханга сөенче хаты! — дип кычкыра-кычкыра, сакчыларга хатны бирә, тегеләр мөһерне карыйлар да төргәкне аңа кайтаралар. Ни кычкырса да, ни шапырынса да, сарай сакчылары Исламны кахан кырына уздырмадылар, ә Чокыр һаман кычкырды.

— Кычкырма ул хәтле,— диде сакчыларның берсе.

— Каханның улы Ибраһимны уятуың бар,— дип куйды очлым башына тутый кош каурые элгән сакчы.

— Кырык хатынга бер генә улымыни? — дип шаяртырга теләде Чокыр, әмма аның авызын бик тиз капладылар.

— Бер хатын белән яши хәзер кахан, бер хатын белән. Бик күп кычкырсаң, богаулап алырмын да үзеңне, Ханбалыкка озатырмын, тагылып йөргән якташыңны әллә кайчан суга ташладык инде.

— Карале, Атнабай, кордаш бит син? Нигә алай бик койты сөйләшәсең. Атаң хат яза белми, сиңа әйтергә кушты, туганнарга каты бәрелмәсен, Тәңре алдында каргармын үзен, диде. Атаң синең акыл иясе, хөрмәткә ия зат иде. Син дә, мин әйтәм, үскәнсең, кахан сарае кадәр кахан сараен саклыйсың, әй!

Сакчы Атнабай аны әллә тыңламый иде, әллә, тыңлап, юри ишетмәгәнгә салышты, төргәкнең мөһерен әйләндерә-тулгандыра карады да:

— Ярлык-тәңкәң үзең беләнме? — дип сорады.

— Ярлык-тәңкәсез йомышчы буламы, кордаш. Менә ул! Бак! Кахан үзе мөһер суккан.

— Кахан сине кабул итәр, ләкин башта өлкән раввага күренерсең. Искәрдеңме, кордаш?!

— Искәрми буламы...

Йомышчы Чокыр сарай мәйданын үтүгә, өлкән равва ишегенә юнәлде, ишеген шакыды. Аңа баш түбәсен ак чәпләшкә белән каплаган сакал-мыексыз хәрам атакай ишек ачты.

Чокыр бусаганы атлап узды һәм, өлкән раввага күзе төшүгә, бер тезенә чүкте.

— Галиҗәнаплары өлкән равва, Таман тарханы Гали бәк Йосыф каханга хат юллаган иде.

— Үзең кертеп бир! — дип кырт кисте өлкән равва.

Чокыр сикереп торды, ишектән чыгып, кахан бүлмәсенә таба атлады. Ишекъяры ике айбалта тоткан сакчы тора, айбалталарын чалыштырганнар. Чокыр аларга мөһерле төргәкне күрсәтте, әмма бер сүз дә әйтмәде. Әмма чалышкан айбалталар ничек бар, шулай калдылар. Ишек ачылды, аннан бер равва чыкты. Хатны Чокыр кулыннан алды да «кит» дип, кул селтәде.

— Мин каханга хатны үзем бирергә тиешмен, равва.

Равва хәтта аңа таба күз дә ташламады, борылды да тәхет ягына кереп китте.

— Миңа китәргәме? — дип сорады айбалта тоткан сакчылардан Чокыр, ләкин алар, каткан агач кебек, тик тора бирделәр. Чокыр бер урында таптанып алды һәм кире борылды. Ислам аны күпер башында зарыгып көтеп тора иде инде.

— Минем эш бетте, хат кахан кулында, мин буш,— диде Чокыр.— Әйдә, калага чыгабыз да тамак ялгап алабыз.

— Яугирләр белән нишлисең? — дип сорады Ислам.

— Мин аларны кайтарып җибәрәм, ә синең белән, әйтәм бит, Болгар базары янындагы ашханәдә ашап чыгабыз, шуннан соң синең кайгыңны кайгыртырбыз,— диде Чокыр.

Ашханәдә тамак ялгап чыккач, Идел елгасының сул як ярына урнашкан өйләр яныннан бара-бара, бер тыкрыкка килеп чыктылар, тыкрыктан елга буена төштеләр. Яр буенда көймәче тора, Чокыр әкрен генә аның янына юнәлде, ә Ислам аның артыннан титаклады.

— Менә нәрсә, кордаш,— диде ул, көймәче янына җитүгә.— Бу егеткә Аккошлар култыгына эләгергә кирәк. Бәһадә тормас.

Көймәче мыегын сыпырып алды, килеште, Исламны ым кагып кына көймәгә узарга дәште. Ислам кузгаласы иткән иде, Чокыр аның җиңеннән эләктереп алды.

— Тукта, сабыр ит. Мин сиңа елга астыннан юл уза, дип әкият сөйләмәдем. Менә сиңа су асты юлына ачкыч. Атам миңа аны истәлек итеп калдырган иде. Искәр: йозакны ачканда, бер тапкыр уңга, ике тапкыр сулга борасы. Бу булыр — бер. Икенчедән, табибә киеме үзең беләнме?

— Капчыгымда,— диде Ислам, көймәчегә карап.

— Аккошлар култыгына җиткәндә, эңгер иңгән булыр. Эңгер иңүгә, көймәче сине Аккошлар култыгына кертер. Комлыктан ерак түгел, каханның чатыры бар. Кеше-кара булмаса, шул чатырга кер дә өстеңне алыштыр — хатын-кыз киемең ки. Тик сак бул. Киенеп беткәч, сарайга таба кузгал. Кеше-фәлән күренсә, хатын-кыз кебек яулык очың белән авызың капла. Исәнләшмә, тын гына үтеп кит. Башта Айбиби хатын бүлмәсенә кагыл, Айбиби анда булмаса, сарайга үт. Әйе, зур сынау узасың бар, кордаш. Сиңа кахан ятагына узарга туры килер, ә анда сакчылар. Гадәттә, алар кахан янына кергән хатын-кызны туктатмыйлар. Сарайда инде шәмнәргә ут салган булырлар. Салмаган булсалар, шәм салучыны көтеп тор һәм Айбибине сора. Мин аның табибәсе, каханбикә дәшкән иде, диген. Ул сине Айбиби бүлмәсенең янына ук илтеп туктатыр. Эчкәре кермәс, чөнки хәрам атакайларга кахан хатыннары кырына керергә тыела. Айбиби хатын кахан ятагында, дисә, шәм салучы, дип, ишекне шакымый гына кер, мыштым гына. Сакчыларга игътибар итмә, синең өчен алар юклар. Калганы Тәңре кулында, йә исән-имин Айбиби кырына барып басасың, йә...

— Аңладым, кордаш.

— Ул-бу була калса, сарайның елгага таба төшә торган тарлавыгы аша кахан зинданына йөгер. Анда тонык кына шәмнәр янар. Ишеккә килеп төртелүгә, йозакны ач та су юлына кер. Эчкәре үтүгә, шудыргычны этәреп куй. Куй, дим. Зиндан су юлына барып төртелергә тиеш. Анда да ишек, ләкин бикле булмаска тиеш. Атам шулай дигән иде. Анда эләксәң, ул юл сине туп-туры Ханбалыкка алып чыгачак. Ханбалык яклап су астына керәсе капкада безнең кордашлар тора... Калганын Аллаһыга тапшыр. Иншалла, хәлеңә керерләр. Юк, син алар янына хатын-кыз киемендә чыкма инде, кордаш. Өстең алыштыр, тегеләрнең шикләре төшүе бар. Каханның бер хатыны шул юлдан качарга ниятли, ләкин сакчылар кулына эләгә... Калганын үзең беләсең... Күптән булган хәл, халык әле булса гыйбрәт итеп сөйли... Исән-имин Ханбалыкка чыксаң, Болгар базарындагы Шәрык мәчетенә кер. Шәрык мәчетен кахан җимертергә кушса да, соңыннан тимәскә кушкан дигән хәбәр ирешә. Калганын үзең беләсең, Болгар базарындагы сәүдәгәрләргә ияр дә илеңә кайтып кит. Шул булыр минем сиңа киңәшем, шашкан мәхәббәт диванасына...

Чокыр аны кочагына алды, хәерле юл теләде һәм колагына:

— Шулай баш алыр дәрәҗәгә җитеп гашыйк булып йөрүеңә мин көнләшәм, кордаш! — дип, Исламны көймәгә таба этәреп җибәрде.

* * *

Аккала янына җиткәндә, эңгер иңгән иде инде. Көймә комлыкка килеп төртелүгә, Ислам көймәдән төште, төенчеген чишеп, көймәчегә дүрт көмеш дирһәм сузды. Рәхмәт әйтте. Ул аңа көймәгә утыргач ук алты дирһәм бирәсе иткән иде, ләкин, сөйләшкәнчә, дүртне генә бирде. Көймәче ашыга-ашыга ишә — китеп бара иде инде. Ислам дәшәргә кыймады, учын кыздыра башлаган ике дирһәмне суга ташлады. Догасын укыды. Инде караңгы төшә башлаган булса да, кахан чатыры күренә иде әле. Ислам шунда таба атлады. Кыю рәвештә, чатыр япмасын ачып, эчкәре үтте. Тиз-тиз генә хатын-кыз киемен киенеп, ират киемнәрен төенчегенә бәйләде дә чатырдан чыкты. Сарай яклап таштан сукмак түшәлгән, шул сукмактан әкрен генә сарайга таба кузгалды. Һәм атлаган саен, үз-үзен тынычландырды. «Курыкма, сиңа кем дә тимәс. Син кахан хатыны Айбибинең табибәсе». Әмма сарайга якынайган саен, йөрәге ешрак тибә башлады. Күр әле, сарай тирәсендә бер генә җан иясе дә юк. Ишекъяры җиткәч, бертын йөрәк тибешен тоеп, туктап торды. Ахыр сарайның ишеген ачты, эчкәре үтте. Ишек яныннан ук шәмнәр яна, шәмнәргә ут салучы аларны кабызып кына йөри иде әле, Ислам аның янына узды һәм, кыяр-кыймас кына:

— Мин Йосыф кахан хатынының табибәсе, шәм салучы, миңа аны табарга кирәк,— диде.

Шәм салучы хәтта аңа әйләнеп тә карамады.

— Каханбикә Йосыф кахан кырында, кояш баер алдыннан гына кереп киттеләр. Хәзер инде сиңа, табибәкәй, иртәнгә кадәр көтәргә туры килер, чөнки...

— Мин аны күрергә тиеш, ул авырып тора иде, үзе мине дәштерде,— диде Ислам, тавышын нечкәртә төшеп.

— Алайса, әйдә, үзем озатам,— диде шәм салучы һәм алдан китте.

Шәм салучы артыннан атлаганда, Исламга янә курку килде. Күр инде, Чокыр кордаш әйтмешли, ул, чынлап та, баш китәрдәй эшләр кылып йөри икән ич. Бит аны...

— Менә бу ишекне ачасың да керәсең, хөрмәткә ия табибә, тавышың матур, үзең дә чибәрсеңдер инде...

Ислам аңа җавап бирмәде, ишекне әкрен генә ачты да эчкәре узды.

— Кем бар анда? — дип сорады бер хатын-кыз, Ислам шундук Айбибинең тавышын таныды.

— Мин бу, мин, синең якташың Ислам,— дигәнен сизми дә калды. Тавыш түр яктан килгән иде, чыгучы булмагач, Ислам тынып калды. Чөнки ул бер ялгышны җибәргән иде инде. Ләкин шундук икенче бер ишектән ике равва килеп чыктылар, җилле генә аңа таба юнәлделәр. Исламның коты алынды, ул тиз генә ишекне ачты да чыгып йөгерде. Чокыр әйткәнчә, елга ягына таба. Йөгерә торгач, ниндидер ишеккә төртелеп туктады, дөп-дөп итеп типкән йөрәге ярсудан гаҗиз калып, ишекнең йозагын капшап тапты. Шул вакыт аркасы белән артында аяк тавышлары ишетте. Ул арада эчкәре яктан берәү:

— Зинһар, зинһар, ачыгыз, минем бер гаебем дә юк. Юк! Зинһар...

Ислам ачкычны кесәсеннән алды, калтыранган куллары белән йозак тишеген эзли башлады. Тапты. Ачкычны тыкты. Әмма ишеккә үк беркетелгән йозак ачылмады. Ә артындагы аяк тавышлары колак төбендә үк кебек иде инде. Шунда кинәт, Чокырның бер тапкыр уңга, ике тапкыр сулга борырга, дигән сүзләре хәтеренә төште. Һәм шулай итте, ишек ачылды. Тик инде аһ-ух килә-килә, аның артында: «Тукта! Тукта! Кем син!» — дигән аваз ишетелүгә, каерып ишекне ачты. Ишекне ачуы булды, берәү аны эләктереп алды һәм эчкәре суырды, һәм бар көченә ишекне япты да шуыргычны этәреп куйды. Тышта кычкырдылар-кычкырдылар да китеп бардылар. Эчтәге кеше, ниһаять, аваз салды, Исламны капшап карады.

— Йа Хода, хатын-кыз. Кем син, кахан җариясеме?

— Мин хатын-кыз түгел, мин ир-егет, Мөхәммәд хан табибы улы Ислам,— диде егет, ары таба ни әйтергә белми куркып.

Ишеккә тагын килеп орылдылар.

— Булат бәк, Булат бәк, ишекне ач, кахан сине кичерде, кичерде,— дип кычкыра башладылар.

— Кем син, Алла бәндәсе? Хәер, кем генә булсаң да, син мине коткардың, агай-эне, коткардың. Кем сине ташлады зинданга?

— Мин үзем кердем, үзем...

— Үзең?! — дип сорады исе-акылы китеп Булат бәк.— Үзең?!

— Кем сиңа ачкыч бирде, кахан үземе?

— Таман тарханы йомышчысы Чокыр. Мин Айбибине эзләп килдем, Булат бәк.

— Йосыф кахан хатыны Айбиби? Кем була ул сиңа?

— Минем яшьлек мәхәббәтем ул, тәүге мәхәббәтем.

Булат бәк арты белән җиргә утырды, маңгаен кулларына салды, икенче мәлдә инде Исламның аякларын кочаклады.

— Мәхәббәт юлында йөргән изге зат син, Ислам кордаш. Барысына да ышанып була, ләкин инде бер бала тапкан хатын артыннан шулай йөрү — мөмкин хәлме, балакай?! Җитмәсә, ул хатын кахан хатыны! Шул хыялың аша кахан зинданына килеп керүеңне мин берәүгә дә аңлата алмам, егетем. Тик шуны беләм, син минем коткаручым, Аллаһы Тәгалә җибәргән изге зат син, егеткәем! Ә хәзер син өстең алыштыр, хәтерем ялгышмаса, Айбиби хатынны Йосыф кахан баласы вә абыстае белән Идел буе Болгарына кунакка җибәрергә җыена дигән хәбәр ирешкән иде миңа. Шуның өчен сиңа да, миңа да моннан котылу җаен эзләргә кирәк, егетем.

— Чокыр кордаш әйткән иде, кахан зинданы елга аша су астыннан үткән юлга барып чыга, дип. Хак булса...

— Минем дә ишеткәнем булды ул хакта, ләкин әлеге юл аша Ханбалыкка чыкканым булмады. Зинданның су юлы капкасында сакчылар йөзендә каханның җәлладлары торалар. Менә анысын мин беләм, егетем. Бик яхшы беләм. Ләкин алар һәммәсе дә миңа буйсыналар иде. Әйе, иде...

Булат бәк аягына басты, кесәсеннән чакма ташы чыгарып, ут алды, уң яктагы майлы пумаланы алып, ут салды.

— Без нишлибез хәзер, Булат бәк?

— Шул юлны эзләп китәбез, зинданнан су асты юлын. Ханбалыкка чыга торган юлны. Киттек.

Булат бәк, шәмдәлен Ислам ягына юнәлтеп, өс-башына игътибар итте.

— Мин киендем инде, Булат бәк.

— Бик әйбәт. Тик ишеккә җиткәч, җәлладлар капкасы алдында мин синең өс-башың ерткалап, авызың сугып канатырмын, егетем. Әйе, син минем әсирем. Мин сине казыйга илтәм, хөкем итәргә.

— Ни өчен?

— Ярлыксыз Аккалага үткән өчен, егетем. Әйдә, кузгалдык.

— Мин Мөхәммәд хан кызы Айбибигә гашыйк идем, Булат бәк,— дия-дия, аның артыннан кузгалды Ислам.— Мин аны бер күрү өчен үләргә дә әзер.

— Башта без, егеткәем, бу мәхшәрдән котылыйк. Ярты ел эчендә каханат асты-өскә килде. Ата — улны, ана кызны белми башлады. Раввалар сөннәтле казаклар ярдәме белән Ханбалыктан мөселманнарны куа башладылар. Күрәсең, сарайда хезмәт итсәм дә, аның очы миңа да килеп ялганды. Безгә, ничек кенәләр булса да, моннан таярга кирәк.

— Кай тарафларга, кая?

— Болгарга, бабаларыбыз йортына, егеткәем. Иң элек раввалар кулыннан ычкынырга кирәк, раввалар кулыннан. Хәтерем ялгышмаса, су асты юлына ишек шул тирәдә булырга тиеш,— диде дә Булат бәк, сул кулы белән Исламның авызына тондырды, теге йөзен каплап торганда, бер җиңен умырып төшерде.— Менә шулай.

— Кан китте бит, Булат бәк, авыздан кан китте.

— Авыздан тиз генә кан китми, борыннан китә, егетем. Түз. Әйдә, ары таба киттек, калышма.

Чынлап та, Булат бәк, ерак та китми, ишеккә тап булды. Ишекне ачар алдыннан, Исламның башыннан эләктереп алды да ишекне ачты.

— Һа-а! — диде ишекнең су юлы ягында торган җәллад.— Булат бәк үзе. Безгәме китердең?

— Юк, казыйга илтәм, башта ул хөкем чыгара.

— Калага үткәнме, елга ашамы? Кичә без көймәчене тоттык инде, балыкларга ташладык.

— Шәп иткәнсез,— диде Булат бәк һәм җәллад яныннан үтеп китте.

Кала капкасы янында да Булат бәкнең егетләре тора иде, ул анда да Исламны сөйрәп китерде.

— Кемгә булса да һөҗүм иткәнме әллә, Булат бәк?

— Өлкән раввага ташланган, өлкән раввага.

— Казыйга илтәсең, димәк. Бит казыйны кудылар түгелме соң, Булат бәк?

— Казые булмаса, раввасы табылыр, кайгырма, кордаш. Хөкемдарсыз дәүләт булмый.

— Анысы хак,— диде сакчыларның берсе, ишекне ача-ача.

Калага чыгуга, Булат бәк Исламны җибәрде, канлы авызын сөртергә кесәсеннән кульяулык алып бирде.

— Сөртен дә, әйдә тизрәк Болгар базарына, Шәрык мәчетенә.

Базарга тиз килеп җиттеләр, урамда халык юк диярлек, халык олау-олау каланы ташлап китә. Мәчеткә җиткәч, киң капканы ачып, эчкәре үттеләр. Мәчет баскычларыннан менеп, ишекне ачтылар. Аларны мәзин каршы алды.

— Әйдүк, әйдүк, Булат бәк. Мулла сезне көтә.

— Ничек көтә?! — дип туктап калды Булат бәк.

— Безгә җиткерделәр инде, сезне... кһм...

Булат бәк мәзинне тыңлап бетермәде, башындагы каешланып беткән түбәтәенә кагылып, күзенә кадәр төшерде дә түр яктагы мулла ишегенә таба атлады. Ишекне ачып керүгә, аңа таба мулла кузгалды.

— Йа Алла, Мөхәммәд рәсүлулла, Булат бәк. Котылдың?..

— Котылдык, котылдык, меллам. Менә бу егет коткарды. Мөхәммәд хан табибының улы Ислам.

Мулла Ислам ягына күз төшереп алды да:

— Башта дога кылыйк, Булат бәк,— дип, түмәргә утырды.

Дога кылгач, янә исәнләштеләр, хәл-әхвәлләрен сораштылар.

— Мине, меллам, калада барган хәлләр кызыксындыра.

— Тынычлан, Булат бәк. Хәзер өс-башыгыз алыштырыгыз. Юыныгыз. Ашап-эчеп алыйк. Шуннан соң барысын да җайлап сөйләшербез.

— Ат-корал булырмы, мелла?

— Аты да, дирбиясе дә, коралы да булыр, Булат бәк. Каханга ялланган сөннәтле казаклар Хәрәзем базарындагы сәүдәгәрләрне каладан куа да башладылар инде. Болай орыш-сугышсыз гына куалар, дип ишеттем. Иншалла, без дә исән-имин чыгып китәрбез, Булат бәк. Мин егетләрем дә хәзерләп куйдым инде.

* * *

Иртән аларны мулла уятты.

— Торыгыз, Булат бәк. Юыныгыз-ашагыз да безгә кузгала башларга кирәк. Сөннәтле казаклар елга буендагы мәчетне туздырып ташлаганнар икән инде. Алдан раввалар йөриләр, дигән сүз дә иреште.

Булат бәк сикереп торды, аннан-моннан битен-башын юды да, намазга да утырмыйча, ашап алды һәм, Исламны ияртеп, ишегалдына чыкты. Ишегалдында ун-унбишләп атка атланган егет тора, дирбияле ике атның тезгеннәреннән тоткан мәзин көтә иде. Булат бәк аның кулыннан сугышчы киемнәрен тартып алды да кире ашханәгә керде, тиз генә киенеп, ишегалдына чыкты. Ислам аңардан бер тотам да калмый йөрде.

Мулла хәзрәтләре мәчет болдырына чыккан да намазлык өстендә аларга якты юл тели. Булат бәк сикереп атына атланды, мулла, намазлыгыннан торып, аягүрә басты.

— Оланнар, кордашлар, мөэмин-мөселманнарым, Йосыф кахан раввалары, йөз оятларын югалтып, безне каладан куа башладылар. Орышмый-сугышмый гына чыгып китик, Аллаһының кодрәте илә раввалар үз акылларына килерләр, иншалла. Бүген исә алар иблис коткысында кала бирәләр. Булат углан, мин сиңа үз егетләремнең язмышын тапшырам. Каладан чыгарак, елга буендагы мәчеткә кагылып китәрсез. Иртән шул тирәдә раввалар белән сөннәтле казаклар йөргәннәр иде. Мәчет мулласының хәлен белеп китәрсез. Ак юл сезгә, оланнар!

— Сез, сез беркая да китмисезмени, мелла абзый?

— Мин мәчетемне сакларга калам, Булат углан. Мәчет язмышы — минем язмышым. Ходай язганы булыр. Өнемә качарга мин йомран түгел. Казаклар очрасалар, орышмагыз, узып китегез. Акыллы кеше корал күтәрмәгән кешегә тимәс. Хушыгыз, оланнар!..

Кузгалдылар. Булат бәк, мәчеттән берара киткәч, атын җилле генә куалап, елга буендагы мәчеткә юнәлде, аңа кырыклап яраны иярде. Кырык яугир белән генә сугыш вә орышларда азау тешләре чыккан казакларга каршы торып булмас, ләкин инде Булат бәк тәвәккәлләгән иде. Азлармы, күпләрме — ул беренчеләрдән булып орышка ташланыр. Калганы — Ходай кулында.

Елга буе урамына борылуга, алда утызлап казак күренде. Сөннәтле казаклар урам уртасына ук туктаганнар, гүя урамга аркылы ятканнар иде.

Казакларга җитәрәк, Булат бәк туктады, кынысыннан кылычын суырып чыгарды. Бу инде орышка ишарә иде. Сөннәтле казаклар аны таныдылар — Аккала белән Ханбалык тарханы, кайчандыр төмәнбашмы, меңбашмы булган. Кылыч белән ут уйната, уктан очкан кошны ала. Ләкин бит куркып чигенгән сөннәтле казакларга — үлем. Кахан кануны.

— Һәй, казак туганнар, посканнарданмы, сөннәтлеләрдәнме сез?.. Уздырыгыз безне. Мин сезне күрмәдем, сез — безне. Китегез юлымнан!..

Казаклар үзара киңәшеп алдылар. Кайсыдыр батыр бәккә юл бирергә киңәш итте, күрәсең, атларын якындагы тыкрыкка бордылар. Булат бәк кылычын кынысына тыкты, камчысы белән атына сыдырды.

— Элдер, малкай!

Ишләре аңа иярделәр. Елга буендагы мәчеткә җитәрәк, Булат бәк атын тыя төште, ишләренә әйләнеп карады. Ым кагып кына Исламны янына дәшеп алды.

— Басу капкасында раввалар уралалар. Син алдан кузгал, ә мин елга буйлап, артларыннан төшәм.

— Икегә бүленәбезме?

— Юк, син егетләр белән китәсең, мин — берүзем. Инде сезне уздырмыйлар икән, орышыгыз.

Ислам алдан китте, яугирләре аңа иярделәр, Булат бәк исә кемнеңдер тыкрыгы аша Идел елгасына таба төшеп китте.

Басу капкасына җитәрәк, Ислам атын тыя төште, җаясенә ук элде. Ул күрде: капкада ике равва тора, кулларында сөңге, ләкин арырак өч-дүрт казак утыра, атларын чирәмгә утларга җибәргәннәр. Җаясенә ук элгән бер төркем яугирләр басу капкасына килеп җитсәләр дә, ни өчендер сөннәтле казаклар кузгалып та карамадылар. Капкада торучы раввалар исә сөңгеләрен чалыштырдылар. Сөңгеләрен чалыштырулары булды, алар өстенә кырыклап ук очты. Раввалар егылдылар. Сөннәтле казаклар исә атларына атландылар да елга ягына таба чаптылар. Ләкин аларны Булат бәк көтеп торган икән, казакларның барысын да укка ала башлады. Уктан котылган бер казак кире борылды, әмма ерак китә алмады, күкрәгенә ук кадалып, ат ялы өстенә капланды. Ул арада Булат бәк Исламга кул изәде, ә үзе елга буена таба чапты. Анда унлап равва көймәләргә утырып маташалар, ашыгалар, кабаланалар иде. Килер җайдан Булат бәк аларның икесен укка алды, өчесе исә, көймәгә утырып, ашыга-ашыга, Аккалага таба ишә башладылар. Аның янына Ислам килеп җитте, көймәгә таба ук атты. Булат бәк кулын күтәрде.

— Ук белән елганы тутырып булмас, укларның кирәге чыгар әле, кардәшләр,— диде.

— Хәзер кая, Булат бәк?

— Елга буендагы мәчеткә, Бәкләр урамына!

Мәчеткә килеп җитәрәк күренде: капка янында ук мәет ята. Булат бәк, атыннан төшеп, мәетне бер читкә алып куйды да мәчеткә таба китте. Ислам аны куып җитте, янәшәдә атлады.

— Булат бәк, сине кахан кичергән дә булыр иде.

— Кахан равваларга әсир төшкән кеше, табиб Ислам. Үз вазифасын үтәмәгән каханны һәрчак ефәк бау көтте. Миңа калса, ул да чарасыз калгандыр.

— Карга карганың күзен чукымый, Булат бәк.

— Мине кахан түгел, өлкән равва Ибраһим зинданга ташлатты, табиб Ислам,— диде дә Булат бәк йөгерә-атлый баскычлардан өскә менә башлады. Ишек янында ук аркасына ук кадалган мәзин ята, акайган күзләре белән манара башындагы яшелгә буялган айга төбәлгән. Мәчеткә керделәр. Керделәр дә, тәмам өнсез калгандай, биредә булган хәлгә таң калып, бермәл карап тордылар. Күренеш яман иде: мәчеткә сөннәтле казаклар белән раввалар халык намаз укыганда килеп кергәннәр булса кирәк, күбесенең башлары гәүдәләреннән аерылган иде, гәүдәләре тезләнгән килеш каткан, аяк астындагы келәмдә кан күлдәвекләре.

Исе-акылын жуяр дәрәҗәгә җитеп, булган мәхшәргә карап торганда, беренче булып Ислам сүз катты.

— Булат бәк, кардәшләребезне ишегалдына чыгарып җирлик тә юлыбызны дәвам итик. Каханның безнең өскә раввaларын җибәрүе бар.

— Әйе, әйе, табиб Ислам. Җирлик тә китик. Һәм тизрәк. Бар, көрәкләр барлый тор, егетләргә кабер казырга куш, мин шәһит киткән мөселманнарымны чыгара торам.

Кабер әзер булгач, һәммә шәһит киткән мөэминне дә башын гәүдәсенә җайлап, иплэп кенә кулданкулга кабергә төшерделәр. Бер яугир мәдһи булып чыкты, дога укыды һәм шәһит киткән мөселманнарны дәшми-тынмый гына күмделәр дә атларына таба кузгалдылар. Табиб Ислам кызышкан кулларының калтыравын тоеп, аты янына килүгә, уч төбен ат ялы астына тыгып торды — тынычлана төште.

Ул арада Булат бәк:

— Атларга! — дип боерды.

Җилле генә юырттырып, Идел елгасы буйлап тезелеп киткән Бәкләр урамына таба киттеләр. Күп тә үтми, Булат бәк сарыга буялган капка каршына килеп туктады һәм кычкырып җибәрде.

— Анасы! Бу — мин, ач капканы!

Капка ачылды, Булат бәк яраннары белән ишегалдына үтте. Ул арада Булат бәк янына өстенә камалы камзул кигән хатын килде.

— Ни булды, атасы?!

— Анасы, хезмәтчеләреңә, карачыларыңа әйт, егетләремә ашарга хәстәрләсеннәр. Ә үзең кирәкяракларыңны җыештыра тор. Китәбез, йортны ташлап китәбез. Илгә яу килә.

Хатын «аһ» итте дә ике кулы белән йөзен каплады. Әмма бик тиз исенә килде, атларыннан төшеп, тезгеннәрен киртәгә бәйләп торган хәрби киемдәге егетләрне күрде дә йөгерә-атлый өенә таба китте. Әмма болдырга җитүгә, кисәк туктады һәм борылып:

— Атасы, кай тарафка?..

— Болгарга, Болгарга, анасы. Ашык!.. Иң кирәкле әйберләреңне генә ал, иң кирәкле...

Барысы да җыелгач, ашап-эчкәч, кай тарафтандыр капка карачысы килеп чыкты.

— Син кайда йөрисең, артың эт ялаган нәмәстәкәй! — дип ябырылды аңа ачуы ташкан Булат бәк.— Олау башында бул! — Булат бәк урам якка чыгып, кузгалырга әзер булган олауга күз ташлап алды да: — Кузгалдык! — дип, егетләре белән алдан китте.

Олы юлга төшкәч, атын атлатып барган Булат бәк белән Ислам тигезләште. Булат бәк берничә тапкыр артына әйләнеп карады, матур итеп, манаралап салынган өй ерактан ук күзгә ташлана иде.

— Өйне үзебезнең Болгар осталарыннан күтәрткән идем, мөэминнәрне җирләгән мәхәллә мәчетен дә мин күтәрткән идем, үз исәбемә. Такта-агачны Казан тирәләреннән сал белән китерткән идем. Күрдеңме өемне, көлеп тора кебек. Алтын куллы осталар эшләгәннәр иде. Шуның өчен каерылып карарга куркам, әмма йөрәк түзми, йөрәккә кан сава. Ә бит мин, Ислам туган, хезмәтемне Мөхәммәд хан сараенда башлаган идем. Бермәлне бәйгеләр уздырганда кахан наместнигы мине күзәтеп торган. Анда мин беренче урынны алган идем — уктан алуда да, сөңге ташлауда да, кылыч белән алышуда да, көрәштә дә. Мөхәммәд хан миңа койты дирбияле ат бүләк иткән иде. Сабан туенда булды бу. Ә бу сабан туена кахан наместнигы да килгән иде. Әнә шул кеше мине Аккалага тарттырды. Әлбәттә инде Мөхәммәд хан риза булган. Менә шулай мин сарай куштаны булып киткән идем. Өй күтәрттем, мәчет салдырдым һәм елга буйлап Бәкләр урамы булдырдым. Тукта, сез бара торыгыз, мин Мөслимә абыстаең хәлен белеп килим әле. Бик кайгырмасын, баш исән булсын, мал булыр ул. Мал хезмәт яраткан кешедән йөз чөерми...

Мөслимә хатынның хәлен белеп, җәмәгатенең кайгысын уртаклашып, бераз тынычландырып килгәч, Исламның ни турында уйлап баруын белгән кебек, Булат бәк:

— Табиб Ислам, табиб Ислам, дим. Без Саксинга керәбезме, үтеп китикме? — дип сорады.

— Бу калада борынгы Биләмҗирдән күчеп утырган халык яши бугай бит, Булат бәк.

— Әйе, безнең борынгы бабаларыбыз. Тик хәзер бу каланы кыпчаклар басты. Элек угызлар, баҗайлар ыстан торалар иде. Хәзер монда барысы да буталып бетте инде, Ислам туган. Иң гаҗәбе, бу калада кахан наместникларын тотмый, ясак җыярга да яһүд сәүдәгәрләрен җибәрми, саксиннарның үзләреннән җыйдырта.

— Нигә?

— Баш бирми торган халык яши бу калада, әйе, без туктыйсы калада, Ислам табиб.

— Әти дә шулай ди торган иде аны. Ә бит башта бирегә угызлар утыралар, аннары баҗайлар, ахыр әнә кыпчаклар килеп тулганнар, дисең...

— Дала халыклары каласы бу. Бер генә сәүдәгәрнең дә бу каланы читләтеп үткәне юктыр. Викинглар да бу калага баш тыгарга куркалар, әйе, нә явыз халык булса да, куркалар.

Ул арада алар янына, җилле генә юырттырып, ат менгән бер углан килде.

— Атам, атам, бер арбаның көпчәге ватылды.

— Җай көпчәк юкмыни?

— Бар барын да, арбаны күтәрә алмыйбыз.

Булат бәк Исламга карады.

— Барып киләбезме?

Ислам сүзсез атын бора башлады. Көпчәге ватылган арба янына тиз килеп җиттеләр, җыелышып, бер сулыштан арбаны күтәрделәр дә, күчәргә дегет сөртеп, көпчәкне кигерделәр. Ислам арба тирәсендә боҗырдай йөгереп, теге йә моны кылырга әмер биреп торган Булат бәкнең улына игътибар итте, кире әйләнеп олы юл башына төшеп, атларын атлатып киткәч кенә, Булат бәктән сорап куйды.

— Улың сарай мәктәбендә укый идеме, Булат бәк? Аты ничек әле?

— Хәбир, Хәбир атлы. Ушлы малай. Мин аны сарай мәктәбенә бирмәдем, аерым мөгаллимдә укыттым, Ислам туган, сарай мәктәбендә Тәүратны укытып бала башын катыралар.

— Улыңа ничә яшь инде?

— Быел кылыч такты.

— Димәк, ундүрт яшен тутырды.

— Тутырды, тутырды, Ислам туган. Ушлы егет булып килә инде. Атам, мин дә синең кебек мәргән булам, дип әтәчләнә. Менә нәрсә, Ислам туганый, берсекөнгә без Саксинга җитәрбез. Әмма олау анда бармас. Без елга буенда калырбыз. Ә сез Саксиндагы хәлләрне белеп килерсез. Әйе, керергә ярыймы калага, юкмы. Ни дисәң дә, кала кахан кулында. Аның монда сөннәтле казакларны җибәрүе дә бар. Килештекме?..

— Ике көнгә якын юл үтәсе бар бит әле, Булат бәк.

— Иншалла, үтәрбез. Мин шуны яхшы аңлыйм, безне куа чыкмаслар, раввалар белән сөннәтле казакларга калада да эш җитәрлек. Мин киттем, ә каханбәк Сабир, гомумән, каладагы тәртипләрне белми. Аннары аны, хәтерем ялгышмаса, Йосыф кахан Харәзем әмиренә җибәрергә тора иде, имеш, килешү төзергә. Имеш, кахан аның диненә кагылмый, ә ул Харәзем әмире эшенә тыкшынмый. Бер сүз белән, каханның Аккаладан имамнарны озатуы да шуннан. Йосыф кахан Харәзем әмире белән тыныч яшәргә тели. Бу сәясәтнең каханның чираттагы хәйләсе икәнен ахмак кеше генә белмәсә белмәстер, Ислам туган. Ә бит мондый хәл булган инде, гарәп сәргаскәре килгәч, кахан ислам динен кабул иткән була, гарәпләр китүгә, яңадан үз диненә кайта. Харәзем әмире моны белә булса кирәктер, өлкән равва оештырган гади кармакка эләкмәс дип уйлыйм мин. Сәясәтенең җитдилеген күрсәтү өчен, кахан исеме белән өлкән равва каханбәге Сабирны бер төмәне белән шул тарафка җибәрер, башта каханбәк угыз ханына тукталыр, аның белән килешү төзер, ахыр Харәзем әмиренә юнәлер...

— Сез, Булат бәк, сарайда булган бар нәрсәдән дә хәбәрдар булгансыз икән.

— Сарайда ул-бу шылт иттеме, ышанычлы кешеләрем иң әүвәл миңа җиткерәләр иде, табиб Ислам, миңа...

* * *

Барысын да алдан сөйләшкәнчә хәл иттеләр. Булат бәк бериш халык белән елга буенда калды, ә Ислам дүрт яугир һәм Булат бәкнең улы Хәбир белән Саксин каласына юнәлделәр. Максатлары калада булган хәлләрне белү иде. Кузгалыр алдыннан Булат бәк улы Хәбирне үз кырына дәшеп алды.

— Улым, син калага кермәссең, табиб абыең гына узар. Табиб ич ул, аны кем дә туктатмас.

— Ә ук-җәяләр?

— Ук-җәясен синдә калдырып торыр. Искәрдеңме?!

— Искәрдем, атам.

— Искәрсәң, Аллага тапшырып кузгалыгыз. Имин юл сезгә.

Ярты көн дә үтмәде, алар Саксин каласының басу капкасы янына килеп туктадылар. Капкадан олау узып бара иде, бераз көтеп тордылар. Шулчак Исламның башына бер уй килде, яугирләрне дә, Хәбирне дә калага алып кермәскә, үзе генә керсен һәм табиб йөзендә. Бит моны Булат бәк тә шулай теләгән иде.

— Егетләр, Хәбир энем, сез хәзер берара китәсез дә атларыгызны чирәмгә җибәрәсез, тышаулап түгел, ә тезгеннәрен бәкәлләренә бәйлисез дә минем каладан чыкканым көтәсез. Искәрдек!

— Искәрдек! — диде барысы өчен дә Хәбир углан.

Ислам көлемсерәп куйды һәм олау үткәнне көтте дә капкага таба кузгалды. Капканы үтеп бара иде инде, каравылчы өеннән берәү чыкты.

— Һәй, Исраил баласы, кай тарафка, кайдан?

— Болгар базарына!

— Кемең югалттың анда? Болгар базары сүтелде һәм бер Болгар базары гына түгел. Бар да каланы ташлап китә башлады, угызы-баҗае, грегы-әрмәне. Менә соңгы олау китте, әрмәннәр, Казаннан кайталар. Син кем соң, ни югалттың?

— Мин табиб, Болгар ханы табибы улы Ислам.

Баш сакчы булса кирәк, чөнки үтә койты сөйләшә иде, болдырдан төште, Ислам янына ук килде.

— Күтең ияреңә ябышмагандыр бит, кордаш?

— Юк анысы.— Ислам атыннан төште, баш сакчыга сәлам юллады һәм болдырга чыгып баскан тагын өч сакчыга күз төшереп алды.— Мин табиб.

— Ишеттем,— диде баш сакчы коры гына.— Кай тарафтан, кай тарафка сәфәрең?

— Ханбалыктан Болгарга дип чыккан идем. Әйтәм бит, Болгар ханы табибы улы мин.

— Табиб, димәк. Менә минем ярам сызлый. Дунай буе сугышында алдым. Кайчак чак кына һава алышынса да, төннәр буена йоклый алмый чыгам.

— Син аңа, бәвелеңдә кайнатып, кыр әреме төнәтмәсе сөрт, югандай итәр.

— Бәвелгә салып күпме кайнатырга соң?

— Табак-чуен төбендә бер бармак калынлык калганчы.

— Һы,— диде баш сакчы, янә бер тапкыр Исламны баштанаяк күздән кичереп.— Бар барасы җиреңә, тик озын-озак йөрмә. Тукта! Ханбалыкта ниләр бар?

— Мәхшәр анда, кордаш, мәхшәр.

— Тагын угызлар яу килделәрме әллә?

— Юк, бу юлы ниндидер кыргый варяглар диме...

— Аларны сөннәтле казаклар тиз турарлар. Бар инде, йөри бир,— диде, ниһаять, баш сакчы.

Ислам атына атланды, җилле генә Болгар базарына таба юнәлде. Базар капкасына җитәрәк күрде, шул тирәдә өч-дүрт сөннәтле казак урала. Ислам тиз генә атын кире борды. Кала капкасы янында аны янә баш сакчы туктатты.

— Тпру, туктап тор. Базарда ни күрдең?

— Сөннәтле казаклар...

— Сиңа моннан таю әйбәтрәк булыр, кордаш. Рәшидә абыстай да базарга гына узам, дигән иде, сөннәтле казакларны күргән дә шундук кире борылды.

— Нинди Рәшидә абыстай? — диде Ислам, атыннан төшә-төшә.

— Нинди булсын, хан кызын Йосыф каханга илтеп биргән абыстай. Ул да Болгарга кайтып бара иде, бире кагылды, ләкин сөннәтле казакларны күргән дә коты алынган.

— Кахан казакларымы соң алар?

— Болары кахан казаклары түгел, өлкән равваның сөннәтле казаклары. Өлкән равва Ибраһим кул астындагы казаклар мөселманнарны каладан куарга килгәннәр.

— Син кем соң?

— Мин кахан хезмәтчесе, каханга хезмәт итәм, ягъни өлкән раввага, кордаш.

— Рәшидә абыстай арбада үзе генә идеме?

— Үзе генә иде кебек. Мин инде шушындый олуг кешене тикшереп тормадым. Тизрәк тай моннан, дидем дә җибәрдем. Әйе, сиңа да шул киңәшне тотарга кирәк, табиб. Сөннәтле казаклар белән өлкән равваның ышанычлы кешесе идарә итә. Ә ул монда, калада...

Ислам сикереп атына атланды, чаптырып капканы үтеп китте. Ишләре, ул килә-килүгә, ат менгәннәр иде инде, күрәсең, ияләренең чаптырып килүеннән үк аңлаганнардыр. Хәбир янына килеп туктауга, Ислам аңардан кылычын, җәясен, садагын, укларын сорады. Хәбир кып-кызыл булды, колаклары ут кебек яна башлады.

— Уклар кая?

Яугирләр көлештеләр, ә Хәбир күзен күтәреп карарга кыймый, борын астыннан гына:

— Төлкене куа киткән идем... Ала алмадым.

Ислам көрсенеп куйды.

— Атаңа бу хакта әйтсәм, беләсеңме ул сине нишләтә, Хәбир?

— Мин гаепле, гаепле, Ислам абый... Кичер...

— Ярый, кузгалдык! Безгә ашыгырга кирәк.

Атын юырттырып юлга төшүгә, Ислам Хәбир белән булган хәлне онытты да, аның бөтен уй-хисен Рәшидә абыстай биләде. Нишләп йөри Рәшидә абыстай, Болгарга кайтамы? Үзе генәме?.. Айбиби кая? Аккалада калдымы? Калса, ни өчен калды?.. Кахан җибәрмәдеме?.. Айбиби сүзе теленә килүгә, шундук күз алдында Идел буе, ап-ак күлмәк кигән Айбиби, аккошлар килде.

Ул арада алда олау күренде. Чаптырып килү җаеннан, Ислам алдан килгән олау каршына туктатты, туктатты да, аттан сикереп төшеп, атлар тоткан баш олаучыдан сорады.

— Булат бәк кая?

Олаубаш каерылып, артына карады, икенче арбада барган Булат бәккә таба ишарә ясады. Ул арада арбадан Мөслимә абыстай төште, Хәбир әнисе арбасы янына килеп туктаган иде инде, аттан төшкән улын әнисе кочагына алды һәм кычкырып елап җибәрде. Исламның йөрәге кысылып куйды. Ни булды?! Булат бәк кая? Аның башына килгән беренче уй шул булды. Хәбир әнисе кочагыннан ычкынды да, чирәмгә утырып, ике кулы белән җирне төя башлады. Ислам Мөслимә абыстайга, аның яшьле күзләренә карап алды да Хәбир янына килде.

— Ни булды, Хәбир?

— Әтине һәм аның яраннарын варяглар үзләре белән алып киткәннәр... Аккалага таба...

Алар янына олаубаш килде һәм Исламга барысын да тәфсилләп сөйләп бирде.

— Булат бәкне яраннары белән көймәләренә утыртып, Аккалага алып киттеләр.

— Кемнәр?

— Варяглар, баскынчы пиратлар, юлбасарлар. Аларның бирегә беренче тапкыр гына килүләре түгел инде. Киткәндә Булат бәк әйтте, Болгарга туктап тормагыз, туры Казанга китегез, Гаязетдин тархан каласына. Юлбасарлар Болгарда булганнар инде. Шәмгун хан аларны кальгага уздырмаган, бик каты орышканнар.

— Атың ничек, олаубаш?

— Садретдин мин, табиб Ислам, Садретдин.

— Әйдә, кузгат олавың, Садретдин агай. Юл кешесенең юлда булуы хәерле. Казанга. Булат бәк әмере — миңа аткан уктыр.

Баскынчы варяглар ат көтүенә кагылмаганнар, әмма һәр көймәгә өчәр сарык суеп ташлаганнар. Олаубаш хак булса, Булат бәк әйткән, имеш, аны әсир итмәделәр, ул әсир түгел, аны тылмач йөзендә алып китәләр... Бик ихтимал, Булат бәкне юлбасарлар тылмачлары итеп тә алганнардыр. Тик нигә аның егермеләп яугирен алып китәргә?..

Ислам Мөслимә абыстайны тынычландырды, Хәбирне үзе белән алды һәм юлыбызны дәвам итик, дип, олауга кузгалырга боерды. Бер көн эчендә аның башына меӊ төрле бәла төште. Шул ук вакытта күңелен Айбиби биләп алган иде, Рәшидә абыстай янында Айбиби дә булганмы? Булса, нигә аны баш сакчы күрмәгән?..

— Әйе,— диде барыр җайда Хәбир үсмергә Ислам,— без монда булган булсак, мәнсез варяглар безне дә әсир итеп алып киткән булырлар иде. Менә нәрсә, Хәбир, әйдә без яугирләр белән алдан китик, көн авышып килә, әнә теге инеш янында кунып китәрбез. Олау килгән арада, без ут ала торырбыз, туктар өчен яхшы урын эзләрбез.

Һәм шулай иттеләр дә. Тугайрак урында тукталылар, коры-сары җыйдылар да ут алдылар. Олау килеп җиткәндә, дөрләп ут яна иде инде.

— Ислам абый,— диде Хәбир углан.— Әнә теге әрәмәлек артында үрдәкләр бакылдыйлар. Шунда барып килим әле, бәлкем...

— Ничә угың калды?

— Ике.

— Димәк, ике үрдәк аласың,— дип елмайды Ислам. Аның кинаясен аңлап алган Хәбир, учакка агачлар ташлый башлады.— Бар, син башта атларны эчер, күн капчыкларны ал да су китер.

— Әйе шул,— диде Хәбир һәм ат иярләренә таккан күн капчыкларны алды да әкрен генә елга буена таба китте. Үсмер китергән суны атлар бик тәмләп эчтеләр, Хәбир аларның маңгайларыннан сыйпады: «Тагын китеримме, эчәсезме тагын?» — дигән булып, атлар белән сөйләшеп алды.

— Елга еракмы?

— Якын, әрәмә артында гына. Анда аккошлар да төшкән иде.

Аккошлар сүзен ишетүгә, Исламның йөрәге «жу» итеп китте һәм янә Идел буенда суга кереп аккошлар белән сөйләшкән Айбиби күз алдына килде. Шунда күңеленә якын сүзләр туды.

Баш очымнан очкан аккошлардан
Сиңа сәламнәрем юлладым,
Йөрәк мәхәббәтем язар өчен,
Каурый каләмнәрем тапмадым.
Аккошлар ашатканда,
Сиңа тиңнәр булмады,
Алмагачлар утыртсам да,
Сандугачлар кунмады.
Мәхәббәтем югалттым дип,
Башым ташка орыйммы,
Дәрвиш хәлләренә төшеп,
Сагыш җыруым җырлыйммы?..

Ялгыз калганда адәм баласы сагышка бирелүчән икән. Чарасыз калыр дәрәҗәгә җитеп, ашмас хыялларыннан нидер өмет итеп йөрүен бераз абайлый иде Ислам. Ләкин бит ул адәм баласы. Әнә шул кеч-кенә җыру да аның күңеленә өмет, юаныч китерде. Олау да килеп җитә инде, учак дөрләп яна, ә Исламның күңеленнән Айбиби китми. Ул арада кай тарафтандыр кара болытлар килеп чыкты, күк йөзен кургашындай авыр болытлар томалады. Яңгыр болытымы дип, Ислам күккә карады. Юк, бу кара болыт кына түгел, җир йөзенә ниндидер афәт килә сыман. Курку юк иде, күк күкрәп, яшеннәр яшьнәтеп, коеп яуган яңгырларны күргәне бар аның. Тик бу болыт тоташ ташкынны хәтерләтә. Көтүләре белән олау килеп җитсә, шушында ышыкланып шалашлар ясарга булыр дип уйлап куйды Ислам, һәм тирә-якка карады. Болын җәйрәп ята, әрәмәлекләр, әмма ник бер эре агач заты күренсен.

Ислам учакка берничә эре-эре коры-сары ташлады да Хәбиргә кычкырды:

— Хәбир, мин олауга каршы киттем. Учакны сүндерә күрмә!

— Ярый, ярый, Ислам абый,— диде ике кулына ике капчык тоткан Хәбир.

— Мин олауга каршы барам. Күрәсең, бик каты яңгыр килә,— дия-дия, Ислам олауга таба чапты.

Учак яккан төшкә килеп җитәрәк, эре-эре яңгыр тамчылары тама башлады. Килә-килүгә, атларны туардылар да, болынга ашарга җибәреп, арбаларны киез белән бөркергә керештеләр. Күчмә халыкның яңгырдан качар өчен бердәнбер чарасы киез белән капланган бериш булган. Олаубаш Садретдин атларны җибәрүгә, хезмәтчеләрнең берсенә чыбыркы бирде.

— Башта елга буена төшеп атларны эчерәсең, аннары болында утлатасың.

Көтүче егет атларны елгага таба куып алып китте, сарык көтүчесе дә малларын шунда таба куалады. Ирләр учак өстенә казыклар кагып, аркылы агач куеп, казан аскан арада, олаучы Садретдин көтүдән тотып калган өч сарыкны чалды, тиресен тунап, тиреләр өстенә итләрне кискәләп куеп, хатын-кызларга дәште. Хәбир капчык артыннан капчык белән елгадан су ташыды. Яңгыр бер читкәрәк киттеме, бераз дөбердәп, юлчыларны куркытып алды да туктады. Ләкин офыкта янә болытлар күренде. Мал чалган олаубаш офыкка карап-карап алды да:

— Иртәгә килер бу яңгыр, Алла саклый күрсен, бик хәтәр күренә,— диде.

— Авызыңнан җил алсын, олаубаш,— диде аңа бер пешекче хатын.

Сарык ите казанда гөбер-гөбер кайный башлады, учак янына урнашкан кешеләргә тәмле ит исе килеп житте, ашказанын җилкендереп, тамак кычытып куйды. Теләсәләр-теләмәсәләр дә алар әкрен генә казан аскан учак тирәсенә җыела башладылар.

— Сабыр, сабыр, балакайлар,— диде аларга өлкән бавырчы.— Аз гына сабыр итегез. Хәзер итне алабыз да дөге салабыз. Дөге озак пешми ул, миңа әрәмәгә төшеп, чәй өчен үләннәр җыеп китерегез.

Өлкән бавырчы хатын әйтерсең лә гомер буена аш пешергән иде, һәммәсен дә нәүбәтләп казанга сала барды: тозын, борычын, суганын, хәтта кишерен дә турап салды. Менә шунда инде чынлап та тамак кытыклап кына калмады, ашыйсыны китереп, авыз сулары килде. Өлкән пешекче апага:

— Буламы инде ашың, Мәрхәбә апа,— диючеләр булды.— Эчтә бүреләр улый башлады.

Мәрхәбә апа яугир егетләргә карап алды һәм олаубашка:

— Садретдин, Садретдин, дим, бир үзләренә бот сөякләрен, кимерә торсыннар,— диде.

Уен-көлке белән табынга утырдылар, тамаклары ялгангач, су буена төшеп, казанны юып менделәр дә чәй кайнатырга булдылар. Чәй дигәненә нинди үлән тапсалар, шуны салып җибәрделәр. Мәтрүшкә дә, җир җиләге яфраклары да, карлыган яфраклары да, хәтта кемдер табып китергән бөтнек яфраклары да бар иде, моның өстенә иң соңыннан чин сәүдәгәрләреннән алган чәй салдылар. Табынга зур коштабак белән бал китерелде. Баллап төрле үләннәрдән кайнатылган чәйне эчтеләр дә рәхмәтләрен әйтә-әйтә таралыша башладылар.

— Әнием, Мәрхәбә апа ашны шулхәтле тәмле пешергән,— диде Хәбир.— Рәхмәт аңа. Чәй дә бик тәмле булды.

— Ә балы, балы? — диде көлә-елмая пешекче апа.

— Балы тел йотмалы булды,— диде Хәбир һәм баласын имезеп утырган яшь киленчәккә күз ташлап алды.

* * *

Иртән бик иртә кузгалдылар. Көн бик сәленке иде, күк йөзен кара болыт томалаган, көнбатыш тарафыннан кара болытлар белән бергә күңелгә шом төшкән иде. Ислам үсмер Хәбирне олаубаш янында калдырды да яугирләре белән барасы юлны карап елга буйлап китте.

Елганы кичәргә кичү эзли торгач, алар бер көтүчегә тап булдылар. Саерак кичү турында сорадылар.

— Кинәле елгасында адым саен кичү, кордашлар. Чак кына өстәрәк атлап чыгардай кичү бар. Мин малларымны шул кичү аша чыгарам,— диде.

Берара киткәч күрделәр, чынлап та сай гына кичү. Ислам бер яугирен олауны шул тарафка китер, дип җибәрде дә аръяк чыкты.

— Табиб Ислам, без Болгарда нишләрбез? — диде яугирләрнең берсе.

— Мин сезне хан сараена бирермен. Тора-бара өйләнерсез. Ышаныгыз, сезне хан рәнҗетмәс.

— Безнең Хазарстанда ата-аналарыбыз калды, табиб Ислам.

— Яугирләрме сез, туганнар? Яугирләр. Сезгә үзегезгә гаилә корырга вакыт инде. Болгар кызлары дөнья төркиләренең йөзек кашлары. Каханыгыз белән ни булды әнә...

— Кырык хатынын куып, бер Айбиби хатын белән калды. Бу хакта беләбез белүен дә...

— Иң мөһиме, мин сездән канәгать, туганкайлар. Сезне безгә меллагыз биреп җибәрде. Башта үз вазифагызны җиренә җиткереп үтәгез — Булат бәкнең гаиләсен Болгарга илтеп калдырыгыз, диде. Аннары ни дигәннәр әле борынгы бабаларыбыз? «Юлга чыкканда иптәшең синнән юмартрак булсын»,— дигәннәр. Сез әлегә кадәр минем өчен әйбәт юлчылар булдыгыз. Болгарга күп калса, өч-дүрт көнлек юл калды. Иншалла, исән-имин кайтып җитәрбез.

— Сөннәтле казаклар очраса?

— Сөннәтле казаклар бүреләр түгел, ашамаслар.

— Димәк, сөннәтле казаклар — этләр.

— Син хаклы, яугир, сөннәтле казаклар — этләр, бүре — мөстәкыйль җанвар. Беркемгә дә буйсынмый торган җанвар. Безнең борынгы бабаларыбызның бер кавеме бүреләр тамгасын йөрткән. Әнә олау да килеп җитте. «Әйдәгез, кичүне чыгарышыйк»,— дип, Ислам кичүгә таба китте, аңа икеләнә башлаган яугирләр иярделәр.

Олауны кичүдән чыгарып, юл кузгалганнар гына иде, шаулап яңгыр ява башлады. Яңгыр шул чиккә җитеп шаулап яуды ки, олау туктады, сарыклар олау тирәсенә елышты, атлар аптырап калгандай тын гына басып тордылар. Ләкин яңгыр ничек килгән булса, шулай үтеп тә китте. Үз күзләре белән күрделәр, әле генә чыккан кичү тәмам юкка чыкты, елга ярларына кадәр тулышып ага башлады.

Яңгыр туктап, юл кузгалгач, Хәбир углан Ислам белән янәшә атын атлатты.

— Ислам абый, Йосыф каханның Айбиби хатыны Казанга киткәндер, Рәшидә абыстай белән бергә.

Исламның колаклары торды.

— Син моны каян беләсең?

— Әнинең ахирәте ишектә сакта торучы бер агайның хатыны. Күрше агай исә анда булган барлык яңалыкларны да хатынына җиткерә тора, ә тегесе әнигә сөйли.

— Сине кем укытты?

— Башта раввалар, аннары имамнар. Әти әйтә, раввалар үз куллары белән үзләре төзегән дәүләтне җимерәләр. Җимерә башладылар да инде, диде. Мин әтием белән еш кына шул хакта бәхәсләшә идем.

— Карап-карап торам да, Хәбир туган, сиңа кахан сараенда гына эшлисең калган икән.

— Ә нигә, болай килеп чыкмаган булса, эшләгән дә булыр идем, Ислам абый. Бер равва әтигә әйткән иде: «Малаең үтә дә ушлы, Булат бәк, без аны сарайга хезмәткә алырбыз»,— дип, тик әти, әллә нигә мәктәптән алып, мәдрәсәгә күчерде.

— Кайсысында уку кызыграк иде соң?

— Белем алу кызык түгел, Ислам абый. Мин мәктәпкә дә, мәдрәсәгә дә кызык өчен йөрмәдем, белем алу өчен йөрдем.

— Гафу ит, Хәбир туган, гафу ит. Син акылың белән зурларча фикер йөртәсең, ә кылган гамәлләрең балаларныкы.

— Бәхәсләшмим, бу шулай. Мин бер тапкыр pавваны да шаккатырган идем. Нигә, мин әйтәм, хөрмәткә ия раввам, сез китапка табынасыз, ә без Аллаһы Тәгаләгә? «Китап — белем чишмәсе,— диде равва.— Ә Аллаһы сине дөнья күтәргә өйрәтә. Ә дөньяны китап укымый күтеп булмый». Нигә соң сез, яһүдләр, китапның һәр хәрефе өчен төннәр буена бәхәсләшәсез? «Яһүдне китап шулай тәрбияли, олан. Тыңла мине, әгәр дә мәгәр яһүд адәменә иртәгә үтә куәтле давыллы яңгыр явачак, ә син яһүд булганга күрә исән калачаксың, дисәләр, яһүд, аяк астындагы җир убылса да, шул төбәктә басып торачак. Иң гаҗәбе, ул адәм баласы исән калачагына ышаначак, Булат бәк улы»,— диде миңа равва. Шуның өчен сиңа да Яхвага ышанырга, китапка табынырга кирәк, диде. Һәм миңа төрки телдә Тәүрат китабын биреп җибәрде. Мин ул китапны беренче битеннән азагына кадәр тәфсилләп укып чыктым. Һәм миндә, Ислам абый, адәми зат булганым өчен горурлык хисе туды. Һәр кылырга теләгән гамәлемне Тәүраттагы гыйбрәтләргә таянып кыла башладым. Ә инде мәдрәсәгә күчкәч, Аллаһы үгет-нәсихәтләрен үзләштердем. Һәм инандым, бу китапларның икесе дә — Тәүрат та, Коръән дә дөньяда яшәгән адәм баласына кирәкле вә зарур китаплардыр. Равва әйтә торган иде, без, яһүдләр, бабаларыбыз сипкән ташларны җыярга дип, Хазарстанга килдек, дип.

— Искитмәле, Хәбир, искитмәле. Мин сине, Болгарда каласы итсәң, имам хәзрәтләренә сарай мәдрәсәсенә мөгаллим итеп тәкъдим итәчәкмен.

— Олуг хан, Мөхәммәд хан вафат. Ил башында Дунайдан килгән Шәмгун хан утыра. Аның кем икәнен син дә, мин дә белмим, Ислам абый. Сабыр итик, язмыштан узмыш юк, дигәннәр борынгылар.

— Синең Йосыф кахан белән дә сөйләшкәнең булдымы?

— Булды, мәдрәсәгә күчәргә ул миңа киңәш бирде. Син ике халыкның да телен дә, динен дә белергә тиешсең, диде.

— Хатыны Айбибине дә...

— Юк, Ислам абый, минем аны күргәнем булмады.

— Менә Йосыф кахан сине якын иткән, киңәшен биргән, ә соңра атаңны зинданга ташлаткан.

— Чарасыздандыр. Хак булса, өлкән равва аңа бау салырга җыенган, ләкин Йосыф кахан көтмәгәндә ил белән үзе идарә итә башлаган. Бусы инде мин киткәч булган хәл, бу хакта миңа атам сөйләгән иде.

— Асыл егет, акыллы кеше булып китәрсең син, Хәбир туган. Язмыш аермаса, иншалла, без бергә булырбыз. Бит мине атам сарай табибы итеп хәзерләгән иде. Мин синең белән юлга чыгуыма мыскал да үкенмим. Акыллы юлдаш барган юлыңа ак җәймә җәяр, ахмак юлдаш кырлы таш түшәр, ди.

— Ислам абый, Ислам абый, карале,— диде, артына каерылып,— безне кемнәрдер куа килә.

— Көтеп алабызмы, каршы барабызмы, Хәбир?

— Кораллы кешеләр булса, көтеп алыйк, кораллары булмаса, каршы барыйк, Ислам абый.
— Ә олау?
— Олау йөри торсын. Әнә көн тагын ямьсезләнә башлады.
Шулвакыт Хәбир кычкырып җибәрде:
— Ислам абый, әти бит бу, алдан чабучы, әти, минем әти!..

**XVII**

Арбага җигелгән атлар сабыр гына атлый. Күчәр башында утырган ат тотучы йокымсырап бара. Айбиби куенына кереп йоклаган балага бага. Бала мышный-мышный йоклый. Имә дә йоклый, имә дә йоклый. Ә Айбибинең күзенә йокы керми. Үткән төндә дә рәтләп йоклый алмады. Аны тәмам уй басты. Ние белән, кай сыйфатлары белән Йосыф каханны үзенә генә карата алды ул. Кырык төндә кырык хатын белән йоклаган кахан, кисәк барысыннан да баш тартып, аның белән генә торып калды. Нәкъ шул хәлдән соң сарай раввалары аны гына түгел, каханның үзен дә күралмый башладылар. Ярый әле Рәшидә абыстай өлкән равваны акылы белән дә, ягымлылыгы белән дә тынычландыра алды. Аннары балага Ибраһим исеме кушу да өлкән раввага ошады бугай. Бала да тапкач, Йосыф кахан исә Айбибигә кайнап ябышты. Бу хәлгә сарай куштаннары гына түгел, хәрам атакайлар да, исләре китүен сиздереп: «Балакай, әллә инде Аллаһы коесыннан су эчеп үстең»,— дип шаяртырлар иде, гәрчә Айбибинең кем кызы булуын яхшы белсәләр дә. Дөресен генә әйткәндә, ул үзе дә Йосыф каханга булган мәхәббәтенең асылына төшенеп җитми иде. Йосыф каханның мәхәббәте аңа, аның мәхәббәте каханга ничекләр туды, ни өчен икесе дә яратыштылар да, ни өчен икәүдән-икәү генә калдылар, моңа кайсысының фәрештәләре ярдәм итте — Айбиби белмәде. Тик бернәрсәне ачык абайлап — Йосыф каханны ул ятакта гына түгел, тормышта да яратты. Шушы давыллы мәхәббәткә беренчеләрдән булып өлкән равва игътибар итте. Әйе, нигә Йосыф балакай бер Айбиби хатынга гына тартыла да, нигә һәрдаим нәүбәтсез шул хатынны гына ятагына тарттыра?.. Сарайдагы борынгы тәртипләрне бозган өчен, өлкән равва буйсынмый башлаган каханны ефәк бауга хөкем итәргә тиеш иде. Ә ул итмәде дә итмәде. Хәтта Йосыф каханга яуга чыгарга да рөхсәт итте, хәтта яубаш йөзендә, гәрчә аның кырында тәҗрибәле каханбәк Сабир торса да. Өлкән равва, яудан кайткач, Йосыф кахан йөкле хатыны Айбиби янына бармас дип өметләнеп торган иде. Шул сәбәпле раввалар җыенында ефәк бау турында сүз дә кузгатмады. Ә менә яудан исән-имин әйләнеп кайтуга ук, Айбиби хатынны ятагына тарттыргач, өлкән равва бер мәлгә югалып калды. Җитмәсә, тарафдары булган раввалар: «Йосыф кахан бабаларыбыз кануннарын боза башлады, ни көтәбез?» — дип әйткәләсәләр дә, алар сүзенә колак салмады. Ул һаман: «Хатын балык түгел, балык ите дә туйдыра»,— дип сабыр итәргә булды. Ә инде Айбиби хатын таштай-тукмактай кап-кара күзле, нәкъ Йосыф каханга охшаган угыл бала тапкач, моның өстенә хатыннарын да кудыргач, өлкән равва чарасыз калган берәүдәй йөри башлады.

Моны барысы да күрделәр, хәтта Айбиби өлкән раввадагы үзгәрешне сизеп алды. Ләкин ни дип уйларга белмәде. Чөнки сарай һәм дәүләт дилбегәсен ир канаты Йосыф үз кулына алды. Дөньяга билгеле булган яһүд сәүдәгәрләре дә, илгә килгән илчеләр дә әүвәл өлкән раввага кереп, баш иярләр, шуннан соң гына каханга узарлар иде. Сарайда тора-яши янә шуны аңлады Айбиби: өлкән равва аны кил-килүгә өнәп бетермәде. Өлкән равва да Айбиби хатын алдында тәүге кыюлыгын югалтты. Моны да ачык күрде Айбиби, сукыр түгел иде. Алай да бер тапкыр очрашкач әйткән иде: «Йосыф балакайны чынлап та яратамы Айбиби хатын?» Бу юлы инде Айбиби каушый калган иде, шулай да әйтте, җавапсыз калмады: «Исраил мәмләкәтенең өченче патшасы Давыт улы Сөләйман пәйгамбәр бу хакта болай дигән, өлкән равва: «Һәр адәм баласын — гаделне дә, гаделсезне дә, игелеклене дә һәм явызлык кылучыны да, чистаны һәм нәҗесне дә, корбан чалучыны да, чалмаучыны да бер үк язмыш көтә; гөнаһсызга ничек булса, гөнаһлыга да шул язмыш; ант итүчегә дә, ант итәргә курыкканга да бер үк төрле язмыш. Кояш астында кылынган һәр гамәлнең яхшы һәм начар ягы да шул: һәркем бер үк язмышка дучар булыр; адәм балаларының күңелләре һәм гомер итәсе көннәре явызлык һәм акылсызлык белән тулыдыр; ни генә кылсалар да, алар көннәрдән бер көнне әрвахлар аймагына китеп барырлар. Ә терекләре һәрчак өметтә калырлар, чөнки үле арысланнан тере эт адәми затлар өчен хәерлерәк; тереләр үләчәкләрен беләләр, ә үлеләр бернәрсә дә белмиләр инде, үлеләр өчен дөньялыкта әҗер юк, алар хакында инде хатирә-истәлекләр дә җуелып беткән булыр. Аларның мәхәббәтләре дә, нәфрәтләре дә, дөнья көтү өчен сарыф иткән көчләре дә мәңгегә юкка чыккан булыр; кояш астында кылынган бер генә гамәлгә дә вә эшкә дә аларның катнашлары булмас. Шулай булгач, Аллаһы синең хезмәтләреңә разый чакта, рәхәтләнеп биргән икмәгеңне аша һәм шат күңел белән шәрабыңны эч. Өстеңдәге кием-салымың һәрдаим ак вә пакь булсын һәм синнән тәмле хушбуй исләре килеп торсын. Кояш астында сиңа язган гомернең барлык фани көннәрен сөйгән затың белән бергә рәхәт яшәп уздыр, чөнки кояш астындагы гомерең һәм тырыш хезмәтеңнән килгән байлык сиңа насыйп булган үз өлешеңдер. Хәл, көч-куәтеңнән вә кулыңнан килгәнен барысын да эшләргә тырыш, чөнки анда, син керәчәк кабердә, эш тә, уй-ният тә, белем дә, зирәклек тә булмас. Иң хәтәре, кеше үзенә тиешле Аллаһыдан бирелгән вакытны алдан белми, белә дә алмый.

Балык һәлакәте — җәтмәгә барып керү, кош афәте тозакка эләгү булган кеби, адәм балалары да көтмәгәндә пәйда булган бәла-казалардан ерак йөрмиләр»,— дигән Хазарстан мәмләкәте өлкән раввасы бәни хөрмәткә ия Ибраһим»,— дип сүзен җөпләде Айбиби.

Ни гаҗәп, өлкән равва аңа авыз ачып бер кәлимә сүз дә әйтмәде, борылды да китә башлады... Айбиби күрде, сизде, ә бит өлкән равва аның белән сөйләшергә, аны куркытырга дип килгән иде. Тик нигәдер әйтер сүзен әйтмичә, китеп барды. Айбиби аның бөкрәя төшкән аркасына карап калды. Аңа дәшәсе, аны туктатасы итте, әмма туктатмады. Сөләйман пәйгамбәр сүзләре белән ул аңа барысын да әйткән иде инде.

Әйе, ул Хазарстанга курка-курка, кызыксыну аша курка-курка килгән иде. Курыкмаслык та түгел иде шул — кырык хатын булган каханга тарттырдылар ич! Ә менә кырык хатыннан арынып, Йосыфҗаны белән бер тән, бер җан булып яши башлагач, сөю-назлауның кызыгы бетәр кебек тоелган иде, әмма алай булмады, аларның мәхәббәтләре яңадан дөрләп кабынып китте. Бит Йосыфы назлаганда, ул тәмам күгәрчен кебек гөрли башлар иде. Якынлык кылганнан соң, Айбиби үзен ялгызагын көймәгә салып, елга буйлап агызып җибәрелгән кешедәй тояр иде. Көймә чайкала-чайкала шуа, ә аны кемдер күккә чакыра кебек, зәңгәр күктә йөзгән ак болытлар дәшә сыман. Аһ ул төннәр!..

Айбиби, хатирәләреннән арынып, баланы күкрәгенә кыса төште. Күңел түрендә Йосыф каханга беразгына үпкә дә бар сыман, шул ук вакытта күкрәк түрендә сагышлы хатирә дулкыннары да тулгана иде.

Әллә белеп, әллә нидер сизенеп, иртәгә-берсекөнгә Болгарга таба кузгалыр алдыннан, Айбиби Аккошлар култыгына төште. Аны күрүгә, ялгызак аккош ашыга-ашыга янына йөзеп килде, килде дә кинәнә-кинәнә түгәрәк ясап йөзә башлады, ә үзе бертуктаусыз саубуллашкандай башын иде. Ә бит, аккошкаем, нидер сизенгән булган, Айбибинең китәсен сизгән. Ничекләр, ничекләр сизгән ул аны?.. Сагышланган да кебек, янына суга да дәшә сыман, әмма һични кыла алмавын да сизә. Ә Айбиби аны аңламады, аккош тикторганда су өстендә канатларын җилпи-җилпи биергә кереште. Ул да түгел, йөгереп китеп, һавага күтәрелде, аның колак яныннан ук канатларын чажлатып очып узды һәм күздән язды. Айбиби һични аңламады. Кинәт аның күзләре яшь белән тулды, ахыр үкси үк башлады. Ахыр елады-елады да чатырга кереп ятты һәм шундук йокыга да китте.

Өнеме, төшеме — аңламады. Имеш, ул янә Аккошлар култыгында басып тора. Болгардагы кебек ап-ак күлмәктән, аякларында кызыл болгари итекләр, башында зәңгәрсу аксыл яулык. Кинәт яулыгы иңнәренә төште, канатларга әверелде. Шунда кайдандыр аккош килеп чыкты һәм аны үзе белән дәшә башлады. Айбиби исә күпме генә канатларын җилпемәсен, очып кына китә алмый бит. Ни гаҗәп, кинәт канатлары тагы да үсте һәм ул судан йөгереп барды да һавага күтәрелде. И-и Ходаем, аккош бит мин, аккош!..

— Айбиби, Айбиби,— диде аңа берәү.

Айбиби бик акрын уянды, әмма күзләрен ачмады.

— Айбиби балакай, балага ятып барасың бит, балага. Бир, урынына салыйм.

Менә кайчан уянды Айбиби һәм баланы Рәшидә абыстайга бирде.

— Әллә төш күреп ята идең инде?..

— Мин, аккошка әверелеп, биеккә-биеккә һавага күтәрелдем, абыстай...

— Шатлыкка бу, шатлыкка,— диде Рәшидә абыстай, баланы күчереп сала-сала.

«Нинди шатлыкка?» — диде үз-үзенә Айбиби. Бит ул көнне аңа җиткерделәр — бер каракош ул яраткан аккошның түшен ярган һәм ботарлый башлаган. Айбиби Йосыф кахан янына йөгерде. Юк, чатырдан чыгуы булды, каршында Йосыф кахан пәйда булды.

— Айбиби, Айбиби,— диде ир канаты,— Айбиби.

— Ни булды, Йосыфҗан?..

— Сагынып килдем,— диде Йосыф кахан,— баланы, сине. Ярамыймы?

— Нигә ярамасын, ярый, ярый, этием,— диде атасына бала дәшкәндәй итеп Айбиби.

...Әнә кайчан ук ул миңа Болгарга озатырга теләве турында әйтергә килгән булган, дип уйлады Айбиби һәм арбаның япмасын ача төшеп, далага карады.

Моңсу булып китте аңа. Кахан әйткәнчә, башта Ханбалыкка чыктылар, аннары аларны Алпар йөзбаш кабул итте. Әнә шулай алар Болгарга таба кузгалдылар. Олауны кабул иткәндә, йөзбаш Алпар аның белән баш кагып кына исәнләшкән иде, олы юлга төшкәч, егет, Айбиби утырган арба янына килеп, хәлен сорады:

— Бик селкетмиме, каханбикә?

— Юк, рәхмәт сезгә, йөзбаш.

— Сезне Болгарда көтәләр, һәрхәлдә, Шәмгун хан юлда озын-озак уралма, диде. Биләргә күчеп китмәгән булсалар,— диде йөзбаш.

Арба түреннән, бала йоклаткан җирдән, Рәшидә абыстай телгә килде:

— Алпар йөзбаш, Болгарда көчле яңгырлар явып үткән дигән хәбәр иреште, хакмы шул?

— Булды, яр кырындагы өйләргә кадәр агызып алып китте. Идел ярларыннан чыга язды. Аллага шөкер, калага кермәде... Иншалла, олавыбыз зур түгел, озын-озак уралмабыз,— диде йөзбаш Алпар һәм арба яныннан җилле генә атын юырттырып кузгалды.

Айбибигә янә моңсу булып китте. Ни өчен Йосыф кахан үзе озатмады аларны. Һичьюгы, Ханбалыкка кадәр озатсын иде. Ул үзен әле болыннан өзеп, юл өстенә ташлаган чәчкәдәй хис итте, бер әкәм-төкәм шикелле эченә кереп бикләнде. Рәшидә абыйстай да, Айбибинең хәлен белгән сыман, берни дә сорашмады, сүз башларга да кыймады. Айбиби исә уй җепләрен янә Йосыф каханга ялгап җибәрде. Аккалага килә-килүгә, баш хатын да булып киткәч, күлмәкләрен дә көнаралаш алыштыра башлады. Баш хатын буларак аны яраттылар, аңа сокландылар, зурладылар. Айбиби моны бөтен барлыгы белән тойды. Күлмәкләрне аңа Болгар тегүчеләре җибәреп торырлар иде. Купшылык, гүзәллек, матур киенү аның үзенә дә ошый иде. Айбиби хатын узганда, сарай куштаннары аның артыннан карап калырлар, соклануларын яшермичә, ай-һай, дип, башларын чайкап куярлар иде. Каханбикә ләбаса! Моның өстенә Йосыф кахан, яудан кайткач, сарайда бер Айбиби хатынны гына калдырды. Шул хәлдән соң сарай куштаннары алдында Айбиби янә бер башка үсте. Хәер, төрки кызлары борын-борын заманнардан ук чуар киенергә, купшы-кылтыйрак йөрергә ратканнар. Мөхәммәд атасы сөйләве хак булса, борынгы Кытай императоры Цыймасин төрки кызлары киенгән кебек киенеп йөргән чин кызларын Кытай дивары аша гуннар иленә куган. Имеш, бозмасыннар борынгы чин бабаларының гореф-гадәтләрен. Чин кызларының да матур итеп киенеп йөриселәре килгән, аякларына агач калып киеп йөриселәре килмәгән. Агач калыбны кызларының аякларына Кытай императорлары, аяклары кечкенә булсын дип, унҗиде яшькә кадәр көчләп кигергәннәр, кем дә кем күрше гуннарның бизәкле күн итекләрен кия, ул кызны гуннарга биреп җибәргәннәр. Соңра Кытай кызлары үзләре үк төрки-гуннар хатын-кызлары киемнәрен киеп, базарларга чыга башлагач, император фәрманы белән илдән күпләп китә башлаганнар. Император, имеш, болай халык китә башласа, илдә кызларыбыз да калмас дип, хатын-кызларына төркиләрнең аяк киемнәрен дә кияргә рөхсәт иткән. Дала төркиләре бер чиннар белән генә түгел, фарсылар белән дә сәүдә иткәннәр һәм Ефәк юлын үз кулларында тотканнар. Бу хакта да аз-маз хәбәрдар иде Айбиби. Болгарга Кытай сәүдәгәрләре атлас тукымалар, чәй, алмалар белән бергә, Шайтан каласында коелган һәм каланың кальгаларына куелган туплар өчен дары да китерерләр иде. Дарыны хан сатып алыр, Айбиби атасы янына кереп, Кытай сәүдәгәрләренә карап торыр, ә алар исә Айбибидән күзләрен дә алмаслар иде. Сәүдәгәрләрне атасы кабул иткәндә, Айбиби алар янына ялтыравык күлмәкләр киеп, аягына кызыл болгари итек элеп, кашларын каралтып, керфекләренә сөрмә тартып, уң битенә һинд сәүдәгәрләре китергән миңне ябыштырып чыгар иде. Сәүдәгәрләр аны күрерләр иде дә тәмам өнсез калырлар иде. Бирегә — Аккалага тартылгач та хәрам атакайлардан алып сарай куштаннары вә хезмәтчеләргә кадәр, Айбиби үткән-сүткән саен: «Саумы, Айбиби хатын, хуш киләсез, Айбиби хатын!» — дия-дия, бил бөгеп калырлар иде. Иң гаҗәбе, Айбиби Аккаланың өлкән руханые белән үзен тиң күрә башлады. Очраган саен бәхәскә керде, үз сүзен һәрдаим өстен чыгарырга тырышты.

Менә егерме көн инде алар юлдалар. Хәзер инде үзе дә, бала да юлга өйрәнә башладылар. Айбиби көннәр буена арба япмасын ачык тотты, табигатькә карап бара башлады. Һәр сәгать вә минут саен алышынып торган күренеш аның дикъкатен үзенә җәлеп итте, булган хәлләргә карата истәлек-хатирәләрен оныттырып торды.

Бүген дә көн үтеп бара икән инде, кичкә таба авышып килә, кошлар төн кунарга елга буендагы тирәкләргә таба очалар. Кисәк кенә барысын да бер читкә куеп, кемнеңдер арба тәгәрмәче шыгырдый башлый, шуңа эче пошкан олаубаш, әйләнеп:

— Кара аны, малай актыгы, ыстан туктагач, көпчәгең майланган булсын! — дип кычкыра.

Ул арада арбаларга җиккән атлар, бер-берсе белән сөйләшеп алгандай пошкырышып куялар.

Арбаның түр ягыннан Рәшидә абыстай дәшә:

— Айбиби, баланы имезеп аласыңмы әллә, уянды, боргалана башлады.

— Бир монда, ул да табигатькә карап барсын. Менә күзем ала алмый барам, Болгарга якынлашабыз бит инде, үз якларыбызга.

Айбиби дәшми генә баланы кулына алды, изү бавын чишеп, балага имчәк каптырды. Бала ике кулы белән әнисенең күкрәгенә чытырдап ябышты.

— Авырттырасың бит, улым, улыкаем! — диде аңа Айбиби. Бала гүя анасын аңлады, бармакларын җибәрә төште.— Ачыктыңмыни, улыкаем? Әйт әле, нинди төш күрдең?.. Әйтмисеңмени?..

— Имә дә йоклый, имә дә йоклый, сабый, килеште үзенә юл,— диде Рәшидә абыстай.

Айбиби дәшмәде, тик бернәрсәне аңлады, алар Болгарга кайталар, ары таба Казанга үтәрләр. Барысын да Йосыф кахан кушканча эшләрләр. Тагын Йосыф кахан тел очына килеп кунды. Нигә шулай борчый ул аны, нигә хәтерен бимазалый?.. Килер ул, аларны Казанга ук килеп алыр.

— Рәшидә абыстай, Бозаулыктан Казан еракмы?

— Бер атналык юл кала, бер атнадан Казанда булырбыз, иншалла, балакай. Алпар йөзбаш Кенәле елгасы буенда туктарбыз, диде.

— Без Болгарга кермибезмени, абыстай?

— Олау кермәс,— диде Алпар йөзбаш.— Теләсәң, без кереп чыгарбыз. Атаң каберен күреп, зиярәт кылырбыз. Туганың Гаязетдин дә безне көтә. Кахан аңа сөенчесен җибәрде, безне Мишә елгасына килеп каршы алырга кушып әмер җибәргән.

— Нигә мин бу хакта белмим, абыстай?

— Бала муенында ни дә, үз муенында ни, балакай. Килер ул безнең арттан, килер, балакай. Бала муенына ул бөтине тиккә генә тагып җибәрде дисеңме...

— Мин курка башладым, анакай. Хазарстанда орыш-фәлән булса...

— Анысы инде Ходай кулында, Ходай ни язган булса, шул булыр, балакай.

— Атам вафаты турында хәбәр дә итмәделәр, анакай.

— Кияү сине борчырга теләмәде, балакай, мин дә. Үлгән артыннан үлеп булмый. Әнә хәзер Болгар тәхетендә Шәмгун хан утыра, ди. Атаң утыртып калдырган кардәш дунайлылардан. Алпар йөзбаш әйтә, баскынчы варягларны кальга-калага уздырмаган, бик күпләре кала дивары буенда ятып калганнар.

Бала бер гамьсез күкрәгеен имә, ә анасы эчендә хәсрәт уты көйри. Күз алдына янә Йосыф кахан килеп баса. Хәрби киемнән. Кальга диварларында туплар, сарай тирәсендә сөннәтле казаклар арлы-бирле йөриләр, шунда ук раввалар, сарай куштаннары. Сарай гүя умарта оясы иде. Бу күренешне сиртмәле арбага утырганда гына күз угында тотып калды Айбиби. Нинди мәхшәр килә иде Аккалага? Айбиби белә дә, белми дә иде.

— Абыстаем, әйт әле, Йосыф кахан миңа сер итеп кенә, Аккалага өлкән равва викингларны дәшкән, диде, хакмы бу, син белмәдеңме?

Рәшидә абыстай Айбибидән моны көтмәгән иде, аның янына ук күчеп утырды.

— Хак та, хак та түгел, өлкән равва миңа: «Абыстаем, без моны бер табында хәл иттек»,— диде.

— Димәк, сез атам үлеме турында да, викинглар килүе хакында да алдан ук белгәнсез һәм шуңа безне ашыга-кабалана Йосыф кахан Болгарга озатты...

— Хак сүзгә җавабым юктыр, балакай. Ләкин моны кахан чарасыздан кылды, сезне саклап калырга теләде. Соңгы көннәрдә Йосыф кахан берәүгә дә ышанмый башлады, равваларына да, өлкән раввага да... Шуңа күрә, кинәт исенә килгәндәй, ил белән идарә итүне үз кулына алды. Сарайдагы Харәзем имамнарын өлкән равва куасы иткән, булачак табында шул хакта сүз катасы иде, ә Йосыф кахан моны аңардан алдарак кылды, ил дилбегәсен үз кулына алды. Мин белмим, балакай, викингларның Хазарстанга килүләре ни белән бетәр, ләкин явыз баскынчылардан мәнфәгать көтмим, Йосыф каханның ни теләгәнен белмим. Аның өлкән равва кул астыннан чыгасы килде бугай. Моннан күп еллар элек гарәп хәлифәте сәргаскәре Мәрван каханны җиңә, далага кадәр куа, ләкин ары барырга курка, әмма каханга илчеләрен җибәрә. Ислам динен кабул ит, мин сиңа илеңне дә, әсир ителгән гаиләңне дә, халкыңны да кайтарырмын. Кахан риза була. Шундук кахан туктаган ыстанга унлап имам килеп төшә. Кахан ислам динен кабул итә, иленә кайта. Әмма күп тә үтми, имамнарны куып җибәрә, кире үз диненә кайта.

— Нинди дингә?

— Тәңре диненә.

— Бит хәзер кахан яһүд диненә табына...

— Табына да, табынмый да, Харәзем әмиренә ислам динен кабул иттем, дип ышандырса да, яһүд раввалары уратып алган Йосыф һични кыла алмады, сарайдагы имамнарны куып җибәрергә мәҗбүр булды һәм Ханбалыктагы мөселманнарны да.

— Имамнарны да Йосыф кудымыни?

— Мин сиңа алай дип әйтмәдем, балакай. Ул аларны кунак итеп, илләренә генә озатты, безне озаткан кебек. Хәер, безне ул атаңа дип җибәрде, әмма соңгы чиктә безне Казанга юнәлергә боерган. Мин үзем шаһит.

— Тагын кабатлыйм, анакай, нигә син боларның берсен дә миңа әйтмәдең?

— Әйтсәм әйтим инде, балакай, без өлкән равва белән никах укыттык. Имам хәзрәтләре укыды.

Айбиби, күзләрен зур ачып, Рәшидә абыстайга карады. Ул аңардан берни дә сорамады. Сорар әмәле калмаган иде. Дөресрәге — оялды. Соңыннан гына, Кенәле елгасына җитеп, ыстан туктагач кына:

— Син аны яраттыңмы, абыстаем? — диде.

Рәшидә абыстай арбадан төште, Айбибигә төшәргә ярдәм итте һәм, хезмәтче хатын кулыннан баланы алгач:

— Адәм җанының адәм җанына сыенырга теләве нәҗеслеккә керми, балакай. Мин никахсыз аның кырына ятмадым, Аллаһы алдында күңелем пакь,— диде.

Нәрсә әйтә ала иде Айбиби. Һични! Абыстай хаклы иде.

— Әллә соң казан аскан җиргә кадәр җәяүләп атлыйбызмы, абыстаем?— диде Айбиби.

— Әйдә соң,— диде битараф бер халәттә абыстай.

«Ни хакым бар минем аңа үпкәләргә! Ни хакым!» — дип, үз-үзен орышты Айбиби.

Алар казан аскан төшкә җиткәндә, кояш баюга таба тәгәри иде инде.

— Аш пешкән, киезгә ашъяулык җәйгән, әйдәгез ашап-эчеп алыгыз да су буена төшеп менәрсез. Монда шундаен матур,— диде пешекче апа.

Ашап-эчкәч, Айбиби тынычлана төште. Нигә әле ул кырык яшен яңа тутырган җиләктәй абыстаеның эчке тормышына тыкшына! Ахмакмы әллә син!.. Гафу үтен син аңардан, кичерүен сора, ике затның бергә кавышуы гөнаһмы!

Су буена төшкәч, Айбиби учлап-учлап су алды да битенә бөркеде һәм шуннан соң тагын да тынычланып киткәндәй булды.

Шулвакыт ул ары табарак, камышлар янында аккошларны күрде. Күрде дә, өнсез калып, аягүрә басты, үзе дә сизми: «Би-би, би-би, би-би»,— дия башлады.

Әмма аңа игътибар итүче булмады. Аккошлар шактый еракталар. Ә инде алар кырына үтәргә Айбиби кыймады, анда таллыклар аша барасы. «Мин аларны иртән-иртүк килеп күрермен»,— дип, үз-үзен юатты Айбиби.

* * *

Юл газабы — гүр газабы, диләр, алай да ай ярым дигәндә мең бәла белән Болгар күренде. Басу капкасына җиткәч, алар арбасы янына Алпар йөзбаш килеп җитте.

— Мин калага керергә киңәш итмәс идем, каханбикә,— диде ул, кала читендәге яндырылган өйләрне күреп.— Каланы викинглар талаганнар булса кирәк.

— Минем әтиемнең каберен күрәсем килә, йөзбаш Алпар.

— Мин сезгә бер арба белән генә керергә киңәш итәр идем, курыкмагыз, озатырга унбашым бирермен, ягъни ун яугирем.

Айбиби Рәшидә абыстайның күзләренә карады, ягъни, нишлибез?

— Керәбез,— диде Рәшидә абыстай.— Борчылма, йөзбаш, без озак тормабыз.

— Яхшы, абыстай.

Алпар йөзбаш ун яугирен чакырып алды, сиртмәле арбадан артык әйберләрне бушаттырды да, күчәрбаш биреп, бала белән Айбибигә утырырга кушты. Рәшидә абыстай икенче як ишектән кереп утырды.

— Кузгал. Аллага тапшырдык, күчәрбаш...

Кала аларны колач җәеп каршы алмады. Басу капкасында сакчылар да юк. Бу хәл Айбибине борчуга салды. Йөзбаш Алпар олауны басу капкасыннан да уздырмады. Яр буйларыннанерактарак өйләр исән калган булсалар да, нигәдер ул өйләрнең ишегалларында да, базар куышына утыртылган кибетләрнең дә ишекләре богау йозагында иде. Иң сәере, ник бер кеше урамнарда күренсен. Чатта утырган мәчетнең дә баскычлары җимерек, бер-ике келәм мәчет ишеге янында ята. Рәшидә абыстай күчәр башында утырган егеткә туктарга кушты. Җилле генә төште дә мәчеткә таба китте, ачык ишектән сагая калып эчкәре үтте. Биредә бар нәрсә дә таланган, идәннәр шәп-шәрә иде. Димәк, юлбасар викинглар мәчеттәге келәмнәрне алып киткәннәр, икесе баскычта төшеп калган, каракның көче җитмәгәнме... Рәшидә абыстай, догасын укый-укый:

— Әйдә, оланнар, кальга-калага,— диде.

Кальга-калада, ягъни хан сарае капкасында, ике сакчы тора иде, алар, Болгар яугирләрен күрүгә, капкаларны ачтылар. Сакчыларның берсе Айбибине танылымы, Рәшидә абыстайнымы, аларны күрүгә, күкрәгенә кулын куеп, баш ия-ия эчкәре уздырды. Рәшидә абыстай ханнар каберен белә иде, күчәрбашка шунда барырга кушты. Атлар челтәрле тимер коймага җитеп туктадылар. Әүвәл арбадан Рәшидә абыстай төште, аннары Айбиби, арбадагы карачы хатын Айбибигә баланы бирде. Бала уяу, як-ягына карый, әйтерсең лә нидер аңлый, нидер күрә иде. Ханнар зиратында уткойрыклар очынып йөри, чиркылтыйлар, ул да түгел, каяндыр килеп чыккан саескан шыркылтап ала. Шушы тавышларгамы борчыла балакай, дип уйлады Айбиби. Тимер капка янында ап-ак сакаллы бабай күренде.

— Тукта, тукта, кемне күрәм, Рәшидә абыстай түгелме, ә син, балакай, син — Айбиби, хан кызы Айбиби!

Карт, кабалана-кабалана, тимер капканың богау йозагын ачты, кунакларны, зират кылырга килгән баласын күтәргән хан кызын алдан уздырды.

— Саумы, бабакай!

— Саумы, саумы, иминме, балакай. Бәби белән үк кайтып төштегезме?

— Бәби белән, бабакай.

— Атаң кабере түрдәрәк, әнә теге миләш үскән җирдә,— диде карт һәм үзе үк алдан китте.

— Балаңның аты ничек соң? — дип сорады зират сакчысы карт.

— Ибраһим,— диде Айбиби.

— Пәйгамбәребез исеме икән,— диде карт.

Ниһаять, кабер янына җиттеләр. Кабергә җитүгә, Айбиби баланы карачы хатынга бирде дә, ике тезенә төшеп, белгән догаларын укыды. Рәшидә абыстай да аннан калышмады.

— Хатын-кызга бик зиратка узарга кушмыйлар да,— дигән булды зират карты. Айбиби аның учына ике дирһәм салды һәм, шуны гына көткән кебек, карт кабер янындагы түмәргә утырды да дога кылды.

Айбиби ары таба үтте, әтисе Талиб каберенә. Ул анда тезләнеп кенә калмады, үлән баскан кабер туфрагын кочаклады һәм эченнән: «Тыныч йокла, әтием, тыныч йокла, кызың сине онытмады, онытмады...» Ахыр белгән догаларын укыды, бер уч туфрак алды да, кулъяулыгына төреп, түшенә куйды.

Кире басу капкасына таба кайтканда, җимерелгән өйләрне, ишекләре каерылып ачылган, таланган кибетләрне күреп, Айбибинең җаны сыкранды. Һәм аның кайчандыр гөрләп торган базарлары, халык тулы урамнарының бушап калуларын күреп, тизрәк бу каладан чыгып китәсе килде. Һәм шулай иттеләр дә. Каладан чыгуга, йөзбаш Алпар олауны Казан юлына төшерде, шуннан соң гына Айбиби арбасы янына килде.

— Айбиби каханбикә, калада халык калмаганга шаккатмагыз, халык, нигездә, Биләргә — эчкәрерәк, баскынчы викинглар күзеннән ераграк җиргә күчеп китте. Су юлы белән йөриләр бит викинглар, яссы төпле баркаслары белән елга комлыгына кадәр чыгалар.

— Моңсу, кала бушап калган, илгә афәт килгән, каланы күреп чыктым, күңелем шом белән тулды. Ул каһәр баскынчылар Казанга да кергән булсалар, йөзбаш?

— Казанның кальгасы тау башында, каханбикә. Баскынчы викинглар бер тапкыр гына килмәделәр инде Болгарга. Кальгага үтә алмадылар. Әле дә йөзләрчә яугирләре кальга дивары буенда ятып калдылар. Кальганы Шәмгун хан бирмәде, акырып-бакырып ябырылып килгән дошманнар өстенә туплардан аттылар. Шул хәлдән соң Шәмгун хан башкаланы Биләргә күчерергә булды. Халыкның күбесе инде күчеп тә киткән. Безнең янга кар базында качып калган бер карт килгән иде, шул сөйләде. Казан тарафларына да күчеп китүчеләр булган икән, каханбикә Айбиби. Шәмгун хан сарай куштаннарын гына түгел, үзе белән хезмәтчеләрен дә, төзүчеләрен дә алган икән.

— Без дә кузгалыйк, әрвахларыбыз рухына дога кылдык, атам-анамның каберен күрдек, изге гамәл кылдык.

— Мин дә Талибымны күргәндәй булдым, балакай,— диде Рәшидә абыстай, арбага таба кузгала-кузгала.

Әмма Айбиби аның сүзләрен ишетмәгәнгә сабышты, әле булса янында басып торган йөзбаш Алпарга:

— Без дә кузгалыйк, йөзбаш,— диде.

Әнә шулай хан кызы Айбиби ерак Хазарстанны ташлап туган якларына әйләнеп кайтса да, биредә калмады — язмышы аны Болгар дәүләтенең чиге сыман булган Казан каласына алып китте.

* * *

Өч көннән соң гына олау Чулман елгасына килеп җитте, мең бәла белән аръякка чыктылар һәм яр өстендәге чирәмлектә төн кунып китәргә булдылар. Бериш халык Алабуга авылына юнәлде, аннан ике чиләк сөт, катык алып килделәр һәм бер капчык көлчә-ипи алып кайттылар. Айбиби балага сөт эчерәсе иткән иде, Рәшидә абыстай каршы төште.

— Синең үз сөтең дә савып алырлык, балакай. Эчермә, эче бозылып куюы бар, килешмәс дим. Сабый гына бит әле ул, сабый гына.

Айбиби янына йөзбаш Алпар килде.

— Каханбикә, безне Мишә елгасы ярында Гаязетдин тархан көтәргә тиеш. Һәрхәлдә, Йосыф кахан миңа шулай дигән иде. Ул анда Аккошлар күле янында сезгә утар салдырткан икән.

Мишә елгасына җитә алмадылар. Бик көчле яңгыр яуды, туктап, яңгыр туктаганны көттеләр һәм шунда ниндидер чишмә буенда төн кунарга булдылар. Яңгырдан соң һава сафланып киткән иде, Айбиби, хатын-кызлар аш пешергән арада, чишмә янына төште, учына салкын чишмә суы җыеп, рәхәтләнеп су эчте. Һәм баласы чишмә суы яратканны искәреп, пешекчеләр янына менде, агач табак алып, балага су эчерәсе итте. Әмма моны Рәшидә абыстай күреп алды һәм коты алынып:

— Балакаем, нишләвең бу! Салкын чишмә суы ла! Баланың тамагына тиюе бар. Китер, җылытып китерим. Җиз савыт бар, учак янып тора.

Суны җылытып китерде, әмма бала нигәдер судан йөзен чөерде.

— Анасының сөтен сорый,— диде карачы хатын.

Айбиби киезгә утырды да баланы, кулына алып, туйганчы имезде. Имеп туйган бала, әнисе белән сөйләшкәндәй, э-э, мә-мә, дигән булды.

— Әннә, диген әле, Ибраһим улым. Әннә, диген.

Әмма бала һаман бер авазны кабатлады: «Ә-ә, мә-ә».

Ләкин хәтта шушы аваз да Айбибинең күңелен күтәреп җибәрде. Ул арада чишмә янындагы әрәмәлектән карачы хатын бөрлегән җыеп китерде. Һәм савытка салып юды да Айбибигә бирде.

— Каптырып кара әле шуны балага, Айбиби.

Айбиби бер бөрлегәнне алды да бала авызына каптырды. Башта бала һични аңламый йөзен чытты, аннары авызын мәзәк итеп чапылдата башлады.

— Ошады бөрлегән, ошады,— диде Айбиби кинәнеп.— Аша әле, улым, аша, оҗмах җимеше бу, оҗмах җимеше.

Бала тагын ике бөрлегән ашады. Олылар барысы да кинәнделәр.

Гаязетдин тархан Йосыфҗан турында горурланып сөйләгән икән. Бу хакта ишеткәч, Айбибинең күңеле иренә карата йомшара төште. Юк, ул безне кумады, ул безне кунакка гына озатты. Шулай бит, улым, әти безне кунакка гына озатты бит, диде Айбиби, арбага утыргач, улының киң итеп ачылган чемкара күзләренә карап. Ләкин Гаязетдинне күз алдына китерә алмады. Йосыфка охшаган булса, каратутсыл йөзле, кара чәчле булырга тиештер. Ләкин аңа анасы Сара аксыл-җирән чәчле, яшел күзле, дигән иде Йосыфҗанны. Айбибигә бер хәрам ата җиткергән иде инде, кайчандыр, өлкән равваның хатыны бер төрки бәгенә ябышып качкач, өлкән равва тол калган Сара каханбикәнең кулын сораган, имеш. Әмма каханбикә Сара аның белән сөйләшергә дә теләмәгән, икенче көнне үк вафат булган Айгөл килененең улы Гаязетдинне алган да Таман тарханы Гали иленә китеп барган. Һәм Гаязетдин балигъ булганчы бер тапкыр да Хазарстанга әйләнеп кайтмаган. Әнә шулай Гаязетдин углан Таман тархан төбәгендә үскән, яхшы мөгаллимнәрдән белем-сабак алган, хәтта, фарсыларда, грекларда йөреп, азмы-күпме тел өйрәнгән икән...

Икенче көнне, Мишә елгасына җиткәнгә кадәр, Айбиби шул хакта уйланды. Йосыф каханның улы Гаязетдин Казанда, анасы Сара да анда булса кирәктер. Ир канаты Йосыф каханның улы Аккош күле янында утар күтәрткән, өй-йортлары, каралты-куралары белән. Димәк, әйткән сүзе хак булса, ул аларны — улы Ибраһим белән хатыны Айбибине — шуннан килеп алачак... Куанычлы хәбәр иде бу Айбиби өчен. Тик әллә нигә барыбер күңел төпкелендә шик саклана. Нигә ул, аның җанкисәге, шул хакта Хазарстанда ук әйтмәде?! Ни өчен яшерде?! Үзенә, аңа, балага бөтиләр ясаткан, димәк, аерыласыларын алдан ук белгән, ә бәлкем, мәңгегәдер...

Күр инде, нинди уйлар гына килми бу күңелгә юл барганда... Ә Аккошлар күленә көтү-көтү аккошлар төшә икән, шунда бибиләрен чыгаралар, дип кинәндерде Айбибине йөзбаш Алпар. Йөзбаш үзе дә шул яклардан икән. Аккошлар! Аның ялгызагы да шул күлдән түгелме икән, шушында югалтмадымы икән ишен?.. Ни генә булмасын, бу хәбәр ирешкәч, Айбибигә күңеллерәк булып китте. Һәм йокы аралаш күкрәген имгән баланы кыса төшеп: «Без синең белән, улым, Аккошлар күленә төшәрбез, аларны ашатырбыз. Ишетәсеңме, улым, Ибраһим, дим. Күзләреңне ач инде, болай да юл буена диярлек йоклап кайтасың. Казанга якынлашабыз әнә, Гаязетдин абаңның каласына. Ул анда таш кальгалар эчендә мәһабәт сарайда утыра, диделәр. Без аларга барырбыз, әбиеңне күрербез, Сара әбиеңне. Ул синең сөннәт горурлыгың күрер, шатланыр...»

Айбиби шулай диде дә бу хәлнең булуына шикләнеп куйды. Сара ана, Йосыф кахан тәхеттә утырганда, бер тапкыр да дияргә була, улы янына кайтмый, Гаязетдин оныгы белән илдән илләргә йөри, хәтта изге җирләре Исраилгә барганнар, дип тә әйткән иде Йосыфы.

Көнләшеп куйды бугай улыннан Йосыфҗаны. Әмма Айбиби моңа бөтенләй игътибар итмәгән иде. Әнә шул улын Йосыф кахан Болгар тәхетенә күтәрергә уйлаган иде, әмма атасы Мөхәммәд хан өлгеррәк булып чыкты — ил тәхетен Дунай тарафларыннан килгән угланга васыять итә. Рәнҗеде бугай бу хәлгә кияве, әмма бу кайгы аның өчен кайгы булмаган булса кирәк. Чөнки кахан буларак сизә-тоя — тәхете селкенә башлады. Айбиби моны сизмәде, ә менә Йосыфы сизгән — өлкән равва аннан котылырга теләгән, баш бирмәгән Йосыфны бер селтәнүдә юк итәргә. Чарасы бер — ефәк бау.

— Бик сагышка батып кайтма әле, балакай,— диде Рәшидә абыстай, Айбибинең уйга калуын күреп.— Аккошлар шушы төбәкләрдә бибиләрен чыгаралар. Рәхәтләнеп ашатырсың...

Айбиби бертын дәшми торды. Һәм уйлады: «Соң, биредәге аккошлар янында аның Йосыфы булырмы? Күл буеннан аны кулына күтәреп кем алып кайтыр, Рәшидә абыстаем, кем?..» Йөрәк сыкравы иде бу, ни әйтергә белми гаҗизләнүдән иде. Иллә ни әйтә ала ул Рәшидә абыстаена. Һични! Шулай да җавапсыз калмады:

— Без бергәләп ашатырбыз аларны, абыстаем-анам, бергәләп,— диде һәм йокыга киткән баланы аңа сузды: — Мәле баланы, абыстай, бераз атлап барыйм, әллә нигә аякларым оеп китте.

Рәшидә абыстай да, күчәрбаш кырына ук күчеп утырган карачы хатын да елмаешып алдылар. Казанга якынлашып киләләр ич инде, гомер итәсе төбәккә. Анда Аккошлар күле, анда алар өчен мәһабәт нарат-чыршы урманы эченә салынган йорт-каралты, зур бер утар. Һәм ул утарны Йосыф кахан аларга дип салдырырга кушкан, Казанда тархан булып утыручы улы Гаязетдингә — Казан тарханына.

## XVIII

Мишә елгасын иртәнге якта кичтеләр. Барысы да кичеп беткәч, Казан яклап бер төркем атлыларны күреп, йөзбаш Алпар Айбиби арбасы янына килде.

— Тархан Гаязетдин бу, каханбикә Айбиби.

Ни өчен Гаязетдинне күрмәс борын ук Айбибигә каушау килде. Аларга таба җилле юыртып җайдаклар килә, инде якынаеп та киләләр. Айбиби арбадан төште, аның артыннан Рәшидә абыстай, һәммәсе дә казанлыларны көттеләр. Алданрак килгән җайдак, олауга җитәрәк, атын чаптыра ук башлады. Менә аларны инде, бигрәк тә алдан килүче җайдакны, Айбиби ап-ачык күрә, шушы җайдак якынайган

саен, ул үзендә гасабилану тойды, ахыр ни кылырга белми, әле Рәшидә абыстайга, әле баланы тотып арбадан төшеп килгән карачы хатынга карады һәм, каударлана төшеп:

— Бир әле кулыма баланы, бир әле! — дип, карачы хатынга таба кузгалды. Баланы кулына алып, килүче җайдакларга борылып каравы булды, аһ! итте. Аларга таба, нәкъ ул баскан арба кырына таба, йа Ходаем, Йосыф кахан үзе килә. Айбиби: «Йосыфҗан!» — дип кычкырырга иткән иде, Алпар йөзбаш инде арба янына килеп җитәр-җитмәс атыннан төшкән Гаязетдин тарханга:

— Рәхим ит, галиҗәнаплары Гаязетдин! — дип, Казан тарханын каршы алды. Гаязетдин аның белән күреште, Рәшидә абыстайга күкрәгенә кулын куеп баш игәндәй итте һәм Айбиби янына таба килә башлады. Айбиби тораташтай катып калды, чөнки аның алдында кулын балага сузган, суеп каплагандай Йосыфы тора иде. Гаязетдин тархан, аңа килеп җитәр-җитмәс, бары тик бер адым кала туктады һәм бер тезенә төшеп, борынгы төркиләрчә Айбибигә сәлам юллады, һәм күтәрелде дә якын ук иелде, җофар юрганга төргән балага үрелде. Айбибинең башы әйләнеп китте, гүя балага Йосыфы үрелгән иде.

— Җиңгәчәй,— диде ап-ачык итеп Гаязетдин тархан.— Җиңгәчәй, төкле аягыгыз белән Казан җиренә. Бирегез, бирегез әле энемне үземә, багыйм әле булачак баһадирга...

Айбиби баланы аңа бирде, вәләкин үзе баскан җирендә кинәт җиргә таба иелә башлагандай итте. Моны күреп, Рәшидә абыстай аның култык астыннан эләктереп алды.

— Айбиби, Айбиби! — дип, аны уятып җибәрде.

— Аллага шөкер, сезне күрер көнебез дә бар икән,— диде Айбиби.

— Күрдегез, күрдегез, җиңгәчәй. Менә без дә сезне күрдек,— диде һәм егетләренә: — Олауны алып китә торыгыз! — дип боерды.

Рәшидә абыстай, Айбибинең колагына үрелә төшеп:

— Ни булды сиңа, балакай? — диде.

Менә кайчан ихлас күңелдән, инде аек күздән беренче тапкыр Гаязетдин тарханның йөзенә бакты Айбиби. Һәм янә әллә нишләп китте. Йосыф бит ул, Казан төбәгенә килеп чыккан Йосыфы! Шул чиккә җитеп бер-берсенә охшарлар икән. Йа Хода! Күзләре дә, карашы да Йосыфныкы кебек чем-кара, йомры сакалы да хәтта, тик бераз кечкенәрәк кенә, ә тавышы — игезәк балаларда да бу хәтле охшашлык булмыйдыр. Әллә соң Гаязетдин бала Йосыфныкы түгелме, игезәк балалар тапканмы Сара каханбикә?..

Ул арада Гаязетдин Йосыф тавышы белән артында басып торган җан сакчыларына:

— Казан асыгыз, бераз чәйләп алыйк, шуннан соң кузгалырбыз. Шулаймы, җиңгәчәй? — дип, баланы анасына бирде.

Айбиби аның белән килешеп баш какты.

Баланы кулына алуга, булган хәлгә бөтенләй башка күз белән карады Айбиби. Әйе, бу кеше Йосыфҗаны түгел, аның улы Гаязетдин тархан һәм ул аларны каршы алырга килгән, бериш яугирләре белән. Тик Айбиби һаман исә аңына килә алмый тора. Күр инде, гәүдә-сыны да Йосыфныкы бит...

— Киез җәелде, табынга узыгыз, җиңгәчәй,— диде аның янына ук килеп Гаязетдин тархан.

Күзләренә бакты да Айбиби бөтен тәне буйлап тетрәнү узуын тойды.

— Әйе, әйе, абыйсы, без хәзер,— дип, Айбиби каушавын тыярга теләп, арба артына баласын пес иттерергә дип кузгалды.

Баланың җофар юрганын Рәшидә абыстайга бирде, Рәшидә абыстай: «Бир баланы, үзем бушандырыйм»,— дисә дә, баланы бирмәде, аңа бераз гына тынычланырга, җилкенгән күңелен тыярга кирәк иде. Йосыф булып, шулай кыланса, дигән уен күңеленнән куарга итте, әмма бу уй күңелгә кереп оялаган иде инде. «Бит ул сакалны бераз кыркырга да була»,— дип, Айбиби һаман тәүге шиген нигезләргә тырышты, гәрчә күңеле белән Гаязетдин тарханның Йосыфы түгеллегенә инанган булса да.

Кызыл һәм саргылт төскә шакмаклап сугылган ашъяулык тирәли чәй эчәргә утыргач та, Айбиби юк-юк та Гаязетдин ягына карап алгалады. Юк, аның Йосыфы түгел бу кеше, кыланышлары башка, сөйләгән теле дә катырак, Таман тархан төркиләренең сөйләменә тартым. Тик шуңа карамастан Айбибигә Гаязетдинне күргәч күңеллерәк булып китте. Ул хәтта юлда булган бер хәлне дә сөйләп бирде, әмма каушый төшеп. Гаязетдин тархан аны бирелеп тыңлады, нигәдер туп-туры карап, дикъкать белән. Һәрхәлдә, нииндидер томан эчендә тулганган Айбибигә шулайрак тоелды.

Ары таба, чәй эчеп юл кузгалгач, Гаязетдин тархан Айбибидән сорады.

— Туры утаргамы, әллә булмаса Казан аша барабызмы, җиңгәчәй? — диде.

Айбиби, баланы тотып, янәшәсендә утырган Рәшидә абыстайга таба борылды.

— Утарда бар да хәзерме соң, Гаязетдин углан?

— Барысы да хәзер, абыстай, барысы да. Хезмәтчеләр дә, карачылар да, сакчылар да анда инде. Атна буена барысын да хәстәрләп, көтеп торалар.

— Алайса, Гаязетдин, безне туры Аккошлар утарына илтегез инде.

— Аккошлар күле янындагы утарга, Айбиби җиңгәчәй,— дип, атын куа төшеп, алдан китте Гаязетдин.

— Уф Аллам,— диде Айбиби уфтанып.— Рәшидә абыстай, барысы да чынмы бу, безне чынлап та Гаязетдин тархан каршы алдымы?..

— Бик матур кеше, әдәпле сөйләшә, җиңгәчәй, дип кенә тора. Иншалла, барысы да әйбәт булыр, балакай. Рәхмәт инде кияүгә, әллә кайлардан яу йөреп кайтса да, улына хәбәр иткән, ә Гаязетдине үтенечен аяк астына салмыйча, утар кадәр утар салдырган, хәтта хезмәтчеләрен дә булдырган.

— Җитмәсә, утары куе нарат урманы эчендәге Аккошлар күле янында икән, абыстаем.

— Сине, балакай, хәрам атакайлар әйтмешли, фәрештәләр үпкәннәрдер, фәрештәләр. Хазарстанга килә-килүгә кияүне нишләттең инә. Кырык хатыннан аерып алдың, кырык хатыннан. Өлкән равва Ибраһим әйтте, Айбиби хатын гына шул көнгә калдырды Йосыф каханны, диде.

— Ничек шул көнгә, абыстай?!

— Бәй, кырык хатыннан аерып алдың түгелме соң Йосыфың!

— Мин аермадым аны, ул үзе аерып җибәрде, абыстаем.

— Йә хуш, без үз дигәнебезгә ирештек, балакай.

Кеше еш кына үз эченә кереп бикләнә икән. Айбиби үз язмышын үзе ясадымы? Юк ич, юк! Аны Йосыф каханга барырга атасы Мөхәммәд хан мәҗбүр итте. Аңа беркем дә кирәкми иде әле, аның хәтта күзе төшкән егете дә юк иде. Ул гүя иреккә җибәрелгән сайрар кош иде. Айбиби баланы имезергә кулына алды. Бала тынычсызланган кебек боргалана, нидер көтә сыман. Бу балада аның һәм Йосыф каханның каны. Кара күз, чак кына озынчарак йөз, юка иреннәр. Кара шул баланы, үстер, тәрбиялә кеше йөзендә, әгәр дә мәгәр тәҗрибәле мөгаллимнәрдән сабак алса, югалмас, дөнья арбасыннан төшеп калмас, иншалла. Айбиби үз-үзен шулай дип тынычландырса да, имчәк каптырып, бала имә башлагач, кинәнеп үк куйды. Аның баласы бар, яраткан кешесеннән тапкан улы. Казан төбәгенә кайтабыз. Рәшидә абыстай әйтмешли, барысы да әйбәт булыр, иншалла. Агач күперлән Казан елгасын уздылар. Күперне чыгуга, алар арбасы янына янә Гаязетдин тархан килеп китте. Имеш, барысы да әйбәтме, туктап ял итмисезме?.. Юк, берсенең дә туктыйсы да, ял итәсе дә килми иде. Казан елгасы артта калгач, бертын баруга, олауны куып җиттеләр. Айбиби утырган күчәрбаш олауны җилле генә узып китте, ә Гаязетдин тархан үз яугирләре белән тагы да алданрак бара башлады.

— Хәтерем ялгышмаса,— диде Рәшидә абыстай,— Аккошлар күле Иделнең борынгы юлында, шул юлда төрле-төрле зурлыктагы күлләр хасил булган, әнә шул күлләрнең берсен аккошлар үзләренә сайлаганнар. Бу хакта миңа мәрхүм атаң Талиб сөйләгән иде, хәтта бер барып күрсәтәм, дип тә ышандырган иде. Ул вакытта күрергә язмады инде, иншалла, бу юлы күрермен.

— Күрерсең дә, шушында яшәрбез дә, абыстаем.

— Язган булса,— диде Рәшидә абыстай, серле генә итеп.

Айбиби аны шундук аңлады. Бит абыстае никахлы кеше. Көтмәгәндә шул кеше бирегә килеп төшсә?.. Ялгыз гына ошбу явызлык белән тулы дөньяны көтүләре ай-һай авырдыр. Ярты гомерен инде Рәшидә абыстай аңа багышлады. Кырык яшьлек хатында мәхәббәтнең сөт өсте, диләр бит. Дөньяда яшәгән һәр гүзәл затны яратып та, сөеп тә бетермәле түгел, телисеңме моны, юкмы, сиңа барыбер тулы канлы мәхәббәтне бер кеше генә бирәчәк. Калганнары сан ягыннан гына хәтереңдә калыр. Ә менә берсе җан биргәндә дә синең белән булыр, дип, Рәшидә абыстай үзе үк сөйли иде ич. Ә күрде-сизде Айбиби, Рәшидә абыстае тикмәгә генә өлкән рavvаны телгә алмый. Бик ихтимал, Йосыф кахан Казан тарафына килергә вәгъдә иткән кебек, ул да аның кырына килеп чыгарга вәгъдә иткәндер.

Айбиби яңа җирне кызыксынып карап барды. Аланнар аша, куе нарат урманнары аша барганда, тып-тын торган җилсез һавага игътибар итте. Ә бит Хазарстанда һәрчак аз гына булса да җил йөреписеп торыр иде. Ә монда черкиләр безелди, баланың йөзен өрфә яулык белән ябарга туры килә. Шулай да бу хозурлык ныграк ошый иде Айбибигә, хәер, бу табигатьтә ул Идел буендагы Болгар каласында ук гадәтләнеп, аның бер тузаны булып үскән иде. Туган ягы ич, борын-борын заманнардан бу төбәкләрдә яшәгән, көн күргән бабаларының җирләре.

Ә Хазарстанда кырында һәрдаим Йосыф кахан булыр, сарай тулы хезмәтчеләр, артыннан, аяк эзләрен сөртеп, хәрам атакайлар йөрер иде. Ләкин шуңа карамастан ул анда курку катыш мәхәббәт сагышы белән яшәде. Чөнки башкалар көнләшерлек дәрәҗәдә бәхетле иде. Ул анда каханны һәм аккошларны гына күрде, хәтта кояшка туры карарга да курыкты, агач яфракларына да бередәге кебек сокланмады, су өстендә җәйрәп яткан төнбоек чәчкәләрен дә, аккошларны гына күрде, аннары тансыклап Йосыфын көтте.

Айбиби, алгы пәрдәне күтәреп, тезелеп киткән чыршыларга карады. Һава саф иде, борынга ярып әчкелтем ылыс исе керә, сулаган саен сулыйсы килә. Айбиби балага күз төшерде, имде-имде дә изрәп йокыга китте. Юл буена йоклады бугай инде бу бала. Рәшидә абыстай Айбибигә: «Баланы уятыйммы әллә?» — дип сораганда: «Йокласын, бала йоклый-йоклый үсә»,— дигән иде. Хәер, бала гына түгел, Рәшидә абыстай үзе дә мендәргә башын салган да изрәп йоклый, карачы хатын да мендәргә башын төрткән, күчәрбаш кына атларга: «Әйдәгез инде, малкайлар, тиздән җитәрбез, анда инде мин сезне куе сүлле Казан үләне белән сыйлармын»,— дип, атлары белән сөйләшеп бара. Йосыф кахан әйткән иде: «Яратырсың син Казанны, бер дә борчылма, Айбибием»,— дигән иде. Айбиби аңа: «Син булмагач, мин анда берьялгызым ничекләр яшәрмен, Йосыфҗаным»,— дип үртәлгән иде. Моны ул ир канатына юри генә әйтмәде, ул чынлап та Йосыфсыз тора алмам, бер көн дә тора алмам дип уйлый иде. Ә бит айга якын

күрми инде, исән-имин, Аллага шөкер кыла. Һәм инде тәгаен белә, ялгызлык халәтеннән аны бала коткарды. Ләкин кем коткарыр аны Гаязетдин күз карашыннан?.. Күрде ич, җаны-тәне белән тойды, ул аңа җиңгәчәсе итеп кенә карамады, ул аңа сокланып карады, яшь кеше бар яктан да тулынкы булган хатын-кызга караган кебек. Җүләр кеше генә бу карашның ни икәнен аңламаса аңламас. Ә Айбиби белә иде ирләрдәге ул карашны, артыгы белән яхшы белә иде. Ләкин Гаязетдин аңа ни дә булса әйтергә кыймады. Шуңа карамастан «җиңгәчәй» диде. Тик бу сүзгә нинди мәгънә, аһәң салды соң ул? Моны янә Айбиби генә тойды, башкалар өчен «җиңгәчәй» гап-гади сүз булып кына калды шикелле. Йөрәккә якын сүз күңелгә шом салырга да, курку китерергә дә мөмкин икән. Хәер, Айбиби моңа игътибар итмәскә булды. Упкынга упкыннан курыккан кеше генә ташлана. Ул хәзер бернәрсәдән дә курыкмый, аның баласы бар — Ибраһимы. Бит ул күрәсен күрде шикелле инде — кырык беренче хатын булып Йосыф каханда яшәп карады. Ул чакта Айбиби болын өчен бер үлән генә иде. Нәрсәдән куркырга миллионлаган үләннәр арасында? Ул үсә, һичнигә карамый ямь-яшел кала бирә. Хак әйткән иде аңа имам хәзрәтләре, кеше ышаныч янына сыенган чарасызлык боҗрасында яши. Ышанычы югалса, ни кала? Чарасызлык. Ләкин Айбиби ул чиккә барып җитмәс, иншалла. Гәрчә үзен кош хәлендә тойса да. Бер ояда утырды-утырды да, баласын алып, яңа җиргә күчеп китте.

* * *

Алдан киткән Гаязетдин тархан утар капкаларын ачтырган, аларны көтеп тора иде инде. Утар йорты болдырында хезмәтчеләр, капка янында сөңге тоткан ике сакчы. Арба утар ишегалдына үтүгә, болдырга җитәр-җитмәс туктады. Гаязетдин арба янына килде, Айбибигә арбадан төшәргә кул бирде. Гаязетдиннең кулы кулына кагылуга ук, Айбибинең тәне буйлап тетрәнү узды. Ләкин ул моңа игътибар итмәскә тырышты. Бу хәл булган иде инде аның белән — Хазарстанда, Аккошлар култыгында, Айбиби янына килеп, Йосыф кахан аның кулыннан алганда. Кемдер әйткән иде аңа: «Яшьлек ул — яшен ташы, бер атуда йөрәгеңне яраларга мөмкин». Ә бит хак, хак әйткән. Хәер, шулай таныйдыр адәм баласы тормышны — югыйсә нигә аңа туып торырга. Тик соң нигә моңа кадәр бер генә акыл иясенең дә мәхәббәтнең ни икәнен аңлата алганы юк. Кем тарафыннан бирелә адәм баласына мәхәббәт?.. Аллаһыданмы?.. Ахыр килеп, ни өчен күрә-күрүгә берәүгә тартыла да күңел, икенче берәүдән йөз чөерәсең?..

— Башта өйгә узыйк, Айбиби җиңгәчәй, өйгә. Минем сезгә башта өйне күрсәтәсем килә. Осталар бик тырыштылар. Мин барысын да атам язганча эшләтергә тырыштым.

— Рәхмәт, рәхмәт, Гаязетдин тархан.

Ул инде аның кулын җибәргән иде. Башта беренче катны карадылар, алгы, аш якларын, ял урыннарын, бала бүлмәсен. Бала бүлмәсе якты, кояш ягында, матур итеп җиһазланган иде. Ахыр икенче катка күтәрелделәр. Икенче катта иркен бүлмә, ике якка да балконнар чыккан.

Айбиби, балконның ике яклы ишеген ачып, сырлап, нәкышләп куелган террәккә барып тотынды һәм Аккошлар күлен күрде дә үзе дә сизмәстән аһ! итте.

— Ни булды, җиңгәчәй, әллә башыгыз әйләнеп киттеме? — дип, Гаязетдин аның беләгеннән тотып алды.

Янә Айбиби тәне буйлап, хәтта аркаларын чымырдатып, тетрәнү узды.

— Юк-юк, болай гына, матур, бигрәк матур күл икән,— диде.

Ул арада астан баланы алып менделәр. Айбиби баланы кулына алды да аңа Аккошлар күлен күрсәтте. Анда камышлы яр буенда берничә аккош җим эзли иде.

— Аккошларны кем ашата, Гаязетдин тархан?

— Безнең кешеләр, ә аръяктагыларын — дәрвишләр.

Айбиби Гаязетдингә таба борылды, күзләренә карады.

— Нинди дәрвишләр?

— Моннан ерак түгел дәрвишләр авылы бар, шуннан килеп ашаталар. Аккошлар оҗмах кошлары, аларны ашаткан кеше саваплы була, диләр ич...

— Еш киләләрме?

— Юк, сирәк-мирәк кенә. Нигездә аккошларны да, күлгә төшкән казларны, үрдәкләрне дә безнең хезмәтчеләр ашаталар.

Айбиби беркайчан да өлкән равва кебек хәйләкәр була алмады. Ул аңа һәрчак барысын да ачыктан-ачык әйтте. Рәшидә абыстай әйткәли иде: «Син арадашчы була аласың, тик идарә итүче түгел. Арадашчы булу хатын-кызга килешә төшә, аның гомерен саклый, ә түрә булу, ил белән идарә итү аның гомерен генә кыскартачак». Хакмыдыр, юкмыдыр, бу нәрсәгә беркайчан да игътибар итмәде Айбиби. Яратуны һәм ир-аттан сөелүне ул мең мәртәбә артыграк күрде. Әмма беркайчан да акылын җуймады. Имам хәзрәтләре аңа әйтер иде: «Акыллы кешенең ихтыяр көчен кайгы да, бәхет тә сындыра алмый. Чөнки акылга, гаделлеккә, канунга таяна, чарасызлыктан ничек чыгарга белә. Акыл белән яшәү кешене күп тапкыр бәхетлерәк итә».

Борылып, балконнан чыктылар, Айбиби карачы хатынга баланы бирде дә, Гаязетдингә ияреп, ишегалдына чыкты. Сукмак яклап чәчкәләр утыртылган, Аккошлар күле кырында ук түбәләп ясалган беседкалар. Алар икәү.

— Берсе кечкенәләр өчен, анда комлык та бар, икенчесе зурлар өчен. Аккошларны да шуннан ашатырга була,— диде Гаязетдин һәм гөлләр утыртылган бакча ягына таба атлады.— Алма агачлары да, балан да, карлыган да, аю камыры да, кура җиләге дә, миләш тә бар монда.

— Йөзем үсмиме?

— Йөзем үсми,— диде Гаязетдин, Айбибигә таба борылып. Ул шундаен итеп карады ки, Айбиби курка калды. Нинди сорау бирәм, дип үкенеп куйды. «Беләсең ич инде, бу якларда йөзем үсми. Әллә ачуын китердем инде» дип уйлады ул, гөлҗимеш агачлары тезелгән сукмак буйлап адымын тизләтә төшкән Гаязетдингә иярде.

Сорыйсы килә иде Айбибинең: «Өйләнгәнме, хатыны бармы? Бер генәме? Бит мөселман ир-аты ике-өч кенә түгел, дүрт хатынга кадәр өйләнә ала. Аннары анасы Сара кай тарафта, Казанда, аның кырында торамы? Казанда яшәсә, бире килерме, оныгын күрергә?..» Ләкин инде сорый алмады, Гаязетдин, аның артык сорау бирүенә үпкәләгән кеше сыман, әйләнеп килгәнче сүз катмады һәм Айбиби дә дәшмәүне артыграк күрде. Әмма юл буена үз-үзен орышты. Кеше никадәр тырышкан, ә ул аңардан мыскыл иткәндәй: «Йөзем үсмиме?» — дип сорый...

— Әти комсызларча кылана. Ил артыннан ил яулый, халык артыннан халык. Хәер, бу хәл бар империяләргә дә хас сыйфат,— дип сөйли башлады, артына әйләнеп карамый гына, гүя ул бу хакта башка берәүгә сөйли иде, әйтерсең лә нииндидер аның кырына килгән күрше илнең илчесенә.— Аңа вакыт җитми, ул империя өчен яши, хәтта сезне озатып куярга да вакыт тапмаган,— диде, Гаязетдин туктады, һәм туп-туры Айбибинең күзләренә карап: — Баскынчыларга хас сыйфат бу, җиңгәчәй, баскынчы империяләргә генә хас сыйфат. Мин ни өчен Хазарстанга кайтмадым дисез?.. Бары тик шуның өчен генә, җиңгәчәй, бары тик шуның өчен генә. Мин бер халыкның да илен вә халкын яуларга теләмәдем, теләмим дә.

— Ләкин бит атаң син түгел, Гаязетдин,— диде Айбиби.

Гаязетдин тархан туктады һәм янә бер Айбибинең күзләренә карады.

— Мин баштан ук кахан булырга теләмәдем, җиңгәчәй. Миңа андый мөмкинлекне өлкән равва биргән иде, атам хакына баш тарттым, атам хакына,— диде Гаязетдин кисәк туктап.

Менә кайчан янә югалып калды Айбиби. «Бу ни инде, нигә мин аңа бәйләнәм соң әле? — дип тиргәде ул үзен һәм күзләрен аяк очларына төшерде.— Килеп җитмәгән килеш бит, килеп җитмәгән килеш. Оял бераз, Айбиби, оял. Ул сиңа ханнар сараедай утар салдырып куйган. Сиңа, атаңның хатынына һәм Ибраһим энесенә...»

— Кичер мине, кичерә күр, Гаязетдин,— диде Айбиби, аның беләгенә сарылып.— Кичер җиңгәчәңне...

Юк, кулын беләгенә салып калмады, бите белән күкрәгенә елышкандай итте.

Ул берни дә әйтмәде һәм кисәк тынып калды. Ахыр:

— Җиңгәчәй, бала елый башлар, сез юлдан, сез арыгансыз,— диде Гаязетдин һәм Айбибигә сарай кебек тоела башлаган өйгә таба кузгалды, һәрхәлдә, ике катлы өй Айбибигә чынлап та хан сарае кебек тоела башлаган иде. Ә анда хезмәтчеләр генә түгел, Айбибиләргә ияреп кайткан гаиләләр дә аларны көтәләр иде инде.

— Гаязетдин углан, Гаязетдин углан,— дип, ак сакаллы карт аңа таба килә башлады.— Безне Казанга алып китсәгез иде, минем анда угылым хезмәт итә.

Айбиби олау артына ияреп кайткан карт кешегә сәерсенеп карады, чөнки ул аны кайтканда бер тапкыр да күрмәде.

— Сез, хөрмәткә ия кеше, безнең белән кайттыгызмыни?

— Минем кешеләр алар, минем кешеләр,— дип, аның каршына ук килеп басты олаубаш.— Өлкән равва биреп җибәрде. Авыру ул, арбадан да төшә алмады, шуңа күренмәде дә.

— Алпар йөзбаш, Алпар йөзбаш,— диде күзләре белән йөзбашны эзләп Айбиби.— Алпар йөзбаш!

— Мин монда,— дип, өйдән чыкты һәм болдырдан төшә башлады Алпар йөзбаш.— Гаҗәпләнмәгез, каханбикә, бу карт Казаннан Хазарстанга күчеп киткән заманында Ефәк юлында йөргән Йосыф каханның сәүдәгәре. Миннән: «Илемә кайтып үлим»,— дип бик ялваргач, аны сезгә әйтми генә олауга алган идем...

— Гаязетдин,— дип, тарханга карады Айбиби,— олы кешегә хөрмәт күрсәтсәгез иде, үзегез белән алсагыз иде.

— Мин бу картны беләм, ил адәме, изге зат,— диде һәм, картка таба борылып, баш иде Гаязетдин тархан.— Казанга кайткач, минем тарафыма кереп чыгарсыз, Габдулла агай.

Олуг карт төркиләрчә бер тезенә төште, әмма торасы итте, аягына баса алмады. Гаязетдин аның култыгыннан алып, аягына бастырды.

Айбибигә ни өчендер кыен булып китте. Нигә ул Гаязетдин алдында гел уңайсыз хәлгә кала. Ул кырын күзе белән генә Гаязетдингә карап алды һәм баланы күтәреп болдырдан төшеп килгән Рәшидә абыстайга таба китте.

— Без китик инде, җиңгәчәй,— диде Айбиби артыннан атлаган Гаязетдин.

Күр инде, җайлап рәхмәт тә әйтә алмадым, ә ул саубуллашмый китеп тә бара ич. Нишләде әле ул, ни булды аңа?.. Әмма:

— Әйе, әйе, Гаязетдин тархан, без урнашып, җайлашып беткәч, сезне дәшәрбез,— диде борылып. Рәшидә абыстай кулыннан баланы алды, һәм баш ия-ия китеп барган кешеләр белән саубуллашты.

— Уф Аллам,— диде ул, китеп барган олауга күз ташлап, кырындагы Рәшидә абыстайга.— Уф Аллам, абыстаем, мин аны күрүгә үк саташып йөри башладым.

— Саташырлык та шул, балакай. Мин дә аны күрүгә чак кына: «Йосыф кияү!» — дип дәшми калдым. Күрдем ич, син дә югалып калдың.

Айбиби Рәшидә абыстайга күз ташлады, әмма бер сүз дә әйтмәде. Бу хак иде. Гаязетдин атасына охшаган иде, суеп каплагандай, ике тамчы судай. Шуңа каушый калды бугай Айбиби. Каушап кына калса бер хәл, башын югалткан берәүдәй аның кырында йөрде.

— Сара анакай да аның кырындадыр инде. Өйләндеме икән соң? — диде зур зал аша узып, бала бүлмәсенә таба атлаган Рәшидә абыстай.

Тик Айбиби бер сүз дә әйтмәде. Чөнки аны баштан ук, Гаязетдинне күргәч тә башында шул сорау туган иде, сорарга гына яхшысынмады. Ни өчен сорамады? Моны Айбиби үзе дә аңламады.

Айбиби бала бүлмәсенә үтте, кош тиресе җәйгән сәкегә утырды да баланы имезергә җыенды.

Рәшидә абыстай аңа:

— Хезмәтчеләр юлдан кайтучыларга мунча якканнар, хәзер ашап-эчик тә, бераз торгач, мунча кереп чыгарбыз,— диде.

— Яхшы, абыстаем. Ә бу бәләкәйне коендырырбызмы соң?

— Аны ләгәндә талымча суда гына үзем коендырырмын, борчылма. Сине дә гел тәпәндә генә коендыра идем.

— Мин бернәрсә дә хәтерләмим шул. Ә син, син, Ибраһим, хәтерлисеңме берәр нәрсә? Без бит, озын юл узып, синең белән Казанга кайттык, Казанга!.. Туган ягыбызга,— диде Айбиби инанып.

Имеп туйган бала, нәрсәдер аңлагандай, аңа:

— Әә-э, әә-э,— диде.

— Менә сөйләшә дә башладык,— диде бала әнисе урынына Рәшидә абыстай.— Әйдә, баланы карачы хатынга бир дә, безне ашарга дәшәләр...

Нәкъ Аккаладагы кебек булмаса да, аш ягында аларны бавырчылар, пешекчеләр каршы алдылар. Озын өстәлгә ризыклар куелган иде инде. Айбиби өлкән карачы хатын күрсәткән урынга утырды, шундук аның янына, җиз таз һәм комган тотып, кул юдыручы килде, кулын югач, аңа озын сөлге бирде, сөлгенең очлары матур җепләр белән чигелгән иде. Айбиби өстәл янында утырган Рәшидә абыстайга, карачы хатынга һәм олаубашка карап алды да Алпар йөзбаш турында сорады.

— Алпар йөзбаш кая?

— Ул Гаязетдин тарханны озата китте, каханбикә,— диде карачы хатын. Айбиби карачы хатынга күз төшереп алды һәм: «Димәк, өй-каралтыларга шушы хатын күз-колак булып торачак»,— дип уйлады һәм дога кылырга кулын күтәрде.

Ашап-эчкәч, Аккошлар күле тирәләрен урап килделәр. Ни гаҗәп, Рәшидә абыстайның да, Айбибинең дә сөйләшәсе килми иде. Күл аларга ошады. Киң яки тараеп киткән урыннары да бар. Ләкин күлдә аккошлар күренмиләр иде. Бары тик үрдәкләр генә камышлыкларда су төбеннән нидер эзлиләр. Кинәт кенә моңсу булып китте Айбибигә. Бит анда аны аккошлары, казлары каңгылдашып, шатланышып каршы алырлар иде, ә монда күзгә дә күренергә куркалар. Аның ни турында уйлаганын белгән кебек, Рәшидә абыстай:

— Борчылма, балакай, барысы да җайланыр,— диде.

Айбиби җавап бирмәде, бары тик уфтанып кына куйды.

— Әйдә, абыстаем, безне анда мунча көтә, һичьюгы, юл тузанын коеп чыгыйк,— диде.

Мунчаны күл буена, зур итеп салдырган иде Гаязетдин тархан. Мунча алды иркен, чәй ягы да бар, мунчаның үзенә янә бер бүлмә аша керәсе. Анадан тума чишенеп, мунчага узгач, ләгәндәге суда үзенең йөзен күреп, Айбиби кеткелдәп көлеп алды.

— Ни булды? — дип сорады Рәшидә абыстай.

— Үземне көзгедән күргәндәй булдым. Үзем дә, үзем түгел дә икән. Шуңа көлдем.

Мунча эссе. Ләүкәгә менеп, бертын тирләп утырдылар. Рәхәт итеп тән җылына, аркалардан тир ага башлады.

— Менә хәзер күлгә чумып чыгасы иде, Айбиби,— диде Рәшидә абыстай.

— Ә нигә чумып чыкмаска икән. Мин кергәндә мунчадан күлгә кадәр басма сузылганны күрдем. Әйдә...

Балаларга хас чыр-чыр килеп, мунчадан чыгып, басмадан күлгә җиттеләр. Килә-килүгә үк Айбиби баскычтан күлгә төште һәм йөзеп китте.

— Кер, кер, абыстаем, кер, су шундаен җылы, рәхәт.

Суга кереп чыгуга, кире мунчага йөгерделәр һәм кайнар ләүкәгә менеп кунакладылар һәм, тезләрен күкрәкләренә терәп, тынып калдылар.

— Мине Казан тарафына атаң Талиб алып килгән иде. Бары бер тапкыр булды ул. Һәм шунда без тархан мунчасында юынып чыккан идек. Ул мунчаны да нәкъ шулай итеп салганнар иде. Тик басма күлгә түгел, Болакка төшәр иде. Һәй, Айбибием, ниндәен бәхетле чакларым булган — белмәгәнмен икән! Әлегә кадәр сөйләргә куркып йөрдем, оялдым. Болгарга кереп каберен күргәч, кыюланып киттем әле. Кичерә күр, балакай. Яраттым мин синең атаңны, яраттым, гөнаһ булса да әйтим инде, хәтта бала табарга теләгән идем, сихерче карчык рөхсәт итмәде. Үз башыңа булуы бар, диде.

Айбиби бертын дәшми торды. Чынлап та, аңа бу хакта сөйләшүе авыр иде. Ләкин хәзер андый хистән арынган иде инде ул. Ни өчендер бу халәт аңа нәкъ менә Гаязетдинне күргәч килде. Гөнаһ кылмагансың, абыстаем, бер дә гөнаһ кылмагансың, диясе килде аның, әмма кыймады, тыелып калды. Бары тик:

— Мин, абыстаем, Йосыфым кочагында тәмам эреп китәр идем,— диде.

— Ни дип атыйлардыр аны, әмма мәхәббәт бар, балакаем, дөньяда, бар.

— Бар, абыстаем, бар,— диде Айбиби һәм ни өчендер аның күз алдына янә кулыннан тоткан Гаязетдин килде.— Бар ул, бар!.. Әйдә әле, чап әле мине әнә шул пешекләгән себерке белән, абыстаем, Болгар мунчасындагы кебек...

Берсен-берсе чабышкач, аһ-ух килә-килә янә күлгә төшеп, сүрелеп чыктылар. Чыктылар да тагын ләүкәгә менеп кундылар. Ахыр Айбиби:

— Коенуйк та, хезмәтче хатынны дәшик, карачы хатын баланы китерсен,— диде һәм, баскычка чыгып, хезмәтчене дәште: — Баланы китерегез, баланы!

Баланы китергән арада, зур ләгәнгә су салдылар, талынкымы, бала түзәрлекме дип, Айбиби үзе суга терсәген тыгып карады.

— Бик әйбәт, түзәрлек, абыстаем.

Ул арада баланы китерделәр. Рәшидә абыстай баланың күлмәк бауларын чишеп салдырды да ләгән янына китерде, һәм сак кына коендырасы итте, әмма Айбиби:

— Бир әле, абыстаем, үзем юындырыйм Ибраһимымны,— диде.

— Мә, мә, балакай.

Айбиби баланы кулына алды, сак кына аякларын суга тыкты, аннары муенына кадәр җиткәч:

— Күр әле моны, күр әле, абыстаем, суда туган диярсең үзен, курыкмады да ичмасам.

— Син аның кулыннан тот та ләгән төбенә бастыр. Ике кулыннан да тот, ике кулыннан да.

— Ул курка, кулларга чат ябышты.

— Өйрәнер, без әле аны күлдә коенырга да өйрәтербез. Мин сине Идел суында да коендыргалаган идем әле, балакай.

Айбиби баланы йөздереп тә карады, су өстендә чалкан да яткырып тотты, ахыр, арыгач, баланы Рәшидә абыстайга бирде.

— Мәле, абыстаем, коендыр да баланы, мин дә коенуйм да, чиста киемнәребезне киенеп, чыга башлыйк. Йә кәефсезләнә башлар.

Мунчада коенып, мунча җылысын тоеп кайткан бала карачы хатын кулына керүгә үк йокыга китте. Айбиби йоклап яткан бала янына керде һәм, бала йөзендә Йосыф кахан төсмерләрен күреп, кинәнеп куйды. Әмма шундук аның күз алдына Гаязетдин тархан килде. Айбиби, ниндидер гөнаһта тотылган кешедәй, тиз генә бала яныннан чыгып китте.

## XIX

*Еллар узгач*

— Ибраһим, Ибраһим, дим, балакаем, күпме йөзәргә була инде. Аккошлар дисеңме?! Аккошларны мин ашаттым инде, ашаттым. Әнә аръяктагы дәрвишләр дә ашаталар аларны. Чык судан, җитте.

Ибраһим ашыкмады, Айбиби, улы судан чыгуга, аның иңбашына сөлге ташлады.

— Безне бүген Гаязетдин тархан көтә. Сарай мәктәбенә бирергә булдым мин сине, улым. Анда сезне Болгардан килгән мөгаллимнәр укытачак. Шулай диде абаң.

— Мин анда укырга теләмәсәм?

— Башта барып күрик әле, улым. Ошамаса, мин сине...

— Нәрсә мине, әнием? — дип, барган җирдән туктап калды Ибраһим.— Хазарстанга илтерсеңме? Белеп тор, әнием, мин анда бармыйм да, анда укымаячакмын да.

— Нигә, улым? Нигә алай дисең?

— Хазарстаннан дәрвишләр Болгарга, Биләргә, Казанга киләләр, без Хазарстанга таба кузгалыйкмы, әнием? Хазар-станны су баскан.

— Кем шулай дип әйтте?

— Дәрвишләр. Алар белемле, бар нәрсәдән дә хәбәрдар халык, әнием. Моннан ерак түгел, авыл утырганнар. Иганә исәбенә генә яшәмиләр, арпа игәләр, яшелчәләр үстерәләр.

— Әллә син дә анда баргалыйсыңмы?

— Бер тапкыр гына булдым. Кемнең нәрсәсе бар, табынга куялар да тамак ялгыйлар. Аннары Хазарстан яһүдләре кебек изге китаптагы һәр хәреф өчен бәхәс башлыйлар. Берсе бер төрле, икенчесе икенче төрле аңлата, өченчесе... Кыскасы, барысы да имамнар, барысы да мөгаллимнәр, белеклеләр, бар нәрсәдән дә хәбәрдарлар.

Ибраһим беседкага кереп, киенеп чыкты. Кара чәчле, кара күзле, атасыныкы кебек тутсыл йөзен күреп, Айбиби сискәнеп китте. Әтисенә охшаган иде улы, кечкенә Йосыф диярсең, йөреше дә, кыланышы да аныкы. И-и Ходаем, кая син, Йосыфҗан, кайларда саташып йөрисең? Рәшидә абыстай әнә Ибраһимы янына китте, иярде дә китте, бер дә исе китмәде. Хәзер әнә өлкән раввасы Биләрдә хан сараенда утыра, имам хәзрәтләре булып. Ә бит өлкән равва иде, өлкән равва, бөтен бер Хазарстанны кулда тотучы. Хазарстанны су баскан елда Биләргә күчеп килгән дә хан сараенда имам хәзрәтләре булып киткән, өченче ел бире килеп, Рәшидә абыстайны алып китте. Никахлылар иде ич. Башында чалма, өстендә кыйммәтле хөллә, аякларында болгари итек. Айбиби ни Рәшидә абыстаена, ни элеккеге өлкән равва Ибраһимга бер сүз әйтә алмады, бер сүз дә хәтта, чалма кигән имам хәзрәтләрен, тегенең һәммә җирдә мөселманнарча дога кыла-кыла вәгазь укуын күргәч, тәмам зиһене чуалды, ул гынамы, Йосыфы турында сорарга да онытты. Менә ни дәрәҗәдә каушаган иде ул. Ә бит сорыйсы булган — аның Йосыфы кая? Вафатмы, орышларда шәһит киттеме, иле-дәүләте су астында калса да, каханын җир йотмагандыр Хазарстанның. Хак, аңа сөйләделәр, имеш, викинглар белән ызгышта Йосыф кахан кинәт юкка чыга. Мәетен таба алмыйлар. Ә менә викингларны чакырган, һәм мөселманнарны таларга һәм илдән куарга өндәгән коткычы өлкән равва бүген Болгар ханы сараенда имам хәзрәтләре!.. Моңа ничекләр гаҗәпләнмәскә кирәк!

Улы артыннан кайтып, ашап утырганда да, юлга җыена башлаганда да, юл чыккач та, Айбиби шул хакта уйлады. Өлкән равва исән, иманын алыштырган да исән-имин яши бирә, ә ул күтәргән, ул Хазарстан каханы иткән аның Йосыфы кая?.. «Әллә соң, чынлап та, викинглар кулыннан һәлак булдыңмы, Йосыфым?» — дия-дия, хатирәләргә чумып барды Айбиби. Улы да дәшми, ни турындадыр уйлап бара. Инде Казан каласының мәчет манаралары да күренә башлады, мәшһүр кальга да. Бу кальганы бик борынгы заманнардан ук күтәрә башлаганнар, диде аңа Гаязетдин тархан.

Гаязетдин өйләнгән, бер хатын белән генә көн күрә икән, хатыны чибәр, җирле халыкның морза кызы булып чыкты. Укымышлы, шигырьләр яза икән хәтта. Беренче тапкыр киленнәрен күргәч тә Айбиби бу баладан күңелендә көнләшү кебек бер хис уянып китүен тойган иде. Үзе дә белми ни өчен. Ләкин бу халәт булып алды. Соңыннан Гаязетдиннең хатынын яратып яшәвен күргәч, күңелендә ниндидер кимсену тойса да, киленгә ясалма елмаю аша якынлыгын сиздерүдән ары китә алмады. Нишләмәк кирәк, Гаязетдинне ул Йосыфына охшаткан иде һәм хәтта үзе дә аңламый нигәдер, нәрсәгәдер өмет тә иткән иде бугай. Әйе, беренче күргәндә. Хәер, Айбиби әле булса, Гаязетдинне күргән саен, аркасы кымырҗып куюын тоя. Иң гаҗәбе, үзе белән һични кыла алмый. Гүя аның Йосыфы аша мәхәббәте Гаязетдингә күчкән иде. Тик ул моны беркемгә дә сиздермәде, хәтта бүген Биләрдә яшәгән Рәшидә абыстайдан да яшерергә тырышты, әмма тәҗрибәле абыстай аның Гаязетдингә карата булган мәхәббәтен беренче көннән үк сизенгән иде шул... Ахыр килеп, улы Ибраһимны ул Шәмгун ханның сарай мәктәбенә дә озата ала иде. Хан сараенда дөньяга исемнәре билгеле булган галимнәр эшли, аларның күбесе сарай мәктәбендәге балаларга сабак бирәләр иде. Тик горур хатынның Гаязетдинне ешрак күрәсе килә иде шул, һәм ул улы Ибраһимны Казан мәктәбенә бирергә булды. Хак, ул аны үзе генә түгел, утарына дәшеп, аерым имамнардан да укытты, әмма бала үскән саен аңа тирәнрәк белем кирәк, ә ул белемне кала мәктәпләрендә һәм хан сарае мәктәпләрендә генә алырга була иде. Айбиби исә улы Ибраһимны Гаязетдин тархан мәктәбенә бирергә булды. Шушы ният белән Казанга юнәлүе иде. Бу хакта улы Ибраһим да белә, ләкин, ичмасам, бер тапкыр да: «Әнием, нигә мине Болгар мәдрәсәсенә бирмисең?» — дигән сорау куймады. Рәхмәт аңа.

Башыннан шушындый уй узуга, Айбиби улына күз төшереп алды. Күчәрбаш атларны куалый башлады, сиртмәле арба, җиңелчә тирбәлә-тирбәлә, Казан елгасы күперенә якынлашты. Кала инде гүя уч төбендә: биек таш диварлар, ук очар ара саен күзәтү манаралары, әле анда, әле монда күккә омтылган мәчет манарасындагы айлар. Утарда яшәү рәхәт, тыныч иде. Монда исә калага җитмәс борын шау-шу ишетелә башлады. Кала капкасына җитәрәк асма күперләр алдында арбалар тора, кальгага керергә нәүбәт көтәләр. Аларның арбасы җиденче булып килеп туктады. Ул арада капкадан үзенең яугирләре, җан сакчылары белән Гаязетдин тархан килеп чыкты. Аның башында каурый кунган алтынга буяган очлым, өстендә ярым җиңле укалы җилән, ат өстендә рум чүпрәге япмасы, япма алтын җеп белән тукылган, күзне үзенә тартып тора. Ләкин Айбиби боларның берсен дә күрмәде, ул бары тик хәрби киемдәге

Гаязетдинне генә күрде. Күр инде, бит аның Йосыфы да нәкъ шулай киенер иде, аты да, дирбияләре дә Йосыфныкына охшаган, очлымына кадәр.

— Саумы, җиңгәчәй, саумы, энекәш Ибраһим! — дия-дия, Гаязетдин тархан алар арбасы янына ук туктады һәм, борылып, арттан килгән җан сакчысына: — Җиңгәчәйне алдан уздыр! — диде.

— Рәхмәт инде, рәхмәт, туганый,— дия алды Айбиби, Ибраһим исә абасына торып басып ук кул изәде.

— Имам хәзрәтләре сезне көтә, көтә,— диде Гаязетдин һәм, атын җилле генә юырттырып, зур күпергә таба элдерде.

— Менә, улым, син шул калада яшәрсең инде. Абаң Гаязетдин минем сарайда яшәр, дигән иде дә, мин аңа мәктәп балалары кайда яши, шунда яшәр, шунда торыр, дидем.

— Рәхмәт, әнием,— диде Ибраһим.

Ашыкмадылар. Урам тулы халык, ике тәгәрмәчле арбага тауар төягән базарчылар агыла, йоннары өяләнгән этләр койрык селкеп калалар. Шулар арасында башына өрфә яулык бәйләгән, муенына кызыл шарф элгән, баш калфагы бер якка авышкан, бала итәкле зәңгәрсу-аксыл күлмәк кигән кыз бала күзгә чалынып китә. Әнә шул кызларны күргәч, Айбиби Хазарстанга килеп төшкән мәлен күз алдына китерде. Ул да шулайрак киенгән иде. Яшерми, Ханбалык аңа ошамады. Пычрак сулар түккән урамнар, еракта ук балык исе килә, хатын-кызлар кебек, иңбашына көянтә сыман асып, озын таякка кипкән балыклар элгән сатучылар уза. Алар күзе чалынган һәр кешегә кипкән балык тәкъдим итәләр. Яшерми, ул Йосыф кахан яшәгән Аккалага курка-курка барды, хәтта арбадан төшеп, халык мыжлап торган базарга кереп качасымы әллә, дигән уй да туган иде башында. Кая инде ул кырык хатын тоткан Йосыф кахан турында уйлау, аны хәтта күз алдына да китерәсе килмәде.

Ә соңра әнә ничек килеп чыкты.

— Яхшы гына укы инде, абаңның йөзенә кызыллык китермә, улым.

— Китермәм, әнием,— диде кырыс кына Ибраһим.

— Бәлкем әле Рәшидә абыстай да яныңа килеп китәр, мин аңа хәбәр итәрмен, үзем дә килә йөрермен.

— Борчылма, әнием, мин синең башыңа кайгы китермәм.

Ниһаять, Гаязетдин тархан күтәрткән мәктәп бинасы күренде. Бина озын һәм ике катлы иде. Ни өчендер Аккаланыкы кебек мәктәп бинасын кальга эченә салдырган иде Гаязетдин тархан. Шәмгун хан каршы булса да, осталарны яһүд сәүдәгәрләре аша румнарны китерткән. Һәм сызымны да үзе сызып биргән, дип җиткергәннәр иде Айбибигә, хак икән. Бинаны күргәч, кальга эченә үтүгә, Ибраһим аягүрә торып ук басты.

— Ошый бу бина миңа, гомумән, барысы да матур монда, таш диварлар, сакчылар, тархан сарае, уң якта атлар тоталар булса кирәк, җайдаклар күренә…

Үзәк урамнан үттеләр, тархан сарае каршында туктадылар. Аларны каршы алырга Гаязетдиннең хатыны чыкты. Килен кешесен өч-дүрт хатын-кыз озата, алардан кала төшә унлап җиткән кыз килә. Барысы да ыспай киенгәннәр, җилләннәренә кадәр бертөрле, килен кешенең генә җиләне ямь-яшел, читләре кеш тиресе белән уелган, киленнең башында очлым сымаграк калфак. Килен ап-ак йөзле, йөзе шулкадәр ак иде ки, Айбиби, ике арада охшашлык күреп, аптырабрак калган иде. Хәер, Идел буеның өске тарафларында яшәгән халыклар күбрәк ак йөзлеләр, күк йөзе кебек зәңгәр күзлеләр иде. Шуның өчен Йосыфы аның күзләренә карар иде дә: «Айбибием, нигә синең күзләрең шул чиккә җитеп зәңгәр, мин синең күзләреңә карасам, үземне күккә ашкандай хис итәм»,— дияр иде.

«Ә мин синең күзләреңә карасам, упкынга очкандай хис итәм үземне»,— дигән иде аңа Айбиби, кет-кет көлә-көлә. Һәм шулай да иде ич! Ул аның кочагына иңсә, гүя упкынга очар иде.

— Хуш килдегез, хуш килдегез, җиңгәчәй! — дия-дия, Айбибине, арбадан төшүгә, каршы алды киленкәй һәм читкәрәк китеп, бер урында таптанып торган Ибраһимны кочагына алды да: — Менә кем килде безгә, менә кем! — дип, энекәшенең аркасыннан сөйде.

Кунакларны сарайга алып керделәр. Аккаладагы сарайга охшаган бүлмәләр, төрле тарлавыклар күреп, Айбиби үзен кахан сараенда итеп хис итте. Ләкин бу ялган чагыштыру гына иде. Тархан сараеның диварлары калын, тәрәзәләре кечкенәрәк иде.

— Юл бик авыр булмадымы, җиңгәчәй? — дип сорады Бибисара.

— Юк-юк, бик әйбәт килдек. Көн дә бик матур булды, кальгага да җиңел генә уздык. Асма күпердән Гаязетдин нәүбәтсез уздырды.

— Гаязетдин Идел буена китте, кораблар туктарга урын карарга. Мин аңа сәүдә корабларын Болакка кертергә канау казырга кирәк, сәүдәгәрнең кораблары Казансу буйлап килерләр дә Болакка кереп бушанырлар, дигән идем, килешеп җитмәде, карап карарбыз, дип кенә калды. Минем әтием гомер буена кораблар төзеде бит, җиңгәчәй.

— Гаязетдингә башта әтиең белән киңәшергә кирәк булган.

— Әтием былтырларны гына вафат булды шул, җиңгәчәй. Казанга нинди бина күтәрсә дә, Гаязетдин әтием белән киңәшер иде,— диде килен һәм кунакларны ашханәгә алып керде.

Алар каршына ап-ак чәче яшел яулык астыннан чыгып торган бер карчык килеп басты. Аны күрүгә, Айбиби ике кулын аңа сузды, баш иде, аннары дога кылды. Шуннан соң гына карчыкның саулыгын сорады.

— Йөрим шунда шәүлә булып,— диде карчык, бер дә исе китмичә, аннары үзе сорады: — Юл бик алҗытмадымы, килен? Әллә Ибраһимны яңа мәктәпкә китердеңме?.. Кил әле, кил бире, улым. Һай, син гел егет булгансың икән бит инде. Кылыч тагарга да вакыт ерак калмагандыр?

— Тагын дүрт ел, тагын дүрт ел көтәсе әле аңа, әни.

— Дүрт ел үтәр дә китәр, акылы белән үссен, акылы белән. Йә, килен,— диде карчык, Бибисарага таба борылып,— табын әзерме анда, юлчылар арыганнардыр. Тамак ялгап алырлар да мәктәпне барып карарлар. Һәй кинәнде инде Гаязетдинем шул мәктәпне күтәргәч, һәй кинәнде. Атамны да уздырдым, дип мактанды.

Аларның (нәкъ Аккаладагы кебек) кулларын юындырырга җиз таз, җиз комган китерделәр. Кулларын чайкагач, сөртергә озын сөлге бирделәр. «Күр инде, барысы да Аккаладагы кебек»,— дип уйлап куйды Айбиби.

Табын мул итеп хәстәрләнгән иде. Һәр кеше авыз эченнән догасын укып ашый башлады, чөнки Сара анакай ашый башлаган иде инде.

— Килен,— диде Сара анакай.— Сине Рәшидә абыстай сагына икән, барып чыгар идең бер. Алар анда ипле генә сарай мәктәбендә балалар укытып яталар, балаларга сабак бирәләр. Мин аны бире дәшкән идем дә, Ибраһимы килешмәгән. Имеш, миңа Биләр ошый төшә.

Айбиби бер сүз дә әйтмәде. Әйе, ул үзе дә Рәшидә абыстаен сагынган иде. Бер утырып серләшәсе килә иде, тик әлегә кадәр нигәдер аягы гына тартмады. Иске хатирәләрен кузгатып, йөрәгемә яңа яралар гына салырмын дип курыкты. Чөнки өлкән равваның кинәттән имам хәзрәтләре булып китүенә күңеле белән әле дә булса ышанмый иде. Әмма Рәшидә абыстаеның хәленә керә — бит ул аны үз баласыдай тәрбияләп үстерде. Еш кына, бала чактагы кебек аның кочагына иңеп, дөньясын онытасы килә иде. Тик һаман да шул бер өлкән равва Ибраһим — хәзер инде сарай имамы…

— Барырмын мин анда, әнием, барырмын,— диде Айбиби.— Менә Ибраһимымны урнаштырыйм да, барып кайтырмын.

— Анда сезнең янда дәрвишләр авыл утырганнар икән, бөтен суфи-сафа шунда җыелган икән. Гаязетдин барып туздырам, дигән иде, каршы төштем, тимә аларга, алар изге затлар, ил өстеңә каракош канаты булып кара болыт төшәр, дидем. Хазарстанга төшкән кара болыт кебек. Ил кадәр илне юк итте бит, гүя туфан калыкты, гүя туфан, дөньяны су басты. Кала артыннан кала су астында калды, кала артыннан кала. Йосыфымны да шул яңгыр аждаһасы йотмадымы дип яшим инде, ил имгәге булып, киленкәй, ил имгәге булып… Йә, ярый, ризыктан җитешеп утырыгыз, карт кешене тыңласаң — ут йотарсың, яшь кешене тыңласаң — ил кичәрсең, дигәннәр. Яшьләрдә өмет хәзер. Ибраһимда. Иншалла, барысы да әйбәт булыр, сабагын да укыр, мәктәбен дә тәмамлар, биленә кылычын да тагар. Йосыфым әнә биленә кылыч тагуга ук тәхет биләгән иде.

— Әйе,— диде Бибисара килене, анасының сүзенә кушылып.— Ил исән булса, җир исән булса, ир исән булса — барысы да булыр, иншалла.

«Тик минем Йосыфым гына кайтмас»,— дип уйлап куйды Айбиби, тустаганын чәй көйләргә сузып.

Әйе, мин хәзер бер байгыш хәлендә, йөрәк парәм улымны да калдырып кайтсам, нинди юаныч калыр миңа?.. Аккошларыммы?! Аларны да дәрвишләр килеп ашата башладылар. Бер аккошның түшен каракош яралагач, Айбиби яралы кошны аларга биреп җибәрде. Чөнки барыбер аның итен ашый алмас иде, ул аларны оҗмах кошларыдай күрде. Ә оҗмах кошын укка алган кеше оҗмахка керми, ди торган иде Харәземнән килгән имам хәзрәтләре. Хәер, имам хәзрәтләре үзе дә тәмам изге зат иде Айбиби өчен. Тик Йосыф кахан өчен түгел. Йосыфы имамнарны хәйләкәр рәвештә илләренә озатса да, Айбиби күңеленнән ир-канаты белән килешмәгән иде. Ләкин рәнҗетмә аларны, дип әйтә алмады…

Ашап-эчкәч, табынга рәхмәт әйтеп, җыелышып, яңа мәктәп бинасын карарга киттеләр. Ибраһим, каерылып-каерылып, арттан бер-берсенә нидер әйтә-әйтә көлешеп барган кызларга карады. Әнисе аның җилән җиңеннән тартып куйды. Имеш, тәртипле генә бар. Ләкин ничекләр синең артыңнан кеткет көлешеп барган кызкайларга әйләнеп карамыйча бармак кирәк. Ибраһим башта аларга телен күрсәтте, аннары тешен ыржайтты. Бу юлы аның колагыннан әбисе эләктереп алды.

— Ипле генә бар, әнә мәктәп каршында ук безне имам хәзрәтләре көтеп тора,— диде.

Чынлап та, мәктәп ишеге янында ук башына яшел чалма ураган, озын ак җилән кигән кара йомры сакаллы берәү тора иде. Ул киләсе кунакларны баш ия-ия каршы алды һәм ишекләрне ачыгыз, дип, ишекъяры торган шәкертләргә әйтте. Тегеләр исә мәктәпнең ике якка ачыла торган ишекләрнең канатларын ачып куйдылар. Иң алдан мәктәп бусагасын атлап, Сара анакай узды, аңа кунаклар иярделәр, ләкин мәктәпкә көлешеп килгән кызларны уздырмадылар.

Имам хәзрәтләре, шәкертләр укыйсы бүлмәләрне күрсәтә-күрсәтә, икенче катка күтәрелде һәм кунакларны, алдан ук сөйләшкәнчә, Ибраһим укыйсы бүлмәгә алып керде. Шәкертләр тез биеклек кенә өстәлләр куелган, асларына кырпача җәелгән урыннарда сабак алачаклар икән. Сара анакайга барысы

да ошады, ул, имам хәзрәтләренә карамый гына, бүлмәдән чыга башлады. Ләкин шул мәлдә Айбиби имам хәзрәтләреннән:

— Бер мөгаллим ничә баланы укытачак? — дип сорады.

— Без Хазарстан мәктәпләренең тәртипләрен сакларга тырыштык, каханбикә Айбиби,— диде имам хәзрәтләре, бер дә исе китмичә.

Ул арада бүлмәдән чыгарга кузгалган Сара анакай алар янына борылып килде.

— Рәсүлем,— диде ул,— мәктәптә сабак бирү Хазар-стандагы кебек калгандыр бит?..

— Калды-калды, анакай, барысы да Аккала сараендагыча алып барылачак, тик инде ислам диненә йөз тотып, изге дингә.

— Рәсүлем,— диде аңа Сара анакай,— балага сабак бирү һәр илдә дә сүздән башлана, сан белән дәвам ителә, тарих вә фәйләсуфия белән тәмамлана. Хәтерем ялгышмаса, син дә Аккала мәктәбен тәмамлаган идең түгелме? Гаязетдин шулай дип әйткән иде.

— Хак Тәгалә шулай, анакай, укыган идем. Без шул тәртипләрне монда да дәвам итәргә булдык.

— Уңган кеше булдың әле син, Рәсүл. Исемең дә матур, үзең дә ипле күренәсең, иншалла, Гаязетдин тархан исеменә тап төшермәссең.

— Боерган итсә, анакай, Аллаһыбыз боерган итсә,— дия-дия, Рәсүл атлы имам хәзрәтләре Сара анакайга бил бөкте.

— Адәм баласына гына түгел, мал көтүчесенә дә тиккә генә чыбыркы шартлатмыйлар, балакай. Әнә шуңардан сак бул, имам хәзрәтләре Рәсүл. Сиңа минем улым Гаязетдин — Казан тарханы Гаязетдин сарай мәктәбен ышандырып тапшырды. Синең мөгаллимнәрең сабак биргән шәкертләр ил түрәләре булып китсеннәр. Шуның өчен тырыша минем улым Гаязетдин, шуның өчен, имам хәзрәтләре…

Бөтен бүлмәләрне дә йөреп чыккач, Сара анакай ашханә бүлмәсенә юнәлде, барчасы да аңа иярделәр. Хәзер инде имам хәзрәтләре алдан йөрмәде, ә Сара анакай аларга суфичы булды. Айбиби янәшәсендә барган улының иңенә кулын салды. Ошады аңа мәктәп, имам хәзрәтләре дә, хәтта Сара анакай да. Ә бит алар элек тә, сирәк-мирәк булса да, сарайга килгәләделәр, ләкин Сара анакай аларны беркайчан да болай җылы каршы алмаган иде. Бүген исә үзе үк суфи ана булып йөри. Аш янында да, кызым сиңа әйтәм, киленем син тыңла дигәндәй, Сара анакай Айбибигә карап:

— Без, киленкәем, Казан каласын Аккаладан ким итмәбез, менә күрерсең, ким итмәбез. Язган булса, киләсе язга румнардан осталар китертеп, кала тирәли зур кальга күтәрергә керешербез. Калын иттереп коймаларын күтәртербез, өстәмә күзәтү манаралары төзетербез һәм тимер белән ныгытылган капкалар. Капкаларда айбалталар тоткан яугирләр-сакчылар торыр. Нәкъ Хазарстандагыча. Казан каласы бер дә Ханбалыктан ким булмас.

— Шулай булыр, иншалла, шулай булыр. Кальгаларны күреп, баскынчы викинглар Казан тарафына әйләнеп тә карамаслар,— диде имам хәзрәтләре, Сара анакай белән килешеп.

— Киленем әйткәнчә, Болакны да кораблар керерлек итсәк, сәүдә үзеге бирегә күчмәгәе әле, имам хәзрәтләре. Шулай бит, киленкәем. Бу мәктәпнең сызымнарын Гаязетдин улым белән киленем икәү сыздылар, икәү киңәшә-киңәшә эшләделәр. Һәм менә нинди мәһабәт бина күтәрдек…

Айбиби бер сүз дә әйтә алмады. Күрәсең, борын заманда да, ягъни Аккалада яшәгәндә дә, Сара анакай беркемгә дә баш бирмәгәндер — бигрәк тә раввааларга.

* * *

Ибраһим улы аны асма күпергә кадәр озата килде. Айбиби күз яше белән елады. Калдырасы килмәгән иде улын Казанда. Әмма һични кыла алмады. Бала белем алырга тиеш, җитмәсә, аның улы. Атасы исән булса һәм алар Аккалада исән-имин көн күргән булсалар, бик ихтимал, Йосыф кахан улын Византиягә укырга җибәргән булыр иде. Шулай иткәннәр борынгы ил башлыклары. Ләкин язмыш аларны туган якларына кайтарып ташлады, Болгарга гына түгел, Казанга кадәр. Зарланмый Айбиби: Аккошлар күле буендагы утарда яшәү өчен барлык шартлар да бар иде. Бит аның хезмәтчеләр тотарлык та акчасы юк, бар чыгымнарны Гаязетдин тархан күтәрә. Казансу елгасының уң ягында зур гына базар. Күперне үткәндә, шул базарга күз ташлады Айбиби. Халык арасында чалмасына тутый кош каурые элгән мөхтәсиб йөри. Хәрәмләшкән сатучыларны тикшерә, бизмәннәренә тамга сала. Шулай дигән иде аңа Рәшидә абыстае, бер тапкыр әлеге базарга туктагач. Бүген Айбибинең базарга керәсе килмәде. Аңа кисәк кенә моңсу булып китте. Сәбәбе дә билгеле: ул Ибраһимыннан аерылды. Инде берьялгызы калды. Әлбәттә инде, Ибраһим бик тиз сарай гадәтләренә өйрәнер, абасы Гаязетдин кырында булырга тырышыр. Әнисен бөтенләй үк онытмаса да, бик сирәк исенә төшерер. Хак, нигәдер Гаязетдингә түгел, Айбибигә Сара анакай: «Борчылма, килен, Ибраһим өчен, айга бер җибәреп торыр ул сиңа аны, үзем исенә төшерермен»,— дигән булды. Күр әле, бик тә гап-гади хәл ителә икән ләбаса! Ул инде карынында йөрәк иңдергән, йокысыз төннәрен калдыра-калдыра ана каздай карап, саклап үстергән бәбкәчен ят кеше кулына калдырып китәргә мәҗбүр ителде. Саубуллашканда Айбиби еламады, түзде, хәзер исә, юлга чыккач, ат

теркелдәп юырткanda, кучәрбаш йокымсырап баргангамы, тамагына яшь төере килеп өелде. Әллә соң Аллаһы Тәгалә һәр адәм баласына да гомерне дә, мәхәббәтне дә, бәхетне дә бизмәнгә салып, тип-тигез итеп үлчәп бирәме?.. Хәзер бер нәрсәне ачык аңлады Айбиби — әлегә кадәр ул кемнеңдер бәхете исәбенә бәхетле булды. Сулаган һава, эчкән су кебек бәхет тә һәр кешегә дә үлчәп бирелә, күрәсең. Мин Хода биргән суны артык эчәм икән, димәк, мин кемнеңдер өлешенә керәм, йөрәк тибеше белән сулаган һава да шуннан. Әгәр дә мәгәр сиңа моңа кадәр бәхет һәм мәхәббәт мулдан бирелгән икән, син шул мәхәббәт һәм бәхет суында кайнап, шатланып яшәгәнсең икән, димәк, бу гамәлең белән син кемнеңдер өлешенә кергәнсең, кемнеңдер мәхәббәтен, бәхетен урлагансың... Күр инде, нинди дөньяда яши икән ул. Бик ихтимал, аның һәр бәхетен, һәр мәхәббәт тулы мизгелен Ходай үзе күзәтеп торгандыр?..

Айбиби шушы уйлардан соң бераз тынычлана төште һәм тирән итеп сулыш алды. Яши бит әле, яши, нигә аңа бу кадәр уфтанырга, бит ул аласын мулдан алды, хәтта артыгы белән мулдан...

Күкрәген имеп үскән, ана канаты астыннан чыкмаган, чыкса да ерак йөрмәгән Ибраһимын калада калдыру аңа җиңел булмады. Кайтыр юлга чыккач, Казансу елгасы күперен узып, урман юлына төшкәч, Айбибигә тагы да моңсурак булып китте. Ул үзен әле агачлар арасында адашып йөргәндәй хис итте, әле корыган агачның ботагына кунып, ялгызлыгына зарланган байгыш хәлендә калгандай әкрен генә ыңгырашып куйды. Әйтерсең лә кемдер аны рәнҗетә, кемдер зинданга ташлаган һәм аның ихтыяр көчен сыный иде. Әйе, ул кем? Аллаһы бармаклары арасыннан җир өстенә төшкән тузан бөртеге генә ич. Азмы аның кебек ялгызлар бу дөньяда?! Бик күптер. Менә кайтырсың да аккошлар ашатырга төшәрсең, нарат башында күлдәге аккошларны күзәткән каракошны куркытырсың. Ә Ибраһим әнә шул явыз каракошны үсеп-исәйгәч уктан алыр, бу тарафларга килмәс итәр.

Һәм шулай итте дә, кайта-кайтуга күл буена төште, җимчедән аккошлар азыгын сорады да, юл киемнәрен дә салмыйча, күл буена төште. Аны күрүгә, тирә-яктагы аккошлар, үрдәкләр, казлар җим салган төбәккә каңгылдаша-каңгылдаша җыела башладылар, иң башта җитез үрдәкләр җитештеләр, аннары казлар, ахыр, салмак кына йөзеп, үз дәрәҗәләрен белеп кенә, аккошлар килделәр. Айбиби аларга җим ташлады, үзе дә белми, нигәдер күзләреннән яшьләр акты. «Ашагыз, ашагыз, кошкайларым, ашагыз, хәзер мин сезне һәр көн үзем ашатачакмын, үзем...» Һәм ни сәбәпледер өстәде: «Хазарстандагы кебек». Әйе, син анда бәхетле идең, Айбиби, бәхетле идең. Тик кем көнләште аның бәхетеннән? Кем күпсенде?..

Шунда Айбибинең аръяктагы балык тотып утыручы дәрвишләргә күзе төште. Ни өчендер дәрвишләр суык көннәрдә дә, эш көннәрдә дә тоташ карадан киенерләр иде. Һәм алар беркайчан да коенмыйлар. Судан куркалар булса кирәк, шулай диде аңа улы Ибраһим. Айбиби аңардан нигә куркалар, дип сорамады. Дәрвишләрнең берәр йоласы дип кенә тынычланган иде. Хәзер исә, көн җылы булуга да карамастан, дәрвишләрнең барысы да тоташ карадан киенгән килеш балык тоталар иде. Дәрвишләр өчәү. Күренеп тора — сөйләшмиләр. Күзләре калкавычларда. Улы Ибраһим дәрвишләр балык яраталар икән, диде. Кем балык яратмый! Тик моның өчен аны тотарга кирәк. Гаязетдин әнә җәйгә ике-өч тапкыр утарга килә дә балыкчы чирмешләрдән Аккош күленнән җәтмә белән балык сөздертә. Шул көннәрдә утар гөжләп торыр иде. Балык шулпасы пешерерләр, куырырлар, утта кыздырырлар, бала-чагалар уйнарлар, көләрләр, бер-берсен куышырлар иде. Айбиби, дөньясын онытып, Ибраһимының каладан килгән балалар белән уйнавын күзәтер иде. Күрде-күзәтте ич, Ибраһим, аның Ибраһимы, гел бер кыз баланы куды, гел аны куып тотты һәм гел аның янында булырга тырышты. Айбиби кечкенә, әле үсмер генә кызга теге яклап та карады, бу яклап та — кыз бала аңа ошады. Әмма соңыннан кыз баланың чирмеш бәге кызы икәнен белгәч, аптырабрак калган иде. Тик моның белән генә кыз баладан гайрәте чикмәде. Чирмешләр гомер-гомерләргә, Аттила бабалары чорларыннан бирле, төрки-татарлар белән бергә булганнар, бергә яу йөргәннәр, бергә ил-җирләрен саклаганнар, дин-йола вә гореф-гадәтләрен читкә куеп, теге якны да, бу якны да рәнҗетмичә, кызларын төрки егетләргә кияүгә биргәннәр, егетләрен төрки кызларына өйләндергәннәр. Тик кем бәгенең кызы икән? Чирмеш бәге Гаязетдин кул астында хезмәт итә булса кирәк, чөнки бәк үзе биредә булмаса да, кызы килгән ич. Шул хакта нә сорарга теләсә дә, нә Гаязетдингә, нә Бибисарага сүз ката алмады. Әмма кыз баланың төсе-йөзе генә түгел, буе-сыны, зифалыгы да күңеленә сеңеп калган иде. Күр инде, ул үзе дә бит нәкъ шулай киенер иде. Бала итәкле күлмәк, башында калфак, зур булмаган хаситә, аягында ак болгари итек. Кыз баланың инде күкрәге дә калкып чыга башлаган. Әле булса хәтерендә, күкрәге үсә башлагач, шул тирәләре кычыта башлаган иде. Ә Рәшидә абыстай, моны күреп: «Курыкма, балакай, угала син аны, угала, кычытуы шундук бетәр»,— дигән иде. Шул мәлләр хәтер күгендә пәйда булуга, Айбиби үзалдына елмаеп куйган иде. Аның тик торганда елмаеп утырганын күреп, тарханбикә Бибисара: «Җиңгәчәй, Гаязетдин бәге кызыннан күз дә алмыйсың, әллә Ибраһимга кыз да сайлый башладың инде?» — дигән иде. Айбиби аңа бер сүз дә әйтә алмады. «Бишектәге бала — бишкә үзгәрә»,— дип әйтергә итсә дә, тыелып калды.

Айбиби аккошларны ашаткач, өйгә таба кузгалды. Шул чакта аның күзенә озын нарат башында утырган каракош күренде. Каракошны күрде дә Айбиби шып туктап калды. Һәм каракошка карады. Юк, ул аңа уктан атарга дип туктамады. Ул — бу явыз кошка тагын ни җитми сиңа? дип туктады. Чөнки ул аңа да нарат агачына ит элдерә башлаган иде. Иң сәере шул, каракош баштагы мәлдә агачка элгән

итне рәхәтләнеп ашаса да, үтә канәгать калып, кай тарафкадыр очып китсә дә, соңрак бу яман кош итне дә алмый башлады. Әмма нарат башына килеп куну гадәтен ташламады. Айбиби аны куркытмады, берни булмаган кебек үтеп китте. Күрәсең, яман кош та аңа өйрәнә башлаган иде инде, кымшанмады да, бары тик битараф бер төстә күзен йөртеп кенә аның ягына карап алды.

Хезмәтчеләре аңа табын хәстәрләгәннәр, аны көтеп торалар иде инде.

— Ибраһим кайтмадымыни? — дип сорады ишектән керә-керүгә өлкән пешекче апа.

— Ибраһим тархан мәктәбендә укыячак хәзер, Хөсниҗамал апа,— диде Айбиби, җиз таз өстендә кулын юа-юа.— Әйбәт кенә тордыгызмы соң үзегез?

— Ибраһим өй тутырып йөри торган иде, ул китkәч, бу өй генә түгел, утар өйләре бушап калган кебек, Айбиби. Кайткалар, шәт, Ибраһимны, дим?

— Иншалла, кайткалар,— диде Айбиби.

— Беләсеңме,— диде аңа аш янына килеп утыргач Хөсниҗамал апа.— Безгә ис итмәгәндә ниндидер тоташ кара киемдәге арыякта яшәүче дәрвишләрнең берсе килеп китте.

— Кемне сорады?

— Ибраһимны. «Теге углан кая булды, абыстай?» — дип сорады, менәтерәк, Айбибием. Мин әйтәм, углан тархан сарае мәктәбенә укырга китте, ул хәзер бик сирәк кайтачак, нигә кирәк булды сезгә ул бала, дигән идем, бер сүз әйтми, борылды да китте, Айбибикәем. Мин аны тозүче итәргә иткән идем, диде, менәтерәк, Айбибикәем. Бөтен йөзен тутырып кара сакал баскан, күзләре генә елтырый үзенең, менәтерәк, Айбибикәем.

— Яңадан килсә, капкадан да кертмәгез,— диде Айбиби һәм бу хакта онытты да. Тик кич кояш баеп, хатын-кызлар зур бүлмәгә җыелып, дөньяви китаплар укып утырганда гына, сәер дәрвиш хәтер күгендә ялтырап үтте. Нигә булыр? Чынлап та, ул йөзе-башы кара сакаллы дәрвиш кем булыр? Нигә аңа нәкъ менә аның улы Ибраһим кирәк булды икән?..

Җырлар җырлап, бәйләм бәйләп утырган һәр хатын-кыз үзенең яшьлектә булган беренче мәхәббәтен, язмышын сөйләде, әмма берсе дә, кыеп, син дә сөйлә әле, Айбиби, дип әйтмәде. Хәер, аның язмышын барысы да беләләр иде инде. Хан кызы ич!..

Нәрсә тапты да нәрсә югалтты Хазар каханы каханбикәсе булып Айбиби? Җавабы бер иде — ул үзенең мәхәббәтен тапты. Ни гаҗәп, кырык хатыны булган Йосыф кахан йөзендә. Кемгә сөйләп, кемне ышандыра ала ул?.. Ләкин ул аңа гашыйк булды ич, булды. Һәм бер күрүдә! Әле булса ул аны юксына, тансыклый. Нәрсә бу? Мәхәббәтме, әллә соң язмышына буйсынумы?..

Ятагында китап укыганда, аны бер читкә куеп, әнә шулай еш кына уйга калгалады Айбиби. Улы да киткәч, аңа көн саен моңсурак була башлады. Ул моны бөтен җаны-күңеле белән тойды. Ялгыз калды ич ул, бөтенләй ялгыз! Аңа хәзер бу утар да, хезмәтчеләре дә — беркем дә кирәкми. Улы, улы кирәк аңа — Ибраһимы...

Менә шунда кинәт, зиһене аша яшен чаткысы узгандай, күз алдына Йосыфы килә. Кинәт кенә ничек юкка чыга ул? Бит ул кахан! Илбашы!

Шул хакта беләсе килә иде Айбибинең, кемнән дә булса сорашасы, кем белән генә булса да шул хакта сөйләшәсе килә иде. Кеше тузан бөртеге түгел ләбаса, адәм баласы, җитмәсә, илбашы. Һәм шул кеше кисәктән юк булсын инде. Ә бит сарай халкын үз кулында тоткан өлкән равва исән! Кахан — юк, өлкән равва исән! Җитмәсә, күзен дә йоммый Шәмгун хан сараена кереп оялаган — мөфти булып киткән, мөфти, бөтен имамнарга имам, муллаларга мулла. Ул гынамы, аның анасы кебек кешене үзенә ябыштырып алып китте. Менә монысына җавап таба алмады Айбиби. Шул ук вакытта ни өчен Сара анакай аны кабул итми дә, ә менә Рәшидә анакае Ибраһим мөфтинең җәмәгате булып китә?..

Айбиби кулына янә укыган китабын ала, укый башлый, башына килгән уйлардан арынасы килә. Тик инде укый алмый, уйлар аның бөтен күңелен биләп алган иде. Ул кузгала, аягына җофар чүәген элеп, өстенә шундый ук җофар халатын салып, йокы бүлмәсенең балконына чыга, күл өстенә мөлдерәп төшкән тулы айга карый. Сәер дә соң бу дөнья. Нигә тулы ай көннәрендә аның күңеле хиссияти истәлекле уйларга чума да һәм ул сагышлана башлый. Әллә соң тулы ай аның хиссияти мәхәббәтен үзендә саклыймы һәм ай саен шул хакта искәреп торамы?..

Күл тыныч түгел, көтмәгәндә адашкан үрдәк бакырып куя, күп тә үтми аның кырына ише килеп төшә һәм алар, үзара сөйләшеп алгандай, тыенкы гына бакылдашып алалар.

* * *

Бер ай да үтмәде, Айбиби янә Казан каласына таба кузгалды. Барысына да иртән күргән төше гаепле булды. Имеш, аның улы Биләрдән килгән мөфти Ибраһимга ияреп китеп бара, ә ул аны күпме Казанда калдырырга теләсә дә, үгетләсә дә, Ибраһим аны тыңларга теләмичә китеп барды. Уянып киткәннән соң күргән төшен янә бер тапкыр башыннан уздырды. Әүвәл Айбиби күргән төшен утар карачысы Хөс-

ниҗамал абыстайга сөйләргә иткән иде, тыелып калды. Юрамый торсын әле, Ходай язганы булыр, үзем барып кайтам, үзем беләм күргән төшемнең хаклыгын, хак түгеллеген.

Күчәрбаш та, аның ашыкканын белгән кебек, атларны куалады, ни гаҗәп, асма күпердә дә гадәттәгечә кальгага керергә чират торучылар юк иде. Айбибинең күчәрбашын күреп, сакчылар капкаларны ачтылар һәм каханбикә күчәрбашы сакчыларга баш кагып кына сәлам юллады да атларын туп-туры Гаязетдин тархан сараена таба куалады. Сарай болдыры янына атлар туктауга, күчәрбаш баскычны төшерергә дә өлгермәде, Айбиби арбадан төште, каханбикәсенә арбадан төшәргә ярдәм итә алмаган күчәрбаш, гафу үтенгәндәй, кулларын җәйде. Айбиби беркемне дә күрми иде инде, йөгерә-атлый баскычлардан сарай ишекләренә таба ашыкты. Сакчылар аңа киереп ишекләрнең бер канатын ачтылар, бусаганы атлап керүе булды, аның каршында Ибраһим мөфти пәйда булды.

— Ау-о! — диде ул, Айбибине күрүгә.— Йа Хода, Айбиби каханбикә үзе. Исәнме-саумы, каханбикә,— дип, күрешергә ике кулын сузды.— Килен, килен, дим, саумы!..

Мөфти булып алган Ибраһим артында кайдадыр күргән таныш йөз чалынып алды, әмма Айбиби игътибарын Ибраһим мөфтигә күчергән иде инде.

— Рәшидә абыстай...

— Монда, монда, Рәшидә абыстай да монда, кызлар мәдрәсәсенә киткән иде. Кайтыр ул, кайтыр, каханбикә Айбиби, кайтыр...

Теләсә-теләмәсә дә Айбиби Ибраһимга күрешергә кулын сузды. Көрәк кадәр кул эченә кереп эләккән сандугачтай сизде Айбиби үз кулын. Кулын гына түгел, тәне-җанын да. Һәм, аркасы буйлап салкын дулкын узуын тоеп, куырылып китте.

Ул арада Айбиби каршына Гаязетдиннең тарханбикәсе Бибисара йөгереп килде.

— Җиңгәчәй, әйдәгез, узыгыз, Гаязетдин сезне көтә,— диде дә Айбибине кочаклап алды һәм колагына: «Улыңызны хан сарае мөфтие Ибраһим Биләргә алырга килгән, Шәмгун хан үтенече»,— диде.

— Мин моңа шатланырга тиешме, киленкәем Бибисара?..— диде барыр җайда Айбиби.

— Шатланырга, шатланырга тиешсең, җиңгәчәй, шатланырга. Хан дәшә ич, хан үзе.

Айбиби бер сүз дә әйтмәде. Ул бу хәлнең мөфти Ибраһим җәтмәсе икәнен бераз чамалый иде, ләкин бу хакта кемгә булса әйтергә курыкты. Бит Гаязетдин тарханның мәдрәсәсендә менә дигән белекле мөгаллимнәр сабак бирә. Әллә соң Гаязетдин дә Ибраһим мөфти җәтмәсенә эләгергә өлгергәнме?.. Башта Рәшидә абыстайны, Гаязетдинне, хәзер улы аша аны — Айбибине...

Ул арада тәхет ягына керделәр, Гаязетдин тархан, хатыннар ишектән керүгә, үзе үк аларга каршы китте.

— Исән-имин килдегезме, җиңгәчәй, иминлекме?.. Утарда иминлекме, дим?..

— Аллага шөкер, анда барысы да әйбәт, Гаязетдин.— Айбиби аның күзләренә карады һәм янә тәне кымырҗып куйды.— Улымны ерагайталар, дип ишеттем дә...

— Барысы да әйбәт булыр, Ибраһим сарай тәртипләренә өйрәнә торыр. Шәмгун хан фарсылардан белекле галимнәр дәштергән, гарәпләрдән дә килгәннәр, сарай мәдрәсәсендә балаларга сабак бирәчәкләр. Әйдәгез, җиңгәчәй, түрдән узыгыз. Башта аш ягына узыйк, тамак ялгап алырбыз. Ул арада Рәшидә абыстай да кайтып җитәр, бергәләп Кабан күленә төшәрбез. Мин, җиңгәчәй, Кабан күлендәге утрауга мәһабәт бер өй-утар күтәртеп ятам бит әле. Сызымнарын да үзем эшләдем. Осталар да таптым. Бишәүләр, өчесе фарсылардан, икесе румнардан.

Аш ягында аның җиз тазга җиз комганнан кулын юдырттылар, кулларын чиккән сөлгегә сөрткәч, Гаязетдин җиңгәчәсенең терсәгеннән алды, табын янына китерде. Кулы терсәгенә тиюгә, янә әллә нишләп китте Айбиби. Бит инанды инде, күптән инанды, Гаязетдин Йосыф түгел, әмма барыбер ул кагылган саен, тәне тетрәп куя иде.

— Сара анакай кая соң? Минем аны күрәсем, утырып бер сөйләшәсем килә, Гаязетдин тархан.

— Кайтыр ул, Самарага киткән иде. Аның тагын бер улы анда тархан булып утыра ич.

— Самарада, Сара анакайның улы тархан?! — дип гаҗәпләнде Айбиби.— Нигә мин бу хакта белмим?..

— Йосыф каханның кырык хатыны бар иде, Айбиби җиңгәчәй,— диде Гаязетдин, табындагыларга ризыктан рәхим итегез дип баш какты.— Ул угланны да Сара анакай карап үстерә...

Килене Бибисара Айбибигә иелә төшеп, колагына гына:

— Ибраһимның монда килүен ишетүгә китте Самарага анакай, миңа күрәсем килми шул мөртәтне, диде. Гаязетдин бу хакта белми, анакай әйтергә кушмады.

Айбиби килене Бибисарага карап алды, елмайды, ияк кагып кына рәхмәт әйтте. Аңа хәзер, менә хәзер, Рәшидә абыстайны күрәсе иде дә, һаман кайтмый, ә Ибраһим мөфти табынга да узмады.

— Ибраһим мөфти Рәшидә абыстайны каршы алырга китте,— диде Гаязетдин тархан, Айбибинең ни уйлаганын белгәндәй.

Айбиби бер сүз дә әйтмәде, чәк-чәк белән әкрен генә чәй эчте, ә үзе уйлады. Өлкән равва буларак, бер илне таратты бит инде бу Ибраһим. Хәзер Идел буе Болгарына керешәчәкме?.. Беләме икән шул хакта Шәмгун хан да Гаязетдин тархан?.. Юк, әлбәттә, белмиләрдер. Белсәләр, сарайларына кадәр бу

кешене уздырмаслар иде. Димәк, Хазарстанны таркаткан өлкән равва Ибраһим инде Идел буе Болгарын таркатырга җыена. Шулай булмаганда, нигә бу кеше ислам динен кабул итеп Болгарга килә дә, хәтта Казанга кадәр уза. Кем кирәк аңа, ни җитми бу Исраил баласына?..

Айбиби шулай дип уйласа да, бу хакта беркемгә дә әйтергә кыймады. Аны, гомумән, монда берәү дә аңламас иде. Аңласа аңлар аны Сара анакай. Ләкин ул өйдә юк, Самарага киткән. Кайтыр ул аннан, кайтыр һәм Айбиби, аның янына килеп, барысын да сөйләр. Ибраһимның чын йөзен ачар.

Ул арада Рәшидә абыстай кайтып керде. Керде дә йөгерә-атлый килеп, Айбибине күкрәгенә иңдерде.

— Сине күрер көнем дә бар икән, балакаем! — Йөзен читкәрәк алды, Айбибинең күзләренә бакты.— Ябыгып киткәнсең димме, балакаем. Юк, ябыга төшкәч, син тагын да сылуланып киткәнсең ич. Күз алмалы түгел үзеңнән, күз алмалы түгел.

Ул аны тагын-тагын күкрәгенә кысты һәм елап ук җибәрде. Һәм колагына: «Талибымны күргән кебек булдым, балакаем, Талибымны»,— диде.

Ашап-эчкәч, фарсы келәменә кырпачалар ташлап, түгәрәкләнеп утырдылар да кем нинди яңалык белә, шул хакта сөйләргә тотындылар. Айбибигә нәүбәт җиткәч, ул:

— Сөйләр яңалыгым юк, без анда яшәргә өйрәндек инде,— диде.— Менә Ибраһимым төшемә керде дә килдем әле. Иртән торабыз да аккошлар ашатырга төшәбез...

— Әнием, дәрвишләрнең безнең якка чыкканнары юкмы? — дип, әнисеннән сорады Ибраһим.

— Юк, чыкканнары булмады. Без киткәчтен берәү килеп киткән, балык тотарга камыр сораган.

— Камырга вак балык каба, эре балык сабан кортына каба, әнием.

— Мин ул дәрвишләргә сабан кортына кадәр казып бириммени инде, улым. Балыкларын үзләре ашыйлар, җимне без бирикме?

— Алар кимсетелгән халык, суфилар, изге җаннар.

— Изге җан күл буенда балык тотып ятмый, кырда эшли, улым.

— Йә булмаса минем төзүчеләр кебек биналар күтәрә,— диде тархан Гаязетдин.

— Кабан күле буенда утар әзер булгач, Айбиби җиңгәчәй, мин сезне шунда алып барам әле. Җәннәт анда,— диде тарханбикә Бибисара.

— Күрәсем килә. Тик мин үзем дә оҗмахта яшимдер кебек, Гаязетдин туганыем шундаен матур итеп күтәргән утарны, үткән-сүткән кеше туктап-туктап карый.

— Тырыштык инде, җиңгәчәй, сезнең өчен тырыштык. Тик менә атамның гына әле булса табылганы юк.

— Илдә чыпчык үлми, иншалла, табылыр. Фарсыларга фәлән киткәндер йә викинглар алып киткәннәрдер үзен,— диде Гаязетдин.

Мөфти Ибраһим тамак кырды, әмма бер сүз дә әйтмәде. Рәшидә абыстай гына:

— Ризыгы бетмәгән булса, иншалла, кайтыр. Минем әле булса хәтеремдә: сезне килеп алырмын, диде. Шулай бит, Айбиби?

Кыен иде Айбибигә бу хакта сөйләшү, аның күңеле тулышты, бер сүз дә әйтмәде, башын тагын да ия төште. Һәммәсе дә аңладылар, Айбибигә авыр бу хакта сөйләшү.

## XX

Хазарстаннан Биләргә күчеп килгән Ибраһим сөннәтле казаклар унбашы Сатлыкны, кая гына барса да, үзе белән йөртте. Хазарстанда унбаш вазифасын үтәгән бу кеше, Биләргә килеп мөфти булып киткәч тә, һәрчак аның янында булды. Нигездә, унбаш Сатлык аның җан сакчысына әверелде. Әйе, гәрчә бу кеше христиан булса да һәм муенына бакыр тәре тагып йөрсә дә, Хазарстан дәүләте диннәргә битараф булган кебек, Шәмгун хан да мондый хәлләргә игътибар итмәде. Иң мөһиме, аның кырында дистәләрчә еллар Хазарстан белән идарә иткән тәҗрибәле сәясәтче Ибраһим үзе иде. Болгар ханы: «Димәк, без Хазарстанның дәвамы»,— дип, үз-үзен юатты. Сарайда мөфти сурәтендә йөргән Ибраһимның чукынган сакчысын Шәмгун хан, гомумән, күрмәде, кызыксынмады да. Тарихлары белән дә таныш түгел иде. Бар белгәне шул — Хазарстан белән, нигездә, раввалар идарә итә, Йосыф кахан түгел, шул ук вакытта хәбәрдар иде инде: Йосыф каханны Хазарстан тәхетенә күтәрүче бүген аның сараенда мөфти вазифасын үтәгән Ибраһим була. Ләкин бит Хазарстанда кала тарханы булып торган Булат бәк тә бүген аның сараенда утыра һәм киңәшчесе генә түгел, сәргаскәре дә. Иң гаҗәбе, Биләр сараена килеп оялаган Ибраһимга Булат бәк тә шаккатмады. Моның өстенә хәйләкәр яһүд ислам диненә күчеп кенә калмаган, сарай мөфтие дәрәҗәсенә әверелеп, Казан тарафындагы Хазарстанда никахлашып, Рәшидә абыстайны да алып кайтты. Шуның өчен нә Ибраһим, нә Булат бәк булган хәлләр турында сөйләргә дә, сөйләшергә дә теләмәделәр. Бу — алар өчен тыелган әңгәмә иде. Моның өстенә бер төрки дөньясының олуг илен югалтып, икенчесен шундый ук куәтләндереп җибәрәсе юнәлешендә хәрәкәт итәләр, җитмәсә, Рәшидә абыстай ярдәме белән булса кирәк, Ибраһим Коръән хафизлыкта барчасын да шаккатырды. Ул гынамы, Ибраһим артыннан ук ислам динен кабул иткән яһүд сәүдәгәрләре Болгар һәм Биләргә килеп ур-

наштылар. Һәм Самара, Казан, Кызсорама калалары аша Киев каласына сәүдә юлын аякландырып җибәрделәр. Идел буеннан күтәрелгән сәүдә юллары әкрен генә алар кулына күчә башлады.

Бу хәлгә бигрәк тә Ибраһим мөфти канәгать иде. Бу кеше сарай мәктәбен киңәйтүдә, яңача уку-укыту эшләрен алып баруда алгы сафларда булды. Дини вә хәрби сабаклар янына дөньяви фәннәрдән сабак бирүне җайга салды. Гыйлемлек төрки-болгар халкының канына сеңеп керә башлады. Мөфти Ибраһим белән Рәшидә абыстай аларның бериш асыл шәкертләрен фарсыларга, хәтта Гарәбстанга укырга, сабак алырга җибәрделәр. Шулар янына сарай табибы үтенече белән аның улы Ислам да фарсыларга укырга озатылган иде.

Тик әллә нигә Ибраһим мөфти еш кына уйга кала. Ни өчен Хазарстан кадәр Хазарстан бик тиз таркалды. Бер туфан калкудан кала-салаларны юдырып алып киткән ташу гына гаеплеме? Әллә булмаса, хазарлылар үзләре гаеплеме моңа?.. Әйтик, ил белән идарә итүдә алгы сафта торган Ибраһим үзе?!

Шулай шул, соңгы елларда әллә ни булды Хазарстанга. Бу хәл, Айбиби хатын килгәч, үтә койтыга әверелде. Йосыф кахан ил белән үзбаш идарә итә, аңа буйсынмый башлады. Шул көндә үк булмаса да, шул елларда Хазарстан сараенда ике фирка барлыкка килде. Берсенең җитәкчесе халык белән идарә итүдә азау теше чыккан Ибраһим иде, икенчесенең башында җирле халыкка якын торган кала тарханы Булат бәк. Йосыф кахан исә боларның берсенә дә игътибар итмәде, әмма яудан кайткач, ил белән идарә итүне үз кулына алды. Моның белән генә канәгатьләнеп калмады, Йосыф кахан, гомумән, табын җыюдан баш тартты. Бу инде каханның ил белән үзбаш идарә итә башлавы иде. Ил өчен куркыныч гамәл иде бу, илне җимерүгә китерә торган гамәл. Шуны аңлап, өлкән равва вазифасын үтәгән Ибраһим Йосыф балакай белән берничә тапкыр очрашырга теләде, әмма кахан күп очракта угыл бала тапкан Айбиби хатын кырында юанды. Моны аңлавы кыен иде. Ахыр килеп, Йосыф кахан мөселманнарга каршы викингларны чакырудан баш тартты. Ә бит Ибраһим аның белән киңәшеп эшләгән иде моны! Янә бер зур хата җибәрде Ибраһим — кара мәзиннәргә янчык-янчык дирһәм түләп, яһүдләрнең синагогаларына ут салдырды, хәтта бер-икесен җимерттерде дә. Бу инде Яхвага каршы бару иде. Ләкин бит аңа, шул яман гамәлгә сылтап, илдән мөселманнарны куу мөмкинлеге туды. Бу үзенә күрә акылга корылган сәясәт иде. Арба ватылса — утын, үгез үлсә — ит кебегрәк килеп чыкты бу сәясәт. Чөнки өлкән равва Ибраһимның төп максаты каладан вә илдән мөселманнарны куу иде. Һәм ул моңа иреште дә. Ул арада викинглар килеп җиттеләр. Нindидер юллар белән кахан зинданга ташлаткан Булат бәк котыла, бөтен мөселманнарны диярлек каладан Биләргә алып китә — мөселманнарны, алдан сизгәндәй, викинглар явыннан гына түгел, Сулак, Терек, Идел елгалары ташкыныннан да коткарып кала. Йосыф балакай да гүзәл хатыны белән улы Ибраһимны Казанга озата. Елгыр, елгыр кылана Йосыф балакай. Бу хәлне Ибраһим белми дә калды. Астыртын эш итте Йосыф кахан, башта Болгар ханы Шәмгуннан Алпар йөзбашны чакырта һәм яшь хатынны, елы тулмаган угылын, шулар белән Рәшидә абыстайны да Казанга озата, җитмәсә, кем кушуы беләндер, Казан кырындагы күл буена Айбиби хатын өчен утар күтәрткән икән. Бу хакта да белми калды Ибраһим. Кем боларның барысын да оештырды?..

Айбиби хатынмы, әллә булмаса, барысын да алдан күреп, барысыннан да хәбәрдар булып торган Сара анакаймы?.. Бик ихтимал ич! Заманында Булан каханның иң яраткан сөекле хатыны булып, каханга ике углан бала тапкан анакай. Кахан вафатыннан соң, Ибраһимга кияүгә чыгудан баш тартып, Таман тарханы кырына күчеп китте. Углан Гаязетдин балигъ булгач, аны Йосыф аша Казан тарханы итүгә ирешә. Ә бит шуларның барысын да белеп, Ибраһим өйләнергә теләгән иде аңа. Сара анакай кырт кисте — чыкмыйм мин сиңа кияүгә! Әле булса хәтерендә — Ибраһимга шул сүзе җитүгә, ул тәмам йокыдан калган иде. Ни өчен чыкмый, ул бит раввалар башы, ә раввалар ил белән идарә итәләр һәм аның аша. Тик күп тә үтми барысы да асты өскә килде. Юк, монда өлкән равва Ибраһимның гаебе юк иде. Җимерде ил-каланы һәм тәүге башкаланы алган Сарманай кахан да, икенче башкаланы ул чакырткан викинглар да түгел, илдә Йосыф кахан алып барган сәясәт җимерде. Ватанны җимерүгә илткән сәясәткә ул да зур өлеш кертте шул. Ни сәбәпледер әлегә кадәр моның төп сәбәбен белми иде Ибраһим. Ләкин нигә, ни өчен Йосыф кахан көтмәгәндә Булат бәкне зинданга ташлый?.. Һәм кем коткара ул батыр бәкне?.. Сорыйсы килә иде шул хакта батыр бәктән, тик әллә нигә күңел моны теләми иде.

Аның тормыш юлы Исраил җирендә башланды. Хазар-станга ул Булан кахан чакыруы буенча бала чагында ук килде. Һәм үкенмәде. Үнды ул монда, өлкән равва дәрәҗәсенә ирешә. Аңа һәммәсе баш иде, һәммәсе дә буйсынды. Әмма еллар үтә-үтә язмыш аны әнә кайларга китереп ташлады — Идел буйларындагы Болгар дәүләтенә. Ул бу хәлне дә табигый кабул итте. Әйе, Яхвасы аны шулай йөртә, борынгы бабаларын да ассирәйләр әсир итеп алып киткәч, Бөек Кир коткарганчы шулай була ич. Килер Яхвасы аның янына, хәленә керер һәм ул, Рәшидә абыстаен алып, Исраил балалары иленә кайтып китәр. Чөнки инде ул Рәшидә абыстайдан башка яши алмый иде. Менә кем аның юанычы да, куанычы да, тормыш юлдашы да булып китте. Шул ук вакытта Ибраһим Биләр каласында мөфти вазифасын үтәсә дә, беркайчан да Яхвасын онытмады, шушы ерак бабалары Алласы аның күңелендә һәрчак зөбәрҗәт кебек җемелдәп торды. Үзе тәхеткә күтәргән Йосыф балакайны да шул юнәлештә тәрбияләргә тырышкан иде ул. Тик балакай кинәт юкка чыкты, әйтерсең лә үзен җир йотты. Йосыф исемен хәтта Рәшидә

абыстай да искә алмады. Тик илдә чыпчык үлми, диләр бит. Гомере булган кешенең аты-исемен бер ишетмәсәң, бер ишетәсең икән ул.

Бу хәл көтмәгәндә булды. Ибраһим еш кына базарга чыкты. Халык сүзенә колак салып йөрде. Базар читендәге мәйданчыкта бер төркем халыкны күреп, шунда таба атлады. Килде, бер читкәрәк басты, мәйдан уртасына җәймә салып бөкләнеп утырган суфиның сүзләренә колак салды. Сүзенең аты-башы юк, вәләкин көйле, җор телле иде суфи. Тагын да якынрак килде. Әһә, суфилыкка йөз тоткан борадәр зат сөйли. Теле телгә йокмый. Борадәрнең алдында тирән кара түбәтәй, кара чикмән башлыгын күзләренә төшереп үк кигән, түбәтәйгә очкан тәңкәләргә күз дә ташламый, сөйли дә сөйли.

«...Атамыз Әхмәт Ясәви әсәрләренә күз салыгыз, мөгаллимебез Мәхмүд Болгари сәяхәттә. Кайтыр ул, кайтыр. Без, борадәрләр, Казан елгасы буендагы салада яшибез. Халык безнең каланы Дәрвишләр саласы дип атый. Табыныбыз, ризыгыбыз уртак, догабыз Ходадан. Дәрвишләр саласында тиздән мәктәп ачачакбыз. Җибәрегез улларыгызны, үкенмәссез. Әйе, без байлар түгел, әмма без рухыбыз белән ярлы янында ярлы, бай янында бай. Күңелем белән бай мин. Күңел байлыгының бәһасе юк. Күңел байлыгы — гыйлемдер, алтын-җәүһәр, көмеш-якут дип бер дә лаф орасы юк. Күңелем келәтендә җәннәт бакчасындагы барлык җимешләр дә бар. Ни өчен шул көнгә калдым соң мин? Гүзәл хатын мине шул көнгә калдырды, җәмәгать, гүзәл хатыным. Юк, мин аңа рәнҗемим. Мактыйм мин аны. Сөбханалла, чибәр иде дә соң, гүзәлкәем. Кочагыма иңү белән күгәрчендәй гөрли башлар иде. Назлап сөйдем, үпкәндә кершәннәрен коймаска тырыштым. Нечкә биленнән кочтым, зифа сынын оныта алмый әле булса җәфаланам, сагышланам, Аллаһыма: «Кайтар шул гүзәлне кочагыма!» — дип ялварам. Бер төнгә булса да. Юк шул, юк, хәзер инде бәхетемне күктән көтәм. Оныта алмый интегәм сөйгәнемнең шомырт кара күзләрен, мин — синеке, син — минеке, дигән сүзләрен. Хыял — эссе, хисләр көчле чак иде, күңел — яшен, тойгым чаткы иде. Юк-юк, мин ялгыз түгел, ул кайтыр миңа, кайтыр, кайтыр минем кырыма, күкрәгемә килеп капланыр да: «Гөрләшеп яшик әле тагын бер, Җәмилем»,— дияр сыман. Шайтан — өметсез, диләр, ә мин адәм баласы ич. Әлегә мин гыйлем җыям, зиһенем чарлыйм, хәтерем баетам. Кайда? Үзебезнең Дәрвишләр саласында. Алай да төшемә керәсең, гүя акбүз атта кайтасың, акбүз атка салып алып киттеләр ич бәгыремне! Төшме, өнме — белә алмый уянам, Хода биргән татлы төшләремә кинәнәм. Бер күрергә моң-зар булып яшимен, чарасыздан мендәр башын тешлимен. Тулган айдай күзләреңне бер күрсәм, үлсәм дә ризамындыр, зифа сының бер сөйсәм. Әмма кавышып булмас, син дә, мин дә сәбәбен беләбез, җәннәтләрдә очрашырбыз дип, әҗәл көтәбез... Көлик, әйдә, көлү безгә килешә лә, йөрәккәем күкрәгемдә тибешә лә. Бәхетсезлегемне белү үзе бәхет миңа, диванадай гашыйк кеше өчен мәхәббәтем тәхет миңа. Артык бәхет исертәдер адәмең, түзмәй җаным, кулга алам каләмем. Агач башлары бөдрә-бөдрә, бөреләрен кояш көйдерә, күз алдыма килгән саен зифа сының, җаным, сөйдерә. Әй кешеләр, яшәмәгез яратмаган җаннар белән, коры-сары чит-ят каннар белән. Кая китте соң яшьлегем, дисезме?.. Сагышланмас өчен кулыма алам дисбемне. Беләм, сизәм, тоям, күрәм, үткәннәргә кайтулар булмастыр, бер баеган кояшларым яңадан чыкмастыр. Тәүбә итә-итә, гөнаһымнан качамын, сөбханалла, дия-дия, намазыма басамын...»

Борадәр тынып калды, түбәтәйгә акчалар коелды. Халык: «Һай, Аллам, һай, Тәңрем!» — дия-дия тарала башлады. Ялгыз калган борадәр янына Ибраһим килде һәм түбәтәйгә бер бәлеш алтын ташлады. Түбәтәйгә алтын тәңкә төшүгә, борадәр башын күтәреп Ибраһимга карады.

— Хатының үзең теләп биреп җибәрдеңме? — дип сорады эретерәк кенә Ибраһим.

— Үзең теләп атларны гына саталар, ил бәндәсе. Батыр бәккә ияреп китте, җанашым, күз нурым.

— Хәзер башың диванага салып, Дәрвишләр саласында көн күрәсеңме?

— Язмыштан узмыш юк, Алла бәндәсе. Мин үз язмышым белән килештем.

«Минем кебек иткәнсең икән»,— дип уйлады Ибраһим һәм түбәтәйгә тагын бер бәлеш алтын ташлады. Бу юлы инде диванага башын салган борадәр торып ук басты.

— Мин үзем дә бәкләр санында йөргән кеше идем, Алла колы, мине хатыным шул көнгә калдырды.

«Мин шул көнгә калмадым, иншалла, юлымда Рәшидә абыстайга юлыктым»,— дип китәргә җыена башлады Ибраһим, гәрчә бу сүзләрне күңеленнән генә уйласа да, аның ни турында уйлаганын белгән кебек, борадәр шагыйрь кисәге аның җиңеннән эләктереп алды.

— Бездә дә кахан бар, үзен Хазарстан каханы булдым, дип мактана. Ләкин аңа без ышанмыйбыз. Бездә һәр унынчы борадәр йә хан, йә кахан.

— Бер сүз белән диваналар оясы, шулаймы?..

— Җүләр — дивана түгел, дивана — җүләр түгел, Алла бәндәсе. Биш тапкыр намаз укыйбыз, тәһарәтен алабыз, мәктәп күтәреп ятабыз. Синең иганәң мәктәп салуга китәчәк, игелекле җан.

— Дәрвишләрдән ханнар да, каханнар да чыкмый, Алла бәндәсе.

— Син хаклы, изге җан, хаклы. Саташкан халык яши бездә, ләкин һәммәсе үз акылында — гыйлем белән саташа, күктәге Аллаһыга һәрберебез үз баскычыбыз үрәбез, Коръән Кәрим аша.

— Мин китим инде, Алла бәндәсе.

— Атың ничек, изге зат?

— Ибраһим атлы мин, пәйгамбәрләр санында йөргән кеше.

— Син дә безнең кебек үк Хода бәндәсе икәнсең,— дип калды дәрвиш һәм, түбәтәйне алып, билендәге күн капчыкка тәңкәләрне койды. Ибраһим моны күрмәсә дә, акча тавышы аның колагында калды. Чөнки акча дәүләтнең генә түгел, кешене дә куәтле итә, дигәнне бик яхшы белә иде ул. Әйдә, төзесеннәр мәктәпне дәрвишләр, бер акча гына түгел, китап та яшәтәчәк илне. «Китапсыз халыкның киләчәге дә юк, акчасыз халыкның да»,— дип уйлана-уйлана атлады ул сарай тарафына таба.

Әйе, алар ил кадәр илне югалттылар. Сәмәндәрне Сарманай кахан җимерде, чөнки ул каланы бик еш су баса иде. Хазарстан каханнары башкалаларын Итилгә күчерделәр, утрауга. Башка халыклар Ханбалыкта торалар. Ил белән яһүдләр идарә итәләр — раввалар. Атна-ун көн эчендә ил кадәр ил су астында калды. Бу хакта ничек, нинди сүзләр белән тарихка язарга, кем ышаныр моңа?!

* * *

Айбиби берьялгызы, берүзе калды. Аны йөрәк мае — улы Ибраһим да ташлап китте. Ә бит ул аны бирелә дә кеше итә ала иде. Мөгаллимнәр яллап. Әмма энесе Гаязетдин тархан моны үзенчә хәл итте — Ибраһимны үз мәктәбендә укытырга тарттырды, кайчандыр аны Йосыф кахан Аккалага тарттырган кебек. Тик Айбибине Хазарстанга каханга хатын итеп тарттырсалар, аның улын белем бирү өчен Казанга тарттырдылар. Моңа да исе китмәде, исе китте Казанда мөфти дәрәҗәсенә ирешкән Йосыф каханның рухи атасы Ибраһимны күргәч! Бу кешегә ул ышанмады, бу кешенең эче тулы мәкер икәнен дә белә иде. Тик дәшмәде, гәрчә бер табында утырса да, чөнки рухи атакай кырында аның анакае Рәшидә абыстай утыра иде һәм, ни гаҗәп, шат иде анакай, һәрхәлдә, күңеле-йөзе елмая кебек тоелды Айбибигә. Бер яктан, аны кызганса, кем куенына кердең дип, икенче яктан, — аның өчен шатланды. Бит кайчандыр аның атасы Талибны үлепләр яратса да, кануни төстә никах укытып, беренче тапкыр кияүгә чыгуы иде абыстайның. Беренче тапкыр. Рәшидә абыстай ир белән яшәүнең кадерен кырык яшен тутырганнан соң тойса, Айбиби бу бәхетне бөтенләй яшь чагында татыды... Тукта, әллә соң аның кебек кешеләргә Ходай Тәгалә бәхет дигәнен яшь чагында бирдеме? Ә Рәшидә абыстайга кырыктан узгач?.. Тик бит Рәшидә абыстай яшь чагында да ул тойган мәхәббәтне тойган — аның атасыннан алган һәм тулысы белән, чөнки әле булса Талиб ханны оныта алганы юк. Бик ихтимал, аңа да кайчан да булса янә бер тапкыр тулы мәхәббәт бәхетен тоярга туры килер... Тик тулы канлы булырмы ул бәхет вә мәхәббәт?! Ул бит бер тапкыр Йосыф җаные кочагында янды, көйде, көйрәде ич инде. Йосыфы назлаган, сөйгәннән соң тәмам күмергә әверелгәндәй тояр иде үзен. Нәрсә әйтте әле аңа мөфти Ибраһим озатырга чыккач? «Чын тормыш — уен ул, килен, уйна шулай, бик матур уйныйсың»,— диде. Мөфтинең бу сүзләре зиһененә кереп, тәмам башын катырды. Ул аңа төрле мәгънәләр салды, мөфтинең сүзләрен төрлечә юрап карады. Ни әйтергә теләде Биләр ханы сараена кереп оялаган, хан сарае мәктәбендә балаларга сабак бирүче Ибраһим — Йосыф каханның өлкән раввасы?.. Ни әйтергә теләде аңа бу сүзләре белән?! Утарына кайткач, берничә көн үткәч кенә китаплар укырга яраткан һәм кече яшьтән үк улына сабак биргән Хөснижамал мөгаллимәдән бу хакта сорады. Ә ул аңа, бер дә исе китмичә: «Балакаем, боларга җавапны Әбү Хәниф, Малика, Несай китапларында табарсың. Укы, миндә бар ул китаплар»,— диде.

Китапларны өч көн буена укыды, әмма Ибраһим әйткән сүзләргә җавап таба алмады.

Көн азагында аның кырына Хөснижамал мөгаллимә керде.

— Айбиби, балакаем, хезмәтче бер үрдәкне аткан, шуны тазартып пешеримме әллә үзеңә, кичә дә тамагыңа берни дә капмадың?

— Безнең күлдән алдымы үрдәкне?

— Юк, Идел буеннан укка алдым, дигән булды.

— Юк, кирәкми. Алган үрдәкне каршы яктагы дәрвишләргә бирсен.

— Үзе ашаса?

— Үзе бер сарыкны чалсын, вак-вак итеп турап, дөге ашы пешерсен.

— Яхшы, шулай дип әйтермен,— диде мөгаллимә һәм борылып чыгып китте.

Ни талкый аны, нигә аңа күңелсез? Әйе, нигә аңа кояш, күңелен кара болыт томалап тоткач? Кем аны бу утарга яшерде? Янында Ибраһим булганда, бу хакта аның уйланганы да юк иде, хәзер исә кара урман эчендә берүзе калган берәүдәй ялгызлык хәсрәте кичерә. Аңа яшәү рәвешен алыштырырга кирәк. Шатлык белән яманлыкны бергә кушарга. Кешеләрдән көләргә, кирәк икән кайберләрен мыскыл итәргә, рәнҗетергә, хәтта елатырга һәм үзеңә кызгану аша күз яше түгәргә, алар белән бергә. Юкса сине ялгызаклык басачак, күңелең кайгы-хәсрәт күмәчәк.

Айбиби көмеш кыңгыравын зеңләтте. Хезмәтче керде.

— Сарыкны чалган булсагыз, зур казанга бөтен итне салыгыз, күп итеп казан-казан дөге ашы пешерегез һәм аръяктагы дәрвишләрне дәшеп, ашатып-эчертеп җибәрегез.

— Бу мөмкин хәлме, Айбиби каханбикә?

— Мөмкин итсәгез, мөмкин хәл, Садрый агай.

— Мөмкин итәргә туры килер,— диде Садрый агай һәм баш иеп чыгып китте.

Китап укый-укый күзе тала башлагач, Айбиби ишегалдына чыкты, күл буена таба атлады. Ә анда чынлап та дүрт-биш казан асканнар, тирә-якка тәмле ит исе таралган, казаннар тирәсендә хезмәтче хатыннар, ир-атлар уралалар иде инде. Берәүләре чирәмгә киез җәя, икенчеләре савыт-саба хәстәрли, беришләре чалган сарыкның баш-аягын көйдерә.

— Дәрвишләрне дәштегезме? — дип сорады Садрый агайдан Айбиби.

— Викинглардан калган баркаслар белән чыгачаклар. Ике баркас кеше булачак, димәк, кырыкка якын сукыр-суфи.

— Нигә сукыр-суфи?

— Казанлылар аларны шулай диләр, сукыр-суфилар, диләр. Чөнки алар арасында акылга җиңеләйгәннәре дә бар, каханбикә Айбиби.

Айбиби Садрый агайга бер сүз дә әйтми күл буена таба китте. Аны күргәч, үрдәкләр, казлар, алар артыннан аккошлар җим ташлый торган басма кырыена җыелдылар. Айбиби тәпәннән киптереп туракланган балыклар, бөртекләр алып кошларга сипте, ә үзе уйлады: «Кая, кайсысы аның аккошы, нигә болар арасындагы аккошларның берсе дә аның янына ашкынып килми? Әллә соң нәкъ менә ул яраткан аккошның түшен ярдымы каракош? Шулай булганда, ул чынлап та укчыны чакырачак һәм аны уктан алдырачак. Күр инде син ул каракошны, нарат ботагына утырган да күзен дә алмый аккошларны күзәтә һәм аны да булса кирәк. Әйе, аккошлар турында Шәмгун ханның мөфтиенә сөйләгәч, нәрсә диде соң әле аңа Ибраһим?.. Әйе, мин сиңа иң оста мәргәнемне җибәрермен, ул аны бик тиз укка алыр, диде бугай бит. Хак, аның әйткән сүзенә Айбиби ышанмады, колагы яныннан уздырды, чөнки сарай мөфтиенең хан мәргәнен җибәрүенә ышанмады.

Айбиби янә нарат ботагында утырган каракошка карап алды. Күр инде, утыра, бер гамьсез утыра. Нигә утырмасын, тамагы тук, Айбиби хезмәтчесенә яңа суйган сарыктан өлеш чыгарырга кушты. Үзе дә белми ни өчен, әмма әйтте: «Теге мөртәткә дә ит кисәге ташла инде»,— диде. Ләкин бу яман кош ашатуның кадерен белерме, яңа чыккан аккош бәбкәләрен алырга ажгырып тормасмы?.. Иң яман кошларның берсе ич!

Әле булса хәтерендә, үткән елның язында аккошлар бибиләр чыгардылар. Һай сакладылар да инде бибиләрен аккошлар. Канат асларына яшерәләр, тегеләрнең башлары гына күренеп тора. Һәм бибиләрен үстергәндә ашаткан җиргә бер генә казны да, үрдәкне дә якын җибәрмәделәр, Садрый агай үрдәк-казларны күрше күлгә барып ашатырга мәҗбүр булды. Ә инде бибиләрнең канатлары үсә төшкәч, тегеләрне ничек кенәләр очарга өйрәтүләрен күрсәң, шаклар катарсың. Тыңламаган, ялкау бибиләрне канатлары белән кыйныйлар, аналарга хас йомшак кына итеп чукыгандай итәләр, әнә шулай бибиләрен дөнья күрергә өйрәтәләр иде. Тагын ни әйтте соң әле мөфти Ибраһим аңа: «Сез минем мәргәнем күрмәссез, ул сезгә күренмәс, ә каракошны укка алыр, сиздерми генә, сак кына»,— дип тә өстәде бугай бит. Бу юлы да аны ишетмәгәнгә сабышкан иде Айбиби һәм бөтенләй башка нәрсә турында сөйли башлаган иде.

Айбиби янә-янә каракош утырган якка карап алды. «Утыра, бер гамьсез утыра. Нигә утырмасын, тамагы тук, Садрый агай ит куйган булса кирәк, ашаган да йокымсырап тик утыра. Инде син мөртәтне ашатып-ашатып та игә китерә алмасам, мин сине чынлап та мөфтинең мәргәненнән укка алдырачакмын»,— диде Айбиби, каракошны якын кешесedәй орышкандай итеп.

Хәер, яши бирсен, миңа тими ич, тик бит күрә-күзәтә, аккош бибиләрен алырга утыра ул, яшь аккош бибиенең итен ашыйсы килә. Җанвар кош ич! Тик һәр адәм баласы кебек яманлык кылган каракош та яманлык кылган өчен үз җәзасын алырга тиеш. Заманында Йосыф кахан да баскынчы Сарманай каханны шулай җәзалатты ич. Яманлык кылган адәм баласы үз җәзасын алган кебек, каракош та теге йә бу яманлык кылса, үз җәзасын алыр, дигән фикергә килде Айбиби.

Һәм кинәт аның хәтеренә Сара анакай белән беренче тапкыр очрашкан мәле калкып чыкты. Сара анакай аңа ошады, беренче очрашуда ук ошады, күңеле белән кабул итте ул аны. Шактый олы яшьтә булса да, зиһене саф иде анакайның, ул аңа, үз итеп, акыллы-акыллы киңәшләр бирде. Әңгәмә барышында үзеннән-үзе Шәмгун хан сараена кереп оялаган Ибраһим мөфти килеп керде. Айбиби авызыннан Ибраһим мөфти исемен ишетүгә, Сара анакай йөзгә үк алышынмаса да, күзен-кашын җимереп, түбән карады һәм бермәл дәшми торды. Шулай бертын торгач кына: «Киленкәем Айбиби, сөйләмә син миңа ул кеше турында, исемен дә ишетәсем килми минем ул адәмнең, исемен дә, киленкәем. Каханымны юлдан яздырды, ил белән идарә итү өчен үзе тәрбияләгән балакаем Йосыфымны үтә яшьли тәхеткә күтәрде. Һәм аның исеменнән ил вә халык белән идарә итә башлады. Тора-бара Йосыфымның тәмам күләгәсенә әверелде, киленкәем, күләгәсенә. Җитмәсә, мине дә үз тозагына эләктермәкче итте. Мин аның кем икәнен беләм ич, Гаязетдинемне алдым да Гали тархан җиренә качтым. Ни кысты Гали тарханны, ни кысты, имеш, син миңа шушы качкын хатынын тотып сарайга китереп бирмәсәң, миннән игелек көтмә... Шуннан соң тархан Йосыф улыма мөрәҗәгать иткән: «Өлкән равваңны йә син тыясың, йә мин аның белән бер-бер хәл кылам». Әнә шунда, беренче тапкыр дияргә була, Йосыф улым өлкән равваны чакыртып ала да кистереп әйтә: «Анамны тынычлыкта калдыр, атакай, хатын-кыз ат түгел, көчләп йөгән кигереп булмый». Ни гаҗәп, шуннан соң, нә гарьләнсә дә, өлкән равва мине тынычлыкта

калдырды. Хәзер әнә Хазарстандагы Шәмгун хан сараена килеп оялаган, җитмәсә, Рәшидә абыстайны кармакка каптырган».

«Рәшидә абыстай аңа яратып кияүгә чыкты»,— дигән иде Сара анакайга Айбиби, Сара анакай аңа бер сүз генә әйтте: «Бүре баласы ул, бүре баласын бүреккә салсаң да, урманга карар, дигәннәр борынгылар, балакаем».

Әйе, очраштылар, эчкерсез сөйләштеләр кебек, вәләкин Сара анакай улы Йосыф турында бер кәлимә сүз дә кузгатмады, хәтта: «Кая башларын салды микән, балакаем?!» — дип тә әйтмәде. Чынлап та, кайларда йөрисең син, Йосыфҗан, нигә син безне оныттың, кан-бәгырең Ибраһимны, ниһаять, мине! Син бит миңа гашыйк идең, мин генә сиңа түгел!

Айбиби әкрен генә өйгә таба кузгалды, кайтыр юлда ул тагын нарат ботагында утырган каракошка күз төшереп алды. Һәм уйлап куйды: «Әйтергә булыр әле Садрый агайга, моннан соң ашатмасын минем аккошларыма теш кайраган каракошны, Ходай Тәгалә яраткан һәр җан кебек үз көнен үзе күрсен».

Шулай дип уйлады уйлавын, ләкин бу хакта Садрый агайга әйтергә онытты. Тик көннәр үтеп, мөфти Ибраһимнан хат килеп төшкәч кенә, келт итеп хәтеренә каракош төште. Бит ул яман кош һаман шунда утыра. Хәтта болай дип язган иде мөфти Ибраһим: «Каракошны алырга мәргән җибәримме, каханбикә Айбиби?»

Айбиби хатны укыды да, гаҗәпкә калып, болдырга чыкты һәм бик озак тирә-юньне күзәтте. Ниндәен хозур бу дөнья, ни җитми тагын бу каракошка да, каракош сыйфатында күңеленә кереп калган Ибраһимга?.. Юк, ул аңа җавап бирмәс... Әллә соң: «Мәргәнеңне җибәр, алсын укка яман каракошны»,— дип язаргамы үзенә? Әйе, язарга. Килсен мәргәне, алсын укка яман каракошны. Иң мөһиме, илгә кайтуның нәүбәттәге елын уздырырга, һәр елдагы кебек. Һәм барысын да утарга чакырырга. Ел саен уздыра килде бит әле шулай. Ләкин кунакларны бик сайлап чакырырга. Тәүгечә Гаязетдинне дә, улы да кайтсын, хәтта дәрвишләрне дә дәшәргә. Тик мөфтине генә дәшмәскә, яшерен рәвештә Рәшидә абыстайны гына чакырырга. Килә алса — килер, килә алмаса — кичерер. Кем Ибраһим мөфтинең укчысы? Әллә соң аның газиз сөйгәне — Йосыфы шул кара йөзгә хезмәт итәме?.. Бик мөмкин ич. Ахыр килеп, нигә Сара анакай аңа Йосыф турында бер сүз дә әйтмәде, әллә соң ул беләме улының кайларда икәнен?..

Хаталанма, Айбиби. Нишләп аның җан сөйгәне әлегә кадәр өлкән раввасына буйсынып яшәсен ди! Юк, Йосыфы аңа бармас. Бит ул яратмый иде өлкән равваны, хезмәт итә, әмма яратмый иде. Соңгы көннәрендә өлкән раввага баш бирми башлавы да шуннан. Ил белән идарә итүне үз кулына алды ич!..

Болдырга менеп басуга, Айбиби ат абзары янында хезмәтчеләр белән сөйләшеп торган Садрый агайны дәшеп алды. Һәр йомышын төгәл үтәп барган, күп нәрсәдән хәбәрдар булган утар агае каршына килеп баскач, ул аңа болай диде:

— Җомга көн узып, бер атнадан соң утарда бәйрәм итәрбез. Күчеп килгән көнгә багышлап. Мин улыма, Рәшидә абыстайга, Гаязетдин тархан белән аның бикәсе Бибисарага чакыру хаты язып бирермен. Хатларны иң ышанычлы чапкыныңа бир. Чакыруны, беркемгә дә күрсәтмичә, киләсе кунакларның үз кулларына тапшырсын. Баш хезмәтчең күрше авылга барып өч сарык, бер тана алып кайтсын — бәйрәм көнгә.

— Бәйрәмгә дәрвишләрне дә дәшәрбезме, каханбикәм?

— Дәшәрбез, тик барысын да түгел, тәүге вакытта бирегә килгәннәрен генә.

— Яхшы, каханбикәм, шулай итәрмен. Хатларны көтеп алыйммы?

— Юк, хатларны иртәгә алырсың, иртәгә үк чапкының да озатырсың.

— Яхшы, каханбикәм.

Садрый абзый китә башлады.

— Тукта, Садрый агай. Әйтергә оныткanмын. Бүгеннән каракошка бер кисәк ит тә бирмә, бер кисәк тә.

— Ул инде кулга өйрәнеп бара, каханбикәм.

— Үзе эзләп тапсын җимне.

— Яхшы, каханбикәм, шулай итәрбез.

Менә ничәмә көннәр уйлап вә икеләнеп йөргән бәйрәмне уздырырга әмер дә бирде. Һәм бик дөрес эшләде. Гаязетдин килер, улы Ибраһимы кайтыр, бер шаулатып ял итәрбез, дәрвишләрдән әрвахларыбыз рухына Коръән чыгартабыз, аннары ярышлар уздырырбыз, тагын бер Гаязетдинне күрер һәм Йосыф җаныкаен күргәндәй булыр.

* * *

Бәйрәм көнне күл буенда иртән-иртүк шау-шу купты. Беренчеләрдән булып бәйрәмгә викинглардан калган баркас көймәләре белән дәрвишләр килгәннәр иде. Аларны Садрый агай каршы ала, һәммәсенә дә көймәдән төшкәндә кул бирә — күл читенә төшәргә ярдәм итә. Дәрвишләр барысы да тоташ карадан киенгәннәр, күзләрен капларлык итеп, хөллә башлыкларын төшергәннәр. Күл буендагы чирәмгә аяк баскан берсе, ике тезенә төшеп, дога кыла, һәммәсе дә Айбиби басып торган балконга күз ташлап ала.

Садрый агай аларны ат абзары кырындагы кечкенә мәчет янына уздырырга тиеш иде, барысы да көймәдән төшеп беткәч, ул аларны шунда таба ияртеп алып китте. Каз бәбкәләре кебек Садрый агай артыннан тезелеп барган дәрвишләр ашыкмый гына артыннан атлыйлар һәм янә-янә Айбиби чыгып баскан, сырлап нәкышләнгән, төрле төсләргә буялган балконга карап алалар. Сәер халык та соң бу дәрвишләр, үз бакчаларында эшләсәләр дә, тамак туйдырырлык җиләк-җимеш һәм яшелчәләр үстерсәләр дә, кунакка йөрүдән дә баш тартмыйлар. Ахыр килеп, кайлардан килә ошбу суфиларга мал асрамау йоласы да һәм нигә алар халыктан читләшәләр?.. Айбиби белми иде. Ләкин бу кешеләргә хөрмәте зур иде. Суфичылык кылганнары өчен генә түгел, үз кагыйдәләренә тугры калып, аны кабергә кергәндә дә саклаганнары өчен. Инҗилдә бу хакта болай диелгән: «...Рухыгызга таянып яшәгез, шул чакта гына камил гамәлләр кылырсыз. Чөнки кешелек табигате сезне Рухка каршы өнди, ә Рух кешелек табигатенә каршы булмаганны ярата: алар бер-берсенә каршы торалар... Әгәр сезнең белән Изге Рух җитәкчелек итә икән, димәк, сез Рухи яктан көчле кеше».

Ихлас суфичылыкка йөз тоткан дәрвишләр идеме ул чакырткан халык, Айбиби белми иде. Әмма билгеле иде: бу халык Аллаһы йөзендә кешелектә булган хакыйкатьне эзли, ләкин, ни гаҗәп, дәрвишләр фәкыйрьләр булсалар да, үзләрен хәерчеләр итеп хис итмиләр, киресенчә, без көннән-көн Аллаһыга якыная барабыз, ә моңа Рухыбыз аша ирешәбез, дип сөйлиләр. Һәр дәрвишнең үз мөгаллиме, остазы бар, дип әйтте аңа Садрый агай. Ни аягы тартса да, Айбиби дәрвишләр янына ашыкмады. Шул ук вакытта белә иде — Казан каласы кырындагы дәрвишләр Харәзем суфилары белән элемтәдә торалар, һәр шәһәрдә диярлек ханәкәләре бар, үзләренең мәчетләре. Садрый агайның сүзләре хак булса, дәрвишләр арасына килеп кергән һәр кеше мәкамәт — суфилар юлын үтәргә тиеш. Мәкамәтне үткән кеше генә мөрид булып китә ала. Мөршаһит белән мөрид арасында бернинди дә сер булырга тиеш түгел, гәрчә икесе дә Аллаһы бәндәләре булсалар да. Акыллы мөршид үз мөридендә йоклап яткан хиссияти тойгысын уятырга тиеш, ягъни үзендә генә түгел, укучысы күңелендә йоклап яткан Рухи тойгыны уятырга һәм аны Аллаһыга йөз тоткан хакыйкатькә якынайтырга.

Аңламады Айбиби бу халыкны, аңларга да теләмәде, ул аларга дөньялыктан аерылган, үзләрендәге «мин» дөньясына кереп адашкан мескен адәмнәр дип карады. Һәм ул аларның мескенлекләрен белгәнгә генә бәйрәмгә чакыртты. Хак, алар төп кунаклар янында булмаслар, бары тик Коръән хафиз гына чакыралар. Калганнарының күңелен Садрый агай күрер.

Тиздән Гаязетдин белән Бибисара бикә, Сара анакай килеп төшәрләр, бәлкем әле, язган итсә, мөфти Ибраһим сизеп алмаса, Рәшидә абыстае да килеп җитәр. Утар ишегалды шау-шу белән тулыр, күңел ачарлар, җырларлар, уйнарлар, көләрләр. Бәйрәм кешене яшәртә, кайгы картайта, диләр. Бәйрәм итеп, бер яшәреп алырлар, иң мөһиме, Айбиби Ибраһимын күрер. Шактый буй алгандыр инде, Шәмгун хан аны, фарсылардан кайткач, үз кырына алган, сәркатибе итеп тота икән, дип ирештерделәр Айбибигә. Моңа куанырга да, кайгырырга да белмәде Айбиби. Чөнки анда, сарайда, аның яман дошманы мөрид Ибраһим эшли иде. Бу кешенең акылы гына түгел, кулы да озын, дип сөйли иде сарай халкы. Әнә шуңардан курка иде Айбиби.

Айбиби өйдән чыкты, бәйрәм ашы әзерләгән пешекчеләргә, бавырчыларга таба атлады. Тирә-юньне тутырып ит исе чыккан, зур-зур казаннарда ит пешә. Күл кырында ук кара чәчле Харәзем егете шашлык кыздыра. Ни сәбәпледер Айбиби каракош утырган наратка карап алды. Үз ботагында утыра иде каракош. Ул да ит исен сизә. Тик бит инде аңа ит бирүче юк. Шуңа үч итепме, каракош күлдәге ике үрдәкне алган һәм Садрый агай күз алдында, нарат ботагына алып менеп, ботарлаган. Янәсе, күрегез, мин үз дигәнем итәм, ашатмасагыз да ач тормыйм.

Айбиби күл кырына таба борылды, аккошлар ашаткан төбәккә җитеп, кошларга җим ташлады. Шул вакыт нарат ботагыннан лап итеп каракош төште. Барысы да шул якка карадылар. Айбиби үзе дә сизмәстән шул тарафка таба йөгерде. Кем укка алды каракошны? Шуны беләсе килде. Әйе, кем?! Әллә соң, чынлап та, Ибраһим мөфти каракошны уктан алырга үз мәргәнен җибәрдеме? Һич булмас димә!

Каракош җирдә ята, әмма исән, бер канаты белән җилпенә, яман итеп ысылдый. Айбиби каракош янына килеп җитәрәк туктады һәм шунда каракош аның күзләренә карады, нәкъ менә кеше кебек ялварып карады, хәтта күзләрендә яшь бар кебек иде. Ул арада Айбиби янына Садрый агай килеп җитте, җирдә ысылдап яткан каракошның ике канатыннан алды да:

— Ит бирмәгәнгә үрдәкләрне алды ул, каханбикәм, ит бирмәгәнгә, үч итеп ботарлады бичараларны.

«Димәк, миңа үч итеп»,— дип уйлады Айбиби һәм капкадан кереп барган сиртмәле һәм кыңгыраулы атларны күреп, шунда таба китте.

Улы Ибраһим, улы Ибраһим кайта иде, янәшәсендә чибәр кыз бала. Айбибинең йөрәге «жу» итеп китте. Әллә соң өйләндеңме, балакаем, дип уйларга өлгерде ул, сиртмәле арба туктауга, кыз балага төшәргә ярдәм иткән Ибраһимына карап. Ләкин улы өлгеррәк булып чыкты.

— Менә без дә кайтып җиттек, әнием. Таныш бул, хан кызы Гөлбикә.

— Саумы, кызым, исән-имин килеп җиттегезме? — дия алды Айбиби һәм, килеп, улын кочагына алды.— Сагындым үзеңне, бик сагындым, балакаем...

Аннары колагына гына: «Әллә соң?..»

— Юк, юк, әнием, Гөлбикә сезне күрергә генә килде, әнием, мин үскән утарны гына.

Айбиби, улыннан аерылып, арбадан төшүгә үк туктап калган хан кызына таба бер адым ясады һәм тукталып калды. Кыз бала, хан кызы Гөлбикә үзе кебек үк ак йөзле, зәңгәр күзле, коңгырт чәчле иде.

— Исән-имин килдегезме, балакаем?

— Аллага шөкер, Ибраһимның туган-үскән җирен күрәсем килде дә, менә иярдем дә үзенә...

— Бик әйбәт булган, бик әйбәт. Йә улым,— дип борылды Айбиби улына таба,— алып кер кунагыңны өйгә, ә мин Гаязетдин абаңны каршы алам, әнә кыңгырау тавышлары да ишетелә анда, шулар киләдер,— дип, капкага таба кузгалды. Атларны Садрый агай лапас астына таба алып китте, Айбиби, борылмада кыңгыраулы атларны күреп, хезмәтчеләренә утар капкаларын киереп ачарга кушты һәм, әйләнеп, хан кызы белән улы Ибраһимга карап алды. Янә йөрәге мелт итеп, сискәнеп китте. Юк, бу курку түгел, шул ук вакытта куанычтан да түгел иде. Моны гына яхшы белә иде Айбиби. Ана кеше ич, ничекләр борчылмасын ди, бердәнбере, аның улы үзе белән хан кызы кадәр хан кызы алып кайткан. Димәк, тиккә түгел, анасына күрсәтергә. Янәсе, әнисе белән таныштыра... Һәй, улым, улым, анаң белмиме ул хәлләрне... Ләкин каршы төшә алмыйм, яратуың хак булса, өйләнсәң дә, сүз әйтмәм, әмма сайлаганың да яратамы сине?.. Яратырмы?!

Ул арада ачык капкалардан Гаязетдин тарханның сиртмәле арбасы килеп керде, кыңгыраулар зеңләүдән тынычлана төшкәч, Гаязетдин тархан арбадан төште, әүвәл ике кыз баласын, аннары әниләре Бибисара бикәсен арбадан төшерде. Арбадан төшә-төшүгә:

— Ак җиңгәчәем, саумы, исән-имин торасызмы?! — дип, ике кыз бала анасы Айбибине кочагына алды, аннары күзләренә карады да: — Җиңгәчәем, бәгърем, нигә болай күзләрең боек? — дип сорады.

— Туктале, тукта, анасы, башта җиңгәчәләре белән балаларны исәнләштер.

Айбиби иелә төште, ике кыз баланы да, кочагына алып, аркаларыннан сөйде.

— Нәфисә белән Айбылбыл, нәниләрем, үсеп беткәнсез икән ич инде. Күр әле, күр боларны, аталары Гаязетдин, кай арада буй алып өлгергәннәр. Ничә яз булды инде сиңа, Нәфисә? — Бала җиде бармагын тырпайтты.— Ә сиңа, балакаем-нәнием, ничә яз булды инде,— дип, янә бер кочагына алды Айбылбылны Айбиби.

— Безнең икебезне дә айдан алып төштеләр бит, әйеме?

— Юк, мине әнием Кабан күленнән алып кайтты,— диде икенчесе.

— Бик тирәннән алып чыктылармы?

— Дилбегә буе тирәннән,— диде кыз бала җитди генә.

Шул сүзләрне әйтүгә, атасы баланы кулына күтәрде һәм бер кулы белән Айбибинең иңенә кагылып алды. Айбибигә янә нидер булды, бөтен тәне тетрәнеп китте. Әмма сер бирмәде, кунакларны өйгә таба әйдәде, әмма китәр алдыннан, әйләнеп, Садрый агайга:

— Атларны урнаштыр, күчәрбашны ашат та, җыелып, күл буена төшәрбез, Садрый агай,— диде.

— Каханбикәм, абзарда бөркет, атлар өркерләр бит?..

— Бөркет, нинди бөркет? — дип аптырап, туктап калды Гаязетдин тархан.

— Комсыз бер бөркет үрдәкләрне ала башлады. Шуннан мин аны уктан алдырдым. Канаты яраланган иде,— диде аңа Айбиби.— Әйдәгез, әүвәл өйгә керик әле, чәйләп алырбыз, аннары бәйрәмгә чыгарбыз. Ә бөркетне урманга җибәр,— диде борылып Садрый агайга.

— Яхшы, каханбикәм,— диде хезмәтчеләр башы Садрый агай һәм пар атларның тезгененнән алып, утардагы түр яктагы лапаска таба алып китте.

Өй баскычларын менгәндә, Гаязетдин тархан:

— Ул явыз бөркетләр Кабан күлендә дә күренә башладылар,— диде.

Айбиби җавап бирмәде, аның, гомумән, бөркет турында сөйләшәсе килми иде.

— Сара анакай кая? — дип сорады.

— Ул Рәшидә абыстай белән килә. Хәзер килеп җитәрләр,— диде Бибисара бикә.

Көн кояшлы, матур, күк йөзендә сирәк-мирәк болытлар күренсә дә, һава тып-тын тора, ә менә күл буендагы аланда шау-шу. Сара анакай белән Рәшидә абыстай табынның түрендә янәшә утыралар, Айбиби аларга карап-карап алды да эченнән генә: «Менә язмыш нишләтә кешене, шушы гүзәл затларның берсе өлкән раввадан баш тарта, икенчесе югалып калган картны үзенеке итте. Юк, юк, үпкәм юк сиңа, анакаем Рәшидә, юк! Яши бир. Җаны теләгән елан ите ашаган, диләр».

Табында утырганда, Ибраһим улы хан кызына әле җиләк-җимеш тәкъдим итә, әле кош ите. Кыскасы, улы хан кызына гашыйк, дигән фикергә килде Айбиби. Бибисара килене балаларын ашата, Гаязетдин тархан аның кырында. Бер-берсенә карашып алалар да елмаешалар. Яраталар бер-берсен, ләкин бит ни сәбәпледер Гаязетдин тарханга Айбиби дә битараф түгел һәм үзе дә белми ни өчен. Юк, белә, бик яхшы белә, ул аны Йосыфы итеп кабул итте. Әгәр дә мәгәр исеме-аты Гаязетдин булмаса, ул аны, бәхәссез, Йосыфы итеп кабул иткән булыр иде. Бу бәйрәмне оештыруы да аны күрү өчен генә булды түгелме?! Юк, юк, аны күрү өчен генә түгел, аларның барысын да күрү өчен оештырды ул бу бәйрәмне...

Хезмәтче хатыннар табынга ризык-нигъмәтләрне ташып торалар, ә монда көлешә-сөйләшә ашап-эчәләр. Бер Айбиби генә гасабиланып утыра. Нигәдер аның җаны тыныч түгел, кем өчендер курка, күңеле нидер сизенә. Әллә соң Ибраһимы чынлап та хан кызына гашыйкмы, өйләнергә ниятлиме, тик әнисенә әйтергә генә кыймый торамы? Шулай, шулай, әйтергә кыймый тора, сукыр түгел әниең, барысын да күрә, йөрәге тоя, балакай, йөрәге. Хәер, иншалла, хан кызы игелекле баладыр, барысы да әйбәт булыр. Тик Айбиби өчен бу хәл кысыр кайгы гына лабаса, кинәнәсе ит, ана кеше. Улың балигъ булды, хан сараенда хезмәттә, хан кызына гашыйк, анасының утарын күрсәтергә булачак кәләшен алып кайткан. Бу начар гамәлме? Бик яхшы гамәл ич. Кәләшен әнисенә күрсәтергә алып кайткан. Хәзер миңа табынга дәрвишләр арасындагы Коръән хафизны дәштерергә кирәк һәм әрвахларга Коръән чыгарга булыр. Әнә теге нарат астына күчәрбез дә шунда укытырбыз. Аннары ирләр вә егетләр уктан алышырлар, ә без, хатын-кыз, серләшеп алырбыз. Шунда булачак килене белән дә якыннанрак танышыр, Сара анакае, Рәшидә абыстае белән дә шул хакта киңәшер.

Төнәтмәләр эчкәч, Айбиби аларны һәрдаим ботакта утырган Бөркет агачы исемен алган нарат янына алып китте. Ул арада Садрый агай уктан алучыларга, ботак саен дияргә була, бөркет карачкылары куйган иде инде. Йөз адымнан бөркетне алган ир-егеткә Айбиби ат бүләк итәргә вәгъдә иткән иде, Садрый агай шул хакта җиткергәч, барча ир-ат, егет-җилбәзәк «ур-ра» кычкырдылар. Егет-җилбәзәк дигәне Ибраһим улы берүзе иде. Ләкин әүвәл нарат тирәли утырдылар да тоташ карадан киенгән Коръән хафиз Коръән чыгарга кереште.

Моңлы тавышлы иде Коръән хафиз, һәр авазы йөрәккә үтеп керә, иң сәере, кемнеңдер тавышын хәтерләтә. Ләкин Айбиби моңа игътибар итмәде. Нининдер суфи, гәрчә Коръән хафиз булса да, бәхәссез, ят бәндә иде. Дәрвишләр белән ул кызыксынмады, бары тик ул бичараларны кызганды гына. Суфичылыкны фәкыйрьлеккә саный иде Рәшидә абыстае һәм ул шулай иде дә. Дөньяви гамәлләрдән баш тарткан, нининдер сихри көчләргә өмет итеп, Рухы белән Аллаһыга тартылган, хәтта Аллаһы кырына ашарга әзер булган затлар дип кабул итә иде.

Утырышкач ук дәрвишнең моңлы тавышы һәммәсен дә әсир итте, алар хафизны бирелеп тыңладылар. Айбиби бигрәк тә. Хак Тәгаләгә өнди иде изге китаптагы сүзләр, адашкан кешене туры юлга төшерергә, шәфкатьле булырга, адәм баласын игелеккә чакыра, гадел булырга куша. Йа Хода, бар кеше дә бу сүзләргә колак салса, дөньяда көн күргән кешеләр нинди шәфкатьле булырлар иде дә бит, изге китап сүзләренә колак салучылар азаеп бара. Һәрхәлдә, шулайрак тоела иде Айбибигә.

Коръән хафиз укып бетерде, кулларын күтәреп дога кылдылар. Шуннан соң гына барчасы да торып бастылар һәм Садрый агай һәммә ир-затына да ук-җәя бирде. Йөз адым бөркет наратыннан авыштылар да уктан ала башладылар.

Айбиби бер читтә җыелып, сөйләшеп торган хатыннар янына китте. Ир-затлар, мәш килеп, уктан алалар. Янәсе, ботакларда чын бөркет утыра. Ук тиюгә, бөркет егылып төшәчәк. Һәр кешегә ун ук бирелә. Уклар төрле-төрле буяуда. Кемнең уклары бөркетләрне күбрәк төшерә — алмачуар ат шуңа, дип игълан итте Садрый агай.

Бер читтәрәк торса да, укчылар арасында Коръән хафиз да урала иде. Һәм нигәдер Ибраһим улы янында урала. Янә Айбибинең йөрәге ешрак тибәргә тотынды. Кем бу суфи зат? Нигә аның улы янында йөри? Аңа уклар биреп тора, хәтта нидер өйрәтә кебек.

Уклар атылып бетәр алдыннан, нарат янында карадан киенгән кеше пәйда булды. Садрый агай кулын күтәрде.

— Туктагыз!

Шул мәлдә үк укчылар тарафына сызгырулы ук очты. Һәм нәкъ Айбибинең улы Ибраһимга таба. Ул да түгел, улы кырындагы суфи күкрәге белән Ибраһимны каплады. Ук дәрвишнең күкрәгенә кадалды һәм ул бер якка авып төште, улы Ибраһим аны тотып калмакчы итте, әмма өлгерә алмады. Ул арада нарат төбендәге яман затка бу тарафтан уклар очты. Кемнеңдер угы тиде булса кирәк, кара киемдәге кеше уң кулы белән күкрәгенә кадалган укка ябышты һәм чалкан төште.

Барчасының да күз алдында булган хәл иң әүвәл Айбибигә килеп җитте, ул чыркылап кычкырып җибәрде.

— Улым, Ибраһим!..

Дәрвишне укка алган карачкы киемендәге кешегә игътибар итмичә, бер читтә торган хатын-кызлар ирләргә таба кузгалдылар, Айбиби исә, хәле китеп, баскан җирендә катып калды. Берара киткәч кенә Рәшидә абыстай аңа таба борылып карады һәм, кире килеп:

— Ни булды, балакай? — дия-дия, аның терсәгеннән алды.

— Кем, кем укка алды минем улымны?..

— Улың Ибраһим исән, исән, балакай. Әнә кәләше янына да барып җитте инде. Дәрвишне укка алдылар, дәрвишне. Ул җирдә ята...

Айбиби улы Ибраһимга килеп сарылгач кына, әле булса җирдә яткан һәм күкрәгенә ук кадалган дәрвишкә игътибар итте.

— Ул коткарды мине, әнием, дәрвиш коткарды.

— Дәрвиш?!

— Садрый агай, дәрвишне чирәмгә илтеп салыгыз да...

Шул сүзләрне әйтергә дә өлгермәде, кан исенә Айбибинең башы әйләнеп китте һәм ул әкрен генә җиргә таба иңә башлады. Улы Ибраһим аны кулына күтәреп алды һәм читкәрәк чирәмгә илтеп салды, яңакларына суккалады. Ул арада Рәшидә абыстай килеп җитте, барысын да куалап, Айбибинең колагына пышылдады:

— Улың исән, киленең дә, балакай. Дәрвиш коткарды улыңны, Коръән чыккан дәрвиш.

Ул арада ирләр нарат төбендә канга батып яткан мәргәннең мәетен дәрвиш белән янәшә китереп салдылар. Күрде дә Ибраһим углан уктан алган адәмнең йөзен, бер адым артка чигенде.

— Ибраһим мөфтинең җан сакчысы Сатлык ич бу! Сатлык! Димәк, димәк...— диде дә Ибраһим углан тукталып калды, Гаязетдин тарханның күзләренә карады.

— Димәк,— диде аның сүзен дәвам итеп Гаязетдин тархан,— Сатлыкны бирегә мөфти җибәргән.

— Хак, угылым, мөфти Ибраһим җибәргән,— диде Сара анакай, алгарак чыгып.

Сара анакай шулай диюгә, Рәшидә абыстай куырылып куйгандай булды, агарынып китте һәм нигәдер барчасы да аңа борылып карадылар. Ни кылырга белмәгән Рәшидә абыстай мәетнең чикмән изүләрен чиште, күкрәгендә бакыр тәре күреп, ике кулы белән йөзен каплады да үксеп-үртәлеп елап җибәрде. Ул арада Садрый агай дәрвишнең күкрәк сәдәфләрен ычкындырды, күлмәк бауларын чиште һәм муенына алтын чылбырга таккан көмеш бөтине күреп, тартып алмакчы итте, әмма аңа Сара анакай моны кылырга бирмәде.

— Тимә изге җан бөтиенә!

Сара анакай шулай диюгә, әлегә кадәр исе-акылы китеп, булган хәлгә ышанмыйча, сихри бер дөньяга китеп торган Айбибинең күзе мәет күкрәгендәге бөтигә төште һәм ул янә һуштан язды. Әмма янәшәсендә басып торган улы аны кулына күтәреп алды, мәетләр яныннан читкәрәк алып китте. Аларга, бер тотам калмыйча, хан кызы иярде:

— Ибраһим, Ибраһим, дим, атама чапкының җибәр, мөфти Ибраһимны каладан беркая да җибәрмәсен, аның эше бу,— диде.

Ибраһим углан барган җиреннән туктады, борылып, артыннан ияргән хан кызына карады.

— Ә син кайдан беләсең, Айгөлем?

— Бирегә киткәндә, атам миңа сине сакларга кушты.

Ул арада Айбиби аңына килде, күрәсең, булачак килененең сүзләрен ишеткәндер, аягына басты һәм хан кызына:

— Балам, бар әле дәрвиш муенындагы бөтине китер миңа,— диде.

Нигәдер чарасыз калды, түшендәге Йосыфҗаны таккан бөтине капшап карады. Ул аны бик сирәк ачты, ачкан саен хатирәләргә чумып утырды. Алар икәү киттеләр: улы да хан кызы. Бөтине Ибраһим алып килде, тырнак очы белән бөтине ачты да әнисенә сузды.

— Миндә дә, синдә дә шундый ук бөти, әнием.

— Ул дәрвиш синең атаң, әтием Йосыф кахан! — диде Айбиби һәм ике кулы белән йөзен каплап елап җибәрде.— Нинди, нинди язмышлар китерде аны монда?.. Мине эзләп килдеңме, безнеме?.. Йосыфҗаным!..

Айбиби мәеткә таба кузгаласы итте, аны култыклап алдылар. Килде, мәетнең йөзенә бакты. Бакты да кычкырып җибәрде:

— Йосыфҗан!.. Йосыфҗан, синме бу?..

Мәет кымшанмады да, ирләр булган хәлгә аптырабрак калганнар иде. Бөтен йөзен кара сакал баскан, тоташ карадан киенгән, күз алларында күкрәгендә ук тиеп үлгән суфиның кахан булуына берәү дә ышанмады. Ул арада дәрвиш мәете янына ишләре килделәр, берсе алгарак чыкты да:

— Безнең кахан бит бу, кем алды укка? — дип сорады.

— Укка алган җан кахан кырында ята,— диде аңа Гаязетдин тархан.

— Каханны безгә бирәсез, без аны үзебез җирлибез. Кадерләп, Дәрвишләр саласы зиратына.

Гаязетдин белән Ибраһим углан күзгә-күз карашып алдылар.

— Кем генә булмасын, бу мәетне без җирләрбез, дәрвишләр. Һәм сез әйткәнчә, кадерләп, олуг затлар зиратына — Казан җирендә. Ә сез менә бу сукбайны җирләгез, дәрвишегезне уктан алган сатлык җанны.

— Адәм канын койган кешене без җирләүдән баш тартабыз, Гаязетдин тархан. Хушыгыз...

Дәрвишләр, су буена төшкән казлар кебек тезелешеп, күл буендагы көймәләренә таба киттеләр. Гаязетдин тархан Ибраһим угланга һәм Айбиби җиңгәчәсенә карап алды. Җиңгәчәсе хәтта аңа күтәрелеп тә карамады. Аның бер ягыннан хан кызы култыклаган, икенче ягыннан Сара анакай. Рәшидә абыстай исә булган хәлгә исе-акылы китеп басып тора. Бит ул Сатлык мәргәнне күрү белән үк таныган иде. Сатлык һәрдаим Ибраһим янында йөргәнгәме, аптырабрак калган, гасабилана иде.

Әмма Гаязетдин тархан дөнья күргән ир-егет булды, ул хезмәтчесен чакырып алды да мәетне тиз арада Казанга алып китәргә, сарай имамына мәрхүмне җиренә җиткереп җирләргә, дип әмер җиткерергә кушты.

Ә үзе Айбиби җиңгәчәсе янына килде дә, иңенә кулын салып:

— Җиңгәчәй, әйт, ни кылыйм бу кан койган адәмнең мәете белән,— дип, Сатлык яткан якка карады.

— Каракош утырган нарат төбенә күмдер ул бичараны, Гаязетдин,— диде бераз тынычлана төшкән Айбиби. Аннары Сара анакайның күкрәгенә капланды да: — Нишлим, инде мин нишлим, анакаем?! — дип үксеп-үртәлеп еларга тотынды.

Аны кем дә юатмады, бары тик булачак килене генә, аның кырына килеп, йомшак кына, сак кына аркасыннан сыйпады.

— Ул бит, киленкәем, бирегә сине эзләп килгән булган, сине эзләп килгән булган,— диде дә Сара анакай үзе дә еларга тотынды.

— Кайчан тукталыр бу дөньяда кан коюлар, кайчан тукталыр,— дия-дия тәкрарлады ачы күз яше аша Айбиби.

* * *

Айбиби Йосыф каханның җидесенә генә Казанга килде. Капкадан ук аны каршы алган Гаязетдин тархан җиңгәчәсенә арбадан төшәргә ярдәм итте һәм култыклап алды да кирмән-кала эчендәге олуг затлар зиратына таба алып китте.

— Җиңгәчәй, без аны җиренә җиткереп җирләдек. Сакалын кыргач, Сара анам шундук таныды: Йосыф улым! дип, күкрәгенә капланып елады. Кичерә күрегез, сезне чакырырга теләмәдек. Яра өстенә яра өстәлмәсен, дип. Бибисара әйтте, җиңгәчәй сарайда калыр, безнең гаиләдә булыр, диде.

Шулай диде дә Гаязетдин тархан Айбибинең уң кулын учына алды һәм уч төбен үпте.

— Мин куркам, куркам, Гаязетдин. Кеше ни уйлар?

— Мин сиңа өйләнергә булдым, җиңгәчәй, улың Ибраһим да ризалык бирде, хатыным-бикәм Бибисара да, анакай да... Йосыф атамның елын уздырганнан соң никах укытырбыз...

Айбиби һич тә моны көтмәгән иде, Гаязетдин тарханның күкрәгенә капланды да тынып калды.

— Ул кичерерме соң мине, Гаязетдин, кичерерме?!

— Кичерер, җиңгәчәй, кичерер, кайчандыр мин аны кичергән өчен кичерер. Ә бит Ибраһим мөфти Хазарстан тәхетенә мине утыртырга теләгән иде. Теге вакытта, без Таман тархан җирендә яшәгәндә...

— Кан коймый гына, әйеме, Гаязетдин?

— Әйе, кан коймый гына, җиңгәчәй.

— Ә бит Ибраһим мөфти кан койды, биредә, Казан төбәгендә, син салдырган минем утарымда. Күпме кан коела җирдә. Барысын да җыйсаң, диңгез булыр иде. Ә кешеләргә, явызларга һаман да аз, һаман кан кою турында уйлыйлар. Мин риза, Гаязетдин, синең хатының булырга риза. Синең баллы сүзләреңнән соң мәхәббәтемә яңадан җан иңгәндәй булды, Гаязетдин бәгырь. Әйтсәм әйтим инде, мин сине беренче күргәч тә Йосыфым дип кабул иткән идем.

Айбиби кисәк тынып калды, аңардан җавап көтте бугай, әмма Гаязетдин бер сүз дә әйтмәде. Шуннан соң Айбиби аның ике кулы белән ике битеннән алды да кара шомырт күзләренә карады һәм, чарасыз калып, Гаязетдиннең күкрәгенә капланды. Ул аңарда Йосыфының тән исен тойды һәм, эчке бер хискә бирелеп, булачак ир канатының күкрәгенә башын куйган килеш бер мәлгә тынып калды. Ул исән икән ич әле, аны яраталар, ул янә үз кешесен тапты — мәхәббәтен. Йосыф улы Гаязетдин йөзендә тапты.

Кабер янында озак тора алмады Айбиби, Гаязетдиннең кулыннан алды да сүзсез генә бераз аптырый калган ир-атны зираттан алып чыкты.

— Минем синең гүзәл Бибисараңны, аның кызларын күрәсем килә, аларның аркаларыннан кага-кага сөясем килә, Гаязетдин. Мин сиңа яхшы хатын булырмын. Мин беркайчан да, беркемне дә рәнҗетмәм. Мин сиңа атам-анам белән ант итәм. Мин кырык хатыны булган ир белән торып караган кеше. Яраткан кешенең кадерен белергә дөнья мине үзе өйрәтте. Мин биекләрдән биекләргә күтәрелгән хатын идем, бүген әнә нинди көнгә калдым. Ярый әле язмыш миңа сине җибәрде, мин аңа шуның өчен кат-кат дога кылармын, намазга утырып, рәхмәт яудырырмын.

Әйе, ул чынлап та һичкемнең кулы җитмәстәй югарыга күтәрелгән иде, әйтергә була — күккә ашкан иде. Беренче тойгысы уянгандагы куанычлы авазы, оялу хисләре, тән тартылуы, чарасыз калып, бияттәй тезләрен кочып, күзләрен йомуы — барысы да якты истәлекләр генә булып калдылар. Аннары Ил-Ватан белән идарә итүне Йосыфы үз кулына алды. Болгарга юнәлгәч, Йосыфы югалганны ишеткәч, югалтуы белән килешеп, тынычлана төшкәч, Айбибинең хәтеренә изге китаптагы сүзләр төшкән иде: «Кайларда булсаң да, әҗәл сине куып җитәр, хәтта Каф тауларына менсәң дә, манараларга менеп пос-

саң да...» Ләкин Сөләйман пәйгамбәр адәм үлеменә бөтенләй башка мәгънә сала. Ул бу хакта: «Гүргә кергәч, син барысыннан да аерылырсың, сиңа анда берни дә кирәкмәс...»

* * *

Никах укыткач, берара торганнан соң, Айбиби барысын да утарга дәште. Гаязетдин дә, Бибисара да, Сара анакай да каршы килмәделәр. Каладан утарга таба кузгалган көнне күк йөзе чалт аяз, мөлдерәп кояш чыккан, шәһәр уянган иде инде. Ашыкмый гына бардылар. Иң алдагы арбага Гаязетдин белән Айбиби утырдылар, икенче арбага Сара анакай белән Бибисара. Балаларны алмадылар, сабакка барасылары бар икән.

Юл шактый булса да, бер дә ялыктырмады, барыр җайда дөнья хәлләре турында сөйләшеп бардылар.

Аларны капкадан ук Садрый агай каршы алды. Ә утардагы хезмәтчеләргә кунакларга табын хәстәрләргә, мунча ягарга кушты. Садрый агайның чын хуҗаларча утарда эш итүенә Айбиби шат иде.

Капкадан арба узуга, Айбиби арбадан сикереп төште һәм Аккошлар күленә таба ашыкты. Гаязетдин Сара анакай белән Бибисараны күтәп алды һәм алар да әкрен генә күлгә таба кузгалдылар. Сара анакай нигәдер өйгә кереп калды.

— Җан кергән, Гаязетдин туган, каханбикәгә, җан кергән.

— Үлгән артыннан үлеп булмый, Садрый агай, дөньялыктагын дөньялыкта алып калу зарур. Ходай кемгә дә ике гомер бирмәгән.

— Айбиби, Айбиби, туктале, безне көт,— дип куып җитте Гаязетдин, әмма ул аңа әйләнеп тә карамады. Күл буена, аккошларны ашаткан җиргә ашыкты. Күл буена җитеп, аккошларга җим ташлагач кына, Айбиби артыннан килүчеләргә әйләнеп карады. Карады да кинәт күктән җиргә төште. Аның артыннан, шактый кала төшеп, кулга-кул тотынышып, Гаязетдин белән Бибисара киләләр һәм кет-кет кемнәндер көләләр иде. Садрый агай алардан кала төшеп килә. Күрде дә бу хәлне Айбиби ни өчендер йөрәге «жу» итеп китте. Әмма икенче мәлдә инде эчке бер елмаю белән Бибисарага таба кузгалды. Килде, хатынның кулыннан алды һәм аккошларга җим ташларга кушты.

— Күрәсең, Бибисара, күрәсең, нинди матурлар алар, горурлар, тәкәбберләр.

Садрый агай, бер читтәрәк калып, кунакларның аккошларны ашатуларын карап-карап торды да Айбибигә:

— Каханбикә, каханбикә, дим, теге каракош исән бит әле, урманда яши, ашарга безгә килә-китә йөри,— диде.

— Каракош?! Теге вакытта Сатлык укка алган каракошмы?!

— Әйе, каханбикә, шул каракош.

— Минем аны күрәсем килә, Садрый агай. Ничек кышларны чыкты, ничек ачка үлмәде?

— Бездә кыш чыкты, аерым абзарда. Ләкин җәй килдеме, урманга биләмгә чыгып китә, кайчан атналар буена кайтмый.

— Әле дә утардамы?

— Юк, атна була инде, күзгә күренми.

— Сатлыкның мәетен ишләре алып китмәделәрме, Садрый агай?

— Шунда ята, нарат төбендә. Без аның каберенә тәре ясап кададык. Ул да Хода бәндәсе иде бит, каханбикә.

Айбиби дәшмәде. Көлешә-көлешә нидер сөйләшкән, үзеннән биш-алты адым читтә басып торган Гаязетдин белән Бибисарага борылып карады. Һәм эчке бер кимсенү белән: «Ул аны ныграк ярата»,— дип көрсенеп куйды.

Кичке ашны ашап-эчкәч, кояш шактый югары булганга, урманга чыгарга булдылар. Гаязетдин белән Бибисара бергә йөрделәр, чәчәкләр җыйдылар. Көлешәләр, үзара нидер сөйләшәләр. Айбиби сиздерми генә алардан аерылды да таныш сукмактан күлгә таба китте. Барган җайдан бөдрә чәчле каеннарның чәчләреннән сыйпады, очраган бер наратны кочаклап, урман шавын тыңлады. Биредә аңа һәр нарат таныш иде. Улы Ибраһим үсмер чакта шушы урманга чыгарлар иде дә, бу нарат минеке, әнә теге нарат минеке, дия-дия куыша башларлар иде. Ниһаять, киң ябалдашларын күлгә кадәр сузарга теләп каракош утырган мәһабәт наратка җитте. Һәм килер җайдан, күптән күрмәгән танышын очраткандай, кочаклап алды да: «Бир миңа куәт, бир миңа көч!» — дип, кат-кат кабатлады. Шунда аның күзе Сатлык каберенә төште. Күр инде, кая ята Йосыфының канын койган яман адәм. Кисәк аның хәтеренә Бохарадан килгән мөгаллименең сүзләре исенә төште: «Хода һәммә халык өчен дә бердер, ә Аңа ышану төрле халыкта төрлечәдер...» Шул чакта ук аның мөгаллименә: «Нигә соң һәр халыкның үз кыйбласы?» — дип әйтәсе килгән иде. Кыймады, әйтмәде. Ә бүген әйтер иде, тик ул еллар күптән үткән шул инде.

Җир-туфрактан терсәк биеклек кенә калкып чыккан, каеннан ясап тәре кадалган кабергә Айбиби бик озак карап торды. Ахыр күзләре каберне күрмәс булды, ә күңел күзе күп еллар элек биредә булган

фаҗигагә юнәлде. Өлкән равва Ибраһимга ялланып, ул кая барса, аңа ияреп йөреп, әҗәлен Казан туфрагында тапкан, каракош яратып утырган нарат төбенә күмелгән Сатлыкның язмышы һәр адәм баласы өчен дә гыйбрәтле хәл иде. Аллаһы колы булсаң да, кеше колы булма икән.

Кичке чәй табыныннан кузгалгач та, Айбиби сиздерми генә Ибраһимын карап үстергән бүлмәгә таба кузгалды. Аны югалттылар бугай, бераздан кемдер ишекне шакыды. Айбиби аңа:

— Мин яттым инде, бик арыдым,— дип, табын янына яңадан чыкмады.

Әйе, чыкмады, ятты, әмма күзенә йокы кермәде. Зиһен тукымасын якты истәлекләр, тәүге хатирәләр күмеп китте. Атасы Мөхәммәд хан, Рәшидә абыстай, Ислам, Йосыф кахан, Сара анакай аның гомер юлында адаштырмый йөрткән изге затлар, ниһаять, Гаязетдин һәм Бибисара. Йа Хода, тагынниләр күрәсе бар икән аның?.. Гаязетдин Йосыф каханның улы һәм инде аның ире. Хәер, төрки халыкларда ирләре сугыш кырларында ятып калган хатыннарны үз канат асларына алган ир-атлар да булган. Ләкин ул бичара хатын-кызлар яраттылар микән йола ябыштырган ир-затны. Ә менә Айбиби Гаязетдинне ярата, гәрчә җиңгәчәй дип йөрсә дә никахлаштылар. Иллә һич кенә дә үкенү юк, тик кайчак йөрәк кенә чәнчеп куйгалый. Иншалла, ул да үтәр... Шул вакыт кемдер капка кага кебек. Җәйге төн кыска, таң да атып киләдер инде, кем йөри икән шулай иртәләп? Торды, тәрәзә янына килде. Таң нурлары яңа гына күккә сузылган. Кем йөрер шулай иртә таң белән? Нигәдер Садрый агай да күренми. Кунакларны сыйлады бит, ул да арыгандыр. Айбиби өстенә халатын салды, итеген киде. Ә кемдер һаман капканы тук та тук шакый да шакый.

Айбиби өйдән чыкты, сак кына капкага якынлашты.

— Кем бар анда?

Дәшмәделәр. Айбиби шикләнә калды. Шул вакыт ул капкага таба килүче Садрый агайны күрде.

— Кем бар анда, каханбикә? Ачыгыз.

Айбиби кече капканы ачты, капкадан сөйрәлеп кереп килүче каракошны күрде дә:

— Абау, Садрый агай, ни бу?!

— Сатлык укка алган каракош бу, каханбикә. Теге вакытта урманга җибәрегез, дип әйткән идегез бит, җибәрдем мин аны урманга, тик әйләнде дә кайтты, әйләнде дә кайтты. Бер канатын сәлендереп, төлке-бүреләр белән сугышып йөри шунда.

— Ашатасыздамы үзен?

— Җан иясе бит, каханбикә, ашатабыз инде. Бүген тагын бүре белән сугышкан, ахры, тәмам канга баткан, бичара.

Ләкин каракош, ишегалдына сөйрәлеп керүгә, берничә тапкыр талпынды да тынып калды.

— Садрый агай, ни булды аңа?

— Җан тәслим кылуыдыр, каханбикә. Бу бичара да котылды,— диде дә Садрый агай каракошны, канатыннан сөйрәп, каядыр алып китмәкче итте.

— Нишләтергә исәбең аны, Садрый агай?

— Урманга чыгарып ташлыйм, бүреләр ашамаса, ишләре ашар.

Айбибинең келт итеп Хазарстанда булган хәл күз алдына килде. Каракошларны укка алучы мәргән бер явызны укка алгач, ишләре җиргә төшеп ботарлый башлаганнар иде бичараны. Айбиби шул хәлгә исе китеп карап торган иде. Өзгәлиләр, тарткалыйлар, ә теге үлеп тә җитмәгән, чыелдый, кемнедер ярдәмгә чакыра кебек. Әмма ишләре, һичнигә карамый, тегене бик тиз юк иттеләр, каурыйлары гына калды мескеннең. Шул хәлне күз алдыннан кичергәннән соң, Айбиби каракошны сөйрәп алып китеп барган Садрый агага:

— Урманга ташлама син аны, Садрый агай. Үзе утырган нарат төбенә илтеп күм, Сатлык яткан җиргә. Явызлыкның чиге юк, ишләре килеп ашаулары бар. Ә минем аны нигәдер ишләреннән ашатасым килми.

— Борын заманда кайбер халыклар үз адәмнәрен ашаганнар, каханбикә. Әйдә ашасыннар, каракошлар өчен гадәти хәл бу.

— Юк инде, Садрый агай, син аны үзе яраткан нарат төбенә күм.

— Димәк, Сатлык белән янәшә,— диде Садрый агай һәм китеп барды, ә озын канатлы каракоштан җирдә кан тамчылары калды.— Хак әйттегез, каханбикә,— дип туктады Садрый агай.— Ятсыннар бергә. Сатлык җан белән, дим. Туган туфрактан аерылган — Ил-Ватаннан аерылган, диләр бит.

— Хак әйттең, Садрый агай, бәхетне адәм баласы туган туфрагында гына тапса таба икән.

— Шулай шул, туган якка җан тартмаса да, кан тарта.

Шул вакыт Айбиби болдырга чыгып баскан, иңенә яшел атлас халат салган Гаязетдинне күрде. Ул Айбибинең өйгә таба килүен күрде дә, йөгереп төшеп, хатынны кулына күтәреп алды һәм барыр җайда колагына:

— Әллә нигә өшеп киттем, бүлмәңә алып кереп җылытчы, җиңгәчәй,— дип, кайнар сулышы белән Айбибинең муенын көйдереп алгандай итте. Бит аны кайчандыр кырык хатыны каршында Йосыфы да шулай кулына күтәреп чатырына алып кереп киткән иде. Ул чакта Айбиби шушындый хәлдән курка

калган иде, үзенә карап калган хатыннардан оялган иде. Хәзер исә үзе үк Гаязетдиннең муенына сарылды һәм яратканда әйтә торган сихри сүзләрен тезде:

— Син мине яратасың, яратасың бит, Гаязетдинем, яратасың бит...

— Яратам, яратам, җиңгәчәй, яратам, мин сезнең икегезне дә яратам...

Айбиби, сабыры төкәнеп, эченнән кабатлады: «Мине яраталар, яраталар! Явызлар, каракошлар бу дөньяга килә дә китә, мин калам, мин сиңа малай табармын, Гаязетдин, халкымның дәвамын бүләк итәрмен, чөнки без, хатын-кызлар, нәсел җебен дәвам итүчеләр, нәсел җебен, җаным-бәгърем, Гаязетдинем...»

# Эпилог

Кече капканы ачып, урам ягына аяк басарга да өлгермәде, аның каршында өч мосафир пәйда булды. Алар бердәй Сара анакай аягына төштеләр.

—Коткар безне, анакай… Без адаштык. Безне язмыш адаштырды. Ил-җиребез су басты, Хазар диңгезе ташты, җир-калаларыбыз су астында калды.

—Әллә туфан калыктымы?

—Туфан калыкты, анакай, туфан. Хазарстан халкы кайсы кая сибелде, таралды. Биләмҗир калабызны җир йотты, Аккала су астында калды. Мәхшәрдән котыла алганнары…

—Торыгыз, мосафирлар, яхшылап аңлатыгыз. Сәнең йөзең таныш та кебек,— дип, Сара анакай кәттәрәк киенгән Шарунга туры карады. Ул күз ташлаган мосафир башына ак чәпләшкә каплаган, керләнеп, каралып беткән чәпләшкәсе баш түбәсен генә каплап тора.

—Шарун равва мин, каханбикә Сара, Шарун равва. Йосыф кахан сараенда өлкән равва Ибраһим кул астында балалар укыттым.

—Димәк, син Ибраһим равва кешесе.

—Юк-юк, мин чарасыздан аның кул астында гомерем сарыф иттем, анакай.

—Сезгә өлкән равва Ибраһим кирәкме, аны эзлисезме?

—Юк, анакай, без синең алга килдек. Коткарыгыз, безне сез генә коткара аласыз. Ибраһим равва Шәмгун хан сараена мөфти булып урнашкан. Безне ул барыбер кабул итмәс иде. Без Болгарга тукталып та тормадык.

—Адашкан Исраил балаларын, шулаймы, равва Шарун?—дип, ирен чите белән генә елмаеп куйды Сара анакай.—Мин сине бераз хәтерлим, равва Шарун, хәтерлим, син коткардың бит мине өлкән равва кулыннан, син… Хәтерләми буламы… Йосыф кахан кая, кай тарафларга юлыкты, балакай?

—Йосыф кахан викинглар килүгә үк гаип булды, анакай. Эзләделәр аны, тапмадылар.

—Викингларны илгә кем дәште?

—Хак булса, өлкән равва Ибраһим, анакай.

—Йосыф кахан түгелмени?..

—Юк. Ул аларны калага кертмәскә тырышты, каршы торды. Өлкән равва Ибраһим викинглар ярдәме белән кала-салалардагы мөселманнар белән христианнардан котыласы иткән иде. Атна буена койган яңгыр барысын да астын өскә китерде. Без дә болгар юлаучыларына ияреп котылдык.

—Алай да, ничек кахан кадәр кахан кинәт гаип булды соң?

—Викинглар китүгә, ул да юкка чыкты, анакай. Пиратларның китүләре булды, коеп яңгыр ява башлады. Тәмам болыты белән төште, елгалар ташты, Ханбалыкның сәмән өйләрен су юды. Әйтәм бит, тәмам туфан калыкты.

—Сез нигә минем каршыма килдегез? Каханмы әллә мин сезгә?.. Нигә Ибраһим кырында калмадыгыз?..

—Ибраһим равва минем сөймәгән кешем иде, анакай. Ул каханатка Гаязетдин угланны кайтарырга тиеш иде, ә Йосыф угланны баш бирмәгәне өчен…

—Ефәк бау беләнме?

—Әйе, анакай. Мин аңа каршы төштем һәм ул мине күралмас булды. Коткарыгыз безне, анакай. Сез олуг каханның бердәнбер сөйгән хатыны идегез.

«Айбиби хатын кебекме?» — дип уйлап өлгерде Сара анакай, ләкин әйтмәде, тыелып калды. Үз алдында баш иеп, нидер өмет итеп көтеп торган мосафирлардан күзен алып, күктәге ак сарыклар кебек тезелеп аккан болытларга күз ташлап алды. Шул ук мәлдә аның күз алдына Убәдәй каханның ничек якты дөньяны ташлап китү мизгеле хәтер күген ачып җибәрде. Аңа аны күрсәтмәделәр, ләкин ул бераз чамалый иде—раввалар аны ефәк бау белән буып үтергәннәр. Сәбәбе билгеле, нәкъ Йосыф кахан кебек үз кырына бары тик бер хатынны — Сараны гына тарттыра башлады. Бу инде каханатның канунын күрәләтә бозу иде. Һәм раввалар яшерен рәвештә табын җыялар да Убәдәй каханнан котылу чарасын күрәләр. Өлкән равва Йосыф урынына Ил тәхетенә Гаязетдин угланны кайтартырга тели, әмма Йосыф кахан аны Казан каласына тархан итеп озаткан була инде. Әле булса хәтерендә, Убәдәй каханны җирләгәч, Сара хатын кырына өлкән равва Ибраһим килеп керде. Сара хатын бала имезеп утыра иде,

күкрәген каплап, баланы асрау хатынга бирде һәм, торып басып, өлкән равваны түргә дәште. Ләкин өлкән равва узмады, ишекъяры калды. Өлкән равваның кулында ефәк бау иде. Бауны күрде дә Сара хатын эсселе-суыклы булып китте, җаны белән түгел, тәне белән тойды бауның кем муенында булып алуын. Өлкән равва кулында Убәдәй каханны буып үтергән ефәк бау. Бау төрле төстәге ефәк җепләр белән ишелгән, оч-очлары төйнәлгән һәм чукланып тора иде. Ни әйтергә теләде икән моның белән Сара хатынга өлкән равва? Куркытасы иттеме?.. Сара хатын белмәде, чөнки ул Убәдәй каханга ике углан бала тапкан яшь, чибәр, иң яраткан хатыны иде. Очрашкан саен өлкән равва, күзен ала алмый йотлыгып, Сарага карап торыр иде.

Өлкән равва Ибраһим бер урында таптанып алды, ефәк бауны кесәсенә салды һәм турыдан-туры:

—Мин сине, Сара хатын, угланнарың белән үземә алып калырга булдым, Убәдәй кахан да каршы булмады,—диде.

«Буып үтергәндә ни вәгъдә итмәс кеше дәҗҗалына»,—дип уйлады Сара хатын, ни әйтергә, ни кылырга белми, чарасыз калып.

—Миңа уйларга ике-өч көн вакыт бир, өлкән равва.

—Яхшы, ике-өч көн вакыт бирәм,— диде өлкән равва, ары таба бер сүз дә әйтми борылып чыгып китте.

Дәҗҗалның чыгып китүе булды, Сараның гүя ташуы ташты, ятагына капланды да үксеп-үртәлеп еларга тотынды. Әбисенең елавын ишетеп, асрау кулындагы бала да шыңшый башлады. Сара баланы кулына алды да, як-якка чайкала-чайкала, раввага каһәр укыды. Менә шунда аның кырына равва Шарун килеп кергән иде. Керде дә бусага төбендә үк:

—Мин сезне коткарам, Сара хатын. Киенегез, җыеныгыз, мин сезне Таман тарханы Галигә биреп җибәрәм,— диде.

Сара хатын һични аңламый бер мәлгә мөлдерәмә тулы яшьле күзләре белән аңа карап торды.

—Өлкән равва Ибраһим җибәрдеме?—дип сорады.

—Мин өлкән равва көчеге түгел, булмадым да, Сара хатын. Мин сезне аның кулыннан коткарырга килдем. Гали тархан сезне алып китәргә риза булды. Ул сезне Ханбалыкта көтеп тора, Сара хатын.

Сара кинәт барысына да ышанды һәм кабалана-кабалана җыена башлады. Равва Шарун алдамады һәм эңгер-меңгер вакытта асравын һәм бала белән Сараны Ханбалыкта көтеп торган тархан Гали кулына китереп тапшырган иде.

Зиһене ачылып китеп, күктән күзләрен алуга, Сара анакай каршында кайчандыр үзен коткаручы басып торуына инанды һәм, кече капканы ачып:

— Җәләлетдин, менә бу мосафирларны кече кунак өенә урнаштыр. Мунча керт. Ашат-эчер. Алар иртәгә юлга чыгалар, үзләренә айлык ризык-нигъмәт әзерлә… Юл акчасын үзем җайлармын,—диде.

— Хуш, анакай, хуш,— дия-дия, кече капкада башына яшел түбәтәй кигән кара сакаллы берәү пәйда булды, ул мосафирларга сәлам юллады һәм өчесе белән дә кушкуллап күреште дә юлчыларны, ияртеп, ишегалдына алып кереп китте.

Сара анакай янә күктәге ак болытларга күз төшереп алды һәм үзалдына:

— Мин дә, ахры, иртәгә Казанга таба кузгалырмын. Әллә нигә киленнәрем, оныкларым күрәсем килә, ичмасам, эчем бушаганчы сайрашырбыз,—дип сөйләнә-сөйләнә, эчкәре узды һәм капканы япты.

*1999–2003*

*Казан—Таман ярымутравы—Әстерхан*

# Белешмә

Тарих фәне һәрдаим хакыйкатькә
омтылырга тиеш, юкса аның беркем
өчен дә кадере калмаячак, бит
хакыйкый дөреслеккә йөз тотмаган
тарих сукыр кешене хәтерләтә —
хакыйкатьтән ерак торган кирәксез
сүз боткасы булып кына кала.

*Б.э.к. икенче гасырда яшәгән грек тарихчысы Полибий*

**Хазарлар**

Без, татарлар, нигездә, Кытай, Рим, Византия, Бөекбритания, Америка, Русия һәм аз-маз Иран-гарәп тарихчыларының язмаларында чагылыш тапкан бабаларыбызның үткәнен өйрәндек. Анда да чикләнгән рәвештә генә. Гун-төрки бабаларыбыз турында VI гасырда яшәгән Иордан, соңрак Н. Бичурин, В.Таскин, Э.Шефер, Швеция галиме Андерс Стриннгольм, бераз гына Владимирцев, Л.Гумилев, А.Меликсетов хезмәтләре һәм Кытай чыганаклары белән танышырга мөмкинлек туды; бигрәк тә инглиз телендә бөтен дөньяга таралган Эдуард Паркер

борынгы Кытай чыганаклары аша татарларның ерак бабалары тарихын ача, шулай ук Рим империясенең нинди сәбәпләр аркасында таркалу сәбәбен мисал итеп биргән Эдуард Гиббон, шул исәптән В.Радлов, В.Бартольд, Н.Баскаков, М.Артамонов, А.Бернштам, Н.Крадин, аеруча галим-тюрколог Л.Гумилевның күпкырлы хезмәтләренә таяна-таяна, бабаларыбызның үткәненә карата күзебез ачыла төште. Бактың исә, безнең бабаларыбызның тарихын б.э.к. V гасырда гомер иткән тарих атасы Геродот та сөн-скифлар йөзендә төрки халыкларының көнчыгыш Ауропада борын заманнардан ук көн күрүләрен искәреп үткән икән. Мин дә, тарихи әсәрләр язучы буларак, V гасырда ук инде Бөек Кытай стенасыннан Дунай елгасы буйларына кадәр җирләрне биләгән һәм меңнәрчә еллар буена Кытай империясенең саруын кайнаткан татарларның б.э.к. ике-өч йөзләр элек башланган тарихын тикшергән Э.Паркерның бай хезмәтен күздән кичердем. Хак, сөн-төрки бабаларыбызның тарихына татар галимнәре дә теге йә бу яклап, борынгы чорларда Хазарстанда булып киткән Иран-гарәп мосафирлары язма-мәгълүматларына да таянып, бабаларыбызга кагылган ташларга һәм археологлар тапкан савыт-сабаларга төшкән язмаларны да читләтеп үтмичә, татар тарихына мөмкин булган кадәр ачыклык кертергә тырыштылар. Әйтик, мөхтәрәм галимебез Шиһабетдин Мәрҗани бу хакта хезмәтенең берсендә болай ди: «...Тарих фәне — барлык милләт һәм кабиләләрнең хәлләрен эченә ала, гыйльми тармакларны һәм фәнни бәхәсләрне тикшерә. Гади халык һәм белмәүчеләр аны белергә тели... Әмма безнең бабаларыбыз — монгол һәм татар таифәләре — бу бөек тарих гыйльме һәм халыклар тормышы белән кызыксынмаганлыктан, тарих фәненнән өлешсез калып, дөньядагы хәлләр, вакыйгалар һәм маҗараларны беркетеп бармаганнар. Шуңа күрә бөек галимнәребез, патшаларыбыз һәм олуг акыл ияләребез турындагы хәбәрләр, ата-бабаларыбызның, нәсел-нәсәбебезнең һәм туганнарыбызның хәлләре вә кылган гамәлләре... билгесезлек пәрдәсе астында капланып калган...»

Хак, бабаларыбызның тарихына Әхмәт-Зәки Вәлиди атлы тарихчыбыз да күз ташлый. Бабаларыбыз тарихы турында үз хезмәтләрендә ул болай ди: «Төрки кауеменең һәммәсенең дә теле бер — төрки телдер... Алтайдагы төрекләр көнбатыштагы Кырым татарлары илә тәрҗемәсез сөйләшә алалар...»

Карендәш төрки туганнары хакында хөрмәткә ия тарихчыбыз Ризаэтдин Фәхретдинов та: «Дөньяда гарәп һәм фарсы, һинд һәм әфган, кытай һәм япон, француз һәм инглиз, итальян һәм рус исемнәрендә милләтләр булган кебек, төрки исемендә дә олуг милләт бар. Төрки милләте — безнең үз милләтебез, без төрки милләтеннәнбез»,— дип, тәүге тарихчыларның сүзләрен куәтли.

Төрки халыкларының көн күргән ил-җирләрен билгеләгәндә, Русия патшаларының мәнфәгатен күз угында тотып, тарих фәнендә гафу итмәслек хаталар җибәргән немец галиме Миллер Герард Фридрих (1705–1787) җәнабларына җавап итеп, тарихчы Һади Атласи катгый рәвештә: «Ауропа халыкларына скиф, сармат, гун, авар, кыпчак-половец, татар исемнәреннән чыгып әтрафка таралган төрки (түрк) балалары иде. Кытай империясен хафаландырганнары өчен, татарлар чиннар тарафыннан һәрчак рәнҗетелделәр, кимсетелделәр»,— дип язды.

Тарихчы Газиз Гобәйдуллин дә бу теманы читләтеп үтми, чөнки бабаларыбызның тарихы һәр дәвердә дә һәммә гыйлем иясен кызыксындырып үзенә тартып тора. Әйтик, кан кардәшләребез угызлар Хазар каханаты җирләренә яу йөргәч һәм андагы бакчаларны, сала-калаларны җир белән тигезләгәч, төрек-яһүд карты күз яше белән искәрә: «... Хазар исемле дәүләтнең башына килгән һәлакәтләр, шимальдан килгән гаскәрләр, Урал тавы артынннан чыккан күчмәләрнең һөҗүмнәрен сөйләп, бу мәгъмүр шәһәрне шуларның уклары көл иткәнен, шуларның кылычлары халыкларны кискәнлеген, шул һөҗүмчеләрнең ат аяк асларында харап булганлыгын сөйләде...»

Шулай ук безнең бабаларыбызга кагылган Ибн Фадланның Болгарга сәяхәтен дә, үз гомерен Идел буе төрки болгарларының дөнья халыклары арасында тоткан урынын ачыкларга керешкән совет чоры тарихчылары Альфред Халиков, Фатих Урманче, Мирфатих Зәкиев, Әзһәр Мөхәммәдиев, Фирдәүс Гарипова һ.б., шул исәптән бөтен дөнья халыкларына ия булырга керешкән полководец Чыңгыз ханга багышланган хезмәте белән безгә соңрак булса да билгеле булган д-р Эренжен Хара-Даван, Алтын Урда империясенең таркалуына багышланган Мөхәммәд Сәфәргалиевнең хезмәте, миңа якын булган Казан ханлыгына караган Михаил Худяков, Равил Фәхретдиновның күпсанлы хезмәтләрен, Илдус Таһиров, Гамир Дәүләтшин, Олжас Сөләйманов, Мурат Аджи, Рафаиль Бәзертдинов һ.б. хезмәтләрен дә читләтеп үтә алмадым. Чөнки соңгылары, хакыйкатькә якынрак килеп, татарлар тарихын тулыландырдылар. Хак, соңгы елларда татар халкы тарихына кагылган шактый хезмәтләр туды. Тарих фәненә яңа аяк басып, шактый җитди хезмәтләр башкарган Солтан Шәмси, Булат Хәмидуллин һ.б. яшь тарихчылар да бабаларыбыз тарихын тәгаенләүдә саллы гына хезмәтләр яздылар. Бу хәл дә, бәхәссез, куанычлы гамәлдер. Ә инде хазарларга килгәндә, Хазарстан тәгаен безнең бабаларыбызның тарихы, дип әйтергә тулы хокукыбыз бар. Элегрәк заманда Ауропа һәм аларга йөз тотып Русия тарихчылары тарафыннан язылган төркиләргә багышланган хезмәтләр, тәгаен кызыл җеп белән тегелеп, бары тик легендаларга һәм руханилар уйлап чыгарган риваять-хикәятләргә нигезләнеп кенә өскормаланды. Тик бит кайбер хезмәтләрдә күзне ертып торган бары бер хакыйкатьне күрергә була — Русиянең гүя татарлардан башка дошманы булмаган. Бу хәлне инкарь итәргә теләп, «Рухият» нәшрияты «История татар» – татарлар тарихының беренче томын укучыларга җиткерде. Бу да куанычлы хәл, әлбәттә. Шулай димәс идек, бүгенге көнгә кадәр мәктәпләрдә тарих фәне татарларга карата шундаен яман дошманлык белән сугарылып бирелә ки, мәктәпкә килгәч һәм тарих фәненнән белем ала башлауга, урыс баласы, шул исәптән урыс теллесе дә, бер партада утырган татар дустына бөтенләй башка күзлектән карый башлый. Иң яманы: бу елларда бала шушы хәлне мәңгегә күңелендә калдыра, чөнки хәтере, зиһене саф чак. Ил белән идарә итү дилбегәсен Алтын Урда кулыннан алсалар да, Русия тарихчылары татарларның мәрхәмәтсезлекләрен шундаен тәмләп язалар ки, тарихта булмаган хәлләрне булды, дип, булганны җиде тапкыр

күпертеп вә арттырып бирәләр. Алтын Урдага һичбер мөнәсәбәтләре булмаган, бары тик төрки-татар телендә сөйләшкән өчен генә чыңгызлылар кылган гөнаһларны ике дә уйламый Идел буенда көн күргән татарларга кайтарып калдырдылар. Әнә шулай, кара этнең бәласе ак эткә дигәндәй, Идел-Урал буйларында көн күргән татарларга, ул гынамы, бөтен Русиядә яшәгән барлык татарларга да еллар буена каһәр укылды. Хәер, бу гамәлнең бүген дә туктаганы юк, урыс халкы татарлардан башка дошманны белми, белсә дә, чит баскынчылар Русия җирләренә керсәләр дә, кан койсалар да, алар инде күптән дәүләтнең рухи туганнарына әверелгәннәр — кочаклашып йөрү генә түгел, бер-берсен уздыра-уздыра мактыйлар. Чөнки бүгенге Русиядә янә христиан дине чәчәк ата башлады, ул гынамы, православие дине дәүләтнең төп идеологиясенә әверелеп китте. Коммунизм идеологиясеннән мәхрүм ителгән Русия империясе, кисәктән бар идеяләрдән дә ваз кичеп, 988 елда Византия империясеннән алган православие дине идеологиясен алгы планга тартып чыгарды һәм, президент аппараты чиновникларына кадәр чиркәү руханилары белән берләшеп, җиң сызганып, ил белән идарә итәргә керештеләр.

Иң яманы, цивилизацияле илләрдәге кебек светский рәвештә түгел, ә турыдан-туры православие диненә нигезләп. Тагы да сәере шулдыр: руслар татарларны гасырлар буена каһәрләүдән арына алмадылар, аларның ялганын тәгаен дәлилләр белән фаш итеп, саллы хезмәтләр язган чит ил галимнәренең китапларын Русия чигеннән уздырмадылар, Казан ханлыгының чын тарихын язган Михаил Худяковны диварга терәп аттылар, башкалары турында әйтеп тә торасы юк. Бары тик еллар үтә-үтә генә Бернштам, Худяков, Гумилев кебек галимнәрнең гуманизмга, гаделлеккә йөз тоткан хезмәтләре белән таныша алдык. Калган Русия тарихчылары исә Рим империясен җимергән татар-төрки халкының каһарманы Аттила ханны да, Даланы биләгән кыпчак-угызларны да, төрки халыклары кылган барлык яманлыкларны да ахырда Идел буенда көн күргән татарларга кайтарып калдырдылар, һәм Русия тарихчылары уйлап тапкан ялган тарихны дөнья халыкларына тараттылар. Нәтиҗәдә, баштагы мәлдә, яңа оешып килгән Америкага кадәр иленә татарларны кабул итмәде, империядән качкан татар мөһаҗирләрен кире борып җибәрде. Хак, соңрак Америка халкы моның Русия тарихчыларының ялганы, империянең төп сәясәте булуын аңлады, ләкин инде ялган тамыр җәйгән иде. Русия тарихчылары башлап җибәргән ялган-гайбәт дөнья халыкларына таратылган иде инде. Баскынчы варяглар ярдәме белән, күрше-тирә илләрне яулап, барлык халыкларны канат астына җыярга керешкән Русия империясенең мәкерен Аурупа илләре генә түгел, Азия илләре дә соңгарыбрак аңладылар — Рим империясенең байрагы икенче Рим — Византиядән өченче Рим — Русия кулына күчкән икән ич!

Русиянең тарихын язучы Кырым татары Кара Морза улы Миңлегәрәй, чукынганнан соң, Михаил Карамзин исем-атын ала һәм империянең тарихын язарга керешә. Һәм шул тарих бөтен дөнья халыкларына тарала. Шушы тарихны укыган дөнья халыклары төркиләрне, бигрәк тә татарларны, кыргыйларга тиңлиләр һәм, һич оялмый, килмешәкләр дип язалар. Ә бит чынында исә Аурупаны монголлар афәтеннән, беренчеләрдән булып, Идел буе төрки болгарлары коткарырга алыналар. 1223 елда Чыңгыз ханның җиңелмәс баһадиры Сүбәдәй берләштерелгән рус-кыпчак гаскәриләрен туздырып ташлагач, 30 мең гаскәре белән Идел буе Болгарына таба юнәлә, әмма төрки болгарлары баһадирның гаскәрен, ике тау арасына алдап кертеп, тәмам тетеп ташлыйлар. Ике-өч меңгә дә тулмаган сугышчылары белән бер күзен югалткан баһадир көчкә качып котыла. 1229 елда Урал елгасы буенда төрки болгарлары белән монголлар арасында янә канлы сугыш була — бүген татарлар дип аталган халык монголларны янә Аурупага таба уздырмыйлар. 1232 елда монголлар Идел буендагы Саксин каласын алуга ирешәләр, әмма Илһам хан үзенең көчле алаен (гвардиясен) ярдәмгә җибәрә, нәтиҗәдә монголлар Саксиннан куылалар. Бары тик 1236 елда гына, чорына күрә тиңе булмаган гаскәр белән килеп, монголлар Болгарстанның башкаласын алуга ирешәләр — каланы яндыралар, ил-халкын канга батыралар. Иң гаҗәбе, Русия тарихчылары еллар буена баскынчыларга каршы торган халыкны үзләрен яулаучылар итәләр — «монголлар явын» «татар-монголлар явы» дип, тарихларына кертеп җибәрәләр, ә канга бата-бата баскынчы монголларга каршы, Аурупага уздырмый каршы торган Идел буе төрки болгар-татарларын баскынчылар итәләр. Моны аңлавы кыен, кыен гына түгел, бу гамәлне аз-маз булса да тарихтан мәгълүматлы кеше күзгә бәреп торган уйку вә хыялый тарих дип бәяли ала. Ни гаҗәп, Русия тарихында татарларга карата язылган ялганны кем дә түгел, гап-гади гимназия укытучысы Наумов: «Татарлар баскынчы монголларга ияргән халыклар гына, шуның өчен ары таба мәктәп дәреслекләренә «татар-монголлар явы» дип язарга кирәк»,— дигән тәкъдим белән чыга. Иң сәере, бу чорның бер генә тарихчысы да гимназия укытучысының бу тәкъдимен инкарь итми, чөнки бу дәвер Русиядә тарихны фальсификацияләүнең чәчәк аткан чоры була.

Борынгы төркиләргә яңа хун исемен беренчеләрдән булып б.э.к. үк Кытай тарихчылары бирәләр, Аурупага килгәч, татар-төркиләрне гуннар дип яза башлыйлар. Моңа кадәр бу исем татар-төркилек белән йөргән була. Бу хакта Византия тарихында мондый юлларны укырга була: «Шул чакта элек без төркиләр дип атаган гуннар безнең тарафларга яу килделәр...» Ары таба византиялеләр өчен гун сүзе тәмам сүгенү сүзенә әверелә. Русия тарихчылары идеологияне тотырып Византиядән алганга күрә, гуннар турында Аурупа тарихчыларыннан да арттырыбрак яза башлыйлар. Әйтик, гуннар турында энциклопедиядә мондый юлларны укырга була: «II–IV гасырларда Урал төбәкләрендә оешып киткән күчмә төрки телле гуннар, җирле угор һәм сармат халыкларын ияртеп, көнбатышка таба Бөек күчеш башлыйлар (470 елларда). Шушы күчеш халыкларның Бөек күчешен башлап җибәрә. Барыр юлларында гуннар, герман кавемнәренең беришен һәм башкаларны буйсындырып, кабиләләр союзы төзиләр. Әнә шул халык бик күп илләрне җир белән тигезләп уза. Яуларның иң яманы Аттила хан чорына туры килә. Гуннарның көнбатышка таба яуларын Каталун кырындагы (451ел) сугыш туктата. Аттила хан үлгәч (453 ел), кавемнәр союзы таркала».

Энциклопедиядәге мәгълүматта сүз саен ялган тулып ята. Энциклопедиядә Бөек яу-күчеш IV йөздә башлана дип бирелә. Хакыйкый тарихта исә Бөек күчеш Уралдан түгел, II гасырда Алтайдан кузгала. Дөресрәге, Бөек күчеш II–IV йөзләрдә төрки-гуннар тарафыннан Алтай якларында оештырыла гына әле. Шушы дәвердә төрки һәм угро-фин халыклары хәрби союзга берләшә. Бу берләшмә башында әүвәл Баламир хан тора. 372 елда Баламир хан җитәкләгән союз гаскәриләре Дон елгасын кичәләр. Бирегә килеп оялаган готларны кууга ирешәләр. Ахыр килеп, Русия тарихчылары язганча, гуннарга килеп кушылган сарматлар бер дә фарсылардан чыккан халык булмый, бу халык туа-туганнан бирле төрки телдә сөйләшкән. Моны Русия тюркологы Лев Николаевич Гумилев та раслый. Аурупа тарихчылары сарматларны Ираннан чыкканнар, дип чамалап кына язалар, аларга ияреп сүзгә-сүз Русия тарихчылары кабатлыйлар. Бу хакта Кытай тарихыннан мондый юлларны укырга була: «Рим империясе һәм Византия Аурупаның Бөек илләре Дәште Кыпчакка IV гасырдан башлап ясак түлиләр».

Хәер, ни гаделтугры булырга теләгән Англия тарихчылары да Аттила хан төркиләре турында Русия тарихчыларыннан бер дә калышмыйлар. Державалар барлыкка килгәч, империяләр, сүз куешкандай, төркиләргә карата сәясәтләрен вә эмоцияләрен генә үзгәртеп калмыйлар, ә бәлки тарихларын да яңабаштан язарга керешәләр. Нәтиҗәдә Дәште Кыпчак бөек державалар санына кертелми. Ә бит бу дәвердә төрки-гуннар һәм аларга ияргән угро-фин, ант-славян кавемнәре кулында Байкал күленнән алып Дунай елгасына кадәр сузылган җирләр була. Византия империясе сановнигы Зимарх һәм гарәп Ибн Батута төркиләрнең ил-җирләрен сигез ай буена үтәргә кирәк, дип язалар. Дәште Кыпчак державасына шулай ук төркиләр каханаты — Кубрат хан төзегән (VII) Бөек Болгар дәүләте дә кергән. Бүгенге Татарстан республикасы җирләре Дәште Кыпчакның төньяк төбәге дип саналган.

Хан һәм Сөн державалары тарихын язган көнчыгыш тарихчысы Н. Крадин үзенең хезмәтендә бу державалар хакында болай ди: «Империя Хань һәм Хун державалары ун ел эчендә аякланып китәләр. Төрки каханаты Сөн династиясе, ары таба Тан династиясе белән берләшкәннән соң барлыкка килә...»

Әмма тынычлык озакка бармый, б.э.к. 215 елда Кытай императоры күчмәләрдән Суыксу елгасы буйларын яулап ала, хуннар Уртак (Ордас) дигән калаларын югалталар, күчмәләр өчен үтә хаҗәт болын-тугайлы, куе үләнле Суыксу елгасы буйларыннан мәхрүм ителәләр. Сөннәрнең илбашы өчен бу гаять зур югалту була. «Алтай таулары яныннан үткәндә, сөннәр һәрчак күз яше белән елап үтәләр иде»,— дип яза Кытай тарихчысы. Яуланган җирләргә император Мәнтән 40 кирмән күтәртә, кальгалар арасына юллар салдыра һәм яуланган җирләрне 37 өязгә бүлеп, кытайлыларны күчереп утырта. Ул гынамы, тарихларга кереп калган Бөек Кытай стенасын күтәртүгә керешә. Ә бит бу җирләр безнең эрага кадәр төрки халыклары кулында була. Суыксу болын-тугайларында бүген калалар күтәргән, дөге игү өчен барлык шартлар булдырган Кытай империясенең иң уңдырышлы җирләрендә безнең төрки-хун бабаларыбыз көн күргән һәм, һичшиксез, бүген Татар бугазы дип аталган төбәкләр дә алар кулында булган. Моны топонимия фәне дә раслый.

Әнә шулай безнең бабаларыбыз яңа эрага кадәр үк инде үзләренең төп йортларын вә эргәләрен югалталар, әмма яшәеш өскормаларын саклап калалар — яңа җирләр эзләп, төньякка таба юнәләләр.

Бу ни хакта сөйли соң, кадерле укучым? Бу шул хакта сөйли — тарих атасы Геродот скифлар дип язган бабаларыбыз безнең эрага кадәр үк инде Идел-Урал буйларына күчеп утыра башлаганнар, хәтта Александр Македонскийның атасы Филипп белән сугышканнар. Бу хакта тарих атасы Геродот: « Бу сугышта скифларның илбашы Әти һәлак була»,— дип яза. «Әти» дә безгә бик якын сүз ич!

Хак, Аурупа халыкларын коллыктан азат иткән каһарман Аттила хан туган якларына әйләнеп кайта алмый. Күпсанлы улларының берише генә аталары җирләренә әйләнеп кайталар. Без татарларның бабасы булган Кубрат хан да, аның уллары да Аттила ханның дәвамнары. Кубрат хан вафат булгач, яшь хан Аспарухны хазарлар җиренә килеп оялаган Ашин ыруыннан килгән Юлыш кахан эзәрлекли, чөнки Аспарух атлы углан аңа баш бирми, Юлыш кахан аңа кан кардәш төрки ыруынннан булса да. Аспарух углан кул астындагы кардәшләре белән әүвәл Днепрны кичә һәм Византия империясе җирләренә таба юнәлә. Ә Хазар каханының төп максаты Аспарухны җиңү түгел, башбирмәс ханны илдән куу була. Һәм ул моңа ирешә. Ә бит Каспий диңгезе буйларында иркле яшәгән бар нәрсәдән дә азат хазарлар да ниндидер күләмдә Бөек Болгар ханы Кубратка буйсынган булалар. Бары тик бирегә күчеп килгән яһүдләр раввалары ил белән идарә итүне үз кулларына алгач кына, Хазар каханы Юлыш Кубрат ханның дошманына әверелә. Биредәге иркле көн күргән төрки халыкларына көнбатыш каханатыннан үз кавеме белән кахан улы килеп кушылгач кына, бу ике бертуган халык арасыннан гүя кара мәче уза. Юлыш каханның тамгасы бүре була. Бүре җанвары, гадәттә, адәм баласына буйсынмый, туа-туганнан бирле мөстәкыйль һәм бәйсез яши. Шул ук вакытта адәм баласы белән күзгә-күз очрашудан һәрчак читләшеп көн күрә.

Әнә шулай ишәеп киткән ыру кавеме башына Бумын кахан килә. Бу кахан күршеләре жужаннар белән берничә тапкыр сугышкан була инде һәм хәтта соңгысында аларны җиңүгә, жужаннарны кул астына җыюга ирешә. Бишенче гасырда ук инде кытайларга якын жужаннар күчмә төркиләр белән бергә яшәп китәләр. Бик ихтимал, бу халыкның безнең кардәшебез башкортлар булуы да бар. Чөнки башкортларда гына кытайлардан кергән «һ» авазы сакланып калган. Бу хәлгә кадәр Бумын кахан, жужаннар ханы Анахуанга хатынлыкка кызын сорап, яучы-илчеләрен җибәргән була. Әмма тәкәббер жужан каханы Бумын каханны мыскыл итә, чөнки кияү буласы каханның кешеләре жужаннар каханына тимер коеп яткан булалар. Шуңа күрә тәкәббер кахан булачак кияүнең илче-яучыларына болай дип җавап бирә: «Син бит минем бары тик тимер коючым гына, ничекләр кыйдың син минем кызымның кулын сорарга!»

Кытай тарихчыларына ышансак, Бумын кахан моны махсус эшли — ул бераз чамалый, Анахуан кахан аңа кызын бирмәячәк, ә Бумын каханга шул гына кирәк тә. Ул үзенә килгән Анахуан каханның илчеләрен җәзалый, ә

буш кул белән әйләнеп кайткан үзенең илче-яучыларын икенче күршесе император Вәй-Ди иленә юллый һәм инде аның кызын кияүгә сорый. Император Дала каханы белән килешә, аңа кызын кияүгә биреп җибәрә. Бу буладыр 552 елда. Үзенә аркадаш табу белән үк Бумын кахан жужаннарга яу кузгала. Яу килеп җитәр-җитмәс үк, Анахуан кахан үз-үзенә кул сала, ә гаскәрен җитәкләргә тиеш улы бер төркем ишләре белән илен-халкын ташлап кача.

Әмма Бумын кахан яшь хатын белән озак яши алмый — ул, илхан титулы алып, 552 елда вафат була. Тауларга качкан Анахуанның улы да тик ятмый. Ул үз кырына төрки кавеменнән булган Кара Иссек ханны дәшә һәм аңа ил дилбегәсен тәкъдим итә. Тик күп тә үтми, Кара Иссек хан да үлеп китә. Ә тәхеткә утырырга тиешле Иссек ханның улын жужаннар кабул итмиләр, чөнки бу углан талаучылар санында йөргән була. Жужаннар тәхеткә Кара Иссек ханның кече улы Мәңгүк ханны күтәрәләр.

Жужаннар белән туганлашып киткәч, союз төзү максатыннан Мәңгүк хан тәүге кан кардәшләренә илчеләрен җибәрә — берләшергә тәкъдим итә. Канат асларына керергә теләмәгән кайбер кан кардәшләрен көч белән берләшмәгә керергә мәҗбүр итә. Әнә шулай 554 елда Мәңгүк хан башта кыргызларны, аннары кидан ыруларын һәм утыз татар кавемнәрен буйсындыра.

572 елда Мәңгүк хан үлә. Ил тәхетен аның улы Табахан били. Ошбу яшь хан Кытай императоры белән солых төзи. Солых төзелүгә үк төркиләр иленә Будда монахлары килеп төшәләр. Әнә шулай Кытай империясе белән солых төзегән төркиләр уңалар — 580 елларда ук инде аларның даны еракларга ирешә. Бу илнең сәүдәгәрләрен шул чорның Кытай тарихчылары күреп алалар һәм шул елдан тарихларына терки башлыйлар. Данга күмелгәч кенә Табахан хан үлеп китә. Төркиләр каханатының тәхетен Бумын каханның кече туганы Истеми били. Истеми кахан тәхеткә утыра-утыруга, көнбатышка таба яу кузгала. Тиз арада Каспий диңгезе буйларына килеп җитә. Күп тә үтми, төркиләр Идел елгасының уң як ярына чыгалар. Бу тарафларда җәйли башлау белән үк төркиләр аварларга яу йөриләр, ә курка калган аварлар көнбатышка таба кузгалалар. Аварлардан бушап калган җирләрне Истеми кахан үз кул астына ала. Һәм борынгы заманнардан ук Идел-Урал арасында көн күргән төрки халыкларны берләштерергә керешә. Берләштерүне тәмамлагач, аңа хәбәр ирештерәләр: эфталитлар Ефәк юлын япканнар. Аварларны буйсындырып вә куа барып җитә алмаган Истеми кахан табынга җыелган аксакалларына болай ди: «Аварлар кош түгел, минем кылычтан качарга теләп, һавага күтәрелә алмаслар, алар су төбенә качарга балыклар да түгел, алар җир адәмнәре; эфталитларны җиңгәч, мин аварларны да юк итәрмен, алар миннән качалмас».

Тарихта мәгълүм булганы шул: Истеми кахан эфталитларны җиңә, Ефәк юлы ыстаннарына үз кешеләрен куеп, Идел буена әйләнеп кайта. Һәм аварларга яу кузгалырга җыена башлый. Әмма аңа хәбәр ирешә, имеш, аварлар ерак киткәннәр, ул гынамы, авар каханы Византия императоры белән Иранга каршы сугышырга килешү төзеп ята икән. Аварларның империя белән берләшеп китүенә Истеми каханның кәефе кырыла. Әмма чарасыз калмый, үзенә аркадаш эзләргә керешә. Башта ул Ефәк юлында йөрүче бай Согдиан сәүдәгәрләре белән килешү төзи, аннары Дон елгасының өске тарафларында көн күргән көтрегурлар белән элемтәгә керә. Византия тарихчылары Төркснаф, Кытай тарихчылары Төнхан (Түрхан) дип язган төркиләрнең каханы Истеми империянең ярымколониясе булган Боспор дәүләтен яулый. Шуннан соң гына төрки халыкларының легендаларына каһарман булып кергән Истеми кахан, аркадашлыкка исәп тотып, илчеләрен шаһиншаһка җибәрә. Шаһиншаһ башкаласына юл Урта Азия халыклары аша уза. Бу вакытта Ефәк юлы Урта Азиядә көн күргән эфталитлар кулында. Борынгы Согда каласына җитәрәк, эфталитлар Истеми каханның шаһиншаһка юнәлгән кәрванын талыйлар, илчеләрен үтерәләр. Илчеләрдән бары тик бер елгыр егет кенә качып котыла һәм, иленә кайтып, булган хәлне Истеми каханга ирештерә. Истеми кахан ашыгыч рәвештә эфталитлар ханы Гатфарга илчеләрен җибәрә һәм аны катгый рәвештә кисәтә: «Төркиләр кәрванына баскынлык иткән һәм минем илчеләремне үтергән юлбасарларны миңа тотып бирәсең».

Эфталитлар ханы Истеми каханның кисәтүен кире кага. Бу хәбәр ирешүгә үк, Истеми кахан Гатфар хан җиренә таба яу кузгала, Урта Азиягә җитә, тиз арада Чәчә (бүгенге Ташкент) каласын ала, ә алдынгы атлы гаскәренә, Чирчек елгасын кичеп, Маймыр каласын алып туктарга куша. Эфталитларның төп көче Бохарага таба чигенә һәм шунда Истеми яугирләрен көтеп алырга була. Истеми кахан төп көче белән Бохарага таба юнәлә. Ләкин төркиләрнең якынлашуын күреп, Гатфар хан гаскәре Нәсибә тауларына таба юнәлә. Эфталитлар белән төркиләрнең очрашуы Нәсибә таулары итәгендә була. Тәмам көч-куәткә ия булган төркиләр тарафыннан эфталитлар җиңеләләр, гаскәриләрнең берише тауларга кача, күбесе, Гатфар ханнан ваз кичеп, Истеми кахан яугирләренә килеп кушыла.

Ефәк юлының иң күп өлешен кулына төшергән Истеми кахан дөнья илләре арасында сәяси яктан гына түгел, икътисади яктан да күзгә күренеп күтәрелә. Төркиләрнең бу җиңүен Кытай тарихчылары аеруча ассызыклап язалар. Шул елдан алып төркиләр Ефәк юлына ия булып китәләр һәм сәүдәгәрләрдән тамга-ясакны да Төрки каханлыгы җыя башлый. Әмма төркиләрнең бу уңышы белән Иран шаһиншаһы килешми. Ефәк юлы үз иле аша үткән ыстаннарда төркиләрнең сәүдәгәрләреннән икеләтә салым җыя башлый. Бу хәбәр тиз арада Истеми каханга ирешә. Истеми кахан Иран шаһиншаһы Хәсрәүгә илчеләрен җибәрә. Һәм шаһиншаһка шарт куя: «... минем сәүдәгәрләремнән икеләтә салым җыюны туктат!»

Тик Иран империясенең илбашы ниндидер ярымкүчмә төркиләрнең шарт куюын ошатмый һәм Истеми кахан илчеләренә «Сезнеңчә булмас!» дип кенә җавап бирә. Каханның илчеләре бернигә ирешә алмый әйләнеп кайталар. Һәм көне белән Истеми каханга шаһиншаһ әйткән сүзләрне ирештерәләр. Истеми кахан табын җыя һәм аксакалларына булган хәлләрне җиткерә. Табындагылар барысы да бер фикергә киләләр — кахан дипломатиясендә сыгылмалылык җитми, шаһиншаһ Хәсрәүгә тәҗрибәлерәк илчеләр җибәрергә кирәк. Илчеләргә өлкәнрәк кешеләрне сайлыйлар һәм аларны шаһиншаһка юллыйлар. Бу юлы инде илчеләр артыгы белән тыйнак

кыланалар, әмма горур шаһиншаһ Хәсрәү моны төркиләр бездән куркалар дип кабул итә, Истеми кахан илчеләренә мыскыллы сүзләр ташлый, сакчыларына төркиләрне сарайдан куып чыгарырга куша. Ул гынамы, шаһиншаһ сакчылары Истеми кахан илчеләрен ил чигенә кадәр озаталар.

Истеми каханга бердәнбер чара кала — сугыш.

Яу чыгуга, Истеми кахан юл өстендәге сәүдә калаларын кулга төшерү нияте белән уң кул гаскәрен Амударья елгасы аша кичеп чыгарга һәм уң як ярдан йөрергә боера. Ә үзе төп гаскәре белән туры Иранга юнәлә. Әмма V гасырда ук фарсылар күтәргән кирмән-каланы ала алмый, чигенергә мәҗбүр була.

Иленә кайту белән үк, Истеми кахан көнбатышка таба җәйли башлый, кулыннан ычкынган аварларны куып җитәргә тели.

571 елда төркиләр, ниһаять, тулысы белән диярлек Кавказны яулыйлар һәм Кара диңгез буйларындагы далага чыгалар.

Тарихта хакыйкать шулай ачыла бит ул. Табында катнашкан илчеләрнең берсе ике арада барган сөйләшүне сүзгә-сүз диярлек куен дәфтәренә теркәп бара. Менә нәрсә ди табында Истеми кахан Византия императоры илчеләренә: «Сезмени ул ун телдә сөйләшкән халыкны ун телдә алдаучы римләннәр! Без, төркиләр, дипломатиядә алдауның да, ялганның да ни икәнен белмибез. Мәгәр белеп торыгыз: минем аварларны яклаучы, колларымны минлекләүче, әмма үзе минем белән дустанә яшәргә телим диюче илбашыгызга әйтегез — мин аңардан моның ничек һәм кайчан үч алырга җаен табармын»,— ди.

Әнә шулай V гасыр башларында Алтай тарафларыннан кузгалган төркиләр кешелек ике меңенче елларга аяк басканда ук инде Урал-Идел буйларында төпләнеп калалар. Бирелә алар утрак көн күргән борынгы угро-фин халыклары белән туганлашып, берләшеп китәләр. Беренче гасыр башларында ук Алтай тарафларыннан бире килеп урнашкан татар-төркиләр аларга бик теләп кушылып киткән һәм Дулу ыруы исеме белән тарихка кереп калган төркиләр кавемен тагын да куәтләндереп җибәргәннәр.

Әмма күп тә тормый, 576 елда нәсел чыбык очы Аттила ханнан килгән Истеми кахан да үлә. Ил тәхетенә аның улы Кара Чуринны күтәрәләр.

Кадерле укучым, тарихка кереп калган янә бер мәгълүмат белән сине таныштырыйм әле. Русия тарихчылары, гадәттә, Кырымда көн күргән киммерәйләрне еш кына үз дошманнары итәләр. Әйтик, Рыбаков хезмәтләрендә еш кына киммерәйләр белән славяннарның (роксаланнарның) сугышканнары искәртелә. Ә менә киммерәйләр кемнәр булганнар дигәндә, борынгы тарихчы Прокопий «киммерәйләр болгарларның бабалары» дип яза.

Истеми каханның улы Кара Чурин тәҗрибәле сугышчы, оста укчы, елгыр сөңгече була. Ундүрт яшендә беленә кылыч тагуга ук, углан атасы белән яуларда катнаша һәм төмәнбаш булуга ирешә. Атасы үлгәч, төркиләр тәхетен биләгән Кара Чурин ике фронтка сугыш башлый — аварларны тәмам буйсындыруга ирешә һәм Византия империясенә сугыш игълан итә. Сугыш башлана һәм ул 683 елларга кадәр дәвам итә. Ниһаять, ике якның берсен сайларга дигән фикергә килгән Кара Чурин ярдәмче яучысы Бүрехан белән Дербент кирмәненә таба кузгала. Бу чорда бүгенге Дербент кальгасын Тимер капка дип атаганнар. Кала-кальганы Иран шаһиншаһы Хәсрәү күчмәләрне үз җирләренә уздырмас өчен күтәрткән була. Ул гынамы, кәрваннар Төньяк Кавказга бары тик шул кала аша гына үтә алганнар. Бу кала-кирмәнне заманында күчмәләрне Иран җирләренә уздырмас өчен күтәргән булалар. Кала-кальганың ныклыгына, мәһабәтлегенә әле булса сокланмый мөмкин түгел. Кальганың бөек дивары 20 метрдан артып киткән җирләр бар. Озынлыгы 40 километр тәшкил итә. Диварларга 30 саклау манарасы утыртылган. Көнчыгыш тарафтагы стена шактый тирәнгә, диңгезгә кертеп салынган. Әлбәттә, ил-империяләрне яуларга керешкән төркиләргә бу кала-кирмәнне алу җиңел булмагандыр. Ләкин Кара Чурин төркиләренә бирегә калаларда көн күргән кардәшләре хазарлар белән төрки болгарлары ярдәмгә киләләр. Менә кайчан тарихка беренче тапкыр «хазар» атамасы килеп керә. Гуннар заманыннан ук әүвәл далада җәйләгән, тора-бара утрак тормыш итә башлаган төрки гуннары — Каспий диңгезе буйларына туктап калган хазарлар ул. Моны археологик казылмалар алып барган мәшһүр галим Лев Николаевич Гумилев та үзенең «Открытие Хазарии» хезмәтендә раслый. Беркемгә дә буйсынмаган, бер генә ил-дәүләткә дә ясак-салым түләми яшәгән иреклe халык була хазарлар. Әнә шул яктан ярдәм килү белән Кара Чурин Тимер капканы ала һәм, далага чыгып, тиз арада Иран кул астындагы шактый яхшы ныгытылган Тифлис кальга-каласына җитә.

Тарихта Тифлис кальгасы турында мондый мәгълүмат сакланып калган. Төркиләр Тимер капканы алгач, фарсылар шаһиншаһы тәмам курка кала. Чөнки төркиләр чик буендагы фарсы гаскәрләрен бик тиз туздырып ташлыйлар. Исән калган фарсы түрәләре, шаһиншаһның вассаллары булган Тифлис кирмәненә кереп бикләнәләр. Шушында җиткәч, янә бер тарихи вакыйганы искәреп үтик әле: бу вакытта мәңгелек дошманнар булган Византия белән Иран империяләре арасында дәвамлы рәвештә сугыш бара. Ике империя арасында ил-җирләрне бүлешүдә беркайчан да сугыш туктамаган, орыш-сугышлар барышында төзелгән солыхлар да ике яктан да бик тиз бозылган һәм сугыш янә дәвам иткән. Кара Чуринның Дербент кальгасын алуын ишетүгә, Византия императоры Ираклий гаскәре белән Иран җирләренә таба кузгала, янәсе, төркиләргә ярдәмгә. Византиялеләр гаскәрен император Ираклий үзе җитәкләгән була. Кара Чурин белән император Ираклий сөйләшүләр алып баралар һәм нәтиҗәдә уртак бер фикергә киләләр — кальгага бергәләп һөҗүм итәргә. Һөҗүм башлана, әмма кальганың диварлары үтә биек булганга, ике як сугышчылары да диварларга күтәрелә алмыйлар. Бу хакта Византия тарихчылары болай дип язалар: «Ираклий үз кешеләрен кызганды, Кара Чурин үз кешеләрен». Искәреп үтим, «Хазарлар» хезмәтен язган галим М.Артамонов Кара Чуринны Тур-яу-хан дип яза. Ә аның ярдәмчесе Бүре-ханны Бүрешад дип. Бүре-хан шактый яшь кеше була, күрәсең. Император Ираклий аңа кызы Евдокияне кияүгә бирергә вәгъдә итә. Шушы

вакыйга йөзеннән Тифлис кальгасы кырында табын оештырыла. Император Ираклий булачак киявенә табындагы алтын-көмештән торган бар булган савыт-сабаны бүләк итә.

Шул мәлдә төркиләрнең төп илендә чуалышлар башлануы хакында хәбәр ирешә. Кара Чурин бер өлеш гаскәриләре белән төп ыстанга кайтып китә, сәргаскәр итеп Бүре-ханны калдыра. Император Ираклий исә, Бүре-хан кулыннан шактый гаскәри алып, Иранның эчке төбәкләренә юнәлә, анда ул төркиләр ярдәме белән зур җиңүләргә ирешә, хәтта Иранның башкаласына кадәр барып җитә яза. Ләкин, тылының шәрә калуын искәреп, кире борыла.

Тарихта билгеле булганы шул: тарихчы Мурад Аджи Ауропа халыкларының атлы гаскәриләрен төркиләр тәшкил иткәннәр, дип яза. Бу сүзләрдә, бәхәссез, хаклык бар. Меңнәрчә атлы гаскәриләрен Византия императорына калдырып киткән Бүре-ханның сугышчылары бу хакыйкатьнең чишмә башы гына була. Хәер, шул ук галим тарихчы Рим императорының төп атлы гаскәрен дә гуннар тәшкил иткән, дигән фикер әйтә. Хәтта Кушбугаз атлы гун яубашның Рим императоры кагорты полковнигы булуын тарихи язмаларга таянып раслый.

Кара Чурин киткәндә, мыскыл итү йөзеннән, кирмәндәге фарсылар стенага бик зур кабак чыгарып утырталар һәм кабакка каханның йөз кыяфәтен, сурәтен ясаган булалар. Бу аларның каханны мыскыл итүләре була. Кара Чурин бу хәлне онытмый.

Алдагы елга Кара Чурин янә Тифлискә яу килә. Кальга-каланы ала һәм былтыр аның сурәтен ясатып, стенага куйган түрәләрне сукырайтырга боера. Күп тә үтми, яуланган кала кырына Византия илчеләре килеп җитәләр. Алар артынннан олау-олау байлыклар төягән кәрван белән яшь кәләш килеп төшә — булачак ханбикә Евдокия. Ләкин ни чара кылмак кирәк, нәкъ кала-кирмәнне алганда, императорның кияве буласы батыр яубаш һәлак була. Император Ираклийның гүзәл кызы барлык байлыклары белән кире иленә таба борыла. Кызганыч, яшь йөрәкләр кавыша алмыйлар...

Фарсыларны җиңүгә ирешсәләр дә, төркиләр биредә калмыйлар, меңнәрчә әсирләр, таланган маллар белән кайтыр юлга чыгалар. Бу буладыр 630 елда.

Ә менә төркиләрнең төп ыстанында утырган Кара Чуринга ярдәмгә килгән хазарлар һәм төрки болгарлары каханы — Туран-хан, (искәреп үтим, фарсылар төркиләрне тураннар дип атаганнар, бу исем-атаманы «Шаһнамә» поэмасында Фирдәүси дә еш кабатлый) 651 елларда ук инде күрше-күлән халыкларны кул астына җыеп, Ил-Ватан төзи башлаган була. Көчәеп киткән бу дәүләтне ул көнчыгыш Ауропада беренчеләрдән булып дәүләт төзегән Кубрат хан мисалында тормышка ашыра. Дулу ыруыннан килгән Кубрат хан үз дәүләтен Византия императоры ярдәме белән төзегән булса, Туран-хан үз дәүләтен Кубрат хан дәүләтенең нигезенә утырта. Әнә шулай көнбатыш төркиләре оештырган дәүләт тулысы белән Ашин ыруыннан килгән кавемгә күчә. Ни генә булмасын, кулдан-кулга күчкән дәүләт төркиләр кулында кала. Дон буйлары, Таман ярымутравы төбәкләре, Кырым даласы (шуннан татарларга «кырым» сүзе кереп китә, ягъни минем кырым, минем җирем, минем биләмәм), Кара Болгар (төньяк Болгар сүзен аңлаткан, ягъни караңгы яктагы Болгарны), Идел буе Болгары, северяне, кривичи һ.б. хазар каханына ясак түләгәннәр. Византия императоры үз вакытында Кубрат ханның уллары белән дустанә яшәгәнгәме, империягә йөз тота башлаган Хазарстан белән дә араны өзәргә теләми. Бит Дулу һәм Ашин ыруларын нәкъ менә Туран-хан берләштерүгә ирешә. Заманында Кубрат хан уллары аталарына бердәм булырга, бер-берсенә ярдәм итәргә вәгъдә иткән булсалар да, тормыш аларны төрлесен төрле җирләргә тарата. Кубрат ханның баш улы Хазар каханына баш ия, ханның икенче улы үз кавеме белән өске Идел буйларына күчеп китә — кахан белән килешеп булса кирәк, башбирмәс Аспарух углан император Ираклийга барып сыенырга мәҗбүр була, әмма, империя җирләренә барыр юлда Ираклийның үлемен ишетеп, империягә ясак түләп яткан славяннар арасында туктап кала. Ханның Балкыр улы, янә кахан белән килешеп булса кирәк, Кавказ тарафларына юнәлә һәм үзенә Ил таба. Ә Кубрат ханның энесе Шамбат Русия елъязмасында төркиләрнең «кыел» сүзеннән Кий кушаматын алып, Батбай ханның улы кырына килеп, тәхетне били һәм, җиң сызганып, Киев каласы исеме белән тарихка кергән кальганы ныгытырга керешә. X гасырда Византия тәхетендә утырган тарихчы һәм император Константин Багрянородный бу хакта үз хезмәтенә болай дип язып куя: «Киев кальгасына нигезне Шамбат хан салды».

Хак, бу хәлгә икенче бер караш та бар. Чыгышы белән украин милләтеннән булган, бүген Англиядә яшәүче тарихчы Киев исеменә карата үз сүзен әйтә. Бу исем ясак җыючы Куя (Җыя)дан булырга тиеш, ди. Без исә Әскәр, Аскал, Аскольд исемнәреннән башка аерым түрә булып тарихка кереп киткән Дир исеменә дә тап булдык. Бактың исә, Дир хазар каханының Киевтәге наместнигы Җимсар атлы адәм булган икән, ягъни Киев халкыннан каханга җим җыючы. Бу кеше дә Шамбат хан нәселеннән килгән булса кирәк.

Ни чара кылмак кирәк, Киев каласында ант-славяннар һәм төрки болгарлары яшәгәнгә күрә, Хазарстан каханына аларны кул астына алу кыен булмагандыр, әлбәттә. Ә Җимсар-Дир каханга ясак җыйган, әлбәттә инде, бүгенге наместниклар кебек, ул һәрчак кала каханы янында булган. Русия елъязмасындагы баскынчы варяг Хельгның хәйлә белән бу ике түрәне дә үтерүенә бер дә шаккатасы түгел. Бит колдун варяг Хельгны бирегә Швеция колониясе итәргә көчле дружина белән Швеция тәхетендә утыручы Олаф король җибәрә. Баскынчы варяг Хельгның чынында кем булуын Русия тарихчылары бүгенге көнгә кадәр халыктан яшерәләр, Колдун кушаматын йөрткән варягны хәтта үз тарихларына Вещий Олег дип кертеп җибәрәләр. Вещий Олегның колдун йөзендә йөрүен, фәнни рәвештә тикшереп, «Открытие Хазарии» хезмәтендә Лев Николаевич Гумилев та, Швеция тарихчысы Андерс Стриннгольм да «Походы викингов» хезмәтендә раслый.

Инде, укучым, Ауропаның көнчыгыш тарафында тәмам империягә әверелеп киткән Хазарстанга күз ташлыйк әле, чөнки хазарлар безнең бабаларыбызга хәтта бик нык бәйле халык.

Ауропаның көнчыгыш төбәкләрендә төркиләр Хазар каханатын төзеп яткανда, 662 елда Мөхәммәд пәйгамбәрнең тарафдарлары Әрмәнстанны яулыйлар. Бу чорларда кылыч белән дөнья халыкларын иманга китерү гарәпләрнең төп сәяси гамәлләренә әверелә.

Хак, гарәпләр ислам динен таратуны ике юл белән алып баралар: кәнфит һәм кылыч белән. Мөхәммәд пәйгамбәр вафат булгач (632), гарәп миссионерлары Өммәиләр хәлифәтен төзиләр.

Нәкъ шул чорларда Хазар каханаты да көчәеп китә, чикләрен киңәйтә, сәүдә юлларын үз кулында тота. Төрки халыклары арасында хазарлар беренче урынга чыгалар. Бирегә бик күп төрки кавемнәре күчеп утыралар. Идел елгасының уң ягын төрки болгарлары биләсәләр, елганың сул ягын тарихчылар кара хазарлар дип язган татарлар билиләр. Әнә яһүд раввалары, римләннәр тарафыннан илләренннән куылганнан соң, башта Иранга барып оялаган булсалар, шаһиншаһ та аларны үз иленнән куа башлагач, яһүдләр бар диннәргә дә битараф булган илгә — Хазарстанга килеп урнаша башлыйлар. Бу хәлгә аптырабрак калган кахан табын җыя һәм аксакалларына мөрәҗәгать итә: «Нишлибез?..» Яһүдләрнең сәүдәгәрләре бу чорда күп кенә сәүдә юлларын үз кулларында тоткан булалар, тарихчылар язганча, биш телдә сөйләшә алганнар. Коллар белән сәүдә итүдә дә бу халык АуроАзиядә беренче урынны тоткан. Шуларның барысын да исәпкә алып булса кирәк, табынның хөрмәткә ия аксакалы тора да болай ди: «Кадерле каханым, кабул итик Хода тарафыннан рәнҗетелгән бу халыкны, чөнки яһүдләр китаплы халык. Коллар сату-алуда да алар өстенлек итәләр. Гүзәл кызларга да мохтаҗлык кичермәбез...»

Әлбәттә инде аксакалның сүзе аларга ошаган һәм табын туган илләренә яһүдләрне кабул итү турында әмер чыгарган. Әйтергә кирәк, кахан сараена кызлар китерүне дә яһүд сәүдәгәрләре үз кулларына алганнар. Башта кахан сараена чибәр яһүд кызларын уздырганнар, алардан туган балаларга Мишә һәм Талмут китапларыннан белем биргәннәр.

Һәм бу мәктәптә бары тик яһүдә хатыннардан туган балалар гына укыганнар. Тора-бара бай яһүд сәүдәгәрләре кызларын төрки гаскәрбашларына, әмирләргә, бәкләргә, тарханнарга кияүгә бирәләр, ә алардан туган балаларны сарай каршындагы мәктәптә укытканнар. Яһүдләрнең нәсел тамыры анадан килә һәм кахан сараенда да бу кагыйдә-тәртип тиз арада үз көченә керә. Нәтиҗәдә, күп тә үтми, төркиле Булан кахан яһүдләр динен кабул итә.

Ни генә булмасын, VIII–IX гасырларда Хазарстан каханаты көнчыгыш Ауропада иң бай илләрнең берсенә әверелә. Ләкин бу илгә дә бик тиз көндәшләр табыла. Аларның беренчесе — Өммәиләр хәлифәте. 710 елда илләрне яулый-яулый, халыкларны буйсындыра-буйсындыра, гарәпләр Тимер капкага (бүгенге Дербент шәһәре) кадәр килеп җитәләр. Бу төбәкне кулында тоткан хазарлар белән нигездә гарәп мөселманнары арасында канлы сугыш башлана. Кальга-ныгытма берничә тапкыр кулдан-кулга күчә, ике як та бик күп югалтуларга дучар ителә. Ниһаять, 737 елда гарәпләр Тимер капканы алуга ирешәләр.

750 елларда инде Өммәиләр династиясен Габбасилар нәселе алыштыра. Габбасилар, ил башына килә-килүгә үк, башкалалары итеп Багдадны сайлыйлар. Габбасилар да, Өммәиләр кебек, Хазарстан каханатын беренчел дошманнары итеп күрәләр, күрәсең. Иң әүвәл яу кузгалган гарәпләрнең саруларын биредә ил башында утырган раввалар кайната булса кирәк. Иудаизм диненең дөньяга таралуын истә тотып, хәлиф Мансур (754–775) Кавказ тарафындагы гарәп сәүдәгәре Гаязетдингә Хазарстан каханының кызына өйләнергә киңәш итә. Шул хакта сөйләшергә дип, хәлиф Гаязетдингә илчеләрен җибәрә — әлбәттә инде бүләкләрсез дә булмагандыр. Баһадир кахан кызын бай гарәп сәүдәгәре Гаязетдингә кияүгә бирергә риза була. Күп хатыннар тоткан каханның кызы бер генә булмаган, әлбәттә. Бай гарәп сәүдәгәренә иң чибәр, укымышлы гүзәлне сайлаганнар дип уйларга кирәк. Әйе, кахан кызын бирергә риза була, вәләкин хәлифтән бирнәгә 100 мең дирһәм таләп итә. Хәлиф бәһа белән килешә. Әнә шулай ике арада яучы-димчеләр йөри башлыйлар. Иң гаҗәбе шулдыр: гүзәл затны каханның ун мең затлы зыялылары озата бара. Шул ук вакытта бирнә йөзендә кыз ягыннан 10 мең дөя, 10 мең куй куып барыла. Кызны да нык саклыйлар — гүзәл кәләшне бер мең карачы озата. Моның өстенә бирнә йөзендә түбәсе көмеш тәңкәләр белән кадакланган 10 мең арба юллана. Арбаларның эчләре парчалы чүпрәк һәм кеш тиреләре белән җиһазландырылган була. Әлбәттә инде яшь кәләшкә егермегә якын арбага төягән алтын-көмеш савыт-сабалар, таз-комганнар, чиләк-көянтәләр дә бүләк ителгән.

Ни хикмәт, әнә шул олы кәрванны һәм гүзәл кәләшне башта калага кертмиләр. Мөселман миссионерлары кәләшне ислам диненә күндерәләр. Һәм кала кырында корылган чатырда гарәп миссионерлары яшь кәләшне мөслимә итәләр. Илаһи тантанадан соң гына гүзәл затны озата килгән кәрван калага үтә алган. Шул чиккә җитеп зурдан кубып олылауга вә хөрмәт итүгәме, Хода үзе көнләшепме, кахан кызы ир канаты Гаязетдингә бер-бер артлы ике малай таба, әмма көннәрдән бер көнне алар өчесе дә берьюлы якты дөньядан китәләр. Бу хәбәр тиз арада Хазарстан каханына ирешә һәм кайнар канлы кахан ике оныгын һәм кызын агулап үтерделәр дип уйлый (ә ул шулай булган да булса кирәк), һәм тиз арада гаскәр туплый, һәм 762 елда гарәпләргә таба яу кузгала. Беренче орышта ук хазарлар гарәп сәрдары Муса Ибн Кәабәнең сугышчыларын туздырып ташлыйлар һәм, 50 мең гарәп сугышчысын, кала түрәләрен әсир итеп, илләренә әйләнеп кайталар.

764 елда каханның гаскәрбашы Әстерхан, янә кайчандыр гарәпләр яулаган җирләрне кайтару нияте белән, Әрмәнстан, Гөрҗестан җирләренә яу кузгала. Тиз арада биредә тупланган хәлиф гарнизонын туздыра, гарәп миссионерларын, мулла-мунтагайларын илләренә куа. Ләкин хазарлар бу җирләрдән китүгә, гарәпләр янә бу җирләрне вә халыкларны үз канатлары астына алалар. 798 елның азакларында хазарлар янә ошбу илләргә таба яу кузгалалар һәм янә бирегә килеп оялаган гарәпләрне илләренә — ком сахраларына качарга мәҗбүр итәләр. Шушы яулар ук әйтеп тора — VIII гасыр азакларында һәм IX йөзләр башында Хазарстан каханаты үз көчендә була әле.

Гарәпләр белән сугышып ятса да, Хазарстан каханы Ауропага таба кузгалган маҗарларга дәүләт оештыруда да актив катнаша. Борынгы маҗарлар Урал таулары итәгендә көн күргән төрки-татарлар белән Аттила чорларына

кадәр үк инде дустанә-тату яшәп яткан булалар. VIII гасыр азакларында Урал тавы итәкләрендә көн күргән бөҗәнәкләр мажарларны туктаган җирләреннән кузгалырга мәҗбүр итәләр. Хазарстан каханы бу хәлдә дә арадашлык ролен үти, мажарларга көнбатышка таба күчеп китәргә ярдәм итә һәм аларга Днепр белән Дунай арасыннан җир бирә. Бу илне тарихчылар Атылкүз дип язалар. Мажарлар арасында илбашы турында бәхәс чыккач, кахан белән килешеп, Идел буе Болгары ханы Алмас мажарларга илбашы йөзендә улы Арпатны биреп җибәрә. Бик ихтимал, Арпат Алмас ханның мажар хатыныннан туган угланы булгандыр. Арпат җитәкчелегендә мажарлар Дунай-Тисса елгалары арасында үзләренә дәүләт оештыралар. Соңра бу дәүләтне Аурупа тарихчылары Венгрия дип яза башлыйлар.

Русия тарихчылары Вещий Олегны, берсеннән-берсе арттыра-арттыра, үзләренең каһарманнары итәләр. Хәтта олуг исемгә лаек Русия тарихчысы С.М.Соловьев та Вещий Олег хакында: «... он был не храбрый воитель, а хитрый политик и сборщик дани с беззащитных славянских племен»,— дип язарга мәҗбүр була.

Русия тарихчыларының кайберләре күккә чөеп мактаган Хельг-Олег бер дә киялеләр мәнфәгатен кайгыртмаган, киресенчә, алардан җыйган ясакны Швед короленә озата барган. Менә ни өчен Вещий Олегны Хазарстан каханы Киевтән куа. Русларга бу узурпатор варягка гасырлар буена мәдхия укыйсы түгел, киресенчә, Киев каханын һәм аның ярдәмчесен үтергән өчен каһәр укыйсы иде дә... Ил түренә Русия тарихын аякландырып җибәргән һәм норман теориясенә нигез салган Владимир Мономах кенәз килә. Ә ул Швед короле кызына өйләнгән кеше. Король кызыннан туган Мстислав исәйгәч, елъязманы үз кулы белән редакцияли. Бары тик шул гына.

Үзенең шактый саллы «Төрки-татар рухи мәдәнияты тарихы» хезмәтендә татар галиме Гамир Дәүләтшин «Кемнәр соң алар хазарлар, каян килеп чыкканнар, бабалары кемнәр?» дигән сорауны куя да үзе үк болай ди: «Иосиф Яфәт улы Тогарманның (Төрекнең) Савир, Болгар белән бергә Хазар каханның ун улының берседер. Бу легендар хәбәр булса да, хазарларның төркилеге һәм аларның болгар-суарлар белән кардәшлеге фәнни нәтиҗәләргә дә туры килә. Аларның көнчыгыш Ауропага килеп чыгулары Гун һәм Төрки каханлыклары белән бәйле булуы һич кенә дә шик тудырмый...»

Хак әйтә яшь галим Гамирҗан Дәүләтшин, теге йә бу биләмәләр түрәләрен хазарлар гарәпләр кебек «әмир» дип атамаганнар, ә төркиләрчә «тархан» дигәннәр. Төньяк Кавказ, Көньяк Урал, Көнчыгыш Кырым киңлекләре, Таман ярымутравы, Идел, Дон, Азов диңгезе буйлары Хазарстан җирләренә кергәннәр һәм бу төбәкләрдә утырган илбашларын тарханнар дип атаганнар. Тарханнар исә Хазарстан каханына бәйле түрәләр булалар. (Хәер, бүгенге көндә район дип аталган биләмәләрне тарханлык дип атау ана телебезгә ятышлырак булыр иде кебек миңа.) Хазарстанның башкаласы Итил була. Башкала Идел елгасының тамагына якын утрауда — киңлеге километрга якын, озынлыгы 8–9 километрга җиткән җиргә урнашкан. Гарәп тарихчылары Ай-Балда дип атаган бу башкала шул чорларда сәүдә юлының үзәгендә утырган дияргә була. Саркельда (Сарыкала), Русия тарихчылары Белая Вежа дип язган кала-кальгада, нигездә, болгар-аланнар яшәгәннәр, Русия тарихчылары расларга тырышканча, бер дә славяннар түгел. Сарыкала аша Хазарстан сәүдәгәрләре үз тауарларын Ауропага чыгарганнар.

Тарихта янә мәгълүм булганы шул, Хазарстан каханлыгында диннәрне тыю кебек яман чаралар үткәрелмәгән. Каханат калаларында мәчетләр белән бергә синагогалар, чиркәүләр булуы мәгълүм. Ил тәхетен Болан (Булан) кахан били. Нә ислам, нә христиан диненә бәйле булмас өчен яһүдләр динен кабул иткән Булан кахан, төрле сәбәпләр табып, ил-калалардан мөселманнарны һәм христианнарны, шул исәптән мәҗүсиләрне дә иленнән куарга керешә. Бу хәбәр тиз арада Иранда, Византиядә яшәгән яһүд раввваларына барып ирешә һәм алар дәвамлы рәвештә оя-оя Хазарстанга күчеп килә башлыйлар. Булан каханнан соң яһүдә хатыннан туган углан ил тәхетенә утыргач, аның атасы төрки булуына раввалар әллә ни игътибар итмиләр, чөнки яһүдләрдә борын-борын заманнардан ук нәсел җебе анадан килә торган була. Күчеп килгән яһүдләр белән җирле халык тату яши. Сәүдәгә һәм телләр өйрәнүгә хирыс халык буларак, яһүдләр тиз арада Хазарстанның төп халкын тәшкил иткән төркиләр белән туганлашып китәләр. Хазарстан калаларында байлык, муллык — сәүдә гөрләп бара. Тора-бара яһүд сәүдәгәрләре китергән керем кахан дәүләте өчен төп байлыкка әверелә. Ил-халыкларда бүгенге Америка доллары кебек хәлифә дирһәмнәре йөрсә дә, Хазарстан үзе дә Идел буе Болгарында акча суктыра башлый. X гасыр башларында Габбасилар династиясе инде таркалуга йөз тота. Бик борынгы заманнардан ук ил-империя булып яшәгән фарсылар төшенкелеккә биреләләр. Иран, империя буларак, шактый күләмдә җирләрен генә түгел, үз кулында тоткан сәүдә юлларын да югалта. Ил-дәүләткә гасырлар буена мул керем китереп торган Ефәк юлы тулысы белән диярлек Хазарстан сәүдәгәрләре кулына күчә. Нәтиҗәдә яһүд сәүдәгәрләре Азия халкын Аурупа белән бәйләүче бердәнбер тауар йөртүчеләр булып калалар. Ауропага якынрак булсын өчен, Йосыф кахан Донец елгасы ярына Саркель каласын күтәртә. Әлбәттә, сәүдә итүгә җайлаштырып салынган каланы Византия осталары күтәрәләр. Кирмән-кала дүртпочмаклап салына. Ә Византия императоры кешеләре вә инженерлары кальганы үтә начар сыйфатлы итеп күтәрәләр. Дүрт метр биеклектәге диварның нигезе булмый диярлек, күз буяу өчен, нигезгә юка ташлар гына түшиләр.

Бу чорның иң кыйммәтле тауары буладыр — ефәк. Яһүд сәүдәгәрләре ефәкне Кытайдан алып кайталар һәм Ауропага илтеп саталар. Ефәк һәрчак алтынга сатылган. Аурупа һәм Русия тарихчылары төркиләрне күчмә халыклар булганнар, дип язалар. Ләкин болгар-хазар ханнары бик борын заманнардан ук калаларда яшәгәннәр, бик сирәкләре генә эссе җәй көннәрендә хозурланырга далага һәм болын-тугайларга җәйләүгә чыкканнар. Русия тарихчылары бүгенге көнгә кадәр Идел буе төркиләрен вә хәтта бүгенге көнгә кадәр Әстерхан төбәкләрендә яшәгән татарларны күчмә яшәгән кыпчаклар белән бутыйлар. Аурупа халыкларының теленә һәм тарихына безнең бабаларыбыз гуннар исеме белән кереп киткәннәр. Әнә шул халык, кай тарафларда гына туктамасыннар, биләгән

җирләрендә кала-салалар, кирмәннәр күтәргәннәр. Бабаларыбызның бу гамәлләре тарихи язмалар белән дә раслана.

Әйе, безнең борынгы бабаларыбыз, кайларда гына дөнья көтмәсеннәр, кала-салалар күтәргәннәр һәм бераллалыкка йөз тоткан Тәңре диннәренә тугры калганнар. Искәреп үтим, укучым, төрки бабаларыбыз бүген дә телебездән төшмәгән Тәңре диненә 6 мең еллар буена табынганнар. Тәңре ул — бераллалык, күк-кояшка табынуны аңлата. Хәер, җир шарындагы тереклек, бөҗәгеннән алып адәми затына кадәр, күк-кояштан тормыймыни! Шуның өчен төрки халкының рухына ислам динендәге бердәнбер аллалык әллә ни зыян китермәгән. Илләрдән илләргә йөрүче яһүдләрнең бай сәүдәгәрләре ханнарга, тархан-бәкләргә затлы әйберләр бүләк иткәннәр, ә Хазарстан түрәләре сәүдә юлларында тынычлык булдырганнар. Нәкъ шул чорларда төрки түрәләренең күбесе яһүдә кызларга өйләнгәннәр — моның хак булуын татарлар арасында бүген дә Ягудин фамилияле гаиләләрнең, Җәһүдә исемле кызларның күп булуы үзе үк раслый.

Шуңа карамастан, кахан сараен кулларында тоткан раввалар катнаш никахтан туган балаларны, үз араларына алмыйча, шул ук вакытта артык читләштермичә дә, «караимнар» дип йөргәннәр, ягъни кара имгәкләр. Вәләкин бу халык төрки телдә сөйләшкән һәм тулы хокуклы хазар гражданины булган, шул исәптән, бүген тулы канлы автономия хокукы алып, Молдавиядә көн күрүче кан кардәшләребез гагаузлар да.

Әмма ил-дөньялар тик тормый.

802 елда патрикий Никифор Византия империясе тәхетенә утыра. Шул ук елда гарәпле Харун әр-Рәшид үзенең иң якын ишләрен җәзалый.

803 елда көтмәгәндә Хазарстан тәхетенә яһүд Убәдәй утыра. Әнисе яһүдә булганга, сарай равваларыннан белем ала. Нәкъ шул кахан яһүдләр динен дәүләт дине итеп игълан итә. Тарихчыларга ышансак, Убәдәй кахан зыялы вә укымышлы кеше була, гәрчә яһүд сәүдәгәрләрен үтә якын итсә дә, калган халыкларны да читләми. Бит бу чорда Хазарстанда уннарча милләт вәкиле гомер иткән. Һәм аларның күбесе мөселманнар, христианнар, мәҗүсиләр булганнар. Шуңа күрә шул чорның тарихчылары бу кахан хакында: «Ул гадел хаким, тугры кеше иде. Ул илне ныгытты, мәктәпләр ачты, синагогалар күтәрде һәм Исраилдән мөгаллимнәр, раввалар китертте һәм, аларга алтын-көмеш белән түләп, хезмәтләрен югары бәяләде. Аңа раввалар 24 изге Мишнә, Талмуд китапларындагы кануннар турында аңлаттылар, гыйбадәт кылу тәртипләрен өйрәттеләр. Убәдәй кахан Алладан курыкты, борынгыдан килгән кануннарны саклады һәм ата-бабаларның васыятьләрен зурлады, үрнәк итеп алды».

Хазарстанда хакимият алышудан иң әүвәл яһүдләр оталар, шул ук вакытта Ашин ыруыннан килгән төркиләрне дә хөрмәт итәләр, чөнки төркиләр үзләре дә диннәргә сизелерлек тыенкы караганнар. Ә сарай равваларына йөзе белән борылган Убәдәй кахан бар яктан да ота. Күп хатыннар тоткан кахан үзе генә түгел, төрки түрәләре дә, бәкләр, меңбашлар, йөзбашлар, тарханнар да өчәр-дүртәр хатын белән яшиләр һәм бу хәл Хазарстан дәүләте өчен гадәти гамәл булып китә. Нәкъ шул чорларда Идел буеның сул як ярында көн күргән татарларга «Урыс баеса, чиркәү сала, татар баеса, хатын ала» мәкале кереп китә. Әлбәттә, югарыда әйткәнебезчә, раввалар бары тик яһүдә хатыннардан туган балаларны гына сарай мәктәпләренә урнаштырганнар. Анда исә бу балалар Тора, Талмуд китапларыннан белем алганнар. Ләкин төркиләрнең борынгы династияләрен тәшкил иткән, Ашин ыруына кадәр шушы төбәкләрдә көн күргән татарлар һәм төрки болгарлары күп нәрсәдән мәхрүм ителгәннәр. Шул сәбәпле алар тарафыннан баш күтәрүләр дә булгалый. Кахан аларны аяусыз бастыра, әмма соңыннан ташламалар ясарга мәҗбүр була. Әнә шулай Хазарстанда сиздерми генә IX гасыр башларында ук инде фиркаләргә оешкан төркемнәр барлыкка килә. Төркиләр яһүдләрне балалар белән куандырсалар, яһүдләр аларның балаларын яһүд итүләре белән кинәнгәннәр, гәрчә һәммәсе дә төрки телдә сөйләшсәләр дә. Яһүд раввалары, үзләрен Аллаһы сайлаган халыкка санап, дәүләт өскормасын biләп торганнар. Тарихчылар кара хазарлар дип язган татарлар да кул кушырып утырмыйлар, алар күрше-шабра яшәгән маҗарлар, Идел буе төрки болгарлары белән кушылалар, бу чарада яманлык күреп, сарай раввалары илдән мөселманнарны һәм христианнарны куарга керешәләр. Әнә шулай X гасырда Хазарстанда гражданнар сугышы башлана. Бу сугыш хакында Византия императоры Константин Багрянородный үз хезмәтенә болай дип язып куя: «Хакимият халыктан аерыла башлагач, хазарлар үзара сугыша башладылар. Үзара сугышта хакимият өстен чыкты. Баш күтәргән гади халык кылычтан уздырылды, ә беришләре маҗарлар белән Атилькүзгә качтылар». Искәреп үтим, укучым, бүгенге Русиядә дә дистәләрчә еллар инде елдан-ел хакимият халыктан ераклаша бара.

Тик бит илдә нинди генә сугышлар булмасын, хакимият башында торучы раввалар үзләре дә, балалары да кылыч тотып сугышмаганнар, гадәттә, моның өчен сугышчан бәҗәнәкләрне яллаганнар. Яһүд раввалары бу сугышка нокта кую өчен әүвәл ялланган бәҗәнәкләрне маҗарлар өстенә җибәрәләр. Ә инде күршеләре угызлар бу хәлгә канәгатьсезлек белдергәч, алар белән солых төзиләр. Әмма тарих арбасы яһүд раввалары теләгәнчә генә әйләнми, гәрчә яһүдләр Аллаһы сайлаган милләт булсалар да; әйтик, 889 елда угызлар бәҗәнәкләрне Днепр елгасына кадәр куа баралар. Бу чарага кахан угызларга мулдан акча түләргә вәгъдә итә. Угызлар хәтта Киевкә кадәр барып җитәләр. Әнә шул елда киялеләр, аларны беренче тапкыр күреп, елъязмаларына теркиләр. Бу буладыр 915 елда.

Әмма угызлар раввалар белән араны бик тиз өзәләр. Яһүд раввалары тиз арада Дала халыкларыннан 7 мең сугышчы яллыйлар. Бу хакта гарәп тарихчысы Әл-Масуди дә искәреп үтә. Әмма бу вакытта Хазарстан түрәләре башка ил-халыкларын яулаудан һәм аларга ясак салудан баш тарткан булалар инде. Һәр империя кебек, раввалар ничекләр булса да җыйган ил-халыкларны саклап калырга керешәләр. Кул астындагы халыкларның беришенә ташламалар ясыйлар, беришенең җиренә сугышчыларын җибәрәләр. Куркыту өчен. Хәер, бу адым вә алым бүгенге көнгә кадәр империяләр сәясәтендә беренче урында тора. Ялланган сугышчылар, сәүдә юлларын саклау

белән бергә, яуланган илләрдә тәртип сакларга да тиеш булалар. Әлбәттә, 7 мең сугышчысы белән генә әллә ни кыра алмасын яхшы белгән, күрәсең, кахан. Шуңа күрә бу чара да каханга тынычлык китермәгән. Мисал итеп Багдад хәлифәте көч-куәтен күрсәтергә була. Хәлифәттә 70 мең ялланган сугышчы хезмәт иткән һәм хәлиф аларга елына 2 миллион дирһәм түләп торырга мәҗбүр булган. Сугышчылары хәлифнекеннән аз булуына карамастан, Хазарстан гаскәриләренә кахан үтә каты шарт куйган: меңбаш яисә йөзбаш әмерен үтәмәгән яисә сугыш кырын ташлап киткән сугышчы үлем җәзасына тартылган. Әмма яһүдләргә яки яһүдәләрдән туган угланнарга кахан монда да ташлама ясаган: сугыш кырын ташлап качканда да аларны җәзага тартмаганнар.

Ни генә булмасын, Хазарстан каханаты бу чорда әле үз көчендә була. Идел-Урал, Дон елгаларының түбән якларын үз кулында тоткан, бу чорда каханат җирләрендә зур-зур базаркалалы шәһәрләр калкып чыккан. Илдән илгә, калалардан калага кәрваннар йөреп торган. Хазар каханаты, нигездә, сәүдәдән кергән табыш исәбенә яшәгән. Бу хакта Ибн Хәүкәл болай дип язып калдырган: «Хазарлар бернәрсә дә җитештермиләр, чит илләргә кеше кызыгырлык бернинди тауар да чыгармыйлар, бар булган тауарлары — балык җилеме». Хак, бүген Русия исә чит илләргә нефть, газ, камил сугыш кораллары белән бергә Җир-Анабыз, су-елгаларыбыз вә диңгезләребез биргән башка тауарлар сата һәм шуның исәбенә көн күреп ята. Шуннан соң ничек инде әйтмисең, бүгенге Русия борынгы Хазарстан империясе язмышын сүзгә-сүз вә гамәлгә-гамәл кабатламый, дип.

Баштагы мәлдә яһүд сәүдәгәрләре дәүләткә коллар сатудан яхшы гына керем җыйганнар, әмма аларның бу гөнаһлы шөгыленә мөселманнар чик куялар — мөселманнарны, ягъни ислам динендәге адәми затны кол итеп сатарга ярамый, мөселман бары тик Аллаһы колы гына була ала, дигән пәйгамбәрнең чакыруыннан чыгып эш итәләр. Хәер, Аллаһы илчесе Мөхәммәд пәйгамбәр чакыруы чорына күрә дөнья халкын коллыктан азат итүгә йөз тоткан. Ислам диненең иң изге гамәлләреннән берсе булган бу. Бит ошбу дин коллыкка чик куярга чакыра, мөселманнар Мөхәммәд пәйгамбәрнең: «Һәр адәм баласы бары тик Аллаһы колы гына була ала»,— дигән чакыруыннан чыгып эш итә башлыйлар. Бу инде чорына һәм дәверенә күрә большевиклар идеологы Карл Маркcның: «Пролетарии всех стран, соединяйтесь!»— дигән чакыруыннан һич тә ким булмый. Әнә шулай әкренләп яһүд сәүдәгәрләре өстенлекләрен югалталар, вассал йөзендә каханатка кергән Кара Болгар — Киев Русе, Идел буе Болгары, Таман ярымутравында көн күргән төрки болгарлары халыктан җыйган салымнарын империягә җибәрми башлыйлар. Ә бит каханның сарай-калаларын, нигездә, мөселман сугышчылары саклаган. Каханның төп сараен 4 мең гаскәри караган. Күренекле татар галиме, нумизмат фәне белгече Әзһәр Мөхәммәдиев раславынча, гарәп сәрдаре Маслама каханны җиңгәннән соң, җиңелгән кахан 737 елда ислам динен кабул итәргә мәҗбүр ителә һәм, шул чордан башлап, Хазарстанда гарәп шрифты белән суктырылган акча-дирһәмнәр йөрешкә кереп китә. Ә инде Хазарстан каханы ислам динен кабул иткәннән соң, кахан сараена кереп оялаган яһүд раввалары да, баштарак югалып калсалар да, бик тиз аңнарына киләләр, беришләре ислам диненә күчеп, шул диндәге илләргә күчеп китәләр һәм ханнар сараенда хезмәт итә башлыйлар, беришләре исә, бигрәк тә раввалары үзләре дә сизми, каханатны таркатырга керешәләр. Иң әүвәл алар үзләре империя дәрәҗәсенә күтәргән каханат өстенә, алтын таулар вәгъдә итеп, Скандинавия викингларын дәшәләр. Викинг-варяглар X гасырда тоташ еллар буена Идел буе халыкларын вә илләрен һәм Хазарстанны ел саен диярлек таларга килә башлыйлар. Бу хакта XIX гасыр тарихчысы Швеция галиме Андрес Стриннгольм үзенең «Походы викингов» хезмәтендә аеруча тәфсилләп яза.

Иң сәере шулдыр, Хазарстан каханатының тарихта тоткан урынын кимсетеп күрсәтү өчен, Русия галиме шовинист Б.А.Рыбаков VI гасырда ук дәүләт оештырган һәм утрак гомер иткән хазарларны үз хезмәтендә күчмә халык итеп яза һәм бу ил-дәүләтне калмыклар даласына илтеп утырта. Панславянизм томаныннан соңгы көненә кадәр арына алмаган галим хазарларны күчмәләр итеп кенә калмый, аларга урта гасыр тарихында, гомумән, урын булырга тиеш түгел, дип язып чыга.

Дөньяның танылган тарихчылары исә үз хезмәтләрендә Хазарстан каханатын Аттила хан үлеменнән соң Ил-Далаларына кайтып урнашкан төркиләрнең бер кавеме дигән фикер уздыралар. Түбән Дон буйларына, Таман ярымутравына кайтып урнашкан төрки-болгар кавеме дә гуннарның бер ыруы була. VII гасырда бабаларыбыз төзегән дәүләт тә шуларның берсе — Кубрат хан дәүләте аларның дәвамы дип танырга кирәк. Һәм ул шулай була да, гәрчә бу ике халык, бертуган булу белән бергә, бер телдә сөйләшсәләр дә һәм ары таба теге йә бу сәбәпләр аркасында үзара тынышмый яшәсәләр дә.

Хазарстан каханаты таркала башлаганнан соң, көнчыгыш Аурупа халыклары ике зур фиркагә аерылалар. Беренчеләре ислам дине байрагын күтәреп чыксалар, икенчеләре христиан дине аша тарихка керәләр. Яһүдләр исә һәр чордагы кебек ике арада тулганалар, тирәнрәк суны эзләгән балык кебек, баерак, куәтлерәк, сәүдәдә керемлерәк илләргә барып урнашалар. Аларның төп максатлары бер була: «Сезнең дошманнарыгызның дошманнары — безнең дуслар» дигән фәлсәфә белән төрле илләргә таралып, дөнья көтә башлыйлар. Әнә шулай 300 елга якын көнчыгыш Аурупа халыкларына ия вә түрә булып торган хазарлар иле тавыш-тынсыз гына дөнья арбасыннан төшеп калуга таба йөз тота башлый. Әмма Хазарстан каханаты үз көчендә була әле. Хазарларның соңгы башкаласында — Ай-Балдада күпсанлы мунчалар, базар мәйданнары, мәчет, синагога, чиркәүләр булган. Әнә шул Ил X гасыр азакларына таба җимерелүгә таба янә бер адым ясый.

Ә тарих дәвам итә.

Мәгълүм булганы шулдыр, яһүд раввалары Хазарстан халкы белән 150 елга якын идарә итәләр. Алар инде Рим-Византия һәм Иранда бабалары кичергән фаҗигаләрне онытканнар, Хазарстанда үзләренә бер Иерусалим корып яткан булалар. Тарихи хакыйкатьтән чыгып караганда, татар бәкләренә таянып, Хазарстанда гүя оҗмах төзиләр, вәләкин үзләре үк шушы оҗмахны җимерүдә дә актив катнашалар. Ни гаҗәп, тарихта булган хәлләрне бозып, Русия тарихчылары Киев Русе Хазарстанны IX гасырда ук буйсындырды, дип язалар.

Асылда исә болай була.

Бу чорда, ягъни X гасырда, Киев Русенең Хазарстан каханына ясак түләп ятуы хакында Американың Кембридж югары уку йортында бер хат-документ сакланып калган. Тарихчылар раславынча, документ X гасыр азакларында язылган. Ә X гасыр башында тәхеттә утырган Булан каханны яһүд Убәдәй алыштыра, Убәдәйдән соң ил тәхетенә Йосыф кахан килә. Нәкъ шул кахан утырган көртләр хәлифе Габдрахман III сараенда хезмәттә булган Хасдай Ибн Шафрут сәүдәгәр илче Исак бен-Натан аша Йосыф каханга хат юллый. Һәм Йосыф кахан аңа Хазарстанда булган хәлләр турында яза һәм аннан җавап хаты көтеп кала. Йосыф кахан исә аңа җавап хаты яза. Бу документлар барысы да безнең бабаларыбызга кагылганга, кайбер юлларга игътибар итик әле: «... буртас, болгар, арис, чирмеш, венед, сувар, славян һ.б.— алар барысы да далаларда, ныгытылган калаларда яшиләр һәм барысы да миңа салым түлиләр»,— дип яза кан кардәшенә Йосыф кахан. Шул ук вакытттта Йосыф кахан үзе Багдад хәлифенең варис-вассалы булуы турында да искәрә: «Мин елга тамагын саклыйм һәм баскынчы викингларны түбәнгә таба уздырмыйм. Алар минем елга аша диңгезгә чыгарга телиләр. Мин аларны җибәрмим, алар белән сугышам. Мин аларны тынычлыкта калдырсам, алар Багдадның үзенә кадәр барып җитәрләр һәм бөтен мөселман дөньясын җимергән булырлар иде».

Хак, кардәше Хасдайга шулай мактанса да, ил башында утырган Йосыф каханның хәле ул хәтле ал да гөл булмый, әлбәттә.

Мәгълүм ки, бәҗәнәкләр дә (печенеглар), угызлар да төрки кавемнәре булалар. Әмма Русия тарихчылары төрки халыкларын, уннарча исемнәргә бүлеп, тарихларына кертеп җибәрәләр һәм хәтта дөньяга тараталар. Гуннарны — болгарлардан, болгарларны —хазарлардан, хазарларны төрки кавемнәре булган казакъ, үзбәк, кыргыз, татар, башкорт, төрекмән, азәрбайҗан һ. б. төрки кавемнәреннән аерып карыйлар һәм тарихларында бу кавемнәрне бер-берсенә дошман булганнар, дип язалар. Һәм Русия империя булып киткәч тә, төрки-татарларны туктаусыз бүлгәли, Борынгы Рим империясенә хас «Разделяй и властвуй» сәясәтен дәвам итә. Әнә шул бозып язуларга каршы Русиянең исемле Бартольд, Бернштам кебек галимнәре башлап җибәргән төрки кавемнәре араларында булган хәл-гамәлләргә ачыклык кертергә теләп, Русиянең танылган һәм хөрмәткә ия галиме Лев Николаевич Гумилев үз фикерен әйтә. Галим раславынча, төрки хазарларының IX–X гасырларда көч-куәтләре кими барганда, Идел буе Болгары белән угызлар кавеме көчәя баралар. Ә Киев Русе исә империя тырнагыннан иң соңгы колония булып ычкына, әмма Хазарстан, көчен вә куәтен җуя башлауга, Швед короле тырнагына барып каба.

Вәләкин Русия тарихчылары үз тарихларына Швед короле җибәргән баскынчы Хельгның Киев каласын кулына төшерү елыннан башласалар да, бу хәл хакыйкый тарихтан ерак йөри. Шул ук «Повести временных лет» елъязмасында Колдун Хельг үтергән Әскәр-Аскал-Аскольт кахан 860 елда Константинопольга яу йөри һәм патшакала капкасына калканын кадаклап кайта, елъязмачы, күзен дә йоммыйча, әнә шул тарихи вакыйганы да 907 елда баскынчы Хельг кадаклады, дип язып куя. Әнә шушындый шыр әкияти ялганга ышанып, Русиянең А.И. Краницский кебек әдипләре Вещий Олег һәм кенәз Игорьга багышлап романнар яздылар һәм ялган тарихларын әнә шул юл белән дә халыкларга барысы да булган хәлләр, дип җиткерергә тырыштылар. Романда Святослав кенәз болайрак сурәтләнә: «Святослав настоящий варяг... он по мужеству сущий воин». Тарихчылар исәбе буенча, кара уй белән кылынган бу вакыйга елъязмага 200 еллар үткәч кенә өстәлә, ягъни 1100–1113 елларда гына. Ә төзәтелә-төзәтелә, югарыда әйткәнебезчә, елъязма бары тик XVIII гасыр азакларында гына аякланып китә, анда да немец телендә. Бу хакта ачынып, Лев Николаевич Гумилев болай дип язды: «Если верить летописи, не отмечающей с 920 по 940 года ни одного события отечественной истории, то надо признать русичей трусами и обывателями, не способными ни отомстить за преданных и убитых соотечественников, ни отстоять свое добро от сборщиков дани, переправляющих награбленное в Итиль».

Югарыда әйткәнебезчә, әүвәл башта Хазарстан раввалары сугышчыларны, нигездә, Урта Азия мөселманнары гаярьләрдән туплаган булсалар, соңрак сугышчыларны бүген Рязань төбәкләрендә көн күргән угро-фин һәм славян егетләреннән яллыйлар. Мәҗүси булган бу егетләр арасында сөннәткә утыртылганнары да булган. Аларга раввалар зур ташламалар ясаганнар. Рязань каласының исем-атамасы да шуннан ил тарихына кереп китә. Әйе, бүген рус телле хатыннардан туган сөннәтсез угланнарны Исраилгә кабул итми маташкан кебек, борынгы яһүд раввалары да бу йолага гаять зур игътибар биргәннәр. Хазарстан каханаты кул астыннан угызлар белән туганлашкан (Болгар ханы угыз ханы кызына өйләнгән була) Идел буе Болгары чыга, аннары угызлар, ахыр бәҗәнәкләр. Киев Русе исә һаман каханатка ясак түләп ята. Бәхәссез, каханның кул астындагы бер халыкны да ычкындырасы килми. Һәр чордагы империягә дә хас сыйфат бу.

Шуның өчен каханат төрле тиешле-тиешсез һәм хәтта дәүләтләр өчен хас булмаган чаралар кулланырга мәҗбүр була. Ахыр чиктә викингларны илләренә чакыру әнә шул чараларның берсе буладыр. Һәм аларның күбесе безнең төбәкләрдә утырып калалар. Бик ихтимал, югарыда әйткәнемчә, без татарларның теленә «Ватан» сүзе дә викинглар аша шул чорларда кереп калгандыр, чөнки бик күпләре бер төбәккә утырып калуны талап-сугышып йөрүдән артыграк күргәннәр. «Ватан» викингларның тынычлыкка йөз тоткан аллалары була.

Тик бит бер-берсеннән ерак яшәсәләр дә, викинглар үзара хәбәрләшә торганнар, ул гынамы, Швед короле Олаф инде христиан динен кабул иткән һәм мөселманнарның дошманына әверелеп китә. Христиан монахлары вә миссионерлары Византия аша гына түгел, Швед короле аша да Киевкә агылалар, халыкны котырталар, мәҗүсилектән ваз кичәргә чакыралар.

Менә шул вакытларда бер Киевтә генә түгел, Хазарстанда да мәхшәр башлана. Халык ил-җирен ташлап китә башлый. Ялланып хезмәт иткән мөселман гаярьләре дә каханаттан китәләр. Кахан угро-фин, славян халыкларына

таянырга тели, әмма алар да Киевкә тартыла башлыйлар, чөнки әле күбесе мәҗүсиләр, ә Киев тәхетендә мәҗүсиләрне яклаучы Владимир кенәз утыра. Итильдә утырган мөселманнар, бигрәк тә татарлар, Таман ярымутравында яшәүче кардәшләре Идел буе Болгары җирләренә юнәләләр, шушы төбәкне төп ватаннары итәләр, христианнар исә Киев төбәкләренә тартылалар.

Хазарстанның төп этносы булган төрки-татарлар турында гуманист Лев Николаевич Гумилев үз хезмәтләренең берсендә болай дип язып калдыра: «Гуннарның, табгачларның, төркиләрнең дәвамлы еллар буена акыл белән яшәүләренә, гомумән, яшәү рәвешләренә тиешле бәя бирү зарур. Чит-ят җирләргә китеп, кемнәрне һәм нинди халыкларны гына буйсындырмасыннар вә яуламасыннар, кайларга гына җитеп дәүләт оештырмасыннар, беркайчан да вандаллар кебек варварлык дәрәҗәсенә төшмәгәннәр. Төрки халыклары нәкъ шул сыйфатлары аркасында гасырларга сузылган көрәштә җиңүчеләр булып калалар — беркайчан да үзләре яулаган халыкларны илләреннән кууга яисә кырып бетерүгә юл куймаганнар, киресенчә, һәр яуланган халыкларга үзләренең тарихи һәм мәдәни нигезләрен саклап калырга мөмкинлек биргәннәр — яуланган халыкларга туган җирләрен Ватан итеп күрергә комачауламаганнар. Нәкъ шул сәбәпле, Русия даласында 1500 еллар буена төрле милләт халыклары исән-имин көн күрәләр, ул гынамы, төркиләр бу сыйфатларын монголларга биреп калдыралар, хәтта XIV гасырда империя төзергә керешкән русларга биреп калдырдылар — мәңге-мәңге җиңелмәс Бөек Даланы».

Русия тарихчылары күпме генә Хазарстанны Святослав кенәз (965 елда) җимерде, дип язмасыннар, тарих шуны раслый: Хазарстан бары тик 1064 елларда гына яшәүдән туктый. Хазар каханатының яшәү дәверен җентекләп тикшергән тарихчы А.П.Новоцельцев үз хезмәтендә болай дип яза: *«В 1064 году и остатки хазар численностью 3000 семей прибыли в город Казхан (Казань) из страны Хазарии, отстроили его и поселились в нем»*.

Казан татарлары тарихына мин бу сүзләрне алтын хәрефләр белән язып куяр идем. Чөнки бу хәл чынлап та тарихта булган. Татар-хазар халкы бары тик Хазарстан дигән империянең бер шәһәренә күчеп килеп утырган. Ә бит каханатның Иделнең өске якларында Болгар, Самара, Саксин, Казан һ.б. зур базаркалалы шәһәрләре дә булган. Шулар арасында Казан шактый мөһим урынны биләгән булса кирәк, чөнки бирегә төньяк халыкларыннан — борынгы Бөек Пермь якларыннан затлы тиреләр йөзендә байлык аккан. Ахыр килеп, тарихчы бик белеп «построили» дими, ә «отстроили» ди. Димәк, бу кала инде зур сәүдә каласына әверелеп киткән булган, Аурупа илләре белән сәүдә иткән Казан Кремле йортында табылган чех тәңкәсе дә моны раслый.

Әйе, бәхәссез, бу төбәкләргә иң әүвәл Хазарстандагы Биләмҗир каласында көн күргән халыклар күчеп киләләр һәм Казан каласын чын мәгънәсендә урта гасырның чәчәк аткан шәһәре итәләр. Ни гаҗәп, бу каланы хәтта баскынчы монголлар да җимермиләр. Бу хакта хазарлар тарихын тикшергән күренекле Русия галимәсе С.Плетнева болай дип язды: «Население Хазарского каганата продолжало жить вместе с новыми завоевателями (татаро-монголами). Вероятно, именно из-за смешанности населения здесь, на Волге, кипчаки не ставили святилищ с каменными статуями: обычай «заглох» в чужой этнической среде».

Шуның өчен мәркәзебез Казанның монголлар чорында ук Алтын Урданың иң хозур калаларыннан булып үсеп китүенә һәм киләсе 2005 елда меңьеллык олуг бәйрәмен уздырырга җыенуына бер дә гаҗәпләнәсе түгел, ә бары тик: « Без татарлар бик борынгы заманнардан калаларда яшәгәнбез, яшибез, яшәячәкбез!» — дип, дөнья халыкларына мәркәзебезне күрсәтеп, тантана итәсе генә кала.

*Искәрмә:* Эдуард Паркерның «Тысяча лет из истории татар» хезмәтен совет чорында илдән куылган татар галиме якташыбыз Вил Мирзаянов инглизчәдән русчага тәрҗемә итте. Бу хезмәт 2003 елда Казанда нәшер ителде. Моның өстенә Тувада археологик казылмалар алып барган Эрмитажның фән хезмәткәре Константин Чугунов «Известия» газетасында болай дип язып чыкты: «Нынешние раскопки в Туве, где были обнаружены памятники рубежа VIII–VII веков до нашей эры, неожиданно подтвердили верность предположений Геродота. Идентификация племен скифского типа происходит по наличию компонентов так называемой «скифской триады»: оружие, конская упряжь и, конечно, предметы искусства звериного стиля. Находки в так называемой «Долине царей», объединяющей несколько курганов, датируются рубежом VII–VIII веков нашей эры, то есть временем, когда скифов в Причерноморье опять-таки не было... Находкам в Кургане-2 нет аналогий в археологии. Все образцы компонентов скифской триады настолько высокоразвиты, что изначально мы даже не могли представить себе, что они созданы раньше, чем в VI веке до нашей эры. Тщательный анализ и царских захоронений, и могильников, не принадлежавших представителям скифской знати, показал: они созданы позже VII века до нашей эры. Это переворачивает представления об азиатской кочевой культуре: о происхождении и развитии скифского искусства, превосходящего по уровню развития даже современное ему искусство архаичной Греции, можно говорить совсем в ином ключе. Древность находок говорит о том, что скифские племена пришли в Причерноморье из Центральной Азии».

Эдуард Паркер исә үзенең «Мең елларга төшеп татар тарихы» хезмәтендә бу хакта болай ди: «Тыйнак рәвештә һәм сабырлыкка йөз тотып язылган бу китап, Хун-чжоу каласында (Көньяк Хайнан утравы) шәһәр түрәсе ярдәме белән, 1893–1894 елларда Кытай тарихының борынгы чыганакларына таянып язылды. Шуннан соң мин 1894 елда Кытайдан бөтенләйгә китәргә җыендым. Шанхай каласының баш хөкемдары мистер Джордж Джеймсон бик теләп минем тәүге язмаларымны карап, төзәтеп чыкты һәм китапны бастырганда да күз угында тотты. Шул

вакытта Урга тирәсендә археологик казылмалар алып барган руслар өч телдә язылган язмалы таш һәйкәл таптылар. Һәм алар Кытай һәм Сирия язмаларын укыганнан соң, ташка уелган язманың өченчесе төрки телдә булуын ачыкладылар. Копенгаген профессоры В.Томсен бу язманы укыганнан соң (белгеч Розетта Стоун ысулы белән), бу ачышны тәмам раслады. Петербургта яшәгән В. Радлов исә ары таба таштагы бөтен булган төрки язманы тикшергәннән соң, язманың моннан 1200 еллар элек язылуын раслады. Мин исә «China, Review,vol. XX» бик озак еллар буена раcладым — хуннар, скифлар, гуннар һәм төркиләр тарих үсешендәге төрле баскычларда да бер үк кавем вә халык, ахыр, минем бу хезмәтемнең хаклыгын раслап, әйткән кавемнәрнең төрки халыклары булуын Шавань, Хирт кебек галимнәр дә тәфсилләп тикшерделәр һәм мин күтәргән четерекле проблемага өстәмә төстә ачыклык керттеләр».

Бары тик шул, кадерле укучым. Русия тарихчыларының кайбер шовинист галимнәре язганча, без татарлар бүген гомер иткән җиребездә бер дә килмешәкләр түгел, ә бик борынгы төрки-татар кавемнәреннән. Һәм без мең еллар элек көн күргән бабаларыбыз җирендә бүген дә көн күрәбез. Бүген кемнәр килмешәк булуын Идел буйларына күчеп утырган күп кенә урыс авыллары да раслый. Күп кенә авыл утырган күрше-шабраларыбыз авылларында алар күтәргән таш чиркәүләр генә моңаеп утыралар инде, ә килгән халыклар күптән инде йә үз якларына, йә шәһәрләргә күчеп киткәннәр булса кирәк. Ә татар, мари, чуваш, удмурт халыкларының авыллары, әле булса меңнәрчә еллар кебек, үз туфракларында утыра бирәләр, шул исәптән кала-салалары да. Әйе, хакыйкать һәр чорда да хакыйкать булып калачак, ул гүя адәм кулы белән чәчкән орлык, бер шытып чыкмаса, бер шытып чыга икән — моны бүген дөнья күргән Эдуард Паркерның татарлар турындагы саллы хезмәте дә раслый.

*Автордан:* Эдуард Паркерның «Мең елларга төшеп татар тарихы» хезмәтен инглизчәдән русчага безнең якташыбыз — совет чорында бер гаепсезгә диярлек (чамадан тыш күп күләмдә химик кораллар ясаган СССР империясенең дәүләт серен ачкан өчен) шул өлкәдә эшләгән галим-химик Вил Мирзаянов тәрҗемә итә. Бу милләтпәрвәр якташыбызның инглизчәдән тәрҗемә иткән икенче китабы, беренче китабы — Америкада яшәп вафат булган Борис Ишбулдинның «Татарлар тарихы» хезмәтен инглиз теленнән мин бахырыгыз белән татарчага тәрҗемә иткән идек. Татарларга багышланган икенче китабы хакында, русча чыккан хезмәтенә гадел бәһа биреп, китапның җаваплы редакторы тарих фәннәре докторы Равил Фәхретдинев кереш сүзендә болай дигән: «Данная книга, впервые изданная автором (Э.Паркером) в 1895 году в Китае, затем в 1924 году в Нью-Йорке, является первым изданием на русском языке, не считая небольшого доклада Д.Струнина на заседании Туркестанского кружка любителей археологии в 1897 году. Автор, основываясь на оригинальных китайских источниках, изложил главнейшие моменты из жизни татарских племен, населявших некогда северные пределы Китая. Ему удалось разобраться в запутанной истории татар до времени Чингиз хана, отметить ряд свойственных им типических черт и осветить несколько выдающихся образов из числа татарских завоевателей.

Книга переведена и пополнена многими научными комментариями известным российским ученым-химиком Вилем Мирзаяновым, ныне гражданином США, который не только перевел книгу, но и частично финансировал ее издание».

Без капчыкта ятмый икән шул, туганнар!

*Автор*

Литературно-художественное издание

*Хабибуллин Мусагит Мударрисович*

**Айбиби**

Исторический роман

(на татарском языке)

Мөхәррире *Ф.М.Хафизов*
Рәссамы *Ф.З.Зөлкарнәева*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучы *С.Н.Нуриева*
Корректорлары *Л.Ш.Шәфыйкова, Л.З.Шиһапова, Г.Г.Гарифуллина*

Нәшриятка 04184 нче номерлы лицензия 2001 елның 6 мартында бирелгән.

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 1.10.2004. Форматы 84x108 $^{1}/_{32}$.
Офсет кәгазе. Офсет басма. Шартлы басма табагы 15,96 + форз. 0,21.
Шартлы буяу-оттиск 16,59. Нәшер-хисап табагы 17,89 + форз. 0,36. Тиражы 3000 д. Заказ Э-645.

Татарстан китап нәшрияты. 420111. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420111. Казань, ул. Баумана, 19.

**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Идел-Пресс» нәшрият-полиграфия комплексы дәүләт унитар предприятиесе. 420066. Казан, Декабристлар ур., 2.